# Аяз Гилязов

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

в пяти томах

3 том

*Пьесы*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Аяз Гыйләҗев

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

биш томда

3 том

*Пьесалар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-6
Г92

РЕДКОЛЛЕГИЯ:

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, М.Б.Галиев, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

Төзүчесе *Нәкыя Гыйләҗева*

**Гыйләҗев Аяз**

Г92 Сайланма әсәрләр. 5 томда. 3 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 447 б.

ISBN 5–298–01211–6 © Татарстан китап нәшрияты, 2002



# *Кичке әңгәмәләр*

*Драма 3 пәрдәдә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Рәхилә.
Нургаян.
Зөлфәт.
Халидә.
Яфир.
Рахмай.
Фәрди.
Мәсәй.
Әнвәрия.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Җәй башы. Ишегалды. Өйнең ишек-тәрәзәләре ачык. Янбакчада ике кешелек кенә чәй урыны әзерләнгән, ризыклар кызыл ашъяулык белән пөхтәләп бөркәлгән. Өстәл янында Нургаян утыра, урам ягыннан Әнвәрия керә.

Әнвәрия. Һаман ялгыз син, бер башың, ә?

Нургаян. Ялгыз...

Әнвәрия. Безгә кереп утырыр идең, ичмасам!

Нургаян. Син ялгыз түгелме?

Әнвәрия. Синең күк кагаеп утырмыйм инде! Биләменә чыгып керәм — юк йомышны бар итеп чыгып китәм дә йөрим шунда өй борынча. Киленең кайтмадымы?

Нургаян. Иртәрәк әле.

Әнвәрия. Һаман «килен» дип йөрткән буласыңмы үзен?

Нургаян. Килен димичә, кем дип әйтим?

Әнвәрия. Нинди киленлеге калган инде аның? Малаең үлгән, гүр иясе булган, бала-чагасы калмаган.

Нургаян. Барыбер киленем. Үлгәнче үземнеке.

Әнвәрия. Фатирчы диген! Курыкма, кешегә чыгар-

мам. Әлләниләр белеп торсам да, берәүгә авыз ачканым юк.

Нургаян. «Чыбыксыз телефон» дип бикәргә атыйлар алайса үзеңне, Әнвәрия.

Әнвәрия. Бер кушаматсыз да читен инде, күрше, кешенең төсе юк сыман.

Нургаян. Йомышыңны әйт, килен кайтуга вак-төяк бетерәсе эшләрем бар.

Әнвәрия. Оныттым, әй нәләт... Хәзер, Нургаян, хәзер. Өйгә генә кереп чыгыйм. Уйны кайда ниятләсәң, шунда хәтергә төшә. (*Чыгарга бара.*) Ә-ә, ни дигән идем, хәерсез хәтер! Диван янына эләргә келәмем юк. Кеше-кара килеп чыкса, бик күңелсез.

Нургаян. Ишегалды сукмагыңа тездән үлән үскән...

Әнвәрия. Районга бик шәп келәмнәр кайткан, имеш.

Нургаян. Чыбыксыз телефоннан әйттеләрме?

Әнвәрия. Синең килен дигәнең бу араларда районга бармыйдыр?

Нургаян. Ишетелми.

Әнвәрия. Бара-нитә калса оныта, җәме. Акча биреп җибәрермен, үз акчасына алса, түләрмен. Кемгә барып кермә, түрендә келәм. Мин яшәгән булам буш диварлар арасында.

Нургаян. Минем килен киңәшмәгә барганчы келәм тора диме? Аны хәзер йолкып алып бетерәләр.

Әнвәрия. Соң аны кем кибеткә чыгарсын? Йә итәк астыннан бирәләр, йә, киңәшмә җыеп, алдынгыларга саталар. Синең килененң алдынгы. Шулай, дөнья тигез яратылмаган, нишлисең, берәүләр тол калса да, кайнана карап ята, берәүләре исә еллар буе анасы бусагасына аяк басмый.

Нургаян. Чәч тараганда көзгегә кара.

Әнвәрия (*чәчрәп*). Киезләнгәнме?

Нургаян. Гаепләне күрерсең! Телеңә чыдый алмагач, малайларың киленнәреңне берәм-берәм алып качты.

Әнвәрия. Әллә тагын, телем бик яман диләр шул.

Нургаян. Ярар. Барса әйтермен.

Әнвәрия. Үзем дә мең керермен әле, тик онытылып китмәсен дим... Әй, Нургаян, бу ыштыр бит Зөлфәт киленең өйдә юкта да сезгә кереп йөримени?

Нургаян. Анысы сиңа нигә тагын?

Әнвәрия. Матаен туп-туры сезгә чаптыра бит. Хи-хи-хи, күпергә кергәч, матае сүнде.

Нургаян. Әнвәрия!

Әнвәрия. Шулай ямьсез итеп карамачы.

Нургаян. Чыбыксыз нәмәрсәң көне-төне ни былдамас, инде сине мин генә төзәтә алмам, мәгәр, бел: киленемне телеңә кертәсе булма. Ишетсен колагың! Анда эшең булмасын. Үзенчә тереклек кылсын. Мәрхүм Миңлегәрәем белән Зөлфәт дуслар иде. Элек тә килеп йөрде, хәзер дә кергәли. Үлесенә дә, терeләргә дә тел тидермә.

Әнвәрия. Һай Аллам, бөтен авылның телен тыя алмассың. Күпер төбендә киленең белән бригадирның үбешеп торганын күргәннәр.

Нургаян. Кайсыгызның аны гаепләргә теле бара? Аның күңелендә ни барын бу дөньяда кайсыгыз белә?

Әнвәрия. Ә-ә, мин әйтмәсәм дә беләсең икән! Юхаланма! Дулгый-дулгый күпердән тотып чөясе нәрсәне килен дип йөрисең.

Нургаян. Үз киленнәреңне дулгарсың.

Әнвәрия. Минекеләргә ни булган?

Нургаян. Минем киленгә ни булган?

Әнвәрия. Колагына корт кунган. Кәбестә яфрагы төсле ала-колага әйләнгән. Әнә шытыр-пытыр сөяркәсе килеп җитте. Хатынлы ирне供 аздырып, илдән бәрәкәт качырып кем йөри? Минем киленнәрме?..

Чыга. Мотоцикл тавышы. Зөлфәт керә.

Зөлфәт. Син нәрсәкәй монда, Нургаян түти, камыл сыйрагың белән тәртәгә тибеп маташасың?

Нургаян (*сабыр гына*). Әйбәт әлегә.

Зөлфәт. Нәрсә, нәрсә?

Нургаян. Сәлам бирдең ич. Шуңа җавабым.

Зөлфәт. Әй, куйчы! Ни нужалар чигеп осталар чакырдык... Хәзер табып кара син аларны! Бөтен авылларда төзиләр.

Нургаян. Көне-төне тире тунаучы шабашкы этләре диген. Осталар, имеш.

Зөлфәт. Анысы синең маза түгел, белдеңме?

Нургаян. Белмәгән кая, мин шушы колхозда утыз биш ел бозау карамаган шул. Моннан ун ел элек тә шабашкы этләренең каз боты кимереп, аракы чөмереп ятканнарын күрмәгән.

Зөлфәт. Хезмәтеңә күрә хөрмәтен аласың. Колхоз бөтәйткән өйдә торасың. Пенсияң чыга.

Нургаян. Син бирәсеңме әллә аны? Алырсың синнән ярага ябарга бер уч яфрак! Нәселегез белән карун идегез,

үпкәләштән булмасын, эткәң гөрс-мәрс башы белән кибеттә сөрсеп ятты.

З ө л ф ә т. Туктачы, әрепләшергә килмәдем. Мин бригадирыгыз. Минем сүзем закон.

Н у р г а я н. Фатирга җибәргән осталарыңны кире борганга читенсенеп утыра идем, рәхмәт, җанымны ашап тынычландырдың.

З ө л ф ә т. Кертмәм дип беләсеңме?

Н у р г а я н. Гомерләрен кеше бусагасында уздырган җыен әтрәк-әләмнең шакшысын юып ятырга мине әллә лашманчы карчыгы дип белдеңме?

З ө л ф ә т. Нинди әтрәк-әләм? Нинди шакшы? Колхоздан качып шабашкыга йөрүләр бетте, синдәй-миндәй хезмәт ияләре. Кая, салкын су чыгар әле. (*Нургаян су бирә.*) Фермаларга яңа тораклар салабыз. Иң әүвәл бозауларга комплекс, аннан сыерларга. Терлекчеләргә яңа өй планлаштырдык.

Н у р г а я н. Салсыннар гына, тик осталарны кертмим. Бер-бер этлегең, хөсетең бар синең, Зөлфәт!

З ө л ф ә т. Киленең риза. Идарәдә шулай килешендек. Осталардан уңайсыз, Нургаян түти. Ялварып диярлек чакырып китердек, ә син пыр туздырып куып чыгарасың. Ярамый алай.

Н у р г а я н. Йортка әлегә мин хуҗа. Килен... Минем килен августтагы тургай ул! Бүген монда, иртәгә тот син аның койрыгын.

З ө л ф ә т (*әрсез елмаеп*). Китмәс...

Н у р г а я н. Ә син каян беләсең?.. Мин теге... Киленемнең яманатын чыгарырга йөрмисеңме? Нигә шул юлбасарларга эш бирәсез? Басты әрмән, авыл саен шулар... Инде безнең авылны биләгәннәр.

З ө л ф ә т. Министр итеп сине куясы калган! Сал әле чүмеч тутырып суыңны!.. (*Эчә.*) Баш үзеңдә. Өченче ел солдатка киткән унөч егеттән ничәсе кайтты? Икәү! Аларының да күзе басу капкасында. Былтыргылардан берсе кайтса дип өметләнәбез. Быел алтыны озатабыз. КамАЗга алты төтен җибәрдек. Кирәк, бик кирәк, ил сорый, аңлыйбыз. Ә үзебезгә кем кала? Син булып син кәҗәләнеп маташасың. Халыкка ярау авыр. Фермаларда яңа тәртип кертеп, эшне машиналарга тапшырмасаң, илгә сөтне-майны кем бирер?

Н у р г а я н. Сәнәк-көрәк тотып, тездән сазда билсез калсалар да сүз дәшмәгән Нургаяннар заманасы узды диген.

З ө л ф ә т. Аның каравы хәзер телең ачылды! Осталарны куып чыгарган. Вәт җүләр!

Н у р г а я н. Ярар. Керсеннәр. Сүзеңнән куркып кертмим, бел, яңа фермалар дигәч кенә күңелем йомшады. Утыз биш ел суык җилдә абзар тазартуларым әле дә төшемә керә.

З ө л ф ә т. Шулай диген.

Н у р г а я н. Гомергә фатирга керткәнем булмады, анысын да татып карыйк. Тик тел төбеңне аңлап бетермим... Усал ниятең юк микән синең?

З ө л ф ә т. Нинди ният? Өең чиста, иркен. Шул гына.

Н у р г а я н. Юхаланма! Ярар. Заманында улымның әшнәсе идең. Башкалар рәтеннән КамАЗга китәргә ниятләгәндә син аны тотып калдың... Шикләндем шул чакта. Сүзеңне улыма атадың, күзең киленемдә иде... Шома кеше бит син, Зөлфәт. Этли балыгы шикелле, ревизия учыннан да шуып кына чыгасың. Талаша-талаша йөрүеңнең мәгънәсе бар, сизәм... Әнә, Әнвәриянең өе терәлеп кенә тора, нигә аның ишеген какмыйсың? Дүртәүме әле алар?.. Дүрт ир...

З ө л ф ә т. Кәҗәләрне кәбестә бакчасына җибәр дисеңме?

Н у р г а я н. Җырма авызыңны, Шаһбаз иркәсе. Черек тешең күренә. Бәләкәй чагында әткәңнең итәгенә уралып гел кибеттә идең. Ничә карама лач-лоч кәнфит суырасың.

З ө л ф ә т. Рәхмәт әтигә. Яшәп карадык.

Н у р г а я н. Колагың ишетсен: бу эшне хөсетлек белән уйлап, миңа, миннән бигрәк киленгә сүз ишеттерерлек булсаң, каргап каргадан күзеңне чукытырмын.

З ө л ф ә т. Каргыштан курыкмыйм мин, Нургаян түти.

Н у р г а я н. Башкача сине каптырырмын димә.

З ө л ф ә т. Сүз тыңлаучы кешеләр белән яшәве рәхәт.

Чыга. Нургаян, табынны тагын бер кат күздән кичереп, өйдән чынаяклар алып чыга. Посып диярлек Х а л и д ә керә. Нургаян, борылмыйча гына, аңа эндәшә.

Н у р г а я н. Халидә, бу синдер?

Х а л и д ә. Артыңда да күзең бардыр синең, кояштыр.

Н у р г а я н. Аяк тавышыңнан таныдым.

Х а л и д ә. Китсәнә, адәм ышанмасны! Әүлияме син, күрәзәме? Ат шикелле абына-сөртенә йөрүемне әйтсәң генә инде.

Н у р г а я н. Яман күз тимәсен, хәйран матур йөрисең.

Башыңны да түбән имәсәң. Имә башыңны, кол түгел лә син!

Халидә. Китсәнә, үшән ат сыман, чатан-ботан йөрим шунда. Гел абынам мин. Бәләкәй чагымда көянтә-чиләгем белән ничә тапкыр бәке янында тәкмәрләдем. Кайсы кешегә карыйсың, киленең Рәхиләне генә примиргә алыйк, булыр да икән кеше, иңендә мөлдерәмә тулы үтерәм чиләкләр булыр, ә йөреше аккош йөзгән күк... Кая инде миңа! Ятим үстем, үги әнкәй коры иде, биш яшьтән өй арасындагы иң авыр эшне миңа өйде.

Нургаян. Киленемне дә аяк тавышыннан таныйм, Аллага шөкер.

Халидә. Ир-ат дигәнең Рәхилә узганда борылып карамыйча үткәрми инде.

Нургаян. Кулыннан эш килмәгәннәре күз белән ашарга ярата!

Халидә. Акырам да бакырам, өеңдә кеше юктыр ла?

Нургаян. Булса ни?

Халидә. Китсәнә, шуны да искәртмәгән. Оят бит.

Нургаян. Кеше хакын гына хаклап яшәмә шултиклем. Адәм баласы үз рәхәте барын да белеп яшәсен.

Халидә. Үзем өчен дә яшим. Бик рәхәт яшим.

Нургаян. Килен белән яшьтәшме әле син?

Халидә. Ул гыйнварда туган, мин ел ахырында.

Нургаян. Менә бит... Ир белән торасың, сулып-саргаеп барыр көнеңме синең?

Халидә. Туганда ук ямьсез булганмын шул! Үги әнкәй «албасты» дип сүгә иде.

Нургаян. Матурлыгың белән көяз әфисәрне, булганлыгың белән вакчыл булгахтерны да һуштан яздырыр асыл бала идең дә бит, бәһаңны белерлек кешегә тап булмадың.

Халидә. Китсәнә, Нургаян ти, без бик ару торабыз.

Нургаян. Ярар. Үзеңә ничектер, синең тормышка карап, миңа бик читен. Ярасын. Нигә килдең?

Халидә. Килгән осталарны фатирга кертмәгәнсең икән.

Нургаян. Каян ишеттең?

Халидә. Бая кибеткә кагылган идем. Әнвәрия ти...

Нургаян. Аңлашылды.

Халидә. Ничек йөрәгең җитте? Авылда хәзер Зөлфәткә каршы төшәр кеше юк. Бәгыреңә кадалып интектерер, Нургаян ти.

Нургаян. Яле, көн яктысында бер карыймчы үзеңне! Кем син? Үлеме син, тереме син?

Х а л и д ә. Нигә болай каты әйтәсең?

Н у р г а я н. Утыр. Аяк өсте басып торып сөйләшү читен. Буыннар... (*Утырышалар.*) Йөрәк тамырыңа кагылсам, кичерерсең. Киленем җаныма бик якын булса да, ни кылыйм? Ахыр чиктә, үз каным, җан яңартып тапкан балам түгел. Дөрес, язык булмасын, улым белән тигез генә яшәсәләр, Рәхилә хак юлдан тайпылыр бала түгел иде. Юк. Иманым шаһит, бергә чакта, яхшымы-яманмы, бер тамырда иделәр. Шунысына бәхил, артыгы белән бәхил. Хәзер без кемнәр? Төптәнрәк уйлап карасаң, өйдәшләр генә ләбаса. Рәнҗесә дә түзәрмен. Түзәргә өйрәнгән инде. Сугыш ике баламны, иремне алды. Бирсен бер кайтармады. Миңлегәрәй төпчегем вакытсыз дөнья куйды. Ярар. Без чыдадык. Чыдамый нишлисең? Менә син ничек түзәсең дим мин? Яшь, сылу хатын, эшкә дисәң, ут уйнатасың. Зөлфәтең Рәхилә артыннан нык кына чирттерә бит.

Х а л и д ә. Беләм.

Н у р г а я н. Белгәч, ник сөрән салмыйсың? Ник абындырмыйсың үзләрен?

Х а л и д ә. Чирттерсә соң?

Н у р г а я н. Чү, чү. Ни диден син? Ни әйтеп ычкындырдың? Сүзеңнең ашын абайладыңмы, җүләр баш? Ничек җир йотмады сине? Әстәгыфирулла тәүбә! Ничек ходайдан курыкмыйсың да, ничек миннән оялмыйсың?

Х а л и д ә. Нишли алам инде мин?

Н у р г а я н. Аяк астына салып таптасалар, кеше нишли ала? Монысын кешедән сорамыйлар, Халидә, йөрәгең ни куша?

Х а л и д ә. Әллә нинди чит-ят марҗа артыннан йөрми әле. Рәхилә...

Н у р г а я н. Уф, йөрәгем...

Х а л и д ә. Ул минем ахирәтем. Унынчыдан фермага бергә килдек. Алты елыбызны бергә эшлибез.

Н у р г а я н. Сөйләмә, зинһар, туктал.

Х а л и д ә. Зөлфәтнең күзе үткен. Күрә. Рәхилә чибәр. Рәхилә уңган. Тәмле телле, йөзе ягымлы. Районга җыелышларга кем бара? Рәхилә. Төсле журналда кемнең рәсеме басылды? Аныкы. Өч йөз дә егерме җиде егеттән хат алдымы? Алды. Карточкалары гына ике альбом. Фермага делегация килә башласа, кемне алга чыгарабыз? Аны! Ал яулыгын чөеп бәйләп шифырт-мифырт кына бер узсамы, ревизорлар сукырая, корреспондентларның күзе шакмак була. Начальствога уха пешереп, сый-хөрмәт куйганда табын янында кем? Француз туристларын кем һуш-

тан яздырды? Кырык тәңкәлек хушбуй биреп киттеләр... Менә. Кем белән ярышырга боерасың син миңа? Фермада ярышабыз, хак. Узып киткән чакларым да була. Тик мәхәббәттә?.. Үз чамамны беләм. Үги әнкәй...

Нургаян. Ташла Зөлфәтеңне ул чагында! Аерыл. Тап үз ишеңне.

Халидә. Яратам.

Нургаян. Ярату тигез булганда гына җанга дәва ул. Тигезлек юк икән — коллык.

Халидә. Үзем җебегән салма булгангамы, кыю, тәвәккәл ирләрне яратам шул.

Нургаян. Әле Зөлфәтеңә осталарны кертермен кебек сөйләшкән идем, ачуымны китердең, йөрмәсеннәр? Зөлфәт сүзе генә сүз булмасын!

Халидә. Болай усал түгел идең ич син, Нургаян ти.

Нургаян. Фатир итеп нигә безне сайлаганын аңлыйсыңмы, тинтәк баш?

Халидә. Якын иткәнгәдер.

Нургаян. Килеп, иснәнеп йөрергә җайлырак булсын ди ул!

Халидә. Булсын. Йөрсен. Монда ичмасам әйбәт, сылу хатын. Барыбер кемне дә булса эзләп табачак!.. Мин бит...

Нургаян. Бар. Кайт. Шәүлә белән сөйләшә алмыйм. Чүпрәк. Кайт та көзәнеңә әйт: кертмим шабашкыларын!

Әнвәрия керә.

Әнвәрия. Берсе туа, берсе туа! Беренчесе!

Нургаян. Беренчесе актыккысы булыр. Бар, Халидә, башымны авырттырдың. Әнвәрия, шом салып йөрмә.

Халидә белән Әнвәрия чыгалар. Кулына җыйнак кына чемодан тотып, Мәсәй керә.

Мәсәй. Хәерле кич, абыстай.

Нургаян. Мулла затыннанмы әллә син?

Мәсәй. Түгел, абыстай, атам да, бабам да үзем сыңары — балта осталары. Көндез ныгытып белешеп тә өлгермәдек, минем атым Мәсәй булыр.

Нургаян. Нигә Песәй түгел? Шундый котсыз исем дә бар икән.

Мәсәй (*матур гына көлеп*). Кәгазьдә теркәлгәне Мәсәбих. Иптәшләр тел җаена Мәсәй диләр.

Нургаян. Караклар, бурлар гына ата-ана кушкан исемнәрен бозалар, имеш... Башка шабашкыларың кайда, кибет төбендә яланаламы?

Мәсәй. Хәзер киләләр, абыстай.

Нургаян. Син нигә дип ашыктың?

Мәсәй. Алдан килгән урын өчен. Йокым начаррак минем. Иптәшләр интекмәсен дим. Көндез үк бер җайлы урын чамалап куйган идем.

Нургаян. Кертмәскә булдым инде. Башка фатир табыгыз.

Мәсәй. Нигә кертмәскә итәсез инде? Бригадирга «килсеннәр» дип әйтеп җибәргәнсез.

Нургаян. Читтән килеп мондагы хәлләргә тыгылып йөрер идеңме әллә, адәм тәганәсе?

Мәсәй. Кирәк икән, нигә тыгылмаска? Чит түгел инде, кәгазе язылган, имзалар куелган. Бүгеннән сезнеке булдык.

Нургаян. Балта эшенә генә түгел, башка кайбер нәрсәләргә дә маһир сымак әле син, телең бик чарланган!

Мәсәй. Байтактан дөньяда яшибез, абыстай. Күпне күрде баш. Йөргән саен акыл арта димим, мәгәр тәҗрибә өстәлә тора. Шулайдыр бит? Сез минем мәрхүмә әнкәмә бик охшагансыз.

Нургаян. Аналар бер-берсенә охшыйлар алар...

Мәсәй. Киленегез кайтмадымы?

Нургаян. Нинди килен? Анысы тагын нигә кирәк сиңа? Син аңа кагылма!

Мәсәй. Күңелегезгә авыр алдыгыз. Улыгыз вафат булган икән. Бригадир сөйләп торды...

Нургаян. Икәү генә калдык...

Мәсәй. Чир аямый шул.

Нургаян. Чир белән китсә икән кана! Үкенечле үлем белән китте Миңлегәрәй. Тракторчы иде. Мичкәдә бензин калмаганмы дип, мичкә авызына иелеп шырпы сызып караган. Тәкъдире шулай язылгандыр инде. «Миңлегәрәй телеграмма баганасы тиклем күккә күтәрелде»,— дип, иптәшләре кайтып сөйләде. Гәүдәсе күктән төшкән, җаны гына шунда калган баламның...

Мәсәй. Их, башсыз! Инде давайлап кусагыз да чыкмыйм, кардәш икәнсез сез миңа.

Нургаян. Тиз туганлашасың үзең тагын.

Мәсәй. Юк, абыстай, нәзберек, кире кеше мин. Теләсә кем белән табын тирәсенә дә утырмыйм.

Нургаян. Нинди абыстай булыйм ди мин?

Мәсәй. Безнең якларда өлкән татар апаларына шулай дип хөрмәтләп эндәшәләр.

Нургаян. Кайсы якныкы соң син, кардәш?

М ә с ә й. Зәй буенда туганмын. Бәләкәй чакта әтиләр мине Урта Азиягә алып киткәннәр.

Н у р г а я н. Ару кеше баласы дисең, нишләп җүләрләнеп шабашкыда йөрисең? Кеше бусагасын таптыйсың. Тапканың эчәргә җитәме соң?

М ә с ә й. Эчмим. Анысы юк. Йөрү җәһәтенә килгәндә, йөрим инде. Җанга тынычлык тапмаганга йөримдер. Абыстай, мин шушы сарай түбәсендә йокလармын, яме.

Н у р г а я н. Төнлә-төнлә яшь киленчәкләр янына йөрермен дисеңме? Хәйләкәр икәнсең. «Әкерен-әкерен китерәдер көйгә бу!»

М ә с ә й. Булмады, абыстай. Фатирга сезгә төшмим.

Н у р г а я н. Чү, чү.

М ә с ә й. Җанны талыйсыз. Аракы, шабашкы дигәндә рәнҗемәдем. Төрле кеше бар. Тик хатын-кыз дия башлагач...

Н у р г а я н. Алай рәнҗеп китмә. Риза-бәхиллегем юк. Кал. Минем дә җайсызрак, җан кыйналган көннәрем...

М ә с ә й. Төзәлмәс җәрәхәтемә кагылдыгыз.

Н у р г а я н. Сарай түбәсе синеке булыр.

М ә с ә й. Рәхмәт, алайса. (*Сарай түбәсенә үрелеп.*) Монда кемнеңдер урын-җире бар.

Н у р г а я н. Аларын иpләп кенә монда төшереп куй.

Кереп китә. Мәсәй урын-җирләрне төшереп маташканда, Р ә х и л ә кайтып керә.

Р ә х и л ә. Ни актарынасың анда? Сиңа әйтәм, сиңа.

М ә с ә й. Күрмисеңмени, урын җәям.

Р ә х и л ә. Без килен төшердекмени? Шулаймы?

М ә с ә й. Гафу итегез... Бу сезнең урын булгандыр инде?

Р ә х и л ә. Итмим. Мин берәүне дә гафу итмим. Аңлашылдымы?

М ә с ә й. Шылмады.

Өйдән Н у р г а я н чыга.

Н у р г а я н (*Мәсәйгә одеял тоттырып*). Өстеңә шуны ябынырсың. Төннәрен суыта.

Р ә х и л ә. Карак кергән дип торам.

Н у р г а я н. Кайткансың икән, килен. Озакладың.

М ә с ә й. Каракка охшаганмы мин?

Р ә х и л ә. Кешеләрдән качасың бит.

М ә с ә й. Яман гырлап куям кайчакта. Кычкырам да...

Р ә х и л ә. Рәхәтләндерәсең бар икән әле. Фу! Бир ми-

нем мендәремне. Тотынма, кагылма. Бир! (*Нургаянга.*) Әни, килмәсеннәр дип Халидәгә ныгытып әйтеп җибәргәнсең, юлда очратып мин бу алабайның юлдашларын борып кайтардым.

Мәсәй. Хәзер җыеп алып киләм мин аларны. (*Чыга.*)

Рәхилә. Тинтерәттең осталарны, әни. Бер-бер шигең бармы?

Нургаян. Синдә шик юкмы?

Рәхилә. Ашамаслар әле. Аз-маз сиңа юаныч булмасмы дим... Көне буе бер башың. Без җәйләүгә чыккач, төннәрен дә бер үзең булырсың.

Нургаян. Ялгыз калдырасың килмәсә, чыкма җәйләүгә.

Рәхилә. Кушсаң, чыкмам да.

Нургаян. Куша алмыйм. Үзеңчә яшә, килен.

Рәхилә. Артык узындырма мине, әни. Әллә ни эшләп ташлармын. Ачулан аз булса да, сүк, хаталарымны күрсәт.

Нургаян. Ачулана да алмыйм.

Рәхилә. Ныграк тот син мине, әни.

Нургаян. Егыла башласаң, тотармын да. Әлегә бик канәгатьмен, килен.

Рәхилә. Без икәү бик әйбәт яшәдек, әни. Рәхмәттән башка һичбер сүзем юк.

Нургаян. Хак Тәгалә тагын ни язгандыр... Килен, осталар кергәч, йокларга минем янга чоланга керерсең. Анда да йокы бик тәмле. Черки дә бимазаламас.

Өйгә кереп китә, Рәхилә ялгызы. Зөлфәт керә.

Зөлфәт. Әллә барысы да түнгәннәр инде. Тып-тын.

Рәхилә. Синең дә тынлыктан туяр көнең бар икән.

Зөлфәт. Кайда тегеләр?

Рәхилә. Йөгереп кенә эзләп алып кайтыйммы?

Зөлфәт. Үртәшмә.

Рәхилә. Нигә килдең инде? Осталарны эзләгән булып кыланма.

Зөлфәт. Таба майларга исәп.

Рәхилә. Синең таба маең да, тормыш җаең да бер — аракы.

Зөлфәт. Ул этләр шуңа ияләнгән. Аракы куймасаң, сөйләшеп тә тормый алар, юк! Ул сабакыларга шул гына кирәк тә.

Рәхилә. Юньсез икәнлекләрен белә торып безгә кертәсеңме шуларны?

З ө л ф ә т. Сездә торулары яхшырак... Тылда да үз кешеләр булсын. Күз-колак булырсың.

Р ә х и л ә. Синеңчә барып чыкмасын иде бу юлы! Ичмасам, бер генә тапкыр син теләгән эш барып чыкмасын иде. Аракыңны эчмәсеннәр иде, сиңа сатылмасыннар иде. Рәхәтләнеп көләр идем!

З ө л ф ә т. Аракы терекөмеш кебек ул, әллә нинди буаларны да ера.

Р ә х и л ә. Расланмасын иде бу юлы сүзең! Теләгең кабул булмасын иде.

З ө л ф ә т. Минем сүзнең раска чыкмаганы юк!

Я ф и р, М ә с ә й, Р а х м а й, Ф ә р д и керәләр.

Я ф и р. Исәнлек-саулыкмы тагын бер мәртәбә?

Р а х м а й. Җә, бригадир, кыздырдың аяк табаннарын бүген.

З ө л ф ә т. Йокларга әйбәтрәк булыр.

Ф ә р д и. Буш корсакка йокы керер микән?

З ө л ф ә т (*Рәхиләгә ым кагып*). Ишеттеңме?

Р ә х и л ә. Утырыгыз урынча. Юынгыч менә монда. Әни ашарга әзерләгән. Теләсәгез, кайнарлыйм.

Ф ә р д и. Суык килеш тә бара! Аш алды гына әйбәт булсын!

Р а х м а й. Табыны болай түгәрәк күренә. Манарасы гына юк. Сабан туе мәйданы сөлгеле колгасыз, туй дугасы кыңгыраусыз була димени?

З ө л ф ә т (*Рәхиләгә*). Ишеттеңме? Туры суктыралар! Кая барып җиттеләр. Хәзер каптырам мин аларны...

Ф ә р д и. Бусы катыкмы?

Р ә х и л ә. Анысы каймак.

Ф ә р д и. Әллә? Ну шәп!

Я ф и р. Комагайланмагыз. Ач кешеләр кук кыланасыз. Ашны олылый белмисез.

Р а х м а й. Син, Яфир агай, кешенең үзәген танып белим дисәң, табын янында күзәт аны. Эшләгәндә сына. Ашауның гаебе юк, ата-бабалардан калган әйбәт гадәт.

Р ә х и л ә. Барыннан җитешегез. Син, ала күз, ипи валчыгыңны җиргә сыпырып төшермә, җиңең җылар!

М ә с ә й. Читтән караганда безне эш кешеләре дип уйлау мөмкин түгелдер. Корсак коллары төсле өстәл тирәли сирбиянкага биисез.

Р а х м а й. Сиңа рәхәт, алдан килеп бураны тутырып куйгач... Нигә утырмыйсың?

М ә с ә й. Мин башка иптәшләрне беләм. Синең белән

беренче тапкыр ризык бүлешәбез. Нинди кеше икәнлегеңне беләсем килә.

Рахмай. Кеше төсле кеше.

Мәсәй. Алайса, олы кешедән — Яфир агайдан узып, нигә табынга ябырылдың?

Зөлфәт. Зарар юк. Аңлыйбыз. Хәзер бит авыл кешесе дә дөньяның бөтен хикмәтләрен белә. Сезгә ни кирәген сизенәбез. Менә миннән нәни генә мәгәрич. (*Шешә чыгарып куя.*)

Рахмай. Манарасы да кунды.

Фәрди. Чистай чыгарган.

Мәсәй. Аракысын да, сәгатен дә Чистай чыгара. Эч тә калган гомереңне сана дигән төсле.

Рахмай. Күз яше төсле чиста Чистай малае.

Яфир. Олыладың, бригадир, рәхмәт.

Зөлфәт. Әллә болай гына булырмы? Килешеп китеп иплән кенә бергә яши башлагач... Без дә мәгънә беләбез. Синнән башлыйк, Яфир агай.

Яфир. Рәхмәт. Тик, тотмыйм мин мондый нәрсәне, бригадир.

Зөлфәт. Ялындырасың килә инде?

Яфир. Иптәшләр нишлидер. Аларның үз эше. Әмма мин үзем күтәрмим.

Фәрди. Мин дә эчмим. Тәмле ризыкны аракы белән бозалармы? Аппетит шәп, кәеф аннан да шәп. Рәхилә апага рәхмәт.

Рахмай. Алып куй. Эчмибез, эчмибез.

Зөлфәт (*Мәсәйгә*). Ә син, суфый? Ничегрәк?

Мәсәй. Иптәшләргә тулысынча һәм конкретно кушылам.

Зөлфәт. Батмады. Егет булсаң, иптәшләреңне үзеңә куш син. Иярт аларны үз артыңнан. Көчең җитәме?

Мәсәй. Аракы тирәсендә көч сынашмыйлар.

Зөлфәт. Син бүгенгә минем кунагым. Кунак сүзе үтәме, хуҗа сүземе?

Рәхилә. Ашап-эчеп утырыгыз, кунаклар. Менә сөзмә.

Фәрди. Сөзмә дә бармы?

Яфир. Бик рәхмәт, бик ашыйбыз.

Зөлфәт. Әле ашау тирәсендә дә сезнең белән килешеп булмады...

Рәхилә. Көчләмә кешеләрне. Күрмисеңмени, алар эчәргә теләмиләр. Өндәмә кешеләрне юньсезлеккә.

Зөлфәт. Кунак сыйлауның кайчан юньсезлек булганы бар? Алар безгә ялланган. Җәй буе бездә эшләргә тиеш. Мин аларны белергә тиешме-юкмы?

М ә с ә й. Исертеп сыныйсың икән.

З ө л ф ә т. Кем хәзер аек баштан дөрес сүз сөйләшә?

Я ф и р. Без бу районда яңа кешеләр түгел. Өченче елыбызны киләбез. Байтак колхозларда беләләр безне.

Р а х м а й. Кәнфитләнмик әле! Эш башлар алдыннан хуҗалар сый куя икән, моның ни ояты бар? Аяклар да талды. Сал булмаса миңа!

М ә с ә й. Эч, Рахмай абый, мин аракыга акча кызганам.

Р а х м а й. Шундый саранмы син?

М ә с ә й. Саран.

З ө л ф ә т. Мин сыйлыйм бит, мин.

М ә с ә й. Шуннан куркам да шул.

Р ә х и л ә. Моңарчы сәер иде, хәзер кызык була башлады.

М ә с ә й. Тиктомалдан аракы кыстырып килә икән, үрдәк биреп каз алырга тели дигән ым була. Бары тик шул гына.

З ө л ф ә т. Казыңны бирмәм дисеңме? Алайса, үрдәккә дә көн юк. Зөлфәт кулына кергән шешәнең гомере кыска! (*Шешәне Рахмай кулыннан тартып ала да җиргә сылый.*)

Я ф и р. Без атлап килгән юлда шешә ваттың. Эшкә тотынасы көн алдыннан.

Р а х м а й. Әрәм итте. Бозылыр идеме?

Ф ә р д и. Иртән үзем себерермен. Рәхилә апа, бармы себеркегез?

Р а х м а й. Кичтән дә ару себердең. Өстәл ялт итте.

Я ф и р. Рәхмәт, килен, сыйга-хөрмәткә. Җыласаң да бер авыз, көлсәң дә бер авыз дигәндәй, син, бригадир, безгә kинә саклап калма. Шулайдыр, ышанам, син монда хуҗадыр, сүзең дә үтәдер. Тик син безне кулга ияләштермә.

З ө л ф ә т. Ияләшмәгән җан иясе тешләшә. Мин тешләгәнне, ай-һай, яратмыйм. Килешә алмадык бүгенгә, агайлар. Белгән булсам договорны төзетмәгән булыр идем.

М ә с ә й. Син китертмәдең безне, бригадир, тормыш чакырды.

З ө л ф ә т. Зөлфәт сыеннан баш тарткан кеше юк иде моңарчы.

Я ф и р. Әйтеп куюың ярады, без дә белеп торырбыз.

Зөлфәт чыгып китә.

Р ә х и л ә. Кызык адәмнәр булып чыктыгыз сез.

Я ф и р. Ярар, туганнар. Тәвәккәлләп таңнан эшкә. Моңарчы сынатмадык, алда да шулай булсын. Халык әйбәт диләр монда, бездән яманлык йогып калмасын.

Р ә х и л ә. Урынны сезгә өйгә җәябез. Тәрәзәләр ачык, ишек тә ачык. Без бикләп йөрмибез.

Р а х м а й. Стоп, Мәсәй кая үрмәли?

М ә с ә й. Минем тәхет анда.

Ф ә р д и. Тәхетме, бәхетме?

М ә с ә й. Тәхет бар җирдә бәхет сыймый, Фәрди энекәш.

Яфир, Рахмай, Фәрди өйгә кереп китәләр, Рәхилә өстәл җыештыра.

Р ә х и л ә. Яфир агай бригадирыгыз булса да, арада иң куркынычлысы син.

М ә с ә й. Әйбәтләбрәк кара. Ялгышма.

Р ә х и л ә. Сүз әйтердән элек бөтенесе башта сиңа карыйлар. Зәһәрең бөркелеп тора. Аракыны да шуңа эчмәделәр.

М ә с ә й. Синең дә эчертәсең килмәде бит.

Р ә х и л ә. Минем ни уйлаганны да белеп алган әле бу кеше.

М ә с ә й. Шулай түгелмени?

Р ә х и л ә. Нигә бер кич өчен битлек киеп маташырга? Хәзерге ирләр бөтенесе бер чыбыктан сөрелгән. Иртәгә үк чөмерергә тотынасыз бит. Иртәгә үк Зөлфәт кубызына сикерә башлыйсыз.

М ә с ә й. Эчмәсәк? Сикермәсәк?

Р ә х и л ә. Зөлфәт сезне чөеп кенә ыргытачак.

М ә с ә й. Ярый, бригадирның теләге аңлашылды. Менә син ни өчен мине яратмадың?

Р ә х и л ә. Усал, астыртын кешеләрдән җәбер күргәнгә яратмадым.

М ә с ә й. Мин дә усалларны сөймим һәм усалларны үзгәртеп булуын да беләм. Хәерле төн, тыныч йокы сиңа.

Түбәгә менеп китә. Рәхилә өйгә керә. Тынлык, музыка. З ө л ф ә т кереп, сарай янына якынлаша.

З ө л ф ә т. Рәхилә, Рәхилә дим!

М ә с ә й. Тагын ярты кыстырып килдеңме, бригадир?

З ө л ф ә т. Син нишлисең анда, мокыт?

М ә с ә й. Ә син ни тикшерәсең?

З ө л ф ә т. Нигә мендең анда?

М ә с ә й. Бүгеннән башлап мин монда йоклыйм.

З ө л ф ә т. Абзар иясенә йортка кердеңмени? Ха-ха-ха! Әллә ни уйлата яздың.

М ә с ә й. Моннан болай тиешле-тиешсезгә уятып йөрисе булма. Йоклаганда характерым бик начар.

З ө л ф ә т. Бу ни дигән сүз? Кем соң син ул кадәр?

М ә с ә й. Сүземне әйттем, исеңдә тоту синең эш.

Сәхнә караңгылана. Бераз гына пауза. Җиңел музыка. Берничә көн узган. Шул ук күренеш. Вакыт кичкә таба.

Р ә х и л ә. Әни, бик тиз генә чәй суына төшеп менәм.

Н у р г а я н. Эшкә барыр вакытың җитә, суга үзем төшәрмен.

Р ә х и л ә. Син ял ит, әни. Болай да мәшәкатьләрең артты.

Нургаян өйгә кереп китә, Рәхилә чыга башлый, Ә н в ә р и я белән очраша.

Ә н в ә р и я. Сау гынамы, апаем?

Р ә х и л ә. Исәнме, Әнвәрия ти. Ни хәлләрең?

Ә н в ә р и я. Юк, юк, тиктәскә генә кермәдем, олы йомышым бар. Осталарыгыз кайттымы?

Р ә х и л ә. Күзең көн озын койма тишегендә. Бездәге хәлләрне миннән шәбрәк белеп торасың.

Ә н в ә р и я. Җен икән үзләре дә, ничек тамырлары өзелми.

Р ә х и л ә. Ничегрәк эшләргә кирәклеген күрсәтте болар.

Ә н в ә р и я. И-и, апаем, акча өчен шулай комарланалар. Акча дип, шулкадәр көчәнеп, үз кадеремне онытып, иске башмакка әйләнер хәлем юк. Теге чакларда, әллә кайчан инде, әниең белән рәттән эшләдек, ул гел самолетта булыр иде, мин ташбакада. Яшәдек.

Р ә х и л ә. Акча өчен дип кенә тырышалар микән?

Ә н в ә р и я. Уч тутырып акча бирмәсәң, аркылыны буйга да алып салмый алар.

Р ә х и л ә. Әнвәрия ти, кояшның кая тәгәрәгәнен күрәсеңме.

Ә н в ә р и я. Көн дә шулай тәгәри ул, үзгәргәне юк. Бик зур йомышым бар иде, син соң безнең ише ятимялпыны тыңлыйсыңмыни?..

Р ә х и л ә. Син азрак җылый тор, мин аз-маз пәкемне үткенләп алыйм, дип әйтте ди парикмахер, муены киселгән бер абзыйга.

Чыга, Н у р г а я н керә.

Ә н в ә р и я. Әнекәем, син өйдә идеңмени?

Н у р г а я н. Кайда булыйм ди тагын?

Ә н в ә р и я. Синекен белмәссең.

Н у р г а я н. Кичә кибеттә очрашкач та тыр-пыр узып киттең. Бүген көтү куганда биргән сәламемне алмадың. Ни кылануың?

Ә н в ә р и я. Сине ни, тегеләр белән бер исемлеккә тыкканнар икән.

Н у р г а я н. Фәлах малае да, Кәбирнекеләр, Мөслахларның ике кызы, тагын байтак кеше бар ул исемлектә. Дүртәү генә ферма комплексларын сала алмыйлар.

Ә н в ә р и я. Зарплата да куйдылармы?

Н у р г а я н. Аш-су әзерләгән өчен, кием-салымнарын караштырган өчен аена илле биш тәңкә бирәчәкләр.

Ә н в ә р и я. Илле биш тәңкә? Пенсияң дә барамы?

Н у р г а я н. Бармыйча.

Ә н в ә р и я. Ничек җайладың син моны?

Н у р г а я н. Башта карыштым, соңыннан ризалаштым.

Ә н в ә р и я. Син дә шабашкы булдың алайса?

Н у р г а я н. Болары шабашкы түгел икән, договор төзеп, нәрәт белән эшлиләр.

Ә н в ә р и я. Әй, кемгә иш булсаң, шуның җырын җырлыйсың ла ул. Шулай диң, бригадир белән килен төнләтөнлә кыҗыр-быҗыр булгач, эш көйле диң. Пенсия өстенә илле биш тәңкә!

Н у р г а я н. Башымны әйләндер, киленгә тел тидерәсе булма.

Ә н в ә р и я. Бер туктарсың әле шул фатирчыны өфөф итеп торудан!

Н у р г а я н. Ул минем йөрәк ярам, күңелемнең канлы җәрәхәте. Мәңге узмас үкенечем. Син, әрем тел, кузгатма тиешле-тиешсезен.

Кереп китә. Р ә х и л ә су алып менә.

Р ә х и л ә. Җылап туйдыңмы, пычакны үткенләдем.

Ә н в ә р и я. Килче, Рәхилә җаным, чиләкләреңне ташлачы.

Р ә х и л ә. Тагын бер яңа хәбәр.

Ә н в ә р и я. Кайнанаң теге шабашкыларга язылган. Аларны башка авылга күчерсәләр, ияреп китәрме икән?

Р ә х и л ә. Ияртсәләр рәхәтләнеп иярә! Ник иярмәсен ди?

Ә н в ә р и я. Аллакай гына, үзем дә шулай димен.

Р ә х и л ә (*һаман үртәп*). Ничек тотмак кирәк, китсә китә инде.

Ә н в ә р и я. Берәрсенә күңеле төшкән аның. Әйтәм җирле кичәгенәк яңа, чәчәкле алъяпкыч сатып алды, күлмәклек крепдишиннар тотып-тотып карады. Карт-гыйшык пулат җимерер диләр аны.

Р ә х и л ә. Син, Әнвәрия ти, рәхәтләнеп сөйли тор, мин үрдәк бибиләремне генә барлап меним. (*Чыга.*)

Ә н в ә р и я. Әй, Рәхилә дим, йомышым исемә төште.

З ө л ф ә т керә.

З ө л ф ә т. Перс, нәгъләт!

Ә н в ә р и я. Нишләп әле син мине куасың?

З ө л ф ә т. Сукмакта... кара мачы. Синең песиме?

Ә н в ә р и я. Керергә хакым юкмы әллә? Кума син мине!

З ө л ф ә т. Өйдәләрме болар?

Ә н в ә р и я. Әй, Зөлфәт наный, әйтмәм дигән идем. Нургаян тутаң кияүгә чыга.

З ө л ф ә т. Кем песие булыр икән ул?

Ә н в ә р и я. Теге шабашкыларның өлкәне бармы, Яфир атлы бугай, хушбуй сибенеп, кәттәләнеп кенә йөри торганы, шуңа чыга.

З ө л ф ә т. Мин кешене иснәп йөрмим.

Ә н в ә р и я. Яхшы хәбәрнең кадерен беләсеңме соң син?

Чыга. Р ә х и л ә керә.

Р ә х и л ә. Салкын су чыгарыйммы?

З ө л ф ә т. Сыйласаң, агу да эчәм.

Р ә х и л ә чүмеч белән су чыгара.

Р ә х и л ә. Сыйлый үзеңне Халидәң.

З ө л ф ә т. Эштән кайтышлый һәр көнне осталар янына кагылып чыгам диген...

Р ә х и л ә. Фермаларны безнең өчен салалардыр бит?

З ө л ф ә т. Шул Мәсәй дигәненнән күзеңне алмыйсың, чекерәеп катасың.

Р ә х и л ә. Мәсәй дә миңа карыймы?

З ө л ф ә т. Ач күз ул Мәсәй. Күр дә тор, берәрсен тотып ашар әле.

Р ә х и л ә. Тамаклары сыйлы, ач түгел... Әни ошатып тора әле аларны.

З ө л ф ә т. Күзгә карын ачлыгы гына чыкмый.

Рәхилә. Нигә миңа карый икән ул, шуны беләсе иде.

Зөлфәт. Белмәмешкә салышма инде, бала-чага булма.

Рәхилә. Бу юлы мин синең сүзеңнең раска чыгуын бик телим.

Зөлфәт. Нигә җәйләүгә чыкмыйсың? Терлекчеләр шунда яшәргә тиеш. Нигә алар янында өйдә ятасың?

Рәхилә. Алар белән кызык. Бала-чага дисең син... Бер дә тормыш күрмәдем ич мин, Зөлфәт. Унҗиде тулар-тулмаста кияүгә чык... Ни күргән дә, ни татыган?.. Миңлегәрәй.... Хәер, боларын үзең дә беләсең.

Зөлфәт. Әйбәтләп боргычлаучың юк!.. Ярый. Эш белән йөрим. Иртәгә районга барасың.

Рәхилә. Кем әйтә?

Зөлфәт. Мин әйткән җитмәгәнме?

Рәхилә. Бара алмам.

Зөлфәт. Ну, идарәдә хәл кылынган.

Рәхилә. Эш ташлап йөрмим дидемме?

Зөлфәт. Мә инде! Районнан атап чакырганнар. (*Кәгазь бирә.*) Киңәшмәгә.

Рәхилә. Нишлим ди мин анда?

Зөлфәт. Алдынгы терлекчеләрне җыялар.

Рәхилә. Әлегә мин алдынгы түгел. Мине уздырган савучылар да бар.

Зөлфәт. Кем?

Рәхилә. Халидәң. Әллә белми идеңме?

Зөлфәт. Киңәшмәгә син барасың. Син алдынгы. Син чыгыш ясыйсың.

Рәхилә. Ясамыйм. Сөйләр сүзем юк.

Зөлфәт. Тәҗрибәң белән уртаклашырсың. Элек сөйли идең бит. Җаен табып яңа төзелешне, шулар рәтеннән минем исемне дә телгә алырсың. Күнегә торсыннар. Кыскасы, мин синең чыгышны язып алып килдем.

Рәхилә. Кеше язганны укый-укый, кеше сүзен сөйли-сөйли үз телемне оныттым.

Зөлфәт. Карулашма.

Рәхилә. Нигә Халидә бармый? Аның күрсәткечләре әйбәтрәк. Ул тырыш. Ул уңган. Мин әллә ничек ялкауландым...

Зөлфәт. Йөк алашасын чабышка чыгармыйлар. Ике канатлы кукурузник авыл арасында гына оча.

Рәхилә. Нигә һаман алдашабыз соң без?

Зөлфәт. Нинди алдашу? Син колхозыбызның маягы. Адым саен маяк алыштырып тормыйлар.

Рәхилә. Барсам да барырмын инде.

Зөлфәт. Теге шабашкыларга ияреп күңелең иләсмиләсләнде, ахры. Ялгыштым. Ах, ялгыштым! Башкасын уйладым, монысын күз алдына да китермәдем.

Рәхилә. Ялгышыңны таныр көнең җиттемени?

Зөлфәт. Фатирга сезгә төшереп ялгыштым! Чыгар әле бер чүмеч салкын су. (*Рәхилә чыгара.*) Тьфү! Чебен төшкән ич! (*Түгә.*)

Рәхилә. Чишмәдән әле генә алып мендем. Нинди чебен?

Зөлфәт. Суыңны жәллисеңме? Алып мен сап-салкынны. Чистаны!

Рәхилә сыңар чиләк тотып чишмәгә суга төшеп китә. Зөлфәт өй эчен күзәтә. Нургаян өйдән чыгып киләткә уза. Зөлфәт ялт итеп өйгә керә, тиз үк чыга, нидер яшерә. Нургаян керә.

Зөлфәт. Нихәлләр?

Нургаян. Ярыйсы.

Зөлфәт. Ярыйсы, ярыйсы! Шәп диген! Күкрәк как. Һаман бер сүз.

Нургаян кереп китә. Рәхилә чиләге белән суны Зөлфәткә утырта.

Рәхилә. Эч! Моннан болай миңа җикеренәсе булма.

Зөлфәт. Кайнатасың канны бу араларда, ахыры юньлегә булсын.

Чыга. «Перс, нәгъләт!» дип кычкырганы ишетелә. Нургаян керә.

Нургаян. Әзерләнәсеңме, килен?

Рәхилә. Вакыт җитә, әни,

Нургаян. Җәйләүдә торсаң, вакытың иркенрәк булыр иде.

Рәхилә. Юк, әни. Синең янга кайтып йөрү үзе бер рәхәт. Җылыңны тоеп, рәхәтләнеп йоклыйм. Күңелем тыныч.

Нургаян. Калынрак яулык алмыйсыңмы? Кичләрен суыткалый.

Рәхилә. Менә йөрәгем ташып тора иде, чыктың да тынычландырдың. Хәзер Халидә килергә тиеш. Бергә барырбыз дип сөйләштек.

Нургаян. Рәхмәт яхшы сүзеңә.

Өйгә кереп китә. Халидә керә.

Халидә. Үзең генәме?

Рәхилә. Яңалык. Минем кем белән булуны син дә тикшерә башладың.

Халидә. Әниең минем аяк тавышын ишетмәдеме?

Рәхилә. Юктыр.

Халидә. Өзлексез тыңлана бичара. Нидер көтә. Кемнедер көтә. Әллә килгәнен көтә, әллә киткәнен көтә.

Рәхилә. Бүген иртәләгәнсең.

Халидә. Сәбәпсез йөрмим.

Рәхилә. Ишетеп тә өлгердеңме?

Халидә. Әнвәрия ти... өй борынча чабып йөри. Чакырганнар сине.

Рәхилә. Бар дисеңме?

Халидә. Бармыйлармы соң, җүләр.

Рәхилә. Күңелем иләс-миләс... Соңгы ике ункөнлектә син күбрәк саудың. Менә сине җибәрергә иде анда.

Халидә. Китсәнә. Нишләп йөрим ди мин анда? Шушы кыяфәтем белән кеше өркетеп. Дүрт яшемдә микән, үги әнкәй бик кыскач, Сабан туе көнне йорттан-йортка күкәй җыярга чыккан идем. Соң да чыккан-мындыр инде, кирәргә дә читенсенә идем, бер-ике йомырка җыйгач та чабып өйгә кайттым. Шунда әнкәй «чыраеңны күрмәс өчен әллә ниләр бирерсең!» дип ычкындырды.

Рәхилә. Миңа бик оста сөйлисең. Башкаларга да шулай аңлатырсың.

Халидә. Җүләр.

Рәхилә. Иң актыктан икебез дә җүләр булып, төп башына утырып калмыйк.

Халидә. Ни булды сиңа?

Рәхилә. Ардым...

Халидә. Районга барасың. Биек трибунага менәсең. Ел ахырына тиклем һәр сыердан дүрт мең ярым литр алам диген.

Рәхилә. Кулымнан килмәсә?

Халидә. «Алма» белән «Миләүшә»не сиңа бирәм. Хәзергә алар иң сөтләч сыерлар.

Рәхилә. Юк, ахирәт, монысы ярамас. Тана чакларыннан үзең тәрбияләдең, инде иң көчле чакларында миңа бирмәкчесең. Нигә?

Халидә. Бирәм. Син аласың. Менә соңгы айда аларны ничек-ничек ашатуым турында индивидуаль график. Барын язып, санап бардым. Вакыты, азык бирәмлекләре күрсәтелгән. Менә рационга биохимик анализ. Шуны шартлатып укып чык.

Рәхилә. Шуларны яза барасыңмы?

Х а л и д ә. Гаҗәп кызык икән ул бер күзәтә башлагач. Эшең уч төбендә ятамыни, ап-ачык. Тик моны берәүгә дә әйтмә. Безнеке дә белми. Белмәсен.

Р ә х и л ә. Даныңны, тырышлыгыңны, тормышыңны миңа бирергә әзер. Ни бәрабәренә?

Х а л и д ә. Табигать сине сайлаган. Син матур. Син булган. Кыю. Ярып сөйли аласың. Сиңа ышаналар. Синнән көтәләр. Сине беләләр.

Р ә х и л ә. Күңелем төшенке. Үз-үземне сөймим. Белмим, нигә. Йөрәк шашынып куя... Әллә ниләр эшлисе килә. Тот кәгазеңне! Тот чакыруны. Син барасың. Син матур. Син уңган. Ярып сөйләргә өйрән. Минем сыман язып биргәнне татылдама. Сиңа ышанабыз. Синнән көтәбез.

Х а л и д ә. Зөлфәт мине ташлап китәчәк.

Р ә х и л ә. Китсен.

Х а л и д ә. Ничек гомер итәрмен? Җебегән ич мин, быламык...

Р ә х и л ә. Йә, бар кит. Җылатырсың тәки. Син үгетлисең. Ул үгетли. Без үгетлибез. Нәтиҗәдә мин барып халыкка ялган сөйләргә тиеш. Оятын кая куйыйм?.. Мин җебегән монда. Синең хәтерне саклап Зөлфәтеңне абындырмыйча яшим.

Х а л и д ә. Безгә китәргә вакыт.

Р ә х и л ә. Җәйләү юлын синнән башка да табармын.

Х а л и д ә. Ихтыярың.

Чыга. М ә с ә й керә.

М ә с ә й. Бригадир җәмәгате булдымы бу? Нинди сөйкемле хатын.

Р ә х и л ә. Шуны әйтер өчен иртәләдеңме?

М ә с ә й. Түгел. Сиңа йомышым бар.

Р ә х и л ә. Әллә!

М ә с ә й. Ялгызыңны гына очратырга дип ашыктым.

Р ә х и л ә. Кирәкми, Мәсәй. Сөйләмә.

М ә с ә й. Иртәгә районга барасың икән.

Р ә х и л ә. Бар дип үгетләргә кердеңме?

М ә с ә й. Почтада акча салмассыңмы дигән идем.

Р ә х и л ә. Акча? Нинди акча? Почта яныннан узып кайттың ич.

М ә с ә й. Ничегрәк аңлатыйм икән? Мин моны иптәшләрнең белүен теләмәс идем.

Р ә х и л ә. Бир акчаңны, хәсрәт.

М ә с ә й. Минем турыда начар уйладың.

Рәхилә. Аннан сиңа ни зыян? (*Пауза.*) Нигә дәшмисең?

Мәсәй. Болай гына...

Рәхилә. Иптәшләр белмәсен, имеш. Сер капчыгына яшерә. Сүз башлау өчен җаймы бу акча?

Мәсәй. Түгел, алай уйлама.

Рәхилә. Әллә миңа карап күзең янмыймы, Мәсәй?

Мәсәй. Күз белән күңел арасы ерак шул, Рәхилә.

Рәхилә. Йә, бирәсеңме акчаңны?

Мәсәй. Йөз илле сум. Менә адресы.

Рәхилә. Хатының детдомда эшлимени?

Мәсәй. Хатыныма түгел ул.

Рәхилә. Ә, төшендем. Кыланган булдың... «Сер-мер!» Барыгыз бер иш. Хатыныңнан урлап саласың икән акчаны. Сөяркәңә!

Мәсәй. Хатыным да, сөяркәм дә түгел... Гомумән, хатыным юк минем.

Рәхилә. «Хатыным бар» дисәң, ышанмас идем. Капкадан чыккач егет инде сез!

Мәсәй. Юк минем хатыным, Рәхилә.

Рәхилә. Районга гына барам, күз күргән, белеш дип әйтерлек ирләр белән очрашам, шунда да биш-алтысы сүз салып маташа. Запискаларны президиумга түгел, миңа күбрәк язалар.

Мәсәй. Мине гаепләмә алар өчен. Күзем янмый, монысын көтмә.

Рәхилә. Карап карарбыз.

Мәсәй. Карыйсы юк.

Рәхилә. Ямьсезме мин?

Мәсәй. Рәхмәт.

Рәхилә. Ямьсез булганым өченме?

Мәсәй. Йомышымны тыңлаган өчен рәхмәт.

Чыга. Нургаян керә.

Нургаян. Килен, килен!

Рәхилә. Нәрсә, әни, ни булды?

Нургаян. Әйтсәм дә инде, килен. Бик ямьсез хәл.

Рәхилә. Тизрәк әйт, әни.

Нургаян. Син районга бара дигәч, акчаларны караштырган идем, комод тартмасыннан байтак акча югалган.

Рәхилә. Күпме?

Нургаян. Йөз сумнан артыграк дип беләм. (*Рәхилә кулындагы акчаларны күреп.*) Ә, син алгансың икән. Шулар инде, егерме бишлекләр иде.

Р ә х и л ә. Шулар ук түгел, әни... Тик син бу турыда берәүгә дә сүз ычкындырасы булма. Берәүгә дә, ярыймы? Үзем очына чыгармын әле бер.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Ишегалды буш. Ашыгып-кабаланып, З ө л ф ә т керә.

З ө л ф ә т. Нургаян ти. Нургаян түти!

Н у р г а я н. Ай Аллам, ни булды?

З ө л ф ә т. Ни булганын синнән мин сорарга телим.

Н у р г а я н. Бер дә әллә ни булганы юк бугай.

З ө л ф ә т. «Дыр» белән «бугай»ны чәчеп караганнар. Ни үскәнен беләсеңме? Шымытыр үсеп чыккан.

Н у р г а я н. Ярсырлык бер сәбәп тә күрмим, Зөлфәт.

З ө л ф ә т. Үзең ике тапкыр идарәгә кереп чыккансың. «Зөлфәт бик кирәк иде» дигәнсең.

Н у р г а я н. Кергән идем шул.

З ө л ф ә т. Давай, давай, яшермә!

Н у р г а я н. Нәрсәсен яшерим ди?..

З ө л ф ә т. Салкын су чыгар әле. Уф! (*Нургаян су чыгара, Зөлфәт эчә.*) Давай, сиптер. Ни булды?

Н у р г а я н. Гаеп-кыектан булмасын, бу осталарны бездән чыгар, Зөлфәт. Күңелем сизә, азагы яхшылык булмас моның.

З ө л ф ә т. Күңелне кәгазьгә теркәп булмый. Нигә чыгарасың? Моңа олы сәбәп кирәк.

Н у р г а я н. Сәбәбе юк.

З ө л ф ә т. Алдашма, Нургаян ти. Күзеңнән күреп торам. Берәр нәрсә сизденме? Бармы фактың?

Н у р г а я н. Күңел курка. Бары тик шул гына.

З ө л ф ә т. Ике тапкыр мине эзләп кергәнсең. Монда курку гына җитми. Аларга бәйләнерлек сәбәп кирәк.

Н у р г а я н. Алай ук куркыныч сөйләмә.

З ө л ф ә т. Их, Нургаян ти! Беләм мин аларны. Бергә төйнәлгән булып юрамалый кылана алар. Алар арасында да ярык бар. Ярык кына түгел, чокыр, караңгы баз. Кеше дигәнең абынмый калмас, калка да чыга аның кыек эше. Әйт: нигә куасың аларны? Кайсысы ярамады? Ни-нәрсәсе ярамады?

Н у р г а я н. Күчер башка фатирга. Шул гына.

З ө л ф ә т. Аз сүзле син, Нургаян түти. Бу әйбәт. То есть, кешесенә карата әйбәт. Әмма миңа фактлар,

дәлилләр кирәк. Кап-кайнар фактың кайда да, тере дәлилең кайда?

Н у р г а я н. Фактысы юк.

З ө л ф ә т. Чыгару гына түгел, кайсыберсен авылдан этап белән кудырыр идем. Кирәк! Колхозыбызга да бик кирәк, миңа да. Кирәк кешене кулга ияләштергән яхшы. Башкача булмый. Син ярдәм итә аласың. Чыгарам дисең икән, сәбәбен яшермә.

Н у р г а я н. Күңелем берекми.

З ө л ф ә т. Постой, постой. Күңел ул буш капчык. Селкесәң дә бер әйбер төшми. Син, әйдә, булганны яшермә. Бир миңа факт, мин аны шундук дагалыйм.

Бәләкәй чемодан тоткан, матур киемнәрдән Р ә х и л ә кайтып керә.

Р ә х и л ә. Кемне дагаламакчы була бу кеше? Һаман туймаганмы?

Н у р г а я н. Килен кайтты!

Р ә х и л ә. Ат дагалаганда ботын кыстырган бакага ни буласын беләм. Шулай да әйт: кемне дагалыйсың? Һәм нигә?

З ө л ф ә т. Тормыш законнарын ачыклыйбыз.

Р ә х и л ә. Минем әни беләнме? (*Өйгә керә.*)

З ө л ф ә т. Ачмадың сереңне, Нургаян ти. Син монда нәрсә-кара хәстәрләп куй. Рәхиләгә сиздермә, ярыймы?

Н у р г а я н. Киленгә самоварны гөжләтим әле.

Чыга. Бераздан Р ә х и л ә керә.

З ө л ф ә т. Нургаян түти акыллы хатын ул, аның белән бер сөйләшү — бер гомер.

Р ә х и л ә. Мактыйсың икән, син аннан нидер телисең. Башкача син үзеңнән бүтән кешене гомергә мактамыйсың да...

З ө л ф ә т. Кагыйдәм бер: бергә яшик, бергә тырышыйк. Бирәләрме — ал, сыйлыйлармы — эч!

Р ә х и л ә. Бу кагыйдәң белән ерак киттеңме?

З ө л ф ә т. Мин кагыйдәләрдән өстен. Кагыйдәләр башкалар өчен.

Р ә х и л ә. Бигрәк тә килгән осталар өчен, иеме? Синең кагыйдәгә буйсынмасалар, ни?

З ө л ф ә т. Берсе дә ерак китә алачак түгел.

Р ә х и л ә. Студент та ерак китәчәк түгелме?

З ө л ф ә т. Арада иң дурагы шул. Бүген мин аңа гаҗәп файдалы бер тәкъдим ясап карадым, дивана төсле күзен

челт-челт йомып тик тора. Җәтмәсенә капкан балыкны җибәрә, тәмле калҗаны кире чыгара. Гомеренә бил бөгеп, тир түгеп яшәячәк.

Р ә х и л ә. Түгелгән тирнең ояты юк.

З ө л ф ә т. Аның белән мактану чоры узды. Байлык, муллык белән мактанышу чоры җитте.

Р ә х и л ә. Һич тайчанмыйча, ачыктан-ачык боларны миңа сөйлисең. Миңа ышануыңмы бу?

З ө л ф ә т. Сине төзәтергә тырышуым. Ялгыш арты ялгыш җибәрәсең. Хәзер әйт: киңәшмә кичә бетте, нигә бүген генә кайттың?

Р ә х и л ә. Мин ирекле кеше.

З ө л ф ә т. Кеше бер чакта да ирекле булып бетә алмый.

Р ә х и л ә. «Үрнәк» совхозына алып бардылар.

З ө л ф ә т. Тагын шул ялагайларга алып барганнар. Ярар, тиздән арыкны борырбыз. Теләсәк, суны үргә агызырбыз. Безгә килә башларлар. Безгә! Зөлфәт хуҗалыгына! Осталар кырмыска күк кыймылдый. Төзиләр!

Р ә х и л ә. Осталар барына бер куанасың, бер эчең сыза.

З ө л ф ә т. Мин шабашкыларны бер төрле генә була дип белә идем. Ә боларның җепләрен бер учка җыя алмыйм. Җыйсам, курчак күк сикертер идем үзләрен!

Р ә х и л ә. Мин юынып, ял итеп алыр идем.

З ө л ф ә т. Сиңа сүзем бар.

Р ә х и л ә. Әллә кайчаннан бирле көтәм.

З ө л ф ә т. Чыгышың берәүгә дә ошамады. Хаталар җибәрдең.

Р ә х и л ә. «Берәүгә» дә дигәнең син буласыңмы?

З ө л ф ә т. Нигә Халидәне телгә алырга иде? Ни пычагыма аның рационын сөйрәп чыгардың? Нигә мактадың аны?

Р ә х и л ә. Дөресен сөйләү җан рәхәте икән, Зөлфәт.

З ө л ф ә т. Теге этләрнең йогынтысы бу! «Дөреслек, турылык» дип, Мәсәй лыгырдый.

Р ә х и л ә. Алар йогынтысымы икән, Зөлфәт? (*Нургаян керә.*) Әни, бая ашыгычлык белән күчтәнәчемне бирмәгәнмен.

Төргәк сүтеп, Нургаянга бүләген бирә.

Н у р г а я н. Рәхмәт, килен. Аллакай гына, мондый затлы яулык бәйләп кая барырмын?

Р ә х и л ә. Гомерең озын булсын.

Н у р г а я н. Рәхмәт, килен. Эшкә кузгалганчы аз-маз

ял итеп ал. Чәй эч тә чоланга кереп ят. Идәнен яңа сөртеп чыгардым. Салкынча.

Рәхилә. Әллә келәт ишеген бикләгәнсең инде?

Зөлфәт. Бикләгән! Әһә!

Рәхилә. Чолан ишегенә дә йозак элгәнсең.

Нургаян. Кибеткә чыккан идем, йозаклар күрдем дә алдым шунда.

Зөлфәт. Ягез әле, ягез... Йозак! Ачарсың моны!.. Нигә бикләндегез? Ни яшерәсез? Рәхилә, дим! Нургаян түти?!

Нургаян. Хуҗалыкта артмас. Безнең ир-ат юк.

Зөлфәт. Келәтегезнең гомергә бикләнгәне юк. Кар базы өстегез яз-көз ачык тора. Өй келәсенә агач чөй тыгасыз.

Рәхилә. Осталар белән булган гаугаңа нигә әнине катнаштырасың?

Зөлфәт. Нургаян түти, димәк, йозакларыңны миннән яшерен серләреңне бикләр өчен генә алып кайткансың алайса!

Нургаян. Аны-моны уйлап тормадым. (*Кереп китә.*)

Зөлфәт. Их, тешләк җан. Куркак мачы!

Рәхилә. Эшкә ашмас планнарыңа безне бутама.

Зөлфәт. Алгы көн планнарымның үзәгендә син бит, Рәхилә.

Рәхилә. Арыдым. Ял итәсем килә.

Зөлфәт. Рәхиләү! Ишетәсеңме? Минем тавык мие эчкән хатынның башына бер акыллы фикер килгән. «Алма» белән «Миләүшә»не сиңа бирәм, ди. Ә алар рекордсменнар, хет парлаштырып Мюнхенга Олимпия уеннарына җибәр.

Рәхилә. Алмыйм мин аның сыерларын.

Зөлфәт. Сызгыртып аласың.

Рәхилә. Нигә мине данлы итәсең килә синең?

Зөлфәт. Бөтен ягың килгән, дан гына җитми сиңа, җанашым! Эх!

Әнвәрия керә.

Әнвәрия. Рәхилә җаным, Рәхилә апаем.

Зөлфәт. Ни җилпенәсең? Бар әле, бар.

Әнвәрия. Җыелыш түгелдер лә?

Зөлфәт. Аннан да хәтәре. Кон-фи-денциальная әңгәмә!

Әнвәрия. Яратасың да инде хатын-кызны өркетергә.

Рәхилә. Җыелыш ябылды, Әнвәрия түти. Зөлфәт, кизәнмә. Бездән артыгын ала алмассың.

Әнвәрия. Йомышым исемә төште, Рәхилә. Районга барсаң миңа келәм таба алмассыңмы?

Рәхилә. Мин аннан кайттым гына шул.

Әнвәрия. Тагын чакырырлар. Иллә мәгәр тавышың радиодан матур ишетелде. Сине Казанга алмыйлардыр?

Рәхилә (*көлеп*). Чакыручы булмады.

Әнвәрия. Синдәй матурны монда гына калдырмаслар. Чакыртып алырлар сине.

Зөлфәт. Вакытны аласың. Бар әле, бар, Әнвәрия түти.

Әнвәрия. Менә мондый адәм имгәкләре янында сине тоталармы соң?

Зөлфәт. Бар, дим!

Әнвәрия. Әле дә ярый, бригадир гына булып калгансың. Прокурор булсаң урамыбыздан йөртмәс идең. (*Чыга.*)

Рәхилә. Син бәйләнчек була барасың, Зөлфәт.

Зөлфәт. Кит дию булдымы? Китсәм дә, борылып кайтырга китәм, Рәхилә. (*Нургаян керә.*) Нургаян түти, онытма.

Чыга.

Нургаян. Нишләмәк кирәк соң, килен... Башлыкларга карышу читен.

Рәхилә. Сагындым, әни. Сине сагындым.

Нургаян. Үзем дә шулай, килен.

Рәхилә. Әни, мин үземә алка алдым. Матурмы?

Нургаян. Синең колакларың тишекмени соң?

Рәхилә. Әй, безнең Миңлегәрәй белән... Матур бит, иеме? (*Тага.*)

Нургаян. Матур, килен. Сиңа бөтен әйбер килешә.

Рәхилә. Синең янга, үзебезнең өйгә кайтасым килде бу юлы. Таңнарны аттыра алмыйм гына бит.

Нургаян. Беләм — бер чыгып китәрсең дә бөтенләй кайтмассың. Әмма кая гына китсәң дә, минем гомер җебе сиңа ияргән инде. Синнән башка беркемем калмады.

Рәхилә. Китмәм, әни. Кая барыйм?

Нургаян. Алай ук өзеп куйма, килен. Соңыннан читен булыр.

Рәхилә. Нигә шултиклем өйгә ашкындым соң әле мин? (*Пауза.*) Осталар ничек?

Нургаян. Җен кебек эшләп йөриләр.

Рәхилә. Акчаның очына чыкмадыңмы?

Н у р г а я н. Югалган акчаның очына кем чыга алсын?

Р ә х и л ә. Борчылма, үзем җаен табармын. (*Чыга.*)

Н у р г а я н. Ял итәргә ятмыйсыңмыни? И-и, бала, бала.

Пауза. Ә н в ә р и я керә.

Ә н в ә р и я. Көннәр буе җил-җил йөрисең, күрше.

Н у р г а я н. Синең күзгә шулай күренәдер.

Ә н в ә р и я. Шөкер, күзем әйбәт. Инә сапларга кешегә кермим.

Н у р г а я н. Күңел күзе генә тоныклана.

Ә н в ә р и я. Ни дидең?

Н у р г а я н. «Нигә ашкынып кайттым соң әле бу юлы?» диде...

Ә н в ә р и я. Бүген төшкән килен кук, өеңдә урын тапмыйсың. Яшермә, мин үтә хәйләкәрмен. Иртән көтү куганда хатын-кызның малга эндәшүеннән үк күңел серен белеп торам. Берәүләр «каһәр суккан мал, төртенмеш!» дип чыбыклый-чыбыклый куа сыерын. Икенчесе «малкаем, сөтләчем, иркәм» дия-дия сөеп озата, ипи каптыра. Нигә алай? Моны белергә гыйлемлек кирәкми, көн кебек ачык.

Н у р г а я н. Юк-бар әкиятләрдән ничек туймыйсың?

Ә н в ә р и я. Миңа да яшәргә кирәк ич.

Н у р г а я н. Ялгыз яшәүләре бигрәк читен шул.

Ә н в ә р и я. Безнең тормыш мәгълүм: ир куены кайнарлыгын тоеп өлгермәдек, гүр салкыны бәгырьләрне китереп кысты. Балалар таралды. Гомер үтте китте.

Н у р г а я н. Сизми дә калдык...

Ә н в ә р и я. Бер сүз әйтимме? Акылыннан шашкан дип көлмә. Торучыларыңның берсен күчер миңа. Мин дә электр яктысында ир-атка карый-карый чәй эчәр идем.

Н у р г а я н. Кайсысын күчерик? Ничек итеп?

Ә н в ә р и я. Әйбәтрәген. Эшлеклесен. Юашын. Үзең җайларсың инде, бездә тыгызрак диярсең.

Н у р г а я н. Вакытлыча гына суфыйланып йөрмәсәләр, моңарчы чатаклары күренми.

Ә н в ә р и я. Ә акча? Акчагызны кайсысы урлады?

Н у р г а я н. Авызыңнан җил алсын!

З ө л ф ә т керә.

З ө л ф ә т. Әнвәрия ти, кыяр бакчаңа кәҗә тулган.

Ә н в ә р и я. Мур кыргырлары, каһәр сукканнар! (*Чыга.*)

З ө л ф ә т. Ха-ха-ха!

Н у р г а я н. Олысы, кечесе юк сиңа, Зөлфәт. Барыбызны алдыйсың.

З ө л ф ә т. Кешеләр белән азрак уйнап алырга яратам. Кети-кети кытыкларга. Шахмат уенындагы кебек тезеп куясың. Бусы король! Королева! Фигуралар!.. Аннан пешкалар китә. Берәм-берәм ега башлыйсың үзләрен!

Н у р г а я н. Үзеңне ексалар?

З ө л ф ә т. Кем кемне инде, Нургаян түти. Монда санашып тору юк. Эшкә күчик. Вакыт жәл. Син аны-моны хәстәрләдеңме?

Н у р г а я н. Кемне алып кайттың? (*Рахмай керә.*) Менә кемгә төшкән икән гыйшкың! Гомер буе авылда яшәгән, үзе икмәк валчыгын идәнгә сыпырып төшерә. (*Өйгә кереп китә.*)

З ө л ф ә т. Уз. Утыр.

Р а х м а й. Нигә утырмаска? Әйбәт кеше куша икән, утырырга да була.

З ө л ф ә т. Югыйсә сезне аерым-аерым күреп тә булмый. Ишәй белән Кушай күк йөрисез.

Р а х м а й. Алары кем тагын? Ревизорлармы?

З ө л ф ә т. Бар шунда ике ишәк...

Р а х м а й. Безгә таралырга да мөмкин түгел. Эше бергә, әҗере уртак. Бер казаннан ашыйбыз, кесәләр генә аерым-аерым.

З ө л ф ә т. Минем йомыш шәхсән синдә.

Р а х м а й. Алай ук икән.

З ө л ф ә т. Батырып синдә!

Р а х м а й. Көндез теге ертык балак студентны чакырып әгъвәләп азапланган түгел идеңме?

З ө л ф ә т. Ул утын авыз бирәр нәрсә тишмәгәндер?

Р а х м а й. Ишетелмәде.

З ө л ф ә т. Алайса, аңарда өмет бетмәгән. Студенттан башка нәрсә көтеп тә булмый. Дәшмәсен генә. Без кыймылдый башлаганда авызын биктә тотсын, яшьләрнең роле шул. Йомыш синдә, агайне.

Р а х м а й. Әйбәт кешенең йомышы нигә начар булсын икән?

Н у р г а я н ризык чыгара.

З ө л ф ә т. Ә стаканнар? Кырлы стаканнар чыгар.

Н у р г а я н. Менә кая таба киткәннәр икән болар.

Р а х м а й. Яманлык белән түгел, яхшылык белән.

Н у р г а я н. Дәшмә, тоз күз. Бу шайтан сидегенең кая иткәнен беләбез. Бирмим стаканнарымны!

Р а х м а й. Әкәмәт тә әйбәт кеше икәнсең син, апа.

З ө л ф ә т. Нургаян түти, яланкул утка тотынма.

Н у р г а я н (*стакан чыгарып*). Тамагыгызга таш булып утырсын.

Өйгә кереп китә.

Р а х м а й. Әкәмәт тә кунакчыл икән бу апа.

З ө л ф ә т. Үлгән малае бик эчте. Шул аракы җитте аның башына. Исерек булмаса, бензин мичкәсенә шырпы тыгар идеме? Эчә белеп эчәргә, җир астында җылан ничек йөргәнне белеп кенә яшәргә кирәк. Мәле, тотчы берне.

Р а х м а й (*эчеп*). Ай-һай, бугазны көйдереп төшеп китте.

З ө л ф ә т. Фельдшерга кагылдыңмы?

Р а х м а й. Менә төймәләр бирде. Ашар алдыннан кап, диде.

З ө л ф ә т. Ашар алдыннан ни кабарга кирәклеген белмибез, янәсе. Үзегезнекеләргә ни дидең?

Р а х м а й. Өйрәтеп куюың ярады. Ашказаны сыкрап тора, косасыны китерә, дидем.

З ө л ф ә т. Каян иярдең андый мокытларга?

Р а х м а й. Бригада итеп яздылар да куйдылар.

З ө л ф ә т. Яле, тагын берне тәмләп җибәр.

Р а х м а й. У-ух, җелекләргә төшә, усал нәмәстә.

З ө л ф ә т. Җебемә. Шәпләп тыңла. Мин мунча салырга ниятлим.

Р а х м а й. Мунча гынамыни?..

З ө л ф ә т. Тик миңа тегенди-мондый гына мунча кирәкми. Ак мунча! Җылы идәнле. Стеналары ап-ак чынаяк.

Р а х м а й. Ак мунча?

З ө л ф ә т. Озак итеп, аракы-сыра чөмерә-чөмерә мунча керү гадәткә кереп бара. Кунакның шәбрәге килде исә, рәхим итсен!..

Р а х м а й. Стеналары ап-ак...

З ө л ф ә т. Миңа лаек нинди мунча кирәклеген чамалыйсыңмы?

Р а х м а й. Балта эшен дә беләбез, таш эшен дә. Мич чыгарырга да кеше кирәкми. Чынаяк плитәләрне дә ябыштыра алам.

З ө л ф ә т. Күзәтеп йөрим — кулыгыз ята. Эшлисез алайса? Җиффәр берне салып.

Р а х м а й. Эшлибез, эшлибез.

З ө л ф ә т. Иван Иваныч коры куанычкына булып калмассыңмы?

Р а х м а й. Бер читенлеге бар: иптәшләр кәйрәк минем. Бик әкәмәт бәндәләр. Пример сүлик, учка кергәнне ялт итеп йомдыра белмиләр.

З ө л ф ә т. Син аларны үгетлә. Берәм-берәм җиң. Буйсындыр. Хәйләлә. Астан ут йөрт. Берсе киреләнсә, икенчесенә ябыш. Ычкындырма. Мин үз ягымнан чарасына керештем. Йомдырам мин Мәсәйне!

Р а х м а й. Материал ягы ничегрәк синең? Тактасыкадагы дигәндәй, ак мунчага да байтак кара тир түгәргә туры киләчәк.

З ө л ф ә т. Егет кеше материал тапмыймы?

Р а х м а й. Диңгез буена барасың да җылым саласың. Алтын балык әйбәт кешегә үзе килеп каба.

З ө л ф ә т. Кара әле, агайне, укыган кеше икәнсең син. Пушкинны беләсең.

Р а х м а й. Кая инде, ике класс, бер коридоруздык.

З ө л ф ә т. Такта, кирпеч, бүрәнә ишесен, вак-төяген ферма төзелешеннән өлеш чыгарырбыз. Яле, берне тот әле.

Р а х м а й. Иптәшләр сизәр.

З ө л ф ә т. Эчкәнеңне дә сиздергәч, урлаганыңны ничек яшерерсең син? Сизә пычак. Эчең у да бөгәрләнеп ят.

Р а х м а й. Бу апа сатмасмы?

З ө л ф ә т. Телсез ул. Барысы да телсез. Кемгә фатир төшерергә беләбез.

Р а х м а й. Әйбәт кешегә берни җәл түгел. Җаным да, малым да... Тик бераз куркыныч.

З ө л ф ә т. Монда мин хуҗа. Иптәшләреңне берәм-берәм чәйнәп йотачакмын.

Р а х м а й. Эш барып чыкса, миңа бераз аерып өстәрсең. Үз ягымнан сүз башлармын, үгетләрмен. Син дә таба төбен җылытып тор. Беренче ел, мин аларны аңышып бетермим. Бер карыйсың — ак кебек, бер карасаң — чуар алар.

З ө л ф ә т. Ике яктан ипләп кенә кимерик.

Р а х м а й. Алдан ук козырь тузыңны ачып салма. Ярамас. Кая, берне сал да, кереп ятыйм.

З ө л ф ә т. Бетер инде.

Р а х м а й. Үзең йотмадың да түгелме?

З ө л ф ә т. Мин соңыннан... Эш беткәч!

Р а х м а й. Бир шешәсен. Кирәге чыгар.

З ө л ф ә т. Нургаян ти!

Н у р г а я н керә.

Н у р г а я н. Әләй тавышың, кызыллы-зәңгәрле.

З ө л ф ә т. Урын салып бир. Чирләгән.

Н у р г а я н. Сиңа иярсә үлер дә әле.

З ө л ф ә т. Кыскартыйк, Нургаян түти. Күргәннәрең турында читкә таратма.

Чыгып китә.

Р а х м а й. Бригадир бик әйбәт егет.

Н у р г а я н. Моннан әйбәтне табып та булмас.

Р а х м а й. Күңеле пакь.

Н у р г а я н. Гаҗәп инде.

Р а х м а й. Әйбәт кеше белән утыру әйбәт. Син дә, апа, әкәмәт тә әйбәт кеше.

Н у р г а я н. Мин дә шәп, әйтерлек тә түгел.

Р а х м а й. Мин дә ярыйсы, әйеме?

Н у р г а я н. Шулай укмыни?

Р а х м а й. Әйбәт булмасам, әйбәт бригадир шундый зур эшне миңа ышанып тапшырыр идеме? Мунча диләр аны, ак чынаяктан! Европача!

Н у р г а я н. Мунча килештегезмени?

Р а х м а й. Әллә ишетмәдең?

Н у р г а я н. Мин тыңлап йөрмим. Нәрсә ди?

Р а х м а й. Улмы? Ул болай ди... Ни, ди, син, ди, Рахмай абый, ди, искитмәле әйбәт кеше, ди.

Н у р г а я н. Табышкансыз икән, ниһаять. Кем, Рахмай, Рәхмәтулладыр инде син, ходайның рәхмәте төшкере. Зөлфәт белән дә дуслашкач, бик әйбәт тә кеше булгач, сиңа мөгаен генә аерым фатир кирәктер.

Р а х м а й. Кирәк әйберне мин үзем табам, әйбәт апа. Урын салып бирәсеңме, әкәмәт әйбәт авылның иң әйбәт апасы?

Н у р г а я н. Мен шунда сарай түбәсенә.

Р а х м а й. Тукта. Анда Мәсәй йоклый түгелме?

Н у р г а я н. Мәсәбих та әйбәт кешеме?

Р а х м а й. Улмы? Ул шундый әйбәт ки, каберең якын булмасын аңа.

Н у р г а я н. Кер алайса өйгә, җәфа! Аракы исен өемә кертмәм дигән идем. Фу, тынчыгансың.

Рахмай абына-сөртенә өйгә керә, урам яктан Р ә х и л ә күренә.

Р ә х и л ә. Кемне сүгәсең, әни?

Н у р г а я н. Ару кешеләр дип ышанып йөр аларга...

Күрче берсенең кыяфәтен. Акчаны да шулар гына урлады.

Рәхилә. Әни, языклы булма. Әле берни дә билгеле түгел.

Нургаян. Торма болар янында. Җәйләүгә чык. Тыныч колагың булыр.

Рәхилә. Әни, әрләвең шушы булдымы?

Нургаян. Юк, килен. Әрләргә телем бармый. Ничек яшәвеңне үзем генә беләм.

Рәхилә. Зөлфәт килеп йөргәнгә дә рәнҗисеңдер?

Нургаян. Ни әйтим? Ару кеше килеп йөрсә күңеллерәк булыр иде дә, аруын каян табасың? Әнә бит, дүрт ир-ат керттек. Яше бар, карты дигәндәй. Тора-тора акча югалды. Берсе бүген дуңгызга әйләнеп кереп ятты.

Рәхилә. Берәрсе шаяртмадымы икән безне?..

Нургаян. Үзеңчә яшә, килен. Мин озакламый сәфәр чыгасы кеше. Син яшь. Миңа карама.

Рәхилә. Әни! Ничек яшәргә кирәклеген белеп булса икән ул!

Пәрдә.

Авыл читендә төзелеш мәйданы. Көн кичкә таба. Мәйданда Яфир белән Фәрди. Тәмәке тарталар.

Яфир. Укып бетереп врач булгач сине кая җибәрәләр инде?

Фәрди. Укып тәмамлыйсы бар әле, Яфир агай.

Яфир. Синең урында булсам, тотар идем дә шушы авылга кайтыр идем.

Фәрди. Авылларның перспективасы юк шул, Яфир агай!

Яфир. Ничек алай? Шундый бетон нигезләргә таштан комплекслар салып ятабыз, ә син перспектива юк дисең.

Фәрди. Авыллар бетәчәк.

Яфир. Кызганыч, кызганыч.

Фәрди. Әлбәттә, кызганыч. Әмма хәзерге кешеләр заманча яшәргә омтыла.

Яфир. Синең шуны хуплавың кызганыч, дим. Шушы авылны бер дә жәлләмисеңме? Болыннарын кара, су буйларын. Су түгел, чиләк тутырып көмеш ташый бу авыл киленнәре.

Фәрди. Чишмә яратуыгызны белә идем, Яфир агай, киленнәрне мактавыгызны беренче ишетәм.

Яфир. Кырымны немецлардан арчыдык без. Шуңарчы

ул якларга барырга туры килмәде. Менә анда суның кадерен беләләр. Чишмә башына, шул чишмәне тапкан кешенең атын-исемен язып, ап-ак мәрмәрдән һәйкәл коеп куялар.

Фәрди. Юк, бу авылга эшкә кайтмас идем мин.

Яфир. Нигә?

Фәрди. Зөлфәт алла янына кайтып аңа кол булыргамы?.. Шуңа түзеп торалар бит.

Мәсәй белән Рахмай керә.

Рахмай. Ну көйдерде бүген. Бер чиләк су эчеп бетердем.

Яфир. Аңлашыла.

Мәсәй. Балкаларны китереп җиткермәделәр, Яфир агай. Беренче тукталыш. Теге баштан түбә ябарга тотына идек.

Рахмай. Иртәгә чак кына ял итәрбез.

Яфир. Иртәгә бераз җыештырырбыз. Күрегез инде, күпме чүп-чар аунап ята.

Рахмай. Сабан туе узачак мәйдан түгел. Без киткәч җыештырырлар.

Яфир. Үз чүбебезне үзебез җыябыз.

Мәсәй. Үткән-сүткән кереп китә. Сыер савучылар кагылып чыга.

Рахмай (*хихылдап*). Алары чисталык тикшерми.

Мәсәй. Ни тикшерә?

Рахмай. Фәрдине күзләргә керәләр. Егет кеше икәнен ишетеп тә өлгергәннәр. Синең дә ул яктан эш җайлы — хатынсыз! Фәрдигә сүз салган булып сине дә күзәтәләр. Абзагызга да карап алалар.

Мәсәй. Син миңа кагылма.

Рахмай. Әйттем дә, оныттым да.

Яфир. Әйткәч онытма инде син аны.

Фәрди. Юк, мин монда калмас идем.

Мәсәй. Ярдәмчеләрне кайтарып җибәрәм, Яфир агай? Иртәгә иртәрәк чыгыгыз дип кисәтәм.

Яфир. Ял итсеннәр.

Рахмай. Без дә кайтышыйк.

Мәсәй. Сез теләсә нишләгез. Мин кайтмыйм. Әллә нигә фатирга кайтасы килми. (*Чыга.*)

Фәрди. Кыймылдыйк азрак, Рахмай абый, көн яктысы.

Яфир. Җитсен бүгенгә, Фәрди. Көн яктысына без дә кинәник. Мәсәй әйткәндәй, кайтасы килми. Киче дә ма-

тур. Кара инде, теге тау битенә күләгәләр сузылышкан.

Рахмай. Колак кычытып тора, яңгыр булыр.

Фәрди. Тагын берәр атна юмыйча йөрсәң, көн дә яңгыр явар.

Рахмай. Телгә бик үткенләндең син, егет!

Мәсәй керә.

Мәсәй. Көчкә озаттым егетләрне, бергә кайтабыз, диләр.

Яфир. Әйбәт малайлар. Балта эшенә дә өйрәнеп киләләр.

Фәрди. Шәкертләрең арта, Яфир агай. Унынчыдан соң КамАЗга китәбез, диләр.

Яфир. Нигә кайтмыйбыз икән без?

Фәрди. Былтыргы авылда шәп иде ул! Монда әллә ничегрәк. Башта ягымлы гына йөргән апалар үзгәрде дә куйды. Ашауны да кыстылар. Кичә дә тары боткасы, бүген дә!.. Былтыр авыл кешеләре белән туганлашкан идек.

Мәсәй. Өченче көн өр-яңа йозак белән келәтне бикләгәннәр иде, кичә өр-яңа йозакны нәүрәп ишегенә элгәннәр.

Рахмай. Күсе иялләнгәндер.

Мәсәй. Без урнашкач кына йортка күсе иялләнүе шәптән түгел.

Яфир. Сезнең сүз башлаганны көтеп йөри идем. Картлык нәзбереклеге генә дисәм, сез дә сизенеп борчыласыз икән. Нишләп безне яратмыйлар алар?

Мәсәй. Без аңламаган нидер булып узды.

Фәрди. Аңлашыла: ишекләр йозакта!

Мәсәй. Аннан бигрәк мине алар авызындагы йозаклар гарьләндерә! Өч-дүрт көн буе Нургаян ападан бер авыз сүз ишеткән юк. Минем әнкәйгә бик охшаган бит ул.

Фәрди. Ә Рәхилә апа?! Рәхилә апа?!

Рамай. Анысына ни булган?

Фәрди. Ничек шул Зөлфәтнең кыланышларына түзеп тора икән?

Яфир. Халидәсе йөри авызын йомып!

Рахмай. Бездән башка да очына чыгарлар. Без монда кунак кына. Үз эшебезне белик тә, үз ягыбызны кайгыртыйк.

Мәсәй. Гаеп безнең үзебездә түгелме?

Яфир. Алай булуы да бик мөмкин.

Рахмай. Безнең кемлекне белергә теләсәләр, эше безне килеп карасыннар.

Фәрди. Кайберәүләрнең өйдәге эшләрен карамасыннармы?

Рахмай. Фәрди энем, төлкеләнеп утырма. Ташка басып сөткә коенырга син дә фәрештә түгел.

Мәсәй. Бусы инде җитди сүз. Фәрдигә гаеп ташланды.

Фәрди. Минем ни гаебем бар?

Рахмай. Мине надан дисез инде? «Дөреслек», «намыс» дип чәпчеп йөрүегезне әйтер идем... Нигә башка студентлар отрәт белән йә чирәм җиргә, йә берәр зур төзелешкә чыгып киткән дә, нигә Фәрди монда чуала? Бармы аның намысы?

Яфир. Ул чуалмый. Фәрди эшли. Терлекчелек комплексы төзи.

Рамай. Нигә үз ишләре янында түгел?

Фәрди. Беренче курстан соң безне эшкә кирпеч заводына җибәрделәр. Сүз дә юк, эше авыр, тузан-пычрагы да җитәрлек. Унбер егет бардык. Икесенең әтисе профессор. Берсенеке генерал. Өч-дүрте тумыштан ялкау. Аларга нәрсәгә акча? Бер-ике сәгать эленке-салынкы йөриләр дә, чирәмгә кырын-ярын ятып, гитара чиртергә тотыналар.

Рахмай. Барыбыз да акча сугарга чыккан шабашчылар. Белмиләрме әллә безне?

Мәсәй. Фәрди тәрбиясендә биш бала барын да беләләрме?

Рахмай. Эне-сеңелләренең карточкасын караваты янына тезеп куйган. Беләләрдер.

Мәсәй. Аның атасының сукыр, Ватан сугышы инвалиды икәнен дә беләләрме?

Рахмай. Нигә мине йолкасыз? Яман хәбәрне мин таратмадым.

Яфир. Сабыррак сөйләшик.

Мәсәй. Менә мин семьябызда алты бала булганга укый алмадым. Җиденчене тутырдым да балта тотып эти белән төзелешкә чыгып киттем. Энекәшләрне эти белән икәү укыттык. Ә Фәрди миннән акыллырак: ул башлап үзе укырга, аннан туганнарын кеше итәргә тели.

Фәрди. Ярар инде, Мәсәй абый.

Рахмай. Нигә дип миңа бәйләнәсез?

Мәсәй. Бәйләнү икенче төслерәк була... Ишекләр йозакта. Димәк, монда Фәрдинең гаебе юк.

Фәрди. Онытмам, Мәсәй абый, араладың.

М ә с ә й. Зөлфәтнең безнең йортка килеп тәмсезләнеп йөрүен тыям мин.

Р а х м а й. Ай-һай, борчакны эредән чирттерәсең.

Я ф и р. Чаманы гына онытып җибәрмик.

Р а х м а й. Үз эшебезне генә белик! Менә миндә бер тәкъдим бар.

М ә с ә й. Гаделлек өчен тырышу кайда да безнең үз эшебез.

Я ф и р. Хәзер кайтсак та була. (*Тора.*)

М ә с ә й. Мин утырам әле.

Ф ә р д и. Рәхилә апаның кергәнен күтәсеңме?

М ә с ә й. Белмим, Фәрди.

Ф ә р д и. Яфир агай, машина килә!

М ә с ә й. Соңга калып булса да, балкаларны китерделәр.

Р а х м а й. Чукынды марҗа кыярга! Мин эш турында сөйләшергә ниятләгәндә генә...

Я ф и р. Бушатмый ярамый, егетләр.

М ә с ә й. Син, Яфир агай, ял ит. Үзебез башкарабыз аны.

Я ф и р. Киресенчә. Син үзең монда кал. Алар хәзер кайтырлар. Өйдәге хәлне ачыкларга кирәк. Болай яшәргә ярамый.

Чыгалар. Машина тавышы. Х а л и д ә керә.

Х а л и д ә. Кайтып киткәнсез дип торам. Хәерле кич.

М ә с ә й. Хәерле кич, Халидә. Исемегез белән дәшкәнгә ачуланмыйсызмы?

Х а л и д ә. Мин ачулана белмим.

М ә с ә й. Андый кеше булмый. Бар икән, ул кеше түгел. Кискенлегем өчен үпкәләмәгез.

Х а л и д ә. Бар андый кеше. Ул — мин. Рәхиләне көтәсезме?

М ә с ә й. Бүген сез дә миңа бик кирәк.

Х а л и д ә. Минем сезгә йомышым барын да беләсезме?

М ә с ә й. Ул чагында бигрәк әйбәт. Аңлашу җиңелрәк булыр.

Х а л и д ә. Сез Рәхиләгә шундый җиңел, шундый җыйнак агач тагарак чокып биргәнсез. Миңа да шундый кирәк иде.

М ә с ә й. Тагарак? Чучка баласы асрыйсызмы әллә?

Х а л и д ә. Безнеке пилмән ярата.

М ә с ә й. Аһ, шулаймыни? Галиҗәнаплары «безнеке» пилмән ярата икән! Приятного аппетита!.. Ит тарткычы сатып алсын.

Х а л и д ә. Ит тарткычы аша чыккан, тимер аша уз-

ган ит тәмле булмый, ди безнеке. Безнекенә каен тагаракта айбалта белән борынгыча тапаган иттән пешергән пилмән кирәк.

Мәсәй. Пилмәне алтын табакка салынган булсын! Алтын табакны асыл калфаклы Халидә белән Рәхилә җарияләр тотсын...

Халидә. Безнеке сезне «зәһәр кеше» ди.

Мәсәй. Пилмән ярата икән, каен тагаракны «безнеке» үзе чокысын. Рәхиләнең «безнеке»се юк.

Халидә. Хәерле булсын. Безгә мунча салырга тотынгач, шунда бер очтан чокып бирерсез әле.

Мәсәй. Нинди мунча? Кемгә? Нинди сүз бу, Халидә акыллым?

Рәхилә керә.

Халидә. Рәхилә ахирәт, менә бу абыйга «тагарак чокып бир» дигән идем, ачуланды.

Рәхилә. Аның ачуланмаган чагы юк, шуның өчен дөньяга яралган. Хәерле кич, Мәсәй.

Мәсәй. Саумы, Рәхилә. Дөньяга ник туганымны белмичәрәк йөри идем, рәхмәт, аңлатып бирдең.

Рәхилә. Белмәгән нәрсәләрең тагын бардыр. Беләсең, сорашасың киләдер дип, әйләнечтән юл туры, сезнең янга кердем.

Мәсәй. Сорыйсы нәрсәләр байтак җыелды.

Рәхилә. Безнең дә кайбер нәрсәләрне сорыйсы килә, иеме, Халидә?

Халидә. Әллә тагын... Миңа тагарак булса, шул җиткән...

Мәсәй. Мунча салалар дигән гайбәтне кем тарата, Халидә?

Халидә. Нишләп гайбәт булсын? Мин аны сез килгәнче үк белеп тора идем.

Рәхилә. Йә, ничек? Тәмлеме?

Мәсәй. Шулай икән. Килгәнче үк безне бүлеп-турап, айбалта белән тапап, суганлап-борычлап пилмәнгә тутырып куйдыгызмыни? Кабарга да йотарга гына калдымы?

Рәхилә. Кызма син, Мәсәй. Дөреслекне кызып якламыйлар.

Мотоцикл тавышы.

Мәсәй. Зөлфәт килә! Хәзер ачыклыйбыз аны. Халидә, качмыйсың.

Халидә. Мин кайта торыйм... Сезнең белән монда баш китәр.

Зөлфәт керә.

Зөлфәт. Перс, нәгъләт! Нигә тоткарлыйсың минем хатынны?

Мәсәй. Ул үзе белә.

Зөлфәт. Шулай диген, Мәсәй. Иптәшләр тирләп-пешеп эшләгәндә, чибәр-чибәр апалар белән чыжын-быжын уйныйм, диген?!

Мәсәй. Халидә безнең өскә гаеп ташлады. Хәзер шуны аңлатып бирсен. Менә синең күз алдыңда ачыкласын, бригадир.

Зөлфәт. Кирәк чагында аңлашырга аның ире бар. Халидә, юлны онытмадыңмы?

Халидә. Йөгердем, Зөлфәт. (*Чыга.*)

Рәхилә. Их, ахирәт...

Зөлфәт. Мәсәй, иптәшләрең эшли торсын, мин сине алырга дип кердем.

Мәсәй. Кая алып китәсең?

Зөлфәт. Үзебезгә кунакка. Хатын аш салыр. Тавык суяр. Ял итәрбез. Аз-маз эш турында гәпләшербез. Ялгызыңны туры китерә алмыйча йөри идем.

Рәхилә. Ә Халидәнең тутырган тавыгы, Мәсәй! Телеңне йотарсың.

Мәсәй. Тутырган тавыкны мин бик яратам!

Рәхилә. Күптән шулай диләр аны.

Зөлфәт. Син, Рәхиләкәй, Зөлфәтнең сүзе сүз булып калганын тагын бер тапкыр күр.

Мәсәй. Тутырган тавыкны минем иптәшләр дә бик ярата!

Зөлфәт. Иптәшләреңне күрергә өлгерерсең.

Рәхилә. Өлгерерсең, ишеттеңме?

Мәсәй. Безгә айры-чайры йөрү килешми. Мин коллектив белән яшәргә күнеккән. Пионер чаклардан ук...

Зөлфәт. Әйттең ич инде! Ну, иптәшләр... Ну, коллектив. Коллектив лидерсыз булмый.

Мәсәй. Яфир агай безнең бригадир.

Зөлфәт. Бөтенесе синең авызга карап торалар.

Рәхилә. Авызга дидеңме, явызга дидеңме?

Мәсәй. Аннан, шуны әйтмәкчемен, Зөлфәт. Без киткәч, теләсә нишлә, анысы синең намус эше, мәгәр без барында Нургаян апаларга аяк басасы булма. Мин моны байтактан һәм менә нәкъ Рәхилә алдында әйтергә җыенып йөрим.

Рәхилә. Ничек, ничек?

Мәсәй. Сүземне әйттем. Ошамаса, кичер, Рәхилә.

Рәхилә. Кеше тикшерергә синамы соң? Борын астыңны кара!

Мәсәй. Үз күз алдымда гаделсезлеккә юл куймам.

Зөлфәт. Ну, малай. Ну, әйттең! Ә син беләсеңме?..

Рәхилә. Зөлфәтнең ишегалдын барып кара! Күз буярга бер-ике бүрәнә белән кирпеч кыйпылчыклары китереп өйгән. Ә сез аңа мунча салырга килештегез. Чайкама башыңны, муеның авыртыр. Тулы хокуклы илчегез Рахмайның кыяфәтен үзем күрдем. Аннары син... син! Ару гына кешеме дип уйласаң, чит хатынга, сөяркәңә яшертен акча салып ятасың бит. Менә квитанциясе.

Зөлфәт. Әһә!

Мәсәй. Квитанцияне югалттым дигән идең.

Рәхилә. Аны гына аңламаслык хатын ди мин.

Зөлфәт. Син дә шул... Шундый кыйммәтле дәлилне моңарчы яшереп йөрдең.

Рәхилә. Дөреслек дигән буласың тагын, Мәсәй!

Чыгып йөгерә.

Зөлфәт. Йә. Хәзер ничегрәк сөйләшәбез, Мәсәй?

Мәсәй. Ничегрәкме?

Зөлфәт. Тутырган тавык ашап эш турында сөйләшәбезме, әллә?.. Ике арада усаллык калуын теләмим мин. Этләр өреп аңлашалар.

Мәсәй. Койрык болгап диген.

Зөлфәт. Һәр адәм баласында койрык бар. Күренми генә. Койрыгының кайда икәнен кеше үзе генә белә. Йә бот арасында була ул, йә югарыда, биектә...

Мәсәй. Мин синең ишеләргә, бригадир, мунча түгел, бәдрәф тә ясамыйм. Ишеттеңме?!

Зөлфәт. Чамала, Мәсәй! Син менә монда учымда утырасың!

Чыга. Мотоцикл тавышы. Бераздан, Яфирны ике яктан култыклап, Рахмай белән Фәрди керә.

Мәсәй. Ни булды?

Рахмай. Аягына балка төште.

Фәрди. Кыймылдатып карагыз, Яфир агай. Бу төштә авыртамы? Монда?

Яфир. Әлегә түзәрлек.

Фәрди. Хәзер миңа буйсынасыз, Яфир агай. Мин врач.

Рахмай. Җайсызрак тоттым шул, кулдан ычкынды да китте.

Мәсәй. Кичә син исерек идең, Рахмай абый. Өченче көн дә. Һәм син безнең иптәшлекне сатып эчкәнсең.

Рахмай. Бәла аяк астында йөри диләр шул.

Фәрди. Өч-дүрт көн ятырга туры килер.

Рахмай. Менә син агай...

Мәсәй. Эш өчен борчылма, Яфир агай. Синең өчен дә тырышырбыз. Ким дә булмас, начар да итмәбез. Ә Рахмай агайның ике көн эчеп йөрүен искә алып...

Яфир. Безнең иптәшлекне сатуын да шуңа теркәп...

Фәрди. Ике көн прогул ясады дип, табельгә язып куябыз.

Рахмай. Ак эт бәласен кара эткә ягасызмы?

Мәсәй. Шулай яшәргә кирәк. Гадел яшәргә. Кеше җилкәсенә басып ерак китеп булмый!

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук ишегалды. Кич. Өстәл янында Яфир белән Нургаян. Нургаян бәләкәй эскәмия чыгарып Яфирның аяк астына җайлап куя.

Нургаян. Эскәмиянең биегрәге дә бар, чыгарыйммы?

Яфир. Бик ипле булды, рәхмәт.

Нургаян. Фермага эшкә йөргән чаклардан калган эскәмия бу. Егылырга җитеп кайтыр идем дә аягымны кая куярга белмичә утырыр идем.

Яфир. Бик уңайлы булды. Фәрди сүзен сүз итеп кенә өйдә калдым бүген. Болай да җиденче көнем... Эшне тизләтәсе бар.

Нургаян. Кышка кая барасың инде?

Яфир. Кая булсын? Өйгә.

Нургаян. Өеңә кайтырга теләмәгән кук сөйләшәсең.

Яфир. Өй газиз... Тик өең кайда бит?..

Нургаян. Гел-гел читтә йөрү читендер?

Яфир. Җиңел дип кем әйтсен?.. Гел-гел өйдә тору да читен...

Нургаян. Мин моны аңламыйм.

Яфир. Аңламаска язсын. Нигезендә картаясың. Син бит минем хәлгә төшмәгән. Төшә күрмә.

Нургаян. Кәй яшәдеңме?

Яфир. Юк, яшәвемнән мең риза. Мәшәкатьле чо-

рыбызга да риза. Үткәннәрем өчен үкенмим. Үкенерлек яшәмәдем. Намус кушканча эшләдек. Безнең авыл зур түгел, бик үк бәләкәй дә димәссең, нибарысы йөз капка. Совхоз ясап эреләндерделәр дә безне җиде чакрымга, «Бүләк» дигән урынга күчерделәр. Ике катлы таш өйләрдә тора башладык.

Н у р г а я н. Мич ягып йөрү җәфасыннан котылгансыз икән.

Я ф и р. Анысы шулай, сүз дә юк. Тик кешеләр үтә тиз үзгәрешеп бетте. Сөйләп бирсәң, кызык икән ул крестьяннан китеп бетмәгән, рабучийга барып җитмәгән халык! Кояштыр! Моннан берничә ел элек яңа урынга күчеп килгән елны көз бик әшәке килде. Хәтереңдәдер, сентябрь буенча коеп түкте, октябрьдә дә иркәләмәде. Элек, колхоз оешкан чакларда, безнең авыл кар астында иген, яшелчә калдыру дигәнне белми иде. Кая сиңа калдыру! Вагы-төяге, саламы-кибәге белән берәмтекләп ташып бетерә торган идек. Менә берзаман совхоз рабучие булдык та куйдык. Ху-уш, мал асрасы юк, йорт-җир саласы юк, бәрәңге утыртасы юк... Мәшәкать бетте, вәссәлам! Шул көзне син күр дә мин күр! Кишәрлеге-кишәрлеге белән кишер-чөгендер, гектары-гектары белән кәбестә утырды да калды. Кышкы чатлама суыкларга хәтле кукуруз җилфердәде. Әллә кем икән ул рабучийга җитмәгән, крестьянлыгы бетмәгән халык! Соң гына торалар, сәгатькә карап кына эшлиләр, һәрберсенең беләгендә сәгать. Сәгать крестьянның күкрәгендә булырга тиеш югыйсәм. Төш авышуга таралалар да өй ышыгында домино шакылдаталар... Мин алай эшли алмыйм. Өйдән бизебрәк торам әле, Нургаян. Югыйсә, ел саен яңа урында яшәү дә читен.

Н у р г а я н. Син аларның үзгәргәнен көтәсеңме?

Я ф и р. Үләргә үк җыенмыйм. Көтәм. Матур эшли идек без, күмәк идек.

Н у р г а я н. Әллә ниләр сөйлисең син, Яфир.

Я ф и р. Тр-р, балавызың эреде түгелме?

Н у р г а я н. Нихәл итәсең, утыз биш ел бозау карадым, кулымнан сәнәк-көрәк төшмәде дисәм, хәзер кайберәүләр көлә генә.

Я ф и р. Көлдермәскә кирәк. Ирек бирмәскә!

Н у р г а я н. Кояшны уч белән каплап булмаган шикелле, тишек авызны томалап та булмый.

Я ф и р. Хак сүз белән томала тишек авызны. Тугры яшәп, пакь гамәл белән томала!

Н у р г а я н. Кыеп сүз әйтү дә читен инде кешегә.

Яфир. Сүз әйтерлек дәрәҗәгә ирешү кыен. Сүзне аны, ачуым да бер килмәгәе, Әнвәрия күршең дә әйтә!

Нургаян. Менә кая килеп җиттең. Сиздермичә генә мине әрлисең.

Яфир. Сиңа сүзем юк, һич, Нургаян. Изге син. Килененңә бер-ике сүз әйтсәң дә ярар иде.

Нургаян. Син олы кеше. Тимә аңа. Кагылма.

Яфир. Хөрмәткә лаеклы затны яклау гына хак эш.

Нургаян. Кеше турында сүз әйтергә ашыкмыйк. Менә мин дә сине белми идем. Комсыз бер акча капчыгы дип уйласам, сине шабашкылыкта бөтенләй башка сәбәпләр йөртә икән.

Яфир. Иртәрәк мактыйсың. Торыйк, эшлик. Киләсе елга да килеп чыгуыбыз бар.

Нургаян. Анысы ук булмас. Зөлфәт китертмәс.

Яфир. Авылыгызга алла да куйгансыз икән.

Нургаян. Идарә ерак. Авыл советы күрше авылда. Алла булыбрак калды шул.

Яфир. Артыгын табынасыз. Лаек булмаган бәндә кулына власть тапшырсаң, аннан яхшылык көтмә инде. Менә Рәхилә дә аңа табына сыман.

Нургаян. Киленне кыерсыту җиңел аны хәзер.

Яфир. Бетте, бетте... Өч-дүрт көн күзгә-башка күренми...

Нургаян. Җәйләүдә куна кала.

Яфир. Алай икән, алай...

Әнвәрия керә.

Әнвәрия. И-и, сездә берәр кызык ишетермен дип керсәм, сездә дә кадер киче икән.

Нургаян. Эш бетте, көлтә җыясы гына калды.

Әнвәрия. Синең шулай... Әллә ничек җайлыйсың үзен! Утыным китерелмәгән, печән әзерләнмәгән, лапас түбәм ябылмаган. Әле радиодан бер чибәр абый сөйләде. Авылларны бетерәбез, тамырын корытабыз, ди. Кырын ятып кына радио тыңлар көннәр булырмы бер.

Яфир. Кырын ятып туймадыңмы син?

Нургаян. Тормыш шуңа таба бара икән, туктатып булмас аны, Яфир. Безнең дә чак кына булса да заманча яшәп каласы килә бит.

Әнвәрия. Әллә һаман эшләтер идеңме?

Яфир. Кушып эшләтүдән ни файда? Кешенең җаны эшкә сусап торсын.

Әнвәрия. Безнең авылны Казан тирәсенәрәк күчер-

сеннәр иде. Театрга йөрер идек. Анда бит шундый чибәр абыйларны кәмит итеп күрсәтәләр, көлә-көлә эчең катып бетәр. Хәер, театрга йөрергә юньле күлмәге дә юк бит анының. Әйт әле Рәхиләңә, алдынгыларга өләшкәндә киңәшмәдән бер шәп күлмәк алып кайтсын.

Нургаян. Әле авылны күчерәбез дигәннәре юк.

Әнвәрия. Әллә матай тавышы инде?

Яфир. Шулай бугай.

Әнвәрия. Яратмыйм шуның үкерүен. (*Чыга.*)

Яфир. Зөлфәт булса, килмәскә тиеш иде ул монда.

Нургаян. Сез аңа берәр сүз әйттегезме?

Зөлфәт керә.

Зөлфәт. Көтмәвегезне яхшы беләм.

Нургаян. Салкын су чыгарыйммы?

Зөлфәт. Кирәкми... Чистай малае чыгар син миңа. Сыйлачы бер, Нургаян түти. Суны мин аны юри генә сорый торган идем.

Нургаян. Мамадыш камчысы кирәк сиңа. Лаеш шулпасы эчертергә кирәк.

Зөлфәт. Аякка көч кердеме, гайрәтле Яфир агай?

Яфир. Акрынлап рәтләнә.

Зөлфәт. Ә минем хәл.. Тиз-тиз начарлана бара.

Яфир. Әле эшләрбез, Зөлфәт.

Зөлфәт. Сиңа бу дөньяда ни кирәк тагын? Нигә өеңдә генә утырмыйсың?

Нургаян. Тупас телле син, Зөлфәт.

Зөлфәт. Фельдшер кердеме? Аны мин җибәргән идем. Кирәксә районнан врач китертәм. Момент!

Яфир. Безнең үзебезнең врач ышанычлы.

Зөлфәт. Әле ул врач булганчы! Пешмәгәннәр әле алар, яшелләр. Синең янда алар тфү! Төкерек! Менә син — алтын кеше. Килүгә сизендем, яныңа килергә кыюлык җитмәде. Әйдә, Яфир агай, безгә!

Яфир. Килгәннән бирле безне сагалыйсың. Нигә яманлык белән эш майтарырга телисең? Коралың аракы, мәкер, хәйлә булды. Кеше төсле юньләп сөйләшсәң ни булыр иде?

Зөлфәт. Шулай ук булдымыни? Белмим.

Яфир. Кешеләргә ышанмыйсың син. Яхшылыкка ышанычны югалткансың. Чынлык юк синең өчен.

Зөлфәт. Сезгә ышанып ерак барырсың.

Яфир. Аңлат.

Зөлфәт. Мәсәй Рәхилә артыннан сөйрәләме? Минем

хатынны котыртамы? Семья боза! Бөтен җирдә йозак. Йөз тәңкәдән артык акчаны кайсыгыз сукты?

Н у р г а я н. Җир бит икәнсең, абау. Оятсыз!

З ө л ф ә т. Килененңне генә кара! Әгәр син оят белә торган булсаң, әллә кайчан мине куып чыгарыр идең.

Я ф и р. Әле соң түгел. Яле! (*Торып баса.*) Ычкын моннан. Сыпырт.

З ө л ф ә т. Аягың аксак чак. Күрсәтер идем мин сиңа! Нургаян ти, бу килмешәкләр килер дә китәр. Алар чамасына да чарасы табылыр. Шуны онытма. (*Чыга.*)

Я ф и р. Яхшылыгың аркасында никадәрле яман сүз ишетәсең.

Н у р г а я н. Хәзер әйтми калырга ярамый. Киленем ни кыланса да, авыз ачып әрләргә йөрәгем кушмый. Улым начар иде минем, Яфир агай! Көне-төне санаусыз эчте. Оятын, намысын, хатынын онытып эчте. Эчте дә көнләште, туктаусыз җәберләде. Беркемгә серен чыгармады киленем, түзде, сарыга сабышса да зарланмады. Ире кием-салым алдырмады. Фермадан туптуры өйгә йөгерде. Чөнки биш минутка соңга калса, өйдә җәнҗал чыгасын белә иде. Улым кадерле булса да, берни эшләтә алмадым. Зөлфәт җылан ул, үзе эчмәсә дә улымны аракы эчәргә шул өйрәтте, шул явыз үгетләде. Каһәр суккан аракы-явыз җитте улымның башына. Эчкән килеш шартлады бит ул. Элекке замаларда эчкән кешене зыяратка күмдермиләр иде. Хәзер исә эчкәннәрне аерым күмә башласаң, олырак зыярат кирәк булыр. Ат караклары белән рәттән зыярат читенә ташлыйлар иде мөртәтләрне. Улым киленемне шулай җәберләде, хәкарәт итте ки, рәхмәт Рәхиләгә, данымызны сатмады, минем белән бергә түзде, бергә чыдады. Ире үлгәч кенә чәчәк атты шул бала, иркен сулыш алды.

Я ф и р. Нинди олы фаҗига!

Н у р г а я н. Рәхиләгә төс кунды дип ире үлгәч кенә әйттеләр. Моннан да олы хурлыкның булуы мөмкинме?.. Йә, шул балага кыеп сүз әйтә аламмы? Юк бит, авылда юньле бер кешесе юк бит аның. Җитмәсә арага Зөлфәт килеп кысылды. Иренең иптәше булгач, башта юатып йөрде, таш куйдырышты. Баксаң, эче тулы мәкер икән.

Я ф и р. Әнвәрия түбәмнән су үтә дип зарлана. Әллә бүген җимереп, иртәгә түбәсен ябып бирәсе инде? Җимерәсе дә, төзисе дә килеп китте.

Н у р г а я н. Картаймассың әле син, Яфир!

Я ф и р. Әһә, безнекеләр кайтты.

Р а х м а й белән Ф ә р д и керәләр.

Н у р г а я н. Мәсәбих кайда?

Ф ә р д и. Су керәм диебрәк калды.

Н у р г а я н. Тәгаен шулаймы?

Я ф и р. Дөресен әйтегез.

Р а х м а й. Безгә әйткән кадәресе шул. Күзе җәйләү юлында иде.

Ф ә р д и. Алтынчы блокны күтәреп бетердек, Яфир агай. Синең хәлләр шәпме?

Я ф и р. Булдыргансыз, егетләр. Минем хәл дә ярыйсы. (*Йөреп күрсәтә.*) Ничек?

Н у р г а я н. Мәсәбих кына кайтмаган...

Я ф и р. Болайга киткәч, мин дә бер серне ачыйм, Нургаян туган. Мәсәй өйдә булса сөйләтмәс иде.

Р а х м а й. Соңыннан давылы булмасмы, Яфир агай? Мәсәйнең талкан коры.

Я ф и р. Мәсәйнең энисе, хатыны һәм ике яшьлек кызы җир тетрәгәндә һәлак булган.

Н у р г а я н. Миңа «кардәш икәнбез без» дигән иде шул.

Я ф и р. Хәзер менә урын таба алмый, җаны янганга ил гизә. Урта Азиягә дә барып чыга. Бар тапкан акчасын җир тетрәгәндә ятим калган балалар хакына детдомга салып тора.

Н у р г а я н. Рәхиләне генә алып кайтыймчы?

Я ф и р. Алып кайт, Нургаян. Булмаса булган икән, ал да кайт.

Ф ә р д и. Ур-ра! Яфир агай йөгерә үк башлады.

Я ф и р. Картаерга ирек бирмисез бит, матур кешеләр.

Ф ә р д и. Әнә алар, икәү кайтып киләләр.

Н у р г а я н. Рәхиләме, чын?

Я ф и р. Егетләр, бик арымадыгызмы? Хәлегез булса, әйдәгез Әнвәриянең черек түбәсен каерып ыргытыйк бүген.

Р а х м а й. Фәрди батыр риза булса, мин барам.

Я ф и р. Акча өметләнмәскә. Яртыны сорамаска. Күрше хакы итеп. Ятим солдатка итеп.

Ф ә р д и. Монда да каласы килә... Әйдәгез!

Нургаян, кабаланып, өйгә кереп китә. Яфир, Рахмай, Фәрди чыгып китәләр. Пауза. Музыка. Р ә х и л ә, М ә с ә й керәләр.

Р ә х и л ә. Әни, көн туды исә, «син Мәсәйне белмисең шул, Мәсәбихны белмисең», диергә тотына.

М ә с ә й. Ни әйтергә тели икән аның йомшак күңеле?

Р ә х и л ә. Аның теләге билгеле... Мине бәхетле итеп күрәсе килә. Нигә әйтеп бетермисең, Мәсәй? Ни булды Урта Азиядә?

М ә с ә й. Чын дөресен берәүгә дә сөйләгәнем юк, Рәхилә.

Р ә х и л ә. Кешедән яшерерлек булгач, нинди дөреслек ди инде ул?

М ә с ә й. Йөрәк кыйналмаса, газапланмасам, башкалардан яшереп акча салып йөрер идемме?

Р ә х и л ә. Бәлки, дөресне тыңларга теләгән кешене моңарчы очратмагансыңдыр?

М ә с ә й. Хатыным белән әйбәт яшәдек. Татарстан кызы иде. Арча ягыннан. Менә шул. Ул чакта мин ГРЭС төзелешендә балта остасы булып эшли идем. Бер нормировщица кыз күз атып йөри башлады. Күз дә ата бу, сүз дә сала. Эчтән генә көлемсерәп йөрим.

Р ә х и л ә. Тәбесенә төшердеме?

М ә с ә й. Берзаман икенче сменада идек, соң гына, инде кайтырга дип торганда, цехка теге кыз килеп кермәсенме? «Кинога калган идем, соңладым, озатып куйчы»,— ди бу. Киттем тегеңә ияреп. Шундый җылы, тымызык төн. Бара-бара арык кырына утырдык. Сумкасыннан шәраб чыгарды бу, тегесен-монысын... Эчкәндәй иттек. Шуннан үземә үзем шаккатып утырам. «Нигә болай соң йөри бу кызыкай? Ник озатып йөрим мин аны?» дим. Ашыктыра башладым. Җәһәннәм астында яши икән. Барабыз, барабыз... Шуннан ни булганын хәтерләмим. Зилзилә, җир тетрәү икебезне дә юлдан тотып чөйгән. Юлдан байтак читтә, канауда аңыма килдем. Бөтен тирә-як караңгылыкка чумган, шомлы тынлык. Кинәт җылый-җылый этләр өрә башлады. Андасанда ялкын телләре күтәрелде. Атом сугышы башланып, калабызга бомба төште дип торам. Тагын җир гүли башлады, шунда гына җир тетрәвен, үзебезнең исән калуыбызны аңлап алдым. Кыз өенә чапты, мин үзебезгә йөгердем... Тик соң иде инде. Үземнекеләрне таш җимерекләр арасыннан тәүлек узгач кына казып чыгара алдым.

Р ә х и л ә. Берәрсе генә дә исән калмаган икән.

М ә с ә й. Мин кайтып өлгерә идем бит!

Р ә х и л ә. Бергәләп үләргәме?

М ә с ә й. Исән калалар иде алар. Ишегалдына чыгып

йоклаган булыр идек. Андагылар исән калды. Ни үкенеч!

Рәхилә. Синең турыда начар уйлавым өчен кичер.

Мәсәй. Синең турыда икеле-микеле уйлаганым өчен ачуланма.

Рәхилә. Мин Халидәнең сыерларын алмадым.

Мәсәй. Вәгъдәңне ничек үтәрсең?

Рәхилә. Үз сыерларым белән дә үтәп чыгармын төсле, Зөлфәт кенә аяк чалмасын. Мин, Мәсәй, ничектер, җиңеләеп киттем. Адымнарым җиңел. Барын да булдырырмын төсле.

Мәсәй. Халидәнең хәле кыен.

Рәхилә. Ул хәзер безгә килергә тиеш.

Мәсәй. Нигә?

Рәхилә. Бөтенләйгә.

Мәсәй. Син шулай киңәш иттеңме?

Рәхилә. Нигә алай дидең?

Мәсәй. Китү өчен йөрәк кирәк бит, көч. Син «Көчәеп киттем!» дидең. Халидә дә көчәйгәнме, анысын белмим.

Рәхилә. Шулай диде, мин аны куәтләдем.

Мәсәй. Инде нишләргә уйлыйсыз?

Рәхилә. Бирешмәскә теләк. Сез барында көчле икәнлекне исбатлый алсак, аннан үзебез дә бирешмәбез. Аннан, бәлки, безне бөтенләй үк ташламассыз?

Мәсәй. Дөрес уйлыйсың, Рәхилә. Дөрес сөйлисең.

Пауза.

Рәхилә. Тагын нәрсә?

Мәсәй. Күзең үткен. Сизәсең. Күңелең саф — аңларсың.

Рәхилә. Әнвәрия түтинең түбәсен җимереп бетереп киләләр. Тукта әле, нигә син булышырга кермисең?

Мәсәй. Иптәшләр барыбер кире борыр иде.

Рәхилә. Рәхилә белән сөйләшсен өчен?

Мәсәй. Әйе. Рәхилә белән аңлашсын өчен.

Рәхилә. Элек тә фатирларда торгансыз. Элек тә шулай итәләр идеме синең сизгер иптәшләрең?

Мәсәй. Бервакытта да алай эшләмәделәр. Чөнки Рәхилә дөньяда бер генә, берәү генә.

Рәхилә. Акыллы кешеләр синең иптәшләрең.

Мәсәй. Тугры дуслар.

Рәхилә. Менә Халидә килеп тә җитте.

Мәсәй. Бүген ул чак кына ашыккан.

Рәхилә. Шулай дисеңме?

М ә с ә й. Без барын да сөйләшеп бетерә алмадык.

Р ә х и л ә. Иң кирәге әйтелде бит, Мәсәй. Син иң кирәген әйттеңме?

М ә с ә й. Мин синең җавапны ишетмәдем.

Х а л и д ә керә.

Х а л и д ә. Килеп җиттем.

Р ә х и л ә. Без сине көтә идек, дустым.

Х а л и д ә. Мәсәй дә көтәме?

Р ә х и л ә. Авылда Мәсәй белмәгән ни-нәрсә калды хәзер?

М ә с ә й. Бер мөһим нәрсә бар әле, Рәхилә.

Р ә х и л ә. Нигә аны телдән әйтеп торырга?..

Х а л и д ә. «Баланы калдырып торам» дигәч, әнкәй егылып китә язды. «Шундый ирне ташлагач, сиңа кем кирәк?» дип әрли.

Р ә х и л ә. Шул кирәк ул кара йөзгә, димәдеңме?

Х а л и д ә. Алай дип тә карадым, әйтмәгәнем калмады. Шуңа озакладым. Чыгармый. Кияү килеп алсын, ди. Мин әйтәм, синең ише куштаннар барында ул мине җиңәр, димен. Теләктәшләр кирәк миңа, дидем.

Р ә х и л ә. Алары кем дип төпчендеме?

Х а л и д ә. Төпченмәгән кая!

Р ә х и л ә. Безне әйттеңме?

Х а л и д ә. Артыгын да ычкындырдым бугай. Бер яктан бала җылый. Аны көч-хәл белән йоклаттым. Икенче яктан әнкәй быжлый. Чак кире уйламадым. Көчсез мин, Рәхилә, җебегән. Эрим дә агам. Ничек гомер итәрмен, ничек тамак туйдырырмын дип баш ватам.

Р ә х и л ә. Өйрәнербез. Эшләрбез. Бергә-бергә. Ферма комплекслары Зөлфәт өчен салынмый, онытма. Безнең киләчәк көн өчен салына. Шулаймы, Мәсәй?

М ә с ә й. Бу мәсьәләне үзегез хәл итегез.

Р ә х и л ә. Син аннан курка башладыңмы?

М ә с ә й. Юк. Курыкмыйм.

Я ф и р, Ф ә р д и, Р а х м а й керәләр. Аларга Ә н в ә р и я ияргән.

Ә н в ә р и я. Аштан олы булдыгызмыни? Самоварым җырлап утыра, чәемне эчмәдегез.

Я ф и р. Җимергәч эчмәсәк тә ярый. Төзегәч баш тартмабыз!

Ф ә р д и. Безне бу табын ашыктырды, Әнвәрия апа.

М ә с ә й. Тиз тоттыгыз.

Н у р г а я н самовар чыгара.

Н у р г а я н. Җыелыштыгызмы, кунаклар? Килен... Утырышыгыз әйдә.

Р а х м а й. Әнвәрия, утыр.

Ә н в ә р и я. Әллә мине дә кыстыйсыз?

Р а х м а й. Үз яныма утыртып, тәмләп бер сыйлыймчы.

Ф ә р д и. Нургаян апа, бу бавырсакмы?

Н у р г а я н. Хәзинәмдә нием бар, һәммәсе сезнең өчен.

Ф ә р д и. Яшәсен Нургаян апа.

Я ф и р. Без дә яшик дип өстә.

Х а л и д ә. Әнвәрия апа, салам түбәңне каерып аткач, очыгыз тагын да ямьләнгән.

Ф ә р д и. Халидә апа нигә читтә тора?

Я ф и р. Кил, кил, Халидә.

Х а л и д ә. Китсәнә, шултиклем ир-ат арасына кереп утырырга.

Р а х м а й. Җәмәгать! Гайбәт таратырга җай бар икән монда. Без сигезәү. Бөтенесе парлы-парлы, мин генә йөрим зарлы.

М ә с ә й. Юкны юрама, Рахмай абый.

Я ф и р. Ашны олылап чөкердәшеп утырыйкчы бер.

Р ә х и л ә. Җитешеп калыгыз, Фәрдинең утыз ике ташлы тегермәне тарта башлады.

З ө л ф ә т керә. Башта аңа берәү дә игътибар итми. Бер-берсен кыстышып утыралар. Халидә аны абайлап китәргә талпына.

Р ә х и л ә. Утыр. Кузгалма. Табынның ямен җибәрмә.

З ө л ф ә т. Туй икән монда. Мөбарәк булсын! (*Табынга акча китереп сала.*)

Р ә х и л ә. Ал акчаңны, Зөлфәт.

З ө л ф ә т. Үз акчагыз. Сорамыйча гына бурычка алган идем.

Я ф и р. Шушындый тату мәҗелескә дә усаллык белән кердәсең, Зөлфәт.

З ө л ф ә т. Зөлфәткә ни булган?

М ә с ә й. Зөлфәт тормышында зур үзгәрешләр барын табындагылар белә. Син үзең белеп бетерәсеңме икән?

З ө л ф ә т. Миңа акыл өйрәтергә соңардыгыз.

Ф ә р д и. Яман чир йоккан бригадирга.

Р а х м а й. Аңлашыла.

З ө л ф ә т. Син! Чабата калыбы! Минем аракыны чөмергәндә ни сайраган идең.

Р а х м а й. Аерма мине иптәшләрдән. Гомеремдә бе-

ренче тапкыр диярлек рәхәтләнеп, оялмыйча утырам. Аракы акчаңны почта аша салырмын. Барыбер бер таптырырсың.

Нургаян. Йөрмә монда, Зөлфәт.

Зөлфәт. Хатынымны гына алам да китәм.

Халидә. Кайтмыйм. Юк.

Зөлфәт. Бу дөньяда мине яклаучы берәү дә калмадымыни?

Мәсәй. Бу дөньяда синең кебекләр, синең кебекләрне тудыручылар һәм яклаучылар бетә барган саен безнең халыкка шәбрәк булачак.

Яфир. Илгә җиңеллек киләчәк!

Нургаян. Дөрес.

Рәхилә. Әйе, Мәсәй. Шулай икән.

Мәсәй. Күрәсең: сине аңлаучылар күп, яклаучылар юк!

Пәрдә.

*1972—1973*
*Казан*

# Сары чәчәк ата көнбагыш...

*3 пәрдәле героик драма*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Фролов Федор Максимович — Паратскида комячейка председателе.
Хәлил — тимерче, коммунист.
Вилдан — судно ремонтлау мастерскоенда слесарь, коммунист.
Кириллов Михаил Петрович — инженер, сул эсер, максималист.
Анна — монашка, керәшен кызы.
Лиза — монашка, керәшен кызы.
Анакай — Зөя утравында хатын-кызлар монастыренда башлык.

Вакыйга 1918 елның җәендә Паратскида һәм Зөя утравында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Идел яры. Кич. Су өстендә ара-тирә утлар ялтырап китә. Сирәк-мирәк булса да атыш тавышлары яңгырый. Еракта кемдер «аһ-ай!» дип кычкыра да тына. Вилдан ялгызы. Иске көймә кәмәше кырына яткан да акрын гына җырлый. Билендә кылыч.

Вилдан. Карадагынай урма-а-ан!.. Караңгы-ы тө-ө-өн!
Яхшый атлар кирәк үтәргә-ә-әй!..

(*Шул сүзләрне кабатлый-кабатлый яр астына төшеп менә.*) Карадагынай урма-ан! Караңгы тө-ө-өн! (*Сөйләнә.*) Әһә, караңгы төн шул, кап-караңгы... Атларның да кәттәсе кирәк. Йөгереге.

Хәлил керә.

Хәлил. Сәлам Вилдан агайга.
Вилдан. Исәнлек-саулыкмы?
Хәлил. Ничек дисәм дөрес булыр икән?
Вилдан. Ай-һай, чибәр киенгән син.
Хәлил. Аптыраганнан, Вилдан агай. Федор Макси-

мович чакыртты да, фәлән-фәлән вакытта, Идел буенда, Вилдан агаң катында бул, диде. Нигә, нәрсәгә — әйткән кеше юк. Төнгә каршы булгач, алай яшертен дә булгач, киендем менә. Янәсе, балыкчы дип белсеннәр. Үзең дә кылычны тагып җибәргәнсең.

В и л д а н. Эшче кешегә хәзер коралсыз шаг атларга ярамый.

Х ә л и л. Килдем. Шуннан нәрсә?

В и л д а н. Суалчаның да бармы?

Х ә л и л. Камыр алган булдым.

В и л д а н. Юк, хәзер камырга чиртми балык. Әйдә, утырып җибәр. (*Җырлый.*) Карадагынай урма-а-ан! Караңгы тө-өн!

Х ә л и л. Куйчы, агай, билгә корыч кылыч таккач шушы җырны җырлап йөриләрме?

В и л д а н. Җүләр. Җыр тыңлый белмисең икән син. Саңгырау. Менә тыңлап бак. Тыңла да — аңла. Җыр бит ул, җаным, сер. Аны тыңлый белергә генә кирәк. Җыр — борынгылардан калган хикмәт. Хикмәт булмаса, кем аны сиңа-миңа китереп җиткерер иде? Җыр ул, ай-һай, чор киртәләрен дә үтә белә. Менә тыңла син. «Кара урман» дигән. «Караңгы төн» дигән. Әйтче миңа: кара урманны егет нигә кара төндә кичә? Ә-ә, танавына бетчә чыккыры! Шул шул, якты көздә ярамый. Ә, өзеп әйтик, яхшы атлар, аргамаклар нигә кирәк аңа? Кара төндә чабышка чыкканмы?

Х ә л и л. Яхшы ат — канат, аргамак ир-егеткә тансык.

В и л д а н. Куа баралар аны. Куалар! Явызлар, кара йөрәкләр куа чыккан. Ә ул, батыр егет, мөгаен генә, йә карун алпавытны кискән, йә капкорсак ишанга кызыл әтәч җибәргән.

Х ә л и л. Кара син... Чыннан да шулайрак икән.

В и л д а н. Моңайттым, ахры, сине?

Х ә л и л. Әнкәйдән хат алдым бүген. Бер кайтып килер идең, ичмасам, ди. Күрше кызы Айсылу үсеп җитте, гел сине сораша, ди. Мин авылдан киткәндә сәке астында уйнап калган бала, хәзер менә буйга үсеп җиткән, диген. Әнисенә охшаса, өздерерлек булгандыр, чын. Әнисе, Хәтимә апа, гаҗәп уңган, чибәр хатын иде менә.

В и л д а н. Нигә кайтып килмисең соң? Кайт, әнкәңне куандырып өйләнеп җибәр. Ялгызың чиләнеп ятасың.

Х ә л и л. Җае чыкмый, Вилдан агай. Башта революция ясадык. Хәзер заводны худка җибәрергә дип йөрибез. Тәүлекләр буе цехтан чыккан юк. Менә эшләр бераз җайлансын инде. Заводны худка җибәрик. Кайтам

әле бер, кайтам. Әнкәйгә чуклы читле шәльяулык алып куйдым.

Вилдан. Ә Айсылуга?

Хәлил. Карарбыз анда! Чибәр дә булса, мине өзелеп яратса, Айсылуга бер пар чиләк ясап бирербез. Эче кояш, тышы ай булыр. «Көянтәсе-чиләге, үзе кура җиләге!» дип җырларлык булсын. Тукта әле, Вилдан агай. Федор Максимович, ячейка председателе, мине монда җыр тыңларга җибәрмәгәндер бит?

Вилдан. Анысын инде, Хәлил Туганаем, сине нигә җибәргәннәрдер, мин дә белмим.

Хәлил. Ничек?

Вилдан. Борыны тишек. Шулай. Миңа да шундый-шундый урынга, фәлән-фәлән сәгатькә килергә кушылды. Яныңа Хәлил килер, диделәр.

Хәлил. Алай. Бүген сменадан берәүне дә кайтарып җибәрмәделәр. Кемне кая! Атлашкинода кораллы бандитлар тимер юл күперен шартлатканнар. Телефон чыбыкларын өзеп бетергәннәр. Элемтәгә киткән Зуевны, беләсең ич, слесарь, шуны суеп, ияренә аркылы салып җибәргәннәр. Тирә-як авыллар белән элемтә юк.

Вилдан. Кичә төнлә Идел күперен шартлатырга да маташканнар ди түгелме?

Хәлил. Илле кешелек кораллы отряд һөҗүм иткән. Артларыннан алты тартма динамит калган.

Вилдан. Коралын каян алалар диген? Өченче көн базар аша узып барам, каршыма шалама гына бер хәерче килә. Яхшылабрак карасам, энекәй генәм, Кабачище авылы кулагы Мамалыгин.

Хәлил. Якасыннан эләктереп алдыңмы?

Вилдан. Алдырыр! Үзе генә түгел, тагын өч-дүрте ияргән. Барысы да тазалар, күмешкә чөмереп чыкканнар ахры, бүртенешеп беткәннәр. Берсенең итәк астыннан маузер ялтырап китмәсенме! Алай-болай патруль чакырганчы эзләре суынган мөртәтләрнең. Кылычын түгел, мылтыгын алыр идем дә, юк бит, корал юк, диләр.

Хәлил. Әйе, бандитлар котырыналар. Ә без эшчеләрне юньләп коралландыра да алмыйбыз.

Вилдан. Корал булса, Мамалыгин таш капчыкта бет симертә иде хәзер. Болай башың ват хәзер — Идел күперен шартлатучылар арасындамы ул, әллә Зуевны үтереп җибәрүчеләрнең берсеме? Тик ята торганнардан түгел, агасы Зөя утравында икмәк кибете тота. Иген, балык белән сәүдә итә.

Х ә л и л. Самарада чехлар! Шуны сизенәләр. Тукта әле, нишләп монда бер эшсез утырабыз әле без?

В и л д а н. Кирәккә, Хәлил энем, приказ шундый. Приказның асылын исә ячейка белдерер. Ашыкма. Кемдер килә. Әйдә, яшереник.

Х ә л и л. Безгә кирәкле кешедер, бәлки? Берәр хәбәр әйтмәсме?

В и л д а н. Бу ни бит, теге...

Х ә л и л. Кем, кем?

В и л д а н. Бир кармакларны. Яшер кылычны!

Кылычны көймә астына тыгалар. Кармак җепләрен сүтәләр. К и р и л л о в керә.

Х ә л и л (*аны күрмәмешкә салышып*). Җебе чуалган моның, Вилдан агай.

В и л д а н. Сал әйдә! Балык кап, яр башында ялтырап ят.

К и р и л л о в. Чү, мине эләктермәгез. Хәерле кич.

В и л д а н. Саумысыз, чибәр гражданин.

К и р и л л о в (*утырып*). Уф... Сез заводтан бит? Әйе, таныйм. Большевиклармы?

Х ә л и л. Большевикларга балык ашау хәраммы әллә?

К и р и л л о в. Мин алай димәдем. Уф, сменадан кайтып барышым. Сез дә ял итәсез икән.

В и л д а н. Балык тотып булмасмы дигән идек.

К и р и л л о в. Яр астында сезнең көймәме?

В и л д а н. Безнеке булса ни әйтерсең?

К и р и л л о в. Кемнедер көтәсез, димәк. Рәхәт икән монда!

Х ә л и л. Көтсәк нәрсә?

В и л д а н. Иптәш килергә тиеш. Балыкка өчәү җыенган идек. (*Хәлилгә ымлый.*) Тс-с...

К и р и л л о в. Патшаны төшердек, ирек алып бирдек, хәзер сезне көн-төн эшләтәбез. Зарланмыйсыз да, ә?

В и л д а н. Без бит, чибәр гражданин, ирекне үзебез алдык. Мәшәкатьле, авыр ирек буласын белеп алдык.

К и р и л л о в. Яхшы, яхшы... Бәхәсләрдән, сүзләрдән, дискуссияләрдән арылган. Ялгыз каласы килә. Хушыгыз. (*Чыга.*) Кылычны көймә астыннан алсагыз да була, конспираторлар!

Х ә л и л. Күзләре яман елтырый бу бәндәнең.

В и л д а н. Ә син аны беләсеңме?

Х ә л и л. Белмичә. Сезнең цехтан инженер, буржуй.

В и л д а н. Сул эсерлар ячейкасының рәисе булыр бу

кеше. Кириллов атлы. Нишләп йөрер ул монда? Көймә турында сорады, кылычны күреп алды. Нигә?

Хәлил. Көймә турында син миңа берни әйтмәгән идең.

Вилдан. Нигә үзең абайламадың?

Хәлил. Мин бит дус янына килдем.

Вилдан (*кылычын алып, биленә тага*). Миңа да бит көймә хакында сүз әйтергә кушылмаган. Миңа «Хәлил килер» диелгән, и все. Киңәшем шул: вакыты җитмичә сорашма, кирәкмәгән сүз ычкындырма. Тиккә иснәнми бу эсер! Ардым дигән була, үзе яшь этәч күк күкрәгән киергән. Ә син шулай текәлеп авылыңны, Айсылуны карыйсыңмы әллә?

Хәлил. Зөя утравын карыйм.

Вилдан. Күренәме соң?

Хәлил. Чиркәү гөмбәзләре шәйләнә. Өй түбәләре.

Вилдан. Булганың бармы анда?

Хәлил. Юк.

Вилдан. Кара, кара. Байгуралар оясы ул. Ике йөз кибет кенә бар анда. Ирләр монастыре, хатын-кызныкы. Шөпшә оясы! Шунда үтерделәр безнең өч большевикны. Көпә-көндез. Урам уртасында. Халык алдында. Танауларына бетчә чыккыры.

Хәлил. Тагын кемдер килә!

Вилдан. Бусы безнең кеше. Федор Максимович, без монда.

Фролов керә.

Фролов. Егетләр, шәпме?!

Вилдан. Көтә-көтә арыдык, Федор Максимович.

Фролов. Тиз генә ычкынып булмады.

Хәлил. Тагын күңелсезлекме, Федор Максимович?

Фролов. Гадәттән тыш! Троцкийдан телеграмма алынды. Заводны ябарга, эшне бөтенләй туктатырга боера.

Хәлил. Ничек? Безнең Паратск заводын ябаргамы?

Вилдан. Ничек алай? Корал юклыктан җәфа чигәбез. Инде ныгыйбыз, Идел флотилиясенә сугышчан корабльләр чыгарабыз дип торганда заводны ябаргамы? Самарада ак чехлар!

Фролов. Коммунистик ячейка исеменнән Владимир Ильичка телеграмма суктык. Эшчеләрнең күпчелеге, менә сезнең кебек үк, Троцкий директивасына капма-каршы фикердә тора, заводны ябу белән катгый риза түгелләр, дидек.

Вилдан. Питердан чыккан кәрванның язмышы ничек?

Фролов. «Ижорец»ны көтәбез. Безнең чама буенча, бер-ике көннән алар монда булырга тиеш иде дә... Телеграмма алдык, кәрван Чабаксарны узган. Әмма Троцкий директивасы нигезендә кәрван да кире Питерга борылырга тиеш.

Вилдан. Безне чалып егалармы шулай итеп?

Фролов. Шулайрак. Кәрванны күз текәп көтеп торабыз. Анда корал, запчастьләр, станок-приборлар.

Хәлил. Троцкий шуларны кире бора диген. Менә сиңа нарком военмор!

Вилдан. Танавына бетчә чыккыры.

Фролов. Ул гына да түгел. Бүген-иртәгә акларга каршы сугышка китәргә тиешле «Дельфин», «Ольга», «Сережа» судноларын гади транспортка әйләндереп, сүтелгән заводның җиһазларын төяп, Питерга озатырга боера. Заводның байлыгы чехлар кулында калмасын дип тырыша, янәсе.

Хәлил. Нигә алай? Сугышсыз-нисез шәһәрне, заводны ак чехларга тапшырыргамы?! Булмас!

Вилдан. Безнең «Дельфин»ны?! Ай ярым чыкмадым мин аннан! Федор Максимович! Корал! Бирегез корал! Судноларны әзерләп өлгертәбез. Корал табыгыз! Танауларына бетчә чыккан ак чехларны кырып себерәбез.

Хәлил. Заводны бирмибез!

Фролов. Мәсьәлә гаять катлаулы. Заводта ике хуҗа. Сул эсерлар ячейкасы Троцкийның директивасын көтеп кенә торганмыни, шундук күтәреп алды. Без заводны сүтүгә каршы чыккач, теге, Троцкий җибәргән моряклар отрядының командиры «большевикларны завод аппаратыннан куарга!» дип боерык биргән.

Хәлил. Әйдәгез тизрәк заводка!

Фролов. Ашыкма чак кына, Хәлил.

Вилдан. Су буе саклап утырып та ярамас. Йөрәк сабан туена ашкынган ат кебек.

Фролов. Сабан туе дигәннән, Хәлил, син, сабан туенда бәхәсләшеп, Иделне ике тапкыр иңләгән, диләр. Дөресме?

Хәлил. Иделне күп иңләгән инде мин аны.

Фролов. Тагын бер тапкыр иңләргә туры килә сиңа, Хәлил. Тыңла. Соңгы атнада заводта гына түгел, тимер юлда, станцияләрдә диверсияләр күбәйде. Берән-сәрән генә түгел, оешкан отрядлар хәрәкәт итә. Шул диверси-

он отрядлар коралны Зөя утравындагы кара монастырьлардан алмый микән дигән шигебез бар. Хәлил, яхшы йөзә белгәнең өчен генә түгел, үткен егет булганың өчен дә без сине сайладык. Сиңа бер төн вакыт. Зөя утравына үтеп кереп, монастырьдагы хәлләрне төгәл белеп кайтасың. Элемтәгә бер картны җибәреп караган идек, ул күперләр аша утрауга уза алмады. Көймә әзердер бит, Вилдан?

Вилдан. Иделендә бер. Оча гына. Үзе җиңел, үзе җайлы. Ногман бабай көймәсе. Көймәңне, Хәлил дус, суда калдырырга туры килсә, ихтималның җае киң — разведка диләр аны, якоре дә, биш-алты аршын таза җебе дә бар.

Фролов. Анда корал барын белсәң, без тизүк отряд җибәрербез. Ашыгыч рәвештә тимер юлчы дружиналарны, заводта теләктәш эшчеләрне коралландырырга кирәк. Чехлар якынлаша.

Хәлил. Утрауга дисез икән. Яхшы. Тырышып карыйк.

Вилдан. Федор Максимович, монда сиңа кадәр сул эсерлар рәисе Кириллов булып китте әле. Менә шул әкәмәттән исәнгерәп торам.

Фролов. Идел ягыннан көймәләр килмәдеме?

Вилдан. Килмәде.

Фролов. Кемнедер озатамы? Әллә каршы аламы? Каян? Кая?

Хәлил. Кузгалыйм мин, Федор Максимович.

Фролов. Караңгылык чак кына куерсын. Кирилловның иснәнеп йөрүе җанны тырный.

Вилдан. Икәү китик без, булмаса!

Хәлил. Вилдан агай миңа ышанмый.

Вилдан. Мин сиңа ышанам, чөнки мин сине беләм. Тик мин синең нинди хәлләргә тап буласыңны белмим. Кырыкка төрләнергә туры килә разведкада, танавына бетчә чыккыры! Юк нәрсә белән эш бозылып куюы бар. Берзаман шулай, Украинада, бер ташландык йортның чормасына менеп яшерендек тә юлны күзәтәбез. Төчкерәсе килә бит, каһәр төшкере. Үлеш! Танау эченә тычкан койрыгы тыгып болгыйлармыни, үтер, кис, ас, түзәр әмәл юк. Беләкне кан чыгардай итеп тешлим...

Фролов. Тәвәккәллә, Хәлил. Вилдан ярты төннән соң сине монда көтәр. Менә сиңа иптәш. (*Наган бирә.*) Юлны үзең беләсең.

Хәлил. Вакытында кайтырга тырышырмын, иптәшләр.

Вилдан. Мәле, моны да ян кесәңә җай гына салып куй.

Хәлил. Аракымы? Эчмим бит мин.

Вилдан. Каз мае диләр аны.

Хәлил. Балыкка дигән камырыңны манчып ашарсың дисеңме?

Вилдан. Ал, кирәге булыр. Суда-мазарда озаграк утыруың бар. Көймәсез калсаң шушы коткара сине. Аягыңны көзән җыермас, туңмассың. Разведкада өч нәрсәне сакла: башны, күзне һәм аякны. Башыңны сакла, күзеңне кадерлә, аягыңны белеп бас.

Фролов көймәне карап менә.

Фролов. Рәхмәт, Вилдан, шәп көймә хәстәрләгәнсең.

Хәлил. Сау булыгыз, иптәшләр.

Фролов. Хуш, иптәш. Паратск заводы эшчеләре синнән җавап көтә!

Хәлилне озаталар. Су чопырдаган тавыш.

Вилдан. Җиңел бара.

Фролов. Егет тә шәп, ничек каерып ишә.

Вилдан. Әле җил дә каршы булмаса, очар иде.

Фролов. Зарар юк. Кайтканда җиңелрәк булыр.

Вилдан. Тагын ни кушасыз, Федор Максимович?

Фролов. Теге этнең яр буен иснәп йөрүе күңелне тырнап тора. Кайтып аз-маз ял ит тә, туп-туры монда кил.

Вилдан. Хәлил күренми. Бара.

Фролов. Аталар.

Вилдан. Бу яктарак аталар.

Фролов. Аталар. Пулеметлары бар, динамитлары... Кайда саклыйлар алар коралларын?! Кайдадыр корал чыганагы бар... Их, шуны кулга төшерсәк, Троцкие да, ак чехлары да күзгә күренмәс иде.

Вилдан. Күренми. Еракта ул хәзер.

Фролов. Таралышыйк, Вилдан.

Икесе ике якка чыгалар. Бераздан Вилдан кире керә.

Вилдан. Иптәш Фролов! Федор Максимович!

Фролов (*керә*). Нәрсә бар?

Вилдан. Әнә теге борма артында Ногман бабайның, мондагы балыкчының, икенче көймәсе тора иде.

Фролов. Шуннан?

Вилдан. Йозагын ватканнар, көймәсен алып киткәннәр. Баягы кош — Кириллов эше бу!

Фролов. Хәлилнең утрауга китүен без өчәү генә беләбез.

Вилдан. Сизмәгәннәрдер... Башка бер этлекләре юкмы? Тиккә йөрмәс.

Фролов. Хәзер үк тикшерәбез: Кириллов мондамы, юкмы.

Вилдан. Их, Хәлил яшьрәк!

Фролов. Мин аңа ышанам. Алай да, киттек заводка!

Чыгалар. Сәхнә караңгылана.

Зөя утравында хатын-кызлар монастыре. Хөҗрә. Төн. Почмакта ак пәрдә белән томаланган тәре тактасы. Ак пәрдәнең уртасына күренер-күренмәс итеп кенә тәре чигелгән. Кулына шәм тотып, Лиза керә. Бераз икеләнеп тора да киң агач караватта йоклап ятучы Анакайны уята.

Лиза. Анакай! Анакай! (*Пауза.*) Уяныгыз, зинһар, анакай!

Анакай. Ә? Кем бар? Кем бимазалап йөри?

Лиза. Мин әле бу.

Анакай. Бер төндә икенче тапкыр тынычлыгымны бозасың, Елизавета. Тиешле-тиешсезгә уятмаска боерган идемме?

Лиза. Анакай, уятмас та идем. Сезне бер юлаучы сорый.

Анакай. Юлаучы? Иртәгә кадәр көтсен!

Лиза. Ул теге кеше...

Анакай. Әвәләмә авызыңда камыр.

Лиза. Аның сезнең янга килгәне бар, анакай. Ул ар яктан. Тик ул бүген...

Анакай. Йа Ходам! Ни булган? Тизрәк әйт.

Лиза. Кириллов әфәнде, анакай.

Анакай. Нигә аны әллә кайчан әйтмисең? Кайда ул?

Лиза. Түбәндә көтә. Ул әллә нишләп үзгәргән, анакай.

Анакай. Бик исерекме?

Лиза. Әйе. Киеме дә бүтән. Үзе дә... миңа үреләә, чеметә...

Анакай. Чеметеп карарга кытай ефәгеме әллә син? Исерек икән, айныр. Хода акылын җуймасын кешенең.

Лиза. Уятырга куша. Башка чакта песи иде, бүген ярсыган...

Анакай. Кайчан килгән? Кем белән? Мондагылар белән күрештеме?

Лиза. Әле белешмәдем, анакай.

А н а к а й. Ничә кат кисәтергә инде сиңа? Монастырь бусагасын атлап узган һәр җан иясе турында син барын белеп торырга тиеш. Үрмәкүч үрмәләп керә икән, аның ничә аягы барын да бел!

Л и з а. Анакай уятмаска боерды дип кат-кат инәлдем. «Безнең кояш чыкты хәзер, уят!» дип җикеренде.

А н а к а й. Нигә болай вакытсыз килгән ул? Нигә алай сөйләнә? Берни белмичә очрашсаң, аннан түбәнәергә туры килә. Ну, Елизавета! Бар, дәш үзен. Күргән-күрмәгәнең миннән узмасын. Элек килгәннәр арасында да, яңалар арасында да төрлеләр бар. Шпионнар булмасын! Кириллов әфәнде килгәч тә кем янында булган,— ачыкла. Шыпырт кына хәбәр итәрсең. Йоклама!

**Лиза тавышсыз-тынсыз гына чыгып китә. Анакай төзәтенә. Офицер киеменнән К и р и л л о в керә.**

К и р и л л о в (*тезләнеп*). Анакай, кулыгызны, кулыгызны! (*Кулын үбә.*)

А н а к а й. Узыгыз, кадерлем. Сезне бу киемнән күрү сәер. Әмма килешә икән.

К и р и л л о в. Мине түгел, Россияне бу киемнән күрү сәер. Нишләттеләр Россияне, анакай! Киемнәр генә түгел, адәмнәрнең рухы үзгәрде. Тотышы үзгәрде. Элек мужик очрый икән, аның бар булганы мужик иде. Муены бөгелгән, башы иелгән. Ул үз урынын бик яхшы үзләштергән иде. Очрый икән, юл саба, сәламли. Гыйбадәтханәләрдә ходай каршында тезләнә... Ә хәзер?.. Мужигы да, башкасы да бүредәй карый. Сак тормасаң, тотып ашаячак.

А н а к а й. Йокым килә. Мәшәкатьләр бихисап...

К и р и л л о в. Мужикны тасларга кирәк. Артык-портыгын юныштырырга.

А н а к а й. Мин бит, кадерле Михаил Петрович, өлкән кеше. Хәлем дә тиз китә, егәрем дә юк. Кичләрен ишегалдына чыгарга базмыйм: күзләрем начарланды... Сез утрауга шушы киемнәрдән уздыгызмы?

К и р и л л о в. Нигә, анакай?

А н а к а й. Аңламый торам. Нигә бу вакытсыз маскарад?

К и р и л л о в. Без икәү идек, анакай. Иптәшләр янында өс-баш алышындык.

А н а к а й. Иптәшләрегез дә ялыктырды. Патриотлар, дисез. Ә бүген кабак мужиклары төсле сугышып беткәннәр. Оят! Әле бая гына куркытып уяттылар. Ян-

нарына барсам, чырайларына карарга җирәнгеч. Белмим, мужикны тасларгамы, әллә офицерларны юныштырыргамы? Ил алдында үз вазифаларын тәмам онытканнар!

Кириллов. Кичерегез аларны, үтенәм. Ишеткәч, мин дә әрләдем. Эшсезлек, билгесезлек борчый аларны.

Анакай. Кәефем коры икәнен белгәнсез. Тиктәскә уятмаска иде. Иртәгә көн беткәнме?

Кириллов. Татлы йокыгызны бүләрлек тәмле хәбәрләрем бар.

Анакай. Каян килсен инде тәмле хәбәр?!

Кириллов. Анакай! Без барыбыз да сезне яратабыз. Сезнең алда бурычлыбыз. Сез иңегездә Россияне күтәреп торучы олуг затларның берсе.

Анакай. Йә.

Кириллов. Ашыктырмагыз инде, анакай. Сезне яратуымны әйтергә кайчан җае чыгар тагын?.. Һавалар үзгәрде. Ашыктырмагыз гына, бу турыда рәхәтләнеп аңлашасы килә. Һәр нәрсәнең тәртибе бар.

Анакай. Тәртип? Кайда калды ул тәртип?

Кириллов. Сездә тәртип юкмыни? Безгә өлге булырлык тәртип саклана сездә!

Анакай. Нинди тәртип, илаһым?! Иисус хәзрәт шаһит —дөнья мәшәкатеннән арынып, алла йортында тынычлык тапкан безләргә дә сан бетте. Язынка батып, өченче атна күпме гөнаһкярларны яшереп асрыйм. Хөҗрәләр пычрана! Кызларымның намусы таптала. Иманнары какшый. Йа Ходам, кичерә күр берүк. Изге гыйбадәттән башканы белмәгән, Алла сүзеннән мыскал да чыкмаган кызларым дөньяви уйларның вәсвәсәсенә бирелде. Языгын кая куярмын? Инде килеп, бер карасаң акыллы гына күренгән кешем «сездә тәртип» дип утта дөрләгән җанымны кыйный.

Кириллов. Языгын миңа калдырыгыз, анакай.

Анакай. Барыгыз. Йоклагыз, кадерле Михаил Петрович.

Кириллов. Сүзем бар.

Анакай. Бездәге офицерларны алырга килдегезме?

Кириллов. Әлегә юк.

Анакай. Башкача нинди сүз булуы мөмкин?

Кириллов. Чак кына көтәргә, түзәргә туры килер. Минем юлдашым монда кала. Таңда тагын бишәү килергә тиеш.

Анакай. Тагын алты әрәмтамак.

Кириллов. Ватан сакчыларын, монархиянең өметен шулай атыйсыз?

Анакай. Ялган акчалар төсле буш сүзләр, Михаил Петрович. Сафсата. Өченче атна йокы симертәләр. Төннәр буе, әйттем исә кайттым, азыналар. Кичер, Аллам! Изге keләү белән бу язгымны юармын. Бәхетсез ватан тел тегермәннәренә мохтаҗ түгел, аңа бүген арысланнар кирәк. Ә сез һаман чүбек чәйнисез! Әнә Мефодий ата!.. Чиркәү кешесе, Алланың юаш колы, ә үз куллары белән комбедта өч большевикны буып үтерде. Менә сезгә өлге! Менә сезгә гыйбрәт. Сөйләнәсез шунда, койрык сыртта, хәтәр, ә бүгенге көндә авылның иң кара мужиклары большевиклар артыннан бара. Барыгыз, йокымны юкка булдергәнсез.

Кириллов. Башта ук әйтәсе иде! Җебеп калдым, сөенечтән...

Анакай. Тәртип диюегез кайнатты канымны. Безнең утрау патшага терәк иде. Ә безнең монастырь тирәюньдә бер. Аһ, безнең җир-сулар! Болыннар! Судагы балык та, һавадагы киек тә безнеке иде. Ерак-еракларга безнең бөеклекне раслап яңгыраган дәһшәтле чаңнар. Әгәр сезгә бик аз да җитә икән, нигә большевикларга иярмисез? Йә!

Кириллов. Сөйләргә ирек бирмисез, анакай.

Анакай. Офицер киемнәре киеп шамакайланып йөрүгә дә канәгатьме?

Кириллов. Юк.

Анакай. О, миңа бик күп кирәк. Бик күп! Үзем өчен түгел, Аллам өчен тырышам.

Кириллов. Анакай! Куыш кирәк булды. Бирдегез.

Анакай. Йокыны китерәсең.

Кириллов. Акча сорадык. Кызганмадыгыз.

Анакай. Сузма.

Кириллов. Инде корал да бирегез.

Анакай. Шарт-шорт үрдәк атаргамы?..

Кириллов. Без сул эсерлар Россиядәге бердәнбер революцион партия. Безгә сүз кирәкми. Сүз сагыз ул — кем ярата, шул чәйни. Без әзерләндек. Без ныгыдык. Самара ягыннан союзниклар — чехлар килә. Бүген-иртәгә алар монда булачак. Безнең вәкилләр аларның аръергарды белән очраштылар. Без аларга Мәскәү юлын ачып бирергә тиеш. Казан юлын! Безнең сугышчан отрядлар оеша. Шикләнмәгез, Мәскәүдә дә нык кулларыбыз бар безнең.

Анакай. Мәскәү ерак, бик ерак.

Кириллов. Мәскәү якын, бик якын. Сез заманында рус гаскәрләренә Казан юлын ачкан атаклы утрауда

яшисез. Белегез, бүген иртән Троцкийдан кыйммәтле директива алынды. Паратск суднолар төзү заводы таратыла. Җиһазлар ашыгыч озатыла. Ни бу? Асылда бу большевикларның тамырына балта чабу. Чигенү. Капитуляция. Ленин Питердан Паратск эшчеләренә корал, кирәк-яраклар төяп кәрван җибәрә. Ә Троцкий аны кире бора! Ленинның нарком военморы үз янында торып ниләр эшли ала! Чехлар, анакай, чехлар! Өермә булып киләләр.

Анакай. Фу, бөркү монда. Лиза, тәрәзәләрне ач. (*Лиза, кереп, тәрәзәне ача да чыгып китә.*) Хәбәрләрең дөресме?

Кириллов. Корал бирәсез, анакай.

Анакай. Расла.

Кириллов. Атлашкинода тимер юл күперен шартлаттык. Тиз арада Идел күперен күккә очырачакбыз. Тагын...

Анакай. Корал... Корал бар, шөкер Ходайга. Сакладык. Кирәк кадәрле табарбыз. Тик кем минем белән исәп-хисапны ясар? Соңыннан... соңыннан, дим?

Кириллов. Без. Россиянең сул эсерлар хөкүмәте.

Анакай. Элекке хокуклар кайтырмы? Элекке шан-шөһрәт булырмы? Болыннар! Болыннарым, кырларым...

Кириллов. Россия туфрагында тәртип урнаштырырлык бердәнбер партия без. Хаосны чиклибез. Без — кискенлек. Без — террор. Без — тәртип. Без — көч.

Анакай. Каты кычкырасың. Фәрештәләрне куркытма. Монда кабак түгел. Алла йортында шыпырт сөйләш. Мәле, бераз тамагыңны чылатчы. Миләш аракысы. Үзем ясадым. Мең авыруга шифа.

Кириллов. Иң өметсез чакларда да ышанычлы кешең булу бәхет.

Анакай. Кайчан кирәк? Күпме?

Кириллов. Мондагы удар отрядны баштанаяк коралландырасыз. Бу бик кирәк. Отряд командиры итеп әле генә штабс-капитан Мишулинны билгеләдек. Алдагы төндә утрауга катер җибәрәбез. Отрядны, бар тупланган коралны шәһәргә күчерәбез. Алдагы төндә, таң алдыннан, ил буйлап эсерлар фетнәсе күтәрәбез.

Анакай. Фетнә?

Кириллов. Әйе. Большевиклар властена каюк.

Анакай. Ике шартымны тыңла!

Кириллов. Баш өсте, анакай.

Анакай. Безнең йорт бер җирдә дә телгә керми. Аннары, әчеп куегызчы, көч керер... Изге Мефодий атаны коткарасыз. Бер бөртек чәченә тиклем саклыйсыз.

Кириллов. Сезнең өчен барына әзер.

Анакай. Тәңрем, Иисус... Кайтар элекке рәхәтләрне.

К и р и л л о в. Мин таңга кадәр монда булам. (*Төчеләнеп.*) Сез: «Кызларымның май яфрагы кебек сафлары бар»,— дигән идегез.

А н а к а й. Языкка батма, атакай, килешми сезгә.

К и р и л л о в. Аһ, анакай. Сезгә шәхси бүләгем бар иде бит. Онытып торам. (*Куен кесәсеннән затлы муенса чыгара.*)

А н а к а й. Әнҗе муенса? Һиндстан эше?

К и р и л л о в. Бары тик сезгә! Чын күңелдән.

А н а к а й. Гүзәл бүләк.

К и р и л л о в. Мин таңда китәм дигән идем.

А н а к а й (*уйланып*). Беразга чыгып торыгыз. (*Кириллов чыга.*) Елизавета! Елизавета! (*Лиза керә.*)

Л и з а. Анакай, ул сезгә кагылганчы аш бүлмәсендә офицерларны җыеп утырган.

А н а к а й. Кирәкми. Беләм. Син бар, Аннаны дәшеп китерче.

Л и з а. Ә ул кайда, анакай?

А н а к а й. Миңа андый сорау бирергә ничек батырчылык итәсең?

Л и з а. Сестра Анна кичке гыйбадәттә күренмәде, анакай.

А н а к а й. Бусы нинди дәһрилек тагын?

Л и з а. Бер ул гына түгел... башкалар да йөрми.

А н а к а й. Алланың каһәреннән курыкмыйлармы?

Л и з а. Офицерлар аларны хөҗрәләреннән чыгармыйлар.

А н а к а й. Телең артык озын. Бар, сестра Аннаны тап. Җилдәй йөр.

Л и з а. Сез аңа бик күренеп йөрмәскә боерган идегез.

А н а к а й. Тыңлаучан булуы әйбәт, әмма хәзер тиз үк минем катыма ашыксын.

Лиза чыга, кабаланып К и р и л л о в керә.

К и р и л л о в. Анакай, кулыгызны, кулыгызны! (*Кулын үбә.*) Сүзегез — закон. Әйе, Россия мужигын өр-яңадан мәңгегә дагаларга кирәк. Буйсыну — рус халкының беренче сыйфаты булса, буйсындыру — икенче сыйфаты.

А н а к а й. Төчеләнмәгез. Бер муенса белән күңелемне йомшарттым дисәгез, бәһагез сукыр бер тиен. Миңа бик күп кирәк. Россия кирәк! Сезнең белән тагын ничек һәм кайчан очрашабыз?

К и р и л л о в. Иртән килергә тиешле офицерлар белән очрашып сөйләшүгә, мин Паратскига кайтам. Хәбәр алырсыз. Тиз дип уйлыйм.

А н а к а й. Бишне генә түгел, биш йөзне кабул итәрбез. Корал бирербез. Акча, кызлар җәл түгел. Ходаем белә, ярлыкар. Россияне генә коткарыгыз.

Сәхнә караңгылана.

Хөҗрә. Тимер рәшәткәле бәләкәй тәрәзә. Тәрәзә каршысында юан пар каен кәүсәсе шәйләнә. Төн. А н н а белән Л и з а керәләр. Лизаның кулында зур ачкыч. Шәм.

Л и з а. Абау! Куркыныч ич монда. Гүр салкыны.

А н н а. Салкын булса да тыныч ичмасам.

Л и з а. Менә шул: ул һаман сине таптыра. Теге Кирилловны әйтәм, зур кеше булган димме, офицер киеменнән. Ул килеп җитүгә, бездәгеләр әй куаныштылар, әй куаныштылар. Эчтеләр, исерешеп беттеләр. Шуннан, таралышкач, Кириллов анакай янына керде, озак кына нидер сөйләшенделәр.

А н н а. Әле ярый син бар. Рәхмәт.

Л и з а. Ни булып бетәр! Йа раббем... Рәхмәтеңне сибәргә ашыкма.

А н н а. Искәртүең өчен рәхмәт. Ярдәмең өчен рәхмәт. Моннан ары ни булырын бер Ходаем белә, ул ярдәмче.

Л и з а. Бигрәк шомлы икән монда. Иң шәбе сиңа утраудан ычкынып торырга иде.

А н н а. Ничек китәсең? Күперләрдә сак. Солдатлар ачыктан-ачык тормаса да беләм, җентекләп тикшерәләр. Кая китеп торасың? Әти йорты ерак. Анда да тынычлык калмагандыр, дөньясының асты өскә килгән. Инде алла йортына давыл кергән икән, юкны каян табасың?

Л и з а. Шулаен шулай да...

А н н а. Косасым килә... Бөтен җирдә ят ис. Ат исе. Күн исе. Тимер исе. Аракы исе. Голдыр-голдыр тавышлар. (*Пауза.*) Бая тагын якында гына атыштылар.

Л и з а. Ишеттем. Бездәге офицерлар тузынышып чыктылар берзаман, котым калмады.

А н н а. Ни булган соң анда? Сиңа мәгълүм булмаган нәрсә юк.

Л и з а. Утрау янында ят көймә күргәннәр дә ата башлаганнар.

А н н а. Кешесе булганмы?

Л и з а. Белүче юк. Теге пеләш капитанның «бер большевикны тончыктырдым» дип мактанганын анакайга кереп әйттем.

А н н а. Анакай да, изге гыйбадәтне онытып, дөнья ыгы-зыгысына чумды хәзер. Дөньяга беркайчан да ты-

нычлык кайтмас микәнни? Шул явызларны нигә җир йотмый икән?

Л и з а. Чү, ят тавыш ишетелмәдеме сиңа?

А н н а. Юк. Сүндер утыңны. Болай да яктыра.

Л и з а. Мәче тырманган кук булды.

А н н а. Мәчеләрне анакай сөйми. Күсе булса гына инде. Күсе бик әшәке бит ул.

Л и з а. Килеп чыкса, тотарсың да берәр әйбер белән түбәсенә бәрерсең. Әлерәк кенә тагын бишәү килделәр. Урын җитми башласа, бу хөҗрәгә дә китереп тыгарлар. Исерекбашларга аларга ни, монда, бу хөҗрәдә, бер кыз бала асылынып үлгән иде дип санап тормаслар, курыкмаслар.

А н н а. Күңелем болай да шикләнеп тора иде, каян тагын шуны искә төшерәсең?

Л и з а. Үлгәннәрдән курыкма син.

А н н а. Килгән кешеләрне мин дә абайлап калдым.

Л и з а. Кайчан?

А н н а. Күпер башына чыккан идем дә...

Л и з а. Качарга ниятләгән идеңме?

А н н а. Исәп юк түгел иде. Әйбәт кенә йөзәм мин. Безнең авыл нәкъ Зәй буенда бит, онытмадыңмы?.. Мин тәвәккәлләгәч кенә атыш башланды. Су җып-җылы... Яр буендагы каравылларны атыш башлангач кына абайладым.

Л и з а. Тотып алсалар?

А н н а. Тоттырмый идем, суга ташлана идем.

Л и з а. Сине берәү дә күрмәдеме?

А н н а. Юк бугай... Күрмәсеннәр дә. Хәзер күзгәбашка күренмәгәч, теләсә ничек юрасыннар. «Монастырьдан качарга маташканда суга баткан», дигән хәбәр тарат син.

Л и з а. Аллам сакласын. Болай да атлаган саен алдашу. Теге дөньяда эссе таба ялатырлар.

А н н а. Анакайга да шуны җиткер. Ышанмаса да күңеле иләсләнсен. Ул җен карчыгына шул кирәк тә.

Л и з а. Алла диген, бәхетсез. Изге анага тел күтәрергә ничек кыйдың?

А н н а. Изгелеген Мефодий ата янында күрдек.

Л и з а. Ходайдан курык, Анна.

А н н а. Аннан да куркам, исерек офицерлардан ныграк куркам.

Л и з а. Гыйбадәт кыл, бәхетсез, Ходайга баш ор. Тәнең арыса да, җаның ял итәр. Монда салкынча. Суың җитәрлекме?

А н н а. Монысы эчәргә. Бусы юынырга. Җитәрлек.

Л и з а. Көндезен берәр җаен табып кагылырмын әле.

А н н а. Йөри күрмә. Синең бу тирәдә чуалганны сизенсәләр, бетте баш. Тыштан йозакны биклә дә ачкычны монда ыргыт. Йә үзеңдә яшереп тот. Билеңә так.

Л и з а. Таптың... Бил иң куркыныч урын кызларның хәзер.

А н н а. Алайса, үзең белгәнчә яшер.

Л и з а. Аларда башка ачкыч юкмы икән әле?

А н н а. Юк. Башкаларын коега ташладым.

Л и з а. Мине хәйләгә оста дисең... Үзең!

А н н а. Хәйлә нәрсә? Кодрәтле буласы иде. Офицерлар ишәя башлагач та, эчтән генә уйлап куйдым. Әзәрлекли башласалар, тотам да сестра Маринаның хөҗрәсендә качып калам, димен. Синдә ни хәлләр, Лиза?

Л и з а. Бүген килгәннәрнең берсе, сөйкемле генә нәмәрсә үзе, почмакка посырып итәк астына үренеп маташа.

А н н а. Яңагыннан ут чыгардыңмы?

Л и з а. Яңакка чалтыраткач ни буласын алдан ук искәртеп куйдылар шул. Сестра Анастасияне нишләттеләр? Чәчен кистеләр, алмадай ак күкрәген итек маена буядылар. Кеше күзенә күренер җирен калдырмадылар.

А н н а. Изге анакай, күрмәмешкә салышып, «чирлим» дип ятып калды.

Л и з а. Ул нишли алсын? Алла каршысында барыбыз да тигез. Анакай да бәхетсез бер зат... Анна, монда нидер кыштырдый!

А н н а. Ярар, Лиза, бар син, чык. Уяна башларлар.

Л и з а. Алла тугры юлдашың булсын.

А н н а. Аминь.

Л и з а. Яктыра.

А н н а. Тәрәзә каршысындагы каен кәүсәсеннән төшкән аклык кына ул.

Л и з а. Тагын бер төн үтте.

А н н а. Йозак ватып ук керерләр микәнни, Лиза?

Л и з а. Келәү ит. Гыйбадәт кыл. Алла мәрхәмәтле.

А н н а. Киңәшеңнән чыкмам.

Лиза чыга. Ишекне тышкы яктан шылтыратып бикли. Тынлык. Анна үзе белән алып кергән әйбер-караларны җайлап урнаштыра. Тәрәзә ягыннан тавыш ишетелә. Анна, сискәнеп, тәрәзә янына бара. Бара да, куркып почмакка чигенә. Тәрәзә рамы тимер рәшәткәсе белән күтәрелә, кул күренә. Менә бер кеше аска шуып төшә. Бу — Хәлил.

А н н а. Ай!

Х ә л и л (*ыңгырашуын көчкә тыеп*). Ah...

А н н а. Сиңа ни кирәк?

Х ә л и л. Миңамы? (*Карана.*) Хәзерге минутта берни дә кирәкми. Ә монда нәрсә бар?

А н н а. Ничек керә алдың монда?

Х ә л и л. Үзем дә белми калдым.

А н н а. Бар чыгып кит. Синең иптәшләрең өстә. Бу подвал. Монда суык, юеш.

Х ә л и л. Тәрәзә биектә шул, менеп җитә алмам.

А н н а. Чык, чык.

Х ә л и л. Ишек бикле!

А н н а. Кергән җиреңнән чык. Ишектән йөртәләр ди сине. Мин кыз бала. Әллә ни уйларлар.

Х ә л и л. Чак кына хәл алыймчы?

А н н а. Кузгалма! Кычкырам!

Х ә л и л. Курыкма син миннән. «Иптәшләрең» диденме, «ишләреңме», бәлки, мин алар ише түгелдер. Син каян белдең? Адәмнең маңгаена тамга сугылмаган.

А н н а. Күрмиләр ди! Исерек бит син, аягыңда чак басып торасың. Кесәңдә шешәң.

Х ә л и л. Каз мае гына ул.

А н н а. Чакырам! Кешеләр монда гына. Күрше хөҗрәдә. Алар хәзер кереп җитәләр.

Х ә л и л. Керәләр дисеңме?

А н н а. Керәләр, керәләр!

Х ә л и л. Алайса, нигә ишекне эчтән элгәнсең.

А н н а. Ачам мин аны.

Х ә л и л. Тукта, сабыр ит. Керәләр икән, керсеннәр. Анда күз күрер.

А н н а. Ничек алай «керсеннәр»? Ансат кына.

Х ә л и л. Үзең чакырасың. Миңа артык хаҗәтләре юк.

А н н а. Кем соң син? Нишләп монда йөрисең?

Х ә л и л. Ә син үзең бу подвалда нигә бикләнеп утырасың? Суык. Дым гына. Почмаклар күгәргән. (*Пауза.*) Ә минем кемлекне күрмисеңмени?

А н н а. Нишләп кесәңдә каз мае йөртәсең?

Х ә л и л. Балыкчы мин.

А н н а. Сиңа монда ни кирәк? Бу бит алла йорты.

Х ә л и л. Күренми.

А н н а. Кем?

Х ә л и л. Йорт хуҗагыз. Алла. Монда син ялгыз бугай? Курыкма син, вәт куян. Дерт итә дә сикереп тора. Балыкчы, дим ич. Җил кузгалды да көймәмне аударды. Йөзеп чыксам, сезнең яр икән.

А н н а. Бүген төнлә җил булмады.

Х ә л и л. Сизми калгансың син, ишетмәгәнсең. Диварларың таштан бит, түшәмең дә көймәле. Калын.

А н н а. Алдашасың, алдашасың!

Х ә л и л. Ярый, алдашам, ди. Шуннан ни?

А н н а. Нигә йөртәсең син үзең белән сыек каз маен?

Х ә л и л. Синең бер дә юлга чыкканың юкмыни? Булса, шунда әнкәң ырымлап берни дә тыкмыймыни? Менә бу каз мае... Кирәк чакта батырмый, кирәк чагында калкытмый торган, уттан, яман күздән саклый торган әманәт.

А н н а. Кодрәт бер Аллада гына.

Х ә л и л. Шулай диик әйдә.

А н н а. Ничек керә алдың син монда?

Х ә л и л. Күреп тордың ич.

А н н а. Әллә шул ырымың булыштымы?

Х ә л и л. Бусы ырымсыз гына.

А н н а. Кеше-кара сизгәнче чык син моннан.

Х ә л и л. Ач ишегеңне, чыгам.

А н н а. Юк, юк, тәрәзәдән. Яр буена чыга торган ике тәрәзәнең берсе. Берәү дә күрмәс сине. Чык.

Х ә л и л. Синнән миңа бер нәрсә кирәк аңынчы.

А н н а. Ни ул?

Х ә л и л. Кумый тор мине. Чак кына баш-күз алыйм. Аннары нишләргә кирәген белермен.

А н н а. Син бурмы?

Х ә л и л. Бурның куллары шушындый буламы? Тимерче мин, тимерче.

А н н а. Якын килмә. Әле балыкчы, әле сихерче, әле тимерче.

Х ә л и л. Кума. Мин сиңа пар чиләк ясап бирермен. Эче кояш кебек балкып торыр. Тышына пар сандугач сурәте ясармын.

А н н а. Нәрсәгә миңа чиләк? Дөнья белән алыш-биреш өзелгән.

Х ә л и л. Чишмәгә йөрерсең, тиле. Чылтырап аккан инеш буена төшәрсең. Карасаң төбе күренмәслек сиртмәле кое янына чыгарсың.

А н н а. Син минем кемлекне күрмисеңмени?

Х ә л и л. Гомерең буе монда бикләнеп ятмассың ла! Син яшь. Таза. Хәзер тормыш бөтенләй башкача булачак.

А н н а. Кем үзгәртә инде аны? Синме әллә?

Х ә л и л. Бу сүзең өчен рәхмәт. Аңлы икәнсең. Күңел күтәрелеп китте. Бусы инде безнеңчә. Кешеләрчә. Юкса шушы суык ләхеттә ятып әллә кара кисәүгә әйләндеңме дип торам. Тормышны мин үзгәртәм дисәм — ни әйтерсең?

А н н а. Тукта!

Тәрәзәдән Л и з а карый.

Л и з а. Анна, Анна!

Х ә л и л. Тавыш бир. Сиңа дәшә.

Л и з а. Анна, мә ачкычны. Йә минем белән бер-бер хәл булыр. Үзеңдә торсын. Анакай пыр туздырып сине эзләтә.

А н н а. Нишләрмен инде, нишләрмен!

Лиза ачкычны ыргыта да югала.

Х ә л и л (*ачкычны барып ала*). Ачкыч дисәң дә ачкыч. Тиз генә ясармын димә. Йозагын кадак белән дә, отмычка белән дә ансат кына ача алмассың. Дугасы ломга бирешмәс йозагы кайда инде моның? Синең хәзинә сандыгың бикләгәнме? (*Анна эндәшми.*) Исемең Анна икән. Ипле исем. Матур.

А н н а. Сиңа аннан ни файда?

Х ә л и л. Ә мине Хәлил дип йөртәләр. Тимерче Хәлил дисәң...

А н н а. Булса соң?

Х ә л и л. Нинди ачкыч була инде бу? Каян? Нинди сере бар?

А н н а. Шуннан торып кына миңа ыргыт әле үзен.

Х ә л и л. Мә. (*Ыргыта.*)

А н н а. Аяк атлыйсы булма.

Х ә л и л. Сине эзлиләр икән. Яхшы. Димәк, син дә минем төсле үк монда качып кергәнсең. Әйбәт. Пар киләбез түгелме?

А н н а. Ничек пар?

Х ә л и л. Качыш-качыш уйнаганда пар булу уңайсыз. Мәсьәлә катлаулана төшә. Ике кешене ике җирдән эзлиләр! Мин дә монда качып кердем.

А н н а. Кем соң син? Нишләп качып йөрисең монда?

Х ә л и л. Бу хикмәтле ачкыч белән иң әүвәл минем телне ачарга булдым диген.

А н н а. Әйтмәсеңне белеп сорадым.

Х ә л и л. Әйтәм. Тимерче мин. Паратск заводыннан. Коммунист.

А н н а. Синме коммунист?

Х ә л и л. Охшамаганмы?

А н н а. Миңа таба килә күрмә. Кычкырырмын. Бел, безнең кызлар тәрәзәгә гел-гел килеп торалар.

Х ә л и л. Синең монда икәнлекне бөтен Зөя белә алайса?

А н н а. Белә, белә.

Х ә л и л. Алайса, кемнән куркабыз без?

Анна. Сиңа миннән ни кирәк?

Хәлил. Бу ачкычның йозагы кайда? Моннан җир асты юлы бармы? Шуның ачкычымы?

Анна. Түгел. Бу ачкычның йозагы шушы ишекнең теге ягында гына.

Хәлил. Ишек таза. Тоташ тимердән коелган. Кагылмыйм мин сиңа, Анна. Кычкырмыйсың да. Сине пыр тузып эзлиләр. Чак кына тавыш бирсәң дә, эләктереп кенә алачаклар.

Анна. Син чыннан да коммунистмы соң? Коммунистларны мөгезле була ди безнең анакай. Алар балаларны ашыйлар, ди.

Хәлил. Син аннан качып ятасың бит! Димәк, ул үзе балаларны ашый. Кил, утыр минем яныма.

Анна. Кычкырам.

Хәлил. Җүләрләнмә, Анна.

Анна. Әйе. Мин качып утырам. Тик мин бүредән ычкынып, юлбарыска барып каптым. Син әшәке кеше. Син карак. Каян килсәң, шунда кит. Сез болгаттыгыз дөньяны. Синең белән янәшә утырганчы мин... әллә ниләргә риза.

Хәлил. Яхшы. Мин моннан чыгам, Анна.

Тәрәзәгә менә башлый, ярасы авыртып ыңгыраша.

Анна. Син яралымы?

Хәлил. Әллә шуны сизмәдең? Бераз бар. Утлы шөпшә чагып киткән иде.

Анна. Шөпшә? Кан... Абау...

Хәлил. Кан, Анна. Безнең байрак төсле кып-кызыл.

Анна. Таң алдыннан сиңа аттылармы?

Хәлил. Анна, син бит дөнья эшләренә тыгылмыйсың. Синең эш көйләнгән. Таш дивар, көймәле түшәм, тимер ишек. Җаның тыныч.

Анна. Безнең монастырьдан аттылармы?

Хәлил. Әйе, Анна. Алла йортыгыздан аттылар. Шуңа мин еракка китә алмадым да.

Анна. Монда таба кемдер килә.

Хәлил. Тагын ачкыч бармы аларда?

Анна. Булмаска тиеш дип беләм.

Хәлил. Тиз генә ача алмаслар. Ачалар икән... (*Наган чыгара.*)

Анна. Ай, куркам. Ходаем, кичер. Языклымын, языклымын!..

Хәлил. Дәшмә. Түз.

Анна. Туп-туры монда таба киләләр.

Х ә л и л. Качар урын юк дисең инде? Алайса, каршы алыйк аларны, Анна. Бергәләп. Әйе, киләләр.

Дөп тә дөп тимер ишекне кагалар. Хәлил белән Анна үтә киеренкелектә тыңланалар. Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хөҗрә. А н н а белән Х ә л и л баягы кыяфәттә тыңланалар. Тимер ишек дөбер-дөбер килә. «Әй, кеше бармы монда? Җавап бир! Эндәш!» дигән тавышлар. Менә тавышлар акрынлап тына.

А н н а. Шөкер Ходага, киттеләр.

Х ә л и л. Тс-с. Берәрсе калмасын... Хатын-кыз монастыренда ирләр? Каян килгәннәр алар монда? Ишләрең дип син шуларны әйттеңме?

А н н а. Уф, баскычтан менеп баралар.

Х ә л и л. Ишекне ватарга тотыналар дип котым калмады. Юк, юк. Мин күбрәк синең өчен борчылдым.

А н н а. Ходай саклады. Бер юлга...

Х ә л и л. Синең гел-гел яши торган почмагың түгел икән бу.

А н н а. Анысын каян чамаладың?

Х ә л и л. Гел монда торсаң, алар әрсезрәк булыр иде. Ансат кына борылып китмәсләр иде.

А н н а. Әйе. Мин монда яшәмим. Монда хәзер берәү дә тормый. Буш хөҗрә. Иясез.

Х ә л и л. Кеше җитмиме?

А н н а. Бәхетсез хөҗрә. Монда сестра Марина тора иде. Вәсвәсәгә бирелде, имансыз калды. Быел яз, май ахырларында, үзенә үзе кул салды. Шуннан бирле буш. Якшәмбе кичләрендә өрәге кайта, диләр. Күргәннәр.

Х ә л и л. Тәрәзә рамы нигә күтәрелә соң?

А н н а. Анык кына белмим. Сестра Марина, әйтәм бит, языклы бәндә иде. Аның бер егете булган. Анысы җиде төн уртасында көймә белән килә икән дә шушы тәрәзә аша Марина янына керә икән. Шулай дип тә сөйләүләр булды. Шул егет өчен үлде дә ул җүләр! Мәңге тәмугта яначак хәзер.

Х ә л и л. Бу таш базда саргаеп, сөрсеп ятканчы, яраткан кешең өчен, кайнар яшьлек мәхәббәте өчен яну начармы, синеңчә?

А н н а. Тәрәзәнең ачылуын төнәген генә белдем. Караңгыда килеп ныгытып та караган идем, һаман ачыла икән. Ә син аны ничек таптың?

Х ә л и л. Пар каен гаепле.

А н н а (*сискәнеп*). Пар каен?

Х ә л и л. Яр як стенагыз буш диярлек. Бер урында гына пар каен үсә. Үрмәләп мендем дә каен күләгәсенә ышыкланып тордым. Яктыра башлады, беркая китәрлек түгел. Аста һаман эзләнәләр! Монастырьның базы, йә подвалы булырга тиеш бит, дип уйлана башладым. Стенаnarыгыз! Бер дә Казан крепостеннан ким түгел, артык та булмаса. Капшана торгач, кул астымда рам какшап китте. Карыйм: кыймшана. Күп уйлап торырга вакыт юк иде. Кердем киттем.

А н н а. Үләм дип торам шул чагында.

Х ә л и л. Синең урысчаң такы-токы гына икән. Чувашмы син?

А н н а. Чувашлар алар денсез, ишек тоткасына баш оралар, өй иясенә. Мин алла колы.

Х ә л и л. Мукшымы?

А н н а. Түгел. Керәшен мин.

Х ә л и л. Үзебезнең татар икәнсең әле.

А н н а. Татар түгел лә, керәшен. Татарлар да денсез.

Х ә л и л. Риза, риза. Кем дисәң дә сүзем юк.

А н н а. Чык яктыгарак. Яраңны карыйм.

Х ә л и л. Карый белерсеңме соң?

А н н а. Без монда барын да беләбез. Аш-суны да, чирчорларны да. Арысак-ачыксак та үзебез, бизгәк тотса да.

Х ә л и л (*сабыр гына ыңгыраша*). Һм-м...

А н н а. Монда ике яра эзе бар.

Х ә л и л. Бер пуля ясаган. Бер җирдән кереп, икенче яктан чыккан.

А н н а. Нәрсә сөртеп бәйләргә инде?

Х ә л и л. Әнә ич каз мае! Тот та шуны сөрт. Ярамас дисеңме? Яраргa тиеш. Яхшы кеше кулыннан алдым. Тик менә... үзем генә... сынат-тым!.. Кулың нинди йомшак синең...

А н н а. Кем сиңа минем кулга карарга кушкан?

Хәлилнең ярасын бәйли.

Х ә л и л. Карамасам да беләм. Тимерче икән, тәнем тимердән түгел лә. Аннары, каз мае йөрәкне әрнетте. Сынаттым!..

А н н а. Болары кайчангы яра?

Х ә л и л. Малай чакта тимер төшкән иде.

А н н а. Син әллә кайчаннан эшлисеңмени?

Х ә л и л. Унбер яшьтән алачыкта. Баштa күрек өрдердем. Әти дә тимерче иде минем, чахоткадан үлде.

А н н а. Ятып торырга иде сиңа. Шешә башлаган.

Х ә л и л. Ятып торырлыкмы соң, Анна.

А н н а. Сорасам да сөйләмәссең инде. Кирәге дә юктыр. Сөйләмә, сөйләмә. Мин берни дә белергә теләмим. Соңгы өч атнада ишеткәннәр, күргәннәр шултиклем булды, акылыма сыймый. Сөйләмә!.. Сөйлә!

Х ә л и л. Аргамагын югалткан юлчы ни сөйләсен, Анна? Тәбе корып китеп, үзе шуңа килеп капкан ачык авыз ни әйтсен? Эх! Утрауның түбән башыннан, икмәк складлары яныннан узган идем инде. Монастырь ягыннан ата башладылар. Җитмәсә, көймәм чоңгылга эләкте. Бөтерә дә тора.

А н н а. Беләм мин ул урынны.

Х ә л и л. Аталар гына. Суга сикердем. Көймәне сакларгамы, үземнеме?.. Кулымнан ычкынды... Яралы икәнемне ярда гына белдем.

А н н а. Алар сине генә эзләгәннәр!

Х ә л и л. Юк, бу юлы сине эзләп килделәр. Мин чумдым да озак кына су астында йөздем. Түзем мин. Аннан калкам да тагын чумам. Дөрес, аргамак югалса да, баш исән. Тик йомышын үтәмәгән башның, ни бәясе бар?.. Тәбедә утырсам да, әлегә тәбе коручылар моны белми-белүен...

А н н а. Син чыннан да коммунистмы? Әллә мине өркетер өчен генә әйттеңме?

Х ә л и л. Һаман да куркасыңмы?

А н н а. Белмим. Сиңа моннан китәргә кирәклеген генә тоям. Алар бер эзли башлагач, тиз генә тынмаслар. Яраң бәйләүле. Каз мае аша су үтеп кермәс. Хәлең бар сыман... Яр ерак түгел. Текә тауга менә алганны, төшә дә алырсың. Әле уянып җитмәделәр. Синең тормышыңны фәрештәләр саклар, мин Ходайга гыйбадәт кылырмын. Килеп таба калсалар, икебезгә дә көн булмас. Минем гомер кемгә кирәк, син кемгәдер кирәктерсең әле.

Пауза.

Х ә л и л. Син кемнән качып кердең монда, Анна?

А н н а. Бүгенме?

Х ә л и л. Юк, бүген генә түгел. Башта ук. Шушы юеш, суык җәһәннәмгә үз ихтыярың белән килеп кердеңме? Бүген нигә качып утырасың?

А н н а. Син сатанамы?

Х ә л и л. Сатанадан кызыл кан агамы? Хәлил мин, Хәлил. Паратск егете. Тимерче.

А н н а. Минем күңел — Алла эше. Бер ул гына барын да белә. Мин аның белән генә сөйләшә алам.

Х ә л и л. Кодрәт иясеме син табынган Алла? Ә? Дәшмисең...

А н н а. Алланың кодрәте барыбызга да җитә.

Х ә л и л. Алайса сорап кара әле, мине яр буе сакчылары арасыннан үткәреп җибәрсен.

А н н а. Бәлки син кеше үтерергә барасыңдыр? Алла андый эшләргә катышмый.

Х ә л и л. Ул чагында син миңа ярдәм итәсең, Анна.

А н н а. Аллам кодрәтле булса да, мин аның бичара колы гына. Андый чослыгым юк.

Х ә л и л. Иң әүвәл шуны төшендер: нишлиләр монда ир-атлар? Ничәү алар?

А н н а. Мин каян белим?

Х ә л и л. Белергә кирәк. Булыш.

А н н а. Дөнья эшләренә катнашырга ярамый миңа.

Х ә л и л. Шуны белмичә торып, мин моннан чыгып китә алмыйм.

А н н а. Җай барында котылып кал. Үкенерсең. Кит. Бераздан чыгып ычкына алмассың. Әнә! Мин барын ишетеп, сизеп торам. Сестра Клавдия подвалга төшә. Әнә төнге каравылчы почмактан узып китте. Ишетәсеңме? Хәзер иртәнге келәүгә чаң кагачаклар.

Х ә л и л. Юри генә сөйлисеңме?

А н н а. Биш ел буе тыңланып яшәгән ич мин монда. Кайда ни кыймылдаганын барын белеп торам. Миңа чүт кенә тавыш та җитә. Шушы таш диварлар, түшәмнәр белән, хөҗрә белән, монастырь белән бер гәүдәгә әверелгән инде без. Белеп сөйлим: сиңа хәвеф килә!

Ир кеше хихылдаган тавыш яңгырый.

Х ә л и л. Ә бусы нинди тавыш булды, пигамбәр?

А н н а. Бусын белмим.

Хатын-кыз чинаган тавыш яңгырый.

Х ә л и л. Ә бусы?

А н н а. Белмим.

Исерек ир җикеренгән аваз ишетелә.

Х ә л и л. Бусын сорамыйм да инде.

А н н а. Әйтә алмыйм.

Х ә л и л. Минем колакка гына керә торган авазлар да бар икән сездә. Мин аңлый торган гына тавышлар да яңгырый икән. Хәзер икәү тыңлап карыйк. Ишеткәннәреңне син аңлатырсың, үз чиратымда мин дә сиңа кайбер нәрсәләрне төшендерермен.

А н н а. Сестра Клавдия подвал ишеген ачты...

Х ә л и л. Нигә төшә ул анда?

А н н а. Мичкәләрдә тозлы ит тора.

Х ә л и л. Менә ул зур бөкеле шешә куелган кәрҗингә үрелде... Теге калын тавыш, ачык ишек янында чайкалып, аннан аракы сорый. Кичтән җыелып эчеп утырганнар иде, хәзер махмыр, баш авырта...

А н н а. Мин боларны белмим.

Х ә л и л. Шуңа күрә үзем сөйлим. Подвал ишеге моннан еракмы?

А н н а. Утыз сажиннар булыр.

Х ә л и л. Подвалдан ярга чыгу юлы бармы?

А н н а. Белмим.

Х ә л и л. Биш ел шушында ятып ни беләсең соң син?

А н н а. Алла сүзен беләм.

Х ә л и л. Аракы шешәләреннән тыш анда озын-озын агач тартмалар да бар. Тартмаларда мылтыклар...

А н н а. Мин тыңламыйм инде. Туктадым.

Х ә л и л. Сөйлимме? Тыңла. Төнлә монастырьга ике кеше килде. Аларны хөрмәтләп каршы алдылар. Ике ир кеше. Икесе дә заводтан. Паратскидан.

А н н а. Күрмәдем.

Х ә л и л. Алар монда яшеренеп ятучыларны җыеп ашыгыч сөйләшеп алдылар. Аннары сезнең хуҗаны күрделәр. Байтактан бирле сезнең монастырьга кулак, бай балалары җыела. Офицерлар!

А н н а. Нигә интектерәсең мине? Тыңламыйм дидемме?

Х ә л и л. Җыелалар икән — тиккә түгел. Монда әйбәт каршылыйлар, җылы урын бирәләр. Җылы урын гына түгел, тавышларга караганда, җылы куен да биргәннәр аларга!

А н н а. Белмим, белмим.

Х ә л и л. Мин сиңа бер сүз дә әйтмим. Үзем генә сөйләшәм.

А н н а. Җен син. Сатана!

Х ә л и л. Монда тупланалар икән, подвалда тозлы ит кенә тормый. Корал да бар! Агач тартмаларда майлап, төреп куелган винтовкалар, пулеметлар булырга тиеш. Алтын да булыр анда. Чөнки кулак малайлары акчасыз хезмәт итмиләр. Сезнең хуҗагыз безнең заводтагы эсерлар белән туганлашкан булса кирәк.

А н н а. Туктала беләсеңме син?

Х ә л и л. Актыккысы: шул исерекләрдән яшеренеп ятасың син монда, бер дә бүтән түгел. Анакай шуның өчен сине эзләтәдер. Төнлә мин сине яр буенда күрдем. Кулыңда шушы төенчек иде. Кая барырга җыена идең син?

Анна (*жылый*). Җендер син, күрәзәдер.

Хәлил. Җеннең куллары шундый буламы, тотып карачы.

Анна (*курка-курка гына, Хәлилнең кулларын тотып карый*). Каян белдең син боларны?

Хәлил. Үзең сөйләп бирдең.

Анна. Кайчан?

Хәлил. Яфраклар шыбырдый... Әнә, ишетәсеңме? Син аларны һәрвакыт тамыр серен сөйли дип беләсеңме? Юк, тиктомалга да шыбырдыйлар алар кайчак. Бәлки, тамырларга су җитмидер, таш нигезләр ул тамырларны кысып имгәтәдер, изәдер, аларга азык җитмидер, ә яфраклар ваемсыз, күңелле генә шыбырдашалар. Аларга, тамырларга дим, бәла килгәнен бакчачы күңеле белән үзе сизәргә тиеш.

Анна. Бөтенесен тап китердең.

Хәлил. Икәүләп кайбер нәрсәләрне ачыклыйкмы?

Анна. Буташтырма мине, болай да языкка батырып бетердең.

Хәлил. Теләсәң-теләмәсәң дә син катнаштың инде, Анна. Күреп торасың, син булышмасаң, моннан чыгып китәрлек түгел. Инде килеп, минем ярдәмнән башка синең дә барыр җирең калмаган шикелле.

Анна (*жылап*). Нишләргә соң?

Хәлил. Бер-беребезгә кул бирешик. Ничек булышыйм дип торма. Без төрлеләр булсак та, дошманыбыз бер безнең!

Анна. Минем дошманым юк. Ничек булышыйм ди мин сиңа? Чыгар юлны өйрәтә алмыйм, белсәм, үзем дә монда посып утырмас идем. Юк бит аның юлы! Бөтен якта су! Күперләргә якын барырлык түгел. Алар монда бик күп.

Хәлил. Күпме?

Анна. Минемчә, бездә генә илледән артык. Ирләр монастыренда ишле команда качып ята.

Хәлил. Кораллары да бармы?

Анна. И-и, бездәге корал. Әллә ниндиләре бар, исемнәрен генә әйтә алмыйм. Сестра Елизавета белә!

Хәлил. Кем ул?

Анна. Минем якташ. Аның этисе чиркәүдә җырлый. Шул, аның этисе безне монда китерде.

Хәлил. Бүген төнлә килгән ике кешене күрдеңме син?

Анна. Лиза аларны да белә.

Хәлил. Нигә син белмисең?

Анна. Ул анакайның ышанычлысы. Аны карый. Анакай да аны саклый. Офицерларга бирми.

Х ә л и л. Бүген төнлә алар бәйрәм иткән булырга тиешләр.

А н н а. Бәйрәм генәме, дөнья кубардылар. Сөенештеләр. Бәргәләшеп тә алдылар бугай.

Х ә л и л. Нигә икәнен төшенәсеңме? Төнлә килгән кешеләр аларга яңа хәбәр җиткерделәр... Мәскәү юлы өстендә бит без, Анна. Шушы юл буйлап хәзер безнең өскә ак чехлар килә. Эшче-крестьяннарны дар агачларына тезеп килә алар. Болар шуларны көтәләр.

А н н а. Ничегрәк чыгып ычкынырга соң моннан?

Х ә л и л. Ничек алар афәтеннән дөньяны коткарырга диген син.

А н н а. Мин куркак, көчсез...

Х ә л и л. Анна, нигә син миңа ашарга берни бирмисең?

А н н а. Ходаем, син ачсыңдыр бит?

Х ә л и л. Сәфәр болай озакка тартылыр дип уйламаган идем. Әйттеләр миңа иптәшләр, кисәттеләр. Мин барын да ансатрак итеп күз алдына китергәнмен икән.

А н н а. Кайнар чәем дә юк бит. Ипи бар. Бераз искергән. Дуңгыз мае бар, син татар, аны ашамассың.

Х ә л и л. Яле, яле! Бирче. Бара, каз мае тамызасың да каз боты күк тәмле була ул.

А н н а. Яратсаң, күкәй. Син каты пешкәнне яратасыңмы, сыекнымы?

Х ә л и л. Сыекны...

А н н а. Мин дә!

Х ә л и л. Сүзнең йомшагын, корычның катысын, күкәйнең тәмлесен — сыегын яратам.

А н н а. Каты пешкән күкәй чуерташ күк була бит ул. Таш ашап утырып булмый инде.

Х ә л и л. Офицерлар да сезнең белән бер табында ашыймы?

А н н а. Сорашма, төпченмә дип әйттемме?

Х ә л и л. Болай гына. Өстәл янына яулык бәйләп киләләрме дип сорамакчы идем.

А н н а. Аларга ит китереп торалар, балык...

Х ә л и л. Нигә син бүген качасы иттең? Кызлар җитми башладымы?

А н н а. Болары да сиңа нигә?

Х ә л и л. Ризыгың тәмле, рәхмәт.

А н н а. Бар булганы белән.

Х ә л и л. Кайсы як кызы диден әле?

А н н а. Безнең өй моннан еракта. Зәй буенда. Анда керәшеннәр бик күп.

Х ә л и л. Синең әтиең дә чиркәүдә җырлыймы? Әллә ызанда ыңгырашамы?

А н н а. Без «эти» димибез, «тәтә» дибез. «Нәнә» дибез. Тәтәм крестьян. Ат асрыйбыз. Бер ат. Киндер чәчәбез. Син киндер мае белән ярмалы бәрәңгене яратасыңмы?

Х ә л и л. Әллә бармы?

А н н а. Юк... Өйдә бар... Нәнәм юк, тиф кастасыннан үлгән. Без дүрт кыз, ике малай калдык. Тәтә миңа яңа нәнә алып кайтты. Тәтә дигәнгә көлмә, яме.

Х ә л и л. Синең әниең юк. Минем әтием үлгән, ятимнәр без. Керәшен түгел син, минем шикелле татар. Без бертуганнар!

А н н а. Юк инде, керәшен.

Х ә л и л. Ярый, ярый, керәшен булсын ди. Нинди җырлар җырлыйсың соң син, Анна?

А н н а. Җырламыйм, гыйбадәт кылам. Келәүгә йөрим.

Х ә л и л. Гыйбадәт кылмаган арада нишлисең?

А н н а. Анда да келәү итәм, Аллага баш орам.

Х ә л и л. Тәтәңне, туганнарыңны уйлыйсыңмы?

А н н а. Үлгән нәнәмне, үз нәнәмне бик сагынам.

Х ә л и л. Төшеңә дә Алла, канатлы фәрештәләр генә керәме?

А н н а. Төшләремә дә нәнә керә. Үги нәнә бик үк якын итмәде. Күпсенде. Кызлар күп, җир аз. Терлек-туар аз. Ат берәү. Шуннан киттем... Китмәсәм, мине яргыччы кылый Җәгүргә кияүгә бирәләр иде. Исерек алапка. Бер хатынын чабата калыбы белән бәреп үтерде инде ул.

Х ә л и л. Бусы безнеңчә!

А н н а. Ничек алай?

Х ә л и л. Революционер икәнсең син.

А н н а. Анысы кем тагын! Револьвер таккан кешеме?

Х ә л и л. Кара язмышына буйсынмыйча, башын югары күтәргән кешегә зурлап шулай диләр. Тик киңәшче итеп чиркәү җырчысын сайлагансың. Яргыччы җырын җырлый торган кешене. Заводка килергә иде сиңа.

А н н а. Безнең якта заводлар юк. Аннары мин куркам да...

Х ә л и л. Анна, авылыгызда чакта сине ничек дип үртиләр иде?

А н н а. Ни дигән сүз анысы? Үртәү нәрсә ул?

Х ә л и л. Берәр кушаматың бар идеме синең?

А н н а. Ә-ә, ничек иҗеклиләр дисең икән! Әллә тагын, бала чакта булгандыр инде. Барысы да булды, онытылды.

Х ә л и л. Йә инде!

А н н а. Минеме? Мине «Анна-манна-кандала!» дип иҗеклиләр иде.

Х ә л и л. Анна-манна? Шәп.

Анна. Ә сине?

Хәлил. Минеме? Бөтен урам бала-чагасы «йонлы бака» дип үртиләр иде.

Анна. Китсәнә, йонлы бака була димени?

Хәлил. Ә шушындый матур күзле, акыллы кыз «кандала» буламы?

Анна. Чү!

Хәлил (*тыңланып*). Монда таба киләләрме?

Анна. Түгел. Яр ягында.

Хәлил. Тәрәзәдән карыйм?

Анна. Башны бетерәсең. Туктал... Уф, узып киттеләр.

Хәлил. Баш кадерле сиңа, баш... Эх, Анна! Тышта кояш. Көн яктысы. Ә мин ятам... Их, син... Җырламыйм дисең алайса?

Анна. Җырлау — язык. Алла ишетә.

Хәлил. Ишетсә дә, бу чуалчык заманда безгә әйләнеп карарга вакыты табылыр микән? Булса да, җилкә кашырга да вакыты юктыр аның.

Анна. Сине җир йотар.

Хәлил. Йота алмас. Идәнегез таш.

Анна. Языклансаң, чуен идән дә ачылып китәр.

Хәлил. Ачылсын иде әле. Әй, идән, ачыл! Ачылмый шул. Андый көч, кодрәт бирәүдә дә юк. Әнә бая, аяк тавышыннан сискәнеп, чыраең агардымы? Нигә дәшмисең? Беләм! Дөнья мәшәкатеннән, авырлыктан, хурлыктан ничек котылырга юл тапмыйча адашып монда килеп капкан кызларны офицерлар нишләтәләр?.. Кемнең тире түгелеп тапкан акчаны эчәләр? Иртәгә йә берсекөнгә корал тотып кем башын кыярга чыгып китәчәкләр? Менә безнең әүлиядәй иптәшне суеп, ияргә аркылы салып җибәргәннәр. Минем туганнарга, синең тәтәңнәргә каршы чыгып китәчәк алар! Яргыччы Җәгүр дә алар янында булачак. Әйе, әйе! Нигә ичмасам шуларның хет берсен, башкаларга гыйбрәт булсын өчен, берсен генә дөбердәтеп җәһәннәм суырып алмый?!

Анна. Алар теге дөньяда җәбер күрәчәк, эссе табада куырачаклар аларны. Сумала казанында кайнатачаклар.

Хәлил. Кара халыкка анда да рәт булмас. Хуҗалар, шомалар анда да табылыр. Монда остарган кара йөрәкләр анда да шайтан белән килешенер, җаен табар! Ярлыларны сатып тагын бер сүзгә килерләр. Үзебез кайгыртмасак, анда да безгә рәт булмас!

Анна. Саф кызлар, дидең... Җәберләүдән качып кергәннәр, дидең. Ничек белә алдың?

Хәлил. Күзләрең әйтеп тора. Яфрак шыбырдаганга гына ышанып утырырга мин бер тинтәк түгел.

А н н а. Тынычта торасым килде минем. Башкасын уйламадым да.

Х ә л и л. Ә син уйла. Уйла! Кешенең һәр әгъзасы үз бурычын үтәргә тиеш. Монда минем дошманнар җыелган, Анна.

А н н а. Сиңа ни яманлык кылды алар?

Х ә л и л. Миңа гынамы?.. Үзем өчен сугыша беләм мин, Анна. Тик онытма: шушы атна эчендә генә күпме күпер шартлаттылар алар, күпме кешенең җанын кыйдылар. Эсерлар, ак бандитлар соңгы сәгатьләре сукканны сизенәләр. Шуңа чиксез явызланалар алар. Беләсең килсә, син дә алар корбаны.

А н н а. Таба алмыйлар алар мине. Алар киткәнче, мин моннан чыкмыйм.

Х ә л и л. Миңа чыгарга кирәк. Мине иптәшләр көтә. Мин бүгеннән калмый анда булырга тиеш. Булыш.

А н н а. Алар сине үтерерләр, Хәлил.

Х ә л и л (*Анна авызыннан беренче тапкыр үз исемен ишетеп кайнарланып китә*). Мин моннан чыкмасам, вакытында кайтып җитмәсәм, алар тагын да күбрәк халыкны харап итәчәк.

А н н а. Аһ, нишләргә? Чү!

Х ә л и л. Тәрәзәдән карамый түзә алмыйм.

А н н а. Дәшмә.

Тәрәзәдә Л и з а күренә.

Л и з а. Анна, Анна!

А н н а. Нигә килдең? Күреп калсалар, бетерәсең...

Л и з а. Бетәсе беткән. Барыбер. Ачкыч кирәк миңа, ачкыч.

А н н а. Ни булды? Калтыранасың.

Л и з а. Тиз бул, ятьрәк.

Х ә л и л (*шыпырт*). Белеп кал, Анна!

А н н а. Сөйлә, җебемә.

Л и з а. Бүген караңгы төшкәч китәләр. Бир ачкычны!! Ярдан берсе менә.

А н н а (*ачкычны сузып*). Сак бул, Лиза!

Л и з а. Искәртергә соңардың, дустым... (*Югала.*)

А н н а. Ни булыр? Ходаем, сакла. Ни булыр?

Х ә л и л. Синең монда икәнең беленгәндер. Ул сине башка урынга күчермәкче.

А н н а. Башка урын юк. Юк.

Х ә л и л. Кичкә китәләр, ди. Анна, мин алардан иртәрәк кузгалырга тиеш.

А н н а. Беләм. Хәзер беләм. Ләкин, ничек? Көймәң

юк. Үзең яралы. Моннан чыккан тәкъдирдә дә ерак бара алмыйсың. Утрау кайнап тора.

Чаң кагалар.

Хәлил. Бу нәрсә? Пожармы?

Анна. Көндезге гыйбадәткә кагалар.

Хәлил. Гыйбадәткә офицерлар да җыеламы?

Анна. Җыела.

Хәлил. Каравыллар да керәме?

Анна. Керә. Гыйбадәттән соң аш.

Хәлил. Лиза нинди хәбәрләр китерсә дә, син мине монда көт, Анна.

Анна. Ә син кая барасың?

Хәлил. Разведкага. Шунсыз ярамый.

Анна. Тотсалар, үтерәчәкләр... Бер гаепсез кызның чәчен кыркыганны... Жәлләмәсләр сине!

Хәлил. Алар явыз булганга чыгарга кирәк тә миңа.

Анна. Каен артына иплəп кенә сең. Стена буйлап иелеп кенә бар. Анда вак-төяк куаклар. Төнлә син аларны абайлап бетермәгәнсең. Егерме сажинлап киткәч, анда бер олы яшнек күрерсең. Шул яшнеккә кер. Таза ул. Тырма-көрәкләр тора.

Хәлил. Мин сыяммы анда?

Анна. Шуннан яр буйлары ап-ачык күренеп тора. Күперләр дә күренә. Кире кайтма. Чыгып ычкына алсаң, юлыңда бул... Юлың уң булсын. Кире кайтма!

Хәлил. Ә син?

Анна. Мин?

Хәлил. Өндәмә, Анна. Сине монда калдырып китмим. Сиңа да куркыныч яный бит.

Анна. Хәлил!

Хәлил Аннаны күкрәгенә кыса да күзләренә карап тора. Тәрәзәдән чыга. Анна булыша. Шунда ук ишектә йозак шылтырый. Анна куркып бер ишеккә, бер тәрәзәгә карый, чәбәләнә. Лиза керә. Аның күзләре куркынып ачылган.

Лиза. Анна! Син котылдың, бүген китәләр. Алдагы төндә Паратскида фетнә күтәрәчәкләр.

Анна. Фетнә?

Лиза. Сарык булганмын мин моңарчы, Анна. Ә сарык —бүрегә азык икән. Дустым, мине харап иттеләр.

Анна. Кем? Ничек? Синеме? Ә анакай? Ничә ел аны карыйсың. Йомышына чабасың. Бар эше синең өстә. Ул белдеме?

Лиза. Йомылып яткан җылан икән ул. Мин аны үз

анам кебек итеп, хәтта аннан да кадерләбрәк карадым. Изге җанга санап...

Анна. Иртәрәк чыгып ычкына алмадык шул. Ничек чыгып өлгерергә? Болары китүгә, икенчеләре килер.

Лиза. Гел кайтмаска дисеңме әллә? Әй Алла?

Анна. Күңелем иләсләнде. Әллә ниләр уйлап бетердем, Лиза. Языклы уйларга баттым. Китәрмен дә кайтмам төсле. Инде сине дә шулай мыскыллагач... Мине саклап, үзеңне аямадың... Ни ялварып, ни еләү итеп карадым, Алла кулын сузмады... Сине күрмәделәрме?

Лиза. Кем кайда бикләнгән... Таралыштылар. Кызлар еләүдә җылашалар. Исерекләр тулы. Шашканнар!

Анна. Бетәселәрен сизенеп шашалар алар.

Лиза. Каян беләсең?

Анна. Әшәкеләр бер җәзаны татырга тиештер бит?!

Лиза. Подвалдан корал менгерделәр. Җитмеш җан икән алар хәзер бездә. Мылтыклар, пулеметлар. Анакай йөри сөзәргә җыенган тук үгез сыман! Теге сине эзләткән кеше, Кириллов, китмәгән әле.

Анна. Ул кайда?

Лиза. Һаман тынмый. Сине таптыра. Шул явыз инде мине харап итте.

Анна. Бүгеннән калмый миңа да китәргә иде.

Лиза. Аларның эзе тынгач, чыгып ычкынырсың. Син кыю, Анна.

Анна. Миңа алардан да алдарак китәргә кирәк. Бик кирәк.

Лиза. Әллә нишләгәнсең син. Бу хөҗрәнең һавасы шундыйдыр инде! Битең алланган, күзең яна. Көч кергән синә. Әллә үзем изелеп үзгәрдем, әллә син...

Анна. Үзгәрдек, дустым. Бәхетсез ахирәтем, янымнан җибәрмәс идем дә сине... Ләкин, миңа китәргә кирәк. Син шул турыда нығытып уйла.

Лиза. Тырышырмын... Анакай янына ничек кайтып керәсе? Чыраена карый алмыйм шул ялмавыз карчыкның!

Лиза чыга. Йозак тавышы. Анна тәрәзә каршысына барып баса.

Анна. Хәлил... Нинди җырлар җырлыйсың, дидеңме? Анна-манна-кандала... Авылыбыздан күрше авыл татарлары узганда, без болай дип җырлый идек. «Татар-татар, тарама, кермә безнең арага! Кысылырсың, үләрсең. Биш тиен акча түләрсең». Ә алар безгә каршы ничек дип такмаклый иде әле? «Керәшен-керәшен, керкәле, түбә чәчең серкәле» дип җырлыйлар иде. Кызык чаклар булган... Шундый җүләр сүзләрне җырлап йөргәнбез. Тук-

та, күңелемдә башка бер җыр иде бит... Ходаем, изге атабыз, кичер мине, ярлыка! (*Җырлый.*)

Аланлык урамнары киңнәр лә урам,
Пучтавайлар үтә туктамый...
Юл өсләре яшел багана...
Авыр килде безгә замана!

Авыр килде шул безгә заманалар! Җиңел замана берәр вакыт булдымы икән? Хәлил «барысы үзгәрәчәк!» ди. Кая таба үзгәрәчәк?.. Җырладым, күңелем ачтым. Гаҗәп, җир йотмады, түшәм ишелмәде, ишектәге бик тә үз урынында. Хәлил!..

Сәхнә караңгылана.

Анакай хөҗрәсе. Анакай ялгызы. Лиза керә.

Лиза. Анакай!

Анакай. Нәрсә карап каттың?

Лиза. Сестра Анна беркайда да юк.

Анакай. Син... син... ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы? Тотып ашамаганнар бит. Тап!

Лиза. Ул суга батып үлмәдеме икән? Яр буеннан яулыгын табып менделәр.

Анакай. Шул гына җитмәгән иде!.. Безнең изге йорт турында тагын гайбәт... Йә, җитәр, эзләмә. Бар. Күренсә яки кайдалыгы беленсә, шыпырт кына миңа килеп әйтерсең. Бар, гыйбадәт кыл һәм җаныңа тынычлык сора.

Лиза чыга. Бераздан Кириллов керә.

Анакай. Мин берәүне дә кабул итмим, Михаил Петрович.

Кириллов. Анакай, кулыгызны, кулыгызны... (*Кулын үбә.*)

Анакай. Нигә монда бәреп керәсез? Мин Алла белән сөйләшә башлаган идем. Тагын ни кирәк? Алтын сорадыгыз. Бирдем. Урын сорадыгыз. Таптым. Корал, дидегез, анысы да булды. Бүген төнлә мин сезгә серемне ачтым. Серемне уртак иттем, димәк, өлешчә, мин сезнең колыгызга әверелдем. Ә сез, кызлар итәгеннән аерыла алмыйча, монда ауныйсыз!..

Кириллов. Анакай! Таңда килгән биш кеше яңа боерык китерделәр. Миңа Паратскига кайтырга ярамый. Анда большевиклар иснәнә башлаган. Мин, шул арадан файдаланып, мондагы отрядны сугышка әзерләргә тиеш. Почетлы миссия! Мин көпә-көндез, берәүдән дә курыкмыйча, моннан китә алам, монда кайта алам. Әйтеп кара-

гыз: чехларга каршы көрәшергә тиешле Кызыл гаскәрнең баш командующие кем? Муравьев.

Анакай. Барыгыз. Йоклагыз.

Кириллов. Сул эсер! Безнең кеше. Әйдә, Ленин Кремльдә күк күкрәтеп ятсын, тиздән бөтен власть безнең кулга күчәчәк.

Анакай. Ах, тел... Тел белән власть яулап алалармы? Россия телгә ышанмый хәзер. Юк, берәү дә ышанмый. Мин дә ышанмыйм.

Кириллов. Нигә тел? Тел генә түгел, анакай. Эш, хәрәкәт, кырылыш. Хәзер Россиядә бер генә хакыйкать, бер генә юл. Әйе, митинглар, диспутлар чоры узды. Бәхәстә большевиклар көчле. Алар теләсә ни вәгъдә итә алалар. Узды. Без властька иң дәһшәтле юл белән — барын кырып, дар агачлары тезеп, кан дәрьясында йөзеп кенә бара алачакбыз. Террор, тагын бер тапкыр террор һәм террор! Бөтен җирдә фетнә. Бөтен җирдә дәһшәт. Россияне тагын бер кат канга батырмыйча, рус мужигын акылга китереп булмый.

Анакай. Алайса, нигә һаман монда сез? Нигә анда түгел!

Кириллов. Анна кайда?

Анакай. Чыгып китегез, лыгырдык. Лиза җитмәдеме сезгә?

Кириллов. Тамагым ач. Мин аждаһа кебек кан телим бүген, җан телим. Монашкаларына тиклем безгә бүре булып карый. Кан телим, җылы кан, кайнар кан!

Анакай. Мин сезгә ышанып ялгыштым... Моннан соң беркемгә дә!.. Берәүгә дә ышанычым юк... Бетте. Барыгыз, бар!

Кириллов. Безгә властьны икмәк-тоз белән тоттырмыйлар. Большевиклар алар аяусыз, анакай. Бүген йә иртәгә мине үтерүләре ихтимал. Бүген мин үзем булып, максималист Кириллов булып кына яши башлыйм. Бер көн генә, бер көн! Жәлләмәгез, изге ана. Шушы соңгы утрауда гына кешечә яшәп була бүген. Бу бит гади утрау түгел. Бу тарихи утрау. Без шушы утраудан мәгърур Казан ханлыгына җимергеч удар ясадык, бөтен мамай кабиләсен тез чүктердек... Һәм шушы изге утрауның... (*чайкалып китә*) шушы изге утрауның иң биек җирендә безгә һәйкәл торыр.

Анакай (*тыныч кына, җирәнеп*). Җебегән.

Кириллов (*кинәт айнып*). Кем җебегән диде монда? Кем? Кайда ул кеше. Мең дисәтинә җиребезне тартып алдылар. Урманнарыбызга үзебез хуҗа түгел. Ләкин мин җебегән түгел. Мин кан телим.

А н а к а й. Барыгыз. Юанычка мин сезгә Лизаны җибәрермен.

К и р и л л о в. Сез әнҗе муенса бәрабәренә миңа Аннаны саттыгыз. Мин булмасам, аны башкалар тотып ашый. Мин аның хуҗасы. Кайда товар?.. Кан диңгезендә йөзәсем килә. Кайда Анна?

А н а к а й. Мин җуләр, беркатлы...

К и р и л л о в. Маташтырмагыз, анакай! Күз яшегез корыган сезнең. Башка берәүгә тәкъдим иттегезме?! Кайда Анна?

А н а к а й. Бер шигем бар. Бер урын гына калды. Шунда качмадымы икән ул явыз?! Кешесез хөҗрә бар. Әйдәгез, шунда төшәбез. Йә раббым, кичерә күр!

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хөҗрә. А н н а ялгызы.

А н н а (*җырлый*).

Сары чәчәк ата көнбагыш,
Сезнең белән яшәү куаныч!..

Сезнең белән! Сезнең белән дигән икән... Яфрак белән тамыр сере килешсә әгәр... Әйе, пар каен яфраклары шыбырдый. Тик мин бүген бик күпне аңлыйм: яфраклар һәрчакта да үз тамырларының серләрен сөйләмиләр, алар җил ихтыярына буйсынып кына шаулыйлар. Ә бүген минем аларга ышанасым килә. Минем дә күңелемдәге телемдә. Күңел уйлаганны, күңел тойганны телдән әйтеп бирү тәнне җиңеләйтә икән, рәхәт. Бик рәхәт. Хөрлек шушы түгелмени? Үч аласы да килә, ярсу да бар. Лиза жәл... Пар каен! Таш койма буена сыенган куаклар! Яшерә күрегез аны, яшерегез! Яман күзләрдән саклагыз аның илаһи җанын... Тукта! Шашкан нәмәстә! Каенга баш орам түгелме? Аллага ялварасы урында, денсез чувашлар сыман, агачларга келәү итәм түгелме? Тәүбә, тәүбә!..

Менә тавыш ишетелә, рам күтәрелә. Анна Х ә л и л г ә керергә булыша.

Х ә л и л. Төшәм, төшәм!

А н н а. Хәлил!

Х ә л и л. Исән-сау, Анна. Монда тынычлыкмы?

А н н а. Аягың ничек, аягың?

Х ә л и л. Йөри. Аяк йөри. Йөрер җире генә булсын.

А н н а. Ходайга мең шөкер.

Х ә л и л. Сиңа йөз мең шөкер. Син күзне ачтың. Син бәйләдең. Кулың шифалы. Таптым мин, Анна, син әйткән теге яшнекне таптым. Ипләп кенә тырма-себеркеләр янына кердем дә байтак карап яттым. Менгән чакта кызулык белән сизелмәгән, тау текәрәк... Артык текә һәм биек. Аскарак төшсәң, үзәннәрдә куе куак. Шәп! Елга буйларында камышлык. Анда инде яшеренеп була.

А н н а. Лизаны харап иткәннәр.

Х ә л и л. Синең янга килеп киткән кызнымы?

А н н а. Теге кеше, төнлә анакайны уятып кергән юлбасар. Аңа яңа хәбәрләр китергән кабахәт. Шул мыскыллаган. Кириллов атлы икән.

Х ә л и л. Хәбәрең ачы булса да, ахыргы сүзең өчен рәхмәт. Таныш кеше. Үзе таныш, эше генә сер иде. Безнең заводтан, иң-иң кабахәт эсер!

А н н а. Тимерчеме?

Х ә л и л. Әйттем бит, сул эсер дип. Максималист. Террорчы. Кеше үтерүче. Арттан пычак кадаучы. Сатлык җан. Мөртәт. Бай баласы.

А н н а. Каты гаеплисең. Хакың бармы? Хөкем Алла кулында. Кермә аның өлешенә.

Х ә л и л. Хөкем эше дә гадел кеше кулында — эшче, крестьян кулында булачак. Рас әйтәм, Анна. Үз күзләрең белән күргән җәбер-җәфалар, этлекләр азмы әллә сиңа, Анна? Бу дөньяда яктылык барын тәмам оныттыңмыни? Яргыччы Җәгүрдән качып Кирилловлар тозагына килеп капканыңны аңламыйсыңмыни әле?

А н н а. Мин Кирилловтан бик куркам. Килгәне бар иде аның. Үткән килгәннәрдә песи булып кына йөргән иде. Гел анакайның кулын үбә, тезләнә дә үбә... Минем ни хаҗәтем бар аңа?

Х ә л и л. Кулына эләксәң, күрсәтер ул.

А н н а. Куркам!

Х ә л и л. Бирмим мин сине, Анна. Юк, гомергә булачагы юк. Сине генә түгел, үзебезнең Паратск заводын, эшчеләрне, якын-тирә авыллардагы крестьяннарны да бирмим.

А н н а. Лиза кереп чыкты. Мондагы отрядта җитмеш өч кеше икән. Винтовкалар, пулеметлар бар икән монда. Бүген төнлә аларны алырга катер килергә тиеш.

Х ә л и л. Катер?

А н н а. Әйе. Таң алдыннан фетнә күтәрәчәкләр.

Х ә л и л. Фетнә? Син ялгыш ишетмәдеңме?

А н н а. Лиза тыңлый белә ул, барын ишеткән.

Х ә л и л. Фетнә? Бусы зур яңалык! Куркыныч яңалык. Ә мин монда — тоткында.

А н н а. Нишлисең хәзер?

Х ә л и л. Мин үз көймәмне күрдем. Куе камышлыкка кереп туктаган ул.

А н н а. Аннан ни файда?

Х ә л и л. Кириллов кебекләр утрауга ат менеп тә керә алалар. Алар өчен күперләр ачык. Димәк, Зөя утравы сул эсерлар оясы!.. Тапканнар җылы урын. Әйе, өч большевикны көпә-көндез суйган утрау. Ике йөз кибет. Сәүдәгәрләр-купецлар. Чиркәү-монастырьлар. Монархия терәкләре. Революция дошманнары корт күк кайный монда. Әйе, тирә-якны дер селкетеп торган бай монастырьлар билне алай ансат кына бирергә теләмәсләр. Алар эсерлар белән генә түгел, җен-пәриләр белән дә бер сүздә була алалар! Хакыйкатьне буарга җай гына булсын. Фетнә! Моны ничек иптәшләргә белдерергә?

А н н а. Кириллов таңда кузгалырга тиеш булып та китмәгән.

Х ә л и л. Нәрсә көтә ул? Сигнал көтәме? Тагын кешеләр киләчәкме?

А н н а. Аларын белә алмадым шул.

Х ә л и л. Алай! Кириллов белән юллар кисеште бу араларда. Монысы соңгысы булыр. Соңгы кат!.. Аның монда калуы бер караганда начар түгел. Ул Паратскига кайтканчы, мин анда булырга тиеш.

А н н а. Кирилловның монда калуы сиңа бик-бик кирәкме?

Х ә л и л. Без фетнәне кузгалганчы ук басарга тиеш.

А н н а. Башкача мөмкин түгел, алайса?

Х ә л и л. Бик күп кешеләрнең гомер язмышы шуңа бәйләнгән.

А н н а. Моның бер җае бар.

Х ә л и л. Лизамы?

А н н а. Түгел, түгел.

Х ә л и л. Башым җитми.

А н н а. Кириллов мине эзләтте. Анакай мине аңа саткан. Әгәр мин табылсам? Курыкма, мин аңа ансат кына юл куймам. Мин аны тоткарлармын, хәйләсен табармын.

Х ә л и л. Болай ярамас, Анна. Сине күргәннән соң, сине белгәннән соң, эт авызына ничек бирим ди мин? Юк, Анна-манна-кандала! Сине бирмик. Бусы мөмкин түгел. Башка юлын табыйк.

А н н а. Утраудан китү юллары аз шул. Ике күпер. Берсе Зөя аша, берсе Чуртан елгасы аша. Аларны нык саклыйлар. Хәлил, без барыбер икәү китә алмыйбыз. Мин кала алам.

Х ә л и л. Кала аласың? Фетнә турында ишеткәнче дошманның шушы кадәр мәкерле булуы турында уйламаган идем. Балалыгым чыгып бетмәгән дип әйтимме, юлым җиңел генә узар, тиз генә утраудан урап кайтырмын кебек тоелган иде. Хәзер эш үзгәрде. Уйлашыйк: мөмкин булмаганны эшләргә кирәк. Барын да кат-кат исәпләргә кирәк, Анна.

А н н а. Син агарындың.

Х ә л и л. Аяк сиздерә... Монастырьдан читтә синең якын кешең юкмы? Берәр ышанычлы кешең.

А н н а. Без бит бик астында яшибез, аралашмыйбыз.

Х ә л и л (*тәрәзәгә карап*). Кошлар оча. Әнә акчарлакмы? Их, кош буласы иде. Яхшы! Буш сүзләр сөйләгәнче, үз көчебезгә ышаныйк, без бит хәзер икәү.

А н н а. Син миңа таяна күрмә, Хәлил. Мин куркак, мин языктан куркам. Барыннан куркам. Йөрәгем ярылыр дип тә куркам.

Х ә л и л. Син миңа ышан. Әлегә шул җиткән.

А н н а. Хәлил, нинди җырлар җырлыйсың дип нигә сорадың син бая?

Х ә л и л. Күңелеңдә нинди моңнар саклавыңны беләсем килде. Күңелдә сакланган җыр — кешенең иманы.

А н н а. Бая, син югында, мин бер җыр искә төшердем.

Х ә л и л. Нинди җыр ул, Анна?

А н н а. Син көләрсең генә.

Х ә л и л. Бер дә көлмим.

А н н а. Үзебезнең керәшен җыры. Зәй яклары җыры.

Х ә л и л. Авылыгыз җырын онытмагансың.

А н н а. Онытыламы соң? Сагындыра бик. Уйламыйм дисәң дә сагындыра.

Х ә л и л. Миңа да җырлап күрсәтәсеңме?

А н н а. Әйем лә, оят бит.

Х ә л и л. Син җырла. Мин уйлый торыйм. Киткән чакта бер иптәш җырлап калды, күңелгә юлдаш булды. Син җырларсың да мин туры юлны табармын.

А н н а. Ишетсәләр?

Х ә л и л. Ә син акрын гына җырла. Икебез өчен генә...

Пауза.

А н н а (*җырлый*).

Аланлык урамнары киңнәр лә урам,
Пучтавайлар үтә туктамый...
Юл өсләре яшел багана,
Авыр килде безгә замана!

Х ә л и л. Авыр килде, Анна! Хак!

А н н а.

Сез туганнарымны уйлый-уйлый,
Күп төннәрем үтә йокламый...
Алма килә яшел яшьнектә,
Яшәп калыйк әле яшьлектә.

Х ә л и л. Яшәп тә, көрәшеп тә каласы иде лә яшьлектә.

А н н а.

Агыйделкәйләргә без төшәрбез,
Колачларны җәеп йөзәрбез...
Әнә, карабодай тарата,
Күңелләрем сезне ярата.

Х ә л и л. Стоп. Тукта. Төшәрбез, Анна. Яшел яшьнек яныннан аска таба тирән генә ермак төшә. Як-ягы биек үлән. Колачларны җәеп йөзәрбез дә кичәрбез Иделне.

А н н а.

Кычкырыр ла күке, сайрар былбыл,
Шул чакларда ничек түзәрбез?!
Сары чәчәк ата көнбагыш,
Сезнең белән яшәү куаныч.

Х ә л и л. Шәп җыр! (*Кушылып җырлый.*)

Сары чәчәк ата көнбагыш,
Сезнең белән яшәү куаныч.

А н н а. Куансаң да әйбәт бу җыр... Моңайсаң да дөрес сүзләре күп.

Х ә л и л. Безгә атап чыгарганнар ич бу җырны. Җыр бит ул, Анна, сер, борынгылар сүзе. Алар безгә ничек яшәргә икәнлеген җырларында әйтеп калдырганнар. Сары чәчәк ата көнбагыш дигәннәр икән — бусы безнең баш очыбыздагы якты кояш. Каян күңелдәген белеп, сайлап җырладың бу җырны? Мин бая гына, яшел яшьлектән зәңгәр Зөя өстенә карап, күңелемнән генә ант иттем: алып чыгам син былбылны бу аждаһалар өненнән! Тынчыган сатлык утраудан коткарам. Иптәшләр мине көтә анда, Анна, бик көтә. Син җырлаганда тагын бер кат: «Ничек кенә булмасын, барыбер кайтып җитәм!» — дип, күңелемнән уй беркеттем.

А н н а. Күңелемә мең кат килсә дә, бу җырны җырларга курка идем. Язык бит, зур язык. Безнең авыл Зәй буенда. Якты күл исемле. Яфрак бәйрәмендә, тройсында, үз нәнәм исән чакта, безгә бик күп кунаклар килә иде. Тәтә белән нәнә өстәл башына аягүрә басып гел шушы җырны җырларлар иде. Кунак сыйларга бик яра-

талар иде. Яфрак бәйрәмендә урманга шомырт чәчәк аткан аланга менә идек. Арыш уҗымы ямь-яшел булыр иде. Кыр буйлап барыр идек...

Х ә л и л. Утыр минем янга, Анна.

А н н а. Язык була бит.

Х ә л и л. Язык казык башына, диләр бездә.

А н н а (*утырып*). Синең кулың шундый кайнар. Беләкләрең төк кенә.

Х ә л и л. Ә синең кулың шундый йомшак.

А н н а. Синең сөйгәнең бармы, Хәлил?

Х ә л и л. Булмыйча.

А н н а (*аннан тартылып*). Бар?!

Х ә л и л. Җан — сөяр өчен яратылган бит. Сөйгәне юкның —җаны юк. Моңы юк, теле юк, иле юк.

А н н а. Кем ул?

Х ә л и л. Сизмисеңмени? Белмисеңмени, Анна?

А н н а. Белмим, Хәлил.

Х ә л и л. Ул син, Анна.

А н н а. Кояш эчле чиләкне әлегә чаклы берәүгә дә бүләк итеп бирмәдеңмени син, Хәлил.

Х ә л и л. Юк, Анна. Моңарчы уйлаган да юк иде. Кичә әнкәйдән хат алдым. Кайт, ди. Өйләндерәсе килә. Ялгыз башым, ди. Эче кояш булыр аның, Анна. Тышына алтын сары чәчәк аткан көнбагыш ясап куярмын.

А н н а. Чынмы, Хәлил? Синең исең китмәсен, ышансам да, шулай «чынмы» дип сорап куям. Син мине нишләттең? Калдун түгелме син? Җен затыннан түгелме?

Х ә л и л. Күзләремә кара.

А н н а. Ходайдан куркам.

Х ә л и л. Кара, кара.

А н н а. Күңелемнең берчакта да болай куанганын белмим.

Х ә л и л. Былбылым! (*Үбәргә тели.*)

А н н а. Юк, юк... Болай да. Язык була, куркам.

Х ә л и л. Ә хәзер мине сабыр гына тыңла.

А н н а. Инде син дә мине куркытасың. Әле генә булып узганнар татлы төш кебек кенә иде. Син уятырсың да... Куркыныч! Сап-салкын хөҗрәдә мин бер үзем. Йозак, рәшәткәләр. Кирилловны иярткән анакай, пыр тузып, монда төшеп килә. Юк, юк... Барысы да чын бугай. Кошлар оча. Яфрак шыбырдый.

Х ә л и л. Кириллов белән анакай давыл уйнатып монда таба киләләр! (*Елмаеп.*) Куркуны бер читкә куеп торыйк. Без — икәү. Бер солдат — бер солдат, ике солдат — отряд, диер иде безнең Вилдан агай.

Анна. Кем ул?

Хәлил. Син аларны күрерсең. Гаҗәп шәп кеше. Әле Федор Максимович дигәне бар. Безнең ячейка рәисе. Әкәмәт уңган кеше.

Анна. Әйт — курыкмыйм! Икмәктер, курыкмыйм. Алладыр.

Хәлил. Чү, Алла исемен курыкканда гына искә алалар! Без хәзер моннан китәбез.

Анна. Көпә-көндезме? Хәлил, төнне көтик. Караңгыда җиңелрәк булыр.

Хәлил. Булмый, Анна. Төнне көтәргә чама юк. Алар фетнә әзерлиләр! Хәзер яр буенда берәү дә юк. Көймә камыш арасында. Туп-туры Иделгә таба йөзәрбез. Йөзә беләсеңме?

Анна. Беләм дә...

Хәлил. Балтырларыңны каз мае белән ныгытып майла. Көзән җыермас. Син мондагы хәлләрне хәтереңә сеңдер. Фетнә әзерлиләр! Туп-туры Паратскига юл тотарбыз. Ярга якынлашкач, анда сине безнең постлар туктатыр. Каушама. Вилдан абыйны сора. Хәлилдән диярсең.

Анна. Ә син кая барасың?

Хәлил. Дөнья хәлен белеп булмый, Анна. Әгәр көймәгә утырганда сизенә калсалар, ничек тә сине озату ягын карармын. Тоткарлармын мин аларны. Син китә күр. Син хатын-кыз. Син монашка. Көймә белән чыгуың да сәер тоелмас.

Анна. Хәлил...

Хәлил. Шулай кирәк, Анна. Бу тәкъдимне сиңа байтактан сөйләргә кирәк иде дә, мин синең өлгереп җитүеңне көттем. Көнбагышның алтын сары чәчәк атуын көттем. Хәзер үк китәргә, ашыгырга кирәк.

Анна. Хәзер үк?!

Хәлил. Караңгыда китү ышанычлырак булыр иде. Хәвефсезрәк тә! Мәгәр көтү — җинаять. Ярамый. Мин сиңа ышанам. Мин күп уйладым, башка берәр юлы юк микән дип күп сораштым синнән. Шәһәргә чыга алмыйбыз. Күперләр бикле. Ә бу яр иң аулак як икән. Алар төнлә моннан китәргә ниятлиләр икән, хәзер чак кына ваемсыз чаклары. Фетнә турында хәбәр итеп өлгерергә кирәк.

Анна. Куркыныч!

Хәлил. Ә фетнәчеләр үлем әзерләгән йөзләгән, меңләгән кешеләргә ничек? Куркынычмы, түгелме?

Анна. Тотып алсалар?

Хәлил. Тоттырмаска тырышырбыз. Тоткан очрак-

та... Мин балыкчы. Көймә минеке. Син шәһәргә барырга чыккан монашка.

Анна. Таудан ничек төшәрбез? Синең киемнәрең...

Хәлил. Бар булганы белән, Анна. Сайланырга вакыт юк.

Анна. Минем киемнәремне ки дә син кит. Мин калыйм... Сине анда көтәләр. Син аларга кирәк. Син барын да беләсең хәзер.

Хәлил. Минем өчен җанын корбан итәргә торган тугры дустымны ничек монда калдырыйм? Гомерем буе үкенерлек итмә. Әле яши генә башладык бит, Анна. Гомер алда. Кояш эчле чиләк ясамыйча калмыйм мин сиңа.

Анна (*куркып кычкыра*). Монда киләләр!

Хәлил. Китеп калыйк.

Анна. Йөгерәләр.

Хәлил. Лиза түгелме?

Анна. Әгәр Лиза икән, яхшы хәбәр китермәс.

Шалтырап ишек ачыла, Лиза керә.

Лиза. Анна!

Анна. Нигә тагын киләсе иттең?

Лиза. Ай, бу кем?

Анна. Бу... бер балыкчы шунда.

Хәлил. Юк, Анна. Хәзер Лизаны бутарга ярамый. Хәлил мин. Хәлил Якупов. Тимерче. Паратск заводыннан. Тимерче большевик. Коммунист. Беләсеңме? Алайса, Ленинны ишеткәнең бардыр?

Лиза. Сине монда Ленин җибәрдеме? (*Пауза.*)

Хәлил. Әйе. Ленин да җибәрде. Ленин партиясе җибәрде. Мин синең кан дошманың Кирилловны һәм аның иярченнәрен эзәрлеклим.

Лиза. Дөрес сөйлиме ул?

Анна. Син аңа ышан, Лиза.

Лиза. Кириллов сиңа дошманмы? Әчегән кәбестә сыман күпчеп беткән офицерлар да дошманмы сиңа?

Хәлил. Әйе.

Лиза. Безне офицерларга сатып яткан бәдбәхет карчыкның —имансыз аждаһаның да дошманымы?

Хәлил. Барысының да кан дошманы!

Лиза. Алайса, бел: хәзер ул албасты Кирилловны ияртеп монда төшеп килә!

Анна. Беттек.

Хәлил. Курыкма, Анна. Бер солдат — солдат, ике солдат — отряд, өчәү булганда, һөҗүмгә күчәргә дә була. Лиза, үз вакытында искәртүең өчен рәхмәт.

Л и з а. Алар төшеп җиткәнче подвалга кереп бикләнегез. Мин аның ишеген ачтым. Анда корал да бар.

Х ә л и л. Безгә моннан тизрәк китәргә кирәк, Лиза.

Л и з а. Кая?

А н н а. Аяк тавышлары! Бәхил бул, дустым. Ялгыз башың нишләрсең?

Л и з а. Тукта, егет. Бу килеш кая ашыгасың? Ки минем киемнәрне!

Япанчасын салып бирә, Хәлил шуны ябына.

Х ә л и л. Онытмам, Лиза. Сине алырга кайтырбыз без, көт. Көт! Күңелле көннәр алда, Лиза!

Л и з а. Боларын тоткарлармын, каушамагыз. Башкаларга тап була күрмәгез.

Хәлил тәрәзәдән чыга, Аннаны тартып ала. Лиза яланбаш. Чәчләрен туздырып җибәрә. Бераздан А н а к а й белән К и р и л л о в керәләр.

К и р и л л о в. Син?

А н а к а й. Анна кайда, Елизавета?

Л и з а. Белмим.

А н а к а й. Мәңге кичерелмәс язык алып, син качырып тоттыңмы аны монда?

Л и з а. Ни сөйлисездер, хөрмәтле анакай, һич аңламыйм.

А н а к а й (*кискен*). Алла илчесе Изге ана алдында яланбаш басып торасың.

Л и з а. Торсам ни? Чәчләрем матур ич минем. Алар да көнне күрсен. Менә офицер әфәнде дә «матур» диде. Раслагыз инде, анакай шуны да белми. Нәрсәнең ямьсез, нәрсәнең матур икәнен белү кирәк.

К и р и л л о в. Лизочка, минем вакытым аз.

А н а к а й. Сестра Елизавета, җавап бирмәдең.

Л и з а. Пар каенга карап торам. Шушы ак каен җитте бит инде сестра Маринаның башына. «Кешеләр генә түгел, каеннар да парлашып яши»,— диде бит ул үләре алдыннан. Үлде! Ә сез, аждаһалар, шундый затлы кызны зыяратка күмдермәдегез. Чыгарып аттыгыз аның сылу гәүдәсен.

А н а к а й. Җаны мордар киткән бозык затны изге йортта телгә алалармы?

Л и з а. Изге йорт! Анакай да изгедер инде, мөгаен?

А н а к а й. Тый телеңне, дәһри, имансыз.

К и р и л л о в. Лизонька!

Л и з а. Кычкырыгыз, кычкыр. Саңгырау мин, ишетмим. Сукыр мин, берни күрмим. Күзләремне дә, кола-

гымны да шушы имансыз карчык алды. Җаныма да ничә еллар ул хуҗа булды.

Кириллов (*Лизаның чәченнән урап тота*). Чәчең чыннан да матур икән. Әйт, Анна кайда?

Лиза. Җибәр!

Кириллов. Кайда?

Лиза. Кайсы Анна? Кемне сорыйсыз сез?

Анакай. Ул шашкан. Күрәләтә безне мыскыллый.

Лиза. Җи-ибәр! Җибәрсәң бер кызыклы әкият сөйлим. Шуннан аңларсың. Аңламасаң, үзеңә үпкәлә.

Анакай. Сөйләсен.

Лиза (*чәчләрен тузгытып*). Тыңла, әй, офицер кисәге, йолкыш. Бер кеше булган. Аның өч улы бар икән.

Анакай (*шыпырт*). Монда нидер булган.

Лиза. Берсе батыр, икенчесе бик матур икән улларының. Үскәннәр болар, тезелешеп үскәннәр, егет булганнар. Батыры яуга китеп ил саклаган, матуры укырга тотынган, галим булган. Батырын гаскәр башы, матурын ил агасы итен сайлаганнар. Матур да, батыр да булмаган өченче ул матурлыктан да, батырлыктан да гомере буе көнләшеп яшәгән һәм шымчы булып киткән. Авызы — башмак, танавы — тукмак, акыл ягы шыгырдавык капка төсле ачыла да ябыла икән. Син, офицер кәмәше, әнә шул өченче улсың. Сиңа бәхетле өлеш чыкмаган.

Кириллов (*аның чәчен яңадан урап тота, башын стенага бәрә-бәрә*). Кайда Анна? Кайда?

Анакай. Бу ниткән кан таплары? Кем баш киеме бу? Ирләрнеке? Фуражка?

Кириллов. Фуражка? Әһә! Ялгышмасам, мин бу фуражканы кичә кичтән генә бер ахмакның баш түбәсендә күрдем. Бу тәрәзә кая чыга? Яр буена? Яле, песием, йомшаккаем, сөйлә.

Анакай. Сорый белмисең, җебегән!

Кириллов. Кем монда җебегән диде? Анакай, ярама кагылмагыз!

Лиза. Анна суда. Судагы балык. Анна күктә. Һавадагы кош. Анна җирдә. Җирдәге җылан. Һе, тотып карагыз аны. Мин курыкмыйм сездән. Берегездән дә курыкмыйм. Сезнең кем икәнлегегезне белгәнче генә курка идем. Ишекне тышкы яктан биклим дә ачкычны кое төбенә ташлыйм. Рәхәтләнегез аулакта. Пар килгәнсез.

Анакай (*янап, Кирилловка*). Йә. Сүзең, ни?

Лиза. Сасыган чуртан балыгы белән исләнгән кәҗә түшкәсе.

Кириллов. Җиттеме сиңа?!

Анакай. Җебегән! (*Браунинг чыгара да ата, Лиза егыла.*) Мә. (*Кирилловка.*) Әйдә, җебегән.

Лиза. Явызлар... (*Үлә.*)

Анакай. Йөгер! Тап Аннаны! Анысын да! Тавыш куптар! Тап диләр сиңа!

Кириллов. Монда Аннадан да кирәгрәге булган. Әгәр шушы фуражка кигән башны бүген кыеп төшермәсәм... Ул монда булган! Куарга! Әй, кем бар анда. Тотарга.

Анакай. Кит юлдан, җебегән! Мин әйттем «җебегән» дип... Сиңа ышанган мин җүләр. Үзем алып барам отрядны! Үзем!.. Кан телим!

Сәхнә караңгылана.

Идел яры. Беренче күренештәге урын. Көймә кәмәше янында Вилдан басып тора. Фролов керә.

Фролов. Юк Кириллов. Таба алмадык. Юк. Синдә ни яңалыклар?

Вилдан. Хәлилдән дә бер ым юк, Федор Максимович.

Фролов. Димәк, ул да югалды...

Вилдан. Егетне харап итеп ташламадылармы икән? Шыксыз утрау бит ул, җылан оясы.

Фролов. Белештек. Кириллов төнлә дә өендә булмаган. Лениннан телеграмма килгәч, заводның ябылмаячагын белгәч, эсерлар чыгырларыннан чыкты. Ә шул чакта председательләре югалып йөри. Кайсы яктан безне чалырга чамалыйлар алар?

Вилдан. Әллә кайчан заводтан куасы иде аларны, Федор Максимович!

Фролов. Вакыты җитәр, куарбыз да.

Вилдан. Тизрәк җитсен иде ул вакыт.

Фролов. Корабльләр әзер. Кәрван юлда. Алар да Троцкий директивасына буйсынмаган. Хәл кисkенләшә. Сул эсерлар белән нидер эшләргә кирәк булыр.

Вилдан. Миңа да заводка кайтсам яхшырак булмасмы?

Фролов. Әгәр Хәлил кичкә кайтып җитми икән, утрауга син китәсең.

Вилдан. Көймә дә хәстәрләп куйдым инде, Федор Максимович. Нигә кичне көтәргә? Хәзер кузгалам. Көтәргә яратмыйм.

Фролов. Вилдан, көймә! Әнә килә!

Вилдан. Күрмим.

Фролов. Әнә ич, әнә килә. Менә бу якка карагыз.

Вилдан. Ничә көн, ничә төн йокы, ял күргән юк. Карасам, Идел белән күк бергә кушылып зәңгәрләнеп ага.

Ф р о л о в. Чын көймә, Вилдан.

В и л д а н. Күрдем. Килә. Иртән дә берәү узды. Тик ул бөтенләй башка якка, аска кыеклап узды.

Ф р о л о в. Акрын кыймылдый.

В и л д а н. Егет аргандыр. Агымга каршы ишә бит.

Ф р о л о в. Улмы, түгелме? Нигә шулай озаклады ул?..

В и л д а н. Ул булырга тиеш. Хәзер Идел өстенә чыгарга курка халык. Нәрсәгә тукталды ул?.. Чишенәм дә каршысына йөзеп керәм. Түзәр чамам калмады. (*Күлмәген сала башлый, туктала.*) Юк. Ул түгел, Федор Максимович. Ишүе әллә ничек. Туп-туры барган көймә әнә кая кыеклады.

Ф р о л о в. Барыбер көтәбез.

В и л д а н. Башка кеше. Бүтән кеше.

Ф р о л о в. Әйе, хатын-кыз.

В и л д а н. Ялгыз хатын-кыз мондый көндә нишләп йөрер икән?

Ф р о л о в. Безне күрде. Ишүдән туктады.

В и л д а н. Әй, әй, апамы, сеңелме?! Мондарак тартыл. Тизрәк иш! (*Пауза.*) Агым көчле анда. Шуңа борылыпсарылып йөри. Ныграк тот!

Ф р о л о в. Якынайды. Бер үзе. Монда табарак ишегез, монда!

Йөгереп чыгып китәләр. Су чопырдаган тавыш. Өчәүләшеп каты яраланган Х ә л и л н е алып керәләр. А н н а, япанчасын салып ташлаган. Ак күлмәктән. Яланбаш. Хәлил һушсыз.

В и л д а н. Хәлил туган, Хәлил, яраландыңмы?

Ф р о л о в. Хәлил иптәш! Без сине көтәбез.

Х ә л и л. Анна, су.

В и л д а н. Мә, эч, Хәлил. Хәлең ничек?

Х ә л и л. Анна, син иш, иш. Бер дә туктама.

В и л д а н. Борчылма, Хәлил. Кайтып җиттең инде.

Х ә л и л. Кояш эчле чиләкне ясап булмас инде. Су!

А н н а. Хәлил, Хәлил!

В и л д а н. Тагын һушын җуйды.

Ф р о л о в. Юк. Ул үлде. Вафат.

А н н а. Үлде?

Ф р о л о в. Сүзе үзе белән китте.

В и л д а н (*Аннага*). Син кем? Хәлил көймәсенә ничек килеп эләктең?

А н н а. Чыннан да вафатмы? Хәлил! Син үлдеңме? Ә анда, монастырьда, Кириллов исән калдымы? Йа Ходай.

Ф р о л о в. Кириллов?!

А н н а. Әйе, ул. Офицер. Бүген төнлә аларның отрядын алырга катер килергә тиеш. Корал алырга. Безнең

подвалларда корал бик күп. Пулеметлар, мылтыклар. Тартма-тартма патрон. Бүген төнлә фетнә. Паратскида фетнә.

Фролов. Фетнә?!

Вилдан. Кириллов? Фетнә! Димәк, сул эсерлар котырына.

Фролов. Вилдан агай! Син Хәлилне кара! Мин ячейкага, заводка. Хәзер үк утрауны камарга кирәк! (*Аннага.*) Рәхмәт, сеңлем. (*Чыга.*)

Анна. Хәлил... Хәлил җаным... Таптым да, югалттым да мин сине. Кодрәтле Аллам! Нигә син аның җанын саклап кала алмадың? Ишетәсеңме мине, Аллам? Мин сиңа табындым, ялвардым, нигә коткармадың аның җанын?

Вилдан. Сабыр ит, балам. Сабыр!

Анна. Ничек сабыр итим ди мин?! Хәлил юк бит. Кояш эчле чиләк тә юк, күктә кояш та юк, күктә Алла да юк. Әгәр булса, әгәр булса... Шундый асыл җанны әрәм итәр идеме? Юк, мин сабыр итәргә теләмим. Бая моннан киткән абыйлар утрауга баралармы?

Вилдан. Әйе, балам.

Анна. Мин дә алар белән барам! Мин юлын да, урынын да беләм. Барын да беләм! Мин дә алар белән барам. Миңа да мылтык бирегез!

*1973—1974*
*Мәскәү — Казан*

# *Җан җылысы*

*Драма 3 пәрдәдә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Таймас Шабанов — электә тимерче, хәзер пенсионер, 75 яшьтә.
Сабира — аның карчыгы, 75 яшьтә.
Локман Шабанов — олы уллары, нефтьче, 55 яшьтә.
Кәүсәрия — аның хатыны, эшче-төзүче.
Госман Шабанов — икенче уллары, нефть оешмаларының берсендә җаваплы хезмәткәр.
Урал Шабанов — өченче уллары, шәһәрдә горком секретаре.
Якут — аның хатыны, балалар врачы.
Мирхәт — кече уллары, газ-бензин заводында мастер.
Лилия — аның кызы, 13—14 яшьтә.
Регина — күрше хатын, геолог.

Вакыйга 1970—1971 елларда Иске Әлмәттә, Таймас Шабанов йортында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, сәхнәдә шау-шу бара. Шактый зур төркем халыкның гөжләгәне ишетелә: җыелыштан тәнәфескә чыккан халык залга агыла икән, шуның тавышы. Менә звонок шалтырый. Тавышлар язгы су кебек акрынлап тына. Пәрдә күтәрелә. Сәхнә аша ашыгып-кабаланып кешеләр уза. Тәмәкеләрен сүндерә-сүндерә, ирләр ашыга, буфеттан эләктергән апельсиннарын, сөт шешәләрен сумкаларга тутыра-тутыра, хатын-кызлар уза. Мирхәт керә дә берәүне эзли, табалмагач, күзгә чалынмаскарак тырышып, бер почмакка баса, тәмәке кабыза. Урал узып барган җирдән Мирхәтне күреп туктый.

Урал. Звонок булды, ятьрәк керик.

Мирхәт. Суырып кына бетерим инде, абый. Имчәк төбе — иң татлысы!

Урал. Төпчек малай татлыны ярата! Корбановтан соң сүз минеке.

М и р х ә т. Җыелышның тәртибе шулайдыр, абый. Горком секретаре сөйләми калмыйдыр.

У р а л (*гадәттәгедән кискенрәк итеп*). Тәртибе башкачарак планлаштырылган иде аның. Хәзер Госман абый сөйләргә тиеш иде. Тәнәфескә кадәр аның исемен байтак талкыдылар. Нигә килмәгән ул? Нигә чыгыш ясамый? Нигә качып йөри?

М и р х ә т. Ялагайлар күп, ишеттерерләр.

У р а л. Керик, хәзер башлана.

М и р х ә т. Күрәсе кешем бар.

У р а л (*фикерен дәвам итеп*). Килми калма дип, кичтән үзем шалтыраттым. Сүзнең кискен һәм ирләрчә буласын белә иде. Имеш-мимешләргә, юк-барга халык алдында чик куеп, дөреслеккә ирешә ала идек. «Шабановлар ызгышып яши!» дигән ачы гайбәт тә күмелер иде. Җитәкчеләр турында гайбәт таратырга яратучылар юк түгел.

М и р х ә т. Керә тор, Урал абый.

У р а л. Госман абый килмәгәч, син дә качарга булдыңмы?

М и р х ә т. Нишләп качыйм ди?

У р а л. Күреп торам!

М и р х ә т. Әйттерден тәки. Госман абый урынында булсам, мин дә килмәс идем. Кеше чирләп ята, син аны яман каты тешләтәсең, үзең дә тәнкыйтьләргә җыенасың.

У р а л. Чирләп ятмый ул, хәйләгә сабышып ята. Ә син, Госманга яхшы атлы булу өчен, җыелыштан качасың.

М и р х ә т. Кирәкми, абый. Болай да Әлмәтне сасыттык. Ызгышып яшиләр дигән даныбыз таралды. Нәрсә өчен диген әле?.. Юк өчен бит! Үзара талашасыз икән, мине бутамагыз.

У р а л. Вакыт. Мине чакыралар. Син китәсе булма!

Кереп китә. Аяк тавышлары тына. Менә Мирхәт көткән кеше дә күренде. Ул — Р е г и н а.

Р е г и н а. Сүзегез бармы әллә?

М и р х ә т. Үзегез нидер әйтергә телисез. Белдемме?

Р е г и н а. Тәнәфес тәмам. Хәзер башлыйлар.

М и р х ә т. Туй түгел әле. Штрафной белән җәфаламаслар.

Р е г и н а. Хәзер Урал абый сөйләргә тиеш. Шабанов. Горком секретаре. Аны һәрвакыт яратып тыңлыйлар.

М и р х ә т. Зарыккансыз икән Шабановны ишетергә.

Р е г и н а. Гаҗәп. Аның ни сөйләргә җыенганын белгән күк сөйләшәсез.

М и р х ә т. Татарстан нефте бер бүген генә ачылмаган. Шабановлар да Әлмәттә әллә ни гомердән яшиләр.

Р е г и н а. Урал абыйны яратмаган беренче кешене күрәм.

М и р х ә т. Тагын булырлар әле! Шабановлар, җыелыш саен талашып, халыкның күңелен кайтарып бетерделәр. Хәер, сез бездә яңа кеше бугай. Күптән түгел генә күренә башладыгыз.

Р е г и н а. Күзегез үткен. Әйтегез әле, Шабановлар нигә талашалар?

М и р х ә т. Дан бүлә алмыйлар.

Р е г и н а. Дан кайсысына күбрәк җитми соң? (*Үтеп китәргә тели.*)

М и р х ә т. Сүзем бар дигән идем. Оныттыгызмы?

Р е г и н а. Яңа кеше буларак, мин анда тыңларга телим. Тиз тотыгыз.

М и р х ә т. Тормыш җыелыш түгел, регламент куймагыз.

Р е г и н а. Кыланчык икәнсез сез, бусы ирләргә килешми.

М и р х ә т. Сезнең дә миңа сүзегез бар. Ялгышмыйммы?

Р е г и н а. Мәзәк. Сизгер абый икәнсез.

М и р х ә т. Күзем үткен. Ун патронга туксан җиде очко җыям. (*Бармак янап.*) Ничә тапкыр миңа борылып карадыгыз.

Р е г и н а. Аһ, менә нәрсә... Караган өчен акча сорыйсызмы?

М и р х ә т. Акча үзебездә дә җитәрлек, начальство ук булмасак та, төшеп калганнардан түгел. Әлмәттә акчаны теләгәнчә тотып кына булмый, шәһәр бәләкәй. Бер үтенечем! Карышып тормассыз дип уйлыйм, чөнки бу теләкне сезнең серле күз карашыгыз тудырды.

Р е г и н а. Сәер. Тизрәк тотыгыз.

М и р х ә т. Кыскасы, ресторанга барабызмы?

Р е г и н а. Әлбәттә, икәүдән-икәү генә инде? Әлбәттә, монда түгел — Бөгелмәгә! Шулаймы? Әллә сезнең планнар башкачамы?

М и р х ә т. Көне бик уңайлы. Эштәгеләр җыелышта дип беләләр...

Р е г и н а. Хатын?

М и р х ә т (*яңгыратып көлеп*). Ул да шулай дип ышана.

Р е г и н а. Тәкъдимегез мине кызыксындырды. Тик бүген Урал абыйны тыңлыйсы килә. (*Кузгала.*)

М и р х ә т. Мин сезнең исемегезне дә белмим. Телефоныгызны әйтегез, ичмасам.

Р е г и н а. Исемем Регина. Өйдә телефоным юк. Эшкә шалтыратканны яратмыйм, хезмәттәшләрем дә өнәми.

М и р х ә т. Минем сезне югалтасым килми.

Р е г и н а. Теләгегез ихлас икән, табарсыз.

М и р х ә т. Соң ул Урал абыйның, Шабановның диюем, әйтер сүзләрен түкми-чәчми мин дә сөйләп бирә алам.

Р е г и н а. Әкәмәт! Бусын арттырдыгыз.

М и р х ә т. «Нефтьне күп чыгарырга кирәк... Газны әрәм-шәрәм итмәскә... Җир-суларны саклыйк... Елгалар корымасын... Күлләр кипмәсен... Кош-корт кимемәсен!»

Р е г и н а. Бу сүзләрнең кадере бетте дип саныйсызмы?

М и р х ә т. Трибунага чыгып сүз кибәге очыру ансат ул! Теләсә ни сөйләргә була. Тормыш трибуна артында төзелми.

Р е г и н а. Ир-егетнең сүзе эшеннән аерылмый.

М и р х ә т. Сезнең он иләгәнегез бармы?

Р е г и н а. Булмыйча.

М и р х ә т. Бер дә түкми-чәчми бер уч он иләп тә булмый. Ә монда йөз миллионлаган тоннасы белән чыга. Түгелә ул. Йә торба шартлый. Йә башкача. Әрәм булмый нишләсен? Калганы да йөз миллион тонна ич аның!

Р е г и н а. Мин сезне аңладым.

М и р х ә т. Госман Шабанов идарәсе нефтьне иң күп чыгара һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, иң күп әрәм-шәрәм дә итә.

Р е г и н а. Елгаларны иң күп пычратучылар да алар. Нефтьчеләр юлларны, күперләрне бозалар. Чәчүлек җирләрне күпме харап итәләр. Су үткәргечләр ярылып, кырларда боз таулары ясала. Ә нефтьчеләр үзләре иписез, сусыз, ниһаять, табигать матурлыгыннан тыш яши алалармы? Госман Шабановның гаебе бармы монда? Бар! Сез Госман Шабановның нәни генә адвокаты икәнсез.

М и р х ә т. Уттан качам дип тәмугка кердем. Шундый яшь, матур хатын. Сурәтен газета саен басарлык. Ә җыен юк-бар белән агуланып өлгергән! Нефть өчен талашалармы Шабановлар?

Р е г и н а. Ни өчен соң?

М и р х ә т. Һәркемнең беренче буласы килә. Кемнән булса да өстенрәк булырга омтыла кеше.

Р е г и н а. Кызык кеше икәнсез сез, Мирхәт абый!

Кереп китә, ишек ачылганда кул чапкан тавышлар ишетелә.

Мирхәт. Регина! Чү, бу йон тәпи «Мирхәт абый» диде түгелме? Күзен алмый утырды... Каян исемне белеп өлгергән? Хәйләкәрме, әллә күптәннән күз атып йөриме? Кулга төшерәм мин бу нур төргәген!

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл өй эче. Кухняга һәм кече якка керә торган ишекләр. Телевизор. Диван. Бер якта олы мич. Сәгать иртәнге уннар тирәсе. Өйдә Сабира белән Таймас.

Сабира (*кече яктан килеп чыга*). Таймас, бу нинди ят тартма?

Таймас. Нинди тартма? Кайда тартма? Ә-ә, андый тартма гына икән. Бу тартма шундый хикмәтле тартма ки, аның өчен синең эчең сызмасын.

Сабира. Сиңа хикмәтле булгач, миңа да йогынтысы бар түгелме аның? (*Таймас дәшми, көлә.*) Өченче көн генә кече якны сөртеп, юып чыгардым, бер нәмәкәй юк иде.

Таймас. Һи-и, өй иияләре китереп куйгандыр.

Сабира (*тартманы ачып*). Аллакай гынам, каян алдың бу курчакны?

Таймас. Нинди курчакны? Кайда? Кемнән? Ә-ә, андый курчак кына икән. Курчак фабрикасының директоры махсус безгә җибәргән моны, карчык. Сез, дигән, карт белән карчык, ике бөртек кенә, әтәч белән тити, дигән. Икегезгә дә быел җитмеш бишәр яшь тулды, дигән. Дүрт улыгыз, өч кызыгыз үсте. Шабановлар токымын ишәйттегез, дигән. Әмма хәзер өегез язгы бура төсле буш, дигән. Менә шушы курчакка исем кушыгыз да, кадерләп түрегездә тотыгыз, дигән.

Сабира. Тәүбә, диген. Түрдә сын тотарга!.. Пенсия акчасын суга салган икән. Әйтәм җирле, шыпырт йөри. Кемгә атап алдың? Күзләренә тиклем мелт-мелт йомыла бит шөкәтсезнең. Әнекәйләрем, әллә сөйләшә дә инде?

Таймас. Сөйләшә дә, сер ала да белер ул. (*Көлә.*) Күрше кызына ул, Фәридәгә.

Сабира (*үпкәләп*). Йөр инде, йөр. Кылан туйганчы. Үз балаларыңны нигезеңнән читләштер дә, күрше кызына карап куан. Әйдә, көлдер кеше. Ярар.

Таймас. Үз балаларымны да читләштермим. Дөрес әйтмисең, карчык. Соңгы атналарда сирәгрәк киләләр икән, аның сәбәбе дә бик мәгълүм.

С а б и р а. Мәгълүм шул! Бөтен Әлмәт белә. Сине күрәсе килми аларның, сине! Нигә бусы алай, тегесе болай түгел дип, җыен юк-барга тылкышып, таза тештән корт эзләп даим теңкәләренә тигәнгә килмиләр балалар безгә.

Т а й м а с. Килсәләр, шахмат уйнар идек әле бер! Синең белән күңелсез, карчык. Шашкы уйный да белмисең бит, шахматны әйткән дә юк анысы.

С а б и р а. Йөрүеңнең үк рәте юк бит синең, сул аягың алга атласа, уңы артка сөйрәлә башлый.

Т а й м а с. Анысына немец снайперы гаепле.

С а б и р а. Кирелегеңә, үҗәтлегеңә дә мимеч гаепле!

Т а й м а с. Кирелеккә дә мимеч өйрәтте. Аягым яралы килеш, керфек тә какмыйча, немец снайперының үзен белдергәнен ике сәгать ярым көтеп яттым. Аннан соң... (*Кул хәрәкәте ясый.*)

С а б и р а. Кирелегең биш кешегә җитәрлек, мимечтән тыш та.

Т а й м а с. Җитмеш биш ел дөньяда яшәү өчен шактый кире булырга да кирәктер, Сабира.

С а б и р а (*һаман курчакны йолыккалап*). Җиде-сигез тәңкә бардыр бу әкәмәт. Акчаны юкка исраф иткән өчен, рәнҗешем төшәр әле.

Т а й м а с. Синең рәнҗешең дә баллы яңгыр кебек кенә, Сабира-ау!

С а б и р а. Үтә чыгып юхаланасың бу араларда, тагын да зуррак этлегең бардыр, мөгаен.

Т а й м а с. Кеше гел гаепсез булса, узган гомере турында уйлап та карамас иде. (*Числоның битен ертып.*) Уза көннәр. Күктә яшь килен ястыгы калынлыгы кара болытлар. Калхузлар исә бәрәңгенең яртысын гына алып бетергән.

С а б и р а. Син корыга хафаланып ятканнан ни файда? Нигә әле яшь килен дигәнне искә төшерәсең? (*Таймас көлә, дәшми.*) Тагын кая титаклыйсың?

Т а й м а с. Аязытып җибәрмиме икән? Аякның сызлавы кимер иде.

С а б и р а. Мунча өлгерә, ерак китмә. Чабынып чыксаң, җиңеләерсең.

Т а й м а с. Килми малайлар... Шахмат уйнап алыр идек.

С а б и р а. Син гаепле, син!

Т а й м а с. Тормышлары көйле. Шуңа килмиләр! Берәр заман берәрсенең тормышы җайсызга китсәме, мүкәләп килеп җитәрләр.

С а б и р а (*күз яше аша*). Үз балаларының тормышы көйсезләнгәнне теләп утыра, ата диген син аны.

Т а й м а с. Теләмим. Син дә, май салган кайнар таба төсле, «гаепле, гаепле» дип туктаусыз чожлап утырма. Рәхәт яшиләр, дим, ата-ананың кирәге юк. Рәхәт бүлешергә иптәш бар балаларга, кайгы-хәсрәт килсә генә ата-ана кирәк. Гомергә шулай булган. Безнекеләр дә шулай. Рәхәтлек ата-ананы да оныттыра.

Чыга. Сабира, кәефсезләнеп, кече якка кереп китә. Пауза. Р е г и н а керә.

Р е г и н а. Күршеләр! Сабира апа! Ау! Гомергә бер кая чыкмаганны әллә берәр яры киттеләр инде? Ау-у, Сабира апа. Монда икәнсез.

С а б и р а (*керә*). Укып яткан җиремнән оеп киткәнмен, оятлы булдым, Регина. Оеп та киткәнмен, төш тә күреп ятам. Абзаң синең кызың Фәридәне иң өстенә утырткан да кәлә-көлә ишегалды тирәли титаклап йөгерә, имеш...

Р е г и н а (*уңайсызланып*). Төш юрый белмим, Сабира апа.

С а б и р а. Сукыр үзенекен тукыр дигәндәй, синдә ни хәлләр?

Р е г и н а. Мунча идәнен юып чыгардым, себерке керттем.

С а б и р а. Рәхмәтләр мул яусын, Регина, сез күчеп килгәннән бирле, ел ярым булдымы инде, кулдан авыр эш китте. Әлекке күршебез белән дә бик тату яшәдек, бәхетебез бар.

Р е г и н а. Ай-һай, суны мул ташый Таймас абзый. Чапчакларны тутыра, баклар мөлдерәмә, таслар да күздән. Кирәкми димен... һаман артыгын ташый. Мунча саен шулай. Кунак көтмисездер бит?

С а б и р а. Кунакны бик көтәбез, Регина, юклар... Балалар килсә дә, мунча кереп маташамы хәзер? Кунак сыйлау бик ансатлашты, сизәсеңдер. Киләләр дә телевизорга кадалып каталар. Кечесеннән башлап олысына хәтле шулай. Җыелып тиз-тиз генә шешә төбе ялтыраталар да, хапы-хопы табындагы ризыгыңны йоталар. Күзләре һаман шул зәңгәр җендә. Син көне-төне янып хәстәрләгән буласың, юк җирдән бар итәргә тырышасың, аларга ни, кайнар бәлеш ашыйлармы, киндер тастымал чәйниләрме, барыбер. Аннан шахмат дигән казасы бар! Кадалалар шуңа! Әй сөйләтмә дә, сөйләмә дә, Регина. Синнән сорыйсы бер сүзем хәтеремә төште.

Р е г и н а. Сорагыз, Сабира апа.

С а б и р а. Үзең олы гына эштә икәнсең, коммунист та диләр, сезгә теге яңа йортлардан, газлы-ванналы өйләрдән фатир бирмиләрмени соң? Әнәтерәк бит, Әлмәтне кайлардан кайларга җәйделәр.

Р е г и н а. Әнкәйнең андыйдан аласы килмәде. Ә минем Әлмәттә каласым килде.

Т а й м а с керә.

Т а й м а с. Мунчаны Сахара чүле иткәнсең, Регина.

С а б и р а. Үзем дә мактап торам. Берәүләр хас киленнәреннән дә ул хәтле кадер-хөрмәт күрмәсләр, рәхмәт, күрше, гомерең озын булсын.

Т а й м а с. Безнең кебек тигез яшә дип тә өстә.

С а б и р а. Әйе, әйе.

Р е г и н а. Бусы юк инде, Сабира апа. Булмас та кебек тоела.

С а б и р а. Синдәй уңган, синдәй сылу хатынга үз ишедәй әйбәт кеше табылмый калырмы?

Р е г и н а. Әйбәт кешеләр дә бар. Күңелем тартмый... Булгаладылар, җил ягыннан да, каршыдан килеп тә кул сузып карадылар. Яучылар да йөрде, күрәсез, чыкмадым.

Т а й м а с. Сузган җылы кулны алмадым диген...

С а б и р а. Ай аллакай гынам, сузылган кулны кире этәрерлек итеп күңелеңне кайсы юньсезе кайтарды икән? Фәридәнең этисе исән-саумы?

Р е г и н а. Бусын сорамагыз, Сабира апа. Аның этисе бик еракта, бик тә еракта.

Т а й м а с. Шулай ук еракта икән?

Р е г и н а. Күңел ераклыгын әйтәмдер, бәлки...

С а б и р а. Нинди кеше иде? Нинди кеше баласы? Ай, юньсез... Шундый хатынны ташлап марҗалар белән себерелә торгандыр.

Т а й м а с (*сүзне бүлергә теләп*). Капка шыгырдады түгелме?

С а б и р а (*яман чәпчеп*). Яз башыннан колагыңа тукыйм, тәки шул капка күгәнен адәм төсле майлап куя алмадың, авыр аяк.

Т а й м а с. Әйдә, тик утырсын җырлап, җан ияләренә сәлам биреп. Юри майламыйм. Ишек-капкам һәркемгә ачык, җырлап ук каршы ала. Капка шыгырдамасын, морҗа уламасын, пыялалар зыңгылдамасын, тирә-якта күңелгә ятышлы нинди тавыш кала? Самолет улаганын ишетәсең киләме?

Р е г и н а (*карап*). Сәгать әнә күпме булды. Чыгыйм

инде, Фәридәм дә кайткандыр. Кызымны сирәк күрәм, ярты гомерем кырда, яртысы юлда уза.

Таймас (*Регинаны чыгарып җибәрергә теләмичә*). Ничегрәк соң, күрше, яңа ятмалар табыламы? Бетмиме әле җир мае?

Регина. Нефть бар. Әлегә бар. Табылып та тора. Җир шарында нефть табылган унике мең урын бар, мәгәр шуларның йөзләбе генә файдалы чыганак. Барлык нефтьнең алтмыш проценты әнә шул бай чыганаклардан алына...

Таймас. Безнең Тимәш!

Регина. Тимәшкә тиң яңаларын эзлибез.

Сабира. Эш кешесенең вакытын аласың. Чыкса ни дә нефть сиңа, чыкмаса ни... Тфү!

Регина көлемсери, чыгып китә.

Таймас. Нигә күрше кешене куып чыгардың?

Сабира. Күзен алартып көн озын аңа карап утырыр иде бугай!

Таймас. Икәүләп карар идек. Күзгә-башка ай-һай ягымлы хатын.

Сабира. Күршесенә дә өч хатын-кыз килә бит аның. Бу җүләр шуңа шатлана.

Таймас. Көне-төне сугышырга яраткан берәр пенсионер шахматчы килсен иде миңа.

Сабира. Сугышчы, хи-хи-хи! (*Пауза.*) Регина кергәч, курчагыңның сере ачыла башлады. Мә, бүләгеңне бирергә онытkансың.

Таймас. Тимә. Торсын. Әлегә кагылмый тор. Диванга утыртып куйыйм. (*Утырта.*) Менә шулай. Олы кыз булып утыр. Матур бит? Менә без өчәү булдык.

Сабира. Келәт астындагы чуар тавыкны санасаң, без дүртәү...

Таймас. Кешеләр яшергән серне, бәлки, шушы курчак ачып бирер?

Сабира. Нигә сер ачарга маташасың син? Кем серен? Нигә аны миңа да сөйләмисең? Илле биш ел бергә торып болай яшертен эш иткәнең юк иде.

Таймас. Курчак кыз, сөйләш әле минем белән? Кызым, акыллым? Кем синең әтиең?! Әниең әйткәнчә, ерактамы ул, бик ерактамы?

Сабира. Исәрләнде карт, җиңеләйде...

Таймас. Капка шыгырдады!

Сабира. Ай Аллам, шулаймыни? Балаларның берәрсе килә-нитә калса, казаным асмаган, чәй янына куярга

ризыгым юк. (*Таймас рәхәтләнеп көлә.*) Җитмәсә ял көне. Таймас, йөгереп кенә кибеткә...

Таймас рәхәтләнеп көлә. Сабира моны сизеп туктый.

Т а й м а с. Әй, Сабира, әле берәү дә килмәгән... Бәлки, җил шаяргандыр? Балаларның берәрсе килсә — алдан ук сөйләшик —биләмә аны! Томалама аларның авызын чәйшикәр белән! Томалама колакларын тәлинкә-чынаяк тавышы белән.

С а б и р а. Ә мин синең шахмат тактаңны ягам.

Т а й м а с. Сөйләшәсем килә. Иркенләп гәпләшәсем килә. Җитмеш биш ел гомер аз түгел. Кояш та әнә бер чыгып, бер баеп арып бетәдер. Шуңа күрә көзен-кышын аз күренә ул... Малайларга әйтәсе сүзләр дә җыйналды. Шатлык белән кагалармы капкаңны, бәла килепме, сабыр бул, Сабира.

С а б и р а. Ә мин синең телевизорыңның шөрефен яшереп куям.

Таймас көлә, кул болгый. Икесе ике якта кул баглап утыралар. Пауза. Г о с м а н керә.

Т а й м а с. Гроссмейстер килде!

Г о с м а н. Саулармысыз.

Т а й м а с. Исәнме. Уз, улым, уз.

Г о с м а н. Урамыгызны һаман рәтләмәгәннәр икән.

С а б и р а. Сал, сал, җылы башмак бирәм. Мә, ки. Мич буенда гына тотам мин аларны, җылыда.

Г о с м а н (*курчакны кулына ала*). Бу нинди әкәмәт?

С а б и р а. Гөнаһ шомлыгы, этиең алып кайткан.

Т а й м а с. Дөньяда ни яңалыклар? Ниндәен без белмәгән ят хәбәрләр бар, улым?

Г о с м а н (*каш җыерып*). Дөньядан ук тотындыңмыни бүген? Аннан аерым-аерым илләргә, аннан үзебезнең туган Татарстанга, аннан килеп Әлмәт шәһәренә күчәсең инде син. «Урамыгыз пычрак» дип ялгыш ычкындырдым. «Нигә шуны төзәтмисез?» дип бәйләнә башлыйсың. Шулаймы?

Т а й м а с. Әнә, Шәрәфиләр бакчасы турында торба шартлаган, тозлы, зәһәр исле су агып ята. Ул торбаларның хуҗасы син диләр.

Г о с м а н. Шуннан.

Т а й м а с. Андый зәһәр су белән туенган җирдә әллә ничә ел үсемлек үсми ди.

Г о с м а н. Шахматың кайда?

Таймас. Әнкәсе, чыгар! Сабира, сүзне мин башламадым.

Сабира (*шахматны чыгарып бирә*). Куандырдың, Госман улым. Әле капка шыгырдагач, кайсысы килде икән дип, күңелемнән ашыга-ашыга юрыйм. Күңел әйтә, Локмандыр, ди. Олы улың... (*Яшен сөртә.*) Мәскәүдән кайтып җиткәндер дә монда сугылгандыр, дим.

Госман. Абый да йөри инде җуләрләнеп!

Таймас (*фигураларны тезеп*). Ак белән уйныйсыңмы, караларны?

Госман. Миңа барыбер.

Сабира. Әле төпчегем Мирхәтме дип ымсынып та куйдым. Хатынының, Рузия киленнең, вәгъдәле вакыты җитеп килә. Син килерсең дип уема да кереп чыкмады.

Таймас. Бытылдама әле, фикерне чуалтасың. Госманны җиңәргә кирәк миңа, олы мастерны!

Сабира. Икмәктер, ягам бу шакмагыңны! Госман, гаепләмә, синең дә буш вакытың буламыни?

Госман. Курчакны Мирхәтнең тумаган баласына алып өлгердегезме?

Сабира. Юк, улым. Бездә, саф татарларда, көн яктысы күрмәгән балага әйбер алып куймыйлар. Гомере кыска була андый баланың.

Таймас. Игътибар итмә аңа. Синең ход, йөр.

Сабира. Нигә Якут киленне ияртмәдең? Хәзер икәүләп табын хәстәрләр идек. Куйган камырым да бар. Әтиеңә әйтми генә куйган идем. Таймас, тизүк кибеткә титакла, тәмлерәк кәнфит кайтмаганмы?.. Госман, дим, быелгы балыбыз әйбәт түгел. Төсе күгелҗем, үзе әче, әткәң, «асфальттан җыйган бал» дип, мыскыллап гел ашап та карамый.

Таймас. Рас түгелмени? Чәчәкле болыннарың, юкәле урманнарың беткәч, бал корты сыйны каян алсын?

Госман. Эчәр җирем юк, рәхмәт.

Таймас. Кәеф юк синең, егет! Атыңны алам бит!

Госман. Гафу ит. (*Атын кире куя.*) Дөньялар тыныч түгел, әти. Барысы кайный, актарыла. Дөнья белән мин дә кайныйм. Орбитадан һич ычкына торган түгел. Дөньядан качып килдем.

Таймас. Безнең өйне дөньяның аръягында тора димсең?

Госман. Кичә зур гына җыелыш булып узды. Урал, гадәтенчә, тагын мине тетеп чыккан. Телефоным иртә таңнан колакны яра. Берәүләр ялагайлана! Икенчеләре

юаткан булып мыскыллый. Бар да астыртын гына тантана итә. Бер чакта да кулларына власть кермәс җилкуарларның гомерне ничек уздыруларын беләсеңме? Власть кешеләре турында тозсыз анекдот сөйләп юанышалар алар. К черту!..

Таймас. Чү, чү.

Госман. Сезнең йорт ялгыз, аулак утрау бит хәзер. Шул хәтергә төште дә хатынга да, беркемгә дә әйтеп тормадым...

Сабира. Ятып тормыйсыңмы, улым? Дөрес әйтәсең, өебез аулак, тыныч. Йоклап алсаң да була, беркем комачауламас. Атаңа карама, җиңеләя башлаган ул.

Таймас. Уйнап кына бетерик инде.

Госман. Мин җиңелдем, күреп торам. Молодец, эти.

Таймас. Алай ансат кына бирешә торган кеше түгел идең бит син, улым.

Сабира Госманны көчләп диярлек алып кереп китә. Таймас ялгызы. Курчакны баягы урынына — диванга иплэп куя. Сабира керә.

Сабира. Балаларга карарга да ирек бирмисең. Әллә кырынмаган да инде?

Таймас. Шаулама. Юри оттырды. Филне менә болай күчергән булса... Әһә! Оттырмый иде. Уенның менә дигән дәвамы бар, Госман.

Сабира (*курчакны алып*). Тагын бу шөкәтсезне түргә куйган.

Таймас. Дәшмә, Сабира. Шаулама.

Сабира. Нишләвең бу синең? Нигә текәлеп торасың шул курчакка карап?

Таймас. Сабира... Синең шул Фәридәгә, Регина кызына, иплэп кенә карап торганың бармы?

Сабира. Кеше баласына күз челәйтмиләр инде. Күз тияр дип, туры да карамыйм. Бер бөртек кызы, үзе тол...

Таймас. Син аның кемгә охшаганын беләсеңме? Көннән-көн бер кешегә ныграк охшый барганын чамалыйсыңмы? Чынлап әйтәм, чынлап.

Сабира. Үскәндә үзе булыр, үсә төшкәч әнкәсе, үсеп җиткәч әбкәсе булыр. Кемгә охшасын тагын?

Таймас. Безнең теге, авылдан ук килгән, чуар тышлы иске альбом кайда?

Сабира. Шунда, медальләрең белән киштәдә түгелме?

Таймас. Госманның яшь чактагы фотолары шундамы?

С а б и р а. Ни сөйлисең син тузга язмаганны? Авызыңнан җил алсын, бигрәк тагын...

Т а й м а с. Госманның фотолары шундамы дип сорадым мин синнән.

С а б и р а. Әллә шул кызны Госманга охшаган дип, әйтер идеңме?!

Т а й м а с. Охшаган шул. Суйган да каплаган.

С а б и р а. Капка шыгырдады.

Т а й м а с. Әйе. Кемдер килде.

С а б и р а. Әллә Госманымны эзләп тә килделәрме? Сиңа әйтәм, теге сүзеңне кешегә тарата күрмә, көләрләр...

Т а й м а с. Тотынма самоварга. Ял итсен.

**Икесе ике якта, үпкәләшкән сыман, кул баглап утыралар. Кулына бәләкәй төен тотып, олы киленнәре К ә ү с ә р и я керә.**

К ә ү с ә р и я (*күз яше аралаш*). Саумы, әти. Исәнме, әни.

С а б и р а (*сикереп тора*). Нигә бер башың? Локман кайтмадымы?

Т а й м а с. Киленгә тын алырга ирек бир.

К ә ү с ә р и я. Кайтмады шул.

С а б и р а. Мөгаен, бер-бер бәлагә тарыгандыр. Ике атна йөри бит.

К ә ү с ә р и я (*борынын мышкылдатып*). Ни булсын ди аңа? (*Ачулы.*) Бер башы, бала-чага кайгыртасы юк, кесәсе тулы акча. Йортта мин интегәм. Көтә-көтә җыгыбыз чыкты. Хәер, хәзер тынычландык, көтмибез. Үпкәләмә, әни. Бүтәннәр төсле файдалы эш артыннан йөрсә икән. Ел саен китә дә югала. Халык алдында оят. Картаеп та акыл кермәде.

Т а й м а с. Тынычлан, килен. Бала-чагалар саумы?

К ә ү с ә р и я. Галиябануымның теше сызлаштыра. Тәмлене бик ярата, төпчек дип үзебез дә бик иркәлибез. Тәмле дигәннән, әни вак-төяк күчтәнәч ияртеп килдем. Өйдә пешкән шадра печенье. Оренбургтагы апамнар юлаучы аша казылык җибәргән. Сезнең өлеш.

С а б и р а. И киленем-алтыным, табынга ни куярмын дип аптырабрак тора идем...

Т а й м а с. Сабира, боларны ераккарак урнаштыр.

К ә ү с ә р и я. Кунак көтмисездер лә?

Т а й м а с. Синнән дә олы кунагыбыз булмас, син — олы килен.

К ә ү с ә р и я. Тиле кеше сыман ишекле-түрле йөрдем-йөрдем дә ярсып чыгып киттем шунда. Кибеткә чыгар-

га, базарга барырга оялам. «Локманың кайда, нишләп йөри?» дип сорасалар, җир тишегенә кер. Шуннан, аптырагач, сезгә киттем. Хәлләрегезне дә белим, дидем. Кая, әни, ни эшлим?

Сабира (*Таймаска карап*). Эшләсәң эш табылыр...

Таймас. Ярар, килен. Тыпырчынма эшлим дип, дүрт бала үстерәсең. Хәзерге заманда ирле-хатынлы булалар да, үз рәхәтләре өчен генә яшиләр. Бала мәшәкатеннән тайчаналар.

Кәүсәрия. Бала тәрбияләү дә кыенлашты шул, эти.

Таймас. Ихлас! Элек бала туар иде дә, укып, өйрәнеп, үз эшенең остасына әйләнер иде.

Сабира. Хәзер туганда ук профессор булып туа баласы да!

Таймас. Дөрес! Аның инде кулына балта-кәйлә тотасы килми, буровойда майланып йөрергә теләми. Шундый-шундый эшләр, килен. Ирең нефтьче. Көн дими, төн дип тормый, яңгырында-карында скважиналар ремонтлый. Нефтьче хатыннары дүртәр бала үстермәсәләр дә, аларга алтын һәйкәл коярлык. Чын нефтәннекне тәрбия кылу үзе бер каһарманлык. Ир-атның мәшәкате болай да таудай. Нефтәннек мәшәкате бермә-бер артык. Киендер, ашат, каткан өс-башын ю, күңелен күр. Баламның кадерен белеп яшисең, рәхмәттән башка сүз юк сиңа, килен.

Кәүсәрия. Тәмле телеңә рәхмәт, эти.

Таймас. Үзең дә мактаулы штукатур. Дөрес, быел салган дүрт йортыгыз, суы киткән буа төсле, байтактан буш тора-торуын.

Сабира (*сикереп тора*). Менәтерәк! Күрдегезме! Кайчан китереп чыгара дип көткәнем раска килде. Таймас, Таймас, тешең коелган, һаман тешләшергә телисең.

Кәүсәрия. Ояты безгә, эти. Алдынгылыкка чыгабыз дип узыша торгач, сыйфат ягын онытып, адәм хурына калдык. Буялган стеналарыбыз дөнья картасы төсле чуп-чуар, ишек-тәрәзәләребез ябылмый...

Таймас. Шахмат уйнарга өйрәнмәдеңме, килен? Пенсиягә чыкканчы өйрәнеп кал.

Сабира. И-и, моңа ни дисең? Тел чарлап вакыт әрәм иткәнче, кая, чуар тавыгымны суеп бир.

Кәүсәрия. Шул мескенне ялгыз интектерәсезме?

Сабира. Әй килен, булса да булыр икән тавыкның зиһенлесе! Тавык мие эчкән дип дөнья ахмагына әйтәләр иде, ә бу шундый акыллы, заман кошы бит, шундый оста кача!.. Авылдан сыер җитәкләп, биш сарык ияртеп килгән

идек,каз-үрдәген ничаклы асрый идек. Курмы җитмәгәч, башкалар төсле ипекәй ашатыр хәлем юк дип, иң әүвәл атаң сыерсыз калдырды...

Т а й м а с. Ирләре юк хатын-кызлар дөньяның көйсез якларын кемгә сылтыйлар икән?!

С а б и р а. Болын калмады дип сарыккайларыбызның башына җиттек. Итләреннән крәчин тәме килгәч, кош-кортны үзем бетерттем.

Т а й м а с (*моңарчы, шахмат белән мавыгып, сүзгә катышмыйчарак утырган иде, хәзер ярсып китте*). Сүзләрегез хак, әй нәмәхрәмнәр! Сыер юк. Сарык та бәәлдәми. Аның караvы нефть мул: Европага елга булып ага. Асфальт та күп, төрле яктан бер кендеккә — Әлмәткә килеп төйнәлгән. Корымы да җитәрлек. Кая карама, күкне кара баганалар терәгән. Җан ияләре генә кими. Урманда куян чабып чыкмый. Эзе дә юк. Усак урманнарында яшь килен чиккән сөлге күк була иде бит куян эзе.

С а б и р а. Тагын яшь килен...

Т а й м а с. Кышкы ак карда сары төлке уйныймы? Кыр тавыгы пырхылдыймы? Керпе дә юк. Хәтта тузбаш җылан да бетте.

С а б и р а. Карга каркылдаса да «сөбханалла!» дип торабыз инде.

К ә ү с ә р и я. Безнең күршедә берәүләр крокодил асрый башладылар.

С а б и р а. Ул җилпуч авыз бала-чагаларын ничек кимереп бетерми, әстәгыфирулла-тәүбә! Телевизордан күрсәтә башласалар да, кече якка качам.

К ә ү с ә р и я. Бәйдә тоталар, ванналарында.

С а б и р а. Килештерәләр икән, җирәнгечләр.

Т а й м а с. Бир сугым пычагын! Тавыкны суям да сиңа иптәшкә тузбаш җылан алып кайтам әле.

Кулына мылтык тотып, кече яктан Г о с м а н керә.

Г о с м а н. Сиңа пычак түгел, мылтык кирәк, ахры.

Т а й м а с. Нишләп?

Г о с м а н. Ауга барырга атлыгып торган кеше күк сөйләшә башладың. Мылтыгыңның көпшәсе күгәреп беткән.

Т а й м а с. Яшьрәк чакта куяндыр, төлкедер аткалый идем. Менә синең бабаң аючы булган.

К ә ү с ә р и я. Оятлы иттегез, әни. Исәнме, Госман.

Г о с м а н. Саумы, Кәүсәрия җиңги. (*Таймаска.*) Ауга

йөргәнеңне хәтерләмим, әмма берәрсенең бәбәе туса, өй кыегына менеп мылтык шартлата идең.

С а б и р а. Дөньядагы калмады инде, калмады...

Г о с м а н. Аугa йөргәнең юк, «куян бетте, төлке уйнамый» дип, бүрәнә аркылы бүре куып утырасың. Обыватель сүзе сөйлисең. Баштагы елларны чыннан да җирне кадерли белмәдек. Хәзер хәл бөтенләй башка бит!.. Нефть дигән буласың... Нефтьсез кая барыр идең икән? Өстеңдәге киемнәргә генә кара. Йә башкаларның өс-башына күз сал. Хәзер, заманча киенү өчен һәркем үз абзарында илле баш сарык асрарга тиеш булыр иде. Әле ярый нефть коткара...

Т а й м а с. Катырак кычкырдык, хата бездәдер, мөгаен... Син олы киленнән уңайсызланма, Госман. Ул да синең шикелле дөньялыктан качып килгән. Аның качу сәбәбе дә үзенчә бик зур, бик мөһим...

К ә ү с ә р и я. Ну, эти, йомшак җәеп катыга утыртасың.

Г о с м а н. Карап-карап торам да, бу утрауда да тынычлык беткән икән.

Мылтыкны ачу белән Таймаска тоттыра да кече якка кереп китә.

К ә ү с ә р и я. Шундый олы кунак барын кем белгән? Шаулашабыз... Җитмәсә җыен юк-бар сафсата сатабыз бит.

Пауза. Сәхнәдәгеләр ымлашып бер-берсе белән сөйләшергә азапланалар. Салмак кына атлап, бераз сагаеп, Р е г и н а керә.

Р е г и н а. Кунак бар икән, исәнмесез.

К ә ү с ә р и я (*кече якка карап*). Кунак дип... Килеп чыктым шунда.

Р е г и н а. Мунча өлгерде, Таймас абзый. Бара башлыйсызмы?

Т а й м а с. Өлгергән дә икән. Чак кына сабыр итсәк ярармы?

Р е г и н а. Бая ялгыш кына күземә чалындымы... Госман абый килмәгәндер бит?

Т а й м а с (*сискәнеп*). Госман дидеңме?

С а б и р а (*усаллана төшеп*). Каян беләсең син аны?

Р е г и н а. Белмичә... Күрешкәләп тә торабыз.

Т а й м а с. Кайчан күрешәсез? Кайда?

Р е г и н а (*көлә*). Киңәшмәләрдә! Ул президиумда. Мин залда.

Т а й м а с. Көн сүрән. Шәүлә дә кеше булып күренә бүген. Болытлы...

Р е г и н а. Әтисе йортына килгәнен күргәнем юк. Шуңа гына әйтүем. (*Чыга башлый, туктала.*) Госман абыйны Әлмәттә генә түгел, Татарстанда беләләр аны! (*Чыга.*)

С а б и р а. Аңламадым. Нигә тиктомалдан Госманны сораштырды әле бу хатын? (*Кәүсәриягә.*) Күреп калгандыр, быткыч... Госман бераз гына ял итә алмасмы дигән идем...

К ә ү с ә р и я. Хатын-кыз белсә-белмәсә сораша ул, әни.

Т а й м а с (*курчакны кулына алып*). Бая мин сиңа бик акыллы сүз сөйли башлаган идем, тыңларга сабырың җитмәде. Әй, Сабира! Теге альбомны кайда диден әле?

С а б и р а. Тинтәкләнмә, Таймас.

Т а й м а с. Анысын карарбыз.

С а б и р а. «Госман абый» дип авызын ерыпмы тора. Затсыз хатын икән! Бер дә алайдыр димәгән идем. И Аллам. Күзеңне акайтма, характерыңны беләм, симезрәк хатын күрсәң, әле дә күңелең уйный.

Т а й м а с. Килен, тыңлама әниеңне. Гомергә көнләшкәне булмады, белмәде дә. Хәзер ашык-пошык, «миннән дә калмасын!» дигән сыман, шул җоланы үтәмәкче. Соңгарак калдың, Сабира.

К ә ү с ә р и я. Теге чуар качкынны тотып керим, булмаса. Ике кулыма бер эш булыр. Тавык шулпасы тәмле була бит ул! (*Чыга.*)

С а б и р а. Килен алдында альбом дигәнеңне бер кузгатсаң, ярык тагарак.

Т а й м а с. Госман турында юкка гына сорамады бу хатын!

Икесе ике якка карап, кул баглап, үпкәләшкән төсле утыралар. Тавышлар ишетелә. М и р х ә т белән Л и л и я керә.

М и р х ә т. Кү-кү! Кунаклар килде. Нигә каршыламыйсыз?

Л и л и я. Бабай! (*Килеп сыена.*) Исәнме, әбием.

С а б и р а. Һай, кызым, һай, күз нурым. Берәр тәмле әйбер бирим әле үзенә. Куллары боз булган. Бияләйсез чыкканмы?

Л и л и я. Эзләдек. Бияләйне папам тапмады.

Т а й м а с. Сабира, сабыр ит. Нихәлләрдә, улым.

М и р х ә т. Тәмле әйбердән мин дә баш тартмыйм. Әмма ашыгам. Кая, тиз! Әниеңнең борыны сизгер: тәмле нәрсә пешергән. (*Борынын сузып иснәнә.*) Бәлешме?

Л и л и я (*кулын чәбәкләп*). Шә-эп!

М и р х ә т. Әллә пилмән бөктегез?

Л и л и я. Пилмән, пилмяшка!

Таймас. Утыр, улым. Иплэп сөйләп бир: эшеңдә ниләр бар?

Мирхәт. Өчпочмак!

Лилия. Чудо!!

Сабира. Әнә әтиең, эшеңдә ниләр бар, ди. Ай Ходаем...

Мирхәт. Нәрсә? Эштә? Эштәгесе эштә калды, төкер, әти.

Таймас. Юк, син сөйлә. Байтактан күрешкән юк. Минем беләсем килә.

Мирхәт (*театраль поза алып*). Беләсең, безнең Миңлебай бөтен дөньяга атаклы. Карәхмәтне чакырырга чатыр-чатыр чабып киткән Миңлебайдан күп атаклырак. (*Иҗекләп, диктант яздыргандагы кебек итеп сөйли.*) Илдәге барлык газ-бензин заводларын бергә җыйсаң, шулардан да куәтлерәк ул безнең завод. Әти, мин ашыгам.

Таймас. Ашыккач, утыр. Шахмат уйныйсыңмы?

Мирхәт. Шахмат? Кемдер башлап куйган моны. Вакыт җиткереп булмый, әти. Бүген бик кирәкле бер кешене эзләп табасым бар, Лилияне өч-дүрт көнгә сездә калдырам. Әти, мылтыкны әзерләп куйгансыңдыр бит! Дарың бармы?

Таймас. Булмыйча!

Мирхәт. Өй кыегына менеп берне шартлатам! Якын-тирә белсен, дөнья ишетсен! Шулай ди торган идең син.

Таймас. Малаймы, кызмы?

Сабира. Ирештереп кенә маташа, явыз.

Мирхәт. Әти, дим, билләһи! Кор мылтыгыңны.

Таймас. Корам, корам.

Сабира. Тизрәк сөйлә, сүзеңнең тозы юк.

Мирхәт. Лилия, аягың лай, түргә үк узгансың.

Лилия. Ну, папа...

Мирхәт. Папа Ватиканда, монда әти.

Лилия. Әти дидем бит.

Мирхәт. Әти дә дисең икән, акыллы кыз, бар, ботинкаңны ышкып кер. Салып ук куйсаң, тагын да килешә төшәр. Бабаңнарда каласың.

Лилия. Телевизорлары эшләми аларның. Монда скучно.

Таймас. Кәүсәрия җиңгәң тавык куамы анда?

Лилия. Тавык? Это уже интересно. Мин моны яратам. (*Чыга.*)

Мирхәт. Малай. Иртәнге дүрттә туган.

Т а й м а с. Тугызынчы оныгым. Мирхәт, куандырдыгыз.

С а б и р а. Бәхете-тәүфыйгы белән тусын, ярабби.

М и р х ә т. Хәзергә мин сыздым. Ирек! Иректе кош!

С а б и р а (*чак Мирхәтнен, тиҥеннән, эләктереп ала*). Әнисенең хәле ничек? Киленнең дим? Күчтәнәчкә ни алып барсам яратыр икән? Тез буыннарым калмады. Авызында йозак, әйтми тора...

Т а й м а с. Кая кабаланасың?

М и р х ә т. Футбол! Җыелып карыйбыз. «Спартак» ямый инде тегеләргә. Иптәшләр, дус-иш белән малайның тәпиен чылатып алырга да кирәк.

Т а й м а с. Беркая китү юк. Утыр. Абыйларың белән күрешкәлисеңме?

М и р х ә т. Эштә кол... Хатын янында кол. Әти-әни янында һаман кол! Тамак яна. Җырлат самоварыңны, әни. Әти, дим. Малайны әйт син, тишек борынны! Дүрт кило да бер йөз грамм. Әни, нәрсәң бар?

С а б и р а. Нәрсә дип... (*Таймаска карый.*) Әй ятратмыйм шул сабыйларны үлчәүләрен. Кишер-шалканмыни, тоталар да җилтерәтеп үлчәү табасына ыргыталар. Әллә балаларны да тонналап-центнерлап таптырмакчылар инде? Тудыгыз, берегезгә тамга салмадык, үлчәүгә ыргытмадык. Әтиегез алачыктан кайтып керер иде дә, бит-кулын югач, оялып кына чаршауны сыерып карар иде.

М и р х ә т. Дүрт килосы дүрт кило, йөз граммын әйткәч иптәшләрне күрсәгез сез.

Т а й м а с. Куаныч янында борчу... Малай туган куанычтан туганнар янына түгел, шешәдәш әшнәләр янына чабам диген. Сине, малай актыгы, артыгын сала башлаган дип ишеттем. Дөресме? Утыр, кузгалма.

М и р х ә т (*утырып*). Әти, тугызынчы оныгың туган көн. Ә син...

Т а й м а с. Анысын үзем беләм! Тугызынчымы, унынчымы, күз күрер.

С а б и р а. Бар икән бер сер тотмас үрдәк...

М и р х ә т. Ә-ә, хәтерләдем. Унынчы оныкка нәзер иткән әманәтең бар бит әле синең! Шулаймы?

Т а й м а с. Унынчы булуы бар... Сабира, табып бирәсеңме теге альбомны, юкмы?

М и р х ә т. Мин кузгалыйм алай да...

Р е г и н а керә.

Р е г и н а. Сабира апа!.. Гафу итегезчә, сезнең бәйрәмме әллә бүген? Кунак өстенә кунак. Хәерле көн, Мирхәт абый.

С а б и р а (*Таймаска кадалып*). Мирхәтен дә белә!

М и р х ә т. Бу сезме? Нишлисез сез монда?

Р е г и н а. Әтиләрегезгә күрше булып яшәп ятам. (*Көлә.*) Таймас абый, анда чуар тавыкны куалар. Суймасыннар, зинһар. Ничә йортка бер кош. Фәридәмә бер юаныч иде.

Т а й м а с. Үзем дә җәлләп утыра идем. Киленгә әйтим әле.

С а б и р а. Тавык та суймагач, ишле кунакка ни ашатырмын? Табынга ни куярмын?

Т а й м а с. Олы пәринең түшен, кече пәринең ботын. (*Чыга.*)

С а б и р а. И-и Аллам! (*Кухня ягына уза.*)

М и р х ә т. Мин сезне эзләргә чыгып китмәкче генә булып тора идем.

Р е г и н а. Очрашмый калмабыз дип әйттем ич мин сезгә.

М и р х ә т. Бүген сез дә ял итәсездер? Минем дә коллыктан котылган көн. Әйдәгез минем белән!

Р е г и н а. Кая?

М и р х ә т. Әлмәттә дә күңелле урыннар бетмәгән, ризамы?

Р е г и н а (*бармак янап*). Ярамый!

М и р х ә т. Закон әйтә — ярамый! Хатын әйтә — ярамый! Йөрәк әйтә — әйдә китик, ярамыйга карамый.

Р е г и н а. Сез бит акыллы кеше. Могтәбәр кешеләрнең улы. Карагыз, туганнарыгыз кемнәр. Йогышсыз тәкъдимегез белән мине дә, үзегезне дә, басып торган җирегезне дә хәкарәтлисез.

М и р х ә т (*авызын ерып*). Җир күренми, әтинең идәне нык.

Р е г и н а. Ә мин күренмәгәнне дә күрә ала торган кешеләрне генә таныйм.

Чыга. Пауза. Кулына мылтык тотып, кече яктан Г о с м а н керә.

М и р х ә т. Госман абый!

Г о с м а н. Бу ханымны син каян беләсең?

М и р х ә т. Бүген минем малай туды. Дүрт кило да бер йөз грамм.

Г о с м а н. Каян һәм кайчаннан беләсең бу хатынны?

М и р х ә т. Дүрт килосы аңлашыла, бер йөз граммы бар бит әле аның! Мин монда кыстырып килгән идем.

Г о с м а н. Эчеп эшеңә соңга калган өчен сине ике

тапкыр заводтан куа башладылар. Мин яклап калдым. Туры сорауга туры җавап бир. Ир була бел, ахыр чиктә!

Тавышлар ишетелә. Таймас, Кәүсәрия, Лилия керәләр. Госман кече якка кереп китә.

Лилия. Бабай, безнең бәби булды.

Таймас. Бәбине яратырсыңмы соң?

Лилия. Җыламаса яратырмын.

Таймас. Нинди исем кушасыз инде?

Лилия. Папа әйтә, йә Альберт, йә Гамлет.

Таймас. Нигә омлет түгел?

Лилия. Андый исем булмый.

Таймас. Качып китеп өлгермәгәнсең икән, Мирхәт.

Мирхәт (*төшенке*). Булмады шул.

Кәүсәрия. Мирхәт, күрешмәгән дә буласың. Бәбиегез котлы булсын.

Мирхәт. Китеп барышым. Кәүсәрия җиңгәм.

Кәүсәрия. Килмәс борын нинди китү ул?

Мирхәт. Нишлим мин монда?

Кәүсәрия. Мин сиңа эш табам, теләгең генә булсын. Әнә, нәүрәп өстенең өрлеге сынган, терәү куй. Су тамып утыра. Мунча ишегенең яңаклары кыйшайган.

Мирхәт. Какая горькая проза!

Лилия. Нигә тотасыз ул тавыкны?

Кәүсәрия. Кызыл муенчак тагарга.

Мирхәт. Әле тавык тотылмаган... Суелмаган... Корсакта «Спартак» футболчылары кыеш-мыеш туп тибә. Төшке аш якынлаша, иртәнгесе ашалмаган. Буталды көн. Коллыкта рәхәтрәк булган икән!

Сабира керә, җиңнәрен сызганган.

Сабира. Әйдә, килен, бисмилла әйтеп тотын.

Лилия. Капкагыз җырлый, бабай. Шундый кызык?

Мирхәт. Тагын кем? Урал абый килде! Кем белән ул? Якут җиңги!

Сабира (*үтә хафаланып*). Анысы тагын Госманны эзләп бастырып килде микәнни? Бар икән күрәселәр...

Сабира, Мирхәт, Кәүсәрия, Лилия чыгып йөгерәләр. Таймас монда кала. Госман керә.

Госман. Әти, мин Урал белән очрашырга теләмим. Хәзерге хәлдә хатынны да күрәсем килми.

Таймас. Вакланасың, улым, хата эшлисең. Кече энегезнең бәбие туган. Куанычта туганнар бер-береннән ка-

чамы? Ярый торган гадәт түгел. Китмә. Эш турында сөйләшмәссез, кунак булырсыз.

Госман. Син мине ифрат дәрәҗәдә уңайсыз хәлгә куясың. Бала-чага яки гаепле кеше сыман качып утырырга туры килә.

Керел бикләнә. Урал, Якут, Мирхәт, Сабира, Кәүсәрия, Лилия керәләр.

Мирхәт (*авызы белән туш уйный*). Тар-тарарам-тра-та-та! Җир селкенә, Шабановлар килә! Урал абыйга юл бирегез.

Таймас. Әйбәт йөрисеңме, улым?

Урал. Менә дигән. Үзегез ни хәлләрдә?

Якут. Аларның хәлен белүне миңа тапшырыгыз, Урал иптәш. Әни, син ни хәлдә? Кан басымыгызны тикшертеп торасызмы? Башыгыз авыртмыймы?

Сабира. Юк, Якут килен, бик саумын.

Мирхәт. Урал абый үзе килде! (*Җырлый.*)

Уралып-уралып ага
Уралының сулары.
Уралы сулары кебек
Уралышырбыз әле.

Урал. Мин Госман абыйларга барырга чыккан кеше, әни. Барсам, ул иртүк каядыр чыгып киткән икән. Якут ханым да белми. Шуннан исәпләштек тә, сезнең хәлне белеп чыгарга булдык.

Якут. Яхшы кешегә мин дә иярдем.

Сабира. Менә рәхмәт, зурладыгыз.

Таймас. Бүген генә бер кеше безнең өйне тормыш дулкыннарыннан читтә торып калган ялгыз утрау дип атады. Син дә адашып кына килеп кергәнсең икән, Урал улым.

Лилия. Бабай, бу курчак миңамы?

Кәүсәрия. Күсәк хәтле кыз курчак уйныймы?

Якут. Сез борчылмагыз. Госман ял көннәренең күбесен эшләп үткәрә. Бер дә ял итә белми инде.

Урал. Мирхәтнең монда булуы яхшы.

Мирхәт. Мирхәткә михнәт теләмик әле, абый! (*Җырлый.*)

Урал суларына төшәм,
Урал сулары тирән.
Җандай якын, көмеш-алтын
Урал абыем килгән.

Якут җиңгәм, мин җыр чыгардым.

Таймас. Әнкәгез, сез килер дип, бик тәмле катык оетты.

Сабира. Әйдәгез, балалар.

Мирхәт. Ур-ра! Кухняга поход чыгабыз. Юл бирегез, Шабановлар килә! Әйдә, Урал абый, син дә калма.

Барысы да кухняга чыгалар, шау-шу. Таймас аларны озата да Госманга дәшә.

Таймас. Юл хәвефсез, улым.

Госман (*икеләнеп*). Киң күңелле шул син, эти. Юлда тагын да зуррак хәвеф көтәр дип башыңа китереп карамыйсың.

Таймас. Кайда, улым?

Госман. Хәвеф капка төбендә үк сагалыйдыр, бәлки, мине?

Таймас. Бу хәлләрне күрү миңа бик авыр. Без исән бит әле, үлмәгән. Туганнар арасында дуслык җепләренең кимүен чамалыйм. Мәҗлесләргә хәзер туганнарны чакырмыйлар, күбрәк башлыкларга, төшемле урындагы кешеләргә тәлинкә тоталар. Киңәш-табыш иткәндә дә чит кеше ишеген кагалар, дәүләт оешмаларына, юристларга баралар. Туганнар бер табынга җыелган очракта да уртак сүз табылмый. Без яшәдек, сезне, үзебезчә, тәрбия кылдык... Кайдадыр нык кына хаталанганбыз булып чыга. Чәчәкләрне бер бәйләмгә җыю өчен дә зиһен һәм зирәклек кирәк. Ландыш зәһәр янына юаш күккүзне куеп булмый. Балаларны берберсенә яраша торган итеп тәрбияләмәдек, ахрысы. Әле без исән чакта бер-берегезне сөймисез. Ә без үлгәч ни калыр? Атагыз йортында да җыйнала алмагач, кайда җыйналырсыз сез? Кем сезне төенләп тотар? Балаларыгыз узара аралашмый, тел белмиләр. Бар, кит. Мирхәт тә китсен. Футболына.

Госман икеләнеп тора. Сабира керә.

Сабира. И балалар, балалар!

Кухнядан ашый-ашый, Мирхәт белән Лилия, Урал, Якут, Кәүсәрия керә.

Мирхәт. Безнең янга кем килгән? Госман абый...

Госман. Мирхәтнең улы бар икән, котлыйм.

Урал. Киләчәге якты булсын!

Госман. Яктылык турында сөйләгәч, Уралның бүген кәеф шәп бугай?

Урал. Кичә дә начар түгел иде кәеф, Госман абый!

Я к у т. Урал озак яшәячәк. Ул эшли дә белә, үз-үзен карый да белә.

С а б и р а. Тәки җыелдыгыз бит, балалар.

К ә ү с ә р и я. Олы абыйлары, Локманым гына юк.

Г о с м а н. Әтиләрнең хәлен белешкәләп тору әйбәт.

М и р х ә т. Мин иң алдан килгән идем. Китсәм дә ярыйдыр?

У р а л. Әти, берәр партия шахмат уйныйбызмы?

Т а й м а с. Аптырабрак утырам әле, улым.

Р е г и н а керә.

Р е г и н а. Бу мин йөрим, Таймас абый.

Т а й м а с. Сүз җилеме өзелебрәк тора иде, Регина күрше. Мөгаен, синең керүең кирәк булгандыр. Сизгер күңелле бала икәнсең. (*Таныштыра.*) Менә, балалар, яңа күршебез Регина. Ә болары минем малайлар. Кызыңа дип курчак алган идем, үзенә тапшырчы.

Р е г и н а. Шушы кадәр хөрмәтле кунаклар алдында минем кызымны телгә алып зурладыгыз. Рәхмәт, Таймас абый. Курчакны алмыйм, болай да Фәридәне артык иркәлисез.

М и р х ә т (*кул биреп*). Шабановларның төпчеге Мирхәт. Исәнмесез.

Тынлык. Лилия генә пырх-пырх көлә. Урал шахмат тактасын күзәтә.

У р а л. Мавыктыргыч кына уен башланган монда. Тик бераз ашыккансыз...

Р е г и н а. Кибеткә барырга чыккан идем. Йомышыгыз, кирәк нәрсәгез юкмы дип кагылдым.

С а б и р а. Йомыш дип... (*Таймаска карый.*)

Т а й м а с. Рәхмәт, күрше. Бүген кибеткә йөгертерлек җитез аяклар монда җитәрлек булды.

Р е г и н а. Борчып йөрим шунда. Читен булып китте. (*Чыга.*)

У р а л. Ягымлы ханым.

Т а й м а с. Син әйтәсеңме аны, минме...

У р а л. Каян күченделәр дисең, әти?

Т а й м а с. Урал аръягыннан ук кайттылар.

Г о с м а н. Әйе, нефть читкә таралган якташларның байтагысын монда чакырып кайтарды.

Т а й м а с. Нефть чакырганы да бардыр инде! Башка бер сәбәп белән кайтучысы да күптер.

Я к у т. Ире, бала-чагалары бармы?

Г о с м а н. Туктагыз әле, нигә бөтенләй чит кеше белән кызыксынып киттек.

Урал. Үзебез турында сүз кузгатмас өчен, Госман абый!

Сабира. Ир-атлары күренми шул, анысы җайсызрак.

Таймас. Кызы шәп! Матур җырлый. Сигезенчедә укый.

Урал. Фәридә Корбангалиевамы әллә?

Таймас. Беләсең дә икән.

Урал. Әлмәтнең атаклы җырчы кызы.

Сабира. Яшь чагында безнең Госманның да тавышы матур гына иде. (*Үкенеп.*) Әй, әйттем исә кайттым. Яшь чакта кем җырламаган?

Госман. Хәл-әхвәлләрегез әйбәт икән, әти. Якут, син кайтасыңмы? Кайтмасаң, соңрак машина җибәрермен.

Мирхәт. Мин дә синнән калмыйм.

Таймас. Ә мунча? Яккан мунча утыра бит.

Мирхәт. Мунча? Кемгә кирәге бар аның?

Лилия. Мунчада анда бака була.

Таймас. Шушы гади генә мәсьәләдә дә бердәмлек юк. Җыен, карчык, яккан мунчаны тик тотып булмас, үзебез барабыз.

Сабира белән Таймас чыгалар.

Урал. Әти картның хәтерен калдырдык.

Кәүсәрия. Локманым мунча бик ярата да бит, өйдә булалмады.

Урал. Барыйк, Госман абый. Ләүкәгә аркылы-торкылы яткырып чабармын үзеңне.

Госман. Теләмим.

Якут. Аның йөрәгенә эссе ярамый.

Кәүсәрия. Таптым!

Якут. Нәрсә таптың, олы җиңги?

Кәүсәрия. Җыйнаулашып чыгыгыз да нәүрәп өстен төзәтеп керегез. Менәтерәк вәт сезгә булыр эш.

Урал. Килгән-килгән, нидер эшләмичә ярамый.

Лилия. Капка җырлады, чудо-интересно!

Урал. Олы абый кайтты.

Кәүсәрия. Юктыр ла, булмас ла. Кайтмагандыр.

Мирхәт. Шул. Үзе. Эх! Түш киерелгән, авыз ерык.

Локман керә.

Локман. Саумысез, туганнар. Таралышырга торасыз дисәм...

Кәүсәрия. Исән-сау йөреп кайттыңмы, карт. Юк әле, таралышмыйлар. Җыйналырга маташалар.

Л о к м а н. Саумы, карчык, нихәл?

К ә ү с ә р и я. Бәхетең бар икән, вакытында кайтып кердең. Бераз җылыта идем инде мин сине хәзер, берлеккә калсын. Энеләрең янына кайттың.

Л о к м а н. Әтиләр кайда?

У р а л. Мунчада алар, олы абый. Рәхмәт, олы абый, кайтып җиттең.

Г о с м а н. Миңа һөҗүмгә күчәргә Уралга эшче сыйныф вәкиле җитми иде.

У р а л. Җитеп бетми иде. Хәзер көчләр тигезләште. Шахмат уенындагы кебек. Әйдәгез, әтиләр кайтканчы ут уйнатып алыйк.

К ә ү с ә р и я. Сүз дә, табын да берләштерми туганнарны, эш берләштерә. Барыгыз! Юлдан кайткан картымны да җәлләмим.

**Мирхәт авыз белән туш уйный, Лилия кашык кага, башкалар балтапычкы тотып, шау-гөр килеп, ишегалдына чыгалар. Хатын-кыз ирләрне озатып кала.**

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә. Бүлмәдә К ә ү с ә р и я, Я к у т, Л и л и я.

Я к у т. Әллә минем Госманым да эшләшә инде?

К ә ү с ә р и я. Кар базы өстен рәтләргә дигәч, Госманның иреннәре калтырады. (*Көлә.*) Эш кешеләрне шулай тигезли ул. Ипекәй алдында барыбыз да тигез, шулай булгач, эштә дә тигез булыйк. Шәп уйлап таптым, мәгәр, килендәш, ни дисең? Эшнең чыны булса, ызгышырга ара калмый, иңне иңгә терәргә кирәк анда.

Я к у т. Госманга юкка бәйләнәсез. Анда характер. Ул гади эш өчен туган кеше түгел. Аңа киңлек хас.

К ә ү с ә р и я. Локманым белән сөйләшмәсәм сөйләшмәдем, Госманын да, шифырт Мирхәтен дә бер җепкә тездем.

Я к у т. Нигә гел талашалар алар?

К ә ү с ә р и я. Анысына үзем дә бик аптырыйм. Урыннары күркәм. Уралы дисәң — горком. Госманы зур идарәне кулында тота. Мирхәте — мастер. Бер Локманым йөри карга-бозга батып.

Я к у т. Мирхәт белән Госман дуслар. Анысы өйгә килеп тә йөри. Уралның әллә ни гомер кергәне юк иде, бүген килде.

К ә ү с ә р и я. Мирхәт ялагай. Ялагай ялганчы була.

Я к у т. Ялагайлар да кирәк, алар тормышны җиңеләйтә.

К ә ү с ә р и я. Болай кеше эшләгәнгә куанып утырсак, без дә талаша башларбыз. Ни-нәмәрсәгә ул ялагайлар? Шулар боза начальствоны! Шулар дөреслекне күрергә ирек бирми. Әйдә, ир-ат югында өстәл-табын хәстәрен күрик.

Я к у т. Әни сынаткан бүген. Берни әзерләмәгән.

К ә ү с ә р и я. Киленнәр әзерләсен дигәндер.

Я к у т. Нишләргә соң?

К ә ү с ә р и я. Бакча карачкысы сыман аптырап торам әле.

Я к у т. Чәй кайнатыйк.

К ә ү с ә р и я. Аның ише вак-төякне Лилия дә булдыра.

Л и л и я (*Якутның сумкасын ачкан да көзге каршында иреннәрен буяп, ясанып тора*). Мин аны... самоварны бора белмим.

К ә ү с ә р и я. Һай, оятсыз! Нигә кагыласың аларга?

Я к у т. Тимә, килендәш, өйрәнә торсын. Хатын-кыз бит.

К ә ү с ә р и я. Нишләп зиһенем таралды соң болай?

Я к у т. Ир-ат кергәнне көтик.

К ә ү с ә р и я. И-и, килендәш, әйттең сүз. Эшләп, азмаз көч түгеп кергәч, ир-ат сөйләшеп торамы? Колак кимерә башлый ул. Әнинең күмере дә беткән икән, барчы, килендәш, шунда — келәттәдер. Алып кер.

Я к у т. Әнә Лилия барсын.

Л и л и я. Без чәйне чәйнектә генә кайнатабыз.

К ә ү с ә р и я. Һай, кире кыз, кыланчык! Әтиең күрсә!

Л и л и я (*бизәнеп*). Күрсә ни!

К ә ү с ә р и я. Хәзерге яшьләргә эш кушсаң... Кит моннан!

Я к у т. Күмердән кул карала. Юып та бетми. Врач кешегә уңайсыз. Лилияне дә бик ачуланма, бизәнсә ни булган? Бизәнсен.

К ә ү с ә р и я. Ә, күмер монда икән. Эшләсен диген, килендәш, яшьтән эш тәмен татып үссен. Эшле кешенең авызы ашлы була, яманлыкка, хөсетлеккә вакыты калмый. Кызларымны таңнан кухняга өерләп кертә идем, хәзер кияүләремнән моң-зар ишетмим, аерылып кайтырлар дип тә курыкмыйм. Яхшы сыйлаган хатынның һәр яктан күңеле тыныч була.

Я к у т. Безнең Госман өйдә ашамый. Мин дә пешермим. Без кунакта гына бергә туры килеп, бергә ашый-

быз. Госман кебек кеше хатыны алдында лач-лоч бәрәңге чәйнәп утырмас инде.

Кәүсәрия. Барыбызга да Госманың кебек ир тәтемәс шул.

Лилия. Мин кияүгә аш-су пешерер өчен чыкмыйм.

Кәүсәрия. Чыгарсың. Яраткан кешеңә тап булсаң, кар өстенә казан асарсың. Март песие төсле чиный-чиный бәлешләр, гөбәдияләр пешереп ятарсың.

Якут. Лилияләр үсеп җиткән заманда ашарга рестораннарга гына йөрерләр. Шул заманнарда туасы иде ул! Мәшәкатьле чакта яшибез.

Кәүсәрия. Йөрде диярләр, тәки, йөрми торсыннар. Шабановлар күк тамакай иргә язган булса, Лилия-Милия дип башыннан сыйпап тормаслар, күгәргән кубызга биетерләр, Алла боерса. Ашханәдә анда, килендәшкәем, теләгәнеңне түгел, кесә рөхсәт иткәнне дә кабыргасы кипкәнне ашаталар! Даңгыр-доңгыр машинада килгән сыерларны күрүгә ук укшый башлыйм. Ир-ат дөбердәтеп ашасын, хатын-кыз чаж да чож пешеренә белсен. Локманыма сталавай ашатмадым, иллене узса да унсигез яшьлек егет кебек әле ул.

Якут. Җиңгәм, гел-гел кухняда кайнашкан хатын-кызны ир-ат ярата аламы?

Кәүсәрия. Гел кайнашма!.. Менә син балалар врачы. Биш-алты сәгать әпә-чәпә больницада буласың да аннары нишлисең? Госманың коры, өй тәрбиясе җитмәгәнгә ул.

Якут. Әллә тагын. Зарланганы юк.

Кәүсәрия. Хуш. Тагын ни кыландырыйк икән.

Лилия (*төенчек алып керә*). Боларын минем папам сатып алды.

Кәүсәрия. Кая, кая? Мирхәттән дә күчтәнәч килер икән. Йомышка-кибеткә йөрмәгән тинтәк ир алганлыгы әллә каян билгеле. Шултикле хәрам ризык төйиләрме? Үзе мыркылдыкныкы, үзе чат май, тфү, әни табынына куярга оят.

Лилия (*такмаклап*). Ә без бәбигә Гамлет исеме кушабыз. Гамлет.

Кәүсәрия. Әстәгыфирулла, кем, кем?

Якут. Бик матур исем.

Кәүсәрия. Үз балаң юк бит синең, килендәш.

Якут. Баладан башка да дөньяда мәшакәть җитәрлек.

Кәүсәрия. Аш-су пешермә. Бала тапма. Ходай ни өчен генә сине хатын-кыз итеп яраткан соң?

Я к у т. Безнең тырыш эшчеләр керә дә түгелме?

К ә ү с ә р и я. Кирәкмәс чагында ир-ат гомергә шулай өлгер булыр инде! Әйдәгез, күз алларында уралмыйк. Азмаз эш тоткач ир-ат һавалана, кабарына торган була.

Хатын-кызлар кухня ягына узалар. Пауза. Г о с м а н белән У р а л керә.

У р а л. Келәт почмагына да су үтә башлаган, ди абый.

Г о с м а н. Локман абый эш табар ул. Мин түбәгә менмим.

У р а л (*мылтыкны алып*). Бер очтан шартлатып та төшәрбез. Кече энекәшнең улы туган.

Г о с м а н. Теләсәң, мен. Миндә бәйрәм кәефе юк бүген. Булыш олы абыйга. Шунда атарсыз да. Минем плащ кайда икән?

У р а л. Утыннары да азайган. Берәр машина кайтарганда да ярар иде, урамнары адәм йөрерлек түгел.

Г о с м а н. Менә бит син нинди!

У р а л. Нинди?

Г о с м а н. Ял көнне дә миңа ук атасың. Урам начар, чөнки труба шартлаган. Труба безнең хуҗалыкныкы. Аны мин төзәттерергә тиеш идем. Бүген таңнан төзәтергә тиеш иделәр. Белешермен, хәзер чарасын күрермен. Һич булмаса, үзем төзәтешермен.

У р а л. Авырткан җиреңә кагылдым, ачуланма.

Г о с м а н. Тәнкыйть — алкоголь кебек үк, бер күнексәң тиз генә котылырмын димә. Күз гел яманны гына эзли, тел гел начарны гына сөйли. Синең шундый чагың.

У р а л. Әти йортына килеп тә талашмыйк инде.

Г о с м а н. Син башладың, син! Подумаешь, бер урамны су баскан! Бер-ике бакча лайда калган. Алмаздан коелган трубаларым юк, тишелә. Олы җиңги, минем плащ кайда?

К ә ү с ә р и я (*керә*). Мич буена элгән идем. (*Пауза.*) Хәзер чәй өлгертәбез, Госман.

Г о с м а н. Ашыгам, олы җиңги. Ашыктыручылар бар. (*Якут керә.*)

У р а л. Ашыгам, дисең. Акланыр өчен иң кулай сүз.

Г о с м а н. Мин гаебемне кайчан да танырмын. Синең танырга көчең җитәрме?

Я к у т. Нервыларыгызны саклап кына аңлашыгыз.

Г о с м а н (*түземсезләнеп*). Син бит миңа каршы оешкан шайкага эләккәнсең!

У р а л. Шулай укмыни? Шайкамыни?

Г о с м а н. Кичәге җыелышта миңа каршы чыгарга

синең мораль хакың юк иде. Мин чирләп ятам, ә син трибунага менәсең дә уңга-сулга кылыч уйнатасың.

Урал. Сине түгел, эш методларыңны телгә алдык.

Госман. Кеше айлар буе алсыз-ялсыз эшли...

Якут. Чирләп егыла!

Кәүсәрия аяк очларына басып кына чыгып сыза.

Урал. Бик начар. Җитәкче ай буе ял итми икән, үз кул астында эшләүчеләрне дә шул җүләр ритмга кертә. Көне-төне эшли икән, вакытның кадерен белми. Вакыт кадерен белмәгән җитәкче саный да белми. Бу аксиома.

Госман. Син горкомда күптән түгел. Яшь кадр. Нефтьне Татарстанда гына түгел, бөтен ил күләмендә иң күп бирүче идарәнең эшен бер селтәнүдә сызып ташларга кем сиңа хокук бирде?

Урал. Соңгы ике-өч елда күпме эшченең, белгечнең идарәңнән китүен беләсеңдер?

Госман. К черту! Миңа чиле-пешле дилетантлар, позерлар кирәкми.

Якут. Урал, сез акыллы кеше. Нигә Госманны аңламыйсыз? Аның эш методлары үзенчәлекле, үзенчә. Сезгә дә аларны кабул итәргә туры киләчәк.

Госман. Якут, бар, чыгып тор.

Мирхәт керә.

Мирхәт. Җәмәгать, футбол бит бүген, футбол!

Госман. Син бер катлы кеше, Урал. Менә күр. Бу шома егетне, гөнаһсыз күзләрен кыса-кыса футбол кайгыртып йөри дип беләсең инде син. Шуңа ышанасың.

Урал. Ышанмаска нигезем юк. Син ышанмыйсыңмы?

Госман. Юк. Чөнки мин егетне үтәли күреп торам. Ни кайгыртканын да беләм. Эшчеләр дә гади патриотизм аркасында көч түгәме әллә! Кычкырам икән, таләп итәм икән, ял сәгатьләрен дә эшкә алам икән, мин аларга яшәргә мөмкинлек бирәм, акча бирәм. Алар тормышын мин кайгыртам.

Мирхәт. Бетте. Тындым. Авызым йомык.

Госман. Күрдеңме? (*Лилия керә.*)

Лилия. Ну, пап... Әти... Ипи белән май ашыйсым килә.

Мирхәт. Тс-с. шаулама.

Локман керә, Кәүсәрия аны каршылый.

Л о к м а н. Әнкәсе, җылы суың бармы?

К ә ү с ә р и я. Ирем тавышын да ишеттем.

Я к у т. Әнә кунак кызның карыны ачкан.

Л о к м а н. Соң, әнкәгез яламаган киленнәр, ни терәлеп торасыз ул чагында.

Я к у т. Ирецнең тавышы менә кайчан гына ишетелде, олы җиңгәм. Бая ул болай гына, черки безелдәде...

К ә ү с ә р и я. Мирхәт, чоланнан әйберләр кертеш.

У р а л. Сүзне бүлдерделәр, Госман абый.

Г о с м а н. Ә мин әйтәсен әйттем.

Я к у т. Син хаклы булып чыктың, олы җиңги. Безнең егетләр уртак интереслар юклыктан талашалар. Урал, тотын, бәрәңге әрчеш.

К ә ү с ә р и я. Локман, Госман, табын әзерләгез.

У р а л. Бирегез миңа зуп-зур пычак, мин Җир шарын бәрәңге әрчегән кук әрчим.

Г о с м а н. Пычак бирә күрмәгез! Ялгышып бөтен күзәнәкләренә кагылыр.

Я к у т. Анысы да бик мөмкин.

Урал, Якут кухняга керәләр, Мирхәт, Кәүсәрия, Лилия чоланга чыгалар. Бүлмәдә Локман белән Госман кала.

Л о к м а н. Бая, ишегалдында «китәм» дигән сүзеңне ишеттем.

Г о с м а н. Күпме сүз сөйләп, нибары берсе колагыңа кергән! Абый! Шушы Әлмәттән чыгып качарга теләгән минутларың булмыйммыни синең? Хәер, син ел да сәфәргә чыгып, күңел ачып кайтасың.

Л о к м а н. Нигә күңел ачып? Нигә аны мыскыллап әйтәсең?

Г о с м а н. Һаман бер эздән йөреп, сукмакларның искесен таптыйсың икән.

Л о к м а н. Кагылма минем сәфәргә, Госман.

Г о с м а н. Сез минем тормышымда казынасыз. Рәхәтләнеп, кинәнеп. Миңа берегезгә дә кагылырга ярамый. Китәм мин моннан!

Л о к м а н. Безне яратмасаң да, әтиләр хакына түз.

Г о с м а н. Әтиләр дә миннән риза түгел.

Л о к м а н. Кешенең гомере тигез итеп бүлеп куелган, ди иде безнең бабай. Син аны хәтерләмисеңдер дә булыр. Гомернең ил өчен, хезмәт өчен, рәхәт өчен дигән өлешләре бар. Өлешләрнең иң изгесе — ата-ана өлеше. Син шул өлешеңне башка максатларга исраф итәсең. Мин этиләрне белә́м, эти белән, бергә үскән кеше.

Г о с м а н. Көч җитеп бетмәгәч, ярдәмгә бабайларны чакырабызмы?

Л о к м а н. Сиңа ничә яшь булды әле?.. Байтак. Әгәр кеше, шушы яшенә җитеп, үз бабалары җиреннән ризалашмыйча китәргә чәпчеп йөри икән, кара акыл белән генә әйткәндә, бу кешенең көймәсе комга терәлгән дигәнне аңлата.

Пычак тотып, бәрәңге әрчи-әрчи, У р а л керә.

У р а л. Тапкыр әйттең, олы абый.

Г о с м а н. Мине тәнкыйтьләү җиңел сиңа хәзер, Урал. Үз туганың...

У р а л. Абыемны түгел, аның гамәлен, кылган эшләрен тәнкыйтьләдем. Кабатлый дип уйлама, олы абый да ишетсен. Югыйсә, ул безнең тату яшәмәгәнне генә белә. Әйе, башта без җир-суларга игътибар итеп җиткермәдек. Гомумән, безнең эш алымнарында байтак хаталар, ашыгучанлык нәтиҗәсе буларак байтак буталчык киткән, хуҗасызлык. Нефть агыламы, агыла! Мактыйлармы безне? Мактыйлар. Ромашкино да Ромашкино! Бер стакан нефть бер стакан газлы судан арзанракка төшә дип шапырындык бит без җүләрләр. Нефть безгә сансыз-исәпсез бирелгән күк тоелды. Хәзер хаталарны төзәтергә керештек. Халыкның да күзе ачылды, җир-су хакын хаклап, бездән җавап таләп итә башлагач, син моны шәхси бәйләнү дип кабул иттең дә шәһәрдән качарга ук маташасың.

М и р х ә т керә.

М и р х ә т. Абыйлар, сез барыгыз да олы кешеләр. Шулай да мин бер сүз кыстырыймчы.

Г о с м а н. Яралы арысланга тибәргә кердеңме?

М и р х ә т. Аулакта, хатын-кыз югында берне тотыйкчы.

Л о к м а н. Безнең араларны җилемләргә кердеңме, энекәш?

Г о с м а н. Туганлыкны ныгытырга аракы көненә калдыкмы?

М и р х ә т. Тотмаганга да байтак булды.

У р а л. Тәүлектән арттымы?

М и р х ә т (*тиз-тиз рюмкалар әзерли, кулы ятып тора*). Хатынга ярамаганда читен икән ул, төрле яктан уразада.

Г о с м а н (*янап*). Мин сине!

М и р х ә т. Тындым. Олылар сүзенә мохтаҗ мин, ялгышсам, төзәтерсез.

Л о к м а н. Элек «кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың» дигәннәр. Хәзер «кемнең аракысын эчсәң, шуның сүзен җөплисең» дип әйтәләр. Аумакайланма, Мирхәт. Нигә багышлыйбыз?

Г о с м а н. Эчкән аракыны да законлаштырмыйк.

Л о к м а н. Корсак хакы өчен генә бу агуны йотар хәлем юк.

М и р х ә т. Төксе утырасыз, абыйлар. Әйдәгез, минем юеш борын өчен күтәрик.

Л о к м а н. Әби-бабайдан башка малай өчен тотып булмый. Ашыкмыйк.

У р а л. Олы абыйның сау-сәламәт йөреп кайтуы өчен.

Г о с м а н. Батмый. Олы абыйның сәфәрен чеп-чи җүләрлек дип санаганга, эчә алмыйм.

Л о к м а н. Мондый тәккәббер аксөяк белән бер табында утырмыйм. (*Сикереп тора.*)

М и р х ә т. Абыйлар, абыйлар.

Г о с м а н. Урал минем моннан китүемне бик тели. Шуның шәрәфенә эчәбезме?

У р а л. Мин бу тостка кушылмыйм.

М и р х ә т. Шабановларның мәңгелек татулыгы өчен эчик.

Г о с м а н (*көлеп*). Моннан да төгәл, урынлы тостның булуы мөмкин түгел.

У р а л. Нигезе дөрес.

М и р х ә т. Абыйлар, абыйлар... Ят казлар күк каңгылдашасыз.

У р а л. Әйтим. Татарстан быел да нефть буенча беренче урынга чыга. Ил күләмендә. Аерата уңган коллективларга, эшчеләргә хөкүмәт бүләкләре биреләчәк. Бу хәзер берәүгә дә сер түгел. Коллектив җитәкчеләре безгә үз тәкъдимнәрен керттеләр. Җитәкче иптәшләрдән орден сорап кергән кеше берәү генә булды. Берәү!

Л о к м а н. Орден сорап кердеме?

У р а л (*паузадан соң*). Сорады, һәм ул кеше безнең Госман абый иде.

Г о с м а н. Горкомда сөйләшенә торган сүзләр сер булып калырга тиеш.

У р а л. «Шайкага эләккән» дигән сүзләреңне йотып җибәрдем. Түз. Уйлашыйк. Соңгы вакытларда без сине шактый чыбыркыладык. Искергән эш методлары өчен дә, һаман сүнеп бетмәгән факеллар өчен дә, әрәм-шәрәм булган нефть өчен дә, кирәксезгә бозылган җирләр өчен

дә... Нәкъ менә сезнең идарәдән Мирхәтләр заводына килгән күкертле газ өчен дә...

Л о к м а н. Бөтен яктан эләккән икән!

У р а л. Ниһаять, гаебеңне таныр көнең дә килде.

Г о с м а н. Ничек?

У р а л. Орден сорап керү гаебеңне тану түгел идемени? Син шикләнгәнсең, икеләнгәнсең, гаебең барын эчтән генә сизенеп йөргәнсең.

М и р х ә т. Кул арды.

Л о к м а н. Тыңла, тыңла! Сиңа сабак.

У р а л. Синнән «китәм» дигән сүзне беренче мәртәбә горкомда ишеттем. Соңгы вакытларда «китү» сүзен еш ишетергә туры килә. Сөенеп тә, көенеп тә әйтәләр аны. Кешеләрне озатырга яратам да мин. Без бит — Татарстан! Нефть мәркәзе. Без — башкала. Заманында белгечләрне үзебез чакырдык. Башкорт дусларны, әзәрбайҗан туганнарны. Хәзер озатабыз. Русларны, татарларны. Татарстан нефтьчесе дигән сүз — бүгенге көндә иң ышанычлы акция. Иң ышанычлы пароль.

Г о с м а н. Беткәндер?

У р а л. Нефтьче алдында олысыннан башлап кечесенә тиклем бүрекне салып сөйләшергә тиешле. Нефть ул — политика. Нефть ул — дошманнарга каршы төп көчләрнең берсе.

Г о с м а н. Иң күп нефтьне илдә кем бирә? Кайсы идарә?

М и р х ә т. Их, абыйлар.

У р а л. «Китәм» дигән сүзең миңа аерата авыр ишетелде. «Орден бирмәсәгез, китәм» дигән төсле, ямьсез яңгырады ул. Әгәр бертуган энең горкомда утырмаса, син орден сорарга батырчылык итәр идеңме? Мине астыртын эшкә чакыру түгел идеме бу?! Шуларны уйладым да, кичәге чыгышымда мин сиңа аерата кискен кагылдым. Бары шул гына. Шуны әйтергә дип сезгә барган идем.

Л о к м а н. Мондый сүзләрнең эти йортында яңгыравы да әйбәт.

Г о с м а н (*эчеп җибәрә*). Вәссәлам. (*Ишек катына бара.*)

Р е г и н а керә. Барысы да аңа карап торалар. Пауза.

Р е г и н а. Миңа Сабира апа кирәк иде.

У р а л. Бу юлы сез Сабира апаны эзләп кермәдегез. Шулаймы?

М и р х ә т (*ашыгып*). Алар мунчада.

Р е г и н а. Алай икән. Кичерегез.

Чыга. Пауза.

Л о к м а н. Шундый-шундый эшләр.
М и р х ә т. Тора-бара нишләр...

Я к у т керә.

Я к у т. Нишләп йөри бу ханым монда? Ни кирәк аңа?

У р а л. Әйдәгез әле, безнең янга кереп чыккан шушы сәер ханым хөрмәтенә берне тотыйк. Гаҗәпләнеп карап торганым бар иде, хәзер генә аңладым.

М и р х ә т. Мин аңлап җиткермәдем.

У р а л. Бу ханымның кызын күргәнем бар минем. Җырчы кыз... Аның кемгә охшаганын хәзер генә абайладым. Әнисе һәм кызы исәнлеге өчен!

Я к у т. Госман, туганнарга кушылмыйсыңмыни?

Г о с м а н. Син монда кал. Ял ит. Мин кайтам!

Башкалар күтәрә, Госман кырт борылып чыгып китә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шабановлар йортының болдыр баскычы. Вак кына яңгыр сибәли. Р е г и н а баскыч төбендә көтеп тора, өйдән Г о с м а н чыга.

Р е г и н а. Госман абый...

Г о с м а н. Регина, синме бу! Бая үз күзләремә ышанмадым.

Р е г и н а. Күршегездә яшәп ятам. Тик... эзәрлекләп килгән дип уйлый күрмәгез. Очраклы гына күрше булдык, бүген дә очраклы гына күрештек.

Г о с м а н. Һаман үзгәрмәгәнсең. Һич. Шул ук Регина. Тик бу йөз сызыкларының, бу кыйгач кашларның ни аңлатканын мин элек белә алмаганмын.

Р е г и н а. Хәзер тәҗрибә бармы?

Г о с м а н. Алары бар! Тәҗрибә дә, бераз акыл да... Чәнечкеле караш. Иреннәрдә һавалырак елмаю. Кыяфәттә башкаларны аз-маз санга сукмау. «Менә мин кем!» дип кычкырып торган күзләр.

Р е г и н а. Шундый мактадыгыз, җылыйсы килә башлады.

Г о с м а н. Һава суларга чыктым.

Р е г и н а. Әти йортының климаты килешмәдеме? Бик турсаеп утыра идегез бая.

Госман. Эссегә чыдамыйм. Өйдә дә, эштә дә форточкамны япканым юк. Кышкы пальтоның әлегә ни икәнен белмим.

Регина. Томау белән дә җәфаланмыйсыз, алайса? Ир түгел, хәзинә икәнсез сез.

Госман. Йөрәк һаман яшь кала икән, Регина. Хәер, нигә үзгәрсен ди ул? Ни өчен? Дөнья һаман матур ич. Шул ук зәңгәр күк, шундый ук якты кояш. Шул ук сары яфраклар. Чигәләр чаларды, нишлисең, ә үзем сәламәт. Соңгы елларда гына әллә ни үзгәрде. Гимнастика ясарга тотынып карыйм, вәгъдәм атнага гына җитә. Ни үзгәрде, җирме, күкме, абайламый калдым. Шунысы куркыта.

Регина. Сез керергә ашыкмыйсызмы?

Госман. Күрәсез ич, кермим дә, китмим дә.

Регина. Күрешмичә байтак заманнарны уздырдык. Сез президиумда, мин залда утырганнарны санамыйк.

Госман. Бер киңәшмәдә янәшә туры килгән идек, син күчеп утырдың.

Регина. Шуны абайлап калдыгызмы?

Госман. Чираттагы протестың дип кабул иттем.

Регина. Юк, протестым түгел иде. Качмыйм хәзер. Күрәсез, яңгыр астында да сезне көтеп тордым. Минем белән сөйләшмичә китеп барырсыз дип курыктым.

Госман. Нигә кирәге бар боларның, Регина?

Регина. Усак яфрагы төсле калтыранмагыз, сезгә килешми. Бәйләнергә дә, тагылырга да исәбем юк.

Госман. Монда сөйләшеп тору уңайсыз. Әллә ничек... Кичен бер урынга килә аласызмы?

Регина. Юк.

Госман. Нигә дип соравы куркыныч.

Регина. Билгеләнгән урынга сез килә алмыйсыз. Мин ирекле... Ә сезнең китәргә йөргән көннәрегез. Хатыныгыз үтә көнче.

Госман. Барын ишетеп торасыз тагын.

Регина. Госман Шабановның киту-китмәве барыбызга да кагыла.

Госман. Алыштырмас кешеләр юк. Кешеләрне эш урыннарында гына түгел, күңелләрдә дә алыштыра алабыз икән без.

Регина. Сез... үзегезне күз алдында тотасызмы?

Госман. Бәлки.

Регина. Нигә китәргә булдыгыз, Госман абый?

Госман. Тора-бара Әлмәт мине үгәйсетте. Моны аңлау

сиңа кыен түгел, сөйкемсез сөягем барын беренче башлап миңа син ачтың!!

Р е г и н а. Ялган!

Г о с м а н. Нигә ялган булсын? Безнең тормыш шуңа шаһит.

Р е г и н а. Иптәш кызларым барысы да сезгә гашыйк иде. Шул егет белән култыклашып центральныйдан бер узасы иде, дип өзгәләнәләр иде.

Г о с м а н. Кыз йөрәге күбәләк канаты белән бер. Сыңар шырпыдан да дөрт итеп кабына да көеп бетә. Әйе. Сөйкемсез сөяк. Начар нәрсә ул. Тугач та, бәләкәйдән эти мине өнәмәде. Башка малайлар аның алачыгыннан чыкмый ятты, мин башканы телэдем. Башканы сайладым. Әти шуны гомергә кичермәде.

Р е г и н а. «Шагыйрь булам» дип йөргән чагыгызны хәтерлим.

Г о с м а н. Анысы вак мәсьәлә. Җаны бар һәркем яшь чагында шагыйрь.

Р е г и н а. Җанга йөгәнне тиз кигерттегез сез. Һәр адымыгыз үлчәнгән. Хәзер карыйм — карточкага төшкәндә дә укытучы янына сырышкансыз.

Г о с м а н. Нинди матур яшьлектән нинди күңелсез хатирәләр!

Р е г и н а. Без еш кына талашкаласак та, мин сезгә үлеп гашыйк идем.

Г о с м а н. Унынчы класс кызларына иярепме? Шәп! Район комсомол оешмасына яшь егет килгән, җырчы, биюче.

Р е г и н а. Мәҗнүннәрчә гашыйк идем. Шаһитым бар.

Г о с м а н. Кем ул?

Р е г и н а. Вөҗданым, яшьлегем, сафлыгым. Синнән ары берәүне дә сөймәдем мин, Госман абый,

Г о с м а н (*йодырыгын йомарлап*). Нигә, алайса, тиешле көне җиткәч, тәкъдимемне кире кактың? Мәхәббәтең чын икән, нигә минеке булмадың? Кияүгә нигә чыкмадың? Без хәзер як-якка каранып, кача-поса яңгыр астында сөйләшеп тормас идек.

Р е г и н а (*көлә*). Дөрес! Мин җиһазларны ашык-пошык сатып, чемоданнарны төйнәп, Әлмәттән качып китәргә җыенып ятыр идем. Моннан китәсем килми шул, туган ягыбызны бик сагынып кайттым.

Г о с м а н. Без бергә булсак, тормыш башкача агар иде. Бүтәнчә яшәр идем мин дә! Госманның күңеле каты, диләр. Бәлки, сәбәпчесе синдер?! Хәзер сорап торуның файдасы юк-югын, шулай да беләсем килә: кем өркетте синең яшь күңелеңне? Сөя идең бит син!

Р е г и н а. Сез, Госман абый.

Г о с м а н. Яраткан кешеңнән ничек өркергә мөмкин?

Р е г и н а. Мөмкин икән шул.

Г о с м а н. Хатлар яздым. Җиде якка телеграмма суктым. Эзсез югалдың. Өйләнешергә тәкъдим ясагач качып киттең.

Р е г и н а. Шулай дөрес булган, Госман абый. Сез бит яраттырдыгыз, әмма яратмадыгыз. Сез хәзер җаваплы урында. Кулыгызда зур власть. Мондый вак, кечкенә сүзләрне онытып та бетергәнсездер. Сез яшь чакта ук властька омтыла идегез. «Мин тырнак белән җир тараучылардан түгел, Регина, мин өстә, югарыда торырга тиеш». Бу бит сезнең сүзләр.

Г о с м а н. Нигә отпор бирмәдең? Нигә тәрбияләмәдең? Килешмәгәч, нигә мине үз иманыңа кайтармадың? Нигә качтың? (*Пауза.*) Бала туганын да байтак еллар узгач кына ишеттем.

Р е г и н а. Әйе. Кызым үсә. Курыкмагыз, сезнең хакта берәү дә белми. Иптәш кызлар таралышты... Башкалар беләчәк тә түгел.

Г о с м а н. Чыгалар. Китми тор, яме.

Яшеренә. М и р х ә т чыга.

М и р х ә т (*шатланып*). Сез мондамыни?

Р е г и н а. Сезне көтә икән дип уйласагыз, каты ялгышасыз. Кичә дә мин сезне берәүгә охшатып кына караган идем.

М и р х ә т. Хәзер беләм — сез ялгыз. Әйдәгез, моннан китеп ычкыныйк. Сөйләшә алмыйм мин монда. Үземне ир кеше итеп тота алмыйм.

Р е г и н а. Нигә?

М и р х ә т. Абыйлар... Кече энекәш дип гомер буе кысалар. Актыккы сүз генә миңа. Иң соңгы сүз. Мин аларны өлкән итеп санарга тиеш, димәк, бер карышусыз буйсынырга... Шуңа күрә китик моннан! Күрәсем килми аларны. Туйдым, ялыктым. Үземчә яшисем килә. Эшне дә, кәләшне дә алар сайлады. Минем үземчә яши башлыйсым килә.

Р е г и н а. Соңга калгансыз, Мирхәт абый.

М и р х ә т. Теләсәгез кая! Бөгелмәгә, Казанга, хет җәһәннәмгә, икәүдән-икәү генә яшереник. Бер атна!

Регина тартыла, Госман чыгып Мирхәтне йолкып туктата.

Г о с м а н. Читкәрәк китеп тор, Регина. (*Регина чыга.*)

М и р х ә т. Нишләтәсең мине? Нигә китмәдең син?

Г о с м а н. Тәмамлыйсы эшем калган. Ә мин эшнең тәмамланганын яратам.

М и р х ә т. Әнә Якут җиңгәм әйтә, Госман үзен аямый, көне-төне эшли, ди. Ай!

Г о с м а н. Зарар юк. Бер юньсезнең чалбарын төшереп кычыткан белән чарлаганнан саулыкка әллә ни зыян килмәс. Кайберәүләргә файдалы булуы бар. Изге эш — тазалыкны арттыра. Шаһитка Регинаны чакырам.

М и р х ә т. Кирәкми, Госман абый. Ай!..

Г о с м а н (*тегене кычыткан белән чарлый*). Тәмлеме?! Малаең туган көнне чит хатынны ресторанга, аулакка чакырып ятасың, мөртәт.

М и р х ә т. Ай-яй! Җитте, Госман абый! Хәзер урта гасыр түгел...

Г о с м а н. Синең кебек ялагайларны, сатлык җаннарны сытып бетерер идем... Тор, җебегән.

М и р х ә т. Хурлык...

Р е г и н а керә.

Р е г и н а. Җибәрегез аны, Госман абый.

Г о с м а н. Баласы туган... Әнә безнең булмады. Юк. Нинди әйбәт хатын белән гомер итә. Күзенә генә карап тора бит шушы юньсезнең! Бар, югал күземнән.

М и р х ә т. Гомер бирмәгән акылны бүген бирдең. (*Өйгә керә.*)

Г о с м а н. Гомер алмаган акылны мин бүген үзем алдым.

Р е г и н а. Сезнең балагыз юк икән.

Г о с м а н. Хатыным теләмәде.

Р е г и н а. Үзегез дә бик ашыкмагансыздыр инде. «Зур максатка ирешү юлында бала артык»,— ди идегез сез.

Г о с м а н. Син шуннан куркып качтыңмы?

Р е г и н а. Буа китә. Ташкын да каты ага, свайлар да какшаган, яр да җимерелә. Сәбәпләр күп, ә нәтиҗә бер генә — буа киткән. Менә җырчы кызым үсә. Киләчәктә кем булыр, әмма хәзергә кызым бик әйбәт. Әгәр сиңа кияүгә чыксам, ул кыз бүген юк иде.

Г о с м а н. Җүләр булганмын, ахмак! Тиле! Сантый! Исәр!

Р е г и н а. Кимсетелгән ирлек дулый. Дулавы ошый. Тормышны дулаусыз, каршылыксыз күз алдына китерә алмыйм. Бар курыкканым тешсез игәү хәлендә калу.

Г о с м а н. Мин дә шундый идем бит, Регина.

Р е г и н а. Сез үзегезне бик ярата идегез. Шуннан чыгып «шагыйрь булалмас бу кеше» дип уйлый идем.

Г о с м а н. Буа китәрлек сәбәпләр байтак җыйналган шул.

Р е г и н а. Язын кар китеп, гөрләвекләр тынгач, җир кипшергәч, болынга ут җибәрергә ярата иде минем әти. Ут калдык үләннәрне, курай-сабакларны ялмап алга үрмәли иде. Хәтәр! Шул утны салмасаң, болынны әрсез күрән, чүп-чар басып китә, ди иде ул. Шагыйрь кеше әнә шулай чүп-чарларны көйдереп яшәүче ут булырга тиеш. Уттан соң болыннар күпереп, яшәреп чыга. «Мин дә мин» дип яшәгән кеше, үз рәхәте өчен туып өлгермәгән баласыннан баш тарткан кеше ут була алмый. Ут булганчы юк булсын андый кеше. Аңа хатын да, ил дә, бала да кирәкми. Сүзләрем каты булса да, сабырлан, әллә ничә ел әзерләгән сүзләрем ич.

Г о с м а н. Ачык сөйләвең өчен рәхмәт.

Р е г и н а. Дөреслекне аз ишетәдер сезнең колак.

Г о с м а н. Нигә?

Р е г и н а. Ялагайлар болынны басты. Ут җибәрүчеләр юк.

Г о с м а н. Дөреслек белән дөреслек арасында да зур аерма бар. Бутама. Кайбер газетачылар нефтьчеләргә ябырылалар. Иген басуларын бозалар, имеш. Елга-күлләрне пычраталар, имеш. Дөреслекме? Өлешчә дөрес. Ә илдәге дүрт моторның берсен Татарстан нефте әйләндерә. Кайсысы олырак бу дөреслекнең?

Р е г и н а. Сезгә моннан китәргә ярамый, Госман абый.

Г о с м а н. Кайтуыңның сәбәбе шулмы? Нигә иң мөһимен әйтмисең?

Р е г и н а. Белсә идем мин аны, нигә кайтуымны!

Тынлык. Яңгыр ява. Өйдән Л о к м а н белән У р а л чыгалар.

У р а л. Анда энекәш тузына. Минем малай тугач кына элекке йолаларны боздыгыз, ди.

Л о к м а н (*Регинага*). Төпчек малайлар бунт чыгарырга ярата! Яңа туган Шабановны зурлыйк, мылтык атарга кирәк.

Г о с м а н (*уңайсызланып*). Без иске таныш белән гәп куертабыз.

У р а л. Иске таныш — узган гомер ул. Кадерле кеше.

Г о с м а н. Кыекка кайсыгыз менә?

Р е г и н а. Ай, мин мылтык тавышыннан куркам.

У р а л. Шабановларда күршене борып чыгару гадәте юк.

Л о к м а н. Бер-ике чынаяк чәй эчмичә аяк та атламыйсыз. Госман да китми. Әти рәнҗер. Мин этине беләм, без бергә үстек.

Р е г и н а. Әти белән бергә үсәргә мөмкинмени?

Л о к м а н. Мин туганда этигә егерме дә тулмаган иде. Бу тәти егетләр мин исәйгәч кенә дөнья күрде. Әти белән икәү карап үстердек без аларны.

Мунча ягыннан Т а й м а с белән С а б и р а күренәләр. Муеннарында сөлге, пешеп-янганнар. Өйдән М и р х ә т чыга.

Т а й м а с. Менә рәхәт, менә бәрәкәт. Дөнья байлыгы шул булыр: тазалык-саулык.

У р а л. Исәнлеккә-саулыкка булсын, әти.

С а б и р а. Хуш-рәхмәт мунча хөрмәтенә. (*Таймаска.*) Күрдеңме? Ятьрәк чабын, зарыкканнардыр, дим. Ишегалдына чыгып көтеп торалар. Бер кергәч тиз генә алып чыгып буламы соң аны! Мунча пәрие.

Т а й м а с. Локман, сагындырдың, улым.

Л о к м а н. Так точно, солдат Локман Шабанов кайтып җитте. Исәнме, әти. Әни ни хәлләрдә?

С а б и р а (*еламсырап*). Дүртесе дә җыйналганнар. Бер кулга ике карбыз тоталмаган күк, дүрт малайны да бер табында күрә алган юк иде. Хәерлегә була күрсен, берүк. Таймас, дим, ә без мунча ташы саклыйбыз. Чәчләрем тарау... Табын, табыным...

Т а й м а с. Сабыр ит, Сабира.

М и р х ә т. Урал абый, мылтык атар өчен иң кәттә чак.

Т а й м а с. Түз, чак кына түз.

М и р х ә т. Какой-такой түз? Ашамыйча түз, эчмичә түз... Адәм баласы нигә яши? Малаймы әллә мин? Хәзер үк атабыз. Сез атмыйсыз икән, мин атам.

У р а л. Өй түбәсенә мин менәм.

Т а й м а с. Түзегез инде мин әйткәч!

Я к у т белән К ә ү с ә р и я керәләр.

К ә ү с ә р и я. Керегез инде, сездән башка өйдә күңелсез.

Я к у т (*коры тавыш белән*). Әни бәгырем, сез җилдә озак утырасыз. Мунчадан соң кан басымыгызны үлчәп алыйм. Ятып хәл алыгыз.

С а б и р а. Рәхмәт, килен. Бик рәхәт әлегә, бер дә суык түгел. Оеплар утырам. Тамагым гына бик янды. Өч рәт менеп чабынды бит менә бу шүрәле.

Г о с м а н. Газаплама әнине, Якут.

К ә ү с ә р и я. Курка-курка гына табын әзерләгән булдык шунда.

С а б и р а. Ипләп, этиең ишетә күрмәсен.

Л о к м а н. Рәхмәт, эти, мине зурлагансыз. Мин кайтуга олы мәҗлес оештыргансыз. Гомер онытмам.

Т а й м а с. Дөрес, дөрес. Мәҗлес җыярлык сәбәп һәммәгездә дә бар. Шул сәбәпле, сүз куешкандай, бергә җыйналдыгыз. Тик, Мирхәт улым, мылтыкны чак кына төзәтеп тор. Бер дә атарбыз, ике дә дигәндәй... (*Госманга карый.*) Госман басынкыланып киткәнме?

Г о с м а н. Тамашачылар да калсын инде.

Т а й м а с. Синең белән хәзер шахмат уйныйбыз. Ә-ә, Регина күрше дә монда лабаса. Нигә ятим бала төсле бер читкә елыштың? Мунчаны ай-һай кыздыргансың. Менә, балалар, күрше олылап мунча якты. Кайсыгыз бара хәзер?

Л о к м а н. Чират минеке булса, барам.

Г о с м а н. Бу мәҗлес кем хөрмәтенә җыелган, шул барсын.

М и р х ә т. Футбол, футбол! Аңлыйсызмы?

Г о с м а н. Баядан бирле уйлыйм: ничек болай бергә җыела алдык без?

У р а л. Вакыт үзе җыйды безне.

Р е г и н а. Таймас абый, кирәгем чыкса, мин өйдә булырмын.

Т а й м а с. Күздән югалма әле син!

Р е г и н а чыга.

У р а л. Тормыш кайбер чатакларны үзе төзәтә. Җыелырга вакыт җиткән безгә.

С а б и р а (*кырыс*). Как өстәлгә тагын бер кунак өндәдеңме, Таймас?

Т а й м а с. Йә, кайсыгыз батыр?

М и р х ә т. Арка түгел, тамак кычыта...

У р а л. Хәзер дүртәүләшеп китәбез. Әти йортының, мунчасының шифасы кирәк безгә.

Т а й м а с. Локман, таяныймчы, улым, сиңа. Хәлем бетеп китте. Татулыкның башы мунча булыр. Балавыз сыкма, Сабира, барыбер умарта асрап булмас.

С а б и р а. И-и, балакайлар, балакайлар!

У р а л. Әти мунчасыннан баш тартырга кирәкми, Госман абый! Барабыз.

Өйгә керәләр. Госман таркау. Якут башын күтәреп, җыелганнарга кимсетеп карап, иң алдан атлый. Локман белән Кәүсәрия Таймасны култыклыйлар. Сабираны Урал култыклаган. Иң актыктан, зур канәгатьсезлек белән Мирхәт атлый. Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә. Урындыклар гына арткан. Таймас белән Сабира кече якта, мунчадан соң ял итәләр. Якут белән Урал картлар янында. Локман белән Кәүсәрия кухняда. Пәрдә ачылганда Госман белән Мирхәт пиджакларын салып ташлаганнар да, җиң сызганып, иске радиоалгыч тирәсендә азапланалар. Лилия алар тирәсендә йөри.

Лилия. Ну, пап... Әй, әти.

Мирхәт. Чү!

Лилия. Тоташтыр инде музыканы. Миңа күңелсез.

Мирхәт. Тибеп очырырмын.

Госман. Юкмы?

Мирхәт. Шундый җаваплы матчны радиодан тапшырмыйлар!

Госман. Да-а...

Мирхәт. Телевизор тоташтырсак, шау-шу кубар инде?

Госман. Кубар дип... Нидер кирәк безгә хәзер. Спорт ял иттереп кенә калмый, уйлатмый ул кешеләрне, оныттыра. Безгә, барыбызга да нидер кирәк хәзер.

Мирхәт. Әтиләр ял итәргә яткан.

Госман. Әти бүген нидер көтә. Нидер сагалый.

Лилия. Папа!

Мирхәт. Папа Ватиканда. Кабатлатма бер үк сүзне.

Лилия. Ну, әти. Минем майлы ипи ашыйсым килә.

Мирхәт. Минем әллә ниләр эшлисем килә дә бит, үз иркендә түгел. Әбиең янына кермә, берни сорама.

Лилия. Кая барыйм соң?

Мирхәт. Йөгер күршеләргә!

Лилия. Майлы ипи ашаргамы?

Мирхәт. Футбол исәбен белешергә. Исәпне генә сора да выжт. Бу як күршегә түгел, каршыга кер. (*Лилия чыга.*)

Госман. Сигезенчедәме синең кыз? Сигезенчедә кыз шундый була икән...

Мирхәт. Өйдә генә утырган булсам! Иптәшләр керер иде, иллешәр грамм гына кабып зәңгәр ут каршысына тезелешер идек. Гол кергән саен йөзәрне җиффәрергә була. Һәркемнең күңеле ял итә, бәйрәм.

Госман. Өйдә дә утырып булмый шул кайчагында! Каядыр ашкынасың. Әллә белеп, әллә язмыш кушып...

Кухняга кереп китә. Мирхәт, ниһаять, телевизорны тоташтыра да тавышны киметә алмыйча йөди. Футбол уены бара, бик каты тавышлар. Урал, кереп, телевизорны сүндерә.

Урал. Бүген кирәкми. Артык.

Мирхәт. Аз гына, сыңар күз белән генә!..

Урал. Укырсың. Газеталарда отчеты булыр.

Мирхәт. Миңа уен кирәкми. Миңа онытылырга кирәк.

Урал. Башка чарасын тап.

Мирхәт. Мин аның ике генә чарасын беләм: берсе аракы, икенчесе телевизор.

Урал. Бүген безгә уйлый торган, уйлана торган Мирхәт кирәк.

Мирхәт. Мин сез теләгән кеше була алмыйм. Заманы ул түгел. Урал абый, китим мин. Хатын роддомда, ачуланып ятадыр.

Урал. Әтиләр чак кына хәл алсын, роддомга бергә барабыз.

Сабира белән Якут керә.

Якут. Мине тыңлагыз, әни.

Сабира. Хак Тәгалә язган булыр, килен. Хәлем зарланырлык түгел. Ятып тора алмыйм. Кәүсәрия килен янына керәм. Кеше өендә ул ни белә? Балаларым монда чакта ятакта ауныйммы?

Якут. Әни бәгырем, сезгә ял кирәк.

Урал. Якут ханым, әтине карагыз сез.

Якут, Мирхәт чыгалар.

Сабира. Урал, әтиең юри ята. Мунча аның хәлен аламы? Юри кылана. Юри табынга утыртмый.

Урал. Сизенәм. Ник кыланганын гына аңлап бетермим.

Сабира. Башым катты. Шигем бар барын, тик әйтергә тел әйләнми. Теге Регинаның кызы... Нигә әтиең шуны күрде икән?! Бүгенге көн тыныч кына узсын берүк!

Кече якка керәләр. Кухнядан Локман белән Кәүсәрия чыга.

Кәүсәрия. Уф, ирем күзенә туры карар көнем бар икән.

Локман. Әтиләр шундамы?

Кәүсәрия. Хәл җыярга ятканнар.

Локман. Мирхәтнең кызын ашатыр идегез.

Кәүсәрия. Үзем дә гуҗ йотардай булдым әле.

Локман. Нихәлләр соң карчык?

Кәүсәрия. Безгә ни булсын?

Л о к м а н. Мин дә ару гына йөреп кайттым. Озаграк юаныллы. Рәнҗештән булмасын. Мәскәүдә полкташлар очраштык. Смоленскидагы бер авылда иптәшләргә һәйкәл ачылды, анда барып кайттык.

К ә ү с ә р и я. Локман...

Л о к м а н. Карт солдат бөтен заказларны үтәде. Күчтәнәче дисеңме, чүпрәк-чапрак...

К ә ү с ә р и я. Картым, инде соңгысымы?

Л о к м а н. Авыр сүз әйтәсең.

К ә ү с ә р и я. Былтыр да, өченче ел да, элегрәк елларда да: «Актык мәртәбә барам, инде кабат йөрелмәс тә»,— дия идең.

Л о к м а н. «Бармам» дип, ант эчкәнем юк.

К ә ү с ә р и я. Ялварып, зинһарлап сорыйм синнән. Безгә монда бик читен. Кеше арасына чыгарга оялам. Беләм, тиккә йөрмисеңдер. Шулай да камсамул чагың түгел, бабай кеше ласа. Әнә Госман ничек оста төрттерә. Олы урындагы, акыллы кеше.

Л о к м а н. Һәркемнең акылы үзе белән. Берәү дә акыл сатарга базарга чыкмый. Берәүләр акылны үз файдасына гына тота. Мин андый түгел...

К ә ү с ә р и я. Өзеп әйт, актыкка баруыңмы?

Л о к м а н. Аны ничек алдан әйтеп куйыйм? Алда ел яшисе бар. Ел дәвамында ниләр уйланылыр. Кайткан мәлдә аз-маз тынычланган кук булам да, тагын әллә нинди уй-фикерләр туа. Дүрт ел сугышкан кеше бит мин. Мең дүрт йөз унсигез көн эчендә хисапсыз иптәшләремне күмдем. Аларны зыярат итеп бетерү өчен генә дә бер гомер җитәрме? Тыйма син мине, Кәүсәрия. Актыккысымы, дип якамнан алдың. Актыккысы ерак түгел. Полкташлар җыйналабыз. Елдан-ел безнең сафлар сирәгәя. Исән калганнар да кәкре дә бөкре. «Ур-ра!» кычкырабыз, «үр-рә!» килеп чыга... Җыласаң җыла... «Ур-ра» кычкырып җир тетрәтәчәкләрне кем тәрбия кылыр? Синең акыллы Госманыңмы? Аңа ни, үзе рәхәт яшәсә, башкаларның күзенә тоз!.. Яралар сызлый. Көз. Юеш. Дымлы. Сиңа күчтәнәчләр алып кайттым. Яшел йон кофта. Һиндстанның үзеннән килгән.

К ә ү с ә р и я. Рәхмәт алары өчен.

Л о к м а н. Алары өчен генәме, карчык?

К ә ү с ә р и я. Ай, өчпочмагым көя түгелме?

Л о к м а н. Өчпочмак та вакытын белеп көяр икән.

Чыгалар. Г о с м а н белән М и р х ә т керәләр.

Г о с м а н. Син нәрсә мине сагалап йөрисең?

Мирхәт. Мине бер четерекле нәрсә борчый.

Госман. Әйтеп кара.

Мирхәт. Бу хатын артык чая күренә, этигә анымоны тишмәгәндер бит, ә? Әти бик кырын карый миңа.

Госман. Аннан башка да синең гөнаһлар җитәрлек.

Мирхәт. Госман абый, гафу ит, белмәдем. Син ул хатын белән...

Госман. Тый телеңне. Синең ише тиле аңлый торган мәсьәләме ул? Барысын да үзеңнең бозык бизмәнеңә саласың. Ә ул бизмәндә ике кадак шалкан гына үлчәп була.

Якут керә, Мирхәт чыгып китә.

Якут. Госман!

Госман. Нәрсә бар, иркәм.

Якут. Китәм дип ничә талпындың, һаман монда.

Госман. Син таш йөрәкне чәпчетерлек ни булды икән?

Якут. Ниндидер мылтык турында сүз бара. Кыргыйлык ич ул! Бала туды дип түбәгә менеп, шау-шу куптар инде!.. Мәҗүсилек заманыннан килә торган яман гадәтләр.

Госман. Ә бала туган бит. Малай!

Якут. Туса ни? Аңлы кешегә бала комачау гына. Кеше үз максатына ирешү юлында баладан азат булырга тиеш.

Госман. Кем сүзләре болар.

Якут. Акыллы сүзләр. Бәлки, синекедер?

Госман. Ничек балалар врачы булып эшли аласың син?

Мирхәт керә, нишләргә белми арлы-бирле йөри.

Мирхәт. Ничек? Ничек чыгып ычкынырга моннан?

Якут. Ишетәсеңме, Госман?

Локман керә.

Локман. Картлар «гомер итү — бер ишектән кереп, икенчесеннән чыгу кебек кенә» дип мактансалар да, сизәм, җитмеш бишне яшәү өчен байтак батырлык кирәк.

Госман. Олы абый Мәскәү юлларыннан философ булып кайткан. Аның фикерен раслау өчен хәзер Урал килеп керә.

Урал керә.

Урал. Кем мине юксынды?

Г о с м а н. Һәммәсе кабатлана. Әйткән идем бит!
М и р х ә т. Без дүртәү...
У р а л. Киттек мунчага?
Л о к м а н. Мунча сүзен ишетүгә, минем авыз ерыла. Без үскәндә кара мунча кызыл почмак булды. Кәүсәрия җиңгәгез белән шунда, йөзек салышканда таныштык. Минем йөзеккә Кәүсәрия җиңгәгез, ул чагында сылу бер кыз иде, «бигрәк тә матур булгансың, сыер мөгрәгәндә тугансың» дигән мәхәббәтле җыр әйтте.
Г о с м а н. Алдан күргән, Кәүсәрия җиңгәм. Олы абыйның гомергә башы иелгән...
У р а л. Олы абый этигә охшаган. Кешегә бил бөкми. Алдашмый. Тапканын җилгә очырмый. Иртәгә ни киярмен, ни ашармын дип ут йотмый. Үз илендә. Үз җирендә. Үзе хуҗа. Галиҗәнап эшче — олы абый.
Г о с м а н. Хатыны белән тату. Балалары белән дус...
Л о к м а н. Очрашкан саен төрттерәсең син миңа, Госман.
Г о с м а н. Олы җиңгәмнең эти белән әнигә бүген зарланганын ишетсәгез иде сез!

Атылып, К ә ү с ә р и я керә.

К ә ү с ә р и я. Хатын сүзен сүз итеп сөйләп йөргән кешене әйтер идем мин. Ходай сиңа белеп бала бирмәгән! Изге күңелле олы абыеңны яманлыйсың.

Таймаслар ягыннан Я к у т керә, бөтенесе дә тыналар.

У р а л. Этиләр ни хәлдә?
Я к у т. Әйбәт. Мин аңлап кына бетермим...
К ә ү с ә р и я. Әле дә чыдыйлар инде, килендәшкәем. Бая мунча ишегеннән башымны тыгып караган идем, имәнгеч, чәчемне көйдереп алды. Ат йөрәге бар икән үзләрендә, чыдыйлар бит. Андый утсыз тәмугта бусагасына ябышып үләрсең.
Г о с м а н. Яшәсен гадилек! Көчләп-көчләп мине кая җибәрергә маташуыгыз фаш булды.
У р а л. Врач чакыртыйкмы әллә?
Я к у т (*үпкәләп*). Монда бер врач бар. Шул җиткән.
У р а л. Сез, Якут ханым, балалар врачы. Әгәр малай чагым булса, каралырга гел сезгә генә йөрер идем.
Я к у т. Бер дә җыламас идегезме?
У р а л. Якут апам, энҗе-мәрҗәнем дип кенә торыр идем.
Г о с м а н. Уһу!

Я к у т. Менә кешеләр ничек тә сөйләшә беләә! Үземне санга кертмим. Монда тагын бер табиб булырга тиеш.

У р а л. Кайсыбыз ул?

Я к у т. Белмим. Алар дүртегездән берегезгә бик нык рәнҗиләр.

М и р х ә т. Миңа рәнҗиләр, миңа!

У р а л. Миңадыр. Байтактан керә алган юк.

Л о к м а н. Гаеп миндә. Озак та йөрелде...

Г о с м а н. Юкка баш ватасыз. Миңа гына рәнҗиләр!

Л и л и я керә.

Л и л и я. Ноль — ноль!

М и р х ә т. Шайтан, берәрне ямый алмаганнар! Нишләп озак тордың?

Л и л и я. Бәрәңге ашаттылар. И тәмле! Кереп чыккан өчен синнән морожныйга унбиш тиен.

М и р х ә т (*тешен кысып*). Ноль — ноль! Мылтык атылмады. Футбол карап булмады. Очрашу җимерелде. Бөтен яктан ноль — ноль!

Л о к м а н. Синең юка башыңда ноль — ноль!

Г о с м а н. Олы абый Мәскәү юлларында телен чүкеткән.

К ә ү с ә р и я. Тотындылар әйрән бутап май язарга!

У р а л. Якут ханым, Лилиягә чәй эчертсәгез икән.

Якут Лилияне алып чыгып китә.

Г о с м а н. Сүзне уйнап башламадым. Бүген байтак нәрсәләр турында сөйләштек, ачыклыйсы тагын бер әйбер бар. Олы абыйның хисләрен зурлыйм. Беләм, сугышта үлеп калган иптәшләренең каберләрен зыярат итеп кайта. Исемсезләрнең исемен таба. Мондый эшкә кайнар йөрәк кирәк. Олы абый, онытмагансыңдыр, сугыш беткән елларны сәфәрләреңне мин дә хуплый идем. Юллык акча биргән чакларым да булды.

Л о к м а н. Район физкультура комитетында эшләүче гади егет идең син ул чагында, Госман!

Г о с м а н. Олыгайдың, буыннар сызлый дип зарланасың. Елына бер килә торган кадерле ялыңны Мәскәү, Смоленск юлларында уздырмасаң да сиңа үпкәләүче юк хәзер.

Л о к м а н. Адәм балаларының рәвеше, фигыле, шул җөмләдән ялы да төрле-төрле.

Г о с м а н. Гел-гел бер юллардан нинди ямь тапмак кирәк?

Л о к м а н. Әйдә, киләсе елга ияртеп барам.

К ә ү с ә р и я. Әллә?..

Г о с м а н. Карап кайтасы иде бер!

М и р х ә т. Абыйлар, абыйлар... Сөзгәк сыер сөтен имгән үгәйләр төсле талашасыз!

У р а л. Госман абыйның хәзерге минутта Олы абыйга һич бер ачуы юк дип уйлыйм мин. Аның ачуы башкада!.. Тик ул ачылып бетми әлегә. Олы абыйны болай гына, узып барышлый гына кимсетә.

Л о к м а н. Иң башта Кремль янындагы солдат каберенә барам. Кем ул? Урысмы, татармы, әрмәнме? Эшчеме, крестьянмы, укытучымы? Белмим. Төн уртасында, кеше аяк эзе басыла төшкәч барам да шул солдат белән ныгытып сөйләшәм. Эштә дә сөйләшәм мин аның белән, беләсегез килсә... Солдат дуслар... Алар барысы да япь-яшь килеш җир куенында йоклыйлар. Мин җир өстендә. Алар күрмәгәнне күрәм. Алар белмәгәнне беләм. Алар татып өлгермәгәнне татыйм. Кайсылары: «Барып җитә алмадым!»— дип, Берлинга таба йодрык төйнәп ауды. Кайсылары: «Кайтып ла җитә алмадым!»— дип, туган якка таба борылып үлде. Сөйләшер сүзләр күп безнең.

Г о с м а н. Олы абый, үткәннәр белән генә яшәү читен.

Л о к м а н. Беләм. Ләкин кемнәрдер өчен ул канлы сугышлар булмаган да кебек. Фронтовик дисәм, авыз еручылар бар.

Г о с м а н. Үткәннәр белән, хатирәләр белән генә яшәү турында әйтәм.

Л о к м а н. Солдат баш очында ут янып тора. Солдат истәлегенә мәңгелек ут — газ яна. Җирнең кайсы тармагыннан чыккан газ икән бу дип тә уйланам. Әлмәттәнме? Себердәнме? Урта Азиядәнме? Торам-торам да, үзебезнең яклар — Әлмәт — Бөгелмә калкулыкларында мыштым гына янып утыручы факеллар күз алдыма килә. Менә алары кем хөрмәтенә, кем истәлегенә айлар-еллар яна икән?

Г о с м а н. Һиндстанда икешәр мең ел янган факеллар бар.

К ә ү с ә р и я. Факеллары яна, кияргә ыштаннары гына юк.

М и р х ә т. Ыштансызы аның Пакстан!

Л о к м а н. Самолет тәрәзәсеннән ныклабрак карасаң, унлап-егермеләп факелның дулый-дулый янганы күренә. Бу юлы кайтканда бер иптәш: «Вечный огонь в честь

неизвестного разгильдяя»,— дип куйды. Икенчесе офтанды да: «Күренеп торган шушы факелларда янган газның куәте генә дә бәләкәйрәк бер шәһәрне җылытып гөл итәргә җитәрлек»,— дип ачыклап бирде.

Госман. Урал, олы абыйны син әзерләп кергәнсең!

Урал. Әйе, Мәскәүдә дә бергә булдык, самолетта да бергә очтык.

Якут. Ул турыда газеталарда да бик язалар. Мин бер журналда укыдым. «Йә кешеләр җирдә төтенне киметәләр, йә төтен кешеләрне киметәчәк»,— диелгән.

Госман. Ат дагалаганда кемнәр генә юк...

Мирхәт. Госман абый, бир әле шуларның кирәкләрен!

Госман. Бер иш вак кешеләр нәни эмоцияләр, вактөяк хисләр белән яши. Дәлилләре дә вак. Гаепләүләре вак. Сез хәзерге заман кешесенең, нинди саннар белән эш итүенә генә карагыз. Берәүләр өч тиенлек шалкан, ике тиенлек кишер, биш тиенгә автобус билеты дип чутлап утыралар. Ә икенче берәүләр меңнәр, миллионнар белән генә эш йөртә. Миллионнар өчен җавап бирә.

Урал. Кем миллионнары белән эш йөртә бит.

Госман. Нефть аптекадагы дару түгел. Ул илнең эчке һәм тышкы сәясәтен билгеләүче көч.

Урал. Килешәм.

Госман. Нефтьне җир бирә, табигать бирә. Табигать үзе бозыла икән, аңа карап эшне туктатыргамы? Каспий диңгезе бер генә, уникаль диңгез.

Урал. Нигә иген басулары пычрана?

Госман. Ике икең — дүрт. Шул ук сорауны мин сиңа да бирә алам. Олы абыйга да, Мирхәткә дә. Барыбыз да нефтьтә.

Урал. Мин бит синнән генә җавап таләп итмим, синең белән рәттән басып җавап бирергә телим.

Мирхәт. Җәмәгать! Шахмат турниры ачык! Кем уйный?

Госман. Минем җавап күптән бирелгән: йөз миллион тонна!

Мирхәт. Абыйлар, мин дә бер кызык сөйлимме?

Локман. Буразнадан читкә чыгасың, энекәш.

Мирхәт. Ике егет, ике кыз машинага утырганнар да Зәйгә балык сөзәргә төшкәннәр.

Госман. Егетләрнең берсе Мирхәт исемле икән.

Мирхәт. Кызлар кабинада утырып калган, егетләр

анадан тума чишенеп ташлаганнар да җәтмәгә тотынганнар. Урын аулак, елга пычрак, сөзәләр генә. Чытлык кызлар ялгыш машинаны кузгатканнар да чикылдарга тотынганнар — берсе дә йөртә белми икән. Машина бара-бара ярга килеп төртеләм дигәндә, балыкчылар моны абайлаганнар. Шофер егет дөньясын онытып судан сикереп чыккан да чабып барып машинаны туктаткан. Егет шултиклем нефтькә манчылган икән, кызлар аның шәрә тән икәнлеген дә абайламаганнар. Хи-хи, соңыннан гына исләренә килеп, «Илбарның купальнигы бигрәк юка, японскидыр ул»,— дип сөйләшәләр икән.

Локман. Җылыйсы урында көләсең. Урал. Нефть бик күпләргә чамасыз булып тоела. Нефть — җир каны. Җир-анабыз безгә үзенең җан җылысын бирә. Донор кебек.

Госман. Минем ни гаебем бар?

Якут. Әйе. Аның ни гаебен табасыз сез?

Урал. Без барыбыз да гаепле. Тик бер генә аерма бар, зур аерма: сыйлаганда син түрдә утырдың, хисаплашыр, түләр вакыт җиткәч, моннан таярга уйлыйсың.

Таймас белән Сабира керәләр.

Таймас. Без дә монда.

Сабира. Иллә дә мәгәр сезне тыңлап яту кызык икән. Очрашканда сүзгә кереп китә торган гадәтегез барын беләм, әллә мин болгаткыч таяк әтиегезме дисәм, үзегез дә кыдрач әтәчләрдән ким түгел икәнсез сез. Юк, Таймас, ым кагып маташма, сабыр итәрем юк, җитте. Булды, гарык! Җитәр, ызгыштырма малайларны. Эш-мазалары читтә калсын. Ата йортында ял итсеннәр. Түребезгә татуларны утыртыйк. Тоташтырыгыз телевизорны. «Спартак» ямасын әле тегеләргә, әй, кемнәргә әле? Тагын ике шахмат тактасы алып кайтам!.. Теге таяк белән шарга төртә торганны алып куям, Кәүсәрия килен!

Кәүсәрия. Әү, әни.

Сабира. Чыгар ашны! Якут килен!

Якут. Тыңлыйм, әни.

Сабира. Йөгер, китереп тез өчпочмакларны. Самоварны үзем җилтерәтәм.

Мирхәт. Үзем, үзем!

Сабира. Көчем барында балаларны талаштырмам.

Таймас. Ята-ята сөендем дә, көендем дә. Киленнәр,

сабыр итегез. Сезнең һәр аяк тавышыгыз да безнең күңелләргә үк килеп кагыла. Борында бабагыз бер риваять сөйли торган иде.

Сабира. Болгатма дим! Футбол бетә!

Таймас. Борынгыда явыз ханнарның берсе, юк кына гаеп өчен, ата белән улга йөзәр таяк хөкем кылган. Ата тешен кысып үз җәзасын алган. Нәүбәт буенча, аның артыннан ук улын суктырырга тотынганнар. Улы тәненә беренче таяк төшүгә үк ата иңрәп, ыңгырашып куйган. Хан тегеңәрдән: «Ни булды, и адәм, нәрсә бар, тәнеңә йөз таяк төшкәндә түзгән идең, улыңа бер оруга ник ыңгырашасың?» — дип кызыксынган. Адәм: «Әй, хөкемдар, теге йөз таяк тәнгә төшкән иде, хәзергесе туп-туры йөрәккә барып тиде», — дигән.

Урал. Әти, аңлашу өчен урынны дөрес тә сайламаганбыздыр, кичер, рәнҗемә.

Локман. Барысы да үзеннән-үзе килеп чыкты.

Таймас. Инде барыгыз да җыйналгансыз икән, тагын бер сүзем бар. Мирхәт, килче мондарак.

Лилия керә.

Мирхәт. Әти, кызган. Хаталык, ялгышлык булды.

Таймас. Өстәл тартмасыннан күн букчаны алып бирче.

Мирхәт (*алып бирә*). Кыштырдый! Акчамы әллә?

Таймас. Локман, янәшәмдә утыр. Аннан ары Госман утырсын.

Урал (*утырып*). Мирхәт, минем янга.

Таймас. Бу кәгазь бөтен акчалардан да кадерлерәк, бу —Шабановлар нәселенең шәҗәрәсе. Родословная диләр аны руслар. Монда безнең борынгы ата-бабаларыбыз түкми-чәчми язылган. Безнең нәселдә, халкыбыздан килә торган изге йолага буйсынып, шәҗәрә семьядагы төпчек малайга бирелә. Олы балалар үзләре тамыр җәеп, яңа нәсел башлап җибәрәләр.

Госман. Пычакның очы үткен!.. Кадала!..

Таймас. Шәҗәрә — изге йолабыз кушу буенча — Мирхәткә күчә. Ләкин моңарчы аның ир баласы булмады.

Урал. Андый очракта шәҗәрә кемнеке?

Таймас. Төпчек малайда ир бала булмаган очракта, нәсел язуы унынчы оныкка (*әгәр ул ир бала булса*) күчәргә тиеш.

Урал. Менә ни өчен унынчы онык даулагансың икән син, эти.

Мирхәт. Абыйлар, мин моны ала алмыйм.

Таймас. Уйла. Нәселебезнең, ил-йортның, гомернең, җир-суларыбызның, Идел-йортның тарихын җилкәңдә алып бара алырсыңмы? Тавык елы килә калса, нәселне, телне, исемеңне алыштырып бәкегә чуммассыңмы?

Госман. Үзе ничегрәк уйлый?

Урал. Өстеңә нинди бурыч төшкәнне аңлыйсыңмы?

Локман. Барыбызның намусы, вөҗданы, иманы синең кулга күчә.

Мирхәт. Мин... мин... бик начар, вак кеше.

Госман. Хатын-кыз булма!

Таймас. Уйла, уйла!

Регина керә.

Регина. Мине чакырдыгыз кебек тоелды.

Таймас. Чакырдым, Регина. Монда иске кәгазьләр арасында байтак шигырьләр саклана. «Регинага багышлана» дигәннәре дә байтак.

Госман. Кирәкми.

Якут. Нәрсәгә ул архив? Кемгә кирәк!

Таймас. Уңайсызланма. Чит кешеләр бар дисеңме?

Госман. Монда читләр юк. Шигырьләр шушы Регинага багышланган.

Сабира. Ялгышмыйсыңмы? Хак сүз сөйлисеңме?

Госман. Бүгенге көнне эти «хак сүз көне» дип игълан итте.

Таймас. Сабыр. Сабира... Регина кызым, кичер мин карт җүләрне, зурны сорыйм: Фәридәнең этисе кем?

Регина. Ул этисез үсте.

Мирхәт. Гайсә пигамбәр кебек этисез туды дамы?.. Гафу. Бетте!

Таймас. Мондамы аның этисе? Безнең арадамы?

Мирхәт. Нәрсә-ә-ә?! Ну, знаете!..

Госман. Регина! Хәер...

Пауза.

Регина. Монда, Таймас абый. Безнең арада. Инде китимме?

Таймас. Чү, кызым. Рәхмәт. Мине аңладың. Башкасы кирәкми дә. Башкасы аның күңел эше. Күңел ярасын төзәтергә беркайчан да соң түгел. Локман! Урал!

Мирхәт! Өй кыегына менегез дә мылтыктан ике тапкыр атыгыз. Бүген минем унынчы оныгым туды.

Я к у т. Ни сөйлиләр алар, Госман?

К ә ү с ә р и я. Бик матур сөйлиләр. Аңлашылып кына бетми.

Я к у т. Нинди телдә? Мин дә аңламыйм.

Г о с м а н. Без бик теләп оныта башлаган телдә, Якут ханым.

М и р х ә т (*һаман исен җыя алмыйча*). Минем улым унынчы Шабанов?! Әй, абыйлар! Җиңгиләр! Мин аңа Таймас дигән исем кушам.

У р а л. Якты исем.

Л и л и я. Ә Гамлет кем була?

Г о с м а н. Әти!

Т а й м а с. Чүгез, шаулашмагыз.

Г о с м а н. Фәридә минем кызым, әти.

Л о к м а н. Тамырың корымаган икән, энекәш. Атаң йорты янында гына тамырың тибеп яткан икән. Нык тор!

С а б и р а. Ник алай булды соң?

Р е г и н а. Сабира апа, анам бул, аңла. Госман абыйның һичбер гаебе юк. Мин үзем аны читкә каккан идем.

С а б и р а. Нигә?

Р е г и н а. Яшь идем, акылсыз идем. Буталган идем. Ул да нык кына буташтырган иде.

Г о с м а н. Кичер мине, Регина.

Я к у т. Синең балаң бар? Кызың?! Димәк, син дә күктәге йолдыз түгел? Шушы кыргый Шабановлар төсле үк? Бала! Ха-ха-ха!

Г о с м а н. Кәүсәрия җиңгәм, Якут ханымга салкын су бирегез.

Т а й м а с. Локман, өч тапкыр атыгыз. Госман улым, туарга бер чакта да соң түгел. Кеше үлгәнче туа, яңара тора...

Г о с м а н. Урал, булып узганнар барыбызга да сабак булсын. (*Чыга.*)

Р е г и н а. Госман абый!

Я к у т (*аңа карап*). Нинди нахалка!

У р а л. Патроннар әзер, әти.

Локман, Урал, Мирхәт, Сабира, Кәүсәрия, Лилия шау-гөр килеп, сәхнә алдына барып басалар. Таймас янында Регина кала. Аткан тавыш.

Р е г и н а. Бер!

Г о с м а н керә.

Г о с м а н. Әти, автобуска биш тиен бир.

Т а й м а с. Китәсеңме?

Г о с м а н (*паузадан соң*). Якут ханым китә.

Р е г и н а. Ике!

Т а й м а с. Булдырдыгыз, егетләр! Булдырасыз, Шабановлар!

Өченче тапкыр шартлаганда, пәрдә төшә, Госман белән Регина берберсенең кулларына тотыналар.

*1970—1972*
*Әлмәт — Казан — Мәскәү*

# *Кар астында кайнар чишмә*

*2 кисәкле җитди комедия*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Әбүзәр — инженер егет, 25 яшьтә.
Тәзкирә — студентка, 21 яшьтә.
Әнисә — урам себерүче, 43 яшьтә.
Кәримҗан — ресторанда повар, 51 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Заманча җиһазландырылган квартира. Китап шкафы. Тахта. Иртәнге сәгатьләр. Кәримҗан электробритва белән кырына. Радио. Татар җыры. Бүлмәгә боксер пирчәткәләре кигән Әбүзәр керә. Карап-карап тора да бокс күнегүләре ясый-ясый чыгып китә. Тагын керә, көтә, радионы кыса. Ниһаять, түзми, эндәшә.

Әбүзәр. Әти!

Кәримҗан. Хәзер, хәзер...

Әбүзәр. Беткән ич инде. Яңакларың шоп-шома. (*Тотып карый.*)

Кәримҗан. Рәхмәт, рәхмәт. Шул пирчәткәләрең белән яңакның шомалыгын белә алгач, рәхмәт. Зирәк егет икәнсең. Куеп тор дим, кагылма! Шундый алап аша да бармакларың тәннең йомшаклыгын сизә алгач, күзең дә, күңелең дә үткердер синең, егет. Искиткеч сизгер җан икәнсең. Ашыктырма дим, тукта! Ир кеше һәрчакта да бик пөхтә кырынган булырга тиеш. Бусы бер...

Әбүзәр. Өс-баш чип-чиста, үтүкләнгән. Бусы булды ике. Аяк киеме яңгырда-карда ялтырап торсын. Менә бусы өч!

Кәримҗан (*тукталып*). Һе, кара син аны, онытмаган. Әтисенең сүзен онытмаган.

Әбүзәр. Әти дим... Мин өйләнергә булдым.

Кәримҗан (*уенга алып*). Шуны белдерер өчен бу

пирчәткәләрне киденме? Куркытырга телисенме? Һушны алырга? Яле, алышып карыйк алайса. Саклан! (*Һөҗүм итә.*)

Әбүзәр (*чигенеп*). Әти дим, мин чынлап.

Кәримҗан. Мин уйнап маташаммы? Чынлап тотындым. Яле, яле, саклан. (*Һаман һөҗүм итә.*) Бу беләкләрдә көч беткән дип уйладыңмы?

Әбүзәр. Көчең дә, егәрең дә җитәрлек. (*Кулларын күтәрә.*) Бирелəм!

Кәримҗан (*дәртләнеп*). Йә инде, тагын аз гына. Ныклап бер алышкан да юк. Ныкмы син, түгелме, белмим.

Әбүзәр. Мин өйләнәм, әти.

Кәримҗан (*тукталып*). Нәрсә? Нәрсә дидең син? Кайчан?

Әбүзәр. Иртәгә язылышырга барабыз.

Кәримҗан. Язылышырга? Ничек язылышырга?

Әбүзәр (*һаман уен итеп сөйләргә тырыша*). Ничек икәнен белмим шул! Беренче тапкыр гына барам. Абый-апалар булмаган... Бер үзем! Барып, күреп, бер очтан язылышып та кайтыйк, дим!

Кәримҗан. Иртәгә дидеңме? Нинди көн соң әле иртәгә? Әһә, җомга көн икән. Җомга... Иртәгә, алайса? Нигә шулай ашыгыч?

Әбүзәр (*санап*). Тимерне кызуында сук... Камырны вакытында бас... Өлгергән җимешне ботагында тотма... Кем сүзләре? Болары да колагыма кереп калган, әти.

Кәримҗан. Кайчандыр мин аткан укларны учыма җыя бардым диген?.. Һәм шуларны үземә каршы атасыңмы? Үзем татыган ачы тормыш сабакларын миңа каршы көрәшкәндә кулланырсың дип өйрәттемме мин сиңа? Мин ясаган хаталарны ясамасын дип кенә өйрәткән идем.

Әбүзәр. Юк, әти, ашыгыч дип әйтмә. Бер дә алай уйламыйча түгел. Курыкма. Мин аны байтак, төрле яклардан килеп сынадым. Беләм. Ике ел беләм. Моннан ике ел чамасы элек, май кичендә танышкан идек. Язын. Иң шигърилятле вакытта. Җәйге кинотеатр ачылган гына көн иде. Карыйм, ул да ялгызы. Мин дә... Сөйләшә киттек...

Кәримҗан. Ике ел?!

Әбүзәр. Азрак тоеламы әллә, әти?

Кәримҗан. Ике ел аз түгел. Кая ул! Бик күп! Һәр елда өч йөз алтмыш биш көн. Тәүлек саен егерме дүрт сәгать. Сәгате дә алтмыш минутка бүленгән бит аның. Алтмышка, Әбүзәр, беләсеңме? Өйләнүең турында әйтергә

нибары ике минут вакытың китте. Син шул ике минутны, ишетәсеңме, ике генә минутны моннан элегрәк таба алмадыңмы?.. Әтиең өчен ике минут табылмадымы? Кәләшеңне ике ел беләсең икән үзең! Әйбәт!.. Миңа кем була инде ул?

Әбүзәр. Кем дип... Сиңа бала була. Килен дисәң дә ярар. Кызым дисәң тагын да шәбрәк.

Кәримҗан. Кәләш, килен, кызым, үз балам... Загска гариза бирдегезме?

Әбүзәр (*авызы ерык*). Бөтенесе тәртиптә, эти. Гариза бирелгән, машиналар сөйләшенгән. Кияү егетләре әзер, ыжгырып торалар. Кызның иптәшләре төн йокламый. Фотограф бар!

Кәримҗан. Загс марҗалары белә... Диспетчерлар белә!.. Егетләр белә! Кызлар көтә! Бөтен шәһәр, бөтен халык белә. Мин генә берни белмим.

Әбүзәр. Эти, син өйләнмисең бит. Без өйләнешәбез.

Кәримҗан. Төшендереп бирүеңә рәхмәт. Олыладың.

Әбүзәр. Хәер-фатиха диләрме әле?

Кәримҗан. Кем ул?

Әбүзәр (*авызы колакта*). Улмы? Искиткеч кыз. Татарстанда бер. Союзда! Матур да, акыллы да, уңган да!

Кәримҗан. Салып ыргытчы шул пирчәткәләреңне!

Әбүзәр. Әйтәм бит, син аны бер генә күр! Бер генә!

Кәримҗан. Кайда эшли? Кәсебе ни?

Әбүзәр. Укый. Студентка.

Кәримҗан. Яшь икән әле.

Әбүзәр. Йә, ничек? Син ризамы? Ризалыгыңны бирәсеңме?

Кәримҗан. Кәләшең турында бик күп сөйләп ташладың да исемне югалттың.

Әбүзәр. Калганын күрешкәч белерсең.

Кәримҗан (*үтә кырыс*). Ата-анасы бармы, ичмаса? Туганнары? Нинди кешеләр? Күрешкәнегез бармы?

Әбүзәр. Туганнары юк та бугай аның... Әнисе бар! Анысы бар!

Кәримҗан. Нинди һөнәр иясе? Кайда эшли?

Әбүзәр. Эти! Алары нигә кирәк? Мин бит аның әнисенә өйләнмим. Без аларда яшәргә җыенмыйбыз да. Әйе. Без Тәзкирә белән алдан ук сүз беркеттек... Дөресрәге, шулай итик дип ул үтенде. Сиңа да, аның әнисенә дә өйләнешүебезне көнендә генә әйтергә булдык. Ялт иттереп Загстан кайтып керәбез дә, шап иттереп таныклыкны кулыгызга тоттырабыз. Яңачамы?

Кәримҗан. Алайса, нигә син килешүне боздың?

Тирәнтен уйланган, бар җәһәттән нигезләнгән, төн йокыларын качырып төзелгән акыллы килешүне нигә боздың?!

Әбүзәр. Тәзкирәнең әнисе дә, туганнары да берни белми. Чын!

Кәримҗан. Мин аларга караганда күп бәхетлерәк булып чыгам!

Әбүзәр. Син бит миңа эти генә түгел, әни урынына калган кеше дә.

Кәримҗан. Ә син миңа кем? Бер мәртәбә булса да шул хакта уйлап караганың бармы, йомры баш?

Әбүзәр. Мин синең бердәнбер улың.

Кәримҗан. Син? Улым гынамы? Шулай гынамы?

Пауза.

Әбүзәр. Тәзкирә ошамадымы сиңа? Син каршымы?

Кәримҗан. Нинди Тәзкирә?

Әбүзәр. Кәләшемне әйтәм. Сөйләгәннәр азрак тоелса, менә карточкасын кара. Дөрес, тормышта ул мең тапкыр чибәррәк. (*Пауза.*) Нигә карамыйсың? (*Пауза.*) Нигә эндәшмисең? Ни уйлыйсың? Тәзкирә турындамы?

Кәримҗан. Мин аның бичара әнисе турында уйлыйм.

Әбүзәр (*рәнҗеп*). Нишләп бичара булсын ул? Балалар бакчасында мөдир. Иреклe совет гражданкасы. Исеме Әнисә. Әнисә апа. Әнисә Шәйхиевна.

Кәримҗан. Бичара шул, бичара. Кызының нинди юньсез, ахмак егеткә тап булуын белми әле.

Әбүзәр. Мин ахмакмы? Юньсез?!

Кәримҗан. Күз алдына китерәм дә тәнем чымырдый. Бәлки, синең Тәзкирәң дә, ахыр чиктә, ялгыз атаудагы Робинзон түгеллеген, бала икәнлеген, әнисе, туганнары барлыгын исенә төшергәндер. Ул да нәкъ синең төсле: «Шәп егеткә кияүгә чыгам, эчми, тартмый, спортсмен... Ике бүлмәле фатиры бар... Заводта дәрәҗәле генә инженер... Чибәрлеге дә ярыйсы... Әтисе Казандагы иң атаклы ресторанда повар»,— дип мактый-мактый, әнисен юмалап маташадыр...

Әбүзәр. Ул әйтмәс. Ачык авыз түгел!

Кәримҗан. Сиздермәс дисең, алайса?

Әбүзәр. Үлсә дә сер бирә торганнардан түгел.

Кәримҗан. Егетне әтисенә каршы котыртып, әнисен чүпкә дә санамаган кара эчле кызны кәләш иткәнсең икән. Шуны оялмыйча минем алда мактарга телең барамы? Бар, эшеңә соңга каласың.

Әбүзәр. Үзең бит, ике сүздән ризалык бирәсе урынга, суздың...

Кәримҗан. Сиңа ике сүз җитәме? Кирәкме ул сүзләр сиңа?

Әбүзәр. Рәнҗерсең дип уема да килеп карамады. Бөтен яшьләр шулай өйләнә хәзер. Шәһәрдә дә, авылда да.

Кәримҗан. Теләгәнчә рәнҗергә дә ара калдырмагансың. Иртәгә! Иртәгә җомга! Иртәгә загс!

Әбүзәр. Яучылар йөртеп өйләнү заманы узды. Моны үзең дә беләсең.

Кәримҗан. Тормышымны ялган белән башлап җибәрергә булдым, диген. Ярый... Син башка якларны да кыеклатып турыдан җибәргәнсеңдер әле мөгаен?.. Синең кемең... кәләшең... безнең икәүдән-икәү генә яшәгәнне беләме?

Әбүзәр. Белмичә...

Кәримҗан. Нигә икәү генә калганны да беләме?

Әбүзәр. Анысы...

Кәримҗан. Сораштымы, ичмасам?

Әбүзәр. Мин аңа дөресен әйтмәдем.

Кәримҗан. Тагын ялган?! Арык атка атлангансың, улым.

Әбүзәр. Әни үлде, дидем. (*Ярсып.*) Дөреслек кемгә кирәк? Аңамы, миңамы? Беребезгә дә хаҗәт түгел.

Кәримҗан. Арык атта ерак китеп булмый.

Әбүзәр. Сиңа да кирәкми. Алдашма.

Кәримҗан. Дөреслек миңа күңел өчен, сиңа гомер өчен кирәк. Кирәге чыга аның! Хатынны бер көнгә алмыйлар. Туйлар уза, туннар туза. Тормышта әллә нинди чаклар була.

Әбүзәр. Мине куркытырга булдың инде?

Кәримҗан. Әзер тор, дип әйтүем генә...

Әбүзәр. Дөресен ничек сөйлим ди мин аңа? Ничек аңлатыйм? Сине хурларга телем бармый... Әнине яманлап ни файда?

Кәримҗан. Яманлап сөйләмә, дөресен генә әйт. Бәяне үзе куяр. Әнием үлмәгән, диген. Әтине, мине ташлап икенче берәүгә кияүгә киткән, диген... Уналты ел инде хат та язганы юк, диген... Хатын булган кешең моны белми калачак түгел. Син иң теләмәгән чакта беләчәк ул аны.

Әбүзәр. Онытылып беткән хәлләрне нигә кузгатырга? Юк минем әнием. Минем әтием генә бар. Син бар. Безгә шул җиткән.

Кәримҗан. Бая «улың» дидең... Гади улым гына

булсаң, мин сиңа шул язда ук дөбердәтеп яңа әни алып кайта идем. Минем ни өчен өйләнмәвемне беләсеңме?

Әбүзәр. Бу турыда сүз булганын хәтерләмим.

Кәримҗан. Башта бәләкәй идең... Каһәр төшкән җомга көн!.. Мин синең ныгып өлгермәгән йөрәгеңне жәлләдем... Әниең киткәч тә кызамык белән авырдың да кырык өч көн яттың. Авыр кичердең, тырнакларың төште. Шунда врач: «Бу баланың нервлары тәртиптә түгел, ни булды?» — дип сорады. Әниең китүен авыр кичерүеңне шунда аңладым. Мин аңладым, син аңладыңмы?.. Синең белән минем арага чит кеше килеп кермәсен дип өйләнмәдем бит мин. Әйе, мин синең сабый җаныңны, яшьли авыр удар алган сабый җаныңны тагын бераүгә — хатын-кызга бирергә курыктым. Син миңа бала гына түгел идең! Өметем идең син, йөрәк серем, кара кайгым, якты кояшым! Бәхетем, нәләтем, җаным, тәнем, ак куяным, тәмле исем, тәбәнәгем идең син! Хәзер менә кемдер, мин күрмәгән, мин белмәгән кыз килеп чыга да, рөхсәтсез-нисез сине алып китә. Син аңа муеныңны биреп өлгергәнсең, ул сиңа атланган да билеңне сындырган.

Әбүзәр. Әти, гомер буе сиңа табынып кына тормаслыгымны белми идеңмени? Миңа үз оямны корырга вакыт.

Кәримҗан. Белә идем. Уйлый идем. Көтә идем. Тик болай итеп түгел. Болай ямьсез итеп, мондый рәвешле түгел.

Әбүзәр. Кызык кеше син, әти.

Кәримҗан. Кызык малай син, улым.

Әбүзәр. Нишләргә соң миңа хәзер?

Кәримҗан. Юлга син чыгасы. Тикшер: тезгенең ныкмы, ук-җәяң әзерме?

Әбүзәр. Киңәшеңне бир: ни кылыйм?

Кәримҗан. Юлың билгесез. Юлдашларың ят. Киңәшемә мохтаҗ түгелсең, кыланма.

Әбүзәр. Тәзкирәне табып килимме? (*Пауза.*)

Кәримҗан. Кызның үзен күргәнче, мин аның әнисен, туганнарын күрер идем. Синең белән аңлаша алмаганны, Тәзкирәң белән ни сөйләшим мин?

Әбүзәр. Бусы мөмкин түгел.

Кәримҗан. Туганнары Африкадамы?

Әбүзәр. Мин аңа... Тәзкирәгә вәгъдә бирдем.

Кәримҗан. Вәгъдә? Ир башын харап иткән өч нәрсә бар: аракы, кара эчле хатын-кыз һәм ашык-пошык уйламыйча бирелгән вәгъдә. Вәгъдә дә биреп өлгергән! Муенына элмәк, аягына тышау салган.

Ә б ү з ә р. Язылышканга кадәр туганнардан беркем берни белмәс дидем.

К ә р и м җ а н. Шушы урында безнең сүз тәмам. Нокта.

Ә б ү з ә р. Әти, малайсытма мине. Үзең дә малайларча кыланма.

К ә р и м җ а н. Хуш. Олы кеше булып карыйк. Ирләр булыйк. Ул чагында нәкъ ике елга кире кайтасың.

Ә б ү з ә р. Мин тылсымчы түгел лә.

К ә р и м җ а н. Бүген эштән икәү кайтып керәсез. Син миңа: «Әти, бер кыз белән таныштым, менә ул кыз, Тәзкирә»,— дип, каршыма аны китереп бастырасың.

Ә б ү з ә р. Һәм ике елдан өйләнергә рөхсәт сорап киләбезме?

К ә р и м җ а н. Икеме, өч ук булырмы, бәлкем, дүрткә дә тартылыр? Алда күз күрер. Мәгәр мин соңгы сүземне әйттем. Заман да заман дисең. Шагыйрь бу хакта менә болай дигән: «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга!» Менә шулай.

Чыга. Пауза. Бераздан телефон шалтырый. Әбүзәр ала.

Ә б ү з ә р. Әйе. Бу мин, Тәзкирә. Тавышым? (*Йөткерә.*) Тавышым шул ук. Эшкә?.. Эш кайгысымы хәзер миндә. Юк, юк, бер минут торма, безгә кер. Йөгер! Тиз бул!.. Бар да бетте... Сүтелде, таралды, җимерелде, ватылды, ишелде, сынды, чәлпәрәмә килде... Җыешырга син кирәк! Ашык! (*Куя. Номер җыя.*) Заводмы? Иван Семенович? Мин идем әле, Әбүзәр. Нәрсә?.. Нигә шалтыраткан идем соң? Хәзер хәтерлим... Бик кирәкле, ашыгыч хәбәр әйтермен дигән идем. Ә-ә, Иван Семенович, өйләнәм! Котлаулар соңыннан, соңыннан. Сөйләшкәнчә, шуның ялын, ягъни өч көнлек каникулны бүгеннән дип исәпләгез. Туйга? Нинди туйга? Ә үзебезнең туйгамы? Калдырмабыз. Рәхмәт. Хушыгыз.

Ишектә звонок. Әбүзәр чыга, ача, Т ә з к и р ә белән керә.

Т ә з к и р ә. Ни булды? Сүзеңне шаяру дип аңласам да, тавышың шиккә төшерде. Шулай яман шаяралар димени, Әбүзәр?

Ә б ү з ә р. Утыр, Тәзкирә.

Т ә з к и р ә. Абау, кырынмаган да.

Ә б ү з ә р. Кырынмаган? Бик ямьсезме, чиркангычмы?

Т ә з к и р ә. Куркытма мине, Әбүзәр.

Ә б ү з ә р. Куркытасы килмәгәнгә ничегрәк сүз башларга дип баш ватам... Фикер чуалса кармак җебе генә түгел икән. Уф...

Т ә з к и р ә. Хәзер болай итәбез... (*Аның чәчләрен сыйпый.*) Мине тыңла син. Мине генә тыңласаң бер чакта да югалмассың. Эшеңә соңга калмыйсыңмы? Азрак соңарсаң да ярар. Болай да артык тәртипле яшисең. Чыгабыз да җөйче хатын янына керәбез. Нинди күлмәк тектерүемне күрсәң син, исең-акылың китәр. Түшен менә болай иттереп сәйләннәр белән бизибез... Якасы...

Ә б ү з ә р (*таркау*). Җөйче? Өлгертә алмам дип куркыткан идеме?

Т ә з к и р ә. Өлгертә! Мин тотынсам, өлгертмәгән кая! Әй, син мине тыңламыйсың. Ир кеше хатын-кызның һәр сүзенә колак салырга тиеш.

Ә б ү з ә р. Тәзкирә, әйтче, иркәм, син заман турында ни уйлыйсың?

Т ә з к и р ә. Заман? Һм-м... Бик әйбәт уйлыйм. Рәхәт яшибез!

Ә б ү з ә р. Аны «заманасы ул түгел» дигән сүз кимсетте. Шушы сүзгә рәнҗеде ул. Шулай дигәнгә ачуы чыкты.

Т ә з к и р ә. Кем? Нәрсә? Кайда? Ни сөйлисең син? Рәхәт яшибезме? Шәп яшибез. Димәк, заманча! Модадан калышмаска кирәк, модадан. Аны акыллы кешеләр, заманны яхшы белүчеләр уйлап чыгара.

Ә б ү з ә р. Син миңа үпкәләмә... Хәер, азрак үпкәләсәң дә ярый. Тик кичерә күр. Шатлыктанмы, күрәчәккәме, авыз ерылып китте минем. Ерык авыздан кирәксез сүзләр коела торган була... Мин моны белә идем... Тик бүген, бүген...

Т ә з к и р ә. Әтиеңме?

Ә б ү з ә р. Минем зирәк Тәзкирәм! Чибәрем! Тагын кем булсын? Әйе, әти. Мин аңа өйләнәм дип ычкындырдым.

Т ә з к и р ә. Ялгышкансың. Бик нык. Кайчан?

Ә б ү з ә р. Бүген генә. Сизми дә калдым.

Т ә з к и р ә. Минем әни дә сизенә. Бүген төне буе йокламый чыкты. Шыпырт кына керә дә текәлеп карап тора. Бер сүз дә дәшми. Төнлә уянып киттем, баш очыма басып нидер тыңлана!..

Ә б ү з ә р. Картның күтәрелеп бәрелә торган гадәте бар! Ләкин йомшак ул... Балавыздай эри дә төшә... Моңарчы бер чакта да миңа каршы төшкәне булмады. Юк. Хәтерләмим.

Т ә з к и р ә. Иркә малай инде син анысы.

Ә б ү з ә р. Иркәлек тә бардыр...

Т ә з к и р ә. Кызсалар-кызмасалар ни кыра алалар? Заманалары узган.

Әбүзәр. Тукта, тукта. Узган дисеңме?

Тәзкирә. Әйе. Әйттем шул. Җырлары җырланган. Язлары үткән, җәйләре үткән, ичмасам, көзләре дә түгел хәзер, салкын кышлары җиткән. Ә кышын гөлләр чәчәк атмый, кар да боз анда. Кар! У-у итеп бураннар гына улый... Кар астында калган аларның гомерләре! Әбүзәр. Син шулай уйлыйсыңмы?

Тәзкирә. Син дә шулай уйла! Мин ничек уйласам, син дә шулай уйларга тиеш. Безне пар килгән диләр.

Әбүзәр. Моңарчы бер ботакта сайраштык. Тик шуны онытмыйк, бер төптән чыкмаган ботаклар да уралышалар...

Тәзкирә. Мин сине, син мине табыштык. Мәңгегә! Шулай булмасмыни?

Әбүзәр. Әти әйтә...

Тәзкирә. Соңыннан, соңыннан...

Озак итеп үбешәләр.

Әбүзәр. Әти әйтә, кәләшеңне күрсәт, ди.

Тәзкирә. Иртәгә хәтле түзәр. Балык чиртмәгәндә дә көннәр буе утырабыз дисең бит! Иртәгә мин ап-ак туй күлмәгеннән килеп керәм... Түшемдә сәйләннәр җемелди. Загстан туп-туры монда кайтабыз дип аңлаттыңмы? Бу бүлмә синеке, алайса?.. Ягъни безнеке. Кызык та, хатирәле дә булачак безнең өйләнешү.

Әбүзәр. Сине генә түгел, әниеңне, туганнарыңны да күрәсе килә этинең. Кардәш-ыруларың белән очрашып сөйләшәсе килә.

Тәзкирә (*аның кочагыннан ычкынып*). Бабайларны казып чыгарыр идем, берсенең дә каберен белмим. Һи... Аның күрәсе килсә, минем күрсәтәсем килми. Менә әнинең күзе шакмак булачак!.. Загстан кайтышлый, бәлки, аны да кереп алырбыз?

Әбүзәр. Әти, бүген ди, хәзер ди.

Пауза.

Тәзкирә. Бала чакта әниең сиңа әкиятләр сөйләми идемени соң?

Әбүзәр. Әнием юк минем! Әтием генә бар.

Тәзкирә. Кичер.

Әбүзәр. Әнием юк шул...

Тәзкирә. Патшаның өч улы була... Өчесе өч якка

карап ук аталар болар. Төпчек малайның угы сазлыкка, бака күле ярына барып төшә. Атасының фәрманы нык: баканы кәләш итеп алып кайта төпчек егет. Ә бака дигәнең сихерләнгән сылу кыз була. Егет моны белгәч түзми, сихернең көче бер тәүлеккә калгач чыдары бетә!.. Баканың кабыгын яндыра да күпме җәбер-җәфаларга, мәшәкатьләргә дучар була!.. Син дә бер генә көнгә ут яныннан читтәрәк йөргән булсаңчы!..

Әбүзәр. Әтинең көнгә дә түзәр әмәле юк, әтинең.

Тәзкирә. Син аңа әйбәтләп аңлатырлар. Хәзер заманы башка, гореф-гадәтләр башка.

Әбүзәр. Ачуымны арттырып шул сүзне әйтмәсәнә!

Тәзкирә. Әгәр бик үҗәтләнә икән, тот та бүген аңа бөтенләй күренмә.

Әбүзәр. Качарга кушасыңмы?

Тәзкирә. Безнең студент егетләр янына кер дә шунда кунарсың. Урын табылыр.

Әбүзәр. Иртәгә ни йөз белән кайтып керербез? Күзенә ничек күренербез?

Тәзкирә. Бөтен хикмәте дә шунда аның. Мин озын ап-ак күлмәк кигәнмен... Кочагымда ап-ак хризантемалар! Култыгымда син...

Әбүзәр. Куркудан мин дә ап-акмы?

Тәзкирә. Син чем-кара костюм кигән. Күлмәгең генә ап-ак. Костюмың кап-кара.

Әбүзәр. «Нишләп йөрисез монда, йөзекаралар!» дип, әти бер кычкырса?

Тәзкирә. Әтиләр кычкыра торган заман узган дидемме мин сиңа?

Әбүзәр. Ә әти? Ул ничек чыдар? Бүген төнне ничек уздырыр?

Тәзкирә (*чыркылдап көлә*). Чибәр кыз алып кайткан улын гафу итмәгән әтине синең кайда күргәнең бар?

Әбүзәр. Аның сүзенә чак кына колак салсак зарар булырмы? Болай да бик кечкенә ич аның теләге... Нәни генә!

Тәзкирә (*уттай кабынып*). Айлар буе корылган планнар юкка чыгамы? Бөтен нечкәлекләрне исәпкә алдык... Киемнәр, машиналар, иптәшләр, балдаклар, күлмәкләр, туфлиләр, муенсалар... Төймәләренә кадәр уйлап сайланган. Ә хәзер?! Бер кешенең кирелеге аркасында барысы чуалсынмы?

Әбүзәр. Ул сине ошатыр.

Тәзкирә. Кунаклар, дуслар, курсташлар ни әйтер?

Группадан беренче кыз — мин кияүгә чыгам. Калганнар күз текәп безнең хәтәр туйны көтә. Шунда да картлар капризын җиңә алмагансыз дип, фикердәшләр көлсенме бездән? Әти, әти, имеш... Монда синең белән минем язмыш хәл ителә. Әнием бар дип әллә ниләр уйлап чыгармыйм бит әле! Ә хатын-кызның җаны нечкәрәк җепләрдән тукылган.

Әбүзәр. Монда син белмәгән четерекле бер нәрсә бар.

Тәзкирә. Ишетергә дә теләмим.

Әбүзәр. Минем моны берәүгә дә әйткәнем юк. Моңарчы сиңа әйтергә дә батырлыгым җитмәде. Безнең әни... безнең әни...

Тәзкирә. Инде әллә кайчан үлгән әниеңнең дә безнең кавышуга берәр васыяте, боерыгы бармы?!

Әбүзәр. Әнием үлмәгән.

Тәзкирә. Шул котырттымы сине? Шулмы?

Әбүзәр. Тыңлап бетер! Ул әтине, мине ташлап башка берәүгә кияүгә чыккан.

Тәзкирә. Чыкса ни?

Әбүзәр. Син моны шулай тыныч кына тыңлый аласыңмы?

Тәзкирә. Мин сине ташларга җыенмыйм. Курыкма. Ташламам да. «Ташлар ярым түгелсең» дип җырлыйлармы? Девизым шул.

Әбүзәр. Әти тәрбиясендә үстем мин. Дүртенче класска кадәр ул мине мәктәпкә озатты, каршы барып алды. Мин булганга яңадан өйләнмәде, үз тормышын көйләмәде.

Тәзкирә. Нигә син боларны хәзер генә исеңә төшердең? Нигә? (*Йөренә, чәчен тузгытып җибәрә.*) Әни янына барырга дисең инде? Туганнар белән якыннан танышырга?.. Бусы булмый да булмый инде аның, Әбүзәр! Әйдәче, тагын бер көн, бер төн үзебезчә яшәп калыйк. Иртәгә туганнарны очраштырырбыз. Аларга барыбер түгелмени?

Әбүзәр. Тәзкирә, менә хәзер әти кайтып керде, ди...

Тәзкирә. Нигә моңарчы бу турыда уйламадың?

Әбүзәр. Тора-тора үзем дә шуңа аптырыйм. Беләсеңме, соңгы ике елда син миңа ай-кояшны томаладың. Матурлыгың мине исертте. Татлы сүзләрең тилертте. Назга мохтаҗ идем мин... Хатын-кыз назына... Бүген әтинең күзләренә карадым... Аңлыйсыңмы, бүген күрдем мин аны! Бүгенгесен түгел, элекке әтине! Яшьрәк чагын!.. Апрель азаклары... Иделдә боз ага. Мин аны боз акканын карарга чакырам. Ә ул... Ишек кашагасына

кулы белән ябышкан да минем чәчне сыйпый-сыйпый көлә. Боз акканын карарга икенче көнне генә төштек. Көлә әти, көлә дә көлә! Мин җүләр, аңа ияреп чыркылдыйм... Җылаган бит ул шул чагында. Көлмәгән, җылаган!

Т ә з к и р ә (*Әбүзәр бүлмәсенең ишеген ачып куя*). Тәрәзәңне ачып, бүлмәңне җилләтеп алырга кирәк булыр... Бу картинаны моннан алып икенче якка эләрбез...

Ә б ү з ә р. Риза мин, Тәзкирә, риза! Җөйчегә керергә дә риза. Синең белән, синең хакка әллә кайларга, җир читенә чабарга риза. Чәчем белән җир себерергә, юлыңа гөлләр булып сибелергә, йомшак түшәк булып ятырга риза. Әти хакына нәни генә... бер генә тапкыр! Очрашып сөйләшик тә, аннан өчәүләшеп сезгә барырбыз.

Т ә з к и р ә. Юк, дим, юк!

Ә б ү з ә р. Анысына ризалыгың юк икән, синең әниеңне мин күрергә телим. Мин!

Т ә з к и р ә. Кайчан?

Ә б ү з ә р. Бүген үк. Хәзер үк.

Т ә з к и р ә. Юк дим! Ишетәсеңме, мөмкин түгел. Ярамый, ярамый! (*Аяк тибеп.*) Рөхсәт итмим.

Ә б ү з ә р. Әти белән сөйләшкәннән соң, сине тәрбия иткән кешене — әниеңне күрәсем килде.

Т ә з к и р ә. Малай! Әтисенең чалбар балагына ябышкан вак кырмавык!.. Әрәм иттең, барын чүпкә чыгардың!

Ә б ү з ә р. Тәзкирә!

Кыз ярсып чыгып китә. Пәрдә төшә.

Бер бүлмәле квартира. Ә н и с ә ялгызы. «Бу ишегалдын Әнисә Мазанова себерә» дигән язулы калай тотып, өйгә Т ә з к и р ә кайтып керә.

Ә н и с ә. Иртәләгәнсең, кызым. Авырыйсыңмы әллә? Йокың да начар йокладың.

Т ә з к и р ә. Лекцияләр иртә бетте. Укытучыбызны симпозиумга чакырганнар. Польшага!.. Йөри кешеләр...

Ә н и с ә. Керәсе җирләрем дә бар дигән идең...

Т ә з к и р ә. Шулай дидеммени? Кая керәсемне әйттемме икән? Анысын әйтмәгән идемме?

Ә н и с ә. Анысын әйтмәдең. Гадәттәгечә.

Т ә з к и р ә. Ә син сорамадыңмы?

Ә н и с ә. Сорамадым шикелле. Тамагың ачтыр синең. Аш китеримме?

Т ә з к и р ә. Нигә сорамадың? Нигә төпченмәдең, әни?

Ә н и с ә. Нигәме?

Т ә з к и р ә. Мин синең балаң түгелмени? Бердәнбер кызың түгелмени?

Ә н и с ә. Син минем балам. Кызым... Тик син инде минем җиткән кызым. Адым саен: «Кая барасың? Нигә?» — дип, йолкып торырга мин дә тинтәк ана түгел. Кызым акыллы. Мин аңа ышанам.

Т ә з к и р ә. Ансат ул — ышанам! Нигә ышанасың син миңа? Мине беләсеңмени син?

Ә н и с ә. Ышанырлык дәрәҗәдә генә булса да беләм.

Т ә з к и р ә. Әни!

Ә н и с ә. Нәрсә, бәбкәм.

Т ә з к и р ә. Болай гына.

Калайны читкәрәк атып бәрә.

Ә н и с ә. Нинди ямьсез тавыш чыгарасың, сискәнеп киттем. Кем кубарып алган бу калайны? Урамнан табып алып кердеңме? Әле ярый үзең күргәнсең.

Т ә з к и р ә. Аны мин кубарып алдым. Мин. Күземә күрсәтмә, ераккарак яшер.

Ә н и с ә. Тукта, тукта... Нигә яшерергә кушасың? Тәртибе шулай, урынында торсын. Бар, кадаклап куй. Йә үзем кадаклыйм. Бир.

Т ә з к и р ә. Күрше йорт стенасында кара мәрмәр такта тора. Монда профессор Фәлән Фәләнев яшәде диелгән. Безнең йортта исә күгәргән калай. «Бу урамны дворник Әнисә Мазанова себерә» дигән. Аермасы бармы-юкмы?.. Исән чакта ук мемориаль такта урам себерүчеләргә генә куела. Почет!

Ә н и с ә. Нәрсәсе начар? Йомышы бар кеше туп-туры үзебезгә керә. Барыбызга да уңайлы.

Т ә з к и р ә. Нәрсәсе яхшы? Болай да бөтен урам синең урам себерүче икәнеңне белә. Инде бөтен шәһәр белсен дисеңме? Урам себерүче Мазанова!

Пауза.

Ә н и с ә. И-и бәбкәм, бәбчегем... Килче, яныма утыр. Утыр, утыр. Карам йокмас. Менә шулай... Синең сабый чактагы чирең, өянәгең үтеп бетмәгән икән! Студент булгач, ул яман уйлардан әллә котылдыңмы дисәм, юк икән... Җиткән кыз дип йөрсәм...

Т ә з к и р ә. Мине беләм дип әйтмә. Ата-аналар бер чакта да балаларын белмәгәннәр, аңламаганнар. Хәзер бигрәк тә! Заман шулкадәр тиз алмашына.

Ә н и с ә. Беләм. Аңлыйм да. Ошамаган якларыңны төзәтә генә алмыйм. Анысы хак.

Т ә з к и р ә. Белмисең. Белмисең!

Ә н и с ә. Әйтсәң сүз, төртсәң күз чыга дигәндәй, әллә нигә сискәнеп киттем. Беләм, кызым. Мәктәптә укыганда ук, беренче класстан син минем урам себерүемнән гарьләнә идең. Кинога барырга, морожный алырга акча кирәк булганда, себерке тоткан әниең янына чыгарга хурлана идең. Акча бик кирәк булса, мендәргә капланып җылап ята идең, инде чыдарың калмагач, форточкадан кычкыра идең. Кыз булып үсеп җиткәч, без бервакытта да урамнан янәшә узмадык... Болар барысы да балалык җүләрлеге дип йөрсәм, берзаман институт сайлар чагың җитте. Син бит институтның ошаганын түгел, безнең урамнан, сине белгән-күргәннәрдән берәү дә бармаганын сайладың.

Т ә з к и р ә. Әни!

Ә н и с ә. Кеше барында әни дип тә эндәшкәнең юк синең.

Т ә з к и р ә. Үткәннәрдә казынып өчен кузгаттыммы мин бу сүзне?

Ә н и с ә. Үткәнеме, хәзергесеме, барысы да үземнеке. Минем гомер! Эшемнең нәрсәсен яратмыйсыңдыр. Ятим калгач, шушы эш аркасында без фатирлы булдык. Өс-башың бөтен йөрмәдеме? Тамагың ачмы? Кеше арасында йөзебез ак түгелме? Һәммәсе түбәнчелек белән сәлам биреп уза. Рәсемем Мактау тактасында иде, кайсы явызыдыр ертып алып киткән.

Т ә з к и р ә. Мин кубарып алдым аны.

Ә н и с ә. Синдер дип тә уйладым...

Т ә з к и р ә. Төнге алтынчылар, кранчылар, шапшак слесарьлар белән янәшәдә синең рәсемең эленеп торсынмы?!

Ә н и с ә. Кызым җитте, дип юанып йөргән булам тагын... Кияүгә чыгар вакытлары җитте дип борчылып ятам...

Т ә з к и р ә. Чыгармын да, олагырмын да! Әллә гомер буе шушында калыр дип беләсенме? Шушы урамда? Гомер буе кимсенгән шушы стеналар арасында? Кияүгә китсәм дә, шәһәрнең нәкъ икенче читенә чыгып югалачакмын. Шушы якка кайтмам да!

Ә н и с ә. Иптәшләрне, сердәшләрне читтәнрәк сайлаган шикелле, кияүне дә шулай эзлисеңме? Теләсә кем булсын, бары тик моннан ераккарак кына алып китсенме? Тиле кыз, җаныңның бер күзәнәге генә булса да минеке түгелмени синең?

Т ә з к и р ә. Әнием, матурым, берни дә аңламыйсың шул син!

Ә н и с ә. Яхшы. Мин аңламыйм, ди. Син аңлыйсың. Мин шунысына куанам. Сине аңлы итеп үстерә алганмын. Аналарга әллә ни күп кирәкми. Менә үз көнеңне күрә башлагач...

Т ә з к и р ә. Мин кияүгә чыгам, әни.

Ә н и с ә. Чык.

Т ә з к и р ә. Кияүгә дим, ишетәсеңме, тормышка чыгам!

Ә н и с ә. Беләм. Белеп йөрим, сизенеп. Кемендер барын күреп торам.

Т ә з к и р ә. Белсәң дәшми түзәр идең микән?

Ә н и с ә. Сизендем.

Т ә з к и р ә. Нигә кызыксынмадың, алайса? Бер тапкыр булса да нигә сорашмадың?

Ә н и с ә. Сорап ни хәер? Сөйләшәсеңмени син? Тырт та пырт. «Монысын белмә... тегесен сорашма... Барыбер аңламыйсың...» Бар сүзең шул ич миңа.

Т ә з к и р ә. Ә син сорашып кара идең.

Ә н и с ә. Кем ул?

Т ә з к и р ә. Бер егет.

Ә н и с ә. Ай-һай, күп сөйләдең.

Пауза.

Т ә з к и р ә. Сине чыннан да минем язмышым, киләчәгем кызыксындырмыймы? Сорашмыйча ничек түзәсең?

Ә н и с ә. Соңгарак калдым. Син морожный, шоколад даулап тәрәзәдән кычкырып ятканда, яныңа керергә кирәк булган. Себеркедән сыек чыбык йолкып алып, арканны каезларга кирәк булган. Себерке синең тамагыңны туйдырды, өстеңне бөтәйтте, мин аның башка хасиятен юккарак онытып җибәргәнмен. Йә бөтенләй кермәскә иде. Ят идең ялгыз бүре күк улап. Юк шул, шыңшый башлавыңа, бөтен эшемне ташлап атылып керә идем дә өф-өф итеп арканнан кага идем. Кулың каралмасын, тырнагың ярылмасын дип, кулыңа идән мунчаласы тоттырмадым. Укысын, зиһене бүленмәсен дип, кухняга аяк бастырмадым. Күңеле китек булмасын дип, бәйрәм саен яңа күлмәк тектердем. Тәрбиямнең җимешен бик тиз күрдем, соңгарак кына калдым! Институтка имтихан бирергә киткәч, капка төбендә көтеп калдым... Имтиханнан чыккач, син минем янга килми идең, кая ул! Кайта идек урамның ике ягыннан икебез! Иптәшләрең күрмәсен, янәсе, белмәсен! Яныңа барырга да уңлы-суллы яңакларга иде сине шул чагында... Кем сине йөрәге

җитеп кияүгә ала? Нинди акылсыз егет ул? Ничек гомер итәр ул синең белән?! Ничек яшәр! Бәхетсез бала икән!..

Т ә з к и р ә. Без иртәгә язылышабыз... Тик аның этисе... язылышканчы сине, туганнарны күрергә тели.

Ә н и с ә. Ах, менә ни сәбәпле сүз башлагансың икән.

Т ә з к и р ә. Кызың турында бигрәк әшәке уйлыйсың инде, әни.

Ә н и с ә. Кызы әнисе турында әйбәтрәк уйлыймы?!

Т ә з к и р ә. Әбүзәрнең әтисе сине күрергә тели. Әтисе дә, Әбүзәр дә сине балалар бакчасында мөдир дип беләләр.

Ә н и с ә. Әтисе белән күрештегезме соң?

Т ә з к и р ә. Әлегә юк.

Ә н и с ә. Алайса, бу калайны ник кубардың? Бәлки, аның әтисе дә безнең эше кара сөяктер?

Т ә з к и р ә. О-о, аның әтисе иң атаклы ресторанда повар, орденлы!

Ә н и с ә. Бар, кадакла калайны.

Т ә з к и р ә. Бөкләп чүплеккә ыргытам мин аны.

Ә н и с ә. Мин мөдир түгел. Мин гап-гади урам себерүче. Һәм мин үз эшемне яратам да, мактанам да. Шулай булып калырмын да.

Т ә з к и р ә. Мин нишлим соң? Кая барыйм? Әбүзәр белән талаштык... Инде әнием дә мине аңламагач, кемгә сыеныйм?

Ә н и с ә. Сине дә, Әбүзәреңне дә, аның орденлы әтисен дә күрәсем килми. Менә шул.

**Пәрдә. Кәримҗаннар квартирасы. Ә б ү з ә р ялгызы. Чыгарга киенгән килеш, телефоннан сөйләшә.**

Ә б ү з ә р. Тәзкирә сезгә кагылмадымы дип шалтыратуым... Әйе, Тәзкирә... Юк? Анда шалтыраттым инде. Гайсиннарга да. Ике минут саен шалтыратып торам. Институтта юк. Аннан үзләре шалтыратып сорады. Иптәш кызы... Күзегезгә чалынса бер минут тормый миңа хәбәр итегез. Өйдә. Телефонны онытмадыгызмы? Яхшы. (*Трубканы куя, тагын номер җыя.*) Ателье? Нәриманова бүген кайсы сменада? Кичен? Гафу итегез. (*Куя. Телефон шалтырый.*) Тәзкирә, синме? (*Түшенке тавыш белән сөйләшә. Ул сөйләшкәндә, Тәзкирә кереп тыңлап тора.*) Мин. Әйе. Рәхмәт, рәхмәт. Өйдәрәк шул... Туйга? Рәхим итегез. Көнен? Көне, сәгате тәгаенләнгәч, тагын бер хәбәрләшербез әле. (*Трубканы куя.*)

Т ә з к и р ә. Кем булды ул?

Ә б ү з ә р. Тәзкирәм!

Т ә з к и р ә. Кем булды ул, дим мин.

Ә б ү з ә р. Бөтен шәһәрне бетереп сине эзлим. Шалтыратмаган кешем калмады. Ә ул... спорт сараеннан боксер иптәшләр. Туйдан калдырсаң, нокаутны көт тә тор диләр. Эзләп чыгып китәсем килә, син кайтып керерсең кебек.

Т ә з к и р ә. Туйга... (*Елап җибәрә.*)

Ә б ү з ә р (*көлә*). Җыла, җыла. Шатлыктан җыласаң да була. Күңеллерәк булсын өчен, мин дә утырып җылыйммы?

Т ә з к и р ә (*яшь аралаш*). Нинди шатлык?

Ә б ү з ә р. Шатлык! Сөенеч! Бәхет!

Т ә з к и р ә. Нинди бәхет?

Ә б ү з ә р. Син табылдың бит, син!

Т ә з к и р ә. Мин югалмадым да.

Ә б ү з ә р. Ниләр генә уйлап бетермәде бу тиле баш. Сыналу булды бусы, Тәзкирәм, тормышның безне нәни генә сынавы булды. Яратам икән мин сине, сөям икән... Чамасыз, шашып яратам икән. Ышанмыйсыңмы? Шаһитларым бөтен шәһәр! Менә бу — битләре ертылып беткән телефон кенәгәсе! Аның битләрен актарганда, менә бу бармаклар юкка гына калтыранган дисеңме? Кая чыгып йөгердең соң син? Юк, юк, сорамыйм, сөйләмә. Хәзер берни сөйләмәсәң дә риза! Риза, кадерлем. Ә этинең кирелеген җиңәм мин аның. Ул да канәгать булыр. Җаен табармын. Әтием үземнеке бит!

Т ә з к и р ә. Ничек? Безнең планнар нәкъ элеккечә каламы?

Ә б ү з ә р. Әлбәттә! Син югында тиле башыма йомгак-йомгак уйлар килде. Нигә әле без гел юк өчен борчылып ятабыз? Бүген хәер-фатиха бирмәсәләр, иртәгә ризалашырлар. Пустая формальность! Дөнья безнеке! Яшәү безнеке! Киләчәккә без хуҗа.

Т ә з к и р ә. Тамагым яна.

Ә б ү з ә р. Чәй куйыйммы?

Т ә з к и р ә. Чәй озак.

Ә б ү з ә р. Мә, «Шифалы су» йот.

Т ә з к и р ә (*эчә*). Салкын. Әйбәт. Үзең эчмисеңме?

Ә б ү з ә р. Син минем шифалы суым, син! (*Телефонга тотына.*)

Т ә з к и р ә. Нишлисең?

Ә б ү з ә р. Иптәшләргә шалтыратам. Алар бит, бөтен шәһәрне кыдырып, сине эзлиләр. Туйга илле биш кеше чакырган идек, хәзер йөзгә җиткерәм! Килсеннәр, күрсеннәр... Тәзкирәм!.. Нигә туй турында хәбәрләр га-

зетада басылмый икән? Телевизорда ник күрсәтмиләр? Өйләнү — кеше тормышында иң әһәмиятле вакыйга бит. Киләчәккә якты сукмак салу, бәхет диңгезенә чуму, койрыклы йолдызны учыңа утырту... Мин бик, бик бәхетле.

Тәзкирә. Ә этиең?

Әбүзәр. Улының бәхетенә каршы төшкән этиләр юк дип әйттеңме? Акыллым минем, пигамбәрем, зирәгем! Кая шалтыратыйммы! Әллә балконга гына чыгып кычкырыйммы?

Тәзкирә. Бая чыгып киткәч кая таба йөгерүемне аңладыңмы?

Әбүзәр. Анысы кирәкми хәзер. Син борылып кайттың. Син минем янда. Син минеке. Без бергә!

Тәзкирә (*аны читкә кагып*). Әни янына кайтып килдем мин.

Әбүзәр. Син дә әйбәт, Әнисә апа да! Дөнья матур, дөнья киң!

Тәзкирә. Синең белән бәхәсләшкәндә әтәчләнсәм дә, күңел түрендә нидер сызлый башлады. Туктамый гына бит, сызлый да сызлый. Чыгып йөгердем, кая барып сугылырга белмим генә! Трамвайга утыргач кына аз-маз һушыма килдем: үзебезнең якка кайтып барам, имеш.

Әбүзәр (*кызыксынып*). Йә, йә.

Тәзкирә. Трамвай чаба, мин ашыгам. Артымнан син куа киләсең кебек.

Әбүзәр. Син чыгып киткәч тә, бер мәлгә каушап калдым. Гомергә гафу итәсем юк шул мизгелдә җебеп төшүемне. Гаеплемен! Гаеп миндә бит. Әгәр мин кузгатмаган булсам...

Тәзкирә. Бүлдермә. Сөйләп бетергәнне көт.

Әбүзәр. Мин барын да аңладым! Без бергә!

Тәзкирә. Әбүзәр, син мине алдагансың.

Әбүзәр. Мин? Синеме, бәгырем?

Тәзкирә. Үз өстеңә зур гөнаһ алгансың: әнием үлде дип ялганлагансың.

Әбүзәр. Алдау түгел иде бу. Әтине кызгандым... Ахыр чиктә, бу аның сере. Аң бул, ычкындырып ташлама. Ташлап киткән... Сәбәбен беркем белми.

Тәзкирә. Ә минем дә нәни генә, бармак башы хәтле генә ялганым ачылса?

Әбүзәр. Безнең мәхәббәт һәр яктан төгәл, җаным. Кирәкми.

Тәзкирә. Минем әнием балалар бакчасы мөдире түгел. Түгел!

Ә б ү з ә р. Нәрсә, нәрсә?

Т ә з к и р ә. Әнием дим, әниемне әйтәм.

Ә б ү з ә р. Врач? Очучы? Профессор? Галим?

Т ә з к и р ә (*шартларга җитешеп*). Менә бит кемнәрне саныйсың!

Ә б ү з ә р. Мин гади кеше баласы. Минем белән тигезләшергә теләдеңме? Шуңа яшердеңме?

Т ә з к и р ә (*шашып кычкырып*). Түгел. Түгел шул! Гап-гади урам себерүче! Дворник!..

Ә б ү з ә р. Нигә кычкырасың? Нигә кызарындың? Әниең ич ул синең! Әни... Әни! дип авыз тутырып әйткән булмагач, белмәгәнмен, тәмле, тантаналы яңгырый икән!.. Әни! Безнең улыбызның да теле «әни» дип ачылыр.

Т ә з к и р ә. Урам себерә ул мескенем...

Ә б ү з ә р. Нигә мескен? Аңламыйм.

Т ә з к и р ә. Туйга бер көтү кеше чакырдык. Күренекле инженерлар, икесе лауреат, берсе депутат. Сезнең цехтан... Ә Сәлимгәрәй Вафич атказанган фән эшлеклесе!

Ә б ү з ә р. Булса ни? Менә дигән егетләр алар, күрерсең.

Т ә з к и р ә. Ә синең этиең... орденлы! Аны бөтен шәһәр белә!

Ә б ү з ә р. Әти дә үтә чыккан тыйнак кеше.

Т ә з к и р ә. Шушы кадәр абруйлы кешеләр арасына мин урам себерүче кызы булып барып керә алмыйм.

Ә б ү з ә р. Тәзкирә җанашым!

Т ә з к и р ә. Гомерем буе мөдир кызы булып саналдым. Автобиографияләремә шулай язылган.

Ә б ү з ә р. Җүләрем минем! Җитлекмәгәнлек комплексы... Җүләремнең сабыйларча уйлары.

Т ә з к и р ә. Синең дворник кызы булып караганың юк, Әбүзәр. Безнең ишегалдында профессор, полковниклар яши. Аларның да кызлары бар. Яшьтәшләр. Беренче класска бергә барып кердек. Алар дәрескә ялтыравыклы кара машиналарда килде... Ә мәктәп? Мәктәп безгә нинди тәрбия бирде? Укыгыз, югарырак үрләгез дип, көн саен тукыдылар. Хәзер генә эшче, сыер савучының даны күтәрелде. Без укыган әдәбиятка гына кара: начальство турында әдәбият бит. Урам себерүче яки җыештыручы төп герой булган әсәр яки кино күрсәтә аласыңмы? Ә урам себерүчеләр миллион! Мемуар язган солдатны күрсәт син миңа, эзләп табып кара. Маршаллар яза, генераллар...

Ә б ү з ә р. Син минем кәләшем. Син студентка.

Т ә з к и р ә. Ә әнием?

Әбүзәр. Без аларга бер сүз дә аңлатып тормыйбыз. Телисеңме, мин бүген студентлар янында кунам. Иртәгә кадәр күздән югалам.

Тәзкирә. Юк шул инде... Мин кайттым да серне чишеп ташладым.

Әбүзәр. Менә бусы хата! Ялгышкансың. Кирәкми иде. Нигә болай да буталган хәлне катлауландырырга? Әниең ризамы соң?

Тәзкирә. Ризамы сиңа, мәңге бәхилләмәслек итеп рәнҗеде.

Әбүзәр. Хәл кыенлашкан.

Тәзкирә. Сине дә, этиеңне дә, берегезне дә күрәсем килми, ди.

Әбүзәр. Әллә мин барып аңлашып карыйммы?

Тәзкирә. Хәзерме? Пыр туздырып куып чыгарачак.

Әбүзәр. Шул дәрәҗәгә китереп җиткергәнсең икән.

Тәзкирә (*яшь аралаш*). Ә син туй, бәхет дисең.

Әбүзәр. Җайлабрак аңлатырга иде, уйлабрак.

Тәзкирә. Җайлап та карадым...

Пауза.

Әбүзәр. Хатын-кызның шулдыр инде аныңǃ..

Тәзкирә (*кинәт яшен корытып*). Ә син хатын-кызны каян беләсең? Кайда сынаганың бар, ничек?

Әбүзәр (*явыз көлемсерәп*). Беләм дип...

Тәзкирә. Әһә, былтыр командировкага киткәч, биш көн хат язмадың.

Әбүзәр. Командировканың катнашы юк, телеңне тыярга иде.

Тәзкирә. Һәммәсенә син гаепле! Син генә! Минем монда бер бөртек гаебем юк. Синең тик тормас холкың гаепле. Син җебегән.

Әбүзәр. Гаепле? Җебегән! Егет, кәләше турында этисенә бер-ике сүз чишкән икән, гаепме бу?

Тәзкирә. Алай бик нечкә күңелле булып кыланасың икән, нигә миңа тәкъдим ясаган көнне үк — моннан өч атна элек этиеңә кайтып сөйләмәдең?

Әбүзәр. Хата булган. Әмма монысына да син гаепле.

Тәзкирә. Ак эт бәласе кара эткәме?

Әбүзәр. Син булмыйча... Имеш, заманча булсынǃ.. Ата-ана катнашмасын! Үсеп җиткәнебезне аларга ныгытып сиздерик, янәсе. Алар заманы узган... Кем шушы сүзләрне туктаусыз сайрап чикерткә булып колакка керде?

Т э з к и р э. Чикерткә сүзен нигә сүз иттең?

Ә б ү з ә р. Бактың исә, бөтен фәлсәфәң комга корылган. Асылында чеп-чи ахмаклык, җүләрлек. Имеш, энисе урам себерүче. Булса ни! Базарда ит чабучылар да кеше булып йөри!.. Мөдирме, түгелме, хезмәте белән яши, тамагын туйдыра. Чи җүләр икәнсең.

Т э з к и р э. Җүләрнең дә чие?

Ә б ү з ә р. Шулай булмыйча!

Т э з к и р э. Син чи җүләргә өйләнәсеңме?

Ә б ү з ә р. Хәзер кая бармак кирәк...

Т э з к и р э. Ә-ә, алаймы? Мин мондый талымсыз кәҗәгә кияүгә чыкмыйм.

Ә б ү з ә р. Син аңгыра тукран. Чукыйсың, чукыйсың —бер мәгънә дә чыкмый.

Т э з к и р э. Минме тукран? Минме? Кайсы төшем тукранга охшаган?

Ә б ү з ә р. Ә мин кәҗәме?

Т э з к и р э. Кәҗә, кәҗә, мәкәрҗә син! Кире беткән мүкләк кәҗә. Талымсыз, культурасыз, принципсыз. Сиңа теләсә кем кызы да яр икән.

Ә б ү з ә р. Кияүгә чыкмыйм дидеңме? Рәхмәт! Котылдым! Ур-ра, котылды баш! Чыгып бер сызгырсам, ун кыз табам. Бүген үк!

Т э з к и р э. Ах, сиңа унау кирәкме, феодал? Чалмалы ишан! Бакчасарай ханы! Унны түгел, егермене тап та койрыгыңа так. Кәҗә тәкәсе күк йөр. Мине генә эзәрлекләмә! Барыбер эндәшәчәк түгел.

Ә б ү з ә р. Юлыңа ак җәймә! Эзләп барыр димә! Алдыңнан артың мең артык.

Т э з к и р э (*такмаклап*). Кәҗ-кәҗ кәҗә, мәкәрҗә! Кермә безнең бакчага!

Ә б ү з ә р. Бер дистә кыз сатып алам ике тиен акчага!

Т э з к и р э. Кәҗ-кәҗ кәҗә, мәкәрҗә! Сынар әле мөгезең!

Ә б ү з ә р. Уйлап үтсә төннәрең, җылап үтәр көндезең.

Тэзкирэ чыга. Телефон.

Ә б ү з ә р. Алло! Әйе, мин. Рәхмәт, рәхмәт. Тукта, тукта, нинди туй? Кем өйләнә? Минме? Кара гайбәт! Мине өйләнә дигән кешенең авызына сугып канат. Ялган хәбәр. К черту. Өйләнмәдем, өйләнмим, өйләнәсем дә юк! К дьяволу!

Т э з к и р э керә.

Т э з к и р э. Кәҗ-кәҗ, ишек бикле. Бир мөгезеңне.

Ә б ү з ә р. Тукранның томшыгы каты аның. (*Ачкычны ыргыта.*)

Тәзкирә ача, К ә р и м җ а н керә.

К ә р и м җ а н (*паузадан соң*). Мондый көнне бер-береңнән башка яшәп булмый шул. Аңлыйм. Өйдә икәнсез. Хәерле көн! (*Пауза.*) Көне килешкән, тыныч, җиле юк.

Ә б ү з ә р. Җиле юк.

К ә р и м җ а н. Ике ел сынашып йөрсәң дә, өйләнү солдат боткасы пешерү генә түгел... Көне килеп терәлгәч, төбе көя башлый аның! Мин дә, шуны исәпләп, бүгенгә ял алдым. Үзебездән кайтып киләм.

Ә б ү з ә р. Мин өйләнмим.

К ә р и м җ а н. Бу кыз Тәзкирәдер инде.

Т э з к и р э. Тукран мин. Каты томшыклы җүләре.

К ә р и м җ а н. Әбүзәр сезне «Акыллы!» дип бик мактады. Шулай диденме? Дөрес... Әйе... Тәзкирә дә әнисенә синең турыда бүген йомшак сүзләр әйтми калмагандыр. «Төпле егет!» дигәндер. Шулаймы? Дөрес.

Ә б ү з ә р. Хәзер боларның бер әһәмияте дә калмады.

Т э з к и р э. Элек тә булмаган.

К ә р и м җ а н. Гафу итегез, мин монда акыллы кызны да, төпле егетне дә күрмим. Әллә квартираны бутадыммы? Ялгыш кердемме? Сез кемнәр?

Т э з к и р э. Хушыгыз. Минем китеп барышым.

Ә б ү з ә р. Хуш, хуш.

К ә р и м җ а н. Чак кына сабыр итегез инде.

Ә б ү з ә р. Китсен, китсен! Тавышы, үзе, әйткән сүзе, кыланышы, кыяфәте йөрәгемә ярамый башлады.

Т э з к и р э. Салам күшәргә күнеккән кәҗә...

Ә б ү з ә р. Эти, дим, китсен!

К ә р и м җ а н. Бу йортка минем дә хакым бар иде шикелле? Хуҗа кайтып кергәч тә, кунакның китеп баруы яхшы булырмы?

Ә б ү з ә р. Нинди кунак?

К ә р и м җ а н. Сез бит Адәм белән Хава түгел. Халкыбызның матур җолалары бар. Мәңгелек кануннары. Хәлэхвәл белешик тә кунакны тәмле чәй белән сыйлыйк.

Т э з к и р э. Башым чатный... Чигәмдә пулемет ата.

К ә р и м җ а н. Һиндстан чәе белән сәйлүннекен бергә кушып, куе итеп ясаган бер чынаяк чәйне эчеп җибәрсәгез, авыртуның ни икәнен онытырсыз.

Ә б ү з ә р. Монда больница түгел, врачлар да юк.

К ә р и м җ а н. Бу бүлмәгә кереп ятып хәл ал булмаса, Тәзкирә. Әбүзәр, баш даруы бардыр. Күзеңне акайтма, җан даруы сорамыйм.

Т ә з к и р ә. Рәхмәт сезгә. Кайтып җитәрлек кенә хәлем бар.

К ә р и м җ а н. Ерак торасызмы?

Ә б ү з ә р. Моннан күренми.

К ә р и м җ а н. Юлда тагын да ныграк авырта башласа? Юк, юк, җибәрә алмыйм. Уттан чыгып ялкынга керәсегез бар!.. Каласыз! Бу егетнең әдәпсезлегенә исегез китмәсен, әдәп өләшкәндә наданнар арасында калган!

Әбүзәр, бик теләр-теләмәс кенә, Тәзкирәне бүлмәгә озата. К ә р и м җ а н ярты юлдан борылып килә. Телефон шалтырый.

К ә р и м җ а н. Юк, Әбүзәр түгел, әтисе. Өйдә шул. Ни йомышыгыз бар иде? Туй турында белешәсезмени? Белмим. Әтисе, әтисе!.. Атасы гына бит мин. Сау булыгыз.

Ә б ү з ә р керә. Пауза.

Ә б ү з ә р. Әти!

К ә р и м җ а н. Дару табылдымы? Юкмы? Юктыр шул...

Ә б ү з ә р. Кем шалтыратты?

К ә р и м җ а н. Әйтмәде. Туй кайчан була, ди.

Ә б ү з ә р. Туй булмый.

К ә р и м җ а н. Нигә?

Ә б ү з ә р. Без аерылышабыз.

К ә р и м җ а н. Кушылмаган килеш ничек аерылышырга мөмкин икән?

Ә б ү з ә р. Мең бәхеткә каршы, кушылып өлгермәдек.

К ә р и м җ а н. Кызык, үтә кызык.

Ә б ү з ә р. Өйләнәм дидем — кызык, аерылам дидем — тагын кызык. Кызык ярата торган әти икәнсең, белмәдем.

К ә р и м җ а н. Кызык ясаучы малай булып чыктың син, белмәдем!

Ә б ү з ә р. Кызыкны син ясадың, син!

К ә р и м җ а н. Кылган гаебең өчен бер гөнаһлы булсаң, гаебеңне кешегә сылтарга маташып мең гаепле булдың. Мөгаен, мин кайтып кергәндә, Тәзкирәдән дә гаеп чүпләп маташкансыңдыр син.

Ә б ү з ә р. Җүләр башлар, җүләр башлар! Тәзкирә планлаштырганча, шыпырт кына өйләнешкән булсак...

К ә р и м җ а н. Кушылганыгызны да, аерылганыгызны да белми каласы икәнмен.

Әбүзәр. Белеп ни файдаң тиде? Нинди ярдәм күрсәтә аласың син безгә? Аңлыйсыңмы син хәзерге яшьләрне? Заман мөнәсәбәтләрен аңлыйсыңмы? (*Кесәсенә тыгылып, билетлар тартып чыгара.*) Сез булмасагыз, без бүген пар күгәрчендәй гөрләшә идек тә кичен концертка бара идек.

Билетларны атып бәрә.

Кәримҗан. Нигә ташлыйсың аларны? Өйләнешү таныклыгы түгел ич, үчен алма.

Әбүзәр. Кирәкләре бетте.

Кәримҗан. Алай димә. Тәмамланган уй ахырына гына нокта куялар.

Әбүзәр. Ике сәгать ярым чират торып алган билетлар. Шул вакыт дәвамында күңелгә ничаклы якты уйлар иңгән иде!

Кәримҗан. «Сез булмасагыз» дип ычкындырдың. Комачаулаучы бәндә бер мин генә түгел, алайса?

Әбүзәр. Картлар һәрвакыт бер-берсенә охшыйлар... Аның әнисе дә аяк терәп каршы тора.

Кәримҗан. Бусы ярый.

Әбүзәр. Нәрсәсе ярый?

Кәримҗан. Акыллы ана икән.

Әбүзәр. Сез акыллы, без җүләр.

Кәримҗан. Мин әле алай ук димәдем.

Әбүзәр. Күреп торам.

Кәримҗан. Без аталы-уллы икәү... Син тумасаң, дөньяның күпме шатлыгыннан мәхрүм идем мин? Синең җылы тәнең, татлы сулышың... Зәңгәр яллы аксак атың... Казаяк чәчәге төсле сап-сары беренче башмагың... Синең шушы җирдә аупән-таупән тәүге тапкыр атлап китүең... Шушы җирдә, минем җиремдә, бабаңнар җирендә... Миннән, синнән соң да мәңгегә кала торган Иделйортыбызда... һәммәсе якын, кадерле... Шул сары башмагыңны туеңда бүләк итәрмен дип саклап тотам... Менә бу тар ишекне күрәсеңме? Аңа зур шатлык та, чамасыз зур хәсрәт тә сыя. Бу ишектән минем якын кешем бер мәртәбә чыгып китте инде. Син дә чыгып китсәң, бу бүлмәдә кем каласын күз алдыңа китерәсеңме? Беләм, берәүләргә бала — чүп! Ләкин мин андыйлардан түгел. Табигать миңа кайнар зиһенле мәхәббәт биргән. Бүлмә бит ул кеше югында да буш түгел. Аның һәр почмагына күз нуры коелып калган. Син күз текәмәгән берәр почмак бармы монда?.. Очраклы кеше белән кавышуыңны күтәрә алачагым юк иде. Тәзкирәнең әнисен күрергә генә

теләдем. Начарлыгым шул булдымы? Туганнарын, кардәш-ыруын... Базардан бәрәңге алганда да «кайсы яклар, кайсы авыллар», дип сорашам мин. Беләсеңме, кайсы сүзең мине ныграк әрнетте?

Әбүзәр. Чамалыйм.

Кәримҗан. Бу заманны без төзедек. Берәүнең дә сан өчен генә яшисе килми. Берәүнең дә! Иң гади кешеләр дә, асылда, заман өчен җаваплы. Синең өчен, синең кем булуың өчен заман алдында мин җаваплы. Ә хәзер... теләсәң нишлә!

Әбүзәр. Тәзкирә белән килешер дип уйлыйсыңмы?

Кәримҗан. Күмәч беткән икән безнең! Иртәдән бирле чәй эчкән юк, карын ачты. Йөгереп кенә барып кил, булмаса, улым.

Әбүзәр. Күмәч?.. Ярый... алайса!

Чыга. Пауза. Кәримҗан телефонга тотынып карый, кире куя. Тәзкирә керә.

Тәзкирә. Мин барын да ишетеп тордым.

Кәримҗан. Беләм.

Тәзкирә. Сез боларны минем өчен сөйләдегезме?

Кәримҗан. Алай булуы да бик мөмкин.

Тәзкирә. Миңа чыгып китәргә рөхсәтме?

Кәримҗан. Бая да сине тоткарлаган кеше юк иде. Кем синең юлыңа аркылы төшә ала? Тик, минемчә, син болай гына чыгып китә алмыйсың.

Тәзкирә. Китә алам.

Кәримҗан. Юк.

Тәзкирә. Кем мине тота ала? Сезме?

Кәримҗан. Мин синең өчен юк кеше. Башка берәү бар.

Тәзкирә. Әбүзәрме?

Кәримҗан. Чыккач кая барырсыз?! Кем янына? Мин сезне тотмыйм.

Тәзкирә. Күрмисезмени, чыгып барам.

Кәримҗан. Тукталмагыз, атлагыз!

Тәзкирә. Куркыныч.

Кәримҗан. Ишек артында берәү дә юк.

Тәзкирә. Куркыныч ишекнең бу ягында. Сезнең күзләрегез...

Кәримҗан. Кияүгә чыгу сиңа бер мәзәк кебек күрендеме? Тамаша?! Кызганычка каршы, мин дә бу тамашага катнашып киттем. Моңарчы безнең тамашада хатын-кыз юк иде. Менә син килеп чыктың. Тамаша

куерды! Улыма кәләш! Миңа килен! Оныкларыма ана килде! Әти кешеләр үзләре башкарып чыгара алмаганнарны да улларыннан көтәләр, могҗизага ышаналар! Мин гаилә бәхетен күрә алмадым, насыйп булмады. Әбүзәремнең семья шатлыгын көтеп, шуңа өметләнеп яшәдем. Син бу өйнең кояшы булырга тиеш идең!.. Күрче минем кулларымны: аларның бер чакта да ял иткәннәре юк. Төннәрен дә тынмый алар, сызлыйлар. Тукучы сосасы булып яшәдем мин — өйдән эшкә, эштән өйгә. Күпме еллар татлы өмет катыш мәшәкатьтә узды... Нәтиҗә?! Нәтиҗә бер: тамашада сез миңа клоун ролен калдыргансыз икән. Эчтән җыласам да, көләргә кушасыз! Хәер, боларның хәзер ни хаҗәте бар?

Тәзкирә. Ул мине җәберләде. Кимсетте.

Кәримҗан. Ишек ачык.

Тәзкирә. Әбүзәрнең энисе...

Кәримҗан. Әйе, ул исән-сау. Хат язган. Кайтырга теләге бик зур. Үкенә. Тик бу бусаганы бер тапкыр үтеп чыккан кеше кире кайтмый. Сулар үргә акса да! Чөнки бу йортта тормыш бер чакта да уен һәм җиңел булмады.

Тәзкирә. Әбүзәр боларны беләме?

Кәримҗан. Боларны син белергә тиеш идең!

Тәзкирә. Нигә мыскыллады ул мине? Нигә мәсхәрәләде?

Кәримҗан. Синең бер дә хатаң юкмы?

Пауза.

Тәзкирә. Энисе турында сөйләмәгән булсагыз, ичмасам?!

Кәримҗан. Ишек шар ачык!

Тәзкирә. Ике ут уртасында калдым.

Кәримҗан. Юк, өч ут уртасында.

Тәзкирә. Чигенер урын да калмаган дисезме?

Кәримҗан. Өч җирдә дөрләгән өч ут. Энә берсе яшь юкә астында йөренә. Йөрәге янмыймы аның?.. Каршыгызда мин...

Тәзкирә. Өченчесе кем соң?

Кәримҗан. Белмисеңме, Тәзкирә? Энием, балам, энием!

Тәзкирә. Эни...

Кәримҗан. Ата-аналар күңел яраларын бер чакта да күрсәтмиләр. Эчләрендә ялкын булса да, чыдыйлар, ләкин килә бер вакыт, кар астындагы кайнар чишмә дә ургылып бәреп чыга. Чыкмый калмый!

Т э з к и р ә. Миңа нишләргә соң хәзер?

К ә р и м җ а н. Миннән сорыйсыңмы? Кем соң син миңа? Улымның ярәшелгән кызымы, әллә кавыша алмыйча аерылган кәләшеме?

Т э з к и р ә. Өч ут арасында адашкан күбәләктер мин.

К ә р и м җ а н. Безнең заманда кызлар киңәшкә әниләре янына кайталар иде. Хәзер белмим, ничектер.

Т э з к и р ә. Димәк?..

К ә р и м җ а н. Болан тизлеге белән өеңә оч!

Ә б ү з ә р керә.

Ә б ү з ә р. Әти!

К ә р и м җ а н. Ашык, Тәзкирә. Әниеңә әйт, киләләр, диген. Борчылып тормасын.

Ә б ү з ә р. Әти, нишләдең син? Мин бармыйм, бармыйм!

К ә р и м җ а н. Йөгер, Тәзкирә. Бәхетнең адымнары тиз, бәлки, куып та җитәрсең! Йөгер!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Ә н и с ә ялгызы. Т ә з к и р ә керә, сулышын тыя алмыйча, әнисенә килеп сыена.

Т э з к и р ә. Киләләр!

Ә н и с ә (*сөеп*). Йә, йә, йөрәгең купкан. Кайдадыр ут капкан кабуын, әлегә безнең йортта тып-тыныч.

Т э з к и р ә. Әни, дим, син тыныч булып күренергә генә телисеңме, әллә йөрәгеңә туң төштеме?

Ә н и с ә. Кыланам! Кыланам гына! Белмисеңмени, иртәдән бирле кыланырга сәбәпләр өстәлә тора. Туа тора, ега тора. Кызым заманның без белмәгән тагын нинди хикмәтләрен күрсәтер икән дип көтәм.

Т э з к и р ә. Киләләр дидем ич, аңламыйсыңмыни?

Ә н и с ә. Кыңгыраулар тагып, чаптар атларда киләләр... Урам шау итә!.. Балаларга прәннек, кәнфит чәчәләр... Дугаларда сөлгеләр... Әллә аллы-кызыллы куыклар таккан машина гына алганнармы? Куыклар исә яшьләрнең бер-беренә биргән вәгъдәләре, йа тотыналар бер заман шартларга!.. Ярар, булды... Кайгымны уенга кушып йотып җибәрмәкче идем, барып чыкмады. Киләбез дип тәгаен әйттеләрме? Әллә чакырып кайттыңмы?

Т ә з к и р ә. Киресенчә, берүк йөри күрмәгез дип инәлдем.

Ә н и с ә. Шунда да кыеп килергә булдылармы?

Т ә з к и р ә. Әбүзәр генә: «Килмибез!»— дигән булып, кылтаеп калды.

Ә н и с ә. Кем чыгарган мөгез монысы тагын? Син тырыштыңмы, әллә ул да сиңа ияреп исен югалтканмы? Ипләп кенә җепкә тезеп бирче, бу табышмакны икәү чишеп карыйк.

Пауза.

Т ә з к и р ә. Бүген беренче мәртәбә Әбүзәрләр өенә кердем.

Ә н и с ә. Сабырлык кыз кешене бизи торган сыйфат.

Т ә з к и р ә. Әтисен күрдем.

Ә н и с ә. Әлегә бик дөрес алып барасың. Әтисенә күрендем дияргә кирәк иде, башкасы бик әйбәт.

Т ә з к и р ә. Хәзер синең чират. Мин дөрес башлаган сүзне дәвам итә алырсыңмы?

Ә н и с ә. Нигә мин? Син кайда?

Т ә з к и р ә. Сөйләшә алмам мин алар белән. Бигрәк тә Әбүзәрне... күрәсем килми!

Ә н и с ә. Алай, нык ук тәмсезләнгәнсез... Сабырың җитеп бетмәгән. Ялгышканмын, сүзне дөрес үк башламагансың, ахры. Көймәң комга terәлгәч, әнине искә төшергәнсең.

Т ә з к и р ә. Хаклы булсаң да, алар килер алдыннан талашмыйк, зинһар. Коткар мине, әнием.

Ә н и с ә. Кызым, балам, йөрәк парәм. Мин бит аларны белмим. Аларны түгел, сине дә белмим. Кем соң син хәзер? Ни кирәк сиңа миннән бүген? Уртак язмыш кына уртак уйларга китерә. Карының ач, сусаган чагында, әйбер-кара кирәгендә мин сине ярты сүздән аңлый торган идем. Хәзер син ят. Кем син?!

Ишектә звонок.

Т ә з к и р ә. Килделәр!

Ә н и с ә. Без сүз сөйләшеп бетерә алмадык.

Т ә з к и р ә. Күлмәгең, өс-башың!.. Күлмәгең!

Ә н и с ә. Бар, ач.

Т ә з к и р ә. Тез буыным тотмый. Үзең ач.

Ә н и с ә. Телең тотлыга... Тезең йомшаган... Иртә бирешәсең, кызым. Тормыш мең сыный әле ул! Ныграк тор! (*Ишеккә бара, ача, Әбүзәр керә.*)

Т ә з к и р ә. Әбүзәр? Килмәм дигән кеше.

Ә б ү з ә р. Авызыңны шушы сүз белән ачарсың дип курыккан идем. Эх! Әйе, бу мин. Мин. Исәнмесез, Әнисә апа.

Т ә з к и р ә. Әни, бу ул. Әбүзәр.

Ә н и с ә. Күрәм. Исәнмесез.

Ә б ү з ә р. Без... сез... мин... Рәнҗемәгез безгә, Әнисә апа. Әти дә хәзер килә, эшенә кереп кенә калды. Мин базарга кагылдым да монда чаптым. Трамвайларны узам! Менә! (*Кулындагы чәчәк бәйләмен Тәзкирәгә бирергә уйлый, алмаслыгын сизенеп, букетын Әнисәгә тоттыра.*) Сезгә, Әнисә апа.

Ә н и с ә. Рәхмәт, зурлагансыз. (*Пауза.*) Суга утыртыйм мин аларны.

Т ә з к и р ә (*пышылдап*). Күлмәгеңне алыш, кыяфәтең...

Ә н и с ә. Ни кылыйм, бердәнбер баламның теләгенә каршы килеп өйрәнелмәгән. (*Чыга.*)

Т ә з к и р ә. Нигә килдең?

Ә б ү з ә р. Күңел түгел, аяклар китерде.

Т ә з к и р ә. Дөресен дә сөйли беләсең икән әле.

Ә б ү з ә р. Мин дә тәрбияле кеше. Бердәнбер әтиемнең теләгенә каршы килеп өйрәнмәгән.

Т ә з к и р ә. Сине күрәсем дә килмәгәнне беләсеңме? (*Кинәт.*) Бу ак күлмәгеңне бүген кимә дигән идем бит! Иртәгә, загска барганда ни киярсең?.. Гафу ит, ялгыштым...

Ә б ү з ә р (*көлеп җибәрә*). Әти кидертте. Ул!

Т ә з к и р ә. Ә үзең? Ә син?

Ә б ү з ә р. Кичер син мине. Безгә ызгышырга ярамый хәзер.

Т ә з к и р ә. Кем ызгыша соң биредә?

Ә б ү з ә р (*җиңел сулап*). Безгә чак кына акыллырак булырга кирәк.

Т ә з к и р ә. Әтиең шикеллеме?

Ә б ү з ә р. Тимик олыларга... Бер юлга калып торсыннар.

Т ә з к и р ә. Гаеплэп әйтүем түгел иде, киресенчә... (*Яңа күлмәк киеп, Әнисә керә, Тәзкирә аны җилтерәтә.*) Әни!

Ә н и с ә. Чү, чү, котырма.

Т ә з к и р ә. Син нинди яшь! Чибәр!

Ә н и с ә. Чү, дим...

Т ә з к и р ә (*шыпырт*). Без килештек.

Ә н и с ә. Чамаладым. Миңа эш калдырмагансың шикелле.

Ә б ү з ә р. Әтинең сезне бик күрәсе килде. Бик инде!

Ишектә звонок.

Т ә з к и р ә. Кәримҗан абый килде.
Ә н и с ә (*каушап*). Ишек ачык бит. Нигә керми?
Т ә з к и р ә. Бар, каршыла, әнием.

К ә р и м җ а н керә.

К ә р и м җ а н. Менә без дә килеп җиттек. Каланың бу ягына чыккан юк иде, үзгәргән, үскән, матурланган. Сезнең урам бигрәк чиста себерелгән!.. Әйе, кошын күргәч, оясын да күрәсе килеп китте. Ояны бит балалар кормый, олылар тырыша. Исәннәрмесез. Әбүзәр мине көтеп тормас дип уйлаган идем, ялгышмаганмын.
Ә б ү з ә р. Йөрәк түзмәде.
К ә р и м җ а н. Сизеләә.
Ә н и с ә. Узыгыз, утырыгыз. Мин Тәзкирәнең әнисе. Әнисә.
К ә р и м җ а н. Ә без Кәримҗан булабыз. Килергә рөхсәте барында бик узабыз инде.
Ә н и с ә. Әле чакыру да булып алдымыни?
К ә р и м җ а н. Әлегә ишетелгәне юк. Бүлмәгез кояшка караган. Коры. Гөлләр дә күп икән.
Т ә з к и р ә. Әни гөлләр, песи һәм кояш ярата.
К ә р и м җ а н. Кызганыч, гөлләрне син яратмыйсың икән, Тәзкирә.
Ә б ү з ә р. Каян белдең, әти?
К ә р и м җ а н. Хәзер балалар өлкәннәргә охшамаска тырышалар. Артта калганлыкта гаепләрләр дип шүрлиләр. Шулаймы?
Ә н и с ә (*бераз үпкәләп*). Килмәс борын барын да белеп торасыз әле сез!
К ә р и м җ а н. Тырышып-тырмашып ул үстереп ятам бит, Әнисә ханым!
Ә н и с ә. Чәй әзерләп җибәр, кызым.
К ә р и м җ а н. Чәйне рәхәтләнеп эчәр идек. Сез нинди чәй хуш күрәсез?
Ә н и с ә. Безме? Һиндстанныкы белән сәйлүн чәен катыштырып пешерәбез. Берсенең тәме татлы, икенчесенең исе куәтле.
К ә р и м җ а н. Безнең семейный рецептны каян алдыгыз?
Ә н и с ә. Ашым да әзер.

К ә р и м җ а н. Аш та бармы? Нинди аш?

Ә н и с ә. Сезгә тәкъдим итәргә генә уңайсыз. Өй ашы, гадәти аш. Мондый олы, кадерле кунаклар киләсен алданрак белмәдек шул.

Ә б ү з ә р (*шыпырт*). Әти дим, юньлерәк сүз тап инде.

Т ә з к и р ә (*шыпырт*). Син дә шул, әни...

Ә н и с ә (*сабыр гына*). Шакмаклы токмач. Итен дә вак кына итеп шакмаклап турадым.

К ә р и м җ а н. Катык та бармы?

Ә б ү з ә р (*шыпырт*). Нишлисең син?

Т ә з к и р ә (*шыпырт*). Әни, мине хурлыкка калдырасыңмы?

Ә н и с ә. Шакмаклы токмачның катыксыз ләззәте буламы? Мин аңа чак кына яшь кычыткан да йөздердем.

К ә р и м җ а н. Сез аш-суның гаҗәеп остасы икәнсез! Повар булып эшлисезме әллә?

Ә б ү з ә р (*юри кычкырып*). Менә бу киң яфраклы гөлнең исемен белмим.

Т ә з к и р ә (*юри кычкырып*). Әни дим, тамырын каян алдык әле без бу гөлнең? Син Рига култыгына ялга барган идең бит, диңгезгә... Путевкасын бушлай бирделәр. Менә бу чынаякларны да шуннан алып кайтты. Әнием шунда мәскәүле бер яһүдә белән танышкан. Кремль больницасында врач булып эшли икән. Бу гөлнең тамырын шул апа салды.

Ә н и с ә (*сабыр гына*). Минемчә, ашны оста әзерләү өчен ризыкка да, ризыкны ашарга тиешле кешегә дә хөрмәт кенә кирәк.

К ә р и м җ а н. Карагыз әле, ифрат дөрес фикер бу! Шәкертләремә җиткерәчәкмен. Повар булып эшлим мин. Ресторанда. Укучыларым байтак. Тәзкирә дә шулай йорт җанлыклымы?

Ә н и с ә. Тәзкирә талымсыз. Аңа ни, урам чатындагы катып беткән тугыз тиенлек пәрәмәч тә аш.

К ә р и м җ а н. Кайда хезмәт күрсәтәм дидегез әле?

Т ә з к и р ә. Менә бу вазаны әни Чехословакиядән алып кайтты. Матурмы?

Ә б ү з ә р. Искиткеч гүзәл! Бар оста куллар чехларда. Безнең Казанда мондыйларны сатмыйлар, гомергә буласы юк.

Т ә з к и р ә. Ә моны...

К ә р и м җ а н. Тәзкирә чәй тәмен дә аңлыймы?

Ә н и с ә. Тузан итеп очырган вак кофены яратарак төшә.

К ә р и м җ а н. Ялкаулар ашы!

Тәзкирә. Әни, кеше көлкесенә калдырдың.

Әбүзәр. Әти, башны бетердең.

Кәримҗан. Алай, алай... Ашыкканда без дә ул кофены яратабыз. Яшьләр гел-гел ашыгып яшиләр. Ә ризык әзерләү үзе бер ләззәт бит ул! Яхшы әзерләнгән ризыкны ашау бәхет! Тормышта иң рәхәт минутларым ризык әзерләү. Өстәлгә яшелчәләрне таратып ташлыйсың. Кишер-мишер, кәбестә — ак тун, ә укроп? Кыяр? Гөмбәләр! Хуш ис! Һәммәсе поэма!

Әнисә. Көздән вареньесын, компотын, гөмбәсен шактый әзерләп куям, ашаучы гына юк.

Кәримҗан. Гөмбә? Каягыз әле, берәрсен табынга куеп карыйк. Компот та яхшы нәрсә. Мин гомергә шикәр капмыйм, чимал гына ич әле ул. Алъяпкычыгыз бармы?

Әбүзәр. Беттек!.. Юк, юк, Әнисә апа, кирәкми. Мәшәкатьләнмәгез.

Тәзкирә. Таптың сүз, әни. Рига турында сөйләргә иде. Чит илгә чыгуыңны.

Әбүзәр. Кылана, кәмитләнә.

Кәримҗан. Нишләп кыланыйм ди мин?

Әбүзәр. Ачлар дөньясыннан килгәнмени?! Гомергә тамагы туймаган кеше төсле...

Кәримҗан. Ярар, алайса. Кирәкми, Әнисә ханым. Кирәкми икән.

Пауза.

Әнисә. Әйдәгез, алайса, магнитофон тыңлыйк.

Тәзкирә. Менә бусы шәп. Әйдәгез!

Кәримҗан. Татарча, үзебезчә генә җырлар бармы соң?

Тәзкирә. Бар да бугай... Кайда икән алары?

Әнисә. Үзебезнең Әлфияне яратам мин. Афзалованы. Моң дәрьясы инде. Көннәр буе шуның җырларын көйләп йөрим. Өйдә дә ялгыз, эшемдә дә ялгыз дигәндәй...

Кәримҗан. Исемә төште! Балалар бакчасында диделәр сезне. Анда, йөз бала арасында, ничек ялгыз булмак кирәк?

Әнисә. Дворник мин. Урам себерәм. Кышын көрим дә. Бозын ватам.

Тәзкирә. Минем әнием вакытлыча детсадтан китеп торды. Кремль больницасында эшләүче врач ахирәте аңа... Доцент ди!.. Вакытлыча... Саф һавага!

Әбүзәр. Журналларны укып барам: саф һава бөтен нерв авыруларына дәва. Көч бирә. Тәнне ныгыта һәм башкалар...

Кәримҗан. Күркәм эш. Бик кирәкле эш.

Әнисә. Минем бервакытта да детсадта эшләгәнем булмады. Кыстап караганнар иде... Яратып эшләгән эшеңә ни җитә? Җаның тыныч.

Кәримҗан. Ифрат тапкыр фикер. Җан тынычлыгы кирәк, җан!

Әнисә (*Әбүзәр белән Тәзкирәне үртәп*). Дөрес, иптәшләр... Әлбәттә, шәһәр шулай күзгә күренеп зурайганда, фән-техника революциясе чәчәк атканда серберке, көрәк тотып йөрү килешми дә торгандыр. Әмма җыештыручы һөнәре борынгы Римда ук булган. Кирәкле эш. Киләчәктә дә бу һөнәрнең бетүе күренеп тормый.

Тәзкирә (*исе китеп карап тора*). Ә-ни-и!

Әнисә. Сине генә үртим!

Кәримҗан. Каян килде бу безнең балаларга ата-ананың кара эшеннән йөз чөерү?! Гадилектән хурлану каян килде? Эшче-крестьян дәүләтендә мондый яшьләребез ничек пәйда булды?!

Әбүзәр (*тәкате корып*). Әти, бу йортка нигә килдек без?

Тәзкирә. Әни дим, сүзне башкага бор.

Әбүзәр. Без тормыш, яшәү, киләчәк турында сөйләшергә килдек.

Кәримҗан. Ә без ни турында сөйләшәбез?

Әбүзәр. Кишер, шалкан турында.

Кәримҗан. Алары да тормыш, улым.

Әнисә. Син, кызым, алай кискен фикер йөртмә.

Пауза.

Кәримҗан. Күреп торам, Әнисә ханым, яшьләргә кишер-шалкан да, безнең әңгәмә дә ошамый.

Әнисә. Әлфияне телгә алганны яратмады. Афзалованы. Алар бит теге ат койрыгыдай чәчләрен тузгыткан битлзлардан башканы бар дип тә белмиләр. Иманнары башка.

Әбүзәр. Алай ук түгел дә, Әнисә апа, бүген бит... ни... без...

Тәзкирә. Бүген безнең көн иде бит, әни.

Кәримҗан. Барыгыз, яшьләр, үзегез үтереп мактаган саф һаваны сулап керегез. Нервларны ныгыта диде-

гезме? Менә килешер сезгә! Әнисә ханым белән без җай гына аңлашырбыз.

Әбүзәр. Әти, берүк авызыңны үлчәп ач.

Тәзкирә. Дөньяга чыгарлыгымны калдырмассың инде, әни.

Чыгалар.

Кәримҗан (*паузадан соң*). Юккарак чыгарып җибәрмәдекме?

Әнисә. Дерт-мерт итеп, безнең авыздан ни чыгар икән дип сагалаганчы, бераз тынычлансыннар. Иртәме-соңмы безне дә аңларлар. Яши-яши тормыш күзне ача ул бер.

Кәримҗан. Ярый ла безнең күзләр йомылганчы аларныкы ачылса!

Әнисә. Хәзер рәхәтләнеп сезне аш белән сыйлыйм.

Кәримҗан. Рәхмәт. Өй ашыннан баш тарта алмыйм.

Әнисә аш алып керә.

Әнисә. Кичерегез инде, алданрак белсәм... Аш алды тотмыйм.

Кәримҗан. Мондый ләззәтле, тәмле ашны аш алды белән бозалармы?

Әнисә. Күрәсез, һәммә нәрсәбез үзебез төсле үк гади. Бу гөл тамыры да Әмә тавыннан гына килгән. Ашны яратсагыз, өстәрмен.

Кәримҗан. Минем улым...

Әнисә. Минем кызым...

Кәримҗан. Улымны. Әбүзәрне әйтәм...

Әнисә. Безнең Тәзкирә дә...

Кәримҗан. Балалар...

Әнисә. Шулар турында иркенләп, бәйнә-бәйнә сөйләшик әле бер, Кәримҗан ага.

Кәримҗан. Сезнең кызыгыз...

Әнисә. Әбүзәрне әйтәм әле...

Кәримҗан. Тәзкирә турында күбрәк сөйләгез әле.

Әнисә. Әбүзәрне бигрәк белмим инде!

Кәримҗан. Шулай, шулай. Сөйлим, бик сөйлим. Шуның өчен очраштык та. Шулар өчен...

Әнисә. Бөтен яктан беләсем килә.

Кәримҗан. Әбүзәр дип исемен үзем куйдым. Әбүзәр, Әбүзәр... Больницадан алып кайтып чишеп җибәргәч: «Улым, бабай малай булгансың икән!» — дип, кычкырып җибәрдем. Җыерчыклы иде маңгае... Бәләкәй чагында, өч яше тулып кына килә иде, кара савытына

бармагын тыккан да бармак кысылып калган. Хәзер андый кара савытларын эшләмиләр шикелле?

Әнисә. Алтын каләмле ручкалар белән генә язалар.

Кәримҗан. Ә без сиксән алтынчы каләм белән яза идек.

Әнисә. Йә рондо белән.

Кәримҗан. Әллә нишләп сүз тәртибен чуалттым. Сый-хөрмәтегез өчен зур рәхмәт.

Әнисә. Чәй ясап китерәм. Кайнап утыра.

Кәримҗан. Анысы чак кына соңрак, ярыймы? Балалар турында ифрат күңелле сөйләшә идек.

Әнисә. Сөйли башласаң сүзнең бетәсе юк анның. Безнең Тәзкирә...

Кәримҗан. Курчак уйнарга бик ярата иде!

Әнисә. Дөрес! Каян белдегез?

Кәримҗан. Безнең Әбүзәр исә...

Әнисә. Борчак мылтыгы ясап, идәнне чүпкә батыра иде!

Бер-берсенә карап көлешәләр.

Кәримҗан. Хөкем алдына килгән сыман каршыгызда утырам. Үз гомеремдә беренче тапкыр яучы сыйфатында ишек кактым. Кемгә яучылыйм диген, еллар буе күз алдымнан китмәгән улыма... Кош булып сайрарга кирәк иде дә, ни турында сөйләргә белмим! Бүгенге кыланышлары белән фикеремне тәмам чуалтып бетерде. Белмим икән мин улымны! Ичмасам, сүзне сез өзмәгез. Сез — ана. Аналар балалары турында барын да беләләрдер.

Әнисә. Егерме бер яшь. Комсомолка. Укый. Укытасым килде. Тырышып кына йөри кебек. Кинолар ярата, театрны... Аннары, аннары... Беләсезме, Кәримҗан ага, шуннан артыгын сөйли алмыйм.

Кәримҗан. Сер итеп калдырасызмы?

Әнисә. Оятыма каршы, ни сөйләргә белмим.

Кәримҗан. Минемчә, сезнең кызыгыз...

Әнисә. Әбүзәргә килгәндә...

Кәримҗан (*паузадан, соң*). Әйдәгез, булмаса үзебез турында гәпләшик.

Әнисә. Безнең хакта ни сөйләшергә була ди?

Кәримҗан. Нигә, Әнисә ханым?

Әнисә. Без... һи-и! (*Көлә.*)

Кәримҗан. Аңлыйм. Яшьләр коткысына бирелгәнсез.

Әнисә. Коткыга бирелəсе-нитәсе юк, Кәримҗан ага.

Кәримҗан. Җырыбыз җырланган, ябагабыз коелган, кәфен кочаклап кабер ягасында гына утырасы калган дисезме?

Әнисә. Алай ук димәсәм дә, безнең хакта нинди сүз булуы мөмкин? Һөнәр-кәсепләребез бар, йорт-җиребез түгәрәк... Менә яшьләр...

Кәримҗан. Минем малайның сүзләре! Сез аларны Тәзкирәдән откансыздыр! Телләрендә бары шул гына: заманнан артта калгансыз, яшьләрне аңламыйсыз. Әбүзәргә үпкәләсәгез дә була — ана тәрбиясе күрмәде балам... Гаилә нечкәлекләрен өйрәтергә кул да җитмәгәндер. Үзем дә байтак нәрсәне бүген генә аңладым.

Әнисә. Балалар хаклы булып чыга түгелме соң?

Кәримҗан. Сез дә, алар да хаклы түгел, һәм мин моны исбатларга телим! (*Кесәсеннән, кулъяулыгы чыгарып тирен сөртә, кәгазьләр төшә.*)

Әнисә. Кесәгездән нидер төште.

Кәримҗан. Театрга билетлар. Бүгенге число. Каян килгән болар миңа? Бу билетлар минеке түгел.

Әнисә. Минеке дә түгел. Театрга бармаганга әллә кайчан инде! Һаман өлгереп булмый.

Кәримҗан. Ә-ә, хәтеремә төште. Хикмәте бар ич боларның. Балалар бүген театрга барырга тиеш иде.

Әнисә. Әйдәгез, тизрәк чыгарып бирик. Соңга калмасыннар тагын берүк... Ай, Аллам... Тәзкирәмнең күлмәге үтүкләнмәгән. Муенсамны әзерләп куй дигән иде... Башмаклары кайда икән тагын?

Кәримҗан. Әнисә ханым, Әнисә ханым! Аларда театр кайгысымы?

Әнисә. Хәер, алар бездән җавап көтә.

Кәримҗан. Бу хәлләрне ничегрәк күз алдына китерә идегез сез, Әнисә ханым?

Әнисә. Әллә тагын... Яшьләр үзләре белер инде дип йөрелгән шунда.

Кәримҗан. Яшермисезме, Әнисә ханым?

Әнисә. Ә сез?

Кәримҗан. Болай түгел. Бөтенләй башкача күз алдына китерә идем.

Әнисә. Билетларны тагын төшердегез.

Кәримҗан. Тәмам бәла булдылар. Эссе булып киттеме шунда. Әйдәгез без дә өй кысасыннан чыгыйк, Әнисә ханым. Гомергә булмаганны баш әйләнеп китте.

Әнисә. Ә балалар?

Кәримҗан. Бераз көтсеннәр, уйлансыннар. Әзер җа-

вап белән көрешү яхшырак булыр. Безнең гомер болай да алар өчен генә уза!

Әнисә. Булмаса, бераз йөреп керик. Табынны җыештырасы иде.

Кәримҗан. Соңыннан, Әнисә ханым, соңыннан! Эш бездән качмас, башкасыннан коры калмыйк.

Әнисә. Аңлап җиткермәдем, Кәримҗан ага, томаналык!

Кәримҗан. Бергә-бергә ничек булса да аңларбыз, Әнисә ханым. Рәхим итеп, алдан узыгыз!

Чыгалар. Төн. Урам. Эскәмия янында телефон-автомат. Әбүзәр ялгызы. Тәзкирә керә.

Әбүзәр. Кайтмаганмы?

Тәзкирә. Сорама да, ичмасам! Күрмисеңмени?

Әбүзәр. Әти дә кайтмаган. Тагын шалтыраттым. Җитмәсә ике тиенне йотты ачарбак!

Тәзкирә. Берсенең кайда икәнен генә beләсе иде. Табышмакка әйләнде бу!

Әбүзәр. Табышмак кынамы сиңа, лабиринт, кроссворд. Тагын бер кат нык кына башны эшләтеп карыйк әле: без чыгып киткәч өйдә ни булуы ихтимал?

Тәзкирә. Җөйче янына барасы булмаса, гомергә дә чыгып китми идем. Әтиең килеп керүгә нинди буран кубасын сизендем.

Әбүзәр. Әти килеп керде... Йә, шуннан?

Тәзкирә. Пыр тузышып талашканнар да икесе ике якка чыгып чапканнар.

Әбүзәр. Ишекне дә бикләмәгәннәр!

Тәзкирә. Утны сүндермәгәннәр! Ишек бикләргә дә онытып чыгып чабарлык булгач, сүзнең ни дәрәҗәгә барып җитүен чамалыйсыңмы?

Әбүзәр. Ой, ой! Давыл, өермә, ут! Булыр, минем тинтәк этидән әллә ниләр чыгар.

Тәзкирә. Әнине әйт син, әнине! Урам себерәм дип авызын ерып тора бит. Шуны ишеткәч, Кәримҗан абый кара коелды.

Әбүзәр. Әти... күрмәгәндәй комагайланып, ике күзен тиң елтыратып аш теләнеп, гөмбә сорап утыра. Әнисә апага караган идем, ап-ак булган!

Тәзкирә. Тормышта тәмам артта калганнар икән!

Әбүзәр. Наданнар! Күгәргән тимерләр!

Тәзкирә. Талашларын без ишетмәсен дип чыгарып җибәрделәр дә тотынганнар инде алар чукышырга!

Әбүзәр. Әйләнеп кайтуга ук туры керәсе калган.

Тәзкирә. Җөйче яныннан кайткачмы? Безне ут алдады.

Әбүзәр. Ут сүндерелмәгән. Ишек бикләнмәгән. Сугышып милициягә эләкмәсәләр, яратырсың... Күрүгә, бер-берсен ошатмадылар алар.

Тәзкирә. Әтиең вак кеше икән!

Әбүзәр. Әниеңне әйткән дә юк! (*Пауза.*) Ике тиенең калдымы?

Тәзкирә. Соңгысын биреп киттем ич.

Әбүзәр. Ун тиен салырга туры килә.

Тәзкирә. Өегездә телефон булгач, син ул хәсрәтне белмисең. Сиңа гел ун тиен салып шалтыратам. Кайсы көнне илле тиенгә төшәсең син миңа.

Әбүзәр. Шатлан, арзанракка төшә башлармын.

Тәзкирә. Кайчаннан?

Әбүзәр. Кавышкач.

Тәзкирә. Кавышырсың, бар. Тагын кая шалтыратасың?

Әбүзәр. Өйгә бер шалтыратып карыйм да...

Тәзкирә. Кайтмагандыр ла ул!

Әбүзәр. Бер кайтырга тиеш бит. Тиеш!

Тәзкирә. Кайгы-мәшәкать килгәндә абзыйларга йөгерә торган иде, диден. Анда шалтыратып карадык...

Әбүзәр (*әрләп*). Ә менә син әниеңнең кая барырын да белмисең.

Тәзкирә. Беркая йөрмәгән әнинең ниен беләсең?

Әбүзәр. Чыгып югалган бит әнә!

Тәзкирә. Атаңны бел! Төн буена олаккан!

Әбүзәр. Әйдә Галияләргә шалтыратып карыйк. Ахирәтең, сине эзләп әнкәң шуларга кермәдеме икән?

Тәзкирә. Әни югалды дип ничек шалтыратасың?

Ярты төн җитеп килә.

Әбүзәр. Әти табылмый дип, ярты Казанны болгаттык.

Тәзкирә. Шуны да аңламагач... Синең әтиең ир кеше!

Әбүзәр. Анысы шулай икән.

Номер җыя.

Тәзкирә. Юкмы?

Әбүзәр. Дәшми, явыз! Җитмәсә ун тиенне йотты! (*Суккалап.*) Кайтып килер идем, җәһәннәмдә бит. Якынрак торсагыз, ичмасам...

Т ә з к и р ә. Торды диярләр. (*Пауза.*) Картларның кайдалыгын әйтсә, убыр-автоматның авызына ун тәңкә салыр идем.

Ә б ү з ә р. Конфликтның ничек тәмамланганын белер өчен, соңгы егерме бишлекне кызганмыйм. (*Кыланып.*) Әй, убыр-автомат, ишеттеңме?

Т ә з к и р ә. Соңгысы?

Ә б ү з ә р. Кызгану юк!

Т ә з к и р ә. Ә туй?

Ә б ү з ә р. Туй? Туй картның кесәсенә корт булып төшәргә тиеш иде.

Т ә з к и р ә. Туй... Күлмәгем дә өлгермәгән.

Ә б ү з ә р. Таңга өлгертәм диде бит. Кыландыргансың! Түше чуп-чуар, сәйләннәр... Ярамаган иде гадирәге! Җитмеш биш тәңкә!

Т ә з к и р ә. Комиссионкада сиксәнгә сатам мин аны! (*Сикереп тора.*) Әбүзәр, бәлки, алар килешкәндер?

Ә б ү з ә р. Килешсәләр, бергә булырлар иде. Өйдә. (*Номер җыя.*) Алмыйлар. Юк.

Т ә з к и р ә. Ишетәм. Тү-тү-тү итеп тора.

Ә б ү з ә р. Тү-тү дими, үтүт, ди, туйлар сезгә үтүт, ди.

Т ә з к и р ә. Ватып ташла шул комсыз автоматны!

Ә б ү з ә р. Аның ни гаебе бар?

Т ә з к и р ә. Гаеплене эзлибезме? Монда ул, монда. Син! Синдә гаеп!

Ә б ү з ә р. Чәнчелеп китсен иде күлмәге! Нигә чыгып китәргә иде сездән.

Т ә з к и р ә. Ә-ә, оста. Су башыннан болгана! Бу экәмәтләрне кем башлады? Планнарны кем чуалтты? Кем барын сүтеп-җимереп ташлады?

Ә б ү з ә р. Кире беткән, үте сытылган эти.

Т ә з к и р ә. Гаебеңне кешегә сыларга остарган син.

Ә б ү з ә р. Учакка утны син өстәдең. Әй, үпкәләгән булып кылана берзаман. Картларга аларга җай гына бир, хәзер үз чаналарына утырталар. Дөрес, ялгышлык белән мин кузгаттым. Син куерттың.

Т ә з к и р ә. Мин хатын-кыз, көчсез зат. Ир буларак вакытында туктат идең!

Ә б ү з ә р. Аз-маз хәйләләсәң...

Т ә з к и р ә. Нинди хәйлә? Нишләп хәйлә? Үзең алдакчы булгач, миннән адым саен ялган көтәсеңме?

Ә б ү з ә р. Эти янында, дим... Чүт-чүт кенә юхалансаң, җаеннан торсаң, гомергә сезгә аяк атламый иде ул.

Т ә з к и р ә. Үзең, агач тел... Чамалап кына сөйләшсәң...

Әбүзәр. Нәрсәм ошамады тагын?

Тәзкирә. Әни катына килеп...

Әбүзәр. Ямьсез сөйләштемме?

Тәзкирә. Түгел шул. Телен тешләгән дә тора шушы убыр-автомат күк йоклап! (*Автоматка күрсәтә.*)

Әбүзәр. Синең сыман теләсә ни бытылдарга тиеш идемме? Рига, имеш, Кремль больницасы... Ах та ух, ух та ах!

Тәзкирә. Мин, ичмасам, кирәген сөйләп калдым.

Әбүзәр. Үзең инде, үтердең.

Тәзкирә (*еламсырап кычкыра*). Кирәген, кирәген!

Пауза.

Әбүзәр. Тәзкирә, Тәзкирәм... Безнең шөрепләр тагын ычкынды. Гаҗәп! Әбүзәр белән Тәзкирә талашалар дисәң беркем ышанмас. Ике ел пар сандугач күк яшәдек тә хәзер талашабыз. Тәмләп ызгышабыз. Бер-беребезне чәйнәп ташларга әзер.

Тәзкирә. Син башлыйсың.

Әбүзәр. Шуңа гаҗәпләнәм дә! Тыела алмыйм. Әшем көйсезләнгәнне сизүгә, сине чокчыйсым, рәнҗетәсем, җылатасым килә.

Тәзкирә. Бәлки, алар хаклыдыр?

Әбүзәр. Кемнәр?

Тәзкирә. Әти-әниләр. Без чын кешеләр булып җитлекмәгәнбездер.

Әбүзәр. Һәр начарлыктан файда табарга өйрәник. Бүгенге көннән «Тормышта юкка-барга талашудан мәгънә чыкмый!» дигән гыйбрәт алыйк та тыныйк.

Тәзкирә. Риза.

Әбүзәр. Каһәр суккан картлар гаепле.

Тәзкирә. Синең этиеңә ничә яшь?

Әбүзәр. Күп инде! Илле бер!

Тәзкирә. Минем әнигә кырык өч... Әбүзәр, алар безгә ачу итеп качмадылармы икән?

Әбүзәр. Бергәме? Булуы мөмкин түгел.

Тәзкирә. Йокым да килә... Ничек табарга соң аларны?

Әбүзәр. Юкка-барга баш бирмәскә дип килештекме?

Тәзкирә (*такмаклап*). Гомер күзем алмам синнән, алтыным!

Әбүзәр. Авыр сүздән сак булырмын, якыным.

Тәзкирә. Кыенлыклар килсә әгәр, түзәрмен.

Әбүзәр. Кайгы-хәсрәтеңне, җаным, сөйрәрмен.
Тәзкирә. Күрәсеңме, кавышу көне туа?
Әбүзәр. Иң бәхетле кеше бүген кем була?
Тәзкирә. Мин!
Әбүзәр. Мин дә, мин дә!
Тәзкирә. Җаным, мин туңам.
Әбүзәр. Гафу ит. Ки минем пиджакны.
Тәзкирә (*иркәләнеп*). Үзеңә ни кала?
Әбүзәр (*кыланып*). Синең янда миңа болай да эссе!
Тәзкирә (*кыланып*). Алай димә, әллә мин тимер мичме?
Әбүзәр. Тын төн... Без кавыштык...
Тәзкирә (*сыенып*). Рәхмәт, бәгырем.
Әбүзәр. Син янда булганда йөрәк ярсулары онытыла.
Тәзкирә. Әйтерең, бармы...
Әбүзәр (*читкә тартылып*). Көләсеңме?
Тәзкирә. Син ачык авыз тутый кош булмасаң, без бүген пар аккоштай театрда утыра идек. Бәрхет креслоларда.
Әбүзәр (*чалбар кесәләрен актарып*). Театрда? Билетлар кесәдә иде. Юк. Монда да юк. Пиджак кесәләрен актар әле.
Тәзкирә. Мин ир кесәсенә кул тыгачак түгел.
Әбүзәр. Тишелсә?
Тәзкирә. Әллә оялмыйча кесә яматыр идеңме?
Әбүзәр. Акча коелып калмасын дисәң, ямарсың.
Тәзкирә. Ни өчен акча синең кесәдә йөрергә тиеш? Оста!
Әбүзәр. Һәр сүздән ызгышырга җай чыгып тора.
Тәзкирә. Тантаналы кичәбезгә дип алган билетларны югалткан да мырлый...
Әбүзәр. Торгач та алып карадым, барладым... Әллә өстәлдә калдырдыммы? Тукта! Менә бусы номер!
Тәзкирә. Төшереп калдырган.
Әбүзәр. Театрга шалтыратып карыйбызмы?
Тәзкирә. Шалтырат, сора. Безнең дүрт тәңкәлек билетлар анда җылап утырмыйммы, диген.
Әбүзәр. Аптыраганнан әйтәм.
Тәзкирә. Әгәр әни тагын ярты сәгатьтән кайтмаса...
Әбүзәр. Нишлибез?
Тәзкирә. Сине белмим, мин акылдан шашам.
Әбүзәр. Милициягә хәбәр итмичә ярамас.
Тәзкирә. Әтием билгесез югалды дип хәбәр ит, әнине телгә аласы булма.
Әбүзәр. Сорасам икесен дә сорыйм.

Т ә з к и р ә. Синең кире беткән этиең исеме белән янәшә йөрмәсен!

Ә б ү з ә р. Бая «үчегеп берәр яры китмәделәрме?» дидеңме?

Т ә з к и р ә. Уемнан кире кайттым. Әни туры җаваптан тайчана торган түгел. Гадел яшәде, әйткән сүзе туры булды.

Ә б ү з ә р. Минем әти кире! Салпы ягына берәр көлтә кыстырмасаң...

Т ә з к и р ә. Икесе дә кызу канлы! Бутадык без аларның башын.

Ә б ү з ә р. Менә нәтиҗәне кая китереп җиткердең!

Т ә з к и р ә. Аз беләбез икән әти-әнине! Бөтенләй белмибез дисәң дә ярый. Белсәк, кая китүләрен чамалар идек. Алар да бит җанлы кеше... Әнием шундый ягымлы, әйбәт, кече күңелле... Мин син тинтәккә ияреп кенә аны хурлап утырам.

Ә б ү з ә р. Ә минем әти? Тыйнак, сабыр, кулыннан килмәгән эш юк. Мин димәгән сулышы юк. Бер чакта сүземә каршы килми.

Т ә з к и р ә. Бәләкәй генә чирләсәм дә, әни төн йокысын йокламый...

Ә б ү з ә р. Минем әтине бөтен тирә-күрше ярата.

Т ә з к и р ә. Җылатасың инде! Әйдә, аяк оеды.

Ә б ү з ә р. Туңдыңмы?

Т ә з к и р ә. Әнә тегеннән ике кеше килә. Хулиганнар булмасын.

Ә б ү з ә р. Боксер янында куркасыңмы?

Т ә з к и р ә. Бүгенгә маҗаралар җитәрлек булды.

Чыгалар. Пауза. К ә р и м җ а н белән Ә н и с ә керә.

Ә н и с ә. Ниһаять, кайтып җиттек.

К ә р и м җ а н. Шулаймыни? Җәяү кайтыйк дип кыстагач, өемне күрә алмам, адаштырыр бу алабай дип шүрләп калдыгызмы?

Ә н и с ә. Булгандыр инде! Сүзгә керешеп киткәч, алары онытылды.

К ә р и м җ а н. Театрдан чыккан шәпкә сезне һич тыеп булмады, чабасыз гына.

Ә н и с ә. Алай ук булмагандыр ла?

К ә р и м җ а н. Сездә ут бар әле. Сүнмәгән.

Ә н и с ә. Ашыгуым урынлы булган, Тәзкирәм көтеп утыра.

К ә р и м җ а н. Аналар балалары янына ашыга.

Ә н и с ә. Сезнең хәтерегез искиткеч икән.

К ә р и м җ а н. Ә сез үтә сизгер җанлы.

Ә н и с ә. Безнең тәрәзәне онытмагансыз, шуңа әйтүем.

К ә р и м җ а н. Кызлы йорт! Тәрәз пәрдәләрегез онытырлык түгел. Мәк чәчәкләре чигелгән.

Ә н и с ә. И-и, яшь чагында күз бетереп утырылган инде. Кемгә кирәге булгандыр... Аруларын кояш ашый дип, җәйгә шушы искеләрне әләм.

К ә р и м җ а н. Сизгер күңелдән дә саксыз сүз ычкынды.

Ә н и с ә. Сөйләшеп өйрәнмәгәнгә ул, Кәримҗан ага.

К ә р и м җ а н. Пәрдәләрнең миңа ошаганын белгәч, хурларга тотындыгыз.

Ә н и с ә. Әй, шаяртасыз икән. Озак юандык, фикерем таркау. Балалар ни уйлап бетермәс!

К ә р и м җ а н. Мин аларның әллә ниләр уйлавын телим дә.

Ә н и с ә. Куркышып бетмәсәләр ярар да... Тора-тора шаккатам.

К ә р и м җ а н (*бик гаҗәпләнеп*). Шаккатарлык ук ни булды, Әнисә ханым?

Ә н и с ә. «Баш әйләнә» дип, өйдән чыгып кит тә, ярты төндә кайтып кер! Өйдә әйләнмәгән башлар әйләнерлек сәяхәт ясап кайт! Шулай озак йөртеп сез мине сынарга теләгәнсездер инде? Минем аша кызымны — Тәзкирәне?

К ә р и м җ а н. Андый ниятем дә бар иде, яшермим.

Ә н и с ә. Башка ниятләрегез дә булган икән! Анысын көтмәгән идем.

К ә р и м җ а н. Балалар янына керәбезме? Әбүзәр китмәгәндер әле.

Ә н и с ә. Икәүләшеп туп-туры барып керикме? Уңайсыз.

К ә р и м җ а н. Килешеп бетмәс дисезме?

Ә н и с ә. Ни әйтербез без соң аларга? Ни дип җавап бирербез.

К ә р и м җ а н. Башта чын күңелдән рәхмәт укырбыз.

Ә н и с ә. Ни өчен?

К ә р и м җ а н. Без дә яши беләбез икән! Күптәннән болай рәхәтләнеп күңел ачкан юк иде. Ял иттек! Бүген үземне кеше итеп, бәхетле итеп тойдым. Барган иптәшем яхшы кеше, ипле юлдаш булып чыкты. Вакыт узганы сизелми дә калды.

Ә н и с ә. Концертка барганны да әйтербез дисезме?

К ә р и м җ а н. Безнең дә заманча ял итә белүебез белән

мактанмый калалармы? Беләбез икән! Булдырабыз! Сез кичәдән канәгать түгелме?

Әнисә. Канәгать кенәме? Бик рәхмәт анысына. Танышлар очрамаса ярар дип, ут йотыбрак барган идем, Ходай саклады, диләрме?

Кәримҗан. Әйтәм җирле сулаган саен ирен арагыздан ялкын чыга иде, ут йотып утыргансыз икән. Ә мин, киресенчә, театрга бөтен танышларымның туплануын теләгән идем. Алданрак сизенгән булсам, бөтенесенә бушлай билет таратыр идем.

Әнисә (*бик аптырап*). Нишләп алай дидегез, Кәримҗан ага?

Кәримҗан. Көләләр! Монах дип тә, ертык балак дип тә, буйдакның күңеле уйнак, аягы юртак дип тә көләләр. Авыз ерудан туктап торырлар иде, ичмасам.

Әнисә (*тынычланыбрак*). Көлеп кенә калалармы, яучы да йөртәләрме?

Кәримҗан. Булгалады. Элегрәк Уфадан да килгәләделәр. Хәзер тындылар дисәң дә ярый. Яучылык миссиясе үземә күчте.

Әнисә. Алай дисез...

Кәримҗан (*кинәт*). Концерт без икәү булганга бик ошады, Әнисә ханым! Яшермим. Теге биюче кызны әйтегез сез, бөтерчек төсле әйләнеп китә, ничек егылмый, сәхнәдә очкын чәчрәтә бит, ут уйната.

Бию хәрәкәтләре ясый.

Әнисә. Сез үзегез дә биегән, ахры?

Кәримҗан. Барысы да булды инде, кыланмаган калмады. Аш пешереп кенә йөрсәм дә, флотта идем. Ресторанда эшли башлагач та түгәрәкләргә йөрдем...

Әнисә. Тормышыгыздан канәгать, алайса?

Кәримҗан. Барысы да булды дип ялганладым. Булмады. Иң кирәген җәлләде Ходай!

Әнисә. Бәхетнеме?

Кәримҗан. Түгел. Мәхәббәт булмады.

Әнисә. Алай да балаларны барлап чыгыймчы. Күңел тынычлансын.

Кәримҗан. Мин дә керәм.

Әнисә. Сезнең белән кайтып керү уңайсызрак, Кәримҗан ага. Гаеп итмәгез. Мин бит кыз анасы. Аннары, кинәт сүз ычкындырып ташларлык булмасын. Ирләрчә төгәл, үтемле итеп әйтерсез.

К ә р и м җ а н. Минем җавабым һаман әзер түгел, Әнисә ханым.

Ә н и с ә. Шул куркыта мине! Алар сездән төпле, ышанычлы җавап көтә. Сынатмыйк, Кәримҗан ага. Алар безнең сүзгә бик сусаганнар, озак көттереп сез шуңа ирештегез кебек.

К ә р и м җ а н. Шулайдыр дисезме, Әнисә ханым?

Ә н и с ә. Шулай булмыйча! Һаман да балалар бит әле алар!

Кереп китә. Кәримҗан ялгызы. Т ә з к и р ә белән Ә б ү з ә р керә. Кәримҗан яшеренә.

Ә б ү з ә р. Җылындыңмы бераз?

Т ә з к и р ә. Җылынуны да белгән юк. Туңмыйм мин. Әллә нәрсә эчтә калтырый.

Ә б ү з ә р. Монда хәлләр искечә калган.

Т ә з к и р ә. Өметсезме?

Ә б ү з ә р. Тәрәзәгездә ут. Ялганчы ут! Хыянәтче ут! Телефон исә авызына су капкан.

Т ә з к и р ә. Син тутырган ике тиеннәр аның тамагына тыгылгандыр.

Ә б ү з ә р. Әнә, песи генә йөри. Перес, дошман!

Т ә з к и р ә (*паузадан соң*). Соңгы вариант та дөрескә чыкмады.

Ә б ү з ә р. Кайсысын әйтәсең?

Т ә з к и р ә. Театр күптән ябылгандыр.

Ә б ү з ә р. Бармаган алар! Минем әти барамы? Хатынкызны җене сөйми аның. Күңеле мүкләнгән, зиһене бәсәргән. Беләсеңме, безнең әни нәкъ шуның өчен, хатын-кызга кырыслыгы өчен ташлап китмәдеме икән дип уйлыйм.

Т ә з к и р ә. Әни ят ир белән, кода буласы кешесе белән берәр яры чыгамы?.. Бигрәк тә төнгә каршы... Туң йөрәк! Эшеннән, себеркесеннән башканы белми. (*Пауза.*) Фикерләр уртак безнең, шунысына сөенәм.

Ә б ү з ә р. Әйдә, вокзал буфетына.

Т ә з к и р ә. Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?

Ә б ү з ә р. Анда кайнар кофе өзелми. Кофе дигәне болганчык су булса да, кайнарлыгы бар.

Т ә з к и р ә. Бер акылы юк икән әнинең!

Ә б ү з ә р. Әтине әйт син, әтине! Сакаллы сабый!

Т ә з к и р ә. Без дә тәҗрибәсез, беркатлы... Үзләренә булмаган акылны каян безгә бирсен алар? Ә без алардан берәр юньле сүз чыкмасмы дип өметләнгән булабыз. Көтәбез.

Әбүзәр. Көтми нишлисең? Җола шулай куша, гореф-гадәт.

Тәзкирә. Син гаепле! Син генә!

Әбүзәр. Ачык авыз булдым шул. Ачык авызга аңгыра күке очып керә.

Чыгалар. Качып торган җиреннән Кәримҗан чыга, тәмәке кабыза, Әнисәнең килгәнен дә абайламый.

Әнисә (*тынычсыз*). Сез тәмәке дә тартасыз икән.

Кәримҗан. Сезгә ошамаса хәзер ташлыйм?

Әнисә. Кич буе тартканыгыз күренмәгән иде.

Кәримҗан. Без бит сезнең белән әнә кайда идек... Икенче төрле дөньяда! Күңел кинәт кенә шомланып куйды. Сездә ни хәлләр?

Әнисә. Хаклы шомлангансыз, Кәримҗан ага, Аптырашта калдым — Тәзкирәм өйдә юк. Утны сүндермәгәннәр...

Кәримҗан. Шулаймыни? Берәр яры киткәннәрдер...

Әнисә. Язу калдырсалар ни булган?

Кәримҗан. Бик нык ашыкканнар, алайса, ут та сүндермәгәннәр!..

Әнисә. Шушы тирәдә уралсалар ла! Ут кайгысы түгелдер, беләм...

Кәримҗан. Ут кайгысы да, безнең кайгы да түгел аларда!

Әнисә. Кәефегез кырылмасын, Кәримҗан ага. Кайтыр. Сәгатькә карарга куркам, бусын яшермим. Соң бит, соң! Чак кына утырып тормыйбызмы? Үзем өчен дә борчылам, аның өчен дә... Әле шунысы куаныч, безне олыга санап киңәш сорадылар, хәер-фатихабызны өмет итәләр. Ипле балалар!

Кәримҗан. Хаталанасыз, Әнисә ханым. Белмәмешкә салынасыз дип әйтергә йөрәгем җитми, сез бит сизгер җан! Уенны читкә куеп сөйләшик: мин улымны, сез кызыгызны бөтенләй аңламыйбыз! Мохтаҗмы алар безнең сүзгә?

Әнисә. Нигә мохтаҗ булмасын? Әнә ич алар! Бергә!

Кәримҗан. Әнисә ханым! Күренмик аларга, качыйк.

Әнисә. Туктагыз әле, килешмәгәнне!

Кәримҗан. Үтенәм. Җавап әзер түгел. Төпле түгел. Килегез, менә монда посыгыз.

Әнисә. Тузга язмаганны да уйлап чыгара аласыз икән сез.

Яшеренәләр. Тәзкирә белән Әбүзәр керә.

Т ә з к и р ә. Җәзаларга, кызык итәргә кирәк аларны. Башка чарабыз юк.

Ә б ү з ә р. Кызыкны үзләре ясады алар монда!

Т ә з к и р ә. Бүген бөтенләй кайтмыйк. Ябышып җыласыннар! Безнең кемлекне мәңге онытмасыннар! Үзебезчә яшибез, теләгәнне эшлибез.

Ә б ү з ә р. Идел ярына төшәбез дә көймә астында кунабыз. Шулаймы? Каушама, Тәзкирәм! Алдан буфетка барып килик, аннары күз күрер.

Т ә з к и р ә. Атаң алдында саз камышы күк дерелдәп торасы булма.

Ә б ү з ә р. Туктыйсыңмы син мине чәйнәүдән, юкмы?

Т ә з к и р ә. Хатын-кыз кемне булса да чәйнәмәсә, теше үтмәсләнә.

Ә б ү з ә р. Ач кешенең ачуы яман, әйттерерсең әллә ни?!

Т ә з к и р ә. Әни пешергән шакмаклы токмачны ашамаган булдың, кыланчык.

Ә б ү з ә р. Теге таксиның шакмакларын чүпләп ашар дәрәҗәгә җиттем.

Т ә з к и р ә. Такси, такси!

Чыгып йөгерәләр. Ә н и с ә атылып чыга.

Ә н и с ә. Балалар, балалар!

Кәримҗан аны тотып кала.

К ә р и м җ а н. Туктагыз! (*Утыралар.*)

Ә н и с ә. Ни сөйләштеләр алар? Колагым томаланган... Нигә качтык без алардан? Оят бит, Кәримҗан ага? Ишетмим...

К ә р и м җ а н. Качып калганны аларга әйтмәбез. Башка бик күп нәрсәләрне дә әйтергә кирәк булмаган!

Ә н и с ә. Акыл бирегез, Кәримҗан ага. Кыз биреп караганым юк. Ятим-ялпыны туйга да бик чакырмыйлар. Чакырсалар барасы да килми.

Пауза.

К ә р и м җ а н. Туйны искә төшереп йөрәгемне тагын бер ярсыттыгыз, Әнисә ханым!

Ә н и с ә. Томана баш, гел кирегә сукалап утырам, ахрысы, мин.

К ә р и м җ а н. Хәзерге туйларда ата-ананың урыны кайда икәнлеген беләсезме?

Ә н и с ә. Туйда түрдә дә утырмагач аның ни яме бар?

К ә р и м җ а н. Иң читтә, посырык почмакта утыралар алар хәзер.

Ә н и с ә. Нишли алар анда?

К ә р и м җ а н. Куркып утыралар.

Ә н и с ә. Балалары нишли?

К ә р и м җ а н. Тып-тын гына шешәләрне бушаталар да күз тонганчы биилəр. Музыка, стерео авазларыннан колаклар тоташ сызлый. Африка урманнарында әйбәт яңгыраган барабан тавышлары безнең тәбәнәк түшәмнәрне дер селкетә. Кодалар нәкъ шул көнне генә очрашканга беркем берәүне танымый. Уртак сүз юк. Мәхшәр! Туйларда, йөзәрләгән кеше булудан файдаланып, арага ятлар кереп тула. Егетен кыздан аерырлык түгел, ялдай чәчләр җилферди, чалбар балаклары капчыктан киңрәк. Ана кызны, ата улны белмичә тыпырдыйлар, куллар менә болай селкенә (*күрсәтә*), корсакны алга чыгарып, тезне бөкләп биилəр-биилəр дә манма су булгач, җиләскә чыгып тәмәке пыскыталар. Күп күзәтергә туры килә миңа туйларны. Һәркем муеннан бурычка батып ярты шәһәрне чакырырга, танышбелешен уздырырга тырыша. Ата-аналар тәмам бөләләр, яшьләр бер тиенсез кала, бәйрәм үтеп тә бетми, туй күлмәген, туй бүләкләрен тотып комиссионкага чабалар...

Ә н и с ә. Кызлары да тартамы?

К ә р и м җ а н. Авызларында беләк буе икешәр сигарет.

Ә н и с ә. Безнең балалар андый түгел.

К ә р и м җ а н. Шулай дип ихлас күңелдән ышанып әйтәсезме? Мода! Мода чире тинтерәтә алар башын!

Ә н и с ә. Балаларга шушы кыйссаны сөйләп күрсәтәбезме? Җавабыбыз шул буламы?

К ә р и м җ а н. Сез ана кеше. Алдан сез әйтеп карагыз.

Ә н и с ә. Беренче сүз ир ягыннан. Табигать шулай бойерган.

К ә р и м җ а н (*уйчан*). Әйтсәк, сүзне бүген әйтеп калабыз. Иртәгә безнең базар төшә. Кадеребез дә, кирәгебез дә калмый.

Ә н и с ә. Күңелегездә тагын ни бар, Кәримҗан ага?

К ә р и м җ а н. Мин аларга өйләнешергә иртә дип саныйм.

Ә н и с ә. Ничек? Ягъни сезгә минем кызым... Нигә яучы булып килдегез, алайса? Ничек була ди бу?

К ә р и м җ а н. Сез дә шул фикердә түгелмени?

Ә н и с ә. Белмим, бәлки... Әмма сезнең хөкемегез үтә авыр, бик кискен хөкем.

К ә р и м җ а н. Өлгермәгән алар. Үсеп, пешеп җитмәгән. Дөрес, җимешнең вакытында өлгереп җитмәвенә бакчачы да гаепле. Миндә дә гаеп зур, сездә дә юк түгелдер.

Ә н и с ә. Ялгыз анага кем акыл бирсен дә, кем өйрәтсен. Булгандыр инде...

К ә р и м җ а н. Безнең кулда иң соңгы, иң актыккы форсат. Әгәр бүген йомшап китеп, алар капризына баш бирсәк, иртәгәдән безгә сан бетә. Тагын бер тапкыр уйлап-талпынып карыйк.

Ә н и с ә. Максат?

К ә р и м җ а н. Безнең гомер намуслы хезмәт белән уза. Ил өчен, көнебез өчен, балалар өчен берни кызганмадык, барын бирдек. Ә алар безне юк дип исәпли. Нуль без алар өчен! Кеше туйларында почмакка сеңсәм дә, үз баламның туенда мин түрдә утырырга телим. Түрдә! Бармы минем шуңа хакым?!.

Ә н и с ә. Сезгә минем кызым ошамаган!

К ә р и м җ а н. Миңа улым ошамады.

Ә н и с ә. Шулай инде, шулай... Көн кебек ачык. Мин моны беренче сүзегездән сизендем.

К ә р и м җ а н. Хәзер җәберсенгән ана йөрәге сулкылдый башлады.

Ә н и с ә. Әтисез бала беркая да сыймый! Әнисе урам себерүче. Хәзер бит, нәкъ иске замандагы кебек, алдынартын чамалап өйләнәләр. Җайлырак та булсын, майлырак та. Фатирын да уйлыйлар, төшемле урынны да онытып бетермиләр. Минем Әхмәтханым сугыштан алган яраларыннан савыгып өлгерә алмады. Үләр алдыннан: «Әнисә, кызыбызны рәнҗетмә, рәнҗеттермә дә!»— дип инәлде мәрхүмкәем... Килдегез дә рәнҗеттегез менә! Шикләнгән идем аны!

К ә р и м җ а н. Шикләнмәдегез, Әнисә ханым, хәзер генә уйлап чыгардыгыз.

Ә н и с ә. Түгел, түгел! Сез әзер җавап белән безнең ишекне кактыгыз. Тик нигә мине газапларга иде? Нигә арага мине катнаштырырга? Болай да рәхәтне тансыклап гомерем узды... Нигә җанны котыртып театрга өндәргә иде? Кафеда морожный ялап утырган булдык бит җитмәсә!.. Кодалашабыз, янәсе. Уф, үләм... Бөтен шәһәр аша җәяү алып кайтты... Барам мин сантый ияреп! Нигә сүзне өйдә чакта, балалар алдында ук әйтмәдегез?

К ә р и м җ а н. Җавабым әзер түгел иде. Ихлас.

Ә н и с ә. Оялмыйча төн саклап тагын сезнең янга чыктым бит. Хурлык, оят! Күреп калсалар, уф, үләм!..

К ә р и м җ а н. Әнисә ханым!

Ә н и с ә. Артыгы кирәкми. Хушыгыз.

К ә р и м җ а н. Бердәнбер баламның иң якты теләгенә каршы килүнең никадәрле читен икәнлеген аңлыйсызмы?

Ә н и с ә. Алайса, минем җавапны да ишетегез: риза идем! Риза! Улыгыз ошады миңа. Ә хәзер... икәүләшеп җирдә тәгәрәп ялынсагыз да кызымны бирәчәк түгел. Үз ише табылыр!

Чыга башлый.

К ә р и м җ а н. Әнисә ханым, өегез бу якта.

Ә н и с ә. Хәзер миңа барыбер! Ике дөнья бер.

Алды-артлы чыгалар. Ә б ү з ә р белән Т ә з к и р ә керә.

Ә б ү з ә р. Көндез сөйләгән әкиятеңне хәтерлисеңме?

Т ә з к и р ә. Монда син... иртәдән бирле әкият белән сыйлыйсың.

Ә б ү з ә р. Патша, дидең. Аның өч улы булган. Төпчек малай әтисенең сүзен тотып бакага өйләнгән... Син егетнең түземсезлеген генә хәтерлисең, башкасы сиңа искән җил!.. Әтисенә карышмаган егет — баканы яр иткән!

Чыгалар. Ә н и с ә узып бара, К ә р и м җ а н да ияреп килә.

К ә р и м җ а н. Мохтаҗ түгел алар безнең хәер-фатихага!

Ә н и с ә. Минем кызым намуссыз димәкче буласызмы?

К ә р и м җ а н. Бүген алар теләгенә ансат кына юл куйсак, «теге карт җүләрләрне тагын утырттык!» дип мактаначак кына алар.

Ә н и с ә. Җитте.

К ә р и м җ а н. Күрәм, без уртак язмыш кичергәнбез. Сезгә карыйм да, япа-ялгыз үткәргән көннәремне кызганам. Кар астында кайнар чишмәләр ургылып агып яткан лабаса!.. Күңелләребезне кар басмаган икән, анда кайнар дәрт сакланган. Ә без алар өчен яшәп, гомеребезне аларга багышлап үз дәртебезне сизми килгәнбез. Алар өйләнешкәч, без нишләрбез?

Ә н и с ә. Ни язса, шул булыр.

К ә р и м җ а н. Без аларга кирәк түгел. Әйе, бәбәйләре булгач килерләр! Дача салып бирербез. Суыткыч алырбыз. Үткәне дә аларга, хәзергесе дә, киләчәге дә!

Ә н и с ә. Язмышың шулай икән, нишлисең? Гомергә ялгыз булдым. Кеше күңел ачканда, бәйрәмнәрдә аерата кыен иде. Хатын-кыз, кояш яратса да, ир күләгәсендә генә чәчәк ата.

К ә р и м җ а н (*таң калып*). Сез аны да бәяли аласызмы? Менә бит сез нинди бай күңелле! Янәшәмдә генә, бер үк шәһәрдә нинди хатын ялгыз гомер кичергән... Әнисә ханым, кадерлем, чыгыгыз мина кияүгә!

Ә н и с ә. Сез ни дидегез? Ни әйттегез сез? Ничек? Минме? Ай!

К ә р и м җ а н. Балаларга әзерләгән җавабым шул. Әгәр ризалык бирсәгез, мин аларны момент эзләп табам. Курыкмагыз, алар нык, егылып китмәсләр.

Ә н и с ә. Мин тәрбия чарасы буларак сезгә кияүгә чыгарга тиешме? Үзебезнең дөньяда барлыкны, тормышның безнең өчен дә кадерле икәнлеген раслау өченме?

К ә р и м җ а н. Юк, Әнисә, яраттым мин сезне. Күңелегезгә тирән кердем, барын аңладым.

Ә н и с ә. Сез бик игътибарлы, кече күңелле. Уйларыгыз якты.

К ә р и м җ а н. Гомер юлларыбыз уртак, язмышыбыз бер. Бәхетебез дә бергә булсын.

Ә н и с ә. Кәримҗан ага!

К ә р и м җ а н. Шулай итик, Әнисә җаным!

Ә н и с ә. Бөтен урам, бөтен шәһәр бездән егылып көләр! Аллам сакласын, драматурглар ишетсә, комедия язарлар!

К ә р и м җ а н. Бөтен урам, бөтен шәһәр, Татарстан сезнең зирәклектән егылып көнләшәчәк.

Ә н и с ә. Гомер заяга уза, Кәримҗан ага. Җан җылый...

К ә р и м җ а н. Ризамы?

Ә н и с ә. Риза, Кәримҗан ага.

К ә р и м җ а н (*кочаклап*). Әнисә, бәгырем! Нигә иртәрәк килмәде бу бәхет?

Ә н и с ә. Әле дә соң булмас. Рәхмәт, мине терелттегез.

К ә р и м җ а н. Ә сез мине! Төптән уйлаганда, пар килгәнбез без. Гаҗәеп тормыш корып җибәрербез.

Ә н и с ә. Мин риза, Кәримҗан ага, мең кат риза!

К ә р и м җ а н. Бәхетем минем!

Ә н и с ә. Кадерлем!

Үбешәләр.

Ә н и с ә (*кинәт айнып*). Ә балалар? Балалар ни әйтер? Бу хәбәрне аларга ничек белдерербез? Юк, юк, Кәримҗан ага. Оят. Үлем җиңелрәк.

К ә р и м җ а н. Мине ошатмадыгызмы?

Ә н и с ә. Үзегез әйткән безнең күңелләрдәге кайнар чишмәләр кар астында калсын әйдә. Кузгатмыйк без аларны.

К ә р и м җ а н. Балалар өчен тагын бер тапкыр корбан булабызмы?! Бәхетебездән баш тартабызмы? Кадерле Әнисә ханым, ахыр чиктә шул җавапны бирәсегезне белдем. Ярый, шулай калсын. Әмма алардан да җитдирәк, акыллырак тормыш таләп итәргә хакыбыз бармы безнең? Бар!

Ә б ү з ә р белән Т ә з к и р ә керәләр.

Т ә з к и р ә. Әни!

Ә б ү з ә р. Хәерле төн, әти.

К ә р и м җ а н. Без театрда идек. Гаҗәп шәп концерт карадык. Аннан кафега кердек. Кичке кафе ифрат ошады безгә. Тын гына музыка яңгырый. Алтын балыклар йөзә. Морожный ашадык, шампан шәрабе эчтек. Аннан кәефләнеп кенә җәяү кайттык. Кичебез соң дәрәҗәдә чибәр узды.

Т ә з к и р ә. Әнием, чынлапмы?

Ә н и с ә. Хәзер, кызым, хәзер...

Ә б ү з ә р. Кичке кафе?.. Шампан? Җәяү кайтулар... Бусы инде... ай-һай, әти.

К ә р и м җ а н. Их, Әнисә ханым, ышанмадылар. Эшкә ярамый торган иске чиләккә саныйлар безне.

Т ә з к и р ә. Ышанмыйбыз.

Ә н и с ә. Хәзер, кызым, хәзер. Кәримҗан аганы тыңлап бетер.

Ә б ү з ә р. Монда бер хикмәт булган!!

К ә р и м җ а н. Күңелле икән парлашып йөрүләр!.. Очраганнар көнләшеп кала. Борылып-борылып карыйлар. Бергә булганда кич тә бөтенләй үзгә, дөнья да киң, күк тә якты, ризык та тәмле икән. Рәхәт икән бергә булулар!

Ә б ү з ә р. Әти, тел төбеңне аңладым.

Т ә з к и р ә. Рәхмәт, Кәримҗан ага.

Ә б ү з ә р. Әти диген!

Ә н и с ә. Ашыкмагыз, балалар, чүегез.

К ә р и м җ а н. Әнисә ханым белән мин дә заманны бик яхшы аңлыйбыз икән. Пар булып гомер кичерә алыр идек... Ләкин, сезнең хакка, сез канәгать булсын өчен бәхетебездән баш тартып килгәнбез. Кызганычка каршы, безне, хезмәтебезне аңларлык лаеклы ул-кызлар үстерә белмәгәнбез. Барын үлчәгәч, кат-кат сөйләшкәч, ныклап аңлашкач, сезгә өйләнергә чак кына иртәрәк дигән карарга килдек. Шулай бит, Әнисә ханым?

Ә н и с ә. Бик шулай, Кәримҗан ага.

К ә р и м җ а н. Без сезгә бер-берегезне сынау мөмкинлеге бирәбез. Нәкъ бер елдан, шушындый матур язда, чибәр җылы кичтә кавышырсыз... Кар астында кайнар чишмәләрнең нигә яшеренеп калганын белгәч кавышырсыз!..

П ә р д ә.

*1975—1976*
*Казан*

# *Шамил Усманов*[1]

*Өч пәрдәле героик драма*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Куйбышев — Самарада ревком секретаре һәм губерна Башкарма Комитеты председателе.
Шамил Усманов — татар батальоны комиссары.
Кариб Хәйруллин — татар батальоны командиры, элекке вахмистр.
Мәхмүт Урманаев — хәрби белгеч, элекке поручик.
Зәкия — шәфкать туташы.
Хәйрүш — карт гвардеец, элекке крестьян.
Таҗетдин — озын гвардеец, элекке эшче.
Сәгъдетдин — авыл карты, 55 яшендә, гвардеец.
Сәкинә — асрау кыз, хәзер шәфкать туташы.
Гөлҗамал — аның әнисе, пешекче.
Сары бай — Оренбург бае.
Сәхи — аның улы, кызылгвардеец.
Каюм — гармунчы гвардеец, моряк.
Сакаллы гвардеец.
Күшәүче гвардеец.
Садрый Ваһапов — аклар капитаны, шпион.
Телеграфчы кыз.
Сакчы.
Элемтәче.
Белевич — мадьярлар батальоны командиры.
Лайош — мадьяр солдаты.
Әптери — гвардеец.
Мулла.
Мыеклы казак.
Сары чәчле ханым.
Кара чәчле ханым.
Хәсән — аклар ягыннан чыккан солдат.
Кара бай.
Үсмер гвардеец.

Кызыл гвардеецлар, шәһәр халкы, анархист, намазга килүчеләр, бала-чага, хатын-кыз һәм башкалар. Вакыйга 1918 елда Оренбург шәһәрендә һәм Оренбург далаларында бара.

[1] Бу пьеса Альберт Яхин белән бергә язылды.

# ПРОЛОГ

1918 ел. Самара. Губерна Башкарма Комитеты бинасы. Почмакта аппарат янында телеграфчы кыз утыра. Аның янына Башкарма комитеты председателе Валериан Владимирович Куйбышев килә. Ул зифа буйлы, зәңгәр күзле, мул чәчле утыз яшьләрдәге чибәр кеше. Ярым хәрби киемнән, хәрәкәтләре салмак.

Куйбышев. Арыдыгызмы, кадерлем?

Телеграфчы. Билгесезлек йончыта... Бөтен җирдә аклар. (*Аппаратын күрсәтеп.*) Безнең Самара тиздән уртада калачак. Давыл астындагы утрау кебек...

Куйбышев. Мәскәү җавап бирмиме?

Телеграфчы. Көтәм, иптәш Куйбышев.

Куйбышев. Әйе, давыл көчле булачак!.. Ләкин без бирешергә уйламыйбыз...

Телеграфчы. Билгесезлек кимегән төсле булды! (*Көлә.*)

Куйбышев. Нигә?

Телеграфчы. Шундый камалышта, шундый дәһшәтле көннәрдә губерна Башкарма Комитеты председателе шулай уйлый ала икән, мин тыныч...

Куйбышев. Революциягә ышанам, бары шул гына!

Аппарат эшли башлый, лента сузыла, кыз иҗекләп укый.

Телеграфчы. Сезне Оренбург губкомы сорый. (*Укый.*) «Ашыгыч яр-дәм бул-маса, Орен-бург-ның хә-ле чамадан тыш а-выр».

Куйбышев (*лентаны алып*). Хәле авыр... Башта Самара, Сызрань, аннары Казан, Мәскәү...

Телеграфчы. Оренбург сездән җавап сорый, иптәш Куйбышев.

Куйбышев. Җавапны бераз көтәргә кушыгыз. (*Пауза.*) Әйе, Оренбургның гына түгел, революциянең хәле кыенлашты.

Телеграфчы (*шатланып*). Иптәш Куйбышев, телеграфта Владимир Ильич!

Куйбышев (*тиз-тиз телеграфчы, янына барып җитә, әйтеп тора*). Иптәш Ленин, дутовчылар гаскәр туплап яңадан баш күтәрделәр. Алар Советка теләктәш кешеләрне кырып-үтереп, бала-чагаларны суеп, даланы канга батырдылар. Оренбург хәл эчендә. Моңа кадәр бирелгән ярдәм генә җитми. Бүгенгә үзебезнең хәлебез дә мөшкел. Ак чехлар ябырылып Самарага якынлашты, контрреволюция баш күтәрә!

Аппарат бер секунд кына тик тора да эшли башлый.

Т е л е г р а ф ч ы. Владимир Ильич сөйли! (*Укый.*) «Оренбургта Урал Кызыл гвардиясенең төп көче җыйналган. Аларны таркату революция алдында зур җинаять булыр иде. Ул көчне саклап калу безнең бурыч. Мөмкин булган ярдәмне оештыруыгызны үтенәм. Ләкин ул Самараны саклауга зыян китермәскә тиеш».

К у й б ы ш е в. Тырышырбыз, иптәш Ленин.

Аппарат тына. Тагын тавыш бирә. Ул почмак караңгылана. Куйбышев яктыга, уртадагы өстәл янына килә. Ишектә с а к ч ы.

С а к ч ы. Сызраньнан Шамил Усманов килде, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Чакырыгыз үзен. Мин аны көтәм.

С а к ч ы. Яхшы.

Чыга. Гаскәриләрчә төз атлап, Ш а м и л  У с м а н о в керә.

Ш а м и л. Чакыруыгызны алдым, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Узыгыз, утырыгыз, иптәш Усманов. (*Үзе Шамил каршысына бара, кулын бирә, җилкәсеннән дусларча кагып, өстәл янына алып килә. Өстәлнең алгы ягындагы кара-каршы көрсиләргә утыралар. Куйбышев елмая.*) Дөресен әйтим, революционер Шамил Усмановны мондый итеп күз алдына китермәгән идем. Сезгә ничә яшь соң, туган?

Ш а м и л. Унтугыз тулып үтте.

К у й б ы ш е в. Сызрань совдепы председателенә унтугыз тулып үттемени инде?

Ишектә с а к ч ы.

С а к ч ы. Труба заводыннан вәкилләр килде, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Залга озата торыгыз.

Сакчы чыга.

Ш а м и л. Мин Казан хәрби округы Советы члены, Сызрань ревкомының секретаре да.

К у й б ы ш е в. Титулларыгыз патша генералларыныкыннан бер дә ким түгел, алайса?

Ш а м и л. Ким түгел, Валериан Владимирович!

К у й б ы ш е в. Димәк, сезнең турыда легендаларны юкка гына чыгармыйлар?

Ш а м и л. Бәет турында әйтәсездер? Ялган ул, иптәш Куйбышев. Үз абыйсын атып үтерде дип, авылдашлар бәет чыгарган. Ләкин, асылда, ялган ул! Туганнарым арасында революция дошманнары юк. Сүз ак офицер, чы-

бык очы, тал башы кебек кенә кардәш турында бара. Гурьевта фабрикант Акчуриннар өенә тикшерергә кертмәскә маташа. Үтсәгез, минем гәүдә аша гына, ди...

Куйбышев. Һәм шулай булды дамы?

Шамил. Гвардеецларның берсе түзмәде...

Куйбышев. Ә бәетне җитәкче иптәш турында иҗат иткәннәр! Менә шулай... Массалар белән җитәкчелек эшенә алынган кеше үзенең ничек яшәве турында тирәнтен уйланырга тиеш. Бигрәк тә менә хәзерге кебек кыен вакытларда, иптәш Усманов! Бер якта уянып килгән халык массалары, икенче якта без — большевиклар. Масса белән җитәкче мөнәсәбәтләре ифрат дәрәҗәдә җитди мәсьәлә. Ул гомер-гомергә шулай булып барачак. Шул турыда уйлаганыгыз бармы?

Шамил. Тормыш үзе мәҗбүр итә, иптәш Куйбышев.

Ишектә сакчы.

Сакчы. Тимерьюлчылар килде, иптәш Куйбышев.

Куйбышев. Залга керә торсыннар. (*Сакчы чыга.*) Мин сезне Оренбургка җибәрергә уйлыйм.

Шамил. Оренбургка?

Куйбышев. Ак чехлар ярдәмендә дутовчылар зур көч җыйдылар. Төрле шәһәрләрдән Оренбургка чигенгән кызыл отрядларның хәле кыл өстендә. Без аларга ярдәм итә килдек, ләкин бу аз! Бер полкны Мәскәүдән Владимир Ильич җибәрде. Бу да җитенкерәми!

Шамил (*торып баса*). Миннән нәрсә таләп итеҗә, иптәш Куйбышев?

Куйбышев. Оренбург тирәсендәге татар крестьяннарын революция көрәшләренә ныграк тартасы иде. Аларның күбесе теләктәшлек күрсәтә. Шуларны оештырырга, җитәкләргә, сугыш кырларына алып чыгарга сыналган иптәшләр — татар большевиклары кирәк. Нәрсә эшләргә кирәклеген әйтү кыен, һәр очракка әзер өлгеләр табып булмас, әмма үзегезнең бар булганыгыз, һәр хәрәкәтегез, сүзегез, шәхси тормышыгыз белән эшче-крестьяннарга, кызыл гвардеецларга большевик-революционерның нинди булырга тиешлеген күрсәтегез. Мөгаен, хәзергә иң кирәге шулдыр. Һәм, миңа калса, бик аз да түгел бу!

Шамил. Мин риза, Валериан Владимирович.

Куйбышев. Сезнең юл бик-бик кыен булыр... Аклар чолганышын үтү тәвәкәллек һәм акыл сорый. Татарлар арасында эшләрлек кыю, тапкыр егетләрне сайлагыз. Үз урыныгызга кемне тәкъдим итәсез, анысын да уйлагыз. Сезгә юлдашлар итеп берничә тимер юлчы һәм

нәни генә состав бирербез. Әзерлек өчен ярты көн вакыт җитәме?

Шамил. Тырышырбыз, иптәш Куйбышев. Китәргә мөмкинме?

Куйбышев. Хуш, Шамил. Хәерле юл.

Шамил. Хушыгыз, иптәш Куйбышев. (*Чыга.*)

Куйбышев. Син монда да бик кирәк, Шамил Усманов! Ләкин бүтән чара юк, унтугыз яшьлек юлбашчы! Оренбург бездән ярдәм көтә!

Сакчы керә.

Сакчы. Чакырылган кешеләр җыелып бетте, иптәш Куйбышев.

Куйбышев. Бик яхшы! Әйдәгез!

Чыгалар. Пәрдә төшә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Оренбург. 1918 ел. Июнь ае. Эссе көн. Кәрвансарай ишегалды. Сарай почмагына кызыл әләм элеңгән. Парадный ишектән алдарак кызыл эскәтер җәелгән өстәл. Берничә урындык. Ишек өстенә чуарлап: «Мөселман кардәшләр, кызыл гвардиягә язылыгыз!» — дип сырланган. Җирдә кәгазь кисәкләре, төрле чүп-чар ауный. Байрак бер җилферди, бер сүнә. Кәрвансарай ишегалдында кызыл гвардеецлар. Кайсы ята, кайсы йөреп тора, өс-башлары өтәләнгән берничә кеше карта сугалар.

Арткы планда шәһәр. Кәрвансарайга терәлеп мәчет тора. Зәкия өстәл янындагы урындыкта утыра, язу-сызу белән мәшгуль. Мәхмүт өстәл тирәли йөренә. Өстендә бераз таушалган хәрби кием, фуражкасына зур кызыл бант таккан. Вакыт-вакыт көмеш чылбырлы сәгатен чыгарып карый. Үтеп-сүтеп йөргән гвардеецлар очраганда чыраен сыта. Ашыгып, шпорларын шалтыратып, Кариб Хәйруллин кайтып керә.

Кариб (*өстәл янына барып баса*). Приказ алынды, дуслар, татар батальоны бүгеннән сугышка керә! Аллюр —алга!

Шау-шу, кычкырган, хуплаган тавышлар. Кариб янына үсмер гвардеец килә.

Үсмер гвардеец. Кайттыңмы, Кариб абый?

Зәкия (*сикереп тора*). Ур-ра! (*Кәгазьләрне күрсәтә.*) Хәзер күчереп бетерәм, Кариб абый.

Мәхмүт (*тирә-яктагы шау-шуны яратмыйча тыңлап тора*). Штабта җүләрләр утырамы әллә? (*Зәкиягә.*) Кайда ул батальон? Татар батальоны кайда, Зәкия туташ?

З ә к и я (*исемлекне Карибка сузып*). Менә ул батальон! Дүрт йөз туксан тугыз кеше теркәлгән.

М ә х м ү т. Дутовның кавалериясенә, пулеметларына, бронемашиналарына шушы кәгазь каршы тора алса, сез кодрәтле алла, Зәкия туташ.

З ә к и я. Безнең якта дөреслек, идея.

М ә х м ү т. Ертык чалбар балаклары, яланаяклы гвардеецлар, ун кешегә бер винтовка...

К а р и б (*исемлектән башын күтәрә*). Син, Мәхмүт, батальонның хәрби белгече. Безнең өскә нинди бурыч йөкләнүен дә сорамыйсың.

З ә к и я (*канатланып*). Һөҗүмгә күчәбезме, Кариб абый?

Ү с м е р г в а р д е е ц. Әллә һөҗүмгә үк?!

М ә х м ү т. Ачуланмагыз, Кариб, барын да аңлыйм. Татар батальоны дип аталган, әле борынлый гына башлаган толпага сугышчан задание бирелә икән, бу инде итәккә ут капкан дигән сүз.

К а р и б. Хәл авыр. Аны берәү дә яшерми. Штабта да беләләр. Безнең әзерлек юк, корал аз. Әмма гвардеецларга кара, сугышка дип атлыгып торалар. Күбесе аклар тарафыннан кыерсытылган кешеләр.

М ә х м ү т. Аннан ни мәгънә?

З ә к и я (*Мәхмүткә, ачу белән*). Революционермы сез, җылак курсисткамы?

М ә х м ү т. Барыннан да элек, мин хәрби белгеч. Батальон беренче сулышында ук тар-мар ителгәч, кем җавап бирер?

К а р и б. Постой, постой!.. Ә син тар-мар иттермә! Шашки во-он! Ку ак казакны җәһәннәмгә!

М ә х м ү т (*нәзакәт белән*). Гафу сорыйм, Зәкия туташ. (*Карибка*.) Кариб, сез мине Оренбург фронтына чакырганда ниләр гәпләштек? Ызаннан башлары чыкмаган тузанлы агайларны сөреп, һәлакәткә алып барырга мин вәгъдә бирдемме? Бирегез миңа вакыт, мин менә шушы мужиклардан менә дигән гаскәр ясыйм. Бер ел, юк икән, ярты ел вакыт бирегез.

К а р и б. Ах, вакыт кирәкме сиңа? Вакыт!.. Оста... Батальон сугышка бүген керергә тиеш. Губком вакытлыча Оренбургны калдырып чыгарга карар кылды.

З ә к и я. Сугышмыйча-нитмичә чигенәбезме?

К а р и б. Канлы көрәш фронтларында йончыган кызыл отрядларны эшелоннарга төяп шәһәрдән озатыр өчен ике көн вакыт кирәк. Без, яңа, свежий батальон, Дутовны ике көн Сакмардан уздырмый торырга тиеш.

М ә х м ү т. Ә ни өчен именно без?

К а р и б. Башка отрядлар сугышта йончыганнар, яралылар күп. Без аларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиешле. Аңлашылдымы? Әзерләнегез, шашки вон, и походка! Быргычы, алга!

Хуплау, дәртләндерү тавышлары, кемдер гармун сызып куя.

З ә к и я. Ишетәсезме, элекке поручик әфәнде, походка!

М ә х м ү т. Зәкия туташның хисләре аңлашыла... Әмма ләкин герман фронтында булган, ике тапкыр яраланган, газ белән агуланган, сугышның каһәрен җилкәсендә татыган вахмистр Хәйруллинның болай сөйләве...

К а р и б. Ялгышасың, Мәхмүт... Мин күптәннән вахмистр түгел инде. Революционер, большевик мин. Оренбург далалары синең поручиклык тутыгын да кырып чыгарыр, чарлар, күрерсең.

З ә к и я (*Мәхмүткә*). Ә мин сезгә ышанган идем...

М ә х м ү т (*наз белән*). Без икәү ничек тә аңлашырбыз.

К а р и б. Дутовчылар Сакмар күперенә якынлашканчы далага үтеп чыгарга да аларны шунда бик шәпләп пешерергә кирәк!

М ә х м ү т. Батальон бу хәлендә ике көн түгел, ике сәгать тә каршы тора алачак түгел.

К а р и б. Ә без аны кызыл гвардеецларның үзләреннән сорыйбыз. (*Кычкырып.*) Иптәшләр! (*Кызыл гвардеецлар берән-сәрән алар янына җыелалар.*) Иптәшләр! Безнең командование вакытлыча Оренбургны калдырып торырга булды.

Гвардеецлар арасында ризасызлык тавышлары.

— Ничек, сугышсыз-нисезме?
— Урам тулы кызыл этрәт!
— Һай, эттәгенәсе!

К а р и б (*дәвам итеп*). Без үз гаскәребезнең чигенүен тәэмин итәргә тиешле. Йә, ничек, Дутов алдында махы бирмәбезме?

Гвардеецлар җиңнәрен сызганып кычкыралар.

— Кырабыз без аларны!
— Җир күмере ясыйбыз!

М ә х м ү т. Казаклар яхшы коралланган. Өйрәтелгән. Бер полклары фәкать офицерлардан гына тора.

Б е р г в а р д е е ц. Укытабыз әфисәрнең арт сабагын!

Көлешәләр. Тавышлар.

— Ур-ра!

— Ак әтәчләрнең муенын борабыз!

— Татар бар җирдә хәтәр бар.

Бер гвардеец (*Мәхмүткә.*) Иптәш командир, шул аклар көчле дә көчле дисез, кораллары шәп дисез, әнә йөз кешелек әтрәт Сызраньнан чыккан да, акларны кыра-кыра, күпме җир үтеп, Ырынбурга килеп җиткән. Дөресме икән шул?

Кариб (*шатланып*). Рас, иптәшләр. Әйтергә өлгермәдем, биш пулемет белән коралланган отряд, Куйбышев боерыгы буенча, аклар бөҗрасын өзә-өзә, монда чыккан. Үзләре барысы да татарлар икән. Штабта әйтеп тордылар, алар да безнең батальонга кушылачак.

Гомуми җанлылык, ур-ра тавышлары.

Мәхмүт. Ай-һай, кушылырлармы? Андый отрядның командиры кадровый военный булырга тиеш.

Бер гвардеец. Базарда бая сөйләп тордылар, командирлары яшь кенә егет, ди. Ут, ди, инде менә, ут!

Атылып-бәрелеп, Сәхи килеп керә.

Сәхи. Бирегез миңа мылтык, бирегез кылыч!

Кариб. Нинди мылтык? Кем син?

Сәхи. Алар нидер уйлаганнар! Сак булыгыз. Карыйм, бүген таңнан чаж да чож кемнәрдер кереп-чыгып йөри, чышын-пышын нидер сөйләшәләр, киңәшәләр.

Кариб. Әй, егет, йомышыңны әдәмчә генә аңлат әле.

Сәхи. Сары бай малае мин. Әткәйнең дус-ишләре байгуралар тузыналар.

Кариб белән Мәхмүт бер-берсенә карашалар. Гвардеецлар арасында: «Бай малае!», «Шпион!» — дигән тавышлар.

Сәхи. Кызыллар Ырынбурны ташлап чыгалармыни?

Кариб. Кем тарата? Каян ишеттең?

Сәхи. Әткәйләр сөйләшә! Юкны-барны лыгырдап йөрмә дип, үзен складка бикләдем дә монда чаптым. Мылтык, кылыч бирегез миңа.

Бер гвардеец. Мылтык сиңа түгел, гвардеецларга да эләкми әле.

Сәхи. Мылтыгын бирәсезме, юкмы... язылыз мине кызыл әтрәткә! Шәһәрдә калмыйм, валлаһи!.. Бай буласым юк, Дутов казаклары белән гаепсезләрнең җанын кыеп йөрисем килми.

Кариб. Язып куй, булмаса, үзен, Зәкия.

З ә к и я (*шатланып*). Фамилияң ничек? Исемең? Биш йөзенче булырсың.

С ә х и (*тирен сөртеп*). Сәхи мин, Таһиров. Рәхмәт, иптәш командирлар.

М ә х м ү т (*Карибка*). Ошамый бу егет миңа. Чикылдап торган анархист.

К а р и б. Шәһәрдә бунт әзерләнеп ятмасын, штабка хәбәр итәсе, ахры.

Мәчеткә акрынлап халык җыела. Аркасына зур капчык күтәргән Х ә й р ү ш керә. Аның артыннан мылтыклы Т а җ е т д и н килә.

Х ә й р ү ш (*авызы ерык*). Ну, малакаем, Кариб җаным, бие. Кырык кешегә обмундирование алып кайттык.

М ә х м ү т. Командирга шулай докладывать итәләрме?

Х ә й р ү ш (*капчыгын җиргә ташлый, чишә*). Товарын кара син, Кариб җаным, малакаем, товарын, первой сорт! Нинди генә размерын җаның тели, билләһи!

К а р и б. Син, Хәйрүш агай, армиягә беренче көн килгән кебек кыланма инде.

Х ә й р ү ш (*кинәт смирно басып*). Гафу үтенәм вахмистр... тфү! Боерыгыгыз үтәлде, иптәш командир. Аяк киеме белән кырык гвардеец тәэмин ителде. (*Мылтыклы гвардеецка.*) Яле, Таҗетдин, бушат, күрсеннәр.

Капчыкны икәү күтәреп бушаталар. Аннан чабаталар килеп төшә. Барысы да исләре китеп карап торалар.

К а р и б. Сукыр бер тиен дә акчаң юк, Хәйрүш агай, талап алмагансыңдыр бит?

Х ә й р ү ш. Никак нет, вахмистр әфәнде... тфү, иптәш командир! Гадел юл белән алмашып алдым. Базар аша үтеп барабыз, бер бәндә җилән сатып йөри. Менә дигән җилән! Үзе мыдыр-мыдыр большевикларны сүгә. Байга җилән нәрсәгә аңа? Кирәк булса, сатмас иде. Значытся, артык мал. Революция файдасына кон-фис-ка-ция-лә-дек.

С ә х и. Минем әткәйнең җиләне.

Х ә й р ү ш. Дөрес, менә бу җирән егет тә революция өчен тырышты, югыйсә безне базарның әтәм-сәтәм халкы урап алган иде. Яныйлар, ну без, кыскасы... (*Ишарә белән, аңлатып бирә.*)

Т а җ е т д и н (*калын тавыш белән*). Точно так, иптәш командир. Шуннан Хәйрүш агай җиләнне сукнога, сукноны чабатага алыштырды.

Х ә й р ү ш (*мактанган сыман*). Шәп бит! (*Селкеп күрсәтә.*) Ак казакны куа башласаң, үзе җиңел, үзе иркен. Җитмәсә, тирләтми, форточкалары күп.

Кариб. Хәйрүш агай, үзең белеп өләш. Яланаяклыларга беренче чиратта бир.

Чабаталарны кәрвансарай ишек төбенә алып китәләр. Шау-гөр килеп өләшәләр, киенәләр. Кариб бер-ике кешегә өстәл-урындыкларны читкәрәк алырга куша.

Кариб. Язылу тәмам! Боларны да кертеп куегыз.

Табышлар:

— Шәп мал!

— Киндерәсе Дутовны асып куярлык.

— Корсагы зурдыр, чыдатмас...

Үсмер гвардеец. Шадра ике пар эләктергән!

Мәхмүт (*Карибка*). Байракны да алыргамы?

Кариб. Флаг торсын.

Мәхмүт. Мин аптыраштa: хәзер нәрсә эшләргә?

Кариб. Поручик Урманаев! Поход алдыннан нишлиләр? Әзерләнергә кирәк. Аннары, шашки во-он!

Зәкия. Медикаментлар, дарулар бик аз, Кариб абый.

Кариб. Эзләргә! Иң соңыннан язылган егетнең исеме ничек әле? Иярлә шуны!

Зәкия. Бишйөзенчеме? Таһиров!

Кариб. Таһиров!

Сәхи йөгереп керә.

Сәхи. Мин ул, иптәш командир.

Кариб. Хәзер менә безнең сестра белән каланың астын-өскә әйләндерегез. Тик бел: урламаска, таламаска. Безгә дарулар, бинт, мамык кирәк.

Сәхи. Була анысы, иптәш командир. Киттекме, чибәр туташ?

Мәхмүт. Шомлы вакыт, сезгә куркыныч булыр, Зәкия туташ. Озатучы бирикме?

Зәкия. Курыкмагыз, Мәхмүт, мин буш кул белән түгел.

Кесәсеннән браунинг алып күрсәтә. Сәхи капка яныннан аңа сокланып карап тора. Мәхмүт Зәкияне озата. Чыгып китәләр.

Мәхмүт. Туганымнан да якын ул миңа... Аңлыйсызмы, Кариб? Ант биргән патшадан коры калып, дәрәҗәмнән, хыялларымнан баш тартып Сызраньга кайтып егылганда, Зәкия туташ минем бердәнбер терәгем иде.

Кариб. Әйе... Безне дә ул таныштырды... Бар иде синең җебеп калган чакларың!

Мәхмүт. Соңгы бер елда без гел бергә... Тик Оренбург далалары безне аерыр төсле.

К а р и б. Дала дусларны аерамы, җүләр? Иптәшлек далада сынала, бел! Их-х, айкыйбыз аны даланы! По коням!

М ә х м ү т. Ә атлар юк... Гвардеецларны...

С ә г ъ д е т д и н килеп керә. Ул як-ягына каранып, курка-курка гына килә. Аркасында, ян-якларында капчык, кулында таяк.

С ә г ъ д е т д и н. Әссәламегаләйкем, мөселманнар.

К а р и б (*кырыс*). Мәчет монда түгел, әнә тегендә.

С ә г ъ д е т д и н. Мөселман гаскәренә шушында язалармы?

М ә х м ү т. По коням! Биш йөз дә беренче драгун! Кайда кылыч, черкеска, шпорлар... Язылырга килгән, честное слово!

С ә г ъ д е т д и н. Өстенә бастың, нәнкәм, кая, үзең иң кәттә лачанник булсаң, мөбарәк кулың белән, бисмиллаһи рәхман рәхим, шунда бер читкә безнең исемне дә төртеп куй әле.

К а р и б. Нәрсә эшли аласың соң син, бабай?

С ә г ъ д е т д и н. Син миннән нәрсә эшли алмыйсың дип сора, нәнкәм.

М ә х м ү т. Мылтык ата беләсезме?

С ә г ъ д е т д и н. Ә син тәрәзә борысы утырта аласыңмы?

М ә х м ү т. Утыртырга туры килгәне юк.

С ә г ъ д е т д и н. Ә мин утырта беләм. Белгәч, сине өйрәтергә дә кулымнан килә. Мылтык атарга, Ходай насыйп итсә, мине син өйрәтерсең. Өйрәнергә калгач, нишләрсең.

М ә х м ү т. Абзый, болай баш катырып йөрмәгез.

С ә г ъ д е т д и н. Хак сүз әйттең, үзем дә ашыгам. Намаз вакыты да бик җитте. Каячы, язып кына куегыз да... Сәгьдетдин Билалетдин угылы Фәсхетдинов булабыз инде без. Ягъни...

К а р и б. Тай моннан, бабай, тай!

М ә х м ү т (*аның колагына килеп кычкыра*). Язылу бетте, бабай.

С ә г ъ д е т д и н. Ишетмәдем. Һай, ишетми калганмындыр шул. Кайчан бетте әле ул ак казаклар?

К а р и б (*кызыксынып*). Казак бетмәде...

С ә г ъ д е т д и н. Бәс, шулай икән?.. Язылу бетә диме? Һай, намазга соңга калдырмасагыз иде, тәһарәт тә алынмаган дигәндәй...

К а р и б. Бар, бабай, намаз-ниязларыңны тәмамла элек.

С ә г ъ д е т д и н. Шулай диген, нәнкәм, рәхмәт яугыры.

Кереп китә.

Мәхмүт. Көлке.

Кариб. Уйнама, ничек китереп терәде ул безне?.. Бер әйбәт комиссар булса, болардан менә дигән гвардеецлар ясар иде.

Мәхмүт. Командир гына җитмиме?

Кариб. Икебез тиң авызыбызны ачып кызыл гвардиягә язылырга килгән картның мәчеткә кереп китүен карап калдык ич.

Таҗетдин килә.

Таҗетдин. Иптәш командир, бер олау мылтык китерделәр.

Кариб. Мәхмүт, коралларны кабул итеп ал. Әйбәтләп сана. Мылтык тота белгәннәрне ныгытып барла. (*Мәхмүт чыга.*) Таҗетдин, син кал әле. (*Таҗетдин юаш кына басып тора.*) Йә, туган, ни сөйлиләр?

Таҗетдин. Сүзләрнең рәте-башы юк, иптәш командир.

Кариб. Шулай да?

Таҗетдин. Халык бик чуар... Безнең өлешкә даладагы җыен икеле-микеле, калдык-постык калган бит.

Кариб. Күз-колак булыгыз. Тегенди-мондый кешеләр килеп кермәсен. Дөнья бит!

Кәрвансарайдан Хәйрүш чыга.

Хәйрүш. Иптәш командир, сине телефонга дәшәләр.

Кариб. Таҗетдин, син шушы тирәдә чуал. Чит кешене кертмә. Үзебезнекеләрне корал белән чыгарма.

Таҗетдин. Шулай итәрмен, иптәш командир.

Кариб ашыгып кереп китә. Таҗетдин ишек янында басып кала. Гвардеецлар үтеп-сүтеп йөриләр. Җанлылык. Шау-шу. Хәйрүш Таҗетдин янына килә, чүгәләп тәмәке тарталар.

Хәйрүш (*моңаеп*). Таҗетдин, нәнкәм, унсигезенче елның печәнен җыю да насыйп түгелмени инде миңа?

Таҗетдин. Насыйп булмас... Ак казаклар ком бураны кебек киләләр бит... Иң әүвәл аларны кырып бетерергә кирәк.

Хәйрүш. Синең нәрсә, кашың да күзең, мылтыгың да үзең. Гомер-гомергә пролетар. Минекеләр җиде җан бит, җиде җан!

Таҗетдин. Гурьевтагы фабрикант Акчуриннарны, мөгаен, сөргәннәрдер инде... Саниякәй көтә-көтә зарыгып беткәндер... Кайтасы иде...

Акрын гына җырлыйлар.

Без утырган машинаның тоткалары җиз генә,
Бер илләрдән аерылгач, кайтып булмый тиз генә...

Чыгып килүче Кариб белән Мәхмүтне күреп, тиз генә торалар.

Мәхмүт. Патроннар бик аз, Кариб.

Кариб. Губком секретаре иптәш Коростылев сорый: «Татарлар кузгалырга әзерме?» ди.

Мәхмүт. Ни дип җавап бирдегез соң?

Кариб. Ярты сәгать эчендә хәл итәрбез, дидем. Хәзер батальонны тез, сөйләшергә кирәк!

Мәхмүт. Хәйрүш агай, Таҗетдин абый, гвардеецларны җыегыз.

Хәйрүш белән Таҗетдин кычкырып чакырып йөриләр. Мәхмүт белән Кариб бер кырыйда күзәтеп торалар.

Мәхмүт. Батальон, становись!

Тезеләләр. Гвардеецларның кайсы күши, кайсы сөйләшә. Аркаларда төрле зурлыктагы капчыклар. Төрле формадагы мылтыкларны теләсә ничек тотканнар. Нәкъ шул вакытта мәчет манарасыннан мәзин азан әйтә башлый.

Тавышлар:

— Нәрсә ди? Тезелегез диме?

— Шулай ди.

— Үкчәгә басма.

— Кая алып китәләр икән?

Шушы ыгы-зыгыны көчәйтеп, кәрвансарайдан бер-берсенә атланып ике гвардеец чыга. Аларны шаркылдап көлеп каршы алалар.

Кариб. Бусы нәрсә тагын?

Тавышлар:

— Иптәш командир, Әхмәтҗан кәрттә уйнап оттырды.

— Кәрвансарайны өч рәт әйләнеп чыксын.

Кариб. Туктагыз хәзер үк! Тоже мне кавалерия! Марш!

Мәхмүт. Тагын кабатлыйм: тезелегез! Батальон, смирно! (*Стройны күзәтеп чыга.*) Әнекәй генәм...

Сәгъдетдин дә стройга кереп баскан, янындагы капчыклары мәзәк булып сузылып тора. Кариб белән Мәхмүт строй буйлап баралар, Сәгъдетдин янына тукталалар.

Бу нәрсә, пулеметмы?

Сәгъдетдин. Пуләмәт дип мөселман кешедән көлмә инде син, нәнкәм.

Кариб. Коралны капчыкка тыгып йөриләрме?

Капчыкны чишеп җибәрсәләр, анда ялтырап торган җиз комган.

Мәхмүт. Нәрсә бу?

Сәгъдетдин. Соң, лачанник улым, ул казак мәлгуньнәрне — динсез дәһриләрне теге дөньяга тәһарәтсез ничек җибәрәсең?

Күшәүче гвардеец. Иптәш командир, сүз бар иде.

Кариб. Сүзегезне соңыннан сөйләрсез. Команданы ишетмәдегезме әллә?

Сакаллы гвардеец. Анысы шулай, аңладык. Шәйхетдиннең сүзе кирәкле бит. Аны һич тә соңга калдырырга ярамас.

Күшәүче гвардеец. Җәмәгать, әнә намаз башлана.

Сакаллы гвардеец. Митингны намаздан соң тәмамларбыз, иптәш командир.

Сәгъдетдин. Бәрәкалла, акыллы балалар икәнсез, намазсыз һич кенә дә ярый торган эш түгел.

Тавышлар:

— Җан турында да онытмыйк.

— Мөселман батальоны ич без.

— Мәчет күрүләр яңадан насыйпмы-юкмы диген...

Хуплау авазлары, рәтләр таркала, гвардеецлар мылтыкларын җиргә куеп мәчеткә кереп китәләр.

Кариб. Иптәшләр, иптәшләр!

Мәхмүт. Кая барасыз? Таралырга команда булмады.

Кариб. Туктагыз, тукта!

Батальонның күпчелеге мәчеткә кереп китә. Ишегалды уртасында берничә гвардеец, Кариб, Мәхмүт, Хәйрүш, Таҗетдин басып калалар. Тынлык.

Кариб. Их, коралларын ташлап киттеләр!.. Коралларын! Революциягә хыянәт!

Мәхмүт. Хәйрүш агай, коралларын җыеп, кәрвансарайга кертегез.

Хәйрүш, Таҗетдин, гвардеецлар коралларны җыеп алып кереп китәләр.

Кариб. Мәхмүт, син бит поручик булган кеше. Аңлат, ни кылырга? Мин бит... үзең беләсең: шашки вон, марш, марш! Их, далага чыксак өйрәтер идем мин аларны!

Мәхмүт. Бу кадәресен мин дә көтмәгән идем.

Кариб. Губкомга барып хәлне аңлатмый ярамый. От-

каз бирергә кирәк. Ичмасам, теге отряды да килеп җитмәде. Хәйрүш агай, Таҗетдин, әйдәгез минем белән!

Таҗетдин. Арага провокатор кермәдеме икән?

Кариб, Хәйрүш, Таҗетдин чыгып китәләр. Мәхмүт ары-бире каранып торгач, кәрвансарайга керә, аннан саквояж тотып чыга. Капкага бара башлый, кызыл бантын йолкып алып кесәсенә яшерә. Аның каршы сына китаплар, тартмалар күтәргән Зәкия килә.

Мәхмүт. Зәкия туташ?

Зәкия. Сез миңа булышырга киләсезме?

Мәхмүт. Әлбәттә!

Зәкия. Ә саквояжыгызны нигә алдыгыз?

Мәхмүт. Аңлыйсызмы, Зәкия туташ...

Зәкия. Батальон кайда?

Мәхмүт. Беләсезме, бөтен революцияләрдән, байраклардан, идеяләрдән өстенрәк көч бар икән әле монда.

Зәкия. Нинди көч? Кем?

Мәхмүт. Әнә шул мөнбәрдәге бетәшеп беткән карт.

Зәкия. Сез, революционер, шул карттан курыктыгызмы?

Мәхмүт. Юк... Мин толпадан курыктым.

Зәкия. Атлаган саен икеләнерлек булгач, нигә Сызраньнан киттегез? Нигә безгә иярдегез?

Мәхмүт. Зәкия туташ, җирдә мин табынган Алла сез. Мин исә корыч инәгә тагылган төссез, ярым черек җеп. Инә — сез, җеп — мин. Инә кая, мин шунда.

Зәкия. Матур сөйләп бер тапкыр харап була язган идегез инде, тагын кабатлыйсыз.

Мәхмүт. Ходай хакы өчен, үткәннәрне искә төшермәгез.

Зәкия. Сызрань хәрби гарнизоны. 1917 ел. Ялтыравыклы погоннарны уйнатып, шалтыравыклы сүзләр сибеп сез трибунага мендегез. «Җиңгәнгә кадәр сугышны дәвам итик!» Гади солдат Шамил Усманов чыгып отпор биргәннән соң, сезне трибунадан сөйрәп төшерделәр... Шамил коткармаса...

Мәхмүт. Шул исемне телгә алып, җанымны кызган табага саласыз!

Зәкия. Бәлки, сез Сызраньнан да бары Шамилдән качу өчен генә киткәнсездер?.. Революция икеләнүләрне кичерми, Мәхмүт! Кайда батальон?

Мәхмүт. Таркалды, тумас борын үлде...

Зәкия. Кариб абый кайда?

Мәхмүт. Шуны хәбәр итәргә штабка китте... Зәкия туташ! Хәзер иң тыныч чак: китик моннан!

Зәкия. Китәргә?

М ә х м ү т. Хәзер штабтан тикшеренүчеләр килер. Провокаторлар юкмы дип тикшеренә, казына башларлар...

З ә к и я. Сугыш алдыннан батальонны ташлап качаргамы?.. Кариб абыйны? Әнә Сәхиләрне?.. Юк! Батальон яшәр!

Мәхмүт кычкырып кала, Зәкия ярсып чыга. Мәхмүт нишләргә белмичә арлы-бирле сугыла, урам яктан тавышлар килә. Әле тәкбир әйтеп кычкыралар, әле яныйлар.

М ә х м ү т. Монысы ни афәт тагын?

Атылып С ә х и керә.

С ә х и. Иптәш командир!

М ә х м ү т. Нәрсә бар анда?

С ә х и. Коткарыгыз. Әткәй үтерәм дип яный. Монда киләләр. Калада бунт!

М ә х м ү т. Ахмак сез! Үз әтиегез белән дә уртак тел таба алмагач?..

С ә х и. Ничек? Сары бай диләр ич аны!..

Ярсыган халык төркеме кәрвансарайга килеп җитә. Сәхи ишек артына кача. Халык. Оренбургның вак-төяк б а й л а р ы, к и б е т ч е, с ә ү д ә ә һ е л л ә р е. Арада х а т ы н - к ы з да бар. Бер кырыйда я р л ы - я б а г а й, Г ө л җ а м а л, С ә к и н ә дә шунда.

Т а в ы ш л а р:

— Оялары шушында.

— Азгыннар, кяферләр.

С а р ы  б а й. Җәмәгать, мөэмин-мөселманнарны котыртып атна буе шушында язып яттылар. (*Кызыл байракны барып йолкып ала.*)

Б е р ә ү. Мәккә кяферләре.

И к е н ч е с е. Алардан мең ямандыр, билләһи.

Сары байның байракны ертырга азапланганын күреп, кайберәүләр куркышып чигенәләр.

С а р ы  б а й. Курыкмагыз, аларның ике өтеккә бер күгәргән кистәннәре юк. Дутов хәзрәтләре өермә булып килсә, без дә монда тик кенә ятмадык. (*Корал күрсәтә.*)

М ә х м ү т. Сезгә нәрсә кирәк?

С а р ы  б а й. Әһә, менә ул үзе! Комиссар, кая качырдың минем азгынны?

М ә х м ү т. Мин сезгә җавап бирергә теләмим.

С а р ы  б а й. Күрдегезме, сүзне каян чыгара?

М ә х м ү т. Сезгә нәрсә кирәк? Нигә шаулыйсыз?

Т а в ы ш л а р:

— Сорап торган була!

— Җиргә ахырзаман иңдерсеннәр дә шаулама, имеш!

Мәхмүт (*аптырашта*). Мөселманнар, самосуд ясарга закон юк.

Берәү. Ә-ә, закон исеңә төштеме? Үзең бетерден законны, хәзер теләсә нишләсәк ирек!

Икенчесе. Башын бетерик.

Сары бай. Туктагыз, үзем! Безнең балаларны моннан болай котыртып йөрмәсен.

Обрезын чыгара, Сәхи ишек артыннан чыга.

Сәхи. Әгәр канга сусасаң, чыгар канымны!

Сары бай. Менә үзе килеп капты!

Сәкинә (*арага килеп керә*). Сәхи җаным, кач!

Гөлҗамал (*килеп җитә*). Кызым, балам, кайтыйк...

Сары бай. Кит, зиначы! (*Сәхигә.*) Изге Коръәнне атып бәргәндә бик батыр идең, хәзер нишләрсең икән!

Тавышлар:

— Коръәнне атып бәргән? Ах, мордар!.. Җир йотар!

Сәхи. Кый җанымны, дәҗҗал!

Сары бай. Җаның җәһәннәмлек!

Мәхмүт. Байлар, самосуд ясарга ирек бирмәм.

Сары бай. Мөселманнар! Менә бу бер явыз бәндә, (*Мәхмүтне күрсәтә.*) Динебездән көлә, үзебезне мыскыллый. Безнең балалар шул дәҗҗалга ияреп тәмуг юлыннан киттеләр. Нишләтәбез аны?

Тавышлар:

— Үлем аңа!

— Җәһәннәм!

Сәхи. Кагылмагыз командирга!

Сәкинә. Җибәрегез Сәхине!

Сәхине, Мәхмүтне эләктереп алалар, кулларын каерып ишеккә таба сөйриләр. Зәкия кайтып керә.

Зәкия. Нишлисез, явызлар?

Сары бай. Җәмәгать, әнә кәнтәйләре кайтты.

Мәхмүт. Кыргыйлар! Мин сезнең йөзегезгә төкерәм.

Зәкия. Мәхмүт бәгырем!

Зәкияне тотып Мәхмүт янына бастыралар.

Берәү. Төкеренмә, җәһәннәмдә эссе таба ялатырлар.

Сары бай. Дин юлында шәһит китсәм китәм, әмма изге Коръәнне мыскылларга юл куймам. (*Акрын гына обрезын күтәрә.*)

Тавышлар:

— Комиссарга үлем!

— Догаңны укы, комиссар!

Дүрт-биш яхшы коралланган гвардеец ияртеп, капкадан Шамил Усманов килеп керә. Халык ахылдап куя. Сары бай обрезын тоткан килеш ялт кына борыла.

Шамил. Кемгә комиссар кирәк? Мин комиссар!

Мәхмүт. Йә аллам, тагын Шамил Усманов.

Зәкия. Шамил!

Гвардеецлардан берәү. Сызрань отрядының командиры.

Сары бай. Мөселманнар, чыннан да бит Шамил Усманов. Җамалый бай тегермәнендә малай булып йөргәндә үк җыен этрәк-әләмне котыртып ырволюция ясап йөргән юньсез.

Шамил. Таныдың, Сары бай. Мин дә сине онытмадым. Тегермәнгә жандармнар ияртеп килгән идең.

Сары бай. Үзе килеп капты! Шушы мөртәт аның башы! Бәлшәвикләрнең иң усал эте шул!

Зәкия. Шамил, саклан.

Обрезын күтәреп атам дигәндә генә Шамил кесәсеннән наган чыгарып ата. Сары байның обрезы атылып төшә, үзе чыгып йөгерә, җыелганнар куркынып чигенәләр.

Шамил. Бүре сукмагыннан ерак китә алмассың, Сары бай!

Зәкия. Шамил, мең, мең рәхмәтләр дә аз сезгә.

Шамил. Исәнмесез, Зәкия туташ. Сезне монда очратырмын дип һич уйламаган идем. Мәхмүт әфәнде үзгәргән... Сары байның обрезы үзгәрттеме?

Мәхмүт. Сызраньнан чыккан отрядның командиры сез, алайса?

Шамил. Мин. Ә сезне нигә әсир иттеләр? Моңарчы байлар белән уртак тел таба торган идегез...

Мәхмүт. Әгәр батальон дигәннәре яшәсә, мин шунда хәрби белгеч.

Зәкия. Мәхмүтне алуларын Кариб абыйдан мин үтендем.

Шамил. Ә батальон кайда? Кариб кайда?

Сәхи. Әнә намаздан чыгып киләләр.

Шамил (*гвардеецлар каршысына барып*). Командирларын көпә-көндез дошман кулына тапшырган егетләр шушы буламыни? (*Уңайсызлану тавышлары.*) Шушы кадәр батырлар арасыннан хатын-кызны коткарырлык берәү дә табылмадымы?

Сәгъдетдин. Кем уйлаган бит аны...

Шамил. Иптәшләр, дутовчылар революция яклы кешеләрнең үзләрен генә түгел, хатын, бала-чагаларын, ту-

ганнарын кырып Оренбургка якынлашып киләләр. Ак казаклар аяз көндә күтәрелгән әшәке ком бураны кебек. Әгәр без шундый таркау, оешмаган булсак, казак гаскәренә каршы тора алырбызмы? Йә, менә син әйт. (*Күшәүчегә күрсәтә.*)

Күшәүче гвардеец. Ә син үзең кем буласың?

Сакаллы гвардеец. Әйе шул. Кем син безне өйрәтергә? Без доброволь!

Шамил. Мин Шамил Усманов булам. Татар батальонына комиссар итеп билгеләндем. Каюм!

Каюм. Тыңлыйм, иптәш комиссар.

Шамил. Хәзер үк безнең отряд кәрвансарайга килеп җитсен. (*Каюм чыга.*) Ә сез, батыр гвардеецлар, үзегезне кеше төсенә кертегез. Тиздән походка!

Гвардеецлар (*тигезсез генә*). Ур-ра!

Шамил. Ә сез, чибәр апа белән чибәр әби, ни йомыш?

Гөлҗамал. Минем кызым ул, бердәнберем. Сары байда асраулыкта иде...

Сәкинә. Без дә кызыл гвардия белән китәр идек...

Сәхи. Иптәш командир, Сәкинәгә отрядта калырга рөхсәт итегез. Әйбәт кыз ул!

Зәкия. Шамил, ул миңа ярдәм итәр.

Гөлҗамал. Дөнья булгач, кыты-мыты эше миңа да табылыр әле. Әнә ич, кием-салымнары ничек өтелгән.

Шамил. Телисез икән, мин каршы түгел. Без революциягә төрле юллардан киләбез. Безне кузгаткан сәбәпләр дә төрле, максатыбыз гына бер! Мәхмүт, ишегалдын чит кешеләрдән арындырсыннар. Батальонны тәртипкә кертегез.

Мәхмүт. Тыңлыйм.

Теләр-теләмәсрәк китә. Гөлҗамал, Сәкинә, Сәхи кәрвансарайга керәләр. Шамил янында Зәкия генә кала.

Шамил. Зәкия туташ, сез чак кына көтегез. (*Пауза.*) Мәхмүт белән китүегезне беләидем... Тик артыгыздан эзләп килгән дип уйламагыз.

Зәкия. Уйламыйм, Шамил... Сезне монда революция китерде...

Шамил. Мәхмүтне яратуыгызны ачык беләм...

Зәкия. Сез аннан үч алырга тырышмассыз дип өметләнәм.

Шамил. Юк, Зәкия туташ... Тик шулай да әйтми кала алмыйм: сезне күрүем белән бәхетлемен... Качып китсәгез дә очраштык!

Мәхмүт керә.

М ә х м ү т. Тагын кабатлыйм: батальон бу рәвешендә сугышка керә алырлык түгел.

Ш а м и л. Ничек?

Капкадан К а р и б, Х ә й р ү ш, Т а җ е т д и н күренәләр.

К а р и б. Шамил! Комиссар! Штабта сине безнең янга китте диделәр. Аймылыш булдыкмы? (*Күрешәләр.*)

Ш а м и л. Юк, командир, мин батальонга йөкләнгән бурыч турында штабта белештем. Аннан үзебезнең разведчиклар белән Сакмар күпере буеннан әйләнеп килдем. Сугышырга шунда туры киләчәк.

К а р и б. Булмады инде, безнең батальоннан эш чыкмас дип әйтеп кайттым.

Ш а м и л. Әгәр сездән булмый икән, күперне сакларга үземнең йөз кешелек отрядым белән барам.

К а р и б. Нигә күперне? Нәрсәсен саклыйсың аның? Дутовчыларны җәелеп далада каршыларга иде!

Ш а м и л. Нигәме? (*Күзе белән эзләнә, өстәлне күрә, аны күтәреп уртага куя.*) Менә карагыз! (*Каешын чишеп өстәлгә суза.*) Менә бу Сакмар. Дутовчылар моннан килә. Атлары, туплары белән туп-туры күпергә агылалар!

К а р и б. Күперне шартлатырга боердылар.

Ш а м и л. Ярамый. Без шушы күпер төбенә урнашабыз да аларның төп көчләрен тоткарлыйбыз. Ул арада Оренбургтан гаскәр дә, бала-чагалар да чигенеп өлгерәчәкләр.

М ә х м ү т. Ике тәүлек оборонада тору өчен бик күп корал сорала.

Ш а м и л. Корал аз чакта батырлыкны эшкә җигәбез!

К а ю м керә. Отряд килгән тавышлар.

К а ю м. Иптәш комиссар, отряд килде.

Ш а м и л. Каюм, хәзер үк штабка чап: күперне шартлатмасыннар. Татар батальоны оборонада торып дутовчыларның кирәген бирергә әзер диген! Син ризамы, Кариб?

К а р и б. Син булганда барына да риза!

К а ю м. Есть, иптәш комиссар!

К а р и б. Мәхмүт, батальонны тезегез!

М ә х м ү т. Карап карыйк.

К а р и б. Сезне күргәч, беләккә көч керде.

З ә к и я. Алар булмаса, без беткән идек, Кариб абый.

М ә х м ү т. Батальон, становись! Смирно!

Шамилгә докладывать итә.

Иптәш комиссар, батальон тезелде.

Ш а м и л. Иптәшләр, без хәзер үк кузгалырга тиеш. Безнең бурыч Оренбургка дутовчыларны кертми тору булачак. Ике көн, нибарысы ике тәүлек түзәргә кирәк. Ризамы сез шуңа?

Т а в ы ш л а р:

— Риза!

— Барабыз!

— Алып бар безне, Шамил!

Ш а м и л. Шуны искәртеп куйыйм: без тимердәй нык, бердәм, куркусыз булырга тиеш. Бик күп кешеләрнең, гаскәрнең, халыкның язмышы безнең ныклыкка бәйләнгән. Куркакларга безнең арада урын табылмасын! (*«Ур-ра» тавышлары.*) Йә, иптәш командир, батальон белән җитәкчелекне кабул итеп ал. (*Үзе дә стройга баса.*)

К а р и б. Батальон, походка марш!

К а ю м керә. Кулында гармун. Уйнап җибәрә. Батальон капкадан чыгып китә, сафлар «Галиябану» көенә җырлыйлар.

Алдыр Урал буйлары,
Гөлдер Урал буйлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Галиябану, сылуым иркәм,
Калды Урал буйлары.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сакмар елгасы ярындагы бер урын. Камышлык. Зур-зур тирәкләр. Якында гына күпер. Уңда, агачлар арасында, вагон. Сул якта кухня. Кухня янында Г ө л җ а м а л карчык. Сәгъдетдин дә шунда утыра. Сугыш тынып торган ара. Сирәк-мирәк кенә атыш тавышлары ишетелә. Гөрселдәп снаряд ярыла. К а ю м йөгереп керә, аңа яшь кенә э л е м т ә ч е ияргән. Вагонга таба баралар, аннан К а р и б чыга.

К а ю м. Иптәш командир, командующий штабыннан элемтәче килде.

К а р и б. Тыңлыйм.

Э л е м т ә ч е. Иптәш командир, хәзерге вакытка Оренбургтан отрядлар, җиһазлар төяп, сиксән эшелон озатылды.

К а ю м. Тагын утызны җибәрәселәре калган, Кариб абый.

Э л е м т ә ч е. Губком секретаре иптәш Корыстылев шуны тапшырырга боерды: вагоннар җитми, ягулык аз,

эшелоннарны туплау кыенлашты. Ә бер генә хатын-кызны да, бала-чаганы да калдырырга ярамый. Дутовчылар бөтен авыллардагы большевик семьяларын суеп киләләр. Оренбургны бары сезнең батальон гына саклый.

Кариб. Ә корал?

Элемтәче. Сездән тагын ун сәгатькә түзү сорала.

Кариб. Димәк, корал булмаячак. (*Каюмга.*) Разведка кайтмадымы?

Каюм. Күренмиләр, иптәш командир.

Кариб. Комиссар кайда?

Каюм. Күпердә. Хәйрүш агайлар белән динамит куялар.

Элемтәче. Аннары, иптәш командир, шәһәрдән килдем, беркем мине туктатмады. Үткән юлы да постларыгыз ятып йоклаган иде. Дутовчылар Сакмарны югары яктан ат йөздереп чыгулары бар.

Кариб. Каюм, постларны күздән кичереп чык!

Каюм. Есть, иптәш командир.

Элемтәче белән чыгып китәләр.

Кариб (*бинокльдән карый*). Эх, бер-ике атлы сотня булса!.. Йомран кебек казынып ятыр идекме? Шашки воон, ал-люр! (*Ат тоягы тавышы.*) Эх, тояк тавышлары Дутов кабере өстендә җеназа булып яңгырар иде.

Гөлҗамал. Теге егетләр исән-аман кайтып җитә алырлар микән, командир улым?

Кариб. Кайтырга тиешләр. (*Чыгып китә.*)

Гөлҗамал. Бирсен Ходай. (*Сәгъдетдингә.*) Шул Каюмны күрсәң, күзеңне алмыйсың, Сәгъдетдин.

Сәгъдетдин. Улым мәрхүм исемә төшә.

Гөлҗамал. Улым дигәннән, инде үзең олы гына кеше, чал, сиңа монда йөреп ни калган.

Сәгъдетдин. Кулымнан килә торган булса, мин бу нәләт ак казакларны Гали батыр рәвешле берүзем дөмектерер идем. Мәңгегә, Ходай бирсә, мин аларның берсенә шәфкать күрсәтә торган кеше түгел. Тукта, Гөлҗамал, мин сиңа бер нәрсә күрсәтим. (*Капчыгын чишеп бер кәләпүш чыгара.*) Менә күрәсеңме моны? Мәрхүм улымның соңгы кәләпүше. Дөнья бәясе егет иде, акылы дисеңме, сабырлыгын әйтәсеңме, тыйнаклыгын сөйлисеңме, бер дә килмәгән җире юк иде... Ә менә кәләпүшнең ике читендәге ике тишекне күрәсеңме? Ул пуля тигән җир. Шул мәрхүмнең, күрше авылдан кайтканда, ак казаклар канын коеп киттеләр.

Гөлҗамал. Синең улың бәлшәвик идемени?

Күпер ягыннан Ш а м и л килә.

Ш а м и л. Ничек соң, бабай, аклар йокыны бик бозмыймы?

С ә г ъ д е т д и н. Йокы дигәне күптән качты инде, комиссар улым.

Ш а м и л. Кулыгызда нинди кәләпүш ул.

Г ө л җ а м а л. Аның улын ак казаклар атып үтергән.

Ш а м и л. Сезнең улыгызнымы? Ягез әле, ягез, Сәгъдетдин абзый. Утырыгыз, утыр. (*Кәләпүшне ала.*)

С ә г ъ д е т д и н. Бәлшәвик булмаса да, бик ипле бала иде.

Ш а м и л. Син шул кәләпүшкә карап җылап утырыр өчен батальонга язылдыңмы? Монда җылау файдасыз, ак казакның тамырын корытырга кирәк.

С ә г ъ д е т д и н. Мылтык бирмисез бит.

Ш а м и л. Иптәш Урманаев!

М ә х м ү т керә.

Бабайны өченче ротага беркетегез, мылтык бирегез.

М ә х м ү т. Яхшы, иптәш комиссар.

С ә г ъ д е т д и н. Рәхмәт, Шамил улым. (*Тора, шатлыгыннан кабаланып егылып китә, капчыгыннан җиз комганы, вак-төякләр, кәләпүш тәгәри.*)

М ә х м ү т. Бабай, бу нинди тәтиләр? Мин сезне музейга түгел, өченче ротага илтәм.

С ә г ъ д е т д и н. Алай ук димә инде, командир улым.

Ш а м и л. Ә нигә музейга илтмәскә?.. Бала каны сеңгән кәләпүш безнең ал байраклар белән янәшә музейда торырга лаек түгелмени? Вакыты килер, куярбыз! Сөйләрбез дә! Күрсәтербез дә. Язып та чыгарбыз.

С ә г ъ д е т д и н. Мин каршы килмим, Шамил улым.

Мәхмүт, Сәгъдетдин чыгалар. Атыш тавышлары. К а р и б керә.

К а р и б. Кыймылдыйлар! Их, бер-ике сотня булса! Урап артларыннан керергә дә шашки во-он!

Ш а м и л. Ике түгел, бер сотня да юк. Булмаячак та. Үзебез тырышыйк, командир!

Бер-ике кеше ияртеп Х ә й р ү ш керә.

Х ә й р ү ш. Булды, Кариб малакаем, динамитларны оялаттык. Боерсаң, хәзер күперне күккә очырабыз.

К а р и б. Әллә тондырабызмы?

Ш а м и л. Көтик. Әле утыз эшелон китәсе бар. Инде чара калмаса, аннан күз күрер.

Атыш тавышлары көчәя, йөгереп Каюм керә.

Каюм. Аклар җанланды, бер-ике атлы теге тауучыкка менде.

Шамил. Каюм, берүк постларны үзең тикшер. Арттан төшмәсеннәр. Мин күпердә булам. Нык торыгыз.

Чыга. Каюм икенче якка йөгерә. Сәкинә керә, юылган марлялар элә. Кариб йөренеп тора. «Кайталар, кайталар!» дигән тавышлар. Таҗетдин, ят кешегә таянган Сәхи һәм ике гвардеец керәләр. Монда җанлану, шау-гөр килеп аларны каршы алалар.

Таҗетдин. Иптәш командир!

Кариб. Исән-сау кайтуыгыз шәп! (*Сәхигә.*) Син яраландыңмы?

Сәхи. Сәхине пуля аламы?

Бер гвардеец. Ак казак итеге үкчәсен кырды.

Кариб. Эш уңышлы чыктымы?

Таҗетдин. Белгән кадәресе шул. Дутовның төп көчләре Павловкада булырга тиеш. Ул станцага якын барырлык түгел. Шунда җыелалар. Берсен юлдан эләктергән идек, разбой салырга тотынды. Сәхи азрак сыйпаган иде, мәрткә дә киткән каһәр... Шул әйтеп маташты, бөек атаман гаскәр туплап кына бетерсен, җаннарыгызны тубалга төйибез, ди.

Кариб. Телне әрәм иткәнсез... Бусы кем тагын?

Сәхи. Юлда иярде, иптәш командир. Кызыллар ягына киләм, ди. Тотып алып кайттык.

Кариб (*ят кешегә*). Яле, дус кеше, сөйләп җибәр.

Ят кеше. Садрый атлы мин. Ваһапов. Чебенкидән. Моннан ерак түгел шундый авыл бар, Чебенки диләр.

Мәхмүт керә.

Мәхмүт (*Карибка*). Күпернең аръягына атлылар җыела. Пушкалар китерделәр. (*Садрыйны күреп туктап кала, ул аны бик яхшы таный.*)

Кариб. Хәзер.

Садрый. Әтием рабочий минем. Үзем дә рабочий. Менә кәгазьләрем. (*Кәгазьләр чыгара.*) Аклар көчләп мобилизовать иткәләгәнче үзебезнекеләр ягына чыгып калыйм дидем.

Кариб. Хәзерге заманда кәгазьгә ышанып булмый.

Мәхмүт. Калсын, сынап карарбыз.

Кариб. Ата беләсеңме?

Садрый. Белмичә, сунарчы мин.

Кариб. Кал, күз күрер. (*Мәхмүткә.*) Аклар көчләрен тарттыралар диген. Каушап төшмәсәк ярый ла... Их,

күзгә-күз далада очрашып, кылычка кылыч киләсе иде... Ярар инде!

Садрый чыга, һаман шунда урала. Гвардеецларны ияртеп Кариб чыгып китә. Мәхмүт Садрыйны сагалый.

Гөлҗамал. Сәхи улым, тамак ялгап ал.

Сәхи. Тамакны ялгарга була, тәмам өзелеп китә язды.

Сәкинә. Кайтмыйсыз дип шундый курыктым, шундый курыктым, Сакмар буена барам, гел аталар, гел аталар.

Сәхи. Кайтмый ярамый иде.

Гөлҗамал. Атаң күзеңә чалынмадымы?

Сәхи. Очраса котылу юк аңа хәзер!

Мылтыгына суга, чыгалар. Садрый күренә, аның янына Мәхмүт килә.

Мәхмүт. Капитан! Әгәр берәрсе сезне танып алса?

Садрый. Ничек таныр икән?.. Адәм баласына үзгәреш хас. Эволюция. Менә сез, поручик, кызыл командир булып киткәнсез.

Мәхмүт. Сез дә сунарчы икәнсез ич, белми идем.

Садрый. Мәхәббәт авазы кызыллар станына китердеме? Кызармагыз, поручик!.. Ах, шул сихерле көч! Биргән антны оныттыра, идеалларны җиргә таптата!.. Поручик!..

Мәхмүт. Монда поручик юк! (*Шыпырт.*) Сез шпионмы?

Садрый. Шпион булсам, тотып бирер идегезме?

Мәхмүт. Юк, мин болай гына... Бәлки, сез чыннан да рабочий булып киткәнсездер... Бәлки, сез чын сунарчыдыр... Тик үзегезнең элекке капитан икәнлегегезне командирга әйтергә иде. Беленсә, соңы хәерле булмас. Нигә дисезме?.. Алар ышана беләләр. Менә мин дөньядан ваз кичкәндә үз араларына алдылар, ышанып эш тапшырдылар.

Садрый. Нинди кызыклы әкият! Тыңларга сабыйлар гына юк.

Мәхмүт. Миңа ышанмыйсызмы?

Садрый. Араларына кемне алуларын беләләрме? Ә, поручик?! Черноярдагы карательный экспедициянең командирын...

Мәхмүт. Мин ул чакта күп нәрсәне аңламаганмын. Приказ үтәп...

Садрый. Ә алар аны беләләрме?

Мәхмүт. Тс-с, юк андый командир! Чернояр да юк, ишеттегезме?!

Садрый (*җиңел сулап*). Алайса, борыныннан юеше

кипмәгән комиссарыгызга әйтегез, мин атаман Дутов җәнапларының үз фәрманы белән килдем. (*Мәхмүт сискәнеп китә.*) Поручик, сез акылсыз түгел, татар батальонының ныклы бер һөҗүмдә үк һәлак буласын аермачык беләсез. Сез бит тәҗрибәле, укымышлы офицер. Ләкин атаман Дутов — бөек гуманист. Аның бер генә гаепсез мөселманны да харап иттерәсе килми. Югыйсә, без ике көн буена шушы күперне ала алмас идекме?

Мәхмүт (*явыз тантана белән*). Алганыгыз күренми, ә тырышып карадыгыз!

Садрый. Батальонны бөтен килеш саклап калыйк. Татар батальонының лаеклы командиры итеп атаман Дутов сезне билгеләде, поручик әфәнде.

Мәхмүт. Ә хәзер, әлбәттә, казакларны күпердән үткәрегез дип сорыйсыз.

Садрый. Дөрес, поручик. Без чигенүче большевикларның койрыгына басарга тиешле. Аларның паровозлары да, вагоннары да җитешми. Комиссар белән командирны юк итик тә...

Мәхмүт. Командир минем дустым.

Садрый. Ул вахмистр. Без килешә алырбыз. Соң чиктә ялгышын ул да аңлар.

Мәхмүт. Капитан әфәнде, китегез моннан, югалыгыз. Дусларыма хыянәткә өндәмәгез. Үз гомеремдә беренче тапкыр чын дуслар таптым. Каян килеп чыктыгыз сез, кара күләгә?!

Садрый. Ул чагында комиссарны...

Мәхмүт. Комиссарга якын барасы булмагыз!

Садрый. Поручик, сез, чыннан да, кансыз кеше икән. Бер көчле атакадан батальоннан йомычка да калмас!

Мәхмүт. Үзем дә шулай уйлап курыккан идем, капитан. Калдылар, җанкисәкләрем. Яхшы батальон, әйбәт солдатлар!

Садрый. Кызыллар китеп ычкынганчы, без барып басарбыз! Сез шушы һәйбәт батальонның бердәнбер командиры.

Мәхмүт. Мин болай да аның командиры. Капитан, буталмагыз монда!

Чыгып китә, Садрый да аңа иярә. Куаклыкта кала. Шамил белән Зәкия очрашалар.

Зәкия. Бүген йоклаган да юк кебек, төшемә, әллә ничек, гимназия килеп керде. Танцалар икән дим... Сез дә шунда, имеш. Кадет формасыннан. Биибез, биибез... Фабрикант Акчурин да шунда. Пычак тотып сезнең арттан әйләнә.

Ш а м и л. Төш артык куркыныч булганда уянасың да котыласың, Зәкия туташ! Аклар пушкалар тарттыра. Ниһаять, батальонның каты чикләвек икәне аларның исерек миләренә барып җитте!..

З ә к и я. Аңлыйм...

Ш а м и л. Сезгә дә эш кыенлашыр.

З ә к и я. Үзегезне саклагыз, Шамил...

Ш а м и л. Оренбург өчен борчылам.

З ә к и я. Сез миңа кинә сакламыйсызмы?

Ш а м и л. Нигә?

З ә к и я. Очрашсак, сөйләшмибез дә...

Ш а м и л (*көлеп*). Дутов атаман гаепле. Аның казаклары без очрашканны сагалап кына торалар, хәзер атыш башлана.

З ә к и я. Мәхмүтне Сызраньнан алып китеп дөрес эшләгәнмен бит, Шамил. Ул монда бөтенләй үзгәрде... Чын командирга әйләнеп бара...

Ш а м и л. Нигә ата башламыйлар инде?

З ә к и я. Сез мине тыңламыйсыз...

Ш а м и л. Мин аръякны тыңлыйм... Шөбһәле тынлык... Мәхмүт дидегезме?.. Аңа, кайчан да булса бер, кеше булырга тырышырга кирәк иде ич! (*Атыш башлана.*) Ниһаять! Башлана!.. Әйдәгез... Дошман белән каракаршы торганда тынлык һәрчак куркыныч.

Чыгалар. Садрый Шамилне сагалый. Т а җ е т д и н белән К а р и б керәләр.

К а р и б. Таҗетдин, күзең артта да, алда да булсын. Кешеләр бик алҗыган, куркынып-нитеп чигенер булмасыннар.

Т а җ е т д и н. Карармын, иптәш командир.

Чыга. Э л е м т ә ч е керә, ул арыган, тирләгән.

Э л е м т ә ч е. Командир!.. Командир, иптәш Коростылев сездән тагын сигез сәгатькә түзүне үтенде... Су бирегез, су!

Г ө л җ а м а л су бирә.

Тагын егерме ике эшелон... Кемдер паровозларны ватткан... Соңгы эшелон тулаем сезнеке! Ул резервта...

К а р и б. Ә корал? Корал?

Э л е м т ә ч е. Дутовчылар Шәңгәр авылында йөз сиксән кешене суеп чыкканнар. Беркемне аямаганнар.

К а р и б. Иптәш Коростылевка әйтегез: батальон сынатмас!

Чыгалар. Б и ш - а л т ы  г в а р д е е ц кача-кача камышлыкта күренә.

— Күперне алмакчылар...

— Аръякта кырык мең казак җыелган, ди...

— Алайса, бетте инде башлар.

М ә х м ү т (*чабып керә*). Кайда винтовкаларыгыз? Хәзер үк урыннарыгызга, марш!

Тегеләр алга үрмәлиләр, агачлыкта С а д р ы й күренә.

С а д р ы й. Поручик әфәнде, Черноярны мин онытырмын. Тик сез дә, сез дә!.. Ишетәсезме, хәзер иң уңайлы момент! Батальон соңгы сулышын ала.

М ә х м ү т. Юк, капитан. Без әле сугышып карыйбыз!

С ә г ъ д е т д и н керә. Садрый кача.

С ә г ъ д е т д и н. Кайда ул мәлгунь?

М ә х м ү т. Син нишләп урыныңда түгел, бабай?

С ә г ъ д е т д и н. Теге яңа бәндәне эзлим. Садретдин атлымы диде, эт белсен. Комиссар миңа үзе кушты, күзеңне алма диде. Карасам, качкан.

Агачлыкта С а д р ы й күренә.

Әнә йөри бит.

С а д р ы й (*Мәхмүткә*). Иптәш командир...

М ә х м ү т. Барыгыз... Аны мин чакырткан идем.

С а д р ы й. Киттек, кәҗәсакал.

Чыгалар. Мәхмүт гвардеецларны әйдәп китә. Г ө л җ а м а л керә, әйбер-караларны җыештыра. Туп ярыла.

Г ө л җ а м а л. Ходаем-мәүлям, үзең сакла.

Балык күтәреп, К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц керә.

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Әбекәй, кеше-мазар күргәләгәнче шушыны майда куырып кына бирче.

Г ө л җ а м а л. Әнекәй генәм, әллә тере инде? Каян алдың?

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Сул флангка ярга куйдылар безне. Таң белән йокыдан уянсам, Сакмар өстендә балык уйный. Менә әкәмәт! Җиләннән җеп сүтеп алдым, тимер чыбык бөгеп кармак әмәлләдем. Балык кап, яр буенда ялтырап ят. Салуым булды, колак төбемдә пулялар выж галләм! Аклар, тегеләр, карап кына яталар икән. Юк инде, абзыкайлар дим, балыкны тиккә «Эпипә»гә биетеп булмас. Тотындык атышырга?.. Иптәшләр ата, мин кармак салам. Икене төшердем, өченчесе какраз килеп капты. Чат май, иеме?

Каюм үтеп бара.

Каюм. Инде монда килеп суган сатасыңмы?

Күшәүче гвардеец. Бер аягым монда, икенчесе тегендә.

Каюм. Урыныңнан киткәнеңне тагын бер күрсәм, мәңге купмаслык итәм. Кыяматтә дә кымшана алмассың.

Күшәүче гвардеец. Йә, йә, кәпәренмә! Синең каршыңда надан патша солдаты түгел, доброволь красный гвардеец.

Гөлжамалга ым ясап чыгып китә, Кариб белән Шамил керәләр.

Шамил. Менә, командир, сыналыр чак башлана.

Кариб. Куркыныч...

Шамил. Пулеметларны фланглардан алырга туры килер.

Кариб. Мәхмүт белән киңәшик.

Мәхмүт керә.

Йә, военспец, нәрсә тәкъдим итәсең. Күрәсең, кысалар.

Шамил. Без боҗрада түгел, бусы шәп.

Мәхмүт. Патроннар аз, күперне шартлатыйк.

Кариб. Нигә куркып калдың, дус кеше. Комиссар, син сөйлә.

Шамил. Сүз кыска: түзик. Дутов төп көчләрен күпер аша чыгарырга ашыга. Аның кабалануыннан файдаланыйк, бер йодрык булып тупланыйк.

Кариб. Дөрес. (*Кычкырып.*) Әйдәгез!

Китәләр. Атыш тавышлары. Ур-ра кычкыралар. Гвардеецлар куркып чигенәләр. Иң алдан Садрый кача.

Садрый. Бетерәләр безне. Форсат барда качып котылыйк. (*Яшеренә.*)

Тавышлар.

— Беттек, егетләр. Туптан җибәрәләр.

— Илле мең солдатларына йөз илле туплары бар, ди.

Үсмер гвардеец. Фәсхетдинне үтерделәр, күрше абыем иде. (*Елый.*)

Кариб (*чабып килә*). Кая качасыз? Стой! (*Наганнан ата.*) Туктагыз! (*Тегеләр яталар.*) Урыннарыгызга барыгыз, туганнар.

Сакаллы гвардеец. Безнең урын җәһәннәмдә. Ашыксаң, әнә Дутов туп-туры шунда озатам, ди.

Кариб. Кругом, марш!

Гвардеецларны әйдәкләп җибәрә. Каюм керә.

К а ю м. Командир! Дутовчылар күпергә керә башладылар. Безнекеләрне кысрыклыйлар.

К а р и б. Пулеметларны фланглардан алып күпер маңгаена куегыз... Бар, чап!

К а ю м чыга. Гвардеецлар чигенәләр. Капчыкларын күтәргән, мылтыгын кочаклаган С ә г ъ д е т д и н дә керә.

С ә г ъ д е т д и н. Йә Алла, пәрвикадир... Өскә үк киләләр бит, өскә үк... Тәмамысы котырганнар.

К а р и б. Туганнар, үлсәк үләбез, чигенмибез! Их, бер сотня кылыч!

Б е р г в а р д е е ц. Түзәр әмәл юк, командир.

К а р и б. Тагын бер карыш чигенсәгез, үзем атып бетерәм.

Тәртипсез чигенү. С ә х и, К а ю м, Ш а м и л керәләр.

Ш а м и л. Сез монда икән. Сәгъдетдин абзый, син дә мондамы? Капчыгыңны ташладыңмы? Яле, чиш, күрсәт, ни бар анда? (*Сәгъдетдин кабаланып капчыгын чишә, кәләпүшне ала.*) Карагыз, иптәшләр, бу кәләпүшнең ике ягында да тишек. Пуля эзе! Сәгъдетдин абзыйның улын ак казаклар атып киткән. Бер гаепсез сабый баланың канын койганнар. Әгәр без хәзер казакларны үткәреп җибәрсәк, алар бер түгел, меңбаланың гомерен кисәчәк. Дошманга үкчәңне күрсәтергә алып килдеңме ул кәләпүшне, Сәгъдетдин абзый?!

К а ю м. Комиссар, мин синең белән!

С ә х и. Шамил абый, мин дә синең белән!

Ш а м и л. Пулеметчылар, алга! Хәзер патроннарны кызганмагыз!

С ә г ъ д е т д и н. Мин дә синнән калмыйм, Шамил улым.

Б а ш к а л а р. Ур-ра!

Шамил иң алдан, башкалар аның артыннан күпер ягына ташланалар. М ә х м ү т күренә. С а д р ы й керә.

С а д р ы й. Мәлҗерәгән бәндә икәнсез, поручик.

М ә х м ү т. Ничек, күперне алдыгызмы?

С а д р ы й. Комиссарыгызны...

М ә х м ү т. Комиссарга кагыласы булмагыз!

Садрый китә.

Кирәк булса, комиссарны мин үзем... Үзем!

Чыга. Г ө л җ а м а л, С ә к и н ә, З ә к и я яралыны алып керәләр, бәйлиләр.

С ә к и н ә. Куалар, күпер өстеннән акларны куалар.

Гөлҗамал. Ходаем, бар булган афәтеңне ак казак өстенә сал!

Зәкия. Мәхмүт тә Шамил янында. Иң алдан баралар!

Сәкинә белән Зәкия яралыны алып кереп китәләр, куаклыкта Күшәүче гвардеец күренә.

Күшәүче гвардеец. Әбекәй, әбекәй! Сакмар өстендә туплар ярыла... Ул балык, ул балык... Чиләк бир әле. Аклар ягына акмасын. Ашамый торсыннар! Җыеп алам мин аны.

Гөлҗамал. Һай, яхшы атадан яман туган! Каюм урыныңнан купма дидеме? Бирермен мин сиңа чиләк, Дутов фиргавене! Бар урыныңа!

Күшәүче гвардеец. Совет балыгын аклар ашасынмы? Һе, шәп, шәп... Йә, йә, ипләбрәк.

Гөлҗамал. Чүмеч белән кундырсам, ипләп булыр.

Күшәүче гвардеец чыгып китә.

Сәгъдетдинне күр син, тора-ята, өйләндererлек егет икән ләбаса!

Көчле ур-ра тавышлары. Кариб, Шамил, Мәхмүт, Сәгъдетдин керәләр.

Кариб. Коткардың, Шамил, батальонны коткардың. Егет син.

Шамил. Оренбургны коткарган егетләргә укы рәхмәтеңне. (*Гвардеецларга күрсәтә.*) Исәннәргә дә, Сакмар ярларында ятып калганнарга да укы.

Мәхмүт. Һич ышанмаган идем, честное слово!

Кариб. Сиңа да рәхмәт, Мәхмүт... Ничек чаптылар!.. Эх, бер эскадрон булса. Куып барып йоннарын туздырыр идек. Шашки во-он! (*Күз яшьләрен сөртә.*) Ничек чабалар!.. Рәхмәт сезгә, егетләр. Батальон исеменә тап төшермәдегез.

Элемтәче керә.

Элемтәче. Иптәш командир! Иптәшләр! Оренбургтан соңгы эшелон озатылды. Сезгә чигенергә приказ бирелде. Иптәш Коростылев большевиклар партиясе исеменнән татар батальоны сугышчыларына, командирларына рәхмәт белдерә. (*«Ур-ра» кычкыралар.*)

Шамил. Хәйрүш агай! Менә хәзер шартлатсак та була!

Хәйрүш. Үтибез аны, Шамил малакаем, кадерле иптәш комиссар. (*Чыга.*)

Шамил (*кәләпүшне Сәгъдетдингә бирә*). Мә, Сәгъдетдин агай, сакла кәләпүшеңне.

Гаскәр туплана башлый. Көчле шартлау тавышы. Барысы да баш киемнәрен чөяләр, «ур-ра» кычкыралар. Бер кырыйда тәксе генә торган Садрый янына Мәхмүт килә.

Мәхмүт. Күздән югалыгыз, капитан... Яхшы чакта югалыгыз!

Сәгъдетдин (*Садрый янына барып*). Син дә табылдың!

Садрый. Монда мин, кәҗәсакал. (*Стройга басалар.*)

Шамил. Рәхмәт сезгә, батырлар! Төрле чаклар булды, әмма сезне яралы Оренбургтагы бик күп большевик, эшче семьялары онытмас. Сез аларны ак казак үченнән саклап калдыгыз. Ил моны берчакта да онытмас. Ә илнең хәтере мәңгелек! Хәзер походка!

Мәхмүт. Песню начинай! (*Батальон дәшми.*)

Кариб. Сәләхетдин, башла әйдә.

Бер гвардеец. Ул юк инде, командир. (*Тынлык.*)

Кариб. Алайса, Бари башласын.

Таҗетдин. Ул да калды.

Кариб. Кәлимулла.

Сәхи. Сакмар ярына күмдек.

Шамил. Алайса, егетләр, җырламыйча гына барыйк.

Акрын музыка. Батальон сак кына кузгала.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кечкенә генә тимер юл станциясе. Дала. Эшелоннар утын, су алырга туктаганнар. Пәрдә ачылганда утын, су күтәреп мадьяр, татар солдатлары үтеп тора. Алгы планга татар батальоны гвардеецлары җыелышкан. Бер егет гармун уйный. Күшәүче гвардеец шәп кенә бии. Садрый, Сәгъдетдин, Сакаллы гвардеец тамаша итәләр, кул чабып такмаклыйлар.

Күшәүче гвардеец (*биеми торучыларга*). Нәрсә карап каттыгыз? Селкенеп калыгыз. Вагоннарда килә-килә аяклар чабагач таягына әйләнде.

Бер гвардеец. Хак шул, җилкәләр кунадай катты.

Сакаллы гвардеец. Тузаннарыгызны коеп калдырыгыз, югыйсә паровозга авырга килә, чак тарта, бичара, пуф-пуф килеп бара.

Каюм керә, гармунчыга барып ябыша, туктата.

Каюм. Бетер сабан туен!

К ү ш ә ү ч е гвардеец. Командирлар ишәйде түгелме? Эте дә командир, бете дә командир. Иснәп кара әле, ни исе килә? (*Йодрыгын Каюмның борын төбенә тери.*)

К а ю м. Син әрвах утырган эшелон Дутов итчеләре кулына төшмәсен өчен чыбыкны мин ташырга тиешме? Куып җитсәләр, кәтлит ясыйлар бит үзеңнән!.. Ал йодрыгыңны, черек бәрәңге исе килә... Син, син, син! (*Бераембераем төртеп күрсәтә.*) Типтереп ятасызмы? Эзегезне суытыгыз моннан! Хәзер үк.

С а д р ы й. Каты куя, каты... Фәрман ташучы фәрештә кебек. Хуп, хуп...

К а ю м. Әй син, сунарчы, авызыңны үлчәп ач.

К ү ш ә ү ч е гвардеец. Юлыңда бул, Каюм. Без доброволь, уйна, егет!

А н а р х и с т. Дөнья бүген генә!

Б е р ә ү. Шулай шул!

А н а р х и с т. Әйттереп-типтереп калыйк.

К а ю м. Әйләнеп килгәндә монда булсагыз, карагыз аны. (*Чыга.*)

С ә г ъ д е т д и н. Каюм дөрес әйтә бит, балалар, хак сөйли.

С а к а л л ы. Хак сөйләсә дә, нахак сөйләсә дә үз авызы.

К ү ш ә ү ч е гвардеец. Комиссар ялагае диген.

С ә г ъ д е т д и н. Эшләмичә алга барып булмас, балалар. (*Чыга.*)

К ү ш ә ү ч е гвардеец. Акылы зәгыйфьнең биле бөгелә!

С а к а л л ы. Җәмәгать, торып-торып шаккатам: кыш уздырыр өчен далага чыгу кемгә хаҗәт икән?

С а д р ы й. Йомшак җиреңне утлы әтәч тешләсә, кая барасың?

К ү ш ә ү ч е гвардеец. Ничек кая?

С а д р ы й. Шәһәргә кайтыр идең — Дутов... Уңда — аклар. Сулда — чехлар. Бабай мәрхүм әйткәндәй, кругом шестнадцать! Хочешь не хочешь, далада кышларсың.

Б е р ә ү. Бергә-бергә кышлыйбыз аны, егетләр.

И к е н ч е с е. Мадьярларны кара син, кырмыска күк эшләп йөриләр.

Хуплау тавышлары, барысы да чыгып китәләр. З ә к и я утын күтәреп килә. М ә х м ү т аны каршы ала.

М ә х м ү т. Зәкия туташ, сезгә яралылар янында да эш җитәрлек ич! (*Утынын ала.*)

З ә к и я. Уф...

М ә х м ү т. Сез беләсез микән, кышны дала уртасында утырган Актүбә станциясендә уздырачакбыз.

З ә к и я. Шамил әйтә, Ташкент тимер юлын аклардан сакларга барабыз, ди.

М ә х м ү т (*ирония белән*). Ну, ул әйткәч рас була инде.

Чыгалар. Утын күтәреп С а д р ы й керә. Шамилне күреп юри абына, утыннары чәчелә.

Ш а м и л (*кереп*). Аварияме, Садрый иптәш.

С а д р ы й. Зарар юк, хәзер җыям.

Шамил иелеп чәчелгән утыннарны җыеша. Садрый шул чак куныннан пычак алып кадарга итә, М ә х м ү т күренә.

Ш а м и л. Сез үзегезне рабочий дидегезме?

С а д р ы й. Әти дә, бабай да рабочий булганнар.

Ш а м и л. Рабочий кеше эшне тизрәк һәм пөхтәрәк эшләр иде! (*Чыга.*)

С а д р ы й. Комачаулыйсың, поручик.

М ә х м ү т. Бик тиз үзегезгә теләктәш итмәкчесез, капитан әфәнде.

С а д р ы й. Көлке, бер асрау кыз өчен большевикларга сатылгансыз.

М ә х м ү т. Беренче бурычыгызны үти алмадыгыз, капитан. Кызык, атаман сезгә икенче бурыч та йөкләмәдеме икән?

С а д р ы й. Өченчесен дә йөкләде, поручик әфәнде.

М ә х м ү т. О?!

С а д р ы й. Сездән сер юк. Татар батальонындагы ризасызлыктан файдаланып, Ташкентка китәргә үгетләргә кирәк. Батальон чигенүче Оренбург гаскәрләреннән аерылсын. Юлда, җай белән генә, без аларны үзебезнекеләр ягына чыгарырбыз.

М ә х м ү т. Югыйсә, капитан әфәнде Дутов җәнаплары янына кайтырга курка!.. Ха-ха-ха!

С а д р ы й. Онытмагыз, сез татар батальонының командиры.

М ә х м ү т. Булып чыкмас, капитан.

С а д р ы й. Минем түземлекнең дә чиге бар, поручик.

М ә х м ү т. Минем түземлекнең чиген оныттыгызмы, капитан?! Югалыгыз моннан!

Чыгалар. Ш а м и л белән С ә х и керәләр. Икесе дә утын күтәргәннәр.

С ә х и. Чыннан да безнең тормыш сез сөйләгәнчә булырмы, Шамил абый?

Ш а м и л. Безнең көрәш корбаннарының мәгънәсе шунда, Сәхи.

С ә х и. Заманнар узар, сез әйткәндәй, яңа тормыш

төзербез. Шул чак миңа, «Әһә, син Сары бай малае идең бит!» дип, беркем дә бәйләнмәсме?

Шамил. Без кешелексезлекне рәхимсез рәвештә кисеп ыргытырбыз.

Сәхи. Мин бит надан, Шамил абый. Күргәнем кибет тә мәчет кенә.

Шамил. Юк, Сәхи, син хәзер надан түгел. Ирек өчен көрәшеп караган кеше, ирекнең нәрсә икәнен татып караган кеше — иң бәхетле кеше, Сәхи!

Үтеп китәләр. Сәхнәдә хәрәкәт дәвам итә. Менә утын күтәреп, иренеп кенә Сакаллы гвардеец, Күшәүче гвардеец һәм башкалар үтеп баралар. Вагон астыннан иелеп берәү бу якка чыга. Кызыл чапан кигән, гвардеецлар аны туктаталар.

Сакаллы гвардеец. Абзый, монда мәчет юк.

Күшәүче гвардеец. Бәй, үзебезнең Әптери ич бу.

Сакаллы гвардеец. Каян мондый чапанны әләктердең?

Әптери. Әчтерханнар! Монда якында гына базар бар икән бит. Өр-яңа чапаннар унбиш тиен көмеш тора. Йөге белән ал.

Узып барган җиреннән Садрый да туктала.

Күшәүче гвардеец. Китчәле.

Әптери. Чәчрәп китим.

Аны урап алалар, чапанны капшыйлар, тешләп карыйлар.

Берәү. Мал дисәң дә мал.

Икенчесе. Авылга шундый чапан киеп кайтсаң, ә? Күзләре чабата калыбы була инде, ә?

Тавышлар.

— Нәрсәгә ул чапан?
— Бушлай бирсәләр дә, тфү!
— Ат булсын иде ул, ат!

Әптери. Туң исәрләр. Бер йөк чапан сатасың да акча аласың. Акчаң булды исә — ат синеке.

Күшәүче гвардеец. Төтене туры китте түгелме моның? (*Янчыгын чыгарып акча санарга тотына.*)

Сакаллы гвардеец. Базар шушында гына дисеңме?

Садрый. Йөрмәгез! Шушындый чүпне алалармы? Күзегез чыкканмы әллә? Тегелеше ипсез, ефәге кыштырдамый... Чын кытай ефәгеннән тегелгәне унбиш тиен көмеш тора аның.

Күшәүче гвардеец. Кайда, Кытайдамы?

Б е р ә ү. Кытайда анда чапанга өстәп кыз да бирәләр, ди.

Ә п т е р и. Чыгарып тоттыралар...

С а д р ы й. Нигә Кытайда! Кытайда! Кытай ерак... Ташкентта да өелеп ята мондый мал.

И к е н ч е. Чапан дип җир читенә барып булмый инде.

Ә п т е р и. Әтрәтне ташлап кем йөрсен? Әнә генә ич базар, әчтерханнар.

С а д р ы й. Отрядны һич тә ташларга ярамый. Дөрес! Бөтен отряд белән китәргә кирәк.

Б е р ә ү. Ничек?

С а д р ы й. Без бит доброволь! Сүз берләшәбез дә бөтенебез китәбез. Анда, ичмасам, җылы, кыш булмый, утын ташып чиләнәсе юк. Ул Ташкент базарын күрсәгез икән, ул сатучы үзбәкләр. «Әкә, нугай әкә!» дип өзелеп торалар, татарларны яраталар.

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Теге йөземле яклар бит әле ул, иеме?

С а к а л л ы  г в а р д е е ц. Чын кытай ефәгеннән теккән дисеңме? Ун тиен дисеңме?

С а д р ы й. Җәннәт белән тиң йөртәләр аны Ташкентны. Кыш буена ач далада буранда ыжлап утырганчы, Ташкентта ак күмәч ашап ятарбыз. Аклар анда да җитәрлек.

Ә п т е р и. Приказ булса, китәрсең, булмаса, нишләрсең?

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Авыз ачып утырсаң, чабата киптереп калырсың, вәт. Рабочий дөрес сөйли.

С а к а л л ы. Әллә соң, егетләр, чынлап торып тәвәккәллибезме?

Ә п т е р и. Башкалар китсә, без ник калыйк? Түлке бу чапанны берәрсенә бөдәп, килеп җитеп булырмы? Ә, әчтерханнар?

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Кышның корсагы зур... Утыз ике җитезне киштәдә тотып булмас. (*Тешләрен күрсәтә.*)

С а д р ы й. Персидәтел сайлыйбыз! Менә сине!

Күшәүчене күрсәтә. Х ә й р ү ш  үтеп бара.

Х ә й р ү ш. Китәбез дә китәбез дисез, каюк бармакчы буласыз?

Т а в ы ш л а р.

— Китәбез!

— Төркстанга барабыз!

Х ә й р ү ш. Китәсең икән, кит. (*Күшәүче каршысына баса.*) Безне котыртма. Оренбурдан беркая китмибез. Шушында революция ясадык, шунда сугышабыз, шушында үләрбез дә!

Б е р н и ч ә  т а в ы ш. Дөрес!

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Инде син дә комиссарга ялландыңмы? Блюхер китә, Жлобин отряды китә, син безне төпсез чуманда утыртып калдырмакчы буласыңмы? Бернәрсә булса, сөекле комиссарың белән җиңел генә утырып сызарсыз, без, җүләрләр, терсәк тешләп калырбыз.

С а д р ы й. Дөрес сөйлисең, агайне. Кыш уртасында әллә кая барып йөри алмассың!

Х ә й р ү ш. Кем җибәрде сине монда коткы таратырга?

Б е р ә ү. Ошамаса, тыңлама, сыптыр моннан!

К а р и б белән К а ю м керәләр.

К а р и б. Нигә ташымыйсыз? Хәзер кузгалырга команда булачак.

Х ә й р ү ш. Кариб малакаем, иптәш командир, әле дә ярый килеп җиттең. Батальонны Төркстанга китәргә котырталар, гаскәрдән аерырга.

С а к а л л ы  г в а р д е е ц. Кем безне көчли ала? Без доброволь!

Ә п т е р и. Китәбез.

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Менә бу халык сөйләшү өчен мине персидәтел итеп сайлады, эһем-эһем!

К а р и б. Мин сине, персидәтел... (*Наганына тотына.*) Көлсидәтел ясыйм!

К а ю м. Шамилне чакырырга кирәк, комиссарны! Китегез бер кырыйга, тайпылыгыз, а ну!

Шау-шу, кычкырыш, Ш а м и л, С ә х и, С ә г ъ д е т д и н, М ә х м ү т, З ә к и я керәләр.

С а к а л л ы  г в а р д е е ц. Гайрәт җитмәгәч, наганга ябышасызмы?

К а р и б. Комиссар! Батальонда фетнә. Төркстанга китәбез, аерылабыз, дип кычкырыналар.

С ә г ъ д е т д и н. Әллә инде хаҗга ук баралармы?

К ү ш ә ү ч е  г в а р д е е ц. Вәгазь укып маташма, комиссар, барыбер китәбез.

Ә п т е р и. Наган белән дә өркетмә.

С а к а л л ы  г в а р д е е ц. Бауга бәйләп йөртергә өркәчле дөяләрме әллә без? Китәбез тек китәбез!

К а р и б. Тынычланыгыз! Җибәрермен мин сезне!

К а ю м. Тайпылыгыз, ну!

К а р и б. Нигә дәшмисең, комиссар?

С ә х и. Шамил абый, иптәш комиссар, нишләтәбез? (*Пауза.*)

Ш а м и л. Китәргә теләгәннәр китсеннәр!

К а р и б. Ничек?! Берәүне дә җибәрмим. Каюм, чап мадьярлар вагонына! Бездә фетнә диген.

Ш а м и л. Ашыкма, Каюм... Иптәшләр! Большевиклар партиясе оешмасының карары буенча без Актүбәдә тукталабыз. Чигенү тәмам. Аннан ары бер адым да китәчәк түгелбез. Без Ташкент тимер юлын дошманга бирмәскә бурычлы. Сафларны ныгытып төзибез дә Оренбургка һөҗүм башлыйбыз!

Т а в ы ш л а р.

— Китәбез! Даешь!

— Ур-ра!

Т а в ы ш л а р.

— Китмибез!

— Ур-ра!

С ә г ъ д е т д и н. Аерылганны аю ашар, ә Дутов кебек ерткыч җанвар батальон кадәр батальонны бер генә кабып йотар.

Ш а м и л. Алда җиңеллек булыр дип берәү дә көтмәсен. Далада ярым камалышта кышлау уен түгел. Ком бураннары, ком буранынннан да хәтәррәк дутовчылар булыр. Икмәк, кием, ягулык, хәтта бер төрерлек тәмәке дә күктән яумас. Барын да аклардан сугышып алырбыз. Җиңү өчен без барын да үзебез башкарырга тиеш. Кем авырлыктан курка, кемнең җилкәсе җылыны сагынган, китсен. Хәзер кыен, алда тагын да авыррак булачак!

К а р и б. Җибәрмим. (*Шыпырт.*) Батальонсыз калыргамы?

Ш а м и л. Борчылма, Кариб. (*Кычкырып.*) Китәргә теләгәннәр әнә теге читкә басыгыз.

С ә х и. Егетләр, куркыныч алдында бил бирер өчен Кызыл гвардиягә язылдыкмы?

К а ю м. Китүче куркакларны арестовать итеп, атарга!

К ү ш ә ү ч е г в а р д е е ц. Китәбез, җәмәгать! Актүбәдә бет симертеп ятар җай юк.

Беренче булып читкә чыгып баса, берән-сәрән генә аңа ияриләр.

К а р и б. Бетә, бетә батальон! Мәхмүт, нигә дәшмисең?

М ә х м ү т (*Садрыйдан күзен алмый*). Ни әйтим соң?

К а ю м (*Садрыйга*). Ә син нигә чыкмыйсың, бушбугаз? Рабочиймы әле син?

С а д р ы й. Басмыйм. Революция өчен монда эшлисе эшләрем бар.

Х ә й р ү ш. Алайса, ник кычкырындың?

К а ю м. Унҗиде куркак... Башкалар китәргә теләмиләр, иптәш командир!

Ш а м и л (*Карибка*). Күрдеңме?.. Яхшы. Барыгыз, китегез. (*Садрыйга.*) Ә сине, бик шәп үгетләгән өчен, әзрәк капшап карарбыз. Сәхи, сак астына ал.

Сызгырып, шау-шу белән тегеләрне озаталар. Сәхи белән бер гвардеец Садрыйны сак астына алалар.

Т а җ е т д и н (*керә*). Иптәш командир, су, утын җитәрлек кадәрле ташылып бетте.

К а р и б. Вагоннарга утыра башлагыз!

Гвардеецлар вагоннарга төяләләр.

Шамил, әгәр бөтен халык китеп барган булса?

Ш а м и л. Китмәделәр ич.

К а р и б. Боларын да юкка җибәрдек.

Ш а м и л. Үзебезне сынап карыйсым килде! Батальонга ышанмыйча булдыра алмый идем. Безгә хәзер башка отрядлар белән кушылырга туры килә. Владимир Ильич Кызыл Армия төзергә куша. Кушылырдан элек без регуляр армиягә кемнәрне алып баруыбызны анык белергә тиешлеме? Беләсең килсә, бүген шул сынау көне булды.

Паровоз кычкырта.

К а р и б. Кушылырбызмы, юкмы, анысын әле кем белгән?!

Ш а м и л. Кузгалабыз.

Чыгалар. Сәхи Садрыйны алып бара, М ә х м ү т аларга каршы килә.

С ә х и. Нигә туктадың, атла!

С а д р ы й (*Мәхмүткә*). Командир, ни гаебем бар иде минем?

М ә х м ү т. Безнең ихтыяр белән эшләнмәде, дус кеше.

С ә х и. Тизрәк, тизрәк. Кузгалалар.

С а д р ы й. Хәзер, хәзер...

С ә х и (*Мәхмүткә*). Иптәш командир, эшелон кузгала.

М ә х м ү т. Ашыгыгыз, ашык.

С а д р ы й. Хәзер, хәзер...

Иелә дә, пычак алып, Сәхигә кадый.

М ә х м ү т. Син нишләдең, явыз!

С а д р ы й. Поручик, Черноярны онытма.

М ә х м ү т. Куркытма, бандит.

С а д р ы й. Ансат кына котыла алмассың! (*Мәхмүткә барып ябыша.*) Дутов җәнапларының өченче поручениесе бар дидемме? Сезне алып чыгарга тиеш идем мин, поручик. Курыкма, безнекеләр моннан дүрт-биш чакрымда гына.

М ә х м ү т. Юк! Дутовның бер поручениесен дә үти алмадыгыз, капитан. Аклар станына кайтырга куркасызмы?

Садрый. Поручик! Черноярдан карательный экспедициядән кайткач язган рапортыгыз минем кесәдә. Сез лично дүрт большевикны...

Мәхмүт. Бүре сез, капитан!..

Садрый. Чапкын белән мин аны Шамил Усмановка җибәрә алам. Җүләр сатмагыз, поручик, без гомерлеккә бергә бәйләнгән! Әйдәгез!

Мәхмүт. Бәхил бул, Зәкиям!

Садрый. Дөньяда матурлар беткәнме, поручик?!

Вагоннар теркелдәп китеп баралар, кинәт Сәкинә тавышы яңгырый.

Сәкинә. Сәхине үтерделәр, Сәхине үтерделәр!

«Көзге ачы җилләрдә» көе яңгырый. Җыр көчәя, паровозлар туктаусыз кычкыралар.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Актүбәдә мәдрәсә бинасы. Хәзер монда татар батальонының штабы. Пәрдә ачылганда Сәкинә бүлмә җыештырып йөри. Аяк очларына гына басып Каюм керә. Кулында гармун. Бер почмакта песи булып кына утыра да уйный. Сәкинә елый.

Каюм. Синең күңелне юатыйм дип уйнаган булам тагын...

Сәкинә. Сәхинең югалуына да ике атна узды бит, Каюм...

Каюм. Әйе... Актүбәгә килгәнгә дә ун көн...

Сәкинә. Нигә шул чакларда вагоннан сикереп төшмәдем икән дип өзгәләнәм... Әгәр мин җирдә ятып калсам, ул ике уйлап та тормас, сикерер иде...

Каюм. Хәлләр булган анда, чуалчык хәлләр... Теге бездән аерылган Ташкентлы хөрәсәннәр шунда урала... Ала күз Садрый шунда. Рабочий булмады ул!.. Җитмәсә Мәхмүт абый... Үзе дә бик шикле кеше.

Сәкинә. Зәкия апа шул Мәхмүтне ничек ярата ала икән?

Каюм. Аптырган инде... Комиссарны кире кагып, шул селәгәй офицерны... (*Тынлык. Каюм гармун уйный.*) Юк, Сәкинә, Сәхи исән булса, әсир төшә торган егет түгел ул.

Уйный. Сәгъдетдин керә.

С ә г ъ д е т д и н. Кызлар ничек чыдый сиңа, Каюм?.. Без картларның да үзәккәен өзәсең.

С ә к и н ә. Бу заман кызларының үзәкләре күптән өзелеп беткән, Сәгъдетдин абзый. Ак казаклар күпме яшь гомерләрне кыймаган?

С ә г ъ д е т д и н. Каюм, нәнкәем, миңа Шамил кирәк иде бит.

К а ю м. Таңнан мадьяр, немец командирлары белән сөйләшеп утыралар.

С ә г ъ д е т д и н. Немец белән диген, һе... Әллә кайлардан килеп революция ясап йөриләр диген...

К а ю м. Немецларның да төрлесе бар. Бар эшчесе, бар буржуе... Сиңа үз ишең немец ярлысы якынракмы, әллә алтын погонлы татар офицерымы? Моны да бик аңларга вакыт.

С ә к и н ә. Йомыш тапкан булып көн дә комиссар янына килә башладың әле, Сәгъдетдин абзый.

С ә г ъ д е т д и н. Бүген ни бит, теге, гает көн.

К а ю м. Комиссарны намазга өндәп килгән!

С ә г ъ д е т д и н. Монда гына җыелып укыр идек. Актүбә мулласы мәзинен ияртеп тегеләр белән качкан, нәләт... Тфү-тфү, әстәгъфирулла, әллә ни әйтеп салырсың... Елга бер килә торган бәйрәм ул, Каюм нәнкәм. Мөселман гаскәре ич без!

К а ю м (*фуражкасын алдын артка әйләндереп кия*). Бисмиллаһи рахман рахим... Купты, купты, яр башында опты... Авызы бияләй, борыны бармакча... Акча, акча! Йә, суз тизрәк садакаңны. Урының җәннәттә, мулланыкы тәрәттә... Доганың, гаетнең иң шифалысын укып бирәм. Суз, суз акчаңны, чыгар янчыгыңны!

С ә г ь д е т д и н. Син, Каюм нәнкәм, бала гына ич әле.

К а ю м. Ә комиссар?

С ә г ь д е т д и н. Комиссар — егет. (*Чыга.*)

К а ю м. Әйтә бу карт, нык әйтә!

С ә к и н ә. Солдатлар яткан бүлмәләрне әнкәй җыештыра. Штабка юри үзем керәм. Шунда Шамил абый очрар да берәр сүз әйтер төсле.

К а ю м. Их, Сәкинә! Комиссар егет шул!.. Барыбыз да аңа киләбез...

Кыз янына баса, кыз башын аның иңенә сала. Борчылган З ә к и я керә.

З ә к и я. Сәкинә!

С ә к и н ә. Әү, Зәкия апа.

З ә к и я. Сырпаланма егетләргә. Синең Сәхиең бар. Онытма.

К а ю м. Зәкия апа, Сәкинә арып кына башын салды ич.

З ә к и я. Берничек тә ярамый... Кем генә булмасын,ниләр генә күрергә язмасын, начармы-яхшымы, тугрылык белән үзенекен көтсен.

С ә к и н ә. Исән генә булсын берүк, кайтсын гына...

З ә к и я. Кайтамы, юкмы, барыбер көт.

С ә к и н ә. Йөз ел юлдан күземне алмам төсле... (*Чыга.*)

К а ю м. Кыз баланы юкка рәнҗеттегез, Зәкия апа.

З ә к и я. Кыз түзәр дә... Егет халкы әрсезрәк. Гармуныңны акыртасың да аның янына киләсең.

К а ю м. Дуслар ич без аның белән... Үзегез да комиссар янына таянып ял итәр кеше эзләп килмәдегезмени?

З ә к и я. Юк! (*Пауза.*) Менә анысы юк, Каюм.

Чыга. Гармун уйный. Каюм да чыгып китә. Х ә й р ү ш, Т а җ е т д и н, б е р н и ч ә г в а р д е е ц керәләр. Киемнәр сизелерлек үзгәргән, кораллар да башкачарак. Арада билләрен патрон ленталары белән ураган солдатлар да бар.

Х ә й р ү ш. Кайтмаган комиссар...

Т а җ е т д и н. Комиссар каршы килмәс, командир гына, белмим...

Х ә й р ү ш. Каршы киләме соң? Ул үзе дә шундый кинәтлекне ярата!

Б е р ә ү. Командир да ризалашыр. Тәмәке югын белә бит. Берәр якындагы станицага һөҗүм итеп аласы иде.

Т а җ е т д и н. Киемнәре безгә күчеп бара. (*Өс-башын күрсәтә.*) Английский сукно!

И к е н ч е (*чабатасына ишарәләп*). Мин генә һаман Хәйрүш агай иләге белән йөрим.

Х ә й р ү ш. Синең алып аяк булуыңа кем гаепле?

И к е н ч е. Әле дә ярый ике пар эләктереп калганмын.

Х ә й р ү ш. Синең ике аягыңа ике бишек кирәк. Ак казакка каян килсен андый итек?

Т а җ е т д и н. Моннан болай син аклар арасыннан иңиң эреләрен сайлап ат. Чуртаннарын. Югыйсә, кышны яланаяк чыгарсың.

Х ә й р ү ш. Аларда бар! Бөтен дөнья буржуйлары җибәреп тора!

С ә г ъ д е т д и н керә.

С ә г ъ д е т д и н. Бүген ни, гает көн бит, оланнар. Ни әйтсәң дә, без мөселман батальоны.

Б е р ә ү. Юк белән йөрмә әле, абзый.

И к е н ч е. Әйт, мәрхәмәтле Аллаң тәмәке табып бирә аламы? Бирсә, ягъни мәсәлән, гаеткә барам.

С ә г ъ д е т д и н. Мартукка барып гает укып кайтабызмы әллә?

Х ә й р ү ш. Барып кара, Мартуктагы аклар арт сабагыңны укытып җибәрерләр.

Т а җ е т д и н. Тәмәке бетте әле, Сәгъдетдин абзый, интегәбез.

Б е р ә ү. Вәт Мартукта тарталар инде ул тәмәкене!

Көлешәләр. Сәгъдетдин күңелсез генә чыгып китә. Мадьяр солдаты Л а й о ш керә.

Л а й о ш. Мөселман иптәшләр, мадьяр-татар — дус. Мадьяр-татар — революция! Интернациональ! (*Күкрәгенә кулын куеп күрсәтә.*) Тәмәке суыртыгыз, кардәшләр. Мадьяр үлә ярамый. Мадьярны өйдә кыз көтә. Гүзәл кыз!

Барысы да ашыгып-ашыгып янчыкларын чыгаралар, кесә актаралар.

Х ә й р ү ш. Берәүдә дә калмаганмыни?

Т а җ е т д и н. Лайошны буш җибәрергә ярамый.

Т а в ы ш л а р. Юк бит, карга чукыгыры!

— Биш төрерлеге җәл түгел.

Һәркем янчыгын Лайошның фуражкасына кага.

Л а й о ш. О! Менә бу безнең батальонга бүләк! Рәхмәт! Мадьяр-татар — дус, интернациональ!

Т а в ы ш л а р. Интернациональ, Лайош туган!

— Шулай!

— Мировая революция.

— Акларны кырып кына бетерик, аннары кунакка йөрешербез.

Шул чак Ш а м и л белән К а р и б кайтып керәләр.

Х ә й р ү ш. Смирно! (*Барысы да басалар.*)

Ш а м и л. Утырыгыз, утыр. (*Лайошны күреп.*) Без анда батальоннарны берләштерү турында командирлары белән сөйләшеп утырабыз, алар бездән алданрак өлгергәннәр түгелме, Кариб?

Л а й о ш. Мадьяр-татар — интернациональ, иптәш комиссар. Сугышта бергә пуф-пуф, тәмәке уртак пыф-пыф!

Хәйрүшне кочаклап ала да командирларга честь биреп чыгып китә.

Х ә й р ү ш. Киңәш бар иде, комиссар.

Т а җ е т д и н. Тәмәке бетеп китте.

Х ә й р ү ш. Аклар ягына тагын бер сәфәр ясап алыйк, дибез.

Т а җ е т д и н. Рейд кебегрәк нәрсә булсын, дибез...

Ш а м и л. Сәфәрләр ошап китте тагын үзегезгә... Ко-

рал өчен сәфәр, кием өчен сәфәр... Уйлашырбыз! (*Гвардеецларны озата.*) Кариб, күңелле хәбәр ишетәсең киләме? Мадьяр отряды татар батальоны белән кушылырга ризалык бирде.

Кариб. Кая әле монда кушылу... Эшләр яман! Мин иптәш Коростылев янында булдым. Ашхабадта контрреволюция. Мәскәүдән приказ алынган: ике полкны шунда җибәрәләр.

Шамил. Ә Оренбург нишли?

Кариб. Әйтеп бетермәдем. Дутов Орскига каршы зур көч ташлаган. Бер полкны шунда озаталар.

Шамил. Ташкент тимер юлының әһәмияте бермәбер арта...

Кариб. Мәскәүдә бунт. Сул эсерлар кораллы фетнә күтәргәннәр.

Шамил. Димәк, регуляр Кызыл Армия төзү турында Владимир Ильич үз вакытында карар биргән! Сигез яктан ташланган сигез башлы диюгә каршы без йодрык булып оешырга тиеш! Мадьярлар белән нәкъ кирәгендә сөйләшкәнбез! Корал ягы гына... Фәкать корал гына... Төркстаннан патроннар нигәдер килеп җитми...

Кариб. Ком чүлләре аша акрын адымлы дөяләрдә кичү җиңел түгелдер...

Шамил. Солдатларны хәзер үк җыябыз, аңлатабыз. Илдә, үзебезнең арада ни барын белеп, әзер булып торсыннар.

Кариб. Чак кына сабыр итәбезме әллә?

Шамил. Нигәдер әйтеп бетермисең.

Кариб. Әйе шул, менә газета...

Шамил. Ә-ә, «Алга» дип аталса да артка сөйри торган, татар буржуйлары, сәүдәгәрләре, ак гвардиячеләре газетасы. Каян кулга төшердең ул чүпне?

Кариб. Анда тагын сине телгә алганнар.

Шамил. Ачка койрык чәнчеп чаба дигәннәрме? Чабаталы батальонын бетләр кимерә дигәннәрме?

Кариб (*борчулы*). Бу юлы яңачарак. Мә, укы... (*Шамил ала.*) Сөйгән кызы өчен ак шпион Садрый Ваһаповны һәм хыянәтче поручик Урманаевны Дутов җәнаплары янына хәвеф-хәтәрсез генә озатып калды, дигәннәр...

Шамил. Кабахәтләр, төрле яктан капшаналар.

Кариб. Капшана торгач, шактый нечкә җирне эзләп тапканнар.

Шамил. Син шушы газетага ышанасыңмы әллә?

Кариб. Газетаны миңа Зәкия бирде, аны гвардеецлар да укыган. Мин кергәндә бәхәсләшеп яталар иде...

Димәк, кемдер аны безнең батальонга җиткергән!.. Син кара, зинһар, Зәкия белән ягымлырак бул...

Шамил. Кинаяләр белән сөйлисең, Кариб... Кисәтәсең... Кемдер шушы әшәке, кара ялганга ышангандыр, мөгаен...

Кариб. Анысы ук булмас! Шулай да бу хәбәр җайсыз вакытта килеп иреште.

Газетаны ерта-ерта чыга. Каюм керә.

Каюм. Шамил абый, сине Зәкия апа сорап кергән иде.

Шамил. Беләм! Мәскәүнең үзендә фетнә!.. Ашхабадта контрреволюция... Орскига ак бандитлар һөҗүм итә... Киләсе корал кайдадыр юлда... Шундый чакта Шамил Усмановның мәхәббәт маҗаралары... Юк, һич юк!

Сәгъдетдин керә.

Сәгъдетдин. Исәнме, Шамил улым. Иптәш комиссар.

Шамил. Уз, Сәгьдетдин абзый, утыр.

Сәгъдетдин. Вакытсызрак кердем дип әйтимме?

Шамил. Юк, юк, зарар юк.

Каюм. Мин монда гына, Шамил абый. (*Чыга.*)

Шамил. Солдат тормышына күнегәсеңме, Сәгьдетдин абзый?

Сәгъдетдин. Хәлләр ярыйсы. Өйрәнәм. Мылтык та җиңеләйгән кебек булды. Бомбасына да күнегәм. Шулай да чалгы сабы сагындыра...

Шамил. Өйрән, Сәгъдетдин абзыкаем, ух, ничек нык итеп өйрән!.. Әле шундый каты, аяусыз сугышлар булыр, ух, хәтта мин аны күз алдына да китерә алмыйм. Моңарчы булган сугышлар балалар уены кебек булып калыр... Полклар, дивизияләр, Кызыл Армия!..

Сәгъдетдин. Мин ни... теге бит, бүген...

Шамил. Әйе, әйе, дөрес сөйлисең. Бүген, Сәгъдетдин абзый, бүген!.. Штаблар, тәҗрибәле командирлар... Корал! Болар барысы да булыр... Совет власте барын да булдырачак. Нәкъ менә бүген! Ул чагында провокацияләргә дә, почмактан торып чалуларга да урын калмас! Күзгә- күз, Кариб әйткәндәй, шашки, во-он!

Сәгъдетдин. Ни инде... теге, кәләпүшне синдә калдырыйм дип кергән идем. Дөнья хәлен белеп булмый. (*Кәләпүшне чыгарып бирә.*)

Шамил. Ник алай уйладың әле? Үләргә җыенма. Рөхсәт юк. Ярамый. Беребезгә дә үләргә ярамый.

Сәгъдетдин. Синдә торуы хәерлерәк булыр.

Чыга. Шамил нервланып йөри, З ә к и я керә.

Ш а м и л. Зәкия туташ!

З ә к и я. Исемем һаман үзгәрешсез, үзем тәмам коры сөяккә калдым.

Ш а м и л. Әйе, сез үзгәрдегез.

З ә к и я. Зәкия — революционерка, Зәкия — Акчуриннар фабрикасында большевиклар агитаторы, хәзер җылак кыз... Нишлим соң?

Ш а м и л. Хәзер Зәкия — сугышчы!.. Мин дә элегрәк бер кулыма кылыч, икенчесенә чәчәк тотып йөри алырмын дип уйлый идем. Булмый, Зәкия туташ. Менә сез шуның мисалы! Кылычка да үреләсез, чәчәккә дә. Әгәр минем дүрт кулым булса, барысына да кылыч тотар идем.

З ә к и я. Шамил! Батальонның хәрби белгече, командирның дусты эшелоннан калсын инде! Әкият бит бу!

Ш а м и л. Монда мин гаепleme? Гомумән, мин сезне Мәхмүткә тып-тыныч кына, сабыр күңел белән тапшырды дип уйлыйсызмы? Монда сугыш гаепле! Кулларым буш түгел, Зәкия туташ. Сез мәхәббәт телисез, ә мин сугыш...

З ә к и я. Беләм, сез Мәхмүтне яратмыйсыз.

Ш а м и л. Яратмыйм, Зәкия туташ.

З ә к и я. Шуңа күрә аннан котылуны җиңел кичерәсез дә!

К а ю м керә.

К а ю м. Шамил абый, сине бер кеше сорый.

Ш а м и л. Керсен соң.

Каюм чыга, ө л к ә н р ә к  с о л д а т белән керә.

С о л д а т. Пластунский полкның өченче батальоны солдаты Хәсән Биктимеров булам. Вольный казак.

Ш а м и л. Ни йомыш, вольный казак?

Х ә с ә н. Гаепсез кешеләрне үтереп йөрисем килми.

Ш а м и л. Хуш! Нинди ярдәм күрсәтә алам сиңа?

Х ә с ә н. Сине дөреслек өчен көрәшәсең икән, дип ишеттек. Мин синең якта булырга телим.

Ш а м и л. Бездә кәнфит суырырга туры килер дип ялгышмыйсыңмы? Канга кан дип көрәшәбез ич!

Х ә с ә н. Дөреслек шуны сораса, мин әзер.

З ә к и я. Шамил, бәлки, ул Мәхмүт турында беләдер.

Х ә с ә н. Белгәнне яшереп булмас, матур туташ, кирәген сөйләрбез.

Ш а м и л. Кызыллар ягыннан чыккан Мәхмүт Урманаев дигән поручикны белмисезме?

Хәсән (*уйланып тора*). Татар поручигын әйтәсезме? Нигә белмәскә, беләм.

Зәкия. Ул хәзер исәнме?

Хәсән. Исән. Әсир дип әйтимме, болай гына йөридерме, капитан әфәнде белән гел бергә алар. Миннән Мартукта калдылар.

Зәкия. Аны әсир иткәннәр!

Шамил. Әсирләр арасында Сәхи Таһиров дигән егет күренмәдеме? Ишетәсеңме, вольный казак, Сәхи Таһиров!

Хәсән. Әсирләрне атып торалар... Күрмәгәнне күрдем дип әйтә алмыйм.

Шамил. Каюм, абзыйны урнаштыр. Ял итсен. Аннан сөйләшербез. Үзең монда кил!

Хәсән. Рәхмәт, комиссар туган, ышандың. Безнең гәҗитләр юкка гына көчәнмиләр икән, егет икәнсең! (*Чыгалар.*)

Зәкия. Шамил, ул һаман исән! Тик сез... Мәхмүтне кызыллар ягыннан чыккан дип нигә әйттегез?

Шамил. Үзем дә белмим.

Зәкия (*тагы да ярсып*). Әгәр мине — элекке кебек яратсагыз, коткарыгыз Мәхмүтне. Үтенәм, ялварып сорыйм.

Шамил. Сез миннән булдыра алмастайны сорыйсыз.

Зәкия. Аклар тылына ничә кат куркынычлы рейдлар ясадыгыз. Тагын бер тапкыр!.. Сез аны ике тапкыр үлемнән коткардыгыз. Өч булсын! Мин ике кулыма да кылыч тота алмыйм, Шамил, аңлагыз...

Шамил. Мәскәүдә фетнә... Ашхабадта контрреволюция... Орск хәл эчендә!..

Зәкия. Ә мин гап-гади хатын кыз, Шамил!

Шамил. Моны мин үзем генә хәл итә алмыйм!

Зәкия. Ә газета?..

Шамил. Газета?.. Яхшы!

Каюм керә.

Каюм. Мин килдем, комиссар.

Шамил. Килдең.

Каюм. Мин әзер, комиссар.

Шамил. Каюм! Мине монда озатканда Куйбышев, Валериан Владимирович: «Үзеңнең һәр адымың, һәр эшең белән большевик-революционерның кем икәнлеген күрсәт»,— диде.

Каюм. Күрәбез, комиссар, шикләнмә.

Шамил. Әгәр кем дә булса берәү минем чынлыгыма шикләнсә?

Каюм. Ул бәндәне юк итәргә кирәк. Ул хыянәтче.

Шамил. Әгәр икәү шикләнсә, өчәү?.. Монда пуля гына хәл итә алмас. Акыл кирәк монда, кыюлык, зирәклек...

Каюм. Без әзер, комиссар!

Шамил. Бар, Хәйрүш агайны, Садыйкны, Фәхрине чакыр. Сөйләш. Әзерләнегез. Без митингка кадәр әйләнеп кайтырга тиеш. Үз тирәмдәге шикнең тамыр җәюенә ирек бирмәм.

Зәкия. Шамил!

Каюм. Без әзер, Шамил абый. Кая барабыз?

Шамил. Дошманның иң-иң хәтәр өненә!

Пәрдә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мартук станицасы. Мәчет белән янәшә мулла йорты. Мәчет алдында ике бай тора. Аның берсе Сары бай. Ара-тирә кораллы дутовчылар үтеп китә.

Сары бай. Чехлар теге явызларның иманнарын укыталар, ди.

Кара бай. Инде кем сүзенә ышанырга да белмәссең. Бәлшәвикләр тәмамысы бетте дип кайтып кына сөйлиләр, ә алар әле Яйсанга килеп чыгалар, әле Каратүбәгә һөҗүм ясаганнар. Теге, Актүбәдә шул бәлшәвикләрнең җаннары мордар киткән мөселманнары ята, ди.

Сары бай. Син азрак гәҗитәгә күз салмыйсыңмыни? Беткәннәр алар, беткәннәр! Алла боерса, чехлар бүген-иртәгә Мәскәүне алырга торалар, ди.

Кара бай. Бирсен Ходай, бәрәкалла! Шулайлар була күрсен. Югыйсә дөньяның астын-өскә әйләндерделәр, кяферләр. Матур гына барган тормышның яме китте. Иләнмәгән биш йөз тирем ята.

Сары бай. Аллаһе боерса, мин дә озакламый Ырынбурга кайтам. Таш кибетемне бикләп киттем бит, бикләп...

Кара бай. Аны сорармын дигән идем, чын булса, синең улың Сәхиулла да шул Мәскәү кяферләренә ияргән, диләр.

Сары бай. Иярде, кода, иярде. Тик башы беткәндер инде, Дутов җәнаплары кырды инде бәлшәвикне, бик кырды.

Чыгып китәләр. Атыш тавышлары ишетелә. Мәчеттән яшел чапанлы мулла килеп чыга, Сәгъдетдин аңа каршы бара.

Сәгъдетдин (*йомшак тавыш белән*). Ни ашык-

тым инде, барыбер соңга калдым... Әссәламегаләйкем, хәзрәт, гает шәрифләрегез мөбарәк булсын.

Мулла (*үз алдындагы гаскәри киемле кешене күреп, сискәнеп китә*). Вәгаләйкем, энем. Син нинди кеше? Нишләп йөрисең? Кем ягыннан? Үзебезнекеләрдәнме-тегеләрдәнме, ягъни?

Сәгъдетдин. Үзебезнекеләрдән, хәзрәт, Кызыл Армиядән. Сезне гает мөбарәк белән котлап, фатыйхагызны алырга килгән идем.

Мулла. Алай икән, алай икән.

Ат чабып килгән тавышлар ишетелә, атлар туктый, хәзрәт тиз генә капкадан кереп китмәкче була.

Сәгъдетдин. Хәзрәтем, җаным, казаклар килә! Коткара күр, тотсалар харап итәләр.

Капкага кереп китәргә тырыша, хәзрәт җибәрми. Ниһаять, керә, капка ябыла. Берничә казак йөгереп керә.

Казак. Мулла, ач!

Мулла. Кто там?

Казак. Без, казаклар. Ач.

Мулла ача, капка төбендә тора.

Казак. Мулла, синдә большевиклар яшеренгән диләр, чыгар үзләрен!

Мулла. Миндә беркем дә юк, яй-богу, валлаһи-таллаһи, юк.

Казак. Керде бит, үзебез күреп тордык. Станицага унлап большевик үтеп кергән, шуларның берсе синдә.

Икенче казак. Алдалашма, мулла.

Мулла. Правда, юк, господа, яй-богу, юк.

Казак. Тентегез бөтен йортны.

Мулланы бер якка селтәп кереп китәләр. Сары бай күренә. Ул капка төбендә калган казакка эндәшә.

Сары бай. Шунда, шунда. Үз күзем белән күрдем. (*Югала, мулла чыга.*)

Мулла. Бетерде башымны теге явыз! Указ, йорт-җир әрәм китте, эх!

Казаклар Сәгъдетдинне алып чыгалар.

Сәгъдетдин. Имею честь представиться, сверх-срочной службы рядовой 121-го батальона Сәгъдетдин Фәсхетдинов. Кызыллар тарафыннан көчләп мобилизовать ителгән.

Казак. Хәзер карарбыз. Ну-ка, тентегез. (*Тентиләр, кәгазь тартып чыгаралар.*) Бу нәрсә? Карап карыйк. Әһә, удостоверение. «Мөселман отрядының күңеллесе Сәгъдетдин...»

Сәгъдетдин. Хәйлә генә ул, гаспадин хороший. Мин кызылларның серләрен алып йөрүче, мулланың якын кардәше.

Казак. Мулла, дөрес сөйлиме бу?

Мулла. Юкны сөйли, убыр, кяфер, җен! Сафсата! Кызыллар арасында бер генә кардәшем дә юк.

Казак. Йә, ничек, картлач?

Мулла. Ул мине таларга килгән угры!

Сәгъдетдин. Назад! (*Бомбасын күтәрә.*) Назад! (*Казаклар һәм мулла куркышып өелешәләр.*) Юк, кулым күтәрелми... Дошманны үтерәм дип хәзрәтнең, изге кешенең җанын кыям. Хәзрәт, әйт, туганың ич мин синең!

Мулла. Әстәгъфирулла тәүбә, түгел, туганым түгел!

**Казаклар Сәгъдетдинне эләктереп алалар, бомбасын йолкып үзен бер читкә сөйриләр.**

Сәгъдетдин. Хәзрәт, гомерем буе михраб алдындагы кешене олуглап килдем. Башкалар сезне сүккәндә яклады. Сезнең чапан астындагы кара җаныгызны күрмәдем. Хәзрәт, җанымны кыйганга шатланма, минем канымны иптәшләрем болай калдырмаслар.

**Урамнан капитан формасында Садрый, Мәхмүт һәм ике ханым керәләр, барысы да кызмача.**

Садрый. Әфәнделәр, ышаныгыз, дөньяның күчәре безнең кулда!

Кара чәчле ханым. О, нәрсә бу?

Мәхмүт. Туктагыз.

Садрый. Ба-а, кемне күрәм! Иске таныш, Сәгъдетдин карт. Кызыл Армиянең иң батыр солдаты. Каһарман! Хөрмәтле ханымнар, таныш булыгыз: бу мужик кызыл гаскәрнең иң батыр солдаты.

Сәгъдетдин. Ә син койрык болгап йөрүче әнчек. Ике яклы күгәргән пычак.

Садрый. Браво, Сәгъдетдин карт!

Сары чәчле ханым. Капитан, сез юмористлыгыгызны һаман ташламыйсыз.

Мәхмүт. Ничек килеп чыктың син монда?

Сәгъдетдин. Бүген ни бит, ураза гаете... Бәйрәм... Без мөселманнар, ни инде, теге...

Казак. Безне шартлата язды, капитан әфәнде. Алар күбәү иде, дозорлар күреп калган.

Садрый. Как? Станицада большевиклармы?
Кара чәчле ханым. Әнекәй генәм.
Казак. Тыныч булыгыз, ваше благородие, хәзер аулап бетерәбез без аларны.
Сары чәчле ханым. Әгәр аларның иң батыр солдатлары шушындый булса...
Садрый. О, аларның комиссарларын күрсәгез иде! Борыныннан юеше килеп торган малай.
Сәгъдетдин. Шул малай алдында меңәрләгән гаскәрегез дер калтырап тора.
Кара чәчле ханым. О!
Казак. Теленә салынма! Иптәшләрең кайда?
Сары чәчле ханым. Большевикны якыннан беренче күрәм.
Мәхмүт. Капитан әфәнде, намазга килгән карт, әйтегез, атмасыннар.
Садрый. Юк, поручик, мин синең сыман икеләнеп яшәргә җыенмыйм. Минем өчен киләчәк юл ачык. Эш җиңеләеп, бере кими торсын. (*Казакларга ымлый.*)
Казак. Кайда иптәшләрең, карт җүләр?
Сәгъдетдин. Большевик иптәшләрен сатмый.
Кара чәчле ханым. О! Капитан әфәнде, ә комиссарны безгә кайчан күрсәтәсез?
Садрый. Бәйләп шушы мәйданда аяк очыгызга салачакмын. Алыгыз, җанын җәһәннәмдә көтәләр!
Казак. Мулла, моннан соң алдашып маташма.
Мулла. Юк, юк, господин казак.

Казаклар Сәгъдетдинне шунда ук диярлек аталар.

Сары чәчле ханым. Фу, ераккарак алып китә алмаганнар.
Мәхмүт. Картны юкка аттырдыгыз, капитан. Юкка...
Садрый. Бала булмагыз, поручик...
Сары чәчле ханым. Комиссарны эләктергәч, безгә күрсәтми калмагыз.
Садрый. О!

Сары бай күренә.

Сары бай. Большевикны каптырдыгызмы?
Садрый. Рәхмәт сиңа.

Мәчет ихатасы ягыннан картларча киенгән биш-алты кеше күренә. Алар мәйданчыкны урап алалар. Кинәт берсе киемен салып ыргыта. Бу — Шамил.

Шамил (*көр тавыш белән*). Урыннардан кузгалмаска!

Аның бер кулында бомба, икенчесендә наган. Башкалар да чапанна-рын салып ыргыталар. Бу Хәйрүш, Каюм, гвардеецлар.

Мәхмүт. Шамил, комиссар!

Ханымнар (*чырылдыйлар*). Комиссар?!

Шамил. Ханымнар, тыныгыз. Каюм, иң элек капитанны. Сары бай да монда икән.

Сары бай. Минем монда бер гаебем дә юк, мин, мин...

Каюм. Сәхи кайда? Нишләттегез аны, явызлар?

Шамил. Ә сезгә, Мәхмүт әфәнде, безнең белән китәргә туры килер.

Садрый юаш кына торган җиреннән кинәт хәрәкәт ясап, эчке кесәсеннән наган тартып чыгара, Каюм аны бәреп төшерә.

Каюм. Шаярма, «рабочий» әфәнде, әйт, Сәхи кайда?

Садрый. Күрмәдем.

Мәхмүт. Юк Сәхи... Юк!

Хәйрүш. Шамил малакаем, комиссар, алар монда Сәгъдетдинне үтереп ташлаганнар.

Шамил. Ничек?!

Хәйрүш. Гает бит бүген, мәчеткә барам дигән иде.

Садрый (*Сары байны күрсәтеп*). Менә кем тотып бирде аны.

Сары бай. Минем һич гаебем юк, мин кызылларны яратам, минем үз улым красный гвардин...

Шамил. Бандитлар! (*Картның гәүдәсен карый.*) Сәгъдетдин абзый өчен менә боларны! (*Сары байны һәм Садрыйны күрсәтә.*)

Садрый. Сез чолганышта. Дозорлар хәзер килеп җитә.

Каюм. Әйдә, тарттыр, тарттыр!

Садрый. Комиссар әфәнде!

Шамил. Юк!

Мәхмүт. Мине дә, комиссар.

Шамил. Тынычлык саклагыз.

Мәхмүт. Сезнең сабырлык мине җенләндерә! Атыгыз мине дә. Сезне дә, үземне дә күралмыйм!

Шамил. Сезнең яшәү-яшәмәвегезне мин хәл итмим.

Мәхмүт. Атыгыз мине дә!

Якында гына мылтык тавышлары. Каюм, Хәйрүш борылып керәләр.

Каюм. Булды!

Шамил. Сәгъдетдин абзыйны алыгыз. Мәхмүт әфәнде, хыянәтче булу өстенә куркак та булмагыз инде!

Ашыгып чыгып китәләр. Ханымнар чыр-чу килеп кычкыралар. Баягы казак керә.

Х а н ы м н а р. Тотыгыз, тот, комиссар!

К а з а к. Боже мой! Ни булды!

К а р а ч ә ч л е х а н ы м. Капитанны үтерделәр.

Чыгып йөгерә, атыш тавышлары.

К а з а к. Минем арттан, марш!

С а р ы ч ә ч л е х а н ы м. Тотарсың аларны хәзер!

К а р а ч ә ч л е х а н ы м. Ә комиссар нинди симпатичный егет!

С а р ы ч ә ч л е х а н ы м. Бөркет! Юкка большевиклар арасына китмәгәнбез!..

П ә р д ә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Актүбәдә мәдрәсә яны. Кызыл байрак эленгән. Монда татар батальоны урнашкан. Лазарет. Лазареттан ерак та түгел дала башлана. Дала ягында бер төркем г в а р д е е ц л а р басып торалар. Мылтыклардан залп бирәләр дә акрын гына таралышалар. Ш а м и л төркемнән аерылып алгы планга килә. Мадьяр отряды командиры Б е л е в и ч керә.

Б е л е в и ч. Татар батальоны кемне күмде, иптәш комиссар?

Ш а м и л. Татар батальоны комиссар Шамил Усмановны күмде.

Б е л е в и ч. Җитди сорауга шаяртып җавап бирдегез, иптәш Усманов.

Ш а м и л. Шаярту гына булса икән, иптәш Белевич!.. Гәрчә без үзебезнең иң батыр солдатларыбыз Каюм белән Сәгъдетдин абзыйны күмдек.

Б е л е в и ч. Мартукка бик хәтәр рейд ясагансыз дип ишетелгән иде.

Ш а м и л. Ләкин ни бәрабәренә һәм ни өчен?! Ашхабадта контрреволюция...

Б е л е в и ч. Мәскәүдә сул эсерлар фетнәсе... Орскида Дутов котырына!

Ш а м и л. Әйе...

Б е л е в и ч. Отряд командирларын штабка чакырдылар. Иптәш Коростылев үзе булачак. Берләшү мәсьәләсен анда сөйләшәбез дә батальоннардан вәкилләр җыярбыз.

Ш а м и л. Ашыгырга кирәк безгә, Белевич туган! Татар батальоны кушылырга каршы килмәс дип уйлыйм.

Б е л е в и ч. Димәк, бергә-бергә?

Ш а м и л. Бергә-бергә, иптәш Белевич.

Белевич чыга. К а р и б керә.

К а р и б. Кем килеп китте ул?

Ш а м и л. Инде минем янга килеп киткән кешеләр дә синдә шик тудырамыни, командир?

К а р и б. Акыл белән түгел, ачу белән сөйләшәсең.

Ш а м и л. Белевич ул, мадьяр отряды командиры.

К а р и б. Һаман бер балык башын чәйниме?

Ш а м и л. Ул мәсьәләне хәл ителгән дип саныйм.

К а р и б. Ашыкмый тор! Сиңа ашыгырга гына булсын. Уңын-сулын уйлап тормыйсың кайчак, Шамил.

Ш а м и л. Гомуми хәрәкәткә каршы баруның зарарлы булуы бар.

К а р и б. Җайсыз көнне кушылырга өндисең!.. Кыз өчен батальонның ни яхшы егетен әрәм иттең!.. Мондый хәлдә кушылуны кирәкле санамыйм. Мадьярлар да, башкалар да безгә кырын карарлар. Үзебез дә әйбәт сугышабыз ич!

Ш а м и л. Үзем кылган эшләр өчен макталырга да, әр сүзләре ишетергә дә әзер. Мин гомергә комиссар булып тумаган!

Чыга. Кариб янына М ә х м ү т килә.

К а р и б. Дусларны соңгы юлга озаттык, нигә күренмәдең, Мәхмүт?

М ә х м ү т. Мине берәү дә чакырмады.

К а р и б. Син чакырган җиргә генә барасыңмы?.. Аңла, синең өчен мин җавап бирәм! Батальонга хәрби белгеч итеп сине мин тәкъдим иттем.

М ә х м ү т. Анысы өчен рәхмәт, Кариб.

К а р и б. Кайларда булдың, ниләр эшләдең? Нигә качып чыкмадың?

М ә х м ү т. Җибәрмәделәр. Әсир итеп сакладылар.

К а р и б. Бүген трибуналдан килергә тиешләр.

М ә х м ү т. Аларның татар батальонында ни катнашы бар? Без бит аерым, мөселман гаскәре! Син аның бердәнбер командиры!

К а р и б. Батальон... Бүген безне кушалар. Интернациональ полк төзелә. Анда инде командирлар күп булачак. Трибунал да якын.

М ә х м ү т. Алар мине әсир иттеләр!

К а р и б. Әсирләрне аталар! Нигә сине атмадылар? Ник исән калдың?

М ә х м ү т. Бу хатаны да мин ясамадым! Кариб, нигә кушылырга кирәк безгә?

К а р и б. Нигәме? Кушылырга Ленин куша! Владимир Ильич!

Чыгып китә. Мәхмүт гасабиланып йөри, З ә к и я үтеп бара.

Мәхмүт. Зәкия туташ, Зәкия туташ!

Зәкия. Ә? Кулыгызда нәрсә?

Мәхмүт. Кулларым буш.

Зәкия. Әнә, Шамил Усманов: «Дүрт кулым булса, дүртесенә дә кылыч алыр идем»,— ди.

Мәхмүт. Мактанчык!

Зәкия. Кем?

Мәхмүт. Шамил Усманов. Карап карарбыз, хәзер нәрсә тоттырырлар икән кулына.

Зәкия. Тавышыгызда явыз тантана ишетәм.

Мәхмүт. Бүген батальон полк составына керә. Күп сугыш юллары үткән немец, мадьяр отрядлары белән аралаша. Әле аерым чакта буш авантюралар остасы Усманов комиссар булып йөри ала иде. Регуляр гаскәрдә, чибәркәем, калай әтәчләргә урын юк.

Зәкия. Әй сез, поручик!

Мәхмүт. Нишлисең, анысы да мин...

Зәкия. Мин сезне фабрикант Акчуриннар өендә беренче тапкыр күрдем... Сез ярым асрау, ярым ятимә кызны тиң санап сүз каттыгыз. Күңелем эреп китте... Хәер, нигә боларны хәтерләп торырга!

Мәхмүт. Киләчәккә карыйк... Сугыш тиздән бетәр... Безгә җайлы вакыт табып моннан китәргә генә кирәк.

Зәкия. Кайчан инде ул җайлы вакыт?

Мәхмүт. Бүген, Зәкия туташ. Кыргыз далаларына китик! Бу ыгы-зыгылардан, мәхшәрдән күңел катты...

Зәкия. Әй сез... Сезне аклардан йолып алуны Шамилдән мин сорадым. Тагын бер кат йөзегезгә карыйсым килде... Нинди куркак, җебегән бәндә өчен күз яшьләре түккәнмен бит!

Хәйрүш белән берничә гвардеец үтеп баралар.

Хәйрүш. Ничек батальон бетсен ди? Аны кем бетерә алсын?

Зәкия. Хәйрүш агай, комиссарга нәрсә булыр?

Бер гвардеец. Комиссар гаепле, туташ.

Икенче. Яшь тай кебек ярсу, тәртәне сындыра...

Өченче. Тыеп кала алмадык...

Хәйрүш. Дүрт аяклы ат та абына. Аңа карап кына атның аягын кисмиләр. Күпер саклаганданиләр булмады? Онытмагансыздыр әле, батальон сарык көтүе кебек тилереп кача башлады. Ә комиссар нишләде?.. Теге юньсезләр бакыр бугазларын киереп: «Төркстанга китәбез»,— дип дөнья сасытканда, Шамил нинди зирәклек күрсәтте. Хәзер дә хата түгел, батырлык кылды!

Бер гвардеец. Барыгызны да аклар әсир итсә?

Хәйрүш. Әсир төшмәдек бит! Егетлеге дә шунда инде аның!

Зәкия. Дөрес, Хәйрүш агай! Комиссарга күләгә төшертмәскә кирәк!.. Әйдәгез! (*Чыгалар.*)

Мәхмүт. Зәкия туташ!

Зәкия. Ә сез теләсәгез нишләгез! Мин сезне сөймим!

Чыга. Шамил керә.

Мәхмүт. Нигә мине алып кайттыгыз? Нигә шунда атып калдырмадыгыз? Хурлар, түбәнсетер өченме? Трибуналга тапшырыр өченме?

Шамил. Һәркем үзе кылган эшләр өчен җавап бирә белсен!

Мәхмүт. Ах, алаймы?.. Китим дигән идем, калам! Бүген Зәкия туташ кына түгел, татар батальонының бар солдатлары сезнең гап-гади бер авантюрист икәнлегегезне күрерләр.

Шамил. Вакыт бар, сөйләп калыгыз.

Мәхмүт. Сез мине коткарган булып яхшы ат казандыгыз, тик сезне берәү дә йолып алмас. Кояшың баеды, Шамил Усманов!

Чыгып китәләр. Хәйрүш белән Лайош керәләр.

Лайош. Сез аклар тылына тагын рейд ясагансыз икән?

Хәйрүш. Комиссар оештырды.

Лайош. Шамил Усманов! О, батыр, герой! Хәйрушка тоже герой. Сугыш бетә, Лайош Венгриягә кайта. Хәйрушка Венгриягә кунакка килә. О, Венгрия! О, Чардаш! Иштенем!

Хәйрүш. Аннары безнең авылга шулпалы бәлеш ашарга, «Әпипә»гә биергә.

Лайош кесәсеннән авыз гармуны чыгарып, «Әпипә»не уйный.

Лайош. «Әпипә» әйбәт. Татарлар батыр. Бүген митинг. Мадьяр-татар-немец бер полк. Интернациональ.

Чыгып китәләр. Кариб белән Шамил килә. Таҗетдин керә.

Таҗетдин. Иптәш командир, батальон вәкилләре җыелды.

Кариб. Яхшы. Әнә, немец, мадьяр вәкилләре дә килә.

Белевич, Шамил, Кариб, башка командирлар күрешәләр. Батальоннардан вәкилләр кереп тезелә.

Б е л е в и ч. Башладык, иптәшләр. Комиссар, сезгә беренче сүз.

К а р и б. Бәлки, сез әйтерсез?

Б е л е в и ч. Юк, юк. Шамил Усманов әйтсен!

Ш а м и л. Иптәшләр! Сугышның беренче этабы — аерым- аерым отрядлар булып сугышу этабы тәмам. Владимир Ильич отрядларны берләштереп куәтле Кызыл Армия частьлары төзергә куша. Сугыш эшенә өйрәнгән, дисциплиналы регуляр гаскәр генә мәкерле дошманны тәмам җиңәчәк. Бу — көн кебек ачык.

Сафлар ур-ра кычкыралар. Бер кырыйга тезелгән немец, мадьяр, татар вәкилләре янына М ә х м ү т тә килеп баса.

Оренбургны калдырып чыкканнан соң без байтак сугышларда катнаштык. Дошманны каршы алып та, оясына барып та тукмадык. Большевиклар партиясенең губерна комитеты татар, немец, мадьяр батальоннарын берләштереп, Интернациональ полк төзергә тәкъдим итте. Сез ризамы, мадьяр иптәшләр?

М а д ь я р л а р. Риза!

Т а т а р л а р. Без дә риза.

Н е м е ц л а р. Риза, риза!

Ш а м и л. Хәзер без Интернациональ полкның командирын һәм комиссарын сайларга тиешбез.

Т а в ы ш л а р. Ур-ра!

— Командир итеп Белевичны сайлыйбыз!

Ш а м и л. Командир итеп большевиклар партиясе члены Белевичны сайларга дигән сүз булды.

Т а в ы ш л а р. Сайлыйбыз!

— Яхшы командир!

Б е л е в и ч. Рәхмәт, иптәшләр! Комиссар итеп кемне сайлыйбыз?

М ә х м ү т (*бер читкә*). Һаман Шамил Усмановнымы?..

Л а й о ш. Комиссар итеп Шамил Усмановны сайлыйбыз!

Н е м е ц л а р. Шамил Усмановны!

Кинәт аткан тавыш яңгырый, Мәхмүт җиргә егыла.

Б е л е в и ч. Нәрсә булды?

Х ә й р у ш. Поручик Урманаев үзен-үзе атып үтерде Кариб. Мәетне бер читкә алыгыз.

Б е л е в и ч. Татар батальоны нәрсә әйтә?

Т а т а р л а р. Шамил Усмановны сайлыйбыз!

Т а в ы ш л а р. Ур-ра!

С а к ч ы керә.

С а к ч ы. Иптәш командир. Орск полкыннан элемтәче-разведчик килде.

Э л е м т ә ч е керә.

Э л е м т ә ч е. Сезгә пакет, иптәш командир. (*Хатны Белевич ала.*)

Б е л е в и ч (*хатны укып*). Интернациональ полк хәзер Орскига китә.

Э л е м т ә ч е. Орскидан безнең полк белән Оренбургка!

Ш а м и л. Оренбургка!.. Иптәшләр, дуслар!.. Без бик ерак юлларга бергә барасы кешеләр... Нык булыйк! Шулай башланды һәм мәңге туктамас безнең юллар!

Командирлар честь биреп бер кырыйга басалар, вәкилләр бер-бер артлы үтә, оркестр бөтен дөнья эшчеләре гимны Интернационал уйный.

Т а в ы ш л а р. Даешь Оренбургны!
— Яшәсен Интернациональ полк!
— Яшәсен Ленин!

П ә р д ә.

*1966 — 1967*
*Казан*

# *Китмәгез, тургайлар!*

*Драматик повесть ике кисәктә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Наза — клуб мөдире.
Динә — фельдшер кыз.
Фаягөл — бухгалтер кыз.
Азамат — колхоз председателе.
Ахун Галиевич — күрше колхоз председателе.
Нургали — шофер.
Сәймән — колхозчы.
Түрәй — элекке укытучы, хәзер колхозчы.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Табигатьнең матур бер почмагы. Чишмә дә чылтырап ага, таллар да бөдрә, күк тә зәп-зәңгәр. Оҗмах та оҗмах, монда да оҗмах. Фаягөл керә. Сагаеп, куркынып як-ягына карана, ашыгып-кабаланып, укына-укына кушучлап су эчә. Сәймән кереп шыпырт кына аны күзәтеп тора.

Фаягөл (*аны абайлап*). Ай!

Сәймән. Актайның изге чишмәсенә бәлтерәгән карчык-корчык кына йөри дисәм... (*тукталып*) әллә син дә картаерга өлгердеңме?

Фаягөл. Сәймән абый, бетермә башымны, кирәгем чыгар.

Сәймән (*канәгатьлек белән*). Бетерүен бетермәм, яхшылыкның бәясен кадерли беләм. Кирәгең бүген үк чыгарга тора. (*Мутланып кызга якынлаша.*)

Фаягөл. Әнкәйнең буыннары сызлый. Актай чишмәсенең суын эчсәм, шифа булмасмы, дигән иде. Һәммәбез дә өмет белән яшибез.

Сәймән. Бир савытыңны, иң-иң шифалы җиреннән тутырып бирәм.

Фаягөл. Онытканмын. Курка-курка гына килдем. Сүз чыгара күрмә, Сәймән абый, адәм көлкесенә калдырма.

С ә й м ә н. Кулыңда бухгалтер дигән катыргы диплом. Яхшы эшлисең. Кыз башың белән алты почмаклы йорт җиткердең. Болай да (*аны, капшап*)... күрер күзгә дә ярыйсы, кулга да йомшак кына икәнсең! Сипкелләрең дә килешеп тора. Сипкелле кызларның тәне шалкан дип сөйлиләр. Ап-ак була, имеш. (*Кинәт.*) Актай чишмәсенә кияү теләп килгән син!

Ф а я г ө л. Җен икәнеңне белә идем, убыр да икәнсең.

С ә й м ә н. Кияү юк, чибәрем. Синнән яшьрәкләргә дә тәтеми хәзер. Телә, теләмә, авылда кияүләрнең күле кипте.

Ф а я г ө л. Бетебрәк киттеләр шул, Сәймән абый! Әнкәсе итәгеннән төшкәне бере шәһәргә китеп олага. Их, Сәймән абый, әнкәй карчыкны саклап калды авылда башларым.

С ә й м ә н. Әнкәңне дә алып кит, бала карарга ярар.

Ф а я г ө л. Хәзер кая барасың? Йорт-җир. Өй тулы җиһаз. Бәби арбасына кадәр бар. Ефәк мендәре елкылдап тора. Бакчада унҗиде алмагач. Өчесе ак налив. Килосы өч тәңкә чакта өлгерә.

С ә й м ә н. Йорт-җирең килгән. Мамык түшәк җәелгән. Кайнар куен ачылган. Ә кияү юк. Тю-тю. Булмый да! Яхшы чакта, ал битеңә сары пәрәвез сыман җыерчыклар сарганчы китеп котыл син, Фаягөл аппак.

Ф а я г ө л. Авыл иясе булдыңмы әллә, нигә мине куасың?

С ә й м ә н. Кумыйм ла, үгет кенә бирәм. Шуннан берочтан сыныйм: калам дигән иманың ныкмы, түгелме? Китәселәр китсен, Фаягөл! Куанычка булсын. Монда калганнарның кадере арта. Бүген бигрәкләр дә якын күренәсең әле, сипкеллем.

Ф а я г ө л. Әй әле, котырма.

С ә й м ә н. Әйдәле, җаныкаем, куак арасына керик. Чишмә юлы буш тормас, кияүсезләр хәзер чирмеш чирүе кадәр, эт-кош килеп калмасын. Китмәслек булсаң, серем сиңа!

Ф а я г ө л. Оятсызланма, Сәймән абый, мыегың агара башлаган.

С ә й м ә н. Бәби тап син миннән, Фаягөл аппак!

Ф а я г ө л. Бәби? Синнәнме? Улыңны өйләндерергә вакыт, кызың җитеп килә. Шуларның куанычын күр.

С ә й м ә н. Аларны тудырганда мин кем идем? Шыр тиле! Үз күләгәсеннән үзе куркып йөргән куркак куян. Куяннан арыслан туамы? Кан яңарды минем, Фаягөл. (*Күзләрен майландырып.*) Яңа кеше мин. Өр-яңа. Арыс-

лан йөрәге миндә хәзер. Арыслан баласы тәрбиялисем килә. Балалар таралышкан... үзем тол! Яши белсәң, оҗмах хәзер авылда. Кадерен белергә генә кирәк. Ихатама күз сал! Йорт-җире, байлыгы өчен Мирвәлине авылдан сөргәннәр. Шуның нигезенә өемне юри салдым. Мин... атсыз-тунсыз гидай идем. Ә хәзер кара!

Ф а я г ө л. Баедың, хак. Шуннан ни?

С ә й м ә н. Барыбыз да баедык. Тигез. Байлык көч бирә, көч! Мин сине, ак шалканым, патша кәләше күк итәрмен.

Ф а я г ө л (*мыскыллап*). Башымда көмеш таҗ!..

С ә й м ә н. Аягыңда чәмчәле кунычлы болгар итеге. Башыңда сусар бүрек, өстеңдә чәшке тун. Нәзек билеңдә минем намуслы кулым. Килештекме?

Ф а я г ө л. Ә мин боларга гына риза булмасам? Киявемнең патша булуын да теләсәм?

С ә й м ә н. Беләм. Син дә председатель Азаматка күз тотып йөрисең.

Ф а я г ө л (*ачылып*). Йөрим, Сәймән абый. Кешесе йөрмәслекме әллә? Ә син күзгә терәп «кияү юк!» дисең.

С ә й м ә н. Йөземе ярыйсы да, эчеңә килешерме?

Ф а я г ө л. Авылда минем белән тиң кызы бармы аның? Йә, әйт!

С ә й м ә н. Күз алдында. Биш-алты ел тырышып маташтың. Нәтиҗәсе нүл.

Ф а я г ө л. Әйе, аз тырышмадым. Беренче елларны кыз карарлык идеме соң Азамат абыйның хәле? Бухгалтер мин, белеп сөйлим. Колхоз муеннан бурычка баткан иде. Ул килде дә хәлне тамырдан үзгәртте. Хәзер банкта күпме акчабыз ятканын беләсеңме?

С ә й м ә н. Азамат та моннан китәчәк. Калыр дип өметләнмә.

Ф а я г ө л. Шулкадәрле көч куеп, тормышыбызны гөл иткәч кенә китеп барырга аның башына тай типмәгән. Көчен түкте, хәзер рәхәт татыр чагы. Ял кирәк аңа, наз кирәк. Барысын да аңа мин бүләк итәчәкмен.

С ә й м ә н. Калмый дим монда! Динә аны алырга кайткан. Сугансыз-борычсыз кабып йота ул аны. Бу дөньяда хәйләкәр матурлыкны җиңә алган көч юк. Чишмәгә түгел, Алла бабаңның итәгенә ятып җыласаң да эләкми сиңа Азамат!

Ф а я г ө л. Бик. Ие. Шул пырдымсыз Динәгә Азамат абыйны биреп җибәргәннәр ди. Көт.

С ә й м ә н. Минеке бул, Фаягөл аппак. Тап баһадир бер малай! Кем өчен тир түгәм? Кем өчен тырышам? Тота-

сыз да шул Азаматны камыйсыз! Азамат патшамы? Фи! Авылга ул хуҗамы? Мин баш аңа! Мин!

Ф а я г ө л. Тузга язмаганны сөйләмә Сәймән абый.

С ә й м ә н (*кызып ук*). Матурлыгыңа, уңганлыгыңа ышансаң, теләк теләп Актай чишмәсенә ялварыр идеңме?.. Әйдә, куаклыкка керик. Карышма дим, җүләр. Һе, кара әле!

Ф а я г ө л. Сәймән абый, әнә Динә менеп килә!

С ә й м ә н. Чорсыз... Ару азык теш арасына керә дип торганда... Кемне иярткән ул, боты сынгыры кыз?!

Ф а я г ө л. Ишен тапкан! Клуб мөдире Наза. Иртәдән бирле бергәләп табан кыздыралар.

С ә й м ә н. Назасы да китәчәк. Динәсе дә! Барысы да олагачак. Без каласы монда. Рас, шулай икән, үз эшебезне үзебез карыйк. Үзем төсле кара малай кирәк миңа, Фаягөл!

Чыгалар. Д и н ә белән Н а з а керә.

Н а з а. Нигә менгәнеңне аңлыйм. Нигә мине алып мендең, Динә?

Д и н ә. Кычкырып сөйләшмә.

Н а з а (*җырлый*).

Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
Зәңгәр таудан яулык болгасам...

Д и н ә. Монда җырларга да ярамый! Бирче яулыгыңны.

Н а з а. Кемгә болгарбыз? Председатель Азаматкамы? (*Динә Назаның яулыгын алып күзләрен кысып бәйли, бер урында зыр-зыр әйләндерә.*)

Д и н ә. Яле, яле!

Н а з а. Чү, нишлисең? Башым, башым...

Д и н ә. Төньяк кайсы якта да көньяк кайда?

Н а з а. Белмим.

Д и н ә. Алайса, атла.

Н а з а. Аяк асты зыр-зыр әйләнгәндә кая атлыйм ди мин? (*Курка-курка гына атлап бара.*) Чылтырый.

Д и н ә. Хәзер бер теләк телә. Изге теләк.

Н а з а. Теләдем.

Д и н ә. Иел!

Н а з а. Куркам!

Д и н ә. Яныңда мин бар. Эч!

Н а з а (*эчә*). Суы нинди татлы. Тешне камаштыра.

Д и н ә. Эч тә көмеш тәңкә сал.

Н а з а (*яулыгын чишеп ташлап*). Ни сынийсың? Уенчыкмы мин сиңа?

Д и н ә (*өзгәләнеп*). Яратам. Азамат абыйны яратам.

Н а з а. Беләм. Ә ул ни ди?

Д и н ә. Шуның өчен кайттым. Азамат абыйны алырга гына кайткан идем.

Н а з а (*паузадан соң*). Алып ук китәм дисең икән... Председательне алай ансат кына биреп җибәрерләрме? Сайлап куелган кеше.

Д и н ә. Сайлаганнар сиңа! Председатель итеп япь-яшь, чибәр егетне җибәргәннәр дигәч, без дәрестән качып җыелышка кергән идек. Бөтен халык: «Кирәкми, кирәге юк, алып китегез!» — дип кычкырды. Районнан көчләп кушкач кына куйдылар. Җитәр, байтак эшләде.

Н а з а (*паузадан соң*). Яратып эшли, минемчә.

Д и н ә. Укып кайтканыңа күпме генә, барын белеп өлгергән күк сөйләшәсең!

Н а з а. Болары да безнең колхоз җирләре бит!

Д и н ә. Әһә, белмисеңме? Тауның теге ягы «Тукай»-ныкы!

Н а з а. Хәзер синең чират. (*Ярсып.*) Бир әле яулыгыңны! (*Динәнең күзен бәйли.*) Атла, атла! Суын эч! Йөрәк ярсуың басылыр. Телә теләгеңне! Тик теләгең чын булсын! Сал көмеш тәңкәңне! (*Пауза.*) Йә, бер-бер үзгәреш бармы?

Д и н ә. Дөнья шул ук...

Н а з а. Гаҗәп тау бу. Бөтен яктан тау! Дәү печән кибәне төсле. Кырмыска оясына да охшаган. Адәм кулы өйгән дисәң, тау башында чишмә. «Тукай» димәктән, мин эшкә шунда билгеләнгән идем. Нигәдер районнан авылыма кайтардылар.

Д и н ә. Монда туйгач, «Тукай»га китәргә җай калган.

Н а з а. Чишмә тауның нәкъ башында икән!

Д и н ә. Шуңа тылсымлы дип йөртәләр аны.

Н а з а. «Тукай»ның председателе бик һәйбәт кеше диләр.

Д и н ә. Шома кеше диген.

Н а з а. Нигә шома?

Д и н ә. Сәймән абыем шулай ди! Шома булмаса, председатель булып бер авылда шулай озак тора алыр идеме? Менә бездә Азамат абый күпме вакытка ничәнче председатель?!

Н а з а. Азамат абый белән Ахун Галиевичнең арасы нилектән бозылган икән, шуны да беләсе иде.

Д и н ә. Ныграк бозылсын!

Н а з а. Чишмәгә тапшырган изге теләгең шулмы?

Д и н ә. Азамат абыйга моннан китәргә бер сәбәп артыр.

Н а з а. Усалланганда абзаңа охшап киттең.

Д и н ә. Абзыйны яратмыйм, аңа охшаган дисәләр, ачуым килә.

Н а з а. Аяк атлавыңа кадәр аныкы!

Д и н ә. Ачуландырасың киләме?

Н а з а. Үз теләгемә каршы килеп булса да көне буе синең хәтерне саклап йөрим, җитәр!

Д и н ә. Борын төбегездән менә дигән егетне алып китәм. Ачулансаң да урынында!

Наза дәшми, йөгереп диярлек чыгып китә. Динә сихерләнгән күк суга карап тора. Куркынган Н а з а йөгереп керә.

Д и н ә. Ни булды тагын?

Н а з а. Әллә ни бар! Нәни генә җәнлек, өскә ыслап килә башлады.

Д и н ә. Йомрандыр.

Н а з а. Йомран алай озынча булмый. Сырты буй-буй моның.

Д и н ә. Көзән алайса, көзән. Шуннан курыккан. Мин аны! Таш белән башын измәсәм! (*Чыгалар, куркып кире чигенәләр.*) Ай-яй, нишли!

Н а з а. Фыр-фыр итеп өскә килә. Борынсыз калдырыр.

Д и н ә. Усалларга усал бул! Алга! Юлбарыс түгел әле!

Таш ата-ата җәнлекне куа.

Н а з а. Зинһар, үтерә күрмә, куркыт кына! Җан иясе. Матур!

Д и н ә. Бәргәч, үтермимме мин аны? Тиде! Тидердем! Башына гына чәпәдем.

Н а з а. Каян сиңа әйттем...

Тыны бетеп С ә й м ә н керә.

С ә й м ә н. Нишлисез сез, явызлар?

Д и н ә. Мин тидердем аңа, абзый, мин! Үзем!

С ә й м ә н. Шушы ташың белән маңгаеңны ярырмын. Көзәнемне әрәм иттең, корткыч.

Н а з а. Синең абзаң табигатьнең кадерен белә икән, Динә.

С ә й м ә н (*Динәне этеп җибәрә*). Җүләр, йөрмә монда.

Д и н ә. Кагылма, синең таумы әллә?

С ә й м ә н. Көзәнемнең ике баласы бар иде. Оялары әнә теге таш астында. Тими бит ул кешегә, баласын гына саклый. Сез, сукыр тавыклар, аның өненә барып менгәнсез.

Н а з а. Белмәдем, Сәймән абый.

С ә й м ә н. Һәйбәт бүрекне, күпереп торган йомшак яканы ай-һай яратасыз. Хәзер монда калмый алар, качалар.

Н а з а. Хаталык бездә.

С ә й м ә н (*Динәгә кизәнеп*). Ух, алакүз.

Д и н ә. Табигатьне ярата диденңме? Аерата чәшкеләрне, көзәнне ярата. Эт атып бүрек тегә. Су күсесенә капкын куя. Чәшке бүрек сатмадымы әле ул сиңа? Тиреләрен скальпель белән генә туный. Аны мин урлап алып кайтам.

С ә й м ә н. Таегыз моннан, аңгыра саесканнар!

Чыга.

Н а з а. Абзаң белән арагыз килешә дисәм, гаугалы яшисез икән.

Д и н ә. Мин анымы, мин аны!

Н а з а. Кайтырга бик вакыт безгә. Кәеф тә бозылды.

Д и н ә. Кайтасы килми. Абзый кумаса бер хәл иде. (*Җыламсырап.*) Нинди холыктыр инде миндә! Әйткәннең гел киресен эшләргә яратам. Укытучыма үч итеп сулагай кул белән яза башладым!

Н а з а. Киттем! Кайбер нәрсәләрне ачыкларга теләп ияргән идем сиңа.

Д и н ә. Чишмәгә тапшырган теләгемне белдеңме?

Н а з а. Башка кызларны күргәндә Азамат абыемның күзе сукырайсын, дип теләдең.

Д и н ә (*каушап*). Ә син... ни теләдең?

Н а з а. Нәкъ киресен сорадым тылсымлы чишмәдән: моңарчы сукыр Азамат абыйның шәһәрдән кайткан Динәне күргәндә ике күзе дә ныграк ачылсын дип инәлдем.

Д и н ә. Син?! Миңа каршы төшәсеңме? Юлыма аркылы чыгасыңмы?

Чыгалар. Ф а я г ө л керә.

Ф а я г ө л. Йоны коелган чыпчыклар, бер файдасызга чыркылдыйлар, тәккә. Аз-маз кояшта кызынырмын дигән идем. (*Кофтасын салып ташлап, җиргә сузылып ята.*) Бер яктан Сәймән абый сагыз күк сыланды, җирәнгеч. Кабих. Куып кына җибәрер идем, теле тасма каһә-

рнең. Болай да Фаягөлнең җыры җырланган дип уйлыйлардыр бераүләр. (*Яткан җирдән ямьсез тавыш белән җырлый.*)

Сарман буйкайлары яшел алан...

Юк, валлаһи, таллаһи, Азамат абый минеке булыр! Җил итәккә — Динәгә бирәмме мин аны? (*Чәчләрен таратып ташлый.*) Кемдә бар мондый толымнар хәзер? Кемдә бар мондый күкрәкләр? Корышкан алмалары янына Европача булсын дип берәр кадак мамык тутырып йөриләр. Бәби, ди, Сәймән мөртәт... (*Җырлый.*)

Печәннәре җитәр бер заман!

Азамат абыйдан булса, бер дистә малай ашатырлык көч бар бу күкрәкләрдә! Теге йонсыз чыпчыклар ни теләде икән? (*Тора.*) Теләкләре кабул булмасын, акчаларын үземә алам.

Таяк сындырып, акчаларны ала. Машина тавышы. Азамат белән Нургали керә.

Нургали. Әнә ул!

Фаягөл. Беттем.

Азамат. Искәндәрева? Бу сезме?

Фаягөл. Бәхеткәйләрем юк икән, Азамат абый, корыган икән.

Нургали. Егерме тиен салып су анасыннан бәхет теләнергә калдыңмы?

Азамат. Колхоз бухгалтеры, комсомолка әбиләр ырымына ышанамы? Оят, Искәндәрева.

Фаягөл. Алай түгел! Мин аның өчен килмәдем.

Нургали. Чыгардык без аны.

Фаягөл. Кайчан чыгардыгыз? Кемне?

Нургали. Үткән җыелышта сине комсомолдан төшереп калдырдык. Яше чыккан. Нигә килмәдең? (*Чишмә янына барып су белән уйный башлый.*)

Фаягөл. Тау башына менеп, кеше метрикасы тикшереп йөрмәсәң, эшең беткәндер синең, Нургали.

Азамат. Сез икәү идегез. Иптәшең кайда?

Фаягөл (*үзен Сәймән белән күргәннәр дип белеп*). Икәү! Минме? Безме?

Нургали (*юри үчекләп*). Менә сиңа ефәк кебек кыз, көпә-көндез тау башында подручкам гулять итә.

Азамат. Куркытып, кызны телдән калдырма, Нургали.

Ф а я г ө л. Мин?.. Гомердә парлашып йөргәнем юк, Азамат абый. Билемә егет кулы кагылганы юк.

Н у р г а л и. Таптың горурланыр нәрсә! Синең яшьтә егетләр кулы тимәгән кызлар биле сызлаулы була диләр!

Ф а я г ө л. Нигә син кеше яшенә бәйләнәсең?

Н у р г а л и. Ырый-ырый!

Ф а я г ө л. Танавыңның кыек икәнен бел, өрәңге танау!

А з а м а т. Куй, Нургали. Сине әзәрлекләп менгәннәр дип уйлама, Искәндәрева. Үз йомышыбыз. Бер фикер туды әле миндә кичә.

Н у р г а л и. Ул да фикерсез йөрми, ха-ха, чишмә тылсымыннан кияү сорый.

А з а м а т. Ул сораганны чишмә бирерме-юкмы, әмма без сораганны бирәчәк.

Ф а я г ө л. Бәрәч, сез дә чишмәгә келәү белән мендегезмени?

Н у р г а л и. Ха-ха, килеп капты!

Ф а я г ө л. Өзмә үзәгемне, малай актыгы! (*Чыга.*)

А з а м а т. Аның белән алай каты сөйләшмәсәң дә була.

Н у р г а л и. Кызык бит.

А з а м а т. Бүген иртән ни булганын белсәң иде син, Нургали... Күземә күренә дип торам... Турыбыздан аккош кебек кыз узып бара!

Н у р г а л и. Өйләнергә вакыт сиңа, Азамат абый. Азрак сабырланыр идең. Кызлар икәү бара иде, ялгышмасам?

А з а м а т. Ә мин аларның берсен генә күрдем дә!

Н у р г а л и. Кайсысын?

А з а м а т. Һөҗүмне көчәйттеләр кызлар соңгы көннәрдә!.. Юкка йөриләрме?..

Н у р г а л и. Түрәй абый әйтә, кешеләр җир йөзенә юкка гына килмиләр, ди. Туалар икән, табигать кодрәте чакыра аларны, ди. Кызларны да табигать кодрәте йөртә!

А з а м а т (*кискен, кулындагы таягын шарт итеп сындыра*). Җүләр синең Түрәй абыең! Дивана. Ә син шуның сүзен сөйлисең. Минем бу дөньяга нигә килгәнемне белә аламы Түрәй? Ичмасам, бүген шушы тауга нигә менүемне, ашкынып йөрүемне аңлый аламы?

Н у р г а л и. Мондый холкың белән бәла читтә йөрмәс синнән!

А з а м а т. Бүгенгә бәла читләтеп узсын! Бүгенгә генә!

Аннан күз күрер. Бүген мин өйләнәм, Нургали! Бүген үк! Гомумән, күп нәрсәләрне хәл итә торган көн бүген!.. Менә Актай тавы! Башында яшел бүрек. Шул бүрекне салдырсак... Бүреген салгач, тез чүкми хәле юк аның, Нургали. Шулаймы?

Нургали. Тез чүктерергә яратасың син, Азамат абый.

Азамат. Кирәккә! Ике бульдозер кыска гына арада зуп-зур күл казып куячак. Тау үзе — конус формасында — су җыю башнясы булачак. Водонапорная башня ди аны рус абзаң.

Нургали. Юл салганда таудан таш алырга бик теләделәр. Халык изге дип санап йөргәнгәме, рөхсәт бирмәделәр.

Азамат. Үзем абайламас идем, клуб мөдире Наза акыл бирде. Соңгы идарә утырышыннан чыгып кайтып киләбез, табигатьне саклау турында сөйли бу. Ә минем үз хәсрәтем: басуларны ничек сугарырга? Бер сүзе колакка кереп калган. «Актай тавы дәү манара булып кырлар өстенә күтәрелгән»,— диде.

Нургали. Ни кыдырабыз инде хәзер?

Азамат. Өскә күл казыйбыз. Ярларын ныгытабыз. Тау кабыргасына дүрт яктан торбалар сузабыз. Су үз җае, үз авырлыгы белән чөгендер кырларына, иген басуларына агып ятачак. Шәпме?

Нургали. Рөхсәт итмәсләр!

Азамат. Бөтен анализлар, расчетлар безнең файдага булганда, район каршы килмәячәк. Фәнни журналлардан актарынып таптым, башка урыннарда шулай эшләгәннәр!

Нургали. Күз текәп торган бердәнбер тауны ишәргә халык, авылдашлар рөхсәт итмәс. Табыналар аңа.

Азамат. Халыкны белмисең, Нургали. Аңлатам. Диңгез күргәнең бар. Севастопольдә хезмәт иттең. Диңгез ярындагы ташларга игътибар иттеңме? Һәммәсе дә тавык күкәе кебек йом-йомры. Диңгез ярында очлы кырлы таш булалмый. Дулкын тәгәрәтә аларны, Нургали, диңгез! Шомартып бетерә. Үзенә буйсындыра диңгез.

Нургали. Бүген сөйләгәннәреңә тиз төшенә алмыйм.

Азамат. Кешеләр дә шулай, ярдагы ташлар кебек шомаралар. Диңгез аларны да үз ихтыярына буйсындыра.

Нургали. Диңгезе син булып чыгасыңмы?

Азамат. Нигә мин генә? Диңгезе — тормыш. Ит кирәкме — кирәк. Иген кирәкме — бик кирәк. Шикәр теш-

ләмичә дә яшәп булмый. Актай кызганыч, әмма ул әфсентөфсеннәргә түгел, халыкка хезмәт итәргә тиеш.

Нургали. Тауның яртысы «Тукай»га керә. Ахун Галиевич ни әйтер?

Азамат. Зирәклегеңне мактыйм. Ахун Галиевичне көйләү кыен булыр! Мөнәсәбәтләр болай да шәптән түгел. Син ашыгып кемгә дә чишеп ташлама. Монда сак һәм акыл белән эш йөртергә кирәк. Әпчи карчыкларның тузынганын күрәсем килми.

Нургали. Хаксыз эшкә тотынуыңны сизенәсеңме?

Азамат. Эшебез хак, Нургали. Хак эш тә бөтен кешегә ошап бетми. Әйтик, синең абзаңа! Мең яшәр әле, үзе килә.

Сәймән керә.

Сәймән. Машинаңны өскә үк менгерерләр.

Нургали. Ну, абзый! Туйдым синнән!..

Азамат. Сәймән абый, нигә эшеңдә түгел?

Сәймән. Йөзем һәрвакыттагыча ак, Азамат туганым. Өлгерлегем дә бар. Бар! Һәммәсе тәртиптә. Рәт араларын эшкәрттек. Тракторлар икенче бригадага китте.

Азамат. Син шул арада үз биләмәләреңне барлап төшәргә булдыңмы?

Сәймән. Алай дисәң дә риза. Алай карама миңа, чөгендергә күз сал. Нинди яшел келәм җәйдем мин сиңа! Тик, Алла шаһит, тирне жәлләмәдек, тырыштык, әгәр дә мәгәр тагын атна-ун көн яңгыр булмаса, уңыш әрәм булачак! Түккән көч җилгә очачак.

Азамат. Синеке югалмас, көчеңне бишләтә кайтарырсың... Ишеттеңме, Нургали, сугару турындагы фикер минем башка бик вакытлы килгән!

Нургали. Фикерең әйбәт, тик мин аның белән килешеп бетмим.

Сәймән. Тс, җүләр баш! Председательгә карышалармы? Кит!

Азамат. Җир шарын учка салып тәгәрәтергә исәп, Сәймән абый.

Нургали. Азамат абый синең чөгендерне суга шәбәртергә уйлый.

Сәймән. Кит әле, юньсез! Сәнәк белән болыт җыймакчымы?

Нургали. Тау башын кыеп ташлап, син басып торган урында күл ясарга ниятли.

Сәймән. Ни булган сиңа бүген? Җыен киртәгә кермәгәнне лыгырдыйсың.

А з а м а т. Дөресне сукалый ул. Ничек, Сәймән абый, минем план күңелгә ятышлымы? Чөгендерне каер анна- ры!

С ә й м ә н. Тауның яшел чалмасын салдырам дисеңме? Ай-һай, Азамат туганым, көчеңнән килер микән? Биек бит тавы!

А з а м а т. Үрелеп карарга исәп!

С ә й м ә н. Туктале, әй! Фу, тирләп киттем! Көлмә әле син. Юк, баш әйләнә!.. Буш сүз сөйләми идең моңарчы! Ни бит, әй!..

А з а м а т. Нигә гаҗәпләндең?

С ә й м ә н. Соң, атаң башы түгел ич бу, Актай башы!.. Тауның ни файда китергәнен бөтен кешедән шәбрәк беләсең. Фу, хәл китте.

А з а м а т. Элек колач таррак булган, Сәймән абый. Тәҗрибә аз булган! Тауның чын бәясен белмәгәнбез. Заман бездән киңлек сорый. Берочтан, имеш-мимешләргә дә чик куелыр, иеме, Нургали? Югыйсә, комсомолкаларына тиклем ырым-шырым белән йөриләр. Фаягөл!

Ф а я г ө л (*атылып керә*). Мин монда, Азамат абый.

А з а м а т. Менә сиңа метр. (*Нургалигә күрсәтеп.*) Икәүләп әнә теге «кәкре карамадан тау түбәсенә ничә метр икәнен санап килегез.

Н у р г а л и. Кулым бармый, Азамат абый.

А з а м а т. Аягың йөрсен! Соңыннан сине шушы хуҗалыкка механик итеп куярмын. Күтәрелерсең! (*Фаягөлгә.*) Ярдәмче итеп тагын бер-ике кеше ал.

Ф а я г ө л. Үзем дә башкарып чыгам ла мин аны!

А з а м а т. Экономистны ал. Теге кызны, Назаны чакыр. Барыбер эше юк, тик йөри.

С ә й м ә н. Ора алмаган зур күтәрер ди!

А з а м а т. Бу сүз миңа таныш. Колакка да элмим мин аны! Нургали, юргала! Бүгенгә генә карышма. Бүген күп нәрсәләрне хәл итә торган көн!

Ф а я г ө л. Фасон өчен генә кәҗәләнә!

Н у р г а л и (*кинәт, уйлап алып*). Абзый! Түрәй абый кайтып киттеме?

С ә й м ә н. Шунда, аста калды.

Фаягөл белән Нургали чыгалар.

А з а м а т. Йә, Сәймән абый. Эшнең уеннан узганын сизендеңме?

С ә й м ә н. Тауга кагылу юк. Рөхсәт итмим.

А з а м а т. Кем соң син? Туктале, кем син?

Сәймән. Әһә, дусларыңны танымый башладыңмы? Эт симерсә, иясен тешли...

Азамат. Син... минем... дустыммы?

Сәймән. Аерылмас бердәнбер дустың. Җан дустың, туганым. Шулай.

Азамат. Ничек алай булды әле? Башкаларны бөгеп сандалда чүкегәндә сиңа нигә ирек куйдым? Диңгез ярындагы очлы таш буласың киләме?

Сәймән. Беркем дә буласым килми. Хәзергесенә канәгать.

Азамат. Тау иясе иттем сине! Актай печәнен син чаптың! Бүтәннәр монда дары исе чыгарырга кыймадылар, киек-җәнлек ауламадылар. Чәшкеләргә син хуҗа! Көзәннәр синеке! Елына ничә бүрек, ничә шешә бурсык мае сатасың? Соңгы елда гына күпме тире тунадың?

Сәймән (*исе китми генә*). Шул тиреләр ярдәмендә кемдер колхозны аякка бастырды...

Азамат. Зыярәт җиләгенә хәтле җыеп сатасың бит син, дуңгыз!

Сәймән (*әтәчләнеп*). Авылга аяк басуың хәтереңдәме? Йә?! Ничек каршыладылар? Онытмадыңмы? Куып җибәргәндә көчне сиңа мин бирдем.

Азамат. «Азамат нүл ул, колхозны аякка бастыручы мин!» —дип, уңга-сулга мактанып йөрергә сиңа кем хокук бирде?

Сәймән. Мин түгел, акыллы кешеләр үзләре шуны сөйли.

Азамат. Мин килгәнче дә син шушы авылда идең. Нигә хуҗалык күтәрелмәгән? Нигә колхозыгыз артта сөйрәлгән?

Сәймән. Сельхозтехникага ничә бүрек илткәнеңне онытмадыңмы?

Азамат. Булды. Илткән чаклар да бар иде.

Сәймән. Запчастьларны бүтәннәрдән ике тапкыр артык ала башладың. Шәп! Ахун Галиевич белән беренче тапкыр шунда якага-яка килдегез!

Азамат. Ул чакта башкача мөмкин түгел иде.

Сәймән. Элеватордан комбикормны теләгәнчә районда бер генә кеше алды. Районда бер! Ул кеше — син идең. Чыштырдавыклы өтек бишмәт кигән өчен бирделәрме алар ярдәмне?

Азамат. Ул вакытлар белән хушлаш, Сәймән абый. «Мәңгегә хуш!» диген.

Түрәй керә.

С ә й м ә н. Сиңа монда ни кирәк? Нигә эшең ташлап минем тауда йөрисең?

Т ү р ә й. Сәймән, көнне күрәсеңме. Яндыра! Су эчәргә мендем.

С ә й м ә н. Аста эчсәң тамагыңа ярамаганмы?

А з а м а т. Нигә аңа син кычкырасың?

С ә й м ә н. Бүтәннәр аста эчә. Нигә аңа ярамый? Кем булган ул?!

Т ү р ә й. Беркем дә түгел. Кеше.

А з а м а т. Бәйләнмә.

С ә й м ә н. Йөрмәсен! Мин аңа тауга менмәскә кушкан идемме? Менә дә китә. Аның ишелергә монда ни калган?.. Җүләрләргә монда урын юк.

А з а м а т. Ни өчен җүләр дип атыйсың аны?

С ә й м ә н. Җүләр! Яши белмәгән һәрбер бәндә җүләр. Күзенә карап әйтәм. Укытучы иде, заманында директор булып торды. Кем куды аны мәктәптән? Үзе китте. Гариза биреп. Җүләр димичә аны кем дисең? Балалары таралышты, карчыгы дөнья куйды. Байгыш булып авылда ята. Шәһәргә китсен! Югары белем белән монда чүгендер ызанында ауный. Кеше яшәргә өйрәнсен! Өйрәнмәсә —җүләр.

Т ү р ә й (*чишмәгә иелеп су эчә, юына*). Сөйлә, сөйлә. Тыңламыйм мин сине. Ишетмим дә.

С ә й м ә н. Эш бетмәгән килеш нигә трай тибәсең дим мин сиңа?

А з а м а т. Үзеңә дә эшкә тотынырга вакыт, Сәймән абый. Бар! Икәүләшеп монда сезгә ни калган?

Т ү р ә й.

> Ага сулар... Кайда Суар, Болгар?
> Сирәгәеп калган урманлык...
> Биек булмаса да тауларым бар,
> Итәгенә ятып җыларлык...*

С ә й м ә н. Нәрсә, нәрсә?

Ф а я г ө л керә.

Ф а я г ө л. Азамат абый, Нургалигә әйт әле. Тыңламый. Булышмыйм, ди. Теләгәнегез барыбер барып чыкмый, ди.

А з а м а т. Сәймән абый, күз көеге булып йөрмә, бар. Нургалине эзләп тап. Мин аны!..

---

* Гамил Афзал шигыре.

Сәймән. Түрәй, выжт түбәнгә! (*Үтеп барганда Фаягөлне капшый.*)

Фаягөл. Ну бу Сәймән абыйны!

Сәймән. Фаягөл аппак! Их!

Чыгалар.

Азамат. Түрәй абый! Син авылның олы кешесе. Нигә иплəп генә, шау-шусыз гына яши алмыйсың? Нигә Сәймән белән гел-гел гаугалашасың? Ярамый алай.

Түрәй. Син аның белән тату яшәгән дә бик җиткән.

Азамат. Беләм, авылда ул синең иң олы дошманың.

Түрәй. Ялгышасың, Азамат. Авылдагы дошманым син минем.

Азамат (*үзгәреп*). Шулай укмы?

Түрәй. Син булмасаң, Сәйманнәр дә үрчемәс иде!

Азамат. Бер башлагач, әйтеп бетер!

Түрәй. Сөйләсәң озынга китәр. Аңламассың да... Телләр башка безнең. Кыскача — кагылма тауга. Тимә. Калдыр Актайны.

Азамат. Нургали барып чактымы?

Түрәй. Җәберләмә безне. Актай — карап торган матурлыгыбыз.

Азамат. Коры куанычтан ни мәгънә? Безгә бүген күл хаҗәт! Су кирәк. Сугарулы кыр-болыннар кирәк. Сиңа кирәкмиме? Бүген кирәк, киләчәк өчен кирәк.

Түрәй. Син үзеңчә гел хаклыдыр, тик кагылма тауга. Бер җимергәч яңадан кайтара алмассың. Җил тегермәнен бетердек. Су тегермәне ташуда агып китте. Болыннарны сөреп ташладык. Әрәмәләрне төпләдек. Бер җимергәч кире кайтара алмассың.

Азамат. Нигә кирәк сиңа тау?

Түрәй. Нигәме?.. Нигә кирәклеген бөтен йөрәгем белән аңлатсам да барыбер аңламассың!.. Син әле үз тирәндәге куштаннарны да диңгез шомарткан вак ташлар дип кенә саныйсың. Ә мине...

Азамат. Дәлилең булса, аңлатырлык итеп әйт!

Түрәй. Юк, Азамат, аңламыйсың... Һәр елны беренче класска кергән балаларны шушы тауга алып менә идем дисәм — сиңа көлке. Сабан туйлары элек шушы тау итәгеннән башлана иде дисәм — сиңа мәзәк. Каян башланса да барыбер түгелмени?.. Кырык беренче елда без шушы тау итәгеннән сугышка чыгып киттек дисәм

дә синең ис китәчәк түгел... Кешеләр шома таш сиңа, тау дәү бер балчык, туфрак өеме...

Азамат. Тау калачак.

Түрәй. Күз алдына китерәм!.. Башка әмәлен тап, председатель!

Азамат. Башка әмәлен көтәргә вакыт юк. Миңа бүген кирәк. Илгә икмәк кирәк, шикәр, ит-май! Бала-чагаларча кәҗәләнеп күпме үгетләсәң дә үземнекен эшләрмен.

Түрәй. Ярты тау — «Тукай»ныкы. Ахун Галиевич нәрсә дияр...

Азамат. Һәр акыллы кеше шул сүзне әйтәчәк. Районда да шуны хупларлар. Бер тау башы җимерелде дип, тормыш алга баруыннан туктамас.

Түрәй. Гәрчә ул тау Актай булса дамы?.. Хәер, сиңа нәрсә? Үз кирәгеңә син Казбекны, Эльбрусны да җимереп ташлар идең!

Азамат. Ташлыйм. Ике дә уйлап тормыйм. Синең ишеләр: «Елгаларда балык үлә, ашлама агып төшә!» — дип лаф ордылар. Аңа карап тордыкмы? Кирәк чакта елгаларны кире борабыз! Тормыш ул, Түрәй абый.

Түрәй. Бүгенгә дип киләчәкне корбан итү тормыш түгел ул, председатель!

Чыга. Музыка. Пауза. Динә керә.

Динә. Азамат абый, сиңа ни булды?

Азамат. Ә, Динә... Кайтып китмәдеңмени? Бәлки, синең дә сүзең бардыр миңа? Дәгъваң?!

Динә. Сүзем булмаса, «Көтеп торыгыз!» дип кул болгар идемме? Тик сез туктамадыгыз.

Азамат. Ашыга идек, Динә.

Динә. Бездән качарга ашыга идегезме?

Азамат. Барып җитәргә дип ашыктык.

Динә. Һич аңлаша алмыйбыз, Азамат абый!

Азамат. Ачуланма, Динә, гадәттәгечә, бүген дә ашыгам.

Динә. Үтенәм, тыңлап бетер. Сүзем бер җөмлә белән генә аңлаша торган түгел. Шул сүзне әйтер өчен иртәдән артыңнан чабам!

Азамат. Бүген түгел, Динә, яме. Бүгенне үземә калдыр!

Динә (*көрсенеп*). Миңа китәргә вакыт. Авыл белән аерылыр көн җитте. (*Көлеп.*) Сәер бит, Азамат абый, бала чактан шәһәр дип саташкан Динә, укып бетергәч, ярый-

сы гына урында төплəнгəч, тота да авылга кайта. (*Утырышалар.*)

Азамат. Сəер анысы. Бөтен яшьлəр шəhəргə омтылганда борылып кайттың. Сөйлə. Бəлки, миңа практик файдасы тияр. Акыл булыр.

Динə. Ялгызлыктан качып кайттым.

Азамат. Əкият сөйлəр өчен объектны дөрес сайламагансың. Əнə, Түрəй абзаңа сөйлə! Ул яши əкиятлəр, шəүлəлəр дөньясында!

Динə. Мең кеше арасында ялгыз калганда куркыныч икəн, Азамат абый. Эштə йөрисең шунда, ул-бу сизелми. Эш югында коточкыч! Кинодан чыгасың. Урам буйлап гамьсез генə кайтып барасың. Биш минут эчендə унбише сүз салып өлгерə. Чибəр, дилəр, аякларың төз, дилəр... Аулакка дəшəлəр, алтын-көмеш вəгъдə итəлəр. Яшь кызга читен ялгызына зур шəhəрдə! Ничек гомер итмəк кирəк? Гел-гел эш белəн мавыгып та, өйдə утырып та булмый. Башта икешəр смена поликлиникада качып яттым. Бездə, үзең белəсең, хатын-кыз патшалыгы... Кыерсытылган минутларымда бары тик синең хакта уйлый идем.

Азамат. Эшкə тотынган елларда беребезгə дə җиңел түгел.

Динə. Дус кирəк кыз кешегə, ир-егет кирəк. Яклаучы кирəк. Көчле яклаучы.

Азамат. Миндə шул сыйфатлар бар дисеңме?

Динə. Сиңа кадəр авылда ничə председатель булып киткəн? Син килдең дə беренче булдың.

Азамат. Шаярталар! Кем сүзе бу?

Динə. Мин сиңа сафлыгымны сакладым. Яратам мин сине, Азамат абыем, бик яратам.

Азамат. Мин моңа ышана алмыйм.

Динə. Синдəй көчле, гайрəтле ирнең чибəр хатыны булырга тиеш. Мин сине шəhəргə алып китəргə дип кайттым!

Азамат. Мин монда хуҗа. Хуҗа булу хисен татып караганың юк синең, шəфкать туташы!.. Татлы хис ул. Исерткеч хис! Татыдым мин аны, həм син шул кешене гап-гади коллыкка өндисең түгелме?

Динə. Безгə монда калырга ярамый. Авылдан туйдың, белəм. Көчлəп куйдылар сине монда, көчлəп тоталар, бəйдə.

Азамат. Əйтəм ич, белмисең мине! Белмəгəч, ничек яратырга ди?!

Д и н ә. Эштән сорап киткән идем. Вакытым бетте. Хәзер җәй. Отпускылар вакыты. Чакыралар. Ләкин мин шәһәргә синең белән генә кайта алам. Югары белемең бар, тәҗрибәң җитәрлек. Эш табылыр. Миңа фатир вәгъдә итәләр. Синсез яши алмыйм!

Ф а я г ө л керә. Пауза.

Ф а я г ө л. Саныйбыз, Азамат абый. (*Каушап.*) Әллә ни уйламагыз, әнкәйгә чишмә суы дип кенә... Күз алдымда савытым юкка чыкты. Күз будылар инде әллә? Шунда гына куйган идем...

Чыга. Азамат аңа кызыксынып карап тора.

А з а м а т. Чая хәзер кызлар!

Д и н ә. Син дә мине яратасың ич! Шуңа таянып ачыктан-ачык сөйлим.

А з а м а т. Төшеңә кереп: «Яратам»,— дидемме?

Д и н ә. Бүген иртән минем арттан өздереп карап калдың! Шуны сизеп бөтен тәнем калтырана башлады! «Бүген барын да ачып салам»,— дидем.

А з а м а т. Иртән мин дә: «Бүген!» — дидем, Динә...

Д и н ә. Азамат абый...

А з а м а т. Иртән син ялгыз түгел идең, Динә.

Д и н ә. Әллә шул Назага күзем төште дип әйтергә телисеңме? Кирле-мырлы, акылсыз ич ул!

А з а м а т. Әйтмәдем. Иртән сез икәү бара идегез, дидем. Әлегә шул гына.

Д и н ә. «Бүген» дигәнең куркыта... Мин китәсене белеп әйтәсеңме? Әллә көндәш табылдымы?!

А з а м а т. Китмим мин моннан, Динә. Беркая да китмим.

Чыга. Динә аның артыннан бара, нәүмизләнеп, борылып кергәндә, Фаягөл белән очраша.

Д и н ә. Савытың табылдымы, Фаягөл?

Ф а я г ө л. Бер киткәннәр борылып кайтмый иде. Сиңа монда ни калган? Күз көеге булып ник кайттың?

Д и н ә. Кирәк кеше белә. Кайчан, ничек китәсем дә аңа сер түгел. Үзе дә ияреп китәргә ашкынып тора.

Ф а я г ө л. Аның сабый җанын таларга кайттыңмы? Ул бит мәхәббәттә бала кебек беркатлы.

Д и н ә. Гашыйк! Чәчрәп китим, гашыйк!

Ф а я г ө л. Гашыйк булырга хакым бар. Мин саф намуслы кыз!

Д и н ә. Сафлыкның модасы үтте, сазаган чуртан. Хәзер чая һәм сылу кызлар көне килде.

Ф а я г ө л. Бирмим! (*Бер-берсе белән тарткалашалар.*) Бирмим, Казан жулиге.

Д и н ә. Кеше көлдермә, зинһар. Чишмәгә иелеп чыраеңа кара, карт кәҗә.

Ф а я г ө л. Кәҗә сөзгәк була, шәһәр саесканы, таракан!

Д и н ә (*бөеренә таянып*). Әй син, тәкәрлек күкәе! Юлыма аркылы төшсәң, ни буласын чамалыйсыңмы? Яр бирмәк — җан бирмәк, диләр. Үзең дә онытма, белмәгәннәргә дә әйт! Каладан хулиганнар чакыртып кистерермен.

Чыга. Фаягөл ялгызы. Бераздан А з а м а т үтеп бара.

Ф а я г ө л. Беткән баш беткән! Азамат абый!

А з а м а т. Ни бар, Искәндәрева?

Ф а я г ө л. Нигә мине фамилиям белән дәшеп кимсетәсез?

А з а м а т. Тыңлыйм сине, Фаягөл?

Ф а я г ө л. Азамат абый... Көзгә ак мунча салдырам. «Жигули» алам... Унике каз бәбкәбез бар. Үрдәкләр егерме дүрт! Син күркә итен яратасың... Анысын да асрарбыз!.. Тик бу кыска итәккә ияреп китә генә күрмә!

А з а м а т. Нәрсә, нәрсә?

Ф а я г ө л. Бозык кыз ул, яман кыз... Шәһәрдән әллә ничә йөк гайбәте килде. Китә күрмә, әрәм буласың! Монда кал... Җаным, тәнем, бәгырем белән, гомерем белән сине яратам!

А з а м а т. Тр-р, салулап читкә кердең. Нәрсә дидең!

Ф а я г ө л. Яратам, Азамат абый.

А з а м а т. Үз көнен күрә алмаслык җебегән дип саныйсыңмы мине?

Ф а я г ө л. Юк, юк... Сиңа рәхәт чиктерәсем генә килә. Мендәрләрем каз мамыгыннан... Чәчем белән җир себерергә дә риза!

А з а м а т. Син дә мине иярләргә уйлагач!.. Кит юлымнан, Искәндәрева!

Ф а я г ө л. Динә белән рәхәт күрәчәк түгел син, саташма!

А з а м а т. Син саташасың, син! Акылыңа кил!

Чыга. С ә й м ә н керә.

Ф а я г ө л. Сәймән абый, Сәймән абый!

С ә й м ә н. Тозакка төшкән күк тырпылдыйсың, аппак. Кайсы җиреңкычыта? Кашучы юкмы?

Ф а я г ө л. Их, Сәймән абый... Телең...

С ә й м ә н. Синең кайгыларың булса иде миндә!

Ф а я г ө л. Риза! Оят булса да әйтим: риза! Чукынып китсен!

С ә й м ә н. Нәрсә? Ризамы?

Ф а я г ө л. Бар шартыңа күнәм. Нишлим соң, башка чарам, өметем калмады. Барысы киселде... Ә гомер уза, уза! Җан сорый, тән тели... Бәби табарга да риза. Әйдә, синнән булсын. Башкача көтәр чамам калмады. Үтте гомерем. Көн-таң яралган саен тәнемдә көчем, күңелемдә дәртем кими бара күк. Бәби миңа кирәкмиме?! Бетте. Динә белән алышырлык көчем юклыгын таныйм.

С ә й м ә н. Рәхмәт. Җегәремне арттырдың. Көч бирдең. Борынымны салындырып менеп килә идем, куәт бирдең. (*Аны капшап.*) Рәхмәт, җанашым.

Ф а я г ө л (*Сәймәнне кагып җибәрә*). Кайчан икәнен сорама, үзем әйтермен!

С ә й м ә н. Белеп сайладың сердәшне, Фаягөл иркәм!

Н у р г а л и белән Н а з а керәләр.

Н у р г а л и. Тыйнак, сер саклый белүче, телсез-тешсез булышчы алып мендем сиңа, Фаягөл.

Ф а я г ө л. Шулкадәр катламасаң!

Н у р г а л и. Соң, тора анасы яламаган нәрсә төсле башын иеп, ризалашып.

Ф а я г ө л. Үзең! Карышып ни кыла аласың?

Н у р г а л и. Мин, ичмасам, сүземне әйттем.

Н а з а. Мине дә булышырга килгән дип уйлама, Фаягөл.

С ә й м ә н. Кара, кара, сырт йоны кабарган!

Ф а я г ө л. Койрык күтәрмәкче буласыңмы? Син? Авылда, җаным, хуҗа бер. Эссе табада «Әпипә»гә биетер Азамат Сафич, биерсең. Көлә-көлә сикерерсең. Сәймән абыең булып ул да бии әнә. Моңарчы председательләрне бар дип тә белми иде. Азамат абый барыгызны учына йомарлады. Беркем дә кыеп сүз дәшми. Нигә дәшсеннәр, тамаклары тук. Шулай, җанашым, юкка тыпырчынма!

А з а м а т керә.

А з а м а т. Ачуланасы иде сине, Нургали, берлеккә кал-

сын... Хәерле көн, Наза. Хәзер үк эшкә тотынасыз. Хәерле көн, дидем.

Н а з а. Рәхмәт. Без бүген күрешкән идек.

А з а м а т (*көлә*). Тау башында күрешкән юк. Менә ни иде, акыллым. Син бер-ике көнгә Фаягөл апаңа нык кына булыш инде. Ни эшләргә кирәген ул аңлатыр.

Н а з а. Ни эшләргә кирәген дә, алда торган зур бурычларны да Нургали аңлатып бирде.

А з а м а т. Өлгер егет! Мактыйм. Бу эшне шау-шусыз һәм тиз башкарып чыгарга иде. Шау-шусыз дип кабатлап әйтәм. (*Сәймәнне бер читкәрәк алып китә.*) Ә сиңа, Сәймән абый, компенсация ясалыр. Табылыр бер төшемле почмак, тик ят имеп!

Н а з а. Миннән ризалык сорарга оныттыгыз, Азамат абый.

А з а м а т (*көлә*). Кулыңны сорап килгәнем юк әлегә.

Н а з а. Шулай да...

А з а м а т. Башлыйсы эш турында синең ризалык та хаҗәтме, акыллым?

Н а з а. Менә. Рәхим итеп укыгыз. Сезгә турыдан-туры буйсынмасам да гаризамны күрсәтергә булдым.

А з а м а т. Нинди гариза?

Н а з а. Моннан китү турында гариза. Кая икәнен әлегә белмим. Мөгаен, «Тукай»га, Ахун Галиевич янына барып чыгармын. Шунда билгеләгәннәр иде мине башта.

А з а м а т. Мин сорап кайтарттым сине. Нигә китәргә булдың?

Н а з а. Ошамыйсыз миңа. Сезне яратмыйм.

С ә й м ә н. Вәт җен!

А з а м а т (*уенга алып*). Мәхәббәтне шулай халык алдында аңлашалармы?

Н а з а. Кызганычка каршы, сезнең белән мәхәббәт хакында бер дә сөйләшәсе килми.

А з а м а т. Шулай укмыни?

Н а з а. Сабыйга санамагыз, аңлыйм. Диктаторларның олысы да, кечесе дә йә ялганны, йә яланы ишетеп күнеккән. Әмма мин уйлаганымны әйтәм. Хаталанамдыр, бәлки?.. Булсын! Үзегез дә, эш алымнарыгыз да, борынгы байларча кәпәренүегез дә — берсе дә ошамый миңа. Тупас телегезне, гади булып кылануыгызны сөймим. Чөнки сез гади булып уйнап мин-минлегегезне һәм куркаклыгыгызны яшерергә азапланасыз.

Ф а я г ө л. Һай, оятсыз.

С ә й м ә н. Ну әйтә!

Азамат. Бу кәгазьне мин нишләтергә тиеш?

Наза. Бер почмагына «каршы килмим» дип тамга салыгыз.

Азамат. Күз ачып йомганчы!

Фаягөл. Белдем мин аны, белеп тордым.

Сәймән. Үз вакытында юлда булуы әйбәт. Барысы да китәчәк!

Нургали. Әгәр Назаны җибәрсәң, мин дә монда калмыйм.

Азамат. Килешенеп мендегезме?

Наза (*егеткә йомшак кына карап*). Нургали... әлегә мин үзем өчен генә сөйләштем. Сүз берләшкәннәр дип уйламагыз, Азамат абый.

Сәймән. Ни кыланасың син, Нургали? Тамагың туйдымы?

Нургали. Шушы кыз бала да миннән көчлерәк егет булып чыкты! Их, мин дә күп тапкырлар синең белән килешми идем, сүз әйтергә кыймадым. Дәшми уздырдым... Шофер кешегә дә җан рәхәте булырдай бер эш табылыр әле. Болай үз-үзеңне кыйнап яшәгәнче...

Наза. Дөрес, Нургали. Хезмәтең җан рәхәте булса икән лә! Укып кайтуга бозау карарга җибәрдегез. Бардым. Сыныйсыздыр дип уйладым. Бозау багучы апа авырып киткән чак иде. Эшләдем. Аннан бер айга почтага күчердегез. Кайларда гына эшләмәдем. Ниһаять, аңладым — кирәгем юк икән минем монда. Күңелем гел яктыга омтыла иде, сез аңа чик куйдыгыз. Яшьләр арасын җанландыру иде максатым. Китәләр бит, авылны ташлап китәләр. Сезгә бары тик сүзсез ахмаклар гына кадерле. Ахмакларга эш тә, акча гына булсын!

Азамат. Ярар. Яхшы. Карарбыз.

Наза. «Күрсәтермен» дип әйтүегез булдымы?

Азамат. Алай булуы да ихтимал.

Фаягөл. Бары да бер. Җылан!

Нургали. Киттек, Наза.

Наза. Кунак турында оныттың.

Азамат. Нинди кунак тагын?

Нургали. «Тукай» председателе Ахун Галиевич килеп калды.

Азамат. Минем аны чакырганым юк.

Нургали. Идарәдә көтә. Рульгә үзең утырасыңмы?

Азамат. Бер көнгә түзмәгән икән, бүгенгә! Яхшы. Колакларыгызны торгызып тыңлагыз. (*Көлә.*) Наза, акыллым... Синең ультиматумыңны кабул итте дип

сана. Уйлармын. Тик бүген бер карарга да килә алмыйм. Ахун Галиевич көн дә килеп тормый. Тауда көн дә мондый хәл тумый. Гомергә бер була торган көн иде бүген!

Сәймән. Мужыт, Ахун Галиевичнең дә шундый көнедер?

Азамат. Сәймән абый, Фаягөл! Шәп итеп табын әзерләгез. Тәкә суегыз, тәкә янына кәлчә-мәлчәләр дә булсын!

Сәймән. Андый олы кунакны тегендә-монда гына сыйлап ярамас.

Азамат. Шушында, тау өстендә! Сөйләшергә дә уңай. Нургали, абзаң белән Фаягөлне машинаңа утырт та ындыр артлатып кына авылга элдерт.

Нургали. Мин бит... Их, җебегән, тагын әйтә алмадым!..

Наза. Мин дә алар белән кайтам.

Азамат. Ә син, Наза, чак кына сабыр ит.

Нургали, Сәймән, Фаягөл чыгалар.

Наза. Мине нигә дип калдырдыгыз?

Азамат. Мине сакларсың... Гафу ит, Наза. Һич алай дияргә теләмәгән идем. Нидер әйтәсе бар иде! Якты, зур сүз!.. Өметле сүз! Иртәдән бирле шул сүз күңелгә килеп китә... Сез иртән, ике кыз, безнең турыдан үттегез... Сез үтеп киткәч, мин озак уйландым!.. Җылы сүз! Тик ничек әйтергә аны? Белмим...

Наза. Уйланырлык ук нинди сәбәп табылды икән? Сезнең турыдан кызлар күп йөри.

Азамат. Әллә нинди булды бүгенге көн! Ике кыз «сөям» дип миңа гыйшык белдерделәр.

Наза. Туп-туры әйтә алдылармы?

Азамат. Председательләрнең гыйшык-мыйшык уйнарга вакытлары юк дип белепме, кызлар бик актив һөҗүмгә күчтеләр. Икесе «сөям» диде. Өченчесе...

Наза. «Китәм» дигән гаризасын китерде. Бары шул гына.

Азамат. Бу да үзенә күрә активлык! Кызлар төрле яктан камый башлаганнар икән, монда нидер бар. Яки нидер булырга тора... Мин күз белән карап калганда, синең адымнарың үзгәрде, Наза...

Наза. Адымнарымны күрмәдем. Бүген уңыш җыясыгыз килә инде? Өченче кыздан да «сөям!» дип әйттерәсегез килә.

А з а м а т. Бик килә, Наза... Матур атлый идең син.

Н а з а. Матур да атлагач, тагын бер тапкыр карап кал, Азамат абый!

Тиз-тиз чыгып китә.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Шул ук урын. Бер якта учак янганы шәйләнә. Казан асылган. Табын әзерләнгән. С ә й м ә н табын тирәли йөри, Д и н ә керә.

Д и н ә. Ахун Галиевич нигә килгән?

С ә й м ә н. Ник килгәне аңлашыла! Нигә, чакыруны кабул итеп мәҗлескә менгән диген? Менмәс дип уйлаган идем мин аны. Идарәдә очрашып чәкәләшәләр дә аерылышалар дип белдем. Сиңа монда ни кирәк? Бар дим... Минем янда иснәнеп йөрүдән файда чыкмый.

Д и н ә. Абзый, абзый...

С ә й м ә н. Абзыйга ни булган?

Д и н ә. Тар карашлы кеше син. Гыйбад. Үз файдаңны да аңламыйсың. Азаматны алып китсәм, сиңа чат файда гына.

С ә й м ә н. Җүләр! Ахунның аны өркетеп алуы гына кирәк миңа. Асылда Ахун ишеләр куркыныч. Тау аларныкы да!.. Әлегә монда мин бердәнбер хуҗа идем. Азамат белән яшәп була! Тезгеннән генә ычкынмасын!

Хәле бетеп, бәләкәй кәрҗин тоткан Ф а я г ө л, аның артыннан зуррак ике кәрҗин күтәреп Н у р г а л и керәләр.

Ф а я г ө л. Тыңлаулы син, Нургали. Абзаң «машина белән менмә» дип бер әйтте, тау итәгеннән тәпиләттең. Уф, соңга калмадыкмы?

С ә й м ә н. Юк шикелле.

Н у р г а л и (*Динәгә*). Наза кайтып китмәдеме?

Д и н ә. Алып кит шуны бер яры! Олактыр!

Н у р г а л и. Кая?

Д и н ә. Машинаң өр-яңа. Шәп йөртәсең. Егет булсаң, тот та урла — җебеп йөрмә!

Н у р г а л и. Әһә, көндәшнең көчле икәнен сизенә башлагансың!

Д и н ә. Шикләнмим дә... Яратмыйм шуның сүзсез генә текәлеп карап торуын.

Ф а я г ө л. Олагырга үзеңә бик вакыт иде дә...

Нургали. Кызлар! Чамалагыз, бүген Азамат абый кайберәүләргә кызык ясап куймасын.

Фаягөл. Нинди кызык?

Нургали. «Өйләнәм» дигән сүз ычкынды аннан.

Фаягөл. Сиңа шуны әйтеп торгандыр инде...

Азамат керә.

Азамат. Сездә ни хәлләр?

Сәймән. Сәймән бар җирдә эшнең кайчан уң булмаганы бар?

Азамат. Сәймән өчен уң булганның безнең өчен туң икәнен дә беләбез! Нургали, син тагын бер тапкыр авылга җилдер инде. Тиз йөр.

Фаягөл. Бар нәрсәбез җитеш, Сәймән абый. Исегез китәр.

Азамат. Ахун Галиевичнең Түрәй абыйны күрәсе килә.

Сәймән. Кемне, кемне? Көн яктысына ябалакны кем чакыра?

Азамат. Сүз ялганмый безнең, ык-мык йөрибез.

Фаягөл. Ач карынга ир-атка татлы сүз киләме? Тизрәк табын янында түгәрәкләник! Килегез, кил!

Азамат. Табын янына да ашыкмый.

Сәймән. Әһә, алаймы?

Нургали. Бармыйм. Түрәй абый мәҗлесләргә йөрми ул. Килмәс.

Азамат. Кем аны мәҗлескә чакыра? Нинди мәҗлес! Кайда?.. Син, егет! Монда эш хәл ителә, эш! Язмыш хәл кылына! Бар!

Динә. Ахун Галиевич чакырды дип ныгытып әйт!

Азамат (*Нургалине озата бара*). Килмим дисә, үгетләп маташма! Тиз йөр!

Азамат, Нургали, Динә чыгалар.

Фаягөл. Әллә тәмсезләшә башлаганнар инде?

Сәймән. Әлегә юк сыман, аппак. Ну ызгышачаклар.

Фаягөл. Барын да белгән булып кыланасың.

Сәймән. Ахун хәзрәт дошманы өненә юкка гына килмәгән! Түрәйне нигә чакыруларын гына аңлата алмыйм.

Фаягөл. Бөтенесенә хуҗа дип мактанган була бит бер кеше.

Сәймән. Их, ишетеп торасы иде: ни сөйләшәләр

икән? Тау башында гауга булачак бүген. Башымны кисәргә бирәм! Кая баралар инде, сукыр кәҗәләр! Анда байбак өннәре! Әй, аш суына, аш! Аш дим! Җүләрләр, яши белмиләр. Тормышның кадерен белмиләр, сипкеллем! (*Фаягөлне тоткалый.*)

Фаягөл. Куйчы, Сәймән абый. Җитте инде!

Сәймән. Кара, кара, карышып маташа. Баягы җылы сүзеңне оныттыңмы?

Фаягөл. Кайнар чагында телдән ни ычкынмас?

Наза керә.

Наза. Нургалине кая җибәрделәр? Өлгерә алмадым. Кайтып китә идем.

Сәймән. Ә-ә, юк. Председатель сиңа кайтмаска боердымы?

Фаягөл. Кайтсын, кайтсын!

Сәймән. Нургали Түрәйне алып килергә дип китте.

Наза. Нигә аның җанын кат-кат борчып торырга инде?!

Сәймән. Ахун абзаңа карыша алмассың!

Фаягөл. Хәзер әйләнеп килә, хәзер. Утыр да әйбәтләп кайтып кит. Эшне синнән башка да үтәп чыгарбыз. Йөрмә монда.

Сәймән. Китә күрмә! Озакламый монда кәмит башлана, тамаша! Йә кирәгең чыгар. Тамашада күбрәк кеше булган яхшы.

Наза чыга.

Фаягөл (*кәрҗиннәрен бушатып*). Боларын кая куйыйм?

Сәймән. Тагын ни анда?

Фаягөл. Бер түтәрәм каклаган каз.

Сәймән. Түтәрәме саллы икән, ярты каз булыр!

Фаягөл. Тозлы гөмбә. Чия вареньесы. Урман чикләвеге. Чөгендерле катык. Сусаганда бирербез.

Сәймән. Келәтегезне күтәреп киләсең калган. Айһай юмартланган син, аппак! Әнкәңне беләм, сыңар инәсен дә бушка бирмәс... Чәлдереп килдеңме боларны?

Фаягөл (*җылап җибәрә*). Азамат абыйны әллә ничә кунакка дәштем, кермәде-е!

Сәймән. Менә сиңа мыштыбый! (*Ачулы.*) Уңганлыгың, булганлыгың белән мактанып председательне тозакка төшермәкче буласыңмы?

Фаягөл. Ахун Галиевичкә рәхмәт. Файдаланып булмасмы... Нишлисең син, котырган?

Сәймән. Күрмисеңмени, чикләвегең арасына вак таш тутырам. Тешләре сынсын!

Фаягөл. Ах, хәерсез!

Сәймән. Катыгыңа тоз сибәм!

Фаягөл. Бәбәгеңне тырмап алырмын. Ни кыланасың дим, юньсез! Сәймән абый, күпне беләсеңдер, мәгәр хатын-кыз җанын аңламыйсың. Бөртек тә! Бүген Азамат белән Ахун абый якынаерга тиеш. Килешсеннәр дә гомергә тату яшәсеннәр. Ишсеннәр тауны! Азамат абыйның сүзе өстен чыксын. Моннан китмәсен генә!

Сәймән. Ба-а, җил искән саен итәк күтәрәсең икән син! Ахун Галиевич какшамас авторитеты белән безнекен тәмам изеп ташласын. Спасательный круг минем кулда калсын. Ташлар дип өметләнә, ә мин, иң кирәкле моментта, Азамат быкырдап төпкә китә башлагач кына... Ташламыйм!

Фаягөл. Дус дип йөргән буласың тагын!

Сәймән. Дошманны батыру кызык түгел, дусны чумдырып алу рәхәт!

Динә керә.

Динә. Түрәй абыйны килмәс дигән буласыз, күрәсезме ничек теркелде!

Сәймән. Ни хәл бу? Ни хәл? Дөньяны аңламый башладым! Тә-әк...

Ачулы Нургали керә.

Нургали. Тагын ни боерыклар бар миңа? Биреп калыгыз.

Сәймән. Синнән ни сөт, ни йон... Динәгә сүз бар.

Динә. Боерыгыз, абзый.

Сәймән. Әгәр Азаматны Ахун хәзрәт тә җиңә алмаса, алып кит үзең белән. Миннән сиңа кама яка.

Динә. Кама тун тектерсәң иде, абзый!

Сәймән. Фаягөл, минем янда тор!

Фаягөл. Тагын бер талпынып карыйм инде, Сәймән абый. Кем белгән бит... Бер тапкыр гына, яме.

Динә (*Нургалигә*). Син гармуныңны алып менгәнсең икән.

Нургали. Бәйрәм бит!

Динә. Бәйрәм итәргә сәбәбе генә юк.

Н у р г а л и. Сәбәбен табабыз аның. Теләк кенә булсын. Наза да монда.

Н а з а керә.

Н а з а. Мине кайтарып куйчы, Нургали.

Н у р г а л и (*гармунын тартып*). Кайтармыйм, Наза.

С ә й м ә н. Изге тынлыкны шайтан музыкасы белән бозмакчы буласыңмы?

Н у р г а л и. Изге чишмә юк, абзый. Бетте. Тәмам. Финита. Монда гөрләп бульдозерлар менәчәк. Танклар кебек. Алар тауны кимереп бетерәчәк. (*Уйный-уйный сөйли.*)

Бетте инде киек җәнлекләрең,
Бетте инде чәшке бүрекләр!..

С ә й м ә н. Ахмак! Егылганда да күзең күктә булсын!

Д и н ә. Егетләр, хәл итәсе бер мәсьәлә калды.

Ф а я г ө л. Председательләр хәл итсен.

Д и н ә. Фаягөлгә әйбәт кияү табылганчы чишмәне бозмый торсыннар! Тылсым беткәч ул нишләр, бичара, кая барыр?!

Ф а я г ө л. Ертык тишектән көләр ди... Хи-хи...

С ә й м ә н. Да-а, Азамат көчне җыйган икән. Китертте Ахунны тауга, кәҗә бәтие күк ияртеп йөртә.

Н а з а. Түрәй абый аларны ышандыра алмасмы? Шушы матурлыкны җимерергә куллары барырмы?!

С ә й м ә н. Кем тыңласын ул исәрне!

Н а з а. Кайчан исә бер Азамат абый аны аңларга тиеш ич!

Д и н ә. Гашыйк! Чукынып китим, бусы да Азаматка гашыйк.

Н а з а. Гашыйк булсам ни?

Н у р г а л и. Аның ни гаебе бар?

Д и н ә. Сиңа гашыйк түгел, селәгәй. Йөрисең Наза баскан эзгә яшь коеп... Дурак!

Н у р г а л и (*гармунын тартып*). Барыбер! Чын йөрәктән сөя алу бәхет. Сиңа әләкми бит ул.

Ф а я г ө л. Азамат абыйны, боерган булса, берегезгә дә биргән юк.

Д и н ә. Шул таш курчак Азаматны яратасыңмы?

Н а з а. Бар аның җаны, бар. Эзләнә торган җаны бар. Эзләнгән кеше яктылыкка бер чыкмый калмас.

С ә й м ә н. Әйтә бу!

Н у р г а л и. Белеп сөйли!

Сәймән. «Киткән кызлар кире кайта, бар да безнең бәхеттин!» Менә хикмәт кайда, энем!

Нургали (*гармунын тартып*).

Өч кыз тәрәз төбендә,
Кичен җеп эрләгәндә...

Наза. Пушкин әкиятендәге кебекме?

Нургали. Өчәү бит сез!.. Кызлар! Ур-ра! Әйдәгез, кунаклар килгәнче бер кызык ясыйбыз. Пушкин әкиятендәге кебек патша кәләшләре булсагыз, сез ни эшләр идегез?.. Ни кылып дөньяны бизәр идегез? Изге чишмә янында хас дөресне генә сөйләргә!

Динә. Син мине дә алар белән янәшә куясыңмы?

Нургали. Нигә? Әлегә барыгызның да шанслары бертигез. Патша монда юк, Ахун абзагызны көйләп йөри.

Наза. Әйдәгез, сынап карыйк!

Динә. Әйем лә!

Сәймән. Бирешмә! Җиң шуларны! Сыт, яле!

Фаягөл. Бирмим дигәч, бирмим!

Нургали (*Фаягөлгә*). Беренче сүз сиңа — Байлык. Матурлыктан да алда адәм уллары сиңа табынган...

Пауза.

Фаягөл. Патша кәләше булсаммы?..

Сәймән (*шыпырт*). Патша кәләше итәм мин сине! Байлыгым җитәрлек!

Нургали. Тыңлагыз, җәмәгать!

Сәймән. Мыекка чорныйк: хәзерге заман хатын-кызлары ни белән алдыра икән?

Фаягөл. Теләгем бер: минеке генә булсын! Мин аны ефәк эченә урармын!.. Майда йөздерермен!.. Эшләтмәм! Көн саен мунча ягармын!.. Кесәсендә һәр көн ак батист яулык!.. Үзем көне-төне эшләп аны түрдә генә утыртырмын!.. Шәп әйттемме?

Пауза.

Нургали. Чират — Матурлыкка! Динә, алгарак чык! Атла! Онытма, Ходай каршында — барыгыз да бертигез.

Динә. Мин?

Сәймән. Сынатма! Безнең нәсел, һо-һо!

Динә. Мин аның горурлыгын арттырыр идем. Ир кеше тау бөркете кебек кыю һәм буйсынмас характерга ия булырга тиеш. Кызганыч: бөркетләр бетә барган ке-

бек, ир характерлы ирләр дә юк диярлек! Матурлыкны юлдаш иткән ир генә дөнья белән идарә итәргә хокуклы. Мин аны дөнья белән идарә итәргә өйрәтер идем.

Фаягөл. Фи-и, әкият.

Сәймән. Тукта-тукта, постой!

Нургали. Хәзер син әйтеп кара, Наза.

Наза. Бөдрәләп сөйли белмим...

Сәймән. Постой, постой! Кызларның берсен «Байлык» дип, икенчесен «Матурлык» дип атадың. Нигә анысына кушамат юк?

Нургали. Ул кушаматсыз. Бары тик Наза гына. На-за!

Фаягөл. Әйтсен! Ул да ачылсын!

Наза. Мин яраткан кешемә тугры хатын, дус булыр идем.

Динә. Кыланчык...

Наза. Тугры, гадел хатын, дус булу азмы әллә?

Сәймән. Булмады әле! Ә син, энекәш, патша булсаң кызларның кайсын сайлар идең? Яле!

Нургали (*Назага карап*). Билгеле инде...

Сәймән. Вәт, тинтәк!

Нургали. Ә син, абзый?

Сәймән. Байлыкта бәхет, байлыкта! (*Фаягөл янына барып җитә.*) Ефәк корты күк тик ят имеп! Их!

Фаягөл. Ярый инде. Безгә без чыгар, шөшле булмас.

Сәймән. Эх-ма, хәзер дә шул икән. Башта патша диләр, аннан санатка чыгарга өметләнәләр дә солдатка яр булалар. «Киткән кызлар кире кайта, бар да безнең бәхеттин!»

Фаягөл. Киләләр!

Сәймән. Көшегез моннан, көш! Китебрәк торыгыз, кикриксез патша кәләшләре!

Нургали, Наза, Динә чыгалар. Азамат, Түрәй, Ахун Галиевич керәләр.

Сәймән. Рәхим итегез, кадерле кунаклар, дөньяның оҗмахына! Рәхим итегез, ил күрке — Актай тавына!

Фаягөл. Түгәрәк өйнең түре юк. Исәнмесез, Ахун Галиевич.

Ахун Галиевич. Фаягөл дә монда икән. Саумы, аппагым.

Азамат. Фаягөлсез дөнья китек.

Фаягөл. Сез инде, Азамат абый, бигрәк олылыйсыз. Түрәй абый, сез нигә читтә каласыз?

Түрәй. Түгәрәк өйдән йә тәгәрәп төшәрмен. Куркам.

Ахун Галиевич. Түрәй, бүген сине аңламыйм. Гел карышасың. Гел кирле-мырлы сөйләшәсең. Ни әйтергә телисең син?

Түрәй (*көләргә маташа*). Заманнан артта калганмын. Сөйләшә дә белмим.

Азамат. Теләмәсәң, башкалар сөйләр, Түрәй абый. Ахун Галиевич бик кызыклы әңгәмә башлаган иде. Бүлдердек.

Сәймән. Ихлас әңгәмә белән табынны ямьләндерик, кунаклар.

Фаягөл. Аш-суның яме китмәсен.

Ахун Галиевич (*дәвам итеп*). Шул. Урталай ярылган супертанкер Франция ярларына шулкадәр нефть агызган ки, башка бик күп бәла-казалардан тыш, бихисап кошлар, җәнлекләр, балык һәлак булган. Белгечләр утыз җиде төрдән кырык меңгә якын кош үлде дип нәтиҗә ясаганнар.

Азамат. Кырык мең!

Фаягөл. И, бичаралар! Каз ботын алыгыз, Ахун Галиевич!

Сәймән. Кырылганнар икән!

Түрәй. Ахун кордаш, син күршеләрең белән ничек яшисең?

Азамат. Тагын бөтенләй урынсыз сорау.

Түрәй. Нигә урынсыз? Беләсем килеп китте. Күршеләрең белән тату торасыңмы дип сорадым.

Ахун Галиевич. Нигә начар торыйм ди мин алар белән?

Түрәй. Бөтен дөньяны ярату җиңел ул, күрше белән тату тору читенрәк.

Сәймән. Ашап-эчеп утырыгыз әле!

Ахун Галиевич. Дөньяга ачулы кеше генә киналәп, читләтеп сөйләшә. Белүемчә, син андый түгел идең, Түрәй.

Түрәй. Франция ярларында һәлак булган кошларны жәлләргә кирәк. Хак. Бик вакыт. Тик әллә кайларга үрелгәнче, үз туган ягыбызны ныграк кайгыртсак файдалырак булмасмы? Шуны искәртүем.

Ахун Галиевич. Аны бит кызмыйча, дусларча гына да сөйләп була.

Түрәй. Нервылар, Ахун дус, шулар шаяра.

Азамат. Җәмәгать, бер дә мин көткәнчә бармый бу очрашу!

Сәймән (*җанланып*). Табынны оныттыгыз, иң кирәген! (*Азаматка.*) Шешәләрне салкынга куйган идем.

Ахун Галиевич. Актай башында шешәдәшләр булып утыру килешерме икән соң?

Сәймән (*чишмәдән шешәләр алып килә, сала*). Телләрне бераз кыздырыйк, туганнар. Нургали аста сакта, беркем менәчәк түгел.

Азамат. Егетләрчә бер тотыйкчы, Ахун Галиевич!

Сәймән. Үзең дә, Азамат Сафич!

Ахун Галиевич. Моңарчы председательләр белән Сәймәннең борчак пешми иде, күрәм, дус яшисез!

Сәймән. Акыллы хуҗалар белән мин һәрчак дус!

Фаягөл. Ахун Галиевич, менә тозлы гөмбә. Менә симез сарык койрыгы.

Ахун Галиевич. Әллә сарык суеп та өлгерткәннәр инде.

Түрәй. Юк, тере сарыктан ашык-пошык койрыгын өзеп алганнар. Арада бутарга кирәк бит.

Сәймән. Бездә тәртип, Ахун Галиевич, һәр тармакта тәртип. Азамат Сафич яшь булса да моңарчы тәртипне белде. Кабатлап әйтәм: моңарчы! Алтын председатель!

Ахун Галиевич. Моннан соң ни үзгәрәчәк?

Сәймән. Үзе әйтер инде анысын. Аның белән яшәргә була! Алтын кеше дим ич. Шулай.

Фаягөл. Азамат абый дөньяда бер!

Ахун Галиевич (*көлә*). Түрәйнең тагын каш җыерылды.

Түрәй.

> Елан зәһәр булыр өчен агу эчми.
> Алсу чәчәкләрне сыгып агу эшли.
> Сине мактап тәмли-тәмли ширбәт эчкән,
> Бу, мөгаен, бал кортыдыр димә эчтән! *

Сәймән. Коры куаныч син, Түрәй. Ягез, кунаклар, Ходай биргән нигъмәттән авыз итегез. Аштан олы түгелбез.

Азамат. Сезгә нидер ошамады, Ахун Галиевич.

Ахун Галиевич. Әлегә һәммәсе дә әйбәт бара.

Сәймән. Ахун Галиевич, берне җырлап биримме?

Ахун Галиевич. Арабызда олы зат бар икән — җырчы!

---

* М. Кәрим шигыре.

Түрәй. Җырчысы бар, үз җыруы гына юк.

Сәймән. Булган кадәресе үземнеке. (*Беренче җырны утырган җирдән генә җырлый, Нургали гармун тарта.*)

Әлфирак дигән яфырак
Ята суда ялтырап.
Назландырып утырганчы,
Эчеп куйсаң яхшырак.

Фаягөл. Безнең Сәймән абый әйтә ул!

Сәймән. Тагын бер җыр! (*Аягүрә басып, кулларын күкрәккә кушырып җырлый.*)

Өйгә кердем алдым белән,
Өйдән чыктым артым белән.
Фани дөнья шулай бара —
Мәскәүски ярты белән.

Азамат. Әйт шуны! Безнең шулай гади генә. Сез кунакларны башкача сыйлыйсыздыр, Ахун Галиевич?

Түрәй. Аларда һәммәсе дә башкача булырга тиеш. Ахун үзе дә башка кеше. Башкача тегелгән.

Сәймән (*авыз ера*). Аларның песиләре дә бүре тота!

Фаягөл. Нидер болгатасың син, Түрәй абый.

Сәймән. Тагын берне җырлыйм да, аннары сөйләгез рәхәтләнеп.

Азамат. Булгач-булгач, өч булсын!

Сәймән (*пиджагын салып ташлап, бии-бии җырлый*).

Сандугачның балалары
Пи-пи-пи-пи ди икән.
Пи-пи-пи дими алар,
«Выпей-выпей» ди икән.

Түрәй. Ачуланма, Ахун кордаш, кунакны рәнҗетү гадәтем юк. Мәгәр нишлим, җаным турылыкны ярата. Юкка мине чакырткансың. Әйт әле: бу тауга мине күрер өчен генә megendеңме? Юк бит, юк! Бу тәмуг суын эчмәгәнеңне дә беләм. Бүген күз дә йоммыйча тәмләп куйдың. Минем хаккамы әллә болар?

Ахун Галиевич. Килүемнең максаты бер син генә түгел, Түрәй. Мәгәр сине очратуыма шатланам. Бигрәк тә шушы истәлекле тауда күрешүебезгә шат. Әйе, Азамат Сафичка сүзем бар.

Түрәй. Шулай дип котыл. Юк, Сәймән, авызың-борының мимылдатма. Син дә артык монда, мин дә. Фаягөл, синең дә кирәгең бетте!

С э й м ә н. Ярый алайса... Сәйманнең берчакта да артканы юк иде югын. Әйдәле, аппак!

Ф а я г ө л. Куйчы, Сәймән абый!

Сәймән, Фаягөл, Түрәй чыгалар.

А х у н Г а л и е в и ч. Заманында, колхозларны берләштергәндә, синең колхоз безгә керергә тиеш иде.

А з а м а т. Беләм. Авторитетыңа таянып, мең хәйлә табып, син аны читкә тибәреп калдыргансың.

А х у н Г а л и е в и ч. Бөлгенлеккә төшкән хуҗалыкны кушарга йөрәгем җитмәде. Курыктым. Аякка басып, ныгып кына килгән чагыбыз иде. Хаталанганмын мин. Хәзер шул хатаны кичекмәстән төзәтергә кирәк. Безгә колхозларны берләштерәсе иде.

А з а м а т. Кызык фикер белән йөрисең...

А х у н Г а л и е в и ч. Мәсьәләне райкомда кузгатып карадым. Принципта алар каршы түгел. Синең белән килешенсә, идарәләрне көндерәбез дә гомуми җыелыш җыябыз.

А з а м а т. Шулай тиз тотарга дисезме?

А х у н Г а л и е в и ч. Тагын ни көтәргә? Миңа илле тугыз... Син заман кешесе. Килеп эшли башлагач та яратмадым мин сине. Яратмадым бер дә. Аннан кызыксынып күзәтә башладым. Кайда һәм кая барып борынын җимерер икән, дим. Егетлегең җитте, сынатмадың. Хуҗалыкны аякка бастырдың. Кыскасы, миннән хәер-фатиха: ике хуҗалыкның дилбегәсен ныгытып тот.

А з а м а т. Рәхмәт, Ахун Галиевич. (*Пауза.*)

А х у н Г а л и е в и ч. Йөреп киләбезме? Аяклар язылыр. Актай матурлыгын карарга да вакыт җитми. Көннәр оча гына!.. Түрәй кая китте соң?

Чыгалар. Бераздан Азамат Н у р г а л и н е иярттеп керә.

А з а м а т. Председатель шоферы нинди сыйфатка ия булырга тиеш?

Н у р г а л и. Өлгер. Аек. Җитез. Чиста. Уңган.

А з а м а т. Барыннан да бигрәк, телен тыя белергә тиеш шофер!

Н у р г а л и. Ахун Галиевич каршы киләме?

А з а м а т. Мин аңа әйтмәдем әлегә... Әгәр иртән син Түрәйгә лыгырдамаган да булсаң... Әйбәт хәбәр белән йөри кунак! Көтелмәгән яңалык!.. Акыллы, зирәк кеше шул. Ишет, колхозларны берләштерәбез.

Н у р г а л и. Юк сүз лә ул, әллә кайчаннан сөйлиләр.

А з а м а т. Реаль тормыш шуны таләп итә. Шунсыз булмый. Тормыш кичә юк сүз булганны бүген чын итә. Шул акыл картка да килгән, һәм беләсеңме, нинди тәкъдиме бар? Ике колхозны да үз кулыңа ал, ди. Димәк, тиз генә берләшеп алабыз да, Актай мәсьәләсе үзеннән-үзе хәл кылына. Чикләр юк икән, каршылыклар да бетте дигән сүз. Анда инде миңа карышып карагыз! Аңлыйсыңмы син, нинди перспективалар ачыла?! Киңлек кирәк иде миңа, простор!.. Һәм шундый җаваплы минутта Түрәйнең ялгыш ычкындырып куюы бар.

Н у р г а л и. Ахун Галиевичкә мин җиткерәчәкмен.

А з а м а т. Ах, алаймы? Назаны җибәрсәң, мин дә китәм диденңме?

Н у р г а л и. Шулай булачак та.

А з а м а т. Менә мин Назаны җибәрмим... Иртән «өйләнәм» дидемме?.. Син теләсәң кая китә аласың! Миңа мондый шофер кирәкми.

Н у р г а л и. Берләштерелгән колхозга телсез шофер кирәк дисең, алайса? Табалмассың телсезне!

А з а м а т. Бүген бөтенесен хәл кылып бетерәм! Бүген!

Чыга. Н а з а керә.

Н у р г а л и. Бетте, Наза. Моннан китәргә туры килә.

Н а з а. Тагын тарткалаштыңмы?

Н у р г а л и. Китәсе килми иде. Монда син каласың.

Н а з а. Миңа да «Тукай»га китәргә туры килер, бәлки.

Н у р г а л и. Бетте «Тукай».

Н а з а. Шулай ашыгып канатларыңны салындырмачы, Нургали, егет бул!

Н у р г а л и. Колхозлар берләшә. Азамат председатель булып кала.

Н а з а. Ахун абый шул тәкъдимне куәтләп йөриме?

Н у р г а л и. Күрмисеңмени, Азамат тау кәҗәсе күк чаба!

Т ү р ә й керә.

Т ү р ә й. Ягез, балалар, китеп барышым... Ахун белән сөйләшерменме әллә дигән идем, Сәймән эләктереп алды. Сау булыгыз.

Н а з а. Сез киткәч, мондагы хәлләрне кем карар?

Т ү р ә й. Ахун кала. Мине тешләвенә карамагыз, акыллы кеше ул. Сабыр.

Нургали. Акыллы булмый ни!.. Колхозларны кушып председатель итеп Азаматны куярга йөри сезнең акыллыгыз!

Түрәй. Син дә булмастайны майлап йөрисең, Нургали!

Чыгалар. Динә белән Фаягөл керә.

Динә. Ырый-ырый!

Фаягөл. Эчең тулы зәһәр синең. Тышка бөркелеп тора.

Динә. Азамат абый сиңа төсме? Чалыш-болыш атлауларың... Тфү! «Хатыным» дип кеше арасына алып чыга аламы ул сине?!

Фаягөл. Бирмим! Үлгәнче яратам! Минеке!

Динә. Ул мине ярата, мин аны! Миңа!

Азамат кереп көлеп карап тора.

Азамат. Җитәрегез сезгә, кеше көлдермәгез.

Фаягөл. Азамат абый!

Динә. Азамат абый!

Азамат. Ваклана торган минутмы хәзер? Шау-шусыз гына моннан таралыгыз. Түрәйне алып китегез. Сөртегез күз яшьләрегезне!

Ахун Галиевич, Сәймән, Түрәй, Нургали, Наза керәләр.

Сәймән. Җәмәгать, бу нинди сансызлык?

Азамат. Сәймән агай, Фаягөл! Сый-хөрмәтегезгә рәхмәт. Яхшылыкны онытмам.

Сәймән. Табын әзер, ашъяулык сыгылып тора. Мондый халыкны күргән юк иде. Ашны шулай кадерсезлиләрме? Ай-яй, ярамый.

Азамат (*шат*). Массаларның соравын искә алып, бераз гына утырып алабызмы әллә?

Ахун Галиевич. Әйбәт! Массаларга колак салмыйча булмый.

Азамат. Утырдык, Сәймән абый! Тик тиз тот!..

Ахун Галиевич. Мин Азамат Сафичка яучы булып килдем бит әле.

Фаягөл. Яучы?

Ахун Галиевич. Курыкма, Фаягөл.

Фаягөл. Башкалар курыксын!

Ахун Галиевич. Заманында сезнең белән туганлашудан баш тарткан идек. Хаталанганбыз. Колхозлар-

ны бер итәргә вакыт җитте. Терәлеп торган күршеләр бит без!

Ф а я г ө л (*балкып*). Азамат абый председатель?

А х у н  Г а л и е в и ч. Мин шыгырдавык агач... Илле тугыз бит!.. Азамат Сафич заман кешесе. Ул калачак.

Н у р г а л и. Нигә дәшмисез, Түрәй абый?

Н а з а. Чыннан да.

Т ү р ә й. Кемгә дәшәргә белмичә аптырап калдым. Якларны аермый башладым... Буталды. Китик моннан, Наза.

Н а з а. Бая ук китәргә булган.

А з а м а т. Кая, кая? Бәйрәмне бозарга рөхсәт юк. Түребездә олы кунак.

Н а з а. Нәрсәгә кирәк мин сезгә? Аңламыйм.

А з а м а т. Тормыш ул, Наза. Аңларга тырыш.

Т ү р ә й. Аңлап ни файда? Уртак сүзнең кадере калмады.

А з а м а т. Сүзнең кадере калмаса, җырның кадере беткәне юк.

Н а з а. Нинди җыр ди хәзер?..

А з а м а т. Кунак хөрмәтенә бер генә җыр, Наза! Үтенәм!

С ә й м ә н. Чыпчык күк чырылдаса да, ялындырган була.

Ф а я г ө л. Бик, бик.

А х у н  Г а л и е в и ч. Тагын бер җырчымы? Мул яшисез!

Т ү р ә й. Җырчылар да бертөсле генә түгел! Бусы башка калыпка сугылган!

А з а м а т. Үтенәм, Наза.

Н а з а. Кайсысын җырлыйм икән?

А х у н  Г а л и е в и ч. Йөрәктән чыкканын җырла, сеңлем.

Н а з а (*җырлый*).

Җилгә тапшырдым серемне,
Таң җиленә.
Барып җитәр дип уйладым
Күңелеңә.
Уянмады җаның синең,
Уйланмады.
Офыкларым алсу төскә буялмады.
Кире кайтарды таң җиле
Бар серләрем!
Яраланды яшь йөрәгем,
Син белмәдең!

Азамат. Кунак нигә дәшми?

Сәймән. Чыпчык чырылдавына кемнең исе китсен?

Нургали. Абзый дим, җитте сиңа!

Ахун Галиевич. Ачыгыз шампан шешәләрен! Бокалларны мөлдерәмә тутырыгыз! Тост әйтергә телим. Тостны, сеңлем, синең хөрмәткә әйтәм! Әйтегезче, дуслар, тургайларны басу-кырларга кем бүлеп тарата?

Фаягөл. Бездә андый учет алып барылмый.

Ахун Галиевич. Көлкегә алмагыз, соравым җитди... Әйе, төрле-төрле табыннарда төрле кешеләр белән утырдаш булырга, ризык бүлешергә туры килә. Мәгънәлесе була табынның, мәгънәсезе — төрлесе очрый. Кайвакытта, бу табын кешеләрен ни берләштерә соң? Нигә бергә җыйналганнар дип аптырап бетәсең. Бүген дә шундый хәл кичереп утыра идем!.. Шунда җыры, моңы белән берәү килеп чыга да таркау табынны берләштерә! Көнебезгә нур бирә. Үзебезнең бер ана балалары, бер җир уллары икәнебезне хәтергә төшерә. Олымы, кечеме, без бит шушы җир балалары. Шушы җир кадерен саклап яшибез. Бүгенге мәҗлесебез дә тургайсыз түгел икән! Шөкер! Мәңге яшә, тургай, мәңге! Бер кырыбыз да тургайсыз калмасын!

Сәймән. Рәхәтләнеп эчәм, тик бу чыпчык өчен түгел.

Ахун Галиевич. Сәймән, синең тургай тавышын ишеткәнең бармы?

Сәймән. Элек тә, хәзер дә ишеткәнем юк.

Ахун Галиевич. Йөрәгеңә май, колагыңа мүк үскән синең! Тургай тавышы — туган җир авазы ул!

Азамат. Ишетмәве дә ихтимал. Бәлки, безнең колаклар өчен тургай тавышы яттыр хәзер? Алып карыйк. Безнең басулар аша ике җирдән югары вольтлы электр чыбыклары үтә — ЛЭПлар. Өч төштән нефть үткәргече узган. Европа белән Азияне тоташтыра.

Ахун Галиевич. Горурлыгыбыз.

Азамат. Килешәм. Колач иңләмәслек газ, су торбалары уза. Тормышыбызның һәр көне, һәр кешенең язмышы шуларга бәйләнгән. Кырларыбызда бишәр йөз ат көчле «Кировец»лар үкерә. КРАЗлар, БелАЗлар чаба. Мактанычыбыз — сылу КамАЗлар җилдерә. Кем ишетсен ди хәзер кош тавышын?

Түрәй. Юк хәзер тургайлар.

Ахун Галиевич. Ничек юк?

Наза. Үлеп беттеләр микән?

Түрәй. Икенче җәй инде бер генә тургай да юк. Килмәделәр. Тургайлар безне ташлап китте.

Ахун Галиевич. Туктагыз әле!

Сәймән. Әкият! Кем үтерсен аларны? Ни өчен? Көртлек дисәң икән, яисә кыр үрдәге. Во!..

Түрәй. Нигә китлар ярга ташланып үлә? Кешеләр аларны ярдан ачык океанга чыгарып карыйлар, китлар яңадан яр буена кайталар һәм көтү-көтү ярга ташланалар! Сәбәбен кем белә? Океаннар пычрангач, зирәк һәм көчле ияләре шулай әҗәл эзли... Җиргә тургай күзе белән карар идем мин. Махсус, тын гына күккә менеп. Балтыйк буе халыклары кырлары үз төсмерен югалтмасын өчен анда-санда ялгыз агачлар утырта башлаганнар. Мөмкин булган урыннарда межалар калдыралар. Ялгыз агачларны кисеп яктык, куакларны төпләдек, межалар күптән онытылды. Ә тургайлар нишләсен? Кайда оя типсен алар? Тургайлардан рөхсәт алып үзгәрттекме без мохитны?! Уйласак, җир аларныкы да бит! Чыпчыклар һәм тараканнар белән генә — яшәү рәхәт булмас!.. Ярга көтү-көтү китлар ташланганда күрәбез. Алар дәү, әнә нинди! Безнең көмеш кыңгырауларыбыз — бүз тургайлар, бәлки, җиргә яңгыр кебек шыбырдап коелгандыр? Бу гарасатта алар тавышын кем ишетсен? Нигә артыгын сөйләп торырга? Тургай башы түгел, Актай башы кыелырга тора монда. Рәхмәт. Бу табынга әйләнеп килер дип көтмә, Ахун кордаш.

Ахун Галиевич. Сөйләшү бер генә яклы булмасын инде, Түрәй, безне дә тыңлап бетер.

Түрәй. Нигә бер яклы? Син сүзеңне ап-ачык әйттең. Их, син, фронтовик-солдат, эстафета тапшырырлык лаеклы кеше тапкансың! Рәхмәт! Ничә еллар намуслы хезмәт иттең дә дәвамчың итеп Актайны җимерүчене сайладың!

Азамат. Нигә мине шулкадәр яратмыйсың, Түрәй абый?

Түрәй. Сәймән ярата, шуңа канәгать ич син!

Ахун Галиевич. Тыңлап бетер инде, зинһар! Тынычлан!

Түрәй. Мәктәптән нигә киттең дип сорадың. Бел: менә шушы кеше аркасында киттем.

Азамат. Тагын нинди гаеп өяргә мөмкин, өй әйдә!

Наза. Нигә куркып киттең, Азамат абый?

Түрәй. Элек безнең авылда икешәр беренче класс була торган иде. Шушы Актайга алтмышар бала алып менә идем. Дөньяның киң, матур икәнлеген карарга... Хәзер класс бергә калды. Быел беренче класска өч бала барачак. Өч! Үсеп җиткәч ул өченең әле ничәсе авылда

калыр... Димәк, монда кала торган һәр кешенең мәгълүматлы, киң карашлы, туган җирен сөйгән кеше булуы мөһим!.. Чөнки авылның бай тарихы, йолалары, гореф-гадәтләре бар. Ниһаять, туган телебезнең сакчысы ул авыл... Буп-буш классларны күреп, карт укытучының йөрәге әрнемиме? Җан үксеп җылый!.. Шундый көннәрнең берсендә мәктәпкә Азамат килеп керде.

Азамат. Түрәй абый, бу безнең үзара сөйләшкән сүз генә!

Түрәй. Хәлебезне сорашты. Мин аны яхшылык белән килгән дип торам. Укучыларны яхшы укырга өндәгәнемне тыңлап торды да тотынды мине сүгәргә!

Ахун Галиевич. Нигә?

Түрәй. Кемгә кирәк синең «бишле»гә укучыларың, ди! Алары — мәктәптән соң шәһәргә кача аның, «өчле»гә укучылар минеке, ди. «Өчле»гә укыганнар авылда кала, ди. Әйтмәдеңме?

Азамат. Дөрес түгелме әллә?!

Түрәй. Ә син яхшы укучылар да авылда кала торган итеп тормыш кор.

Азамат. Шуның өчен тырышам. Шуның өчен тауны җимерәм.

Түрәй. Киттем мәктәптән, авылны наданнар кулына тапшырасым килми... Тургай тавышын ишетми торган саңгырауларга, тау башын кыярга әзер сукырларга...

Ахун Галиевич. Кая болай? Мин сүземне әйтеп бетермәдем.

Түрәй. Әйтмәс борын барын да аңладым! Ике председатель зарыгып кавышкансыз икән, кинәнегез.

Чыга. Пауза.

Наза. Түрәй абый!

Нургали. Хәзер дәшмә. Дәшмә.

Ахун Галиевич. Туктамады. Туктамас та. Кимсеттек без аны. Саксыз кыландык!

Азамат. Балалар белән эвәрә килеп, сабый акылы керә башлаган.

Сәймән. Шулай, шулай.

Наза. Бәлки, Түрәй абыйның кайбер карашлары бүгенге көн өчен искерәктер, яттыр, әмма мин аның укучысы булуыма горурланам. Тургайсыз кыр буш булган кебек, андый кешеләрсез тормыш соры, ямьсез булыр иде.

Азамат. Баш ярылып күз чыкмаган. Түрәй абыйның кәҗәләнүе бер бүген генәме?

Ахун Галиевич. Алай кискен сөйләшмә. Аны да аңларга кирәк!

Азамат. Нигә ул мине бер дә аңларга тырышмый?!

Наза. Ул сезне бик яхшы аңлады. Менә сез андый җаннарны аңламый башласагыз фаҗига булыр! Максатыгызга ирешү юлында сезгә Сәймән абый кебекләр күбрәк кирәктер...

Сәймән. Әй, кара әле!

Наза. Аларга таянырсыз... Әмма күңел өчен... Андый кешеләр сездән гел читләшерләр һәм сез япа-ялгыз калгач кына акылга килерсез.

Ахун Галиевич. Мин бу кызны үз яныма алыр идем!

Нургали. Гариза бирде. Китә. Без барыбыз да китәбез.

Азамат. Кем ул без?

Нургали. Түрәй абыйның шәкертләре.

Динә. Баш күтәрерлек ни булды соң?

Фаягөл. Йөрмәле кысылып, йон төргәге!

Азамат. Китегез. Барыгыз да китегез. Юлыгызга ак җәймә!.. Дөнья сезгә терәлеп калмаган. Тауны сездән башка да җимерәчәкмен!

Ахун Галиевич. Алай... Җимерәм, дисең инде. Ансат кына, көлә-көлә мең-миллион ел торган тауны ишеп ыргытасың.

Азамат. Кирәк, Ахун Галиевич.

Ахун Галиевич. Син Актайны беләсеңме? Бармы тирә-юньдә аның ише? Туган төбәгебезнең матурлык сакчысы шушы тау. Кырык бердә шушы тау итәгеннән йөз илле кеше чыгып киттек. Шулардан йөз утыз икесе кайтмады. Утызынчы елларда тау итәгендә межада кулаклар Түрәйнең бертуган абыйсын тураклап ташладылар. Пугач явы килгәндә монда канлы бәрелешләр булып узган... Шул тауны син керфек селкетмичә дә җимереп ташлыйсың!

Нургали. Актай безнең мактанычыбыз.

Сәймән. Шулай, шулай. Катнаш!

Азамат. Коры мактанычтан кемгә файда?

Ахун Галиевич. Үткәннәре юкның — киләчәге дә юк. Ничә еллар тауны Сәймән әрсездән кычкыртып талатасың, менә кайда икән аның сере!

Сәймән. Мин дә җимерүгә каршы! Каршы!

Ахун Галиевич. Дусың кем, дип сора кешедән... Усаллыгың, явызлыгың миңа күптән мәгълүм, Сәймән.

Председатель шул кешене нигә табындаш иткән дисәм, алар ике чабата бер кием булып чыкты.

Азамат. Мин хаклы, Ахун Галиевич. Дөреслек минем якта.

Ахун Галиевич. Күп колхозларга, шул җөмләдән безгә дә байтак зыян салдың. Түздек. Хуҗалыклы булуың өчен түздек. Болары яшьлек дуамаллыгы дисәм, усаллык синең сәясәтең, иманың икән!

Азамат. Ахун Галиевич, тыңла әле, башында ярты тиенлек акылы калмаган карт-коры сүзенә карап тормыш агымына аркылы ятып буламы?

Ахун Галиевич. Иртә ышанганмын мин сиңа. Гамәлеңә чын күз белән карамаганмын. Килгәннән бирле бүген сине күзәтәм, гадәтләреңне сыныйм, ә син тәмам азынып киттең! Түрәй фронтовик солдат. Шушы җир өчен газиз канын түккән кеше. Аның бу җирләргә хакы синекеннән йөз кат күбрәк. Хәзер үк Түрәйне куып җит! Гафу үтен! Бер минут торма. Югыйсә һәммәбез дә моннан сынык күңел белән китәчәк. Ярамый болай, һич ярамый! Туган җиребезнең һәр адымын кадерләп тотарга өйрәнмәсәк, нинди хуҗалар ди без? Бар, куып җит. Ашык, Азамат.

Наза. Бар, Азамат абый.

Нургали. Рульгә үзең утырасыңмы?

Ахун Галиевич. Тукта. Мин дә барам. Мине дә аңламады Түрәй... Ямьсез яшисең икән, Азамат!

Азамат, Ахун Галиевич чыгалар.

Динә. Димәк, колхозлар берләшә...

Фаягөл. Икесенә дә председатель булып Азамат абый кала, китми!

Нургали. Бытылдамагыз әле!

Сәймән. Ике ут арасына каптым! Әгәр Азамат калса... Да-а, үчегәчәк! Каян телемә килде...

Нургали. Шауламагыз әле!

Сәймән. Әкә-мәт!

Азамат керә.

Наза. Нигә борылдыгыз? Ни булды?

Нургали. Түрәй абый килмәдеме?

Сәймән. Ахун кайда?

Азамат. Күрәсез... Түрәй абый юк...

Сәймән. Ә-ә, картлач тагын берәр нәрсә кыландыргандыр.

А з а м а т. Туктал! Сөйләве кыен, ышануы тагын да авыррак.

Н а з а. Ни булды соң?

А з а м а т. Түрәй абыйның хәле мөшкел.

Ф а я г ө л. Ай Аллам.

А з а м а т. Таудан җай гына төшеп бара идек. Сак кына. Юлдан түгел, ермак араларыннан барабыз. Сукмак кына. Бәлки, ул очраклы гына тап булгандыр... Ахун Галиевич: «Ялгыш килеп чыкты»,— ди. Ялгыш булмады ул! Ялгыш килеп чыкмады!

С ә й м ә н. Типте бия тәртәгә... Кәҗә койды кабыкка!

А з а м а т. Исән, әмма яраланды. Ахун Галиевич аны больницага алып китте.

Н а з а. Нигә сез монда? Нигә бармадыгыз?!

А з а м а т. Ахун Галиевич калырга кушты.

Ф а я г ө л. Кеше таптаткан өчен сине төрмәгә утырталармы?

С ә й м ә н. Медаль такмыйлар!

Д и н ә. Абзый, председательлектән алалармы?

С ә й м ә н. Болай булгач, хана. Бетте егет.

Н у р г а л и. Кирәксезне сайрыйсыз!

Н а з а. Түрәй абыйның хәле ничек? Нигә мин дә аның белән китмәдем икән бая?!

Ф а я г ө л. Соңгы өмет тә киселде. Харап булдым!

Д и н ә. Нургали! Ни катып торасың?

Н у р г а л и. Ни бар?

Д и н ә. Җаным бул! Тиз үк станцага озат! Китәргә бик вакыт. Болай да ярты елым әрәмгә киткән! Тизрәк!

Н у р г а л и. Машина юк. Безгә кирәк. Түрәй абый янына барырга.

Н а з а. Каным беренче группа. Аңа кан кирәк булыр!

Н у р г а л и. Киттек.

А з а м а т. Наза, калдырма ялгызымны! Гафу итә алсаң, кичер.

Нургали, Сәймән, Динә чыгалар. Фаягөл дә иярә.

Н а з а. Юк, Азамат абый. Гафу итә алган да булыр идем, мәхәббәт хакына күңел ниләр генә эшләми. Әмма туган җир, ил, табигать синдәйләрне берчакта да онытмас. Алар гафу итмәгәндә ничек сине кичерә алыйм? Кеше дә табигать баласы. Дөньяда иң зур җинаятьләрнең берсе — кеше күңелен суыту. Сез бит кешеләрне диңгез ярындагы шома ташларга гына исәплисез.

А з а м а т. Ахун Галиевич: «Түрәй ялгыш, күрмичә сукмакка чыкты»,— ди. Мөгаен, шулайдыр да... Урын

аулак, машина тавышсыз гына төшеп бара. Барыбер мин яраладым аны, мин!..

Машина гудогы.

Н а з а. Чакыралар. Безне Түрәй абый көтәдер. Ә сезгә... аның янына барырга рөхсәт юк. Шуның өчен ияртмәгән сезне Ахун Галиевич! Юк рөхсәт, Азамат абый... һәм бу сезнең кешелексезлеккә иң гадел хөкем.

А з а м а т. Наза! Мин бөтенләй башка кеше хәзер.

Н а з а. Сезнең аркада мин дә бөтенләй башка. Мәхәббәтнең кодрәтенә, көченә ышанмый башладым. Нишләттегез мине?! Бер Түрәй абыйны гына түгел, бик күпләрне яраладыгыз бүген!

Чыга. Д и н ә керә.

А з а м а т. Наза!

Д и н ә. Борылып та карамады.

А з а м а т. Нигә китмәдең? Ашыга идең бит.

Д и н ә. Синең кебек үк мин дә аларга юлдаш түгел. Абзый иярде әнә. Җүләр!.. Әйдә, Азамат абый, Казанга. Урыныңнан очыралар сине!

А з а м а т. Юк!

Д и н ә. Дөньяның тагын бер җүләре артты. Кал, сарык, абзый белән чөгендер игәрсең! (*Чыга.*)

А з а м а т. Мин үтердем аны! Мин!!!

П ә р д ә.

*1975—1978*
*Казан — Ялта — Мәскәү*

# Әгәр бик сагынсаң...

*Драма ике кисәктә*
*(«Әгәр бик сагынсаң...» дилогиясенең 1 нче пьесасы)*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Фәүзия.
Әсфан.
Мәдәния.
Гайсә.
Чал.

Вакыйга безнең көннәрдә, XX гасырның 70 нче елларында бара.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Әле пәрдә ачылмаган. Талгын гына музыка яңгырый. Катнашучылар берәм-берәм сәхнәгә чыгалар. Иң алдан, авыр гына атлап, таякка таянып Гайсә керә.

Гайсә. Юк, юк, кешеләр ни генә сөйләсәләр дә, ышанмагыз. Бу пьеса минем турыда түгел. Кызганычка каршы, миңа багышланмаган. Кызганычка каршы дим, чөнки минем тормыштан да барыбыз өчен дә гыйбрәтле хәлләр табып булыр иде. Миңа быел алтмыш җиде тулды. Бер караганда күп тә түгел, әмма баштан байтак хәлләр кичте. Күпне күрдек!

Мәдәния (*кереп*). Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм! Синең турыда бу пьеса!

Гайсә. Синең турыда түгел микән, карчык?

Мәдәния. Җиде бала үстереп, өй кысасыннан бер генә тапкыр да чыга алмаган, гомере сыер имчәге тартып, бәрәңге әрчеп, камыр басып, башак болгатып үткәргән авыл карчыгы турында нинди пьеса булсын?.. Язмаганны, раббым Алла.

Фәүзия (*алгарак чыгып*). Бу пьеса минем турыда.

Әсфан. Дөресрәге, безнең турыда. Без Фәүзия белән гомеребездә бер генә күрешеп алдык әле...

Ф ә ү з и я. Нишләп бер генә дисең, Әсфан?

Ә с ф а н. Мин хәзер ялганлый алмыйм. Ялган сөйләргә ярамый миңа. Әлегә бер генә күрештек ич, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Аның каравы нихәтле хатлар алыштык! Хатларыңның барысын да кадерләп саклый идем мин.

Ә с ф а н. Бүген, шушы якты залга җыелган халык безнең хатларны күрешү дип санармы соң?

Ч а л. Санар. Хатларны да күрешү дип санар! Чөнки бөтен бәла шул хатлардан башланды. Санамасалар... санатырбыз!

М ә д ә н и я. Бәла?

Г а й с ә. Бә-ла?!!

Ф ә ү з и я. Ни сөйли ул, Әсфан?

Ч а л. Бөтен бәхетсезлеккә шул хатлар гына сәбәп булды!

Ф ә ү з и я. Нинди бәла? Нинди бәхетсезлек? Әсфан, син мине ярата идең бит? Кем мәхәббәтне бәхетсезлек дип атый ала? Кешене тормышка кайтару бәхетсезлек була димени?!

М ә д ә н и я. Ни бәрабәренә кайтардың бит...

Г а й с ә. Безнең кулдан килмәгәнне эшләдең!

М ә д ә н и я. Каның түктең!

Ә с ф а н. Дөньяда иң кодрәтле хис икән ул мәхәббәт!

Ч а л. Бу пьеса минем турыда да... Әгәр катнашучылар арасында бөтенләй булмасам, ярыйсы иде дә... Нишлисең, тормышта үзенчә генә яшәп булмый? Мәхәббәт дошманнары турында ишеткәнегез бармы-юкмы? Шуларның берсе — мәхәббәт дошманы — сезнең каршыгызда.

Ф ә ү з и я. Минем гомерем моңлы бер җыр, дигән иде шагыйрь. Гомер кыска булса да, сөю мәңгелек. (*Башкалар, бер-бер артлы чыгып китәләр, сәхнә алдында Фәүзия ялгызы гына кала.*) Мин нәкъ әнә шул елны Казанда педагогия институтын тәмамлап, Чибәркүлгә эшкә кайттым. Тарих укытырга. Үз авылыма түгел, бөтенләй чит районга җибәргәч, каушабрак кайткан идем. Ямьле күл буена урнашкан авылны бер күрүдә ошаттым. Фатирга бик әйбәт кешеләргә урнаштым. Әби белән бабай, мин, дүртенчебез песи, тату гына, сабыр гына яши башладык. Беркөнне эштән мин бераз соңарып кайттым. Бүгенгедәй хәтеремдә, октябрь ае иде. Үземә калса, соңлап кайтуымның җитди генә сәбәбе дә бар иде...

Ф ә ү з и я чыга. Пәрдә ачыла. Җыйнак кына авыл өе. Стенадагы рамнарда төрле зурлыктагы фотолар. Мәдәния карчык ялгызы хат укый, күз яшен сөртеп-сөртеп ала. Фәүзия керүен ишетеп хатын яшерә.

Ф ә ү з и я. Җитешеп мин дә кайттым, Мәдәния әби.

М ә д ә н и я. Озак юандың, балам, көттердең.

Ф ә ү з и я. Әллә берәр кирәгем бар идеме, Мәдәния әби?

М ә д ә н и я. Кирәгең дип... бабаң да өйдә юк, песи дә иртәдән биләмдә. Син кайтмыйсың. Көн дә шыксыз.

Ф ә ү з и я. Суга барып кайтыйммы әллә?

М ә д ә н и я. Су ташыдым инде.

Ф ә ү з и я. Идән юып чыгарыйммы?

М ә д ә н и я. Әлерәк кенә сөртеп алган идем.

Ф ә ү з и я. Миңа эш тә калдырмагансың, Мәдәния әби. Идән юма дип ничә мәртәбә әйттем? Юасың да, тәнем сызлый дип, уфылдап ятасың.

М ә д ә н и я. Моннан болай уфылдамам.

Ф ә ү з и я. Юма! Үзем эшләрмен!

М ә д ә н и я. Йә, болай да җитешә алмыйсың, балам. Беркөнне дә үз вакытында ашый алмыйсың.

Ф ә ү з и я. Бүген мин берәүләрдә булдым. Бишенчедә укучы малайларын тыңлата алмыйм. Аның әти-әниләре дә шундый кешедер дип кызып барсам, әнисе шулкадәрле дә йомшак күңелле, тәмле телле апа икән, әллә ниләр сөйләшеп бетердек. Кабартма белән чәй эчермичә җибәрмәде үземне. Шундый ягымлы, уңган ата-анадан нигә киребеткән, үҗәт, чамасыз шук балалар туа икән?

М ә д ә н и я. Нишләмәк кирәк, туганны кире Ходайга тапшырып булмый. Хак Тәгалә тәүфыйгыннан аермасын. Ала да туа аттан, кола да туа. Ходайның кодрәте киң.

Ф ә ү з и я. Ипкә китерми калмыйм мин ул ташбашны. Барыбер җиңәчәкмен. Бөтен мәктәпне дер селкетеп тора шул бәләкәй юньсез!

М ә д ә н и я. Гөлҗамал төпчеген әйтәсең инде, алайса! Төпчекне!

Ф ә ү з и я. Шул инде, шул. Мәктәптә бер. Елгырдыр үзе, ут борчасы. Класска кереп чыккан укытучылар зар җылый. Ә мин аларның класс җитәкчесе. Директордан да куркып тормый!

М ә д ә н и я. Беләм. Шуңа әйтәм, балам, ай-һай, дим. Сиңа кадәр килгән мөгаллим дә шул малай аркасында гына авылыбызны ташлап китте, диделәр. Егет кеше иде әле! Буйга да, ай-һай, дим. Шул егет беренче тапкырын дәрескә керә. Исәнләшеп, әйбәтләп урындыкка утырыйм дигәндә генә артка тәкмәрләп барып төшә, менә сиңа әйтәм. Бөтен класс ярыла: ха-ха-ха да хи-хи-хи! Теге ипсез бала урындык аягына кармак җебе бәйләгән дә укытучысы утырам дигәндә генә тартып аударган.

Ф ә ү з и я. Миңа андый этлек күрсәткәне юк. Кылана башласа да кача торганнардан түгел мин. Барыбер кемдер кеше итәргә тиештер ич аны?

Мәдәния (*Фәүзиягә сынап карап тора*). Бер абынганны инде, Ходаем... (*Шикләнеп туктый.*) Нишләмәк кирәк, адәм уллары төрле-төрле шул.

Фәүзия. Төрле булсыннар! Яхшы булып та төрлечә яшәргә мөмкин!

Мәдәния. Ныгытып кына, аулак тыкрыкта, кеше күрмәгәндә колагын борып-борып ал!

Фәүзия. Юк, алай итәргә һич тә ярамый, Мәдәния әби. Яхшылык белән эзгә кертергә кирәк аны!

Мәдәния. Әнә, бабаң әйтә, яхшылык белән явызны ипкә китереп булмый, ди. Муртайган карама бүкәне ни тырышсаң да ярылмый, ди, аны шул чүплек башына чыгарып ыргытып кына котыласың, ди.

Фәүзия. Бу юлы Гайса бабай ялгыша.

Мәдәния (*өмет белән*). Ялгыша дисең, алайса? Менә син, агай, самавыр җырлатып, төче коймак пешереп көтеп торган булам, син ныгытып кайткансың икән.

Фәүзия. Аз булса да эш караштырып, өйдә тән язармын дип кайткан идем, бер эш тә калдырмагансың икән, Мәдәния әби.

Көлешәләр.

Мәдәния. Инде бик булышыйм дисәң, сиңа да бер кулай эш табарбыз... Бер йомышым бар иде барын...

Фәүзия. Кулдан килә торган булса, хәзер үтибез аны.

Мәдәния. Йомыш дип, кечтек кенә, кош теле генә хат кисәге язып бирмәссеңме дигән идем. Вакытың юктыр инде.

Фәүзия. Хат? Алайса, нигә кечтек кенә ул? Күп итеп, иркенләп язабыз аны. Мин хат алырга да, язарга да бик яратам. Бишенчедә укыганда Артекта булдым, Кырымда, пионер лагеренда. Колхозга булышкан өчен җибәрделәр. Шунда танышкан дусларым белән әлегәчә хат алышам. Хат ул — күңел илчесе, ышанычлы арадашчы. Тормышның кадерле бер өлеше. Ерак араларны теләгән кай вакытта якын итә торган кадерле әманәт бит ул хат.

Мәдәния. Бик язар идең дә, озынга сузарга сүзе юк бит аның, күп сүз кирәкми.

Фәүзия. Тәмләп укырлык, кат-кат яратып уйланырлык итеп язарга кирәк аны хатны, Мәдәния әби.

Мәдәния (*каударланып*). Озак мыштырдасак йә бабаң кайтып керер.

Фәүзия. Ур-ра! Гайсә бабайдан качырып күрше картына гыйшык хаты язабыз! Шәп!

Мәдәния. Гыйшык хатларын язалмадым. Терәлеп торган күршегә кияүгә чыктым. Иң бәхетсез кыз шул

булыр — күршесенә кияүгә чыгар. Ат җигеп тә мәшәкатьләнмәде, ике кулыма ике төенчек тоттым да ябышып чыктым. Әйбәт яшәдек яшәвен...

Ф ә ү з и я. Шул чакларны иркенләбрәк сөйлә әле, Мәдәния әби. Үлеп яратам. Өлкән кешеләр тере тарих бит алар! Аларда гыйбрәтләр ни чаклы!

М ә д ә н и я. Кая инде, онытылып беткәннәрне нигә кузгатырга? Хатны сызгалап өлгерик дим.

Ф ә ү з и я (*кәгазь, каләм алып*). Мин әзер. Кемгә, ни дип язабыз? Тизрәк, Мәдәния әби, бабай кайтып кереп сизмәсен эшеңне, коярдыр тешеңне! Миңа да эләгер.

М ә д ә н и я. Рәхәт итеп көләсең дә инде, балам. Рәхәт итеп көлә алу өчен дә җаныңның якты булуы кирәк. Көлгән чакта адәмнең җаны чыраенда чагыла.

Ф ә ү з и я. Рәхәт итеп яшим дә ич мин. Хат башына шулай дип куйыйммы? «Рәхәт яшибез!» дип язсам, кызык булыр!

М ә д ә н и я. Чү, чү, балам. Кызык хат түгел шул, түгел.

Ф ә ү з и я. Ә теге юньсез малайга килсәк, барыбер тиешле ызанга кертәм мин аны!

М ә д ә н и я (*каушап*). Нинди малайны?

Ф ә ү з и я. Кайткач та сөйләдем бит.

М ә д ә н и я. Фу, аны әйтүең икән. Ярый ди, бисмилләһи... Шулай. Гади генә итеп башлыйкчы, кызым. «Улым, Әсфан!» диген...

Ф ә ү з и я (*яза*). Әсфан атлы улыгыз да бар икән. Нигә моңарчы аны бер дә телгә алмадыгыз?

М ә д ә н и я. Алганбыздыр, онытткансың гына! Менә кәртечкәсе.

Ф ә ү з и я. Бу егет рәсемен күптән күреп йөрим, берәр артистмы дисәм... Нәрсә языйк соң? Кайда ул Әсфан?

М ә д ә н и я. Еракта. Әллә кайда. Бик тә еракта.

Ф ә ү з и я. Чик саклый икән.

М ә д ә н и я. Чик дип... Саклый инде! Саклыйлар!.. Бик ныгытып саклыйлар. Син, Фәүзия кызым, бу юлы артыгын төпченеп, берүк, болай да чәбәләнгән акылымны чуалтма. Ни яздырыйм дигән идем? Ай Аллам. Юк, Әсфанны армиягә алмадылар. Без картларны тәрбияләргә дип калдырдылар.

Ф ә ү з и я. Үз теләге белән каядыр китеп бардымыни?

М ә д ә н и я. Башка чакта бер дә болай төпченми торган идең. Актык зиһенемне тараттың. Без картларның ни...

Ф ә ү з и я. Язам, язам.

М ә д ә н и я. Еракта төзелештә эшли. Күрәчәкне күрми, гүргә иңеп булмый, дигәннәр борынгылар.

Фәүзия. Ишле балалы семьяларны яратам мин.

Мәдәния. Җидене үстердек. Заманында гөлдәй идек тә бит. Гомерем буе колхозда бозау бактым, медальләрем ничәү. Тик менә өч ел инде тазалыкка туймыйм.

Фәүзия. Әсфан киткәнгә күптәнме?

Мәдәния. Күптән дип, узган айда өч елы тулды. Өч елы.

Фәүзия. Договорны озаккарак төзегән.

Мәдәния. Хәзер, хәзер. Яз әйдә. Барыбыздан да сәлам, диген. Әти-әниең бик сихәт, диген.

Фәүзия. Чирләштереп торуыңны да кыстырыйммы?

Мәдәния. Берүк ул турыда ләм-мим. Бик таза, гел сихәт, җир җимертеп йөри, диген. (*Иңеннән шәле төшеп китә, иелеп алганда ыңгыраша.*) Ай, билем.

Фәүзия. Авырып торуыңны белә, бер кайтып килер. Күрәм ич, сагынасыз.

Мәдәния. Кайтулар бик тиз эләкмәс шул.

Фәүзия. Сезнең дә каты күңелле улыгыз бар икән.

Мәдәния. Яз син, кызым, яз. Ел килешләре әйбәт булды, диген. Колхоз уңышны түкми-чәчми җыеп бетерде. Бәрәңгене алдылар, диген. (*Бүленеп.*) Яңгыр быел бик аяктан ега! Бәрәңге байтак диләр әле. Ярый ла, дөнья сүзен куйыйк. Синең машинада һаман Әптери малае йөри, диген. Анысын язсак авыр булырмы әллә?.. Фатирга укытучы кыз керттек, диген.

Фәүзия. Минем хакта нигә язабыз? Кирәкмәс иде.

Мәдәния. Бездә тормаска уйладыңмы? Яратмадыңмы? Безнең турыда яман сүз ишетеп кайттыңмы? Гөлҗамал үзенекеләрне белмәс, кеше чәйнәкләп утыргандыр әле. И Ходаем... Бабаңа рәнҗисеңме әллә? Тора да чыгып югала. Беркем белән рәтләп сөйләшеп тормый. Ык та мык! Кәефең шуңа кырылгандыр, мөгаен.

Фәүзия. Алай түгел, Мәдәния әби. Үз балагыздай каршыладыгыз. Сезнең исемгә кушып яман сүзне кем әйтсен?

Мәдәния (*җиңел сулап*). Шушы арада посылка салырбыз, дип куй. Тегесен салганга өч атна узды, алуыңны хәбәр итмәдең, диген.

Фәүзия. Төньякта яшелчә-җимеш һаман җитешмидер шул.

Мәдәния. Әйбәт эшлә, башлыкларыңнан сүз килерлек булмасын, диген. Тәртипле йөр, алама бәндәләргә ияреп күрмә дип бик нык ытып яз! Ахырдан теге тынышыңны, өндәвеңне әйтәм, чукмар хәтле итеп куй. Күзенә керәм дип торсын! Яман юлдаш ашый егет башын. Хәер, боларын нигә катлап торырга? Ни файда?

Ф ә ү з и я. Гаҗәбрәк булды бу хат минем өчен. Конверт үземдә дә бар. Адресы кайда?

М ә д ә н и я. Әдрисе? Каярак кыстырдым икән аны-сын? Ай Аллам, кирәкмәстә җитез бабаң кайтты. Бир тизрәк язганыңны! Берүк авыз ачып аңа бу турыда сүз ычкындырасы булма. Ишетсен колагың.

Ф ә ү з и я. Торган саен гаҗәбрәк була бара.

Г а й с ә керә.

Г а й с ә. Өйдә ни хәл бар дип сорар идем, сорамыйм... Шул ук хәлдер инде. Әһә, Фәүзия кызым кайкан икән. Син, карчык, нигә читтә боегып торасың?

М ә д ә н и я. Торам әле.

Ф ә ү з и я. Гайсә бабай, самавыр яңартыйммы?

Г а й с ә. Түгеп яңаны куй, свежийны. Бергәләп чәйләрбез, бәлки?.. Кибегеп, бик арып кайтып киләм.

М ә д ә н и я. Арырлык булгач, өйдә утыралар аны, кыбырсып чыгып йөрмиләр. Күктәкә мәктәбе директоры тагын кереп чыкты.

Г а й с ә. Нигә кирәктем икән мин аңа, рәхмәт төшкере.

Ф ә ү з и я. Алар сезне укучылар белән очрашырга чакыралар.

Г а й с ә. Укучылар каршысына чыгарып бастыралар алайса...

Ф ә ү з и я. Ватан сугышы инвалиды. Күп орденнар кавалеры. Шуның өстенә берсеннән-берсе әйбәтрәк җиде бала тәрбияләгән ата. Хәзер мәктәпләрдә ир педагоглар аз. Ир-ат тәрбиясе җитми. Бигрәк тә малайларга. Ир кеше тәэсиреннән башка алар абынып та куйгалыйлар.

М ә д ә н и я. Теләсә кайда эт сугарып йөргәнче, барып кайт. Ирегең ачылыр.

Г а й с ә. Туңып торам, карчык. Теге тире эчле камзулым кайда?

М ә д ә н и я. Аны киярга иртәрәк.

Г а й с ә. Кемгә иртәдер, миңа бик вакыт.

М ә д ә н и я. Тагын урман буенда йөргәнсең син, җилдә! Туңып беткәнсең. Камзулыңны күрмәдем.

Г а й с ә. Көя төшмәсен дип әрем сабагы белән урап шушы шкафка элдек түгелме? Тире бияләй дә күренми. Камзул эзләгәндә бер очтан барлап куйыйм дисәм, анысы да юк.

М ә д ә н и я. Актарганым булмады. Үз әйбереңне үзең барлап йөр.

Ф ә ү з и я. Чәйне монда эчәбезме, кече яктамы?

Г а й с ә (*һаман эзләнеп*). Кая олагыр икән!

Ф ә ү з и я. Гайсә бабай, минем бишенчеләр белән очрашырга да килегез әле.

Г а й с ә. Бишенчеләр?.. Алар инде теләсәң ни сөйләсәң шуңа ышанып утырмый.

Ф ә ү з и я. Сугышта кичергәннәрегезне сөйләрсез. Бүген генә ишеттем, сез элек очрашуларга бик теләп йөргәнсез икән. Балаларга дөрес юл табарга ярдәм итәрсез — ничек укырга, ничек яшәргә кирәклеген өйрәтерсез. Бөтен балага да димим, әмма кайберәүләргә өлкәннәр сүзе кирә торган була.

Г а й с ә (*инде ярсый башлап*). Кайда булыр бу нәләт суккан бияләй?.. Хәтер таралган, шуны да таба алмыйм. Ә син сугыш хәлләре дисең. Онытылган.

М ә д ә н и я. Барыр, барыр.

Г а й с ә. Чыгып китсәм, биләмче дисең. Кайтып керсәм, куасың.

М ә д ә н и я. Атап бер сүз әйтергә ярамый инде сиңа.

Г а й с ә. Чыгып киттемме, берәрсен чакырып кертә дә хат яздыра. Акыллы кеше эшеме? Әле синнән яздырмадымы? Булдымы?

М ә д ә н и я. Ай Аллам, аның ни гөнаһы бар? Улыма яздырам.

Г а й с ә. Нинди улың? Мин синең ирең. Кырык өч ел гомер иткән законлы ирең. Син хат яза торган улым юк минем. Онытма, юк! Шофер иде, улыбыз иде, хак. Авылында бер дип йөртә идек. Моннан өч ел элек колхоз икмәген урлап тотылды. Утырып та чыкты... Утырып чыккач нигә туган авылына кайтмый? Ил алдында нигә намуслы исемен казанмый? Юньле юлда йөрсә бер кайтып күренер иде. Рәте юк ул корган тормышның! Шундый бала буламы? Ул булган кеше шундыйны кыла аламы? Юк, бетте! Все, кискән и тәмам!

Ф ә ү з и я. Мин моны белми идем.

Г а й с ә. Авылдашлар алтын. Без картларның кәефен саклап ул турыда артыгын сөйләмәскә тырышалар.

Ф ә ү з и я. Мәдәния әби, мөмкин булса, мин хатка берике сүз кыстырыр идем.

Г а й с ә. Тәки яздырган икән! Яздырып та өлгергән? Тире бияләем кайда дим мин, камзулым! Их, сез, хатын-кызлар! Хатын-кызлар!

Сәхнә караңгылана. Пәрдә ачылганда почмакта ике топчан күренә. Ч а л гитара чиртеп урын өстендә ята, билдән ялангач. Аның аяк очында Ә с ф а н утыра. Чал җырлый.

Ч а л.

Не для меня весна придет,
Не для меня Дон разольется...
Птицы щебечут в саду...
Все это не для меня!

Ә с ф а н. Не для меня! Не для меня! Иртәдән кичкә кадәр бер үк сүз. Туймадыңмы? Ә сиңа нәрсә, үзеңә? Что для тебя?

Ч а л. Сиңа ни булса, миңа да шул! Шиш с маслом!

Ә с ф а н. Миңа алай гына җитми. Риза түгел.

Ч а л. Билгеле бер вакыттан бирле синең ризалыкны бер җирдә дә сорамыйлар шикелле?

Ә с ф а н. Син ул җырны мине кимсетер өчен генә җырлыйсың. Мине җир корты, түбән итәсең килә!

Ч а л. Әсфан!

Ә с ф а н. Нәрсә бар тагын?

Ч а л. Безнең тартырга беткән икән.

Ә с ф а н. Бетеп китте.

Ч а л. Бар, берәр ахмак пошлактан табып кер.

Ә с ф а н. Пошлаклар көтүләре белән囗 эштә.

Ч а л. Баракларда дневальныйлар! Тәмәке табу ысулын да белмисеңме? Белмәсәң, теләнеп тап! Йә!

Ә с ф а н. Юк-бар өчен пычранасым килми.

Ч а л. Кашы минем арканы! (*Әсфан аның аркасын кашый.*) Өстәрәк! Уңдарак! Ныграк, ныграк! Нигә бармыйсың?

Ә с ф а н. Йөргән чаклар бар иде, Чал... Иреннән кан тәме китми. Посылка урлап чыгып чак кына эләкми калдым. Миңа ни-нәрсә җитми иде? Сиңа кирәк иде, сиңа? Шул көнне уйланмадыммы мин? Тагын килеп тотарлар дип төне буе йокламыйча яттым. Ә син яраннарың берлән җырлый-җырлый аракы чөмереп утырдың. Синең алиби, бүлмәңнән чыкмаган, каптерка тирәсендә буталмаган. Тәмәкегә дә үзең чык, Чал!

Ч а л. Мин больничныйда.

Ә с ф а н. Больничныйны ничек алуыңны бөтен дөнья белә. Врачны өркетәсең дә...

Ч а л. Миңа тәртипле булып танылырга кирәк, бала. Мин илгә кайтырга телим.

Ә с ф а н. Илдә бик көтәләр ди сине! Юксынганнар!

Ч а л. Элек яшь булганмын, тәҗрибәсез. Хәзер шабаш! Сак булырмын.

Ә с ф а н. Хәзер утлы күмерне миндәй сарык башлардан көрәтеп, үзең читтә генә өреле аш көтеп торырга өйрәндеңме? Койрык сырттамы?

Ч а л. Вак-төяк белән пычранырга ярамый. Дәрәҗә төшә.

Ә с ф а н. Илгә күз тоткач, нигә эшкә йөрмисең?

Ч а л. Дөньяда «эш яратам!» дигән ишәкләр бетмәгәндә, нигә юкка көч түгәргә?

Ә с ф а н (*менеп ята*). Дөрес, мин дә эшләмим.

Ч а л. Тамагыңны кем туйдырыр?

Ә с ф а н. Синең ачтан үлгәнең юк бит әле.

Ч а л. Әллә үзеңне минем белән чагыштырыр идеңме, гыйбад?! Утын түмәре! Бөҗәк!

Ә с ф а н. Тугры колыңны тагын ни дип мактыйсың?

Ч а л. Син бер шыр тиле идең. Бер машина икмәк тә урлый белмәгән ишәк! Моннан ары урлашуның серләрен үзләштермәсәң, сиңа гомергә рәшәткәдән котылу юк. Тагын барып кабачаксың! Кызулыгың, ахмаклыгың аркасында шытырдап яначаксың! Бәс, шулай икән, маташтырма, топай, мальчик, тартырга телим! Чалның кәефен сакла!

Ә с ф а н. Мәскәүнең «Арагви» ресторанына кереп люля-кебаб ашыйсың килмиме, галиҗәнап?!

Ч а л. Килә! Моннан ычкынып киткәч үк синдәй ахмакларга үч итеп туп-туры шунда юнәләм! Мул күкрәкле чибәр апаны сулга утыртып, бәллүр чәркәләрдән кыйбатлы коньяк «Камю» эчәчәкмен! Французский!

Ә с ф а н. Соң, нигә монда син? Кит, ни көтәсең?!

Ч а л. Туплаган мая азрак! Аз! Болар синең төшеңә дә керми бит, гыйбад! Ишетә тор! Акыл җый! Үз урыныма монда сине калдырам. Әгәр минем сүзне тотсаң, һәммәсе сиңа тәлинкә тотачак! Монда яшьләр, сары томшыклар килеп тулды. Аларга баш булу ансат та, төшемле дә! Хәзергә көч миндә! Мин киткәч коллар сиңа кала.

Ә с ф а н. Тәмәке эзләп киләм. Соңгы кат! Кушма миңа яман эш!

Ч а л. Соңгысы — әҗәл! Башкасы гел кабатланып торачак! Тормыш — таган, дөнья — куласа! Нык тотын!

Ә с ф а н чыга да тиз үк әйләнеп керә.

Ч а л. Өлгерлегең бар! Молодец!

Ә с ф а н. Хат!

Ч а л. Ксиву? Ну ка, бир әле монда. Кемнән?

Ә с ф а н. Өйдән килгән хат сиңа нигә?

Ч а л. Тәмәке тапкач та алырсың хатыңны. Бир.

Ә с ф а н. Моны миңа әни язган.

Ч а л. Синең әниең дә бармыни? Иркә җан!.. Менә мине роддом баскычына караңгы төндә ташлап киткәннәр.

Ә с ф а н. Чал, арттырып җибәрәсең!

Ч а л. Бүген синең анаң — мин! Атаң — мин! Якыннарың да! Сиңа ни кирәген бары мин төгәл әйтә алам! Мин! Атаң беләме сине? Яки анаң? Авылыңда берәр кеше сине нинди язмыш көткәнен аңлыймы? Син минем карамакта. Җаның да, малың да минеке! Без хәзер үлгәнче бергә. Тоташкан. Укы тизрәк! Ана сиңа ярдәмче түгел хәзер, ул бары тик сиңа посылка салучы, акча җибәрүче. Салган-

нармы? Җылы якка тире камзул белән кайта алмыйм! «Арагви» ишеген кагарлык шәп йон костюм кирәк миңа.

Әсфан (*хатны тиз-тиз укып*). Посылка салабыз дигән. Монда бер хәбәр өстәгәннәр. Безгә фатирга укытучы бер кыз төшкән! Институт тәмамлаган кыз!

Чал. Син акылга утырганчы сездә биш укытучы булып китәр әле.

Әсфан. Талама җанымның калган өлешен, Чал!

Чал. Кызлар сиңа нигә? Кирәкми. Юк та! Беркемең юк. Бөтенесен алыштырырлык мин бар! Рәхмәт әйт! Син көчекне муенчак киюдән коткарып калдым. Йөрер идең хәзер бригадниклар белән интегеп эшләп! Ә хәзер алар син күренүгә калтырап тора! Үткәндә түбәнчелек белән юл сабалар! Дөньяда кодрәтле булуга ни җитә?!

Сәхнә караңгылана. Пәрдә төшә. Әсфан авансценага чыга.

Әсфан. Чалның сүзен тыңламыйча ярамый иде хәзер. Нык ук бәйләнеп өлгергән идем мин аңа. Шулай була икән кайчак! Ике яктан да китереп кысалар, артка чигенергә дә, кыймшанырга да әмәл калмый! Теш кысып, күзне йомып алга ташланырга гына кала. Беткән баш беткән дисең! Котылып чыгып, монда эшкә урнашкач та ике егет бәйләнеп йөдәттеләр. Мамай токымы дип тә, авыл салмасы дип тә теңкәгә тиделәр. Шул чагында Чал аралады. Яклады. Юкса, тагын бер тилелек эшләп ташлаган була идем. Дөрес, бәйләнергә үзе боерган икән егетләргә, аларын мин соңыннан гына белдем. Ни өчен якынайдык без? Ярattыммы мин аны, ияләштемме? Туган илдән, якыннардан, күнегелгән гадәтләрдән бер көн эчендә кискен аерылгач, кемгәдер сыенасы да килгәндер. Адашкан песи һәр җан иясенә сырпаланырга әзер. Хуҗасын яраткан эт шикелле мин дә аңа ияләштем, тупаслыгына, кансызлыгына ис китми башлады. Шулай да моңарчы гел белмәгән Фәүзия исемле кыздан хат алгач күңелем әллә нишләде. Хатны мин элеккечә ертып ташламадым. Сүзләре күңелгә гомерлеккә уелып кергән иде югыйсә! «Мәдәния әби белән Гайсә бабайның Әсфан исемле уллары да бар икән. Матур исем. Авылда ике ай торсам да моңарчы сезнең дөньяда барлыкны берәү дә искә алмаган иде. Нигә алай бу?» Бу төртмә сүзләргә ачуым артмады дисәң дә ярый. Минем, Чал боерганча посылка урлап, эләгә язып калгач, кыек эшләрдән, әшәке иптәшләрдән ераклашырга ниятләп йөргән көннәрем иде. Бәлки, шул уйларым тиз-тиз кыз ягына этәргәндер мине? Берсеннән, начарыннан котылып, тагын кемгәдер барып сыенырга теләгәнмендер? Мин аннан хат көтә башладым.

Үзем язмадым. Язаммы соң! Укытучының кәгазе дә, вакыты да күп, язар дип уйладым. Чынын сөйлим, көтә идем. Бу серемне Чалга ачмадым. Бусы да сәер иде. Өч ел янәшә яшәп аннан берни яшерми башлаган идем, ул мине үтәли күреп тора дип белә идем... Икенче хат, шактый озак көттереп, әни исеменнән генә килде. Посылка салмадылар. Монысының сәбәпчесе итеп тә Фәүзияне санадым һәм беркөнне усал гына хат язып салдым. Кешеләргә юлны бары тик усаллык аша гына табып була дип ышанган шыр тиле идем мин... Фамилиясен белми идем, конвертка басма хәрефләр белән «Укытучы Фәүзиягә!» дип кенә куйдым.

Карангылана. Пәрдә ачыла. Гайсә картлар өе. **Гайсә** караватта ята, **Мәдәния** аның тирәсендә йөри.

**Гайсә.** Ай билем, вай билем...

**Мәдәния.** Табада кызган ком да килешмәдеме?

**Гайсә.** Бая чак кына йомшаган кебек иде, хәзер үтерә.

**Мәдәния.** Фельдшер Сәкинәне чакырмый ярамас.

**Гайсә.** Чакырырмын мин сиңа!

**Мәдәния.** Кирелегеңә һич чик-чама калмады.

**Гайсә.** Гайсә карт лапас өстеннән печән төшергәндә егылып билен кузгаткан дигән хәбәр таралсынмы?

**Мәдәния.** Ай Аллам, аның ни ояты бар? Кем лапастан печән төшермәгән дә кем егылып билен кузгатмаган?

**Гайсә.** Башкаларның егылуында эшем юк, мәгәр минеке беленмәсен. Беленмәсен! Сүз буасы бер ерылсамы?.. Җиде бала үстереп Гайсә карт һаман интегеп эшләп йөри, диярләр. Эшләми нишләсен, балаларының игелеген күрми, диярләр.

**Мәдәния.** Шешәгә кайнар сөт тутырып шуны ябып карыйбызмы әллә?

**Гайсә** (*юри куанган булып*). Бусын сынаган юк!.. Яле, китер, яп! Әллә ниләр сынарга риза, хәбәр генә таралмасын!

**Мәдәния** (*сөтле шешә китереп бирә*). Гайсә бабайга килгән чирне таратыйк әле, бисмиллаһи... Булды. Ипләмеме?

**Гайсә.** Аруланып китте сыман.

**Мәдәния.** Сиңа әйтәм, әллә сыерны сатыйк кынамы? Лапас астындагы печәнгә үрелүгә башым әйләнә, күз алларым томалана.

**Гайсә.** Сәнәк сабы сынмаса егылмый идем лә!

**Мәдәния.** Мин дә егылып ятсам, ике имгәк кая барырбыз?

Г а й с ә. Без дә сыерсыз калсак...

М ә д ә н и я. Нигәдер сүзеңне йомгакламадың.

Г а й с ә. Песигә сөтне каян алырбыз? Укытучы кыз да сөтле ашны бик ярата. Сыерлы булганга гына керде бит ул безгә фатирга.

М ә д ә н и я. Алаен алай да...

Г а й с ә. Сыерсыз калсак безне ташлар да чыгар. Син бер башың нишләрсең? Карчык, карчык, гомернең актыгы килде сыман.

М ә д ә н и я. Тузга язмаганнарны сөйләштереп, фәрештәләрне качырып ятмасана.

Г а й с ә. Менә, менә! Элек синең Алла, фәрештәләр белән аралашканың сизелми иде, хәзер әллә нишләдең.

М ә д ә н и я. Картайгач үзгәрә кеше.

Г а й с ә. Нигә болай кинәт үзгәрдек? Бер дә картаер кебек түгел идек бит! Эштә ут уйната идек... Дәррәү йомшадык. Чир-чор ега ала безне. Телебездә ят сүзләр...

М ә д ә н и я. Бүген төшемдә...

Г а й с ә. Сөйләмә төшеңне!

М ә д ә н и я. Тәки җылаттың, әллә бер көнем күз яшьсез узармы дисәм, барып чыкмады. Ничек картаймыйсың, ди? Көннәрең күз яшенә аралашып акканда җан ничекләр чыдасын?

Г а й с ә. Бер караганда сүзең рас, карчык. Сыерга азык кем әзерләр, кем карар аны, кем савар?

М ә д ә н и я. Әсфан кайтып керсә, өйләндерер идек.

Г а й с ә (*сикереп тора*). Ул кешенең исемен әйтмә дидемме мин сиңа!

М ә д ә н и я. Ят тик кенә, билең тагын азыныр.

Г а й с ә. Мә шешәңне. Мә юрганыңны.

М ә д ә н и я. Килеште дигән идең ласа, сиңа әйтәм.

Г а й с ә. Татлыга агу аралаштырып бирәсең.

М ә д ә н и я. Үз улының исеме агу. Йа кадыйр, бу көннәрне күрермен дип кем уйлаган? Тора алмыйм дип назландырып ята бит, җан көеге!

Г а й с ә (*паузадан соң*). Кодалар кунакка дәшкәнгә генә яттым.

М ә д ә н и я (*бот чабып*). Өч көн буе мине биеттең.

Г а й с ә. Кунакка йөри алмыйм.

М ә д ә н и я. Үктәбер бәйрәме бит, үктәбер!..

Г а й с ә. Бара алмыйм. Билем сызлавы да хак. Мәгәр ул ягым түзәрлек. Бик теләсәм, теркелдәгән булыр идем. Кеше, әгәр бик нык теләсә, әллә ниләр башкара ала. Күп чакта теләү җитми адәм баласына.

М ә д ә н и я. Сиңа әйтәм, нигә бу араларда хәбәр-хәтере юк икән?

Г а й с ә. Элек тә юк иде, кинәндермәде. Хат килеп нинди сөенечле хәбәр ишетәбез! Белмәгәнең лутчы.

М ә д ә н и я (*куркып кына*). Кичәгенәк Фәүзиягә бер хат килде.

Г а й с ә. Аңа килгән хатларны тикшермә дигәнем юкмы?

М ә д ә н и я. Сүз җаеннан гына әйтүем. Әллә...

Г а й с ә. Кыз чибәр. Акыллы. Тыйнак. Уңганлыгы турында сүз дә юк. Намыслы. Аңа мең хат килер.

М ә д ә н и я. Ялгыш кына конвертына күз төшердем. Әллә безнең Әсфан кулы булды инде.

Г а й с ә. Миңа түгел, сиңа күренергә кирәк дуктырга, карчык!

М ә д ә н и я. Шуның кулы инде, шуның кулы, таныйм.

Г а й с ә. Яза ди безнең Әсфан кызларга хат! Кызларга аларга ай-кояш, сандугачлар турында язалар.

М ә д ә н и я. Ай, үтерде, язганы бар диярсең!

Г а й с ә. Карагызчы бу шашкан карчыкны! Ниләр фараз кылып, комнан бау ишеп ята! Әгәр яза икән, бүгеннән туктатам.

М ә д ә н и я. Синең ни катнашың бар? Нигә тылкышасың. Язышсыннар. Хат килгәч тә рәхәт булып куя ул.

Г а й с ә. Кем белән язышсын? Алма чәчәге кебек саф кыз хөкем ителгән, исемен авылдашлары телгә алырга җирәнгән, ата-анасыннан ваз кичкән юлбасарга хат язсынмы? Кемгә хаҗәт ул язышу? Ниндиен уртаклык бар алар арасында? Тыям! Тыймасам намыссызлык була. Син теләде дип андый әшәкелеккә юл куяммы? Син иркәләгән, син бозган төпчекне...

М ә д ә н и я. Чү, тыел. Үзе кайтты бугай.

Г а й с ә. Китер сөтле шешәңне! Яп юрганыңны!

Менеп ята. Ф ә ү з и я керә.

Ф ә ү з и я. Өлгер дә инде үзем. Медпунктка кагылдым. Почтага кереп конвертлар алып чыктым. Бабай ни хәлдә?

М ә д ә н и я. Тырышып-тырмашып ята. Кыймшанмый да.

Ф ә ү з и я. Мин аңа җылан мае алып кайттым. Кичен әйбәтләп сыларбыз. Мичкә шәбрәк ягарбыз. Җылы булсын. Мунча яксак тагын да шифалырак булыр.

Г а й с ә (*юрган астыннан борынын гына сузып*). Җылан мае?

Ф ә ү з и я. Ифрат файдалы дару. Дефицит.

Г а й с ә. Медпунктта «бабайга» дип ычкындырмадыңмы?

Ф ә ү з и я. Үземә дидем. Сәкинә апа шикләнеп карап алды алуын.

Г а й с ә. Җылан маен ишеткән бар. Кыйммәтле дару икәнен дә беләм. Җылы тәнемә җыланнан алынганны сыларга дигәч, чирканам. Әллә ничек.

М ә д ә н и я. Ай Аллакай гынам, хат букчаларын бик күп алгансың түгелме? Акча җәлләмисең икән.

Ф ә ү з и я. Хат язасы кешеләрем бар.

М ә д ә н и я. Әйдә, кызым, теге якка. Ашым пешкән. Сөтле өйрә иткән идем. Бабаңны ашаттым. Җылыткан шулпаның ләззәте калмый.

Г а й с ә. Тукта.

Ф ә ү з и я. Син эндәштеңме, Гайсә бабай.

Г а й с ә. Сорыйсы сүзем бар. Кичә кемнән хат алдың?

Ф ә ү з и я. Кичәме, бабай...

Г а й с ә. Шәхси эшеңә тыкшына дип рәнҗемә. Мин юк кеше. Карчыкның зиһенен ачар өчен генә калкындым. Югыйсә ул, күрә-карау, әллә ни уйлый башлаган.

Ф ә ү з и я. Мәдәния әби дөрес уйлаган. Улыгыз Әсфаннан алдым кичә хатны.

Г а й с ә (*торып утыра*). Ни-нәрсә яза ала инде безнең кадерле улыбыз? Син аңа ни язасың? Һава торышын хәбәр итәсеңме, базар бәһаләренме?

Ф ә ү з и я. Гөлҗамал апаның усал малае турында яздым. Киңәш сорадым. Бүген менә чатлама суыкта кызларның яулыкларын җыеп алган да берәм-берәм төйнәгән, озын тәнәфестә форточканы ачкан да икенче каттан җиргә төшкән.

М ә д ә н и я. Егылып билен сындыргыры!

Ф ә ү з и я. Иң гаҗәбе, класста аңа беркем каршы чыкмаган. Малайлар да куркып өнсез калган.

Г а й с ә. Әсфан белән ни уртаклыгын табасың инде син ул юньсезнең, ягъни мәсәләнең?

Ф ә ү з и я. Әсфан миңа шул малайны юлга кертергә ярдәм итәргә тиеш.

Озак пауза.

Г а й с ә. Ничек?.. Минем малай, ягъни теге малайны?..

Ф ә ү з и я. Мин Әсфанга ышанам. Ярдәмен кызганмас. Үзе дә яманлыкны күргән, татыган егет.

Г а й с ә. Иң әүвәл Әсфан явызлык кылган кеше! Семенага дигән бодай урлап тотылган бур. Бур!

Ф ә ү з и я. Болар турында ул бик нык уйланадыр. Уйланса, малайга хат язмыйча түзә алмас.

Г а й с ә (*бик аптырап*). Алай димсең, алай... Кыек сукмакка төшеп барган юньсез малайга авылның кара-

гыннан хат килеп төшә ди көннәрдән бер көнне. Гөлҗамал төпчеге дә үскәч бур булачак! Андыйлардан бер кәррә яхшылык көтәргә ярамый. Рөхсәт итсәләр, мин угрыкаракларның кулын кисеп ыргытыр идем. Урлаштымы —терсәгеннән кх! Кеше җанын кыйдымы — муенын бор. Җинаятьләрнең эзе дә калмас иде.

Фәүзия. Алай эшләп караган дәүләтләр булган. Муенны кем бора? Палач! Палач кем? Кеше. Бүген бора җәллад кеше муенын, иртәгә бора. Бу һөнәр аның төп кәсебенә әйләнә. Муен бору аңа ошый башлый. Ярата! Бусы да куркыныч!.. Кешеләрне гадел юл белән, ышаныч белән дәваларга кирәк.

Гайсә. Димәк, син аңа бу турыда да язасың?

Фәүзия. Хат алышу — кара-каршы сөйләшү кебек ул, сер алмашу.

Мәдәния. Хат алуның күңеллелеген әйтмә инде. Менә синең сугыштан язган хатларың...

Гайсә. Мин сугыштан язган, төрмәдән түгел.

Фәүзия. Аерма зур, әлбәттә. Җир белән күк арасы. Менә бөек педагог Антон Семенович Макаренко болай дип язып калдырган: «Кеше, туганда, саф пыяла кебек чиста була, тормыш үзе аны тапландыра». Һәм ул, гомере буе, шушы кара тапларны бетереп, кешедән табигать биргән матурлыкны эзләгән.

Гайсә. Эзләсә дә тапмаган!

Фәүзия. Тапкан! Тормыш юлында абынганнар да, тайганнар да бар. Тарихның бер өлешендә дә җәмгыять алардан йөз чөерә алмый. Адашканга юл кайда дип сорасалар, адашканга юл — кеше күңелендә дияр идем мин.

Пәрдә төшә. Фәүзия авансценага чыга. Хәзер сәхнәнең бер ягында Әсфан, икенчесендә Фәүзия. Пистолетлардан төшкән ут аларны һәм алар янына эленгән почта ящикларын гына яктырта. Музыка.

Фәүзия. Әсфанның беренче хатлары искиткеч тупас иделәр. Алардан шомлы явызлык бөркелеп торды...

Әсфан. Әй син, укытучы кисәге! Нигә минем тормышка бәйләнәсең? Ошамыймы? Кем син? Ни беләсең минем хакта? Авылда минем исемне телгә алмыйлар, имеш. Алмасыннар. Куркалар миннән! Куркалар! Кешенең гомерлек юлдашы ул куркаклык. Бар кеше дә үзенең соңгы бердәнбер юлга китәсен белә. Әҗәлдән курка. Әҗәлнең формалары күп — кеше ачлыктан курка, чөнки ачлык та әҗәл. Кеше төн күзеннән курка, зираттан курка. Сугыштан курка. Берәрсе, йөрәге җитеп, минем турыда яман сүз ычкындырып карасын. Мин сүзен ишетмәсәм дә куркак җанның коты ботына җитәчәк.

Ишетсәм, кайткач җанын алачакмын! Син дә күпне белмә, юкка-барга кысылма. Кысылырсың — үләрсең! Төпченмә! Минем кул озын, Татарстанга гына җитә минем куллар. Сагай!

Фәүзия. Мин бу хатны алгач, Әсфанның төс-битен, кыяфәтен, характерын күз алдыма бастырырга тырыштым. Стенадан мөлаем генә елмаеп карап торган егет белән бу әшәке хатны язган кеше арасында аерма чамасыз зур иде. Шулай тиз кире якка авышып беткәнме ул, дип уйладым. Әллә монда чакта ук шундый булганмы ул? Фоторәсем битлек, маска гынамы? Озак баш ваттым. Һәм хатлардагы сүзләрнең күбесенең читтән, яман кешеләрдән йогып барганын чамаладым. Егеткә чын күңелдән ярдәм итәсем килде. Без еш-еш хат алыша башладык...

Әсфан! Мине синең хатыңдагы усал сүзләр гаҗәпләндермәде, мине хатыңдагы төпсез өметсезлек сагайтты. Сугыш, ачлык, үлем дигәнсең. Әйе, һәркемнең үләчәге туган минутыннан ук билгеле. Әмма бер кеше дә моны уйлап кына яшәми, аның гомерен иң кыен минутларда да, хәтта әҗәл белән якалашканда да, якты өмет бизи. Өмет ялгыз берәүгә генә хас сыйфат түгел. Ул уртак хис. Кешеләрне, җирдәшләрне якты өметләренең уртак булуы да берләштерә. Мәктәптә моны бигрәк тә ачык сизәсең. Мөгаен, мин шуның өчен укытучылык һөнәрен сайлаганмындыр. Класс, әгәр укытучы уңган булса, бер җанга, бер коллективка әйләнә. Без бергәләшеп һәр иртәне якты өметләр белән каршылыйбыз. Әйе, кыенлыклар аз түгел, язмышлар төрле-төрле. Тормыш — өстәл тирәсенә сырышып кайнар пәрәмәч ашау гына түгел. Хезмәт, ярыш, тырышлык. Синең өметсезлегең — ялгызлыгың дип уйладым. Чын дуслар, яхшылыкка фикердәшләр таба алмаган син анда. Хата кылып та яхшылыкка өмет баглаган, якты киләчәккә табынган кешеләр юкмыни сезнең арада? Бардыр, булырга тиеш. Мин синең төзәлеп чыгарыңа ышанам. Тик аңа бик зур, бик якты өметең булу кирәк. Өметләнергә дигәндә, синең нигезең бар! Сине туган авылың, эти-әниең көтә. Безнең класстагы Кәбир турында язган идем мин сиңа. Үтенәм, шуңа һәйбәтләп кенә бер хат язып сал. Тик бер нәрсә турында алдан ук килешеп куйыйк: син ул малайның тормышка булган өметен кисә күрмә!

Әсфан. Син мине тәмам бер катлы җүләргә саныйсың, ахры, Фәүзия. Ул ташбашка ни яза алам? Тормыш юлымны үзем сайладым, берәү дә мине караклыкка этәрмәде. Һәркем үзе сайлаган юлны акларга тырыша. Үз

юлымны җүләрлек, кылганнарымны ахмаклык дип яза алмыйм ич мин ул маңка сарыкка! Бу чиксез тилелек булыр иде. Инде килеп: «Күр, малай! Чибәркүлдән дә атаклы кеше чыкты, ул — мин. Мин — карак, тирә-юньне дерелдәтеп тотам. Лаеклы алмаш булып менә син үсәсең, рәхмәт!» дип языйммы? «Безнең ишеләр тумаса, тормыш эчпошыргыч төче һәм күңелсез булыр иде!» дип тә өстәп куйыйммы? Син миннән шуларны яздырырга телисеңме?

Фәүзия. Мин синең ул малайның киләчәге турында уйлавыңны телим.

Әсфан. Ни пычагыма кирәк ул миңа?! Кадалып китсен!

Фәүзия. Аның әтисе, туганнары турында уйлавыңны телим. Ул берничә тапкыр инде классташ кызларны җәберләде. Кеше җәберләү — түбәнлек түгелме синеңчә? Кызларны — үзеннән көчсезләрне җәберләде. Хурлык! Үз язмышың белән мактангансың. Көчең белән масаясың. Синең көчеңне кайда, кем күргән? Үз эшләрең белән яуда сынадыңмы аны? Яки стадионнарда? Галимҗан Хөсәенов кебек чемпион исемен алдыңмы? Каравылчы картны сугым пычагы белән куркыта-куркыта машина-машина бодай урлап китүме егетлек? Гафу ит, үзең кузгатмасаң, бүгенгә бу турыда язарга ниятем юк иде. Кылган явызлыгың белән масайганга ачынып язам. Җидесигез үгездәй егет караңгы урамда, соң гына эштән кайтып килүче эшче агайның сәгатен талап алалар. Син мактаган егетлек шулдыр бәлки? Кәбирдә кылган гамәлләреңнең вак һәм кешелексез икәнен аңлау тудыр син! Ачы үкенүеңне яшермә. Тәмам өметсезлеккә төшүеңә ышанмыйм. Әгәр бик сагынсаң, туган илеңә бер кайтмый калмассың! Туган иле бар кеше бер сагынмый калмый ул! Тик туган илеңә дә явыз уйлар төяп кайтсаң, алдагы көнеңнең ни яме калыр? Өметсезлеккә чик куймасаң, яшәү сиңа бик кыен булыр. Болай да яшәү җиңел булмас сиңа, нигә үз ирегең белән өстәмә кыенлыкларга кереп батарга?!

Әсфан. Аннан сиңа ни зыян! Мин синең шәкертең түгел. Шөкер! Туганың түгел. Килдең, киттең, юл такыр, Чибәркүл мәктәбенең буш торганы булмады, булмас та. Сиңа хәтле дә авыл яшәде, син барлыкны белмәгәндә дә авылда гомер туктамаган. Мин киттем, әллә берәр нәрсә үзгәрде дип уйлыйсыңмы?

Фәүзия. Үзгәрмәде дип тагын бик нык хаталанасың! Монда син башкарасы, сиңа йөкләнгән эшләр өелеп калды. Авылда водопровод үткәрәләр — син юк. Сенаж

башнялары салалар — син юк. Яңа таш мәктәпкә нигез салырга тотындылар — син юк. Әгәр син монда булсаң, авылың халкы телдән-телгә: «Ә-ә, ул мәктәпнең нигезен Гайсә бабайның төпчеге Әсфан түшәгән иде!» — дип сөйләр иде. Ә син юк! Әти-әниең карт, туганнарың төп йортны сиңа ышанып тапшырганнар да таралышканнар. Чөнки син яшьтән үк: «Авылда калам. Шофер булам», дип хыялланып йөргәнсең. Сиңа дигән яңа «КамАЗ» кайтты. Татарстанда эшләнгән беренче машина! Сылу! Ә син юк... Урам тутырып чибәр кызлар җырлап узды. «Узган гомер кире кайтмый»,— диләр. Син монда түгел, ишетмисең. Хәзер колхозда эшче куллар җитми, фермалар сменалы эшкә күчә, механизаторлар алтын бәһасенә йөри... Яңалыклар күп — син генә юк!

Фәүзия югала, авансценада Әсфан берүзе кала.

Әсфан. Хәзер Фәүзиянең хатларын чыдарым бетеп көтеп алам. Ул миңа ешрак яза. Вакыты да иркенрәк, сүзнең дә иң кирәген таба белә. Төзелештә эшләү җиңел түгел. Мине бөтенләй яңа урынга, тау-таш арасына күчерделәр. Без монда яңа шахта ачарга тиешбез. «Яңа шахта белән сез дә яңа тормыш башлап җибәрергә бурычлы»,— дип аңлатты начальник. Монда гомумән җиңел эш юк. Сменадан өйгә кайтканда тез буыннары хәлсезләнеп сулкылдый. Көне буе, кайта-кайта, аның хатларын күңелемнән кичерәм. Әрләү сүзләренә мең төрле усал җавап табып карыйм. Кайсыларын язып та салам, бик күпләрен яңа туган уйлар күмеп, каплап китә. Ял көнемне зарыгып көтеп алам. Без график белән берәмләп ял итәбез. Иптәшләр сменага китүгә, көне буе мин аңа хат язам. Көне буе! Иртәдән кичкә кадәр мин аның белән генә яшим, дәртләнәм, моңаям. Кызулык белән, мавыгып, мин янәшәмдә тагын бер зат барлыгын, аның да, Фәүзия кебек үк, минем хәлне өзлексез күзәтеп торуын онытып җибәргәнмен. Ул тагын мине исенә төшерде.

Пәрдә ачыла. Барак почмагы. Ярым караңгы. Әсфан белән Чал очрашалар.

Әсфан. Син чакырттыңмы мине, Чал?

Чал. Миннән башка тагын кемгә кирәк син?

Әсфан. Алай үк димә, Чал.

Чал. Бүген нинди көн икәнен беләсеңме?

Әсфан. Нинди көн?

Чал. Олыларга хөрмәт югалткан аңгыра күкеләрне сөймим!

Әсфан. Тыңлыйм ич!

Чал. Салып торып җибәрермен!

Әсфан. Кем күтәреп торгызыр? Салып җибәрүе ансат ул!

Чал. Егылгансың икән, тыпырчынма! Ят шунда!

Әсфан. Җир салкын монда. Өшетер. Мин җылыны яратам.

Чал. Җылы белән татлыны бөтен кеше ярата, тик ул барыбызга да тәтеми. Җитми ул барыбызга да! Әй син, бөҗәк! Килер көнең, салып җибәрүче син булырсың! Кем көчле — шул хаклы. Әлегә көчле хуҗаң барын онытма! Ярамый. Нинди көн бүген, яле, хәтерлә.

Әсфан. Онытмадым.

Чал. Йә?

Әсфан. Почта килә торган көн. Хатлар килә торган көн!

Чал. Нәрсә, нәрсә? Очрашканнан бирле тукыйм: чын эш арасына хатын-кызны кертмә! Шулар аркасында яндым. Шулар аркасында җык күрәм. Нигә сиңа хат? Уйнап туймадыңмы? Эшләмичә рәхәт яшәргә, тир түкмичә дә тәмле ашарга сине мин өйрәттем. Яшәргә була! Сиңа авторитет өчен дан кирәк, «Усал!» дигән исем кирәк. Куркусыз, дәһшәтле һәм кансыз... шулар өстенә ялгыз да түгел дигән дан кирәк! Исемеңне ишеткәндә бөтенесе калтырап торсын. Аннары, дан үзенекен эшләр! Тар күкрәкле интеллигентлар төсле җылый-җылый кызлар белән хат алышканыңны белсәләрме?.. Каян килсен ди кара дан?! Кем синнән кан калтырап, куркып торсын! Бар, мин кушканны үтә, исемеңә дан өстә! Тик сак була да бел! Әләкмә!

Әсфан. Тиккә чакырмаганыңны белдем.

Чал. Җылы якларга сәфәр чыгарга исәп! Ике ел отпуск алган юк. Җылы як буш кулны яратмый. Бүген зарплата көне, мәми авыз! Яшь җилкенчәк егерме бишәрдән җыеп акчаны сиңа тапшырсын. Боер!

Әсфан. Миңа?

Чал. Бригадирлар кисәтелгән.

Әсфан. Ризалармы?

Чал. Риза булсалар, эшне сиңа йөкләр идемме?

Әсфан. Аңлашыла.

Чал. Бүгеннән калмый бригадирларның бер-икесенә нык кына өйрәтергә! Темный оештыр. Булышчылар ал. Ярты елга больницага кереп ятарлык булсын. Талагын төй!.. Өченче бригададан башла. Калганнары йөгерә-йөгерә китерер!

Әсфан. Иң таза, иң көчле бригадир. Үзе мине больницага кертсә?

Ч а л. Син кайчаннан эшеңнең ахыры, нәтиҗәсе турында уйлый башладың әле?

Ә с ф а н. Туганнан бирле!

Ч а л. Кайда, ни өчен туганыңны оныт. Беләм, син хәзер теге асылкош турында хыялланасың. Атна саен хат салган була бит!

Ә с ф а н. Хыялланам.

Ч а л. Бу кәнфитләнүеңнең азагы ни булачак?

Ә с ф а н. Уйларга куркам.

Ч а л. Куркасың шул, курыкмыйча ярамый. Чөнки аның ахыры сиңа да, миңа да, теге чыркылдыкка да беренче хаттан ук билгеле. Мәче сычкан белән уйнарга ярата мы? Ярата. Син сычкан! Бөҗәк! Ул уйный! Теләгәнчә сине биетә! Җүләр! Томана! Әйе, өченче бригадир таза егет, боксер. Көченә ышанмаса ул миндәйләргә акча җыеп бирергә базмыйча торыр идеме? Син көчлене куркыт! Көчсезләр онытмас! Җылы якны сагындым! Кырым ярларына барырга телим. Кипарислар арасына! Кояшта янган кызларны кочасым килә! Күз яше тамган кәгазьләр генә аз миңа, селәгәй!

Ә с ф а н. Җылы якны минем дә күргәнем юк. Минем төшкә дә кызлар керә!

Ч а л. Бәхет ике кешегә бергә килми. Сиңамы соң! Бәхет зур кешеләр өлеше. Кеше булу өчен сиңа дан җитми. Арт як сыек. Биография бәләкәй.

Ә с ф а н. Башка берәүне ялла.

Ч а л. Кайсы төшеңнедер яратам! Сине сайладым. Син минем шомлы күләгәм. Ниндидер кыз минем белән ярышка чыга диген! Бер якта мин, бер якта ул! Сине миннән тартып алырга телиме? Көлке! Сине генә түгел, хәзер мин үземне дә сыныйм. Ялгышмадым, алай да беләсем килә. Кемнеке син?! Бүген бригадаларны йөреп чыгасың!

Ә с ф а н. Чал, кызган мине.

Ч а л. Кызганам. Черкине үтерергә дә кызганам. Ә мине кем кызгана?

Ә с ф а н. Сине мин кызганырмын.

Ч а л. Синме, бөҗәк?! Кызгану — көчлеләргә генә хас. Хәерче башың белән сәдака өләшмәкче буласыңмы?

Ә с ф а н. Үзең курыкканга мине яңа җинаятькә этәрәсең.

Ч а л. Нәрсә-ә-ә?! Бир теге кәнтәйнең хатларын! Ул өйрәтә!

Ә с ф а н. Синең кулга биргәнче, ертып җилгә таратам мин аларны.

Ч а л. Ул синең белән уйный. Сизмисеңме шуны?

Ә с ф а н. Чын күңеленнән хат язып, уй-хыяллары белән бер рыясыз уртаклашып торган, юаткан, яхшылыкка өндәгән кешене уйный дип әйтә алмыйм. Синең йөрәгең юк, Чал. Ул күптән сүнгән. Минем йөрәгем бар икән. Һәм сөя дә ала икән әле минем йөрәгем!

Ч а л. Кәгазь шәүләне сөя аласыңмы? Миражны! Ха-ха, ул ничек? Ул да сөя аламы?!

Ә с ф а н. Кызганычка каршы, кем мине сөйсен?

Ч а л. Тормышка хәйлә белән ялган хуҗа. Алар гына чын һәм чынлык. Мәхәббәт һәм өмет юк. Бу сүзләрне эчке фәкыйрьлекләрен яшерергә тырышкан салам сыйраклар уйлап чыгарган. Көчсезлекләрен сиздермәс өчен! Көчле бул! Һәр чакта да көчленеке замана. Көч акчада. Мәхәббәт сатыла. Өметне дә акча гына тудыра. Эшләп баеган кеше юк.

Ә с ф а н. Мин баерга уйламыйм. Мин аны сөя генә алам!

Ч а л. Ул сине бер чакта да кеше итеп санаячак түгел. Синең юлың мәңгегә киселгән. Ашлык урлап саткан көнне өзелгән. Башка юл тап!

Ә с ф а н. Көчләмә мине, Чал! Акчамның яртысын биреп барам. Җылы якта җитмәсә, тагын салырмын. Көчләмә! Беләм, син һәр яктан хаклы. Тормыш тәҗрибәң зур. Ничә тапкыр утырып чыккансың. Яшәүнең эчен-тышын гына түгел, тирәнлеген беләсең. Әмма синең төсле салкын җанлы була алмыйм. Мин аны яратам. Бик яратам. Көчләмә мине, Чал, җәберләмә!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Пәрдә әле ачылмаган. «Ал яулыгым» көенә көчле музыка. Катнашучылар берәм-берәм авансценага чыгалар.

Г а й с ә. Язышуларына үз вакытында чик куйган булсам соң!..

М ә д ә н и я. Язышуын да язышсыннар иде... Нигә дип ерак юлга чыгып киттем дә нишләпләр аны ияртгем?

Ф ә ү з и я. Юлыбыз гаҗәп матур булды. Сәфәребез искиткеч күңелле башланды. Юл йөрергә яратам мин. (*Җырлый.*)

Юллар, юллар! Озын булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын.

Ә с ф а н. Кем уйлаган бит! Беренче күрешү шундый бәхетсезлеккә илтер дип кем уйлаган? «Киләм» дигәч,

мин аны күтәп ала алмадым. Тәүлек минутлары ел булып тоела башлады.

Ч а л. Язмыш бу кешеләр арасына тагын мине катнаштырды. Кирәкмәс иде!

Г а й с ә. Үкенүдән мәгънә юклыгын беләм! Үткәннәрне кайтарып та, үзгәртеп тә булмый. Адәм улларында андый кодрәт юк. Алай да... безнең Фәүзиябез чак кына үлми калганда, үкенгән минутлар да булды!

Ф ә ү з и я. Нигә кире кайтарырга? Үлемсезлек бирәүдә дә юк. Адәм балалары җиргә мәхәббәт өчен тумыймыни? Ә мәхәббәтнең сабыры юк... Яна ул, дөрли, ялкынлана! Тормышны мин башкача күз алдына китермим дә. Үкенмим дә! (*Башкалар берәм-берәм чыгалар, авансценада ялгызы гына Фәүзия кала.*) Быел юкәләр бик мул чәчәк атты. Юкә чәчәк атканда урманны кем генә яратмый икән? Мин аерата яратам. Балалар белән әллә ничә кат экскурсия ясадык. Бал кортларына бәйрәм! Таң яралганнан бирле кичке зәңгәрсу эңгергә кадәр туктаусыз выжлап очалар! Чибәркүлдә бер ел эшләп мин җәйге ялга авылыбызга кайттым. Авылмы, минме, нидер үзгәргән иде. Чибәркүл урманнары башкачарак шаулый иде. Андагы инеш тә бүтәнчәрәк чылтырый... Гайсә бабай суырткан аксыл-сары юкә балы да тәмле-татлырак кебек иде. Авылыбызда озак юана алмадым, ниндидер эчке бер ыргым мине Чибәркүлгә, Гайсә бабай белән Мәдәния әби янына, алтынчыга күчкән малай-кызларым янына алып кайтты. Мин кайтканда юкәләр чәчәк койган, игеннәр баш кыса торган чак иде. Әсфаннан төгәл өч ай хат килмәде. Барыбыз да борчылдык. Картлар тәмам акылларын җуйдылар... Ниһаять, без тагын хатлар алыша башладык...

Фәүзия бер кырга күчә, икенче кырда да ут яктыра. Анда — почта ящигы янында Ә с ф а н басып тора.

Ә с ф а н. Авылны бер дә сагынмыйсыңмы әллә, дип сорыйсың, Фәүзия. Бу сорауга бер авыз сүз белән җавап бирү бик кыен. «Сагынмыйм»,— дисәм, ялган. «Сагынам!!» — дисәм, читен. Чибәркүл туган-үскән җирем генә түгел, җинаять кылган, хурлыкка төшкән урыным да бит.

Ф ә ү з и я. Ярaңа кагылсам — түз! Врачлар ярага кагылмыйча гына кеше тәнен дәвалый алмаган кебек, вакыт-вакыт минем дә сиңа ныграк кагылып карыйсым килә. Беләсем, аңлыйсым килә. Бу хакта язмый тәкатем юк. Йорт-җирең килгән, мохтаҗлыгың юк, ата-анаң тигез. Ничек син халык милкенә кул суза алдың? Авылда

бер дә якын кешең — киңәшчең, ышанычың юк идемени? Берәү дә тыймадымы сине? Булмагандыр шул, егетләрне кимсеткәнсең, кызлардан көлеп йөргәнсең. Шулай диделәр.

Әсфан. Кеше күңеле — дәрьядыр... Болай фараз итеп карыйм. Күзәткәнең бармы, син бит педагог, тәрбияче, төпчек балалар гел бер-берсенә охшаш булалар. Алар иң ахырда тусалар да семьяда беренче булырга омтылалар. Миңа да шул йогышлы чир эләккәндер. Абыйлар мине чүт кенә кыерсыта башласалар да әләкләргә әни янына йөгерә торган идем. «Шул дуraклардан элек мине алып кайткан булсагыз!» — дип, идән төеп үкерәм... Алты яшьтә! Төпчекне бөтен кеше ярата, ул гына беркемне дә сөйми. Үзе генә әйбәт! Куркыныч ул, әгәр кеше үзен генә сөя башласа! Аңа бар кешедән күбрәк кирәк була башлый. Син — бар кешедән өстен. Ә ничек өстенлекне расларга? Ярый ла аерым талантың булып тиз үк күтәрелсәң! Минем кебек талантсызга нинди әмәл бар? Мәктәптә мин иң алдынгы булалмадым, нәтиҗәдә, сигезенчедән укуны ташладым. Армиядән калдырдылар. «Әһә!» — дидем мин эчтән генә, яшьтәшләрне озатканда. «Алтыгыз да китеп олагасыз, ә абзагыз монда кала!» Берүзем! Алтының бише авылга кайтты. Алар погоннарын уйнатып, түшләрен ялтыратып урамнан узганда йөрәгемә кан сауды. Яшьтәшләр арасында да мин беренче түгел идем! Андый кешенең дусты яки сөйгән кызы була аламы? Ялгыз идем мин. Ялгызлык — бәхетсезлек. Ялгыз — күмәкләрдән үч алырга ярата. Ялгызлык ялгыштыра. Беренче булырга омтылып, беренче булалмаган ялгыз калса — тагын да әшәкерәк. Күңелемдә ялгызлык өстенлек алды. Әти-әни: «Өйлән!» — дип тезләнеп ялыналар. Көләм генә! Боларны ул чакта да тирәнтен аңлаган димә, монда, кат-кат газаплы уйларымның нәтиҗәләрен язам.

Малай чакта сугышмый идем, шуннан азынып киттем, Чибәркүлгә кыз артыннан килгән егетләргә әләгә иде миннән! Сугышып ике тапкыр яртышар ай утырып чыктым. Өметсез, ялгыз кешенең шешә белән аралашуын беләсең, булды, эчкән чаклар да күбәйде... «Эчмә!» — дигән әти-әнигә өстәл төеп кенә җикерә идем. Бер көзне шәһәрдән автоколонна килде, икмәк ташырга. Иш ишен таба, арада ике көяз егет тә бар иде. Күн картуз кигән болар, иңдә күн тужурка, комиссар күк йөриләр. Байлар, акчаны уңга-сулга сибәләр. Мең анекдот беләләр, бөтен яшьләр алар авызына карап тора. Мин аларга тиз елыштым. Алар да чит итмәде. О, юк, гаепне аларга ташларга

җыенмыйм. Гаепне һәркем үзе ясый. Без ике машина бодай урлап саткан идек инде, өченчесен төяргә килдек. Рульдә мин. Каравылчы карт сизенеп юлга аркылы төште. Картны тибеп кенә очырдым. Үкенеп бетә алмыйм! Исемә төшкәндә: «Ах!» — дип ыңгырашам. Ул бабай вафат инде, дөнья куйды, сәламәтлеге юк иде. Икмәк өчен бик катылык иде ул елда, явымлы ел иде, күпме иген кырда калды, чәчүлекнең һәр бөртеге исәптә иде. Җиде ел бирделәр.

Фәүзия. Нигә дәвам итмисең?

Әсфан. Калганнарын беләсең. Тегендә килеп төшкәндә бөтен дөньяга ачулы, үчле идем. Кеше үз йомшаклыгын аклар өчен сәбәп эзли һәм таба да. Усал кеше көчсезләрдән үч алырга тотына. Көчсезләрне рәнҗетеп тәм таба...

Фәүзия. Чибәркүлне сагынасыңмы, дип сораган идем, язмадың.

Әсфан. Ә син туган авылыңны сагынасыңмы? Яз син, Фәүзия, яз. Мин синең хатларыңны бик көтәм, өзелеп көтәм.

Фәүзия. Сагынмый буламыни?.. Анда әни, сеңел... Туганнар күп. Җәйге ялымны түземсезлек белән көтеп алдым. Бер ел эшләп, олы кеше булып туганнарым янына кайтып киләм. Күчтәнәчләр җыйдым, әнигә ак шәл, акны ярата ул, мин дә акны киям. Асиягә озын кунычлы итек. Мәдәния әби зур итеп, кәнфитләр белән бизәп чәкчәк катырды. Өйдә сөйләп бетергесез мәж килдек. Сөйләшеп сүзебез бетмәде, ике көн, ике төн самавырны сүндермәдек. Эчеп кенә туктыйбыз да яңаны куябыз. Әни янында чәйли-чәйли татыган рәхәтне ни белән алыштырып була?.. Аналар газиз! Сүз арасында, уйнап кына: «Кайчан кияүгә чыгасың, кызым?» — дип сорап куйды. Кызарындым. Туган авылыңның бәбкә үләне каплаган тар тыкрыгыннан яланаяк, керт-керт яшел кыяр тешләп, купшы төклетуралаларга сәлам бирә-бирә суга төшүнең ләззәтен кабат татыдым... Шулай да быел үземдә ят үзгәреш сиздем. Нигә алай, дип баш вата торгач кына, Чибәркүлне сагынуымны, бер ел эчендә сезнең авылга иялэшүемне аңладым. Нигә булыр икән, Әсфан? Кайчагында бөтен нәрсәләрне, җир белән күк арасын аңлыйм кебек. Кайчагында югалам да калам. Дөньяда сораулар күп. Нигә өч ай буе хат язмый тордың?

Әсфан. Больницада ятып чыктым, Фәүзия.

Фәүзия. Больницада? Өч аймы?

Әсфан. Урын өстендә бу юлы озаграк аунарга туры килде. Мине бик каты кыйнадылар, Фәүзия. Кыйный белеп ярдылар.

Фәүзия. Кем кыйнады? Ни өчен?

Әсфан. Узды. Моның әһәмияте калмады хәзер. Кыйналуым, бәлки, файдага гына булгандыр.

Фәүзия. Ә сәламәтлегең? Сиңа яшәргә кирәк ич! Бик озак яшәргә, бик күп эшләргә, ихлас тырышырга кирәк ич сиңа, Әсфан! Саулыгың ничек?

Әсфан. Кыйныйлар икән, димәк, син кемгәдер ошамыйсың. Ошатмагач кыйнаша икән, димәк, ул әйбәт кеше түгел. Акыллы — сүз белән аңлатыр иде, җүләр — йодрыгын йомарлый... Шулаймы? Кемдер тукмап мине буйсындырырга тырыша, мин тыңламыйм, карышам! Карышам икән, үз ихтыярымны эзлим дигән сүз. Ике кабырга сыну әллә ни түгел! Дөрес, сул кулны да беләзек турыннан сындырдылар. Хәзер һәммәсе ялганды. Врач: «Элеккедән дә ныграк булды»,— дип көлә. Ике кабырга бәрабәренә алардан читләшә алуыма мин риза. Хәзер дөньяда Әсфан дигән кеше барын сизәм. Аягы-кулы гына түгел, башы да бар! Йөри, эшли, уйлый.

Фәүзия. Читләшү генә аз, син алардан гомерлеккә котылырга тиеш.

Әсфан. Синнән беләсе тагын бер сүзем бар, Фәүзия.

Фәүзия. Сора, Әсфан. Кулың сызламыймы хәзер?

Әсфан. Сызлаштыра... Монда җәй дә салкын... Авылыгызга кайткач... син... минем турыда уйлый алдыңмы?

Фәүзия. «Авылыгызга кайткач» дип төпченеп соравыңның асылы ни?

Әсфан. Анда авылың. Әнкәң, туганнарың, сеңлең. Сизәм, син аларны яратасың. Таныш урыннар, истәлекле тар тыкрык. Анда синең балачагың.

Фәүзия. Сизәм, син, Чибәркүлне сагына башлагансың.

Әсфан. Белмим, белмим.

Фәүзия. Ә син бел! Бел!

Әсфан. Минем турыда уйларга вакытың калдымы дип кыяр-кыймас кына сораган идем. Моны белеп тору миңа бик мөһим. Чибәркүлдә анда-санда уйлап куюың да гаҗәп түгел! Анда минем әти-әни, авылдашлар. Агыкарасы күз алдында.

Фәүзия. Сеңлем белән синең хакта күп тапкырлар сөйләштек, Әсфан.

Әсфан. Минем кемлегемне, кем булуымны әйтә алдыңмы?

Фәүзия. Кайдалыгыңны яшермәдем. Кемлегеңне...

Әсфан. Асия курыкмадымы? Ике тапкыр хөкемгә тартылган карак, бандит...

Ф ә ү з и я. Мин аңа синең киләчәгең турында күбрәк сөйләдем.

Ә с ф а н. Син үзең миннән ничек курыкмадың?

Ф ә ү з и я. Башта мин синнән бик курка идем. Куркуымны башкаларга түгел, үземә дә сиздермәскә тырыштым. Куркуны кызыксыну җиңде бугай. Белергә теләү җиңде. Бөтен нәрсәне аңлыйсым килә минем. Ничек, нигә алай булган? Син минем чордашым, җирдәшем. Син сулаган һаваны мин дә сулыйм, син йөргән җирләрдә мин дә булам. Аңлыйм, урманда агачлар төрле-төрле. Суда бик күп төрле балык йөзә. Кешеләр дә төрле-төрле... Җинаятьчеләр каян барлыкка килә? Кем сәбәпче аңа? Җәмәгатьчелекме? Әгәр җәмәгатьчелек икән, минем дә гаебем бар булып чыга. Мин дә шушы җәмәгатьчелек вәкиле бит! Синең әтиең мәсьәләне бик ансат хәл итеп куя: җинаятьченең башын кыярга да вәссәлам! Әниең бөтенләй киресен яклый. Өченче булып мин алар арасына килеп кердем һәм барыбызны да берләштерерлек уртак акылны эзләп карадым. Чибәркүл авылы кешеләре. Тарихи бер күмәклек. Борынгы авыл. Шул авылдан япьяшь егетне халыктан аерып куялар. Билгеле бер вакытка! Монысы аерата мөһим! Аның шушы халык арасына кайтасы да бар әле! Димәк... Аның җинаятенең сәбәпләрен эзләгән кебек, аның хәзер ничек яшәве, ни уйлавы белән дә тирәнтен кызыксынырга кирәк. Үткәннәрне һәм киләчәкне ничек уйлый ул? Тоткыннарны эш белән түгел, уй белән төзәтәләр дип беләм. Шуңа аларны яшәп күнеккән шартларыннан аералар. Күнегелгән тормышта кеше еш кына уйлау сәләтен югалта. Эш, ыгы-зыгы белән мавыгып без дә үз арабыздан җибәрелгән кешене онытып бетермик. Ул үзе дә, без дә җинаятьченең киләчәге турында ныклап уйланырга мәҗбүр. Сиңа укырга кирәк, Әсфан. Соңга калдырмыйча тотын. Уйлау өчен бик күпне белергә тиеш син!

Пауза. Музыка.

Ә с ф а н. Фәүзия! Тугызынчы класста укый башладым. Дөрес, уку уен түгел. Күп нәрсә онытылган. Шуның өстенә эш тә бераз авырлашты. Төзелештән шахтага күчерүләрен сорадым. Вертикаль стволны казырга таза-таза егетләр кирәк. Җиңел эшмени? Отбой чүкече көне буе кулдан төшми, смена буена өстән сап-салкын су коелып тора. Врач башта җибәрмәскә маташкан иде дә, ныклап үтенгәч, ризалашты. Норма үтәгәндә монда бер көнне өч көнгә исәплиләр. Сизәсеңме, нинди сикереш ясап була?.. Шул менә. Шахтадан кайтып, юынып, ашап-эчеп алам

да туп-туры класска юнәләм. Тарих белән физиканы ярата башладым. Утырган җирдән авып-түнеп киткән чаклар була. Кыска арада төш күрәм... Төшемә аклы күлмәк кигән син керәсең. Сине күрәм. Гел.

Ут сүнә. Музыка. Пәрдә ачыла. Авыл өе. Гайсә карт белән Мәдәния.

Гайсә. Карап-карап торам да тагын бер карап куям.

Мәдәния. Яратканга карыйсыңдыр, бер дә бүтәнгә түгел.

Гайсә. Идәнеңне кичә генә юган идең түгелме, сиңа әйтәм.

Мәдәния. Җыештырып, тузанын сөртеп чыгаргач, өй һавасы сафлана, сулыш киңәя.

Гайсә. Көн саен шулкадәр көч түгәргә синең яшь чагың түгел.

Мәдәния. Яшь чакларымны сагынып ятасыңмы әллә?

Гайсә. И гомер... Искән җил кебек. Гомеренең бер сызыгында, картайгач димен, адәм баласы җиңеләеп китә диләр. Үз кадереңне белмичә көн-төн чапкан буласың. Тәрәз пәрдәләрен ник алыштырдың? Искеләре нигә ярамаган? Кемгә?

Мәдәния. Матур түгелме әллә?

Гайсә. Матур сыман болай үзе. Бәясе дә бардыр дим?

Мәдәния. Акчасын улым салды. Әсфан. Аның төсе итеп элдем.

Гайсә. Талап алгандыр акчаны дим, төрмәдә эшләгән кешегә кем зарплата бирсен?

Мәдәния. Тырышып эшләсәң анда да югалып калмыйсың икән.

Гайсә. Каян барын да белә башлады бу хатын? Каян бөтен юк-бар хәбәрне җыя башладың? Төшкә хәтле төш сөйли дә төштән соң төш юрый.

Мәдәния. Төшләремне сөйләтмисең генә...

Гайсә. Җыен тузга язмаганны сөйләгәнче, мә, гәҗит укы...

Мәдәния. Син дә чыгып йөр. Хикмәтле сүз ишетерсең. Җаның җиңеләймәсме... Җан авырайса читен кешегә, хәлне ала!

Гайсә. Юри ятмыйм. Теге чакта билем кузгалганнан бирле мантымаганымны беләсең.

Мәдәния. Ышанды ди син карт хәйлә капчыгына! Болай гына ятасың!

Гайсә. Ятасы килгән ди бик... Әле әҗәл чире ки-

ләсе бар. Анда инде сикеренә алмассың. Ятмый хәлең булмас. Бусы болай гына, ялкауландырып кына ауната.

Мәдәния. Гадәтеңә карышу кереп бара, сиңа әйтәм. Берүк дим, Фәүзиянең җаеннан гына тор.

Гайсә. Тора-бара син аның адвокатына әйләндең дә куйдың.

Мәдәния. Күрмисеңмени син бер дә, Гайсә? Күзеңнең нуры коелып беттемени? Әткәй мәрхүм сөйли торган иде. Бер көзне Биш авылына тегермәнгә чыгып китә бу. Юл коры, ат җай гына юрта, мөнәҗәтләр укыштырып бара да бара әткәй. Биш авылына җитеп, тегермән юлына борылганда гына кешеләр дәшәләр моңа: «Әй, кем, Фәйзулла, бер дә артыңа борылып карамыйсыңмыни син, авылыгыз янып бетә ич инде!» — диләр. Шуннан бирле ул безгә гомере буе: «Артыгызга борылып карарга да онытмагыз!» — дип васыять әйтеп килде. Бала элек хат яза идеме? Юк. Туктаган иде.

Гайсә. Шуннан ни мәгънә чыгардың инде син?

Мәдәния. Шөкер дим, хат яза, күрше-тирәгә аермаенча сәламен әйтә. Сихәтлегебезне белешә. Җитешеп акчасын салды. Кем аркасында?

Гайсә (*паузадан соң*). Монда синең белән минем баш җитмәслек могҗиза бар. Әйе, могҗиза!

Мәдәния. Башың югалганга мин гаепleme? Минем баш бик җитә, бик.

Гайсә. Җитеп түгәрәкләнгән башыңда мин белмәгән ниндиен яңа фикер бар алайса?

Мәдәния. Бүгенгесе көндә, белеп кал, Әсфан белән безнең араны Фәүзия ялгады.

Гайсә. Йә, шуннан? Ай-һай, әнкәсе. Куанычыңның азагын аңламыйм. Сүзеңнең тозы таман түгел. Малайның кайтасы юк. Юлының очы-кырые күренми! Фәүзия артыннан су сөлеге егет килеп йөри. Укып кайткан агроном. Әти-әнисе намуслы, атлы-тунлы кешеләр ди. Беркемнәре таплы түгел, чиста икән. Сораштым.

Мәдәния. Әсфан да укыйм дип язган.

Гайсә. Укыталар аңа анда арт сабагын.

Мәдәния. Гел кирегә сукалап, ничек эчең күгәрми?

Гайсә. Юкны бар итәргә тырышуыңны, сынганны «өзелде» дип әйтеп, ялгарга маташуыңны сөймим. Бүген-иртәгә кияүгә чыгасы кыз синең карак улыңа тәтегән ди! Килен итеп бетердең ләбаса! Юкка.

Мәдәния. Ай Аллакайгынам, кем тәтер ди? Алай дигәнем юк. Мәгәр өзеп кире кагасым да килми. Дөнья ул, сиңа әйтәм.

Гайсә. Нигә, алайса, итәк җилфердәтеп, көн дә идән

пычраткан буласың? Ни пычагыма бу пәрдәләрне элдең? Килен төшердеңме әллә?!

Мәдәния. Фәүзия балакаема хөрмәтем зур. Җайсыз чагында улымны хөрмәт итте. Кешегә чутлады.

Гайсә. Хөрмәткә лаекмы ул? Җәзага лаек. Җәза төс аңа. Нигә аның иләс күңелен миләсләндереп маташырга? Барыбер син уйлаганнар барып чыкмаячак, комга язылган. Эшләсен. Эшеннән бүтәнне белмәсен. Аз-маз акылга утырмасмы!.. Бездән булмады. Кулдан килмәде... Мавыкмасын юк белән... Болай, үкенече алда тагын да тирәнгәрәк үтәр. Ахыры ямьсез булыр аның, сиңа әйтәм.

Мәдәния. Үгетлә, үгетләмә, алай ямьсез уйлый алмыйм. Тик, матри, читләтеп тә рәнҗетмә Фәүзияне! Агроном шәп егет, сүз дә юк, мәгәр үз итми ул аны. Өченче көн кинога билет күтәреп килде. Ул киенгән, ул ясанган, әллә күзенә сөрмә дә тарткан инде, хушбуй исе әллә каян аңкый... Бармады Фәүзия, төн ката язып-сызып утырды. Гөл төсле балага чытырман кулың белән кагыласы булма! Берүк җаеннан тор. Теге ташбаш янына, Гөлҗамал Кәбире янына кереп чыксаң да ару. Апаңны кыерсытасы булма, диген, матри, диген. Штубыты әйбәтләп аңлат, яхшылап төшендер. Ярыймы?

Гайсә. Әһем, әһем...

Мәдәния. Тормыш хәлләрен иплəп сөйли башласаң, тамагыңа тора.

Гайсә. Күземә чүп кердеме шунда... Кара әле.

Мәдәния. Чүп кергәнгә шулай чәчәп йөткерәләрме?

Гайсә. Чәпчемә диләр сиңа, канымны кузгатасың.

Мәдәния. Балакаемның исән-аман авылга кайтуын күрә алсам... (*Карап.*) Чүп тә, чурт та юк.

Гайсә. Әсфанның илгә кайтканын күрергә ниятләсәң, азрак саклан. Күп көтәргә туры килмәгәе... Юлы ерак.

Мәдәния. Капкада кемдер бар. Чү.

Гайсә. Ишетәм лә!

Фәүзия керә.

Фәүзия. Гайсә бабай да торып утырган. Куанычка булсын.

Гайсә. Күзгә чүп керде дә, тәрәзә яктысына килим дип калкынган идем.

Фәүзия. Бу арада калкынганыгыз күренмәде.

Мәдәния. Аллакай гынам, нигә алай коры сөйләштең, балам?

Ф ә ү з и я. Шулай сөйләшәсем килеп китте, Мәдәния әби.

М ә д ә н и я. Юньләп йөреп китми шул әлегә бахыркаем. Син өйгә туры кайтмаган, ахры? Идарә тыкрыгына бая син кереп бара идеңме?

Ф ә ү з и я. Туры кайтып булмады, Мәдәния әби. Гөлҗамал апаларга кагылдым.

М ә д ә н и я. Тагын шукланамы, эт колагы?

Ф ә ү з и я. Гайсә бабайдан сора малайның хәлен. Сора, сорамыйча калма, Мәдәния әби.

М ә д ә н и я. Бәрәч...

Ф ә ү з и я. Кичә кичкә кырын Гайсә бабай Кәбирне ишегалдына чакырып керткән дә...

М ә д ә н и я. Иһи, булмасны!

Ф ә ү з и я. Һәм бик шәпләп колагын борган. Менә шулай.

М ә д ә н и я (*чәпчеп*). Ни зыяны тиде аның сиңа?

Г а й с ә. Чүлмәкне ваткач кына чүлмәкче малайны кыйнаудан ни файда? Мин аны болай гына, яратып кына, аванс рәвешендә... Чак-чак кына...

Ф ә ү з и я. Чак-чак кына, ие...

Г а й с ә. Ипләнгәнме? Карышып карасын хәзер.

Ф ә ү з и я. Малай бүген дәрескә килмәде.

М ә д ә н и я. Булыр, булыр. Нык боргандыр, карт мылтык.

Ф ә ү з и я. Тагын бер тапкыр кузгалырга туры килә, Гайсә бабай. Киенегез дә малайдан хәзер үк гафу үтенеп кайтыгыз.

Г а й с ә. Шул килбәтсездәнме, җил-як маңкаданмы?

Ф ә ү з и я. Кеше ул. Бәләкәй гражданин. Хайванны да сыйпап, иркәләп өйрәтәләр. Кешене яманлык белән акылга утыртып булмый.

Г а й с ә. Яшь чагында бөксәң бөгәсең агачны!

Ф ә ү з и я. Бер караганда һәммәсе бик ансат. Бүген колагын бор, иртәгә мәктәптән сөреп чыгар. Котылдың, бетте-китте. Ә кая куасың аны? Кем янына? Колагын борганнан соң дәрескә килмәве ошады. Җебегән салма түгел, егет малай.

М ә д ә н и я. Барып кайт, карт боргыч. Ипләп сөйләш! Гөлҗамалдан оят. Үз балаң, үз малаең шундый булганда...

Г а й с ә. Сыкма балавызыңны!.. Их, балалар ата-аналарына шатлык катыш күпме хәсрәт өстәгәннәрен дә аңласалар икән!

М ә д ә н и я. Үз башларына төшкәч, үз балалары булгач аңларлар...

Г а й с ә. Без күргәнне күрмәсеннәр. Без кичергәнне кичермәсеннәр.

Сәхнә караңгылана. Ф ә ү з и я авансценага чыга. Сәхнәнең икенче ягына Ә с ф а н баскан.

Ф ә ү з и я. Әсфан! Гайсә бабай титаклый-титаклый теге малайдан гафу үтенеп кайтты. Икенче көнне карыйм, малаем тып-тын гына кереп килә. Дәрестә дә шауламады. Тәнәфестә минем янга килеп баскан да дәшми. Мыш-мыш килә, әмма сүзе-өне юк. Чәченнән сыйпадым. Бүтән чаклардагы кебек башын чайкап читкә китмәде, әмма барыбер дәшмәде.

Ә с ф а н. Мин аңа өч хат яздым инде. Әйтмәдеме?

Ф ә ү з и я. Бөтенләй сөйләшмәде.

Ә с ф а н. Минем өчен иң куркынычлы хатны язгансың, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Нәрсәдән куркасың, Әсфан?

Ә с ф а н. Теләгәнеңә ирештең. Бер тәртипсез малайны акылга утыртуны максат итеп куйган идең бит. Күрәм, хәзер сез дуслар. Инде шушында туктыйбызмы?

Ф ә ү з и я. Әгәр мин малайларның икенчесен дә акылга утыртырга теләсәм?.. Мин синең дә дустың түгелмени? Кәбир сиңа дус түгелме? Гади генә бер проблеманы хәл итүгә дөньяның бөтен яклары почмакланды дип ышанырга мин беркатлы сабый түгел. Үз язмышы азмы-күпме җайга салынуга, шөкер, дөнья һәр тарафтан төзәлде, дип ятучы ахмаклардан түгелмен, Әсфан.

Ә с ф а н. Чуалып беткән дөньяны төзәтмәкче буласыңмы? Син?!

Ф ә ү з и я. Нигә мин генә? Минем юлда кыен хәлдә калган син булдың, Әсфан. Башкаларга бүтәннәр очрар. Фикердәшләремне еш очратмасам да, аларның барлыгын белеп, шуңа куанып яшим. Бер чакта да ялгыз калмадым.

Ә с ф а н. Син үзеңә дә авыр юл сайладың...

Ф ә ү з и я. Әсфан, мин синең срогыңны кыскартуны үтенеп Верховный Советка хат яздым.

Ә с ф а н. Бусы артык... Кирәкми иде.

Ф ә ү з и я. Ник?

Ә с ф а н. Файдасыз. Бу турыда әтиләргә белдермәдеңме?

Ф ә ү з и я. Белдермичә генә алар исеменнән яздым.

Ә с ф а н. Авылдагы җинаятем авыр иде, мондагысы аннан да яманрак. Тоткында ясалган җинаять бик авыр санала. Моның өчен баштан сыйпамыйлар. Кеше бер тапкыр җәзага тартыла... Үз юлын яктыга борасы урынга

икенче тапкыр сөрлегә... Мондый очракта җинаятьчегә ташлама юк.

Фәүзия. Син үзгәрдең.

Әсфан. Моны ничек раслый аласың? Кемгә?

Фәүзия. Сәламәтлегең какшаган хәлдә шахтага эшкә күчтең. Ничә айлар планны тутырасың. Нормаңны арттырып үтисең. Укып белем аласың! Уйлап карасыннар!

Әсфан. Син моны эти-әни күңелен күреп кенә эшләдеңме? Әллә мине кызганасыңмы?

Фәүзия. Йогышсыз сүз ычкындырдың, Әсфан! Без дуслар түгелмени?.. Их, егет, егет! Нигә хат язмыйсың? Нигә тукталдың?! Кая югалдың?.. Ә минем көннәр шундый күңелле уза! Атна үткәнен сизми дә калам. Мәктәп, класс... Нигә хатың юк?! Алтынчы класслар колхоз бәрәңгесен чүпләргә бардык. Хезмәт хакыбыз Тынычлык фондына! Ә дөнья тыныч түгел!.. Балаларда нинди куаныч тудыра күмәк хезмәт!.. Күмәк хезмәт, уртак эш балалар дуслыгының нигезе ул, Әсфан. Шулаймы? Минем алтынчы класс җитәкчесе икәнемне онытмагансыңдыр бит?.. Кәбир быел җәй үсеп, җитдиләнеп китте. Бүген әйтеп тора: «Апа, үскәч, колхозда калам, комбайн йөртергә исәп»,— ди. Мин бик куандым. Кыскасы, һәммәсенә өлгерергә тырышабыз. Нигә хатың юк? Концерт әзерлибез. Мин беренче мәртәбә сәхнәгә җыр белән чыгарга уйлыйм. Сиңа ул җырны языйм әле... (*Җырлый.*)

Ал яулыгым, ал яулыгым
Давылларда, җилләрдә;
Күңелләремә кердең син
Мәңгелеккә, тирәнгә.
Ал яулыгым җилләрдә...

Ал яулыгым, ал яулыгым —
Таңның ал нуры төсле.
Сандугач җырын тыңласаң,
Шул минем моңым төсе.
Ал яулыгым, ал яулыгым!..

Ал яулыгым, ал яулыгым!
Казаннарда юк ише.
Үзем таптым, үзем сөйдем,
Гаҗәпләнә күп кеше.
Мәхәббәтнең юк ише...

Әсфан. Кәефем шәп дип язасың, Фәүзия. Тормышым түгәрәк, көннәрем нурлы дисең. Нигә җырың моңлы?

Ф ә ү з и я. Мин сиңа байтактан бер сүз язарга теләп йөрим.

Ә с ф а н. Кирәкми, язма. Яза күрмә. Аңлыйм, Фәүзия. Авылдан яздылар инде. Исемсез хат килде. (*Фәүзия көлә.*) Көлмә, көлмә. Авылга яшь агроном килгән икән. Сөнгать исемле. Синең арттан бик нык йөри икән. Армиядә булып кайткан чибәр егет ди. Ни теләсәм дә яман сүз әйтә алмыйм. Нигә көләсең?

Ф ә ү з и я. Мин синең янга барып кайтырга җыенам, Әсфан... Күрешергә рөхсәт бирәләрдер бит? Ә син Сөнгать дисең...

Ә с ф а н. Минем янга? Күрешергә?.. Туганнары килә. Якыннары килә. Хатыннары да килгәли. Аларын беләм... Шулай кирәктер, тәртибе шулдыр... Ә син?!! Минем янгамы?

Ф ә ү з и я. Уйлама әллә ниләр. Әниеңне дә алып барырга телим. Ул сине бик сагына. Бик! Элек сагынганын әйтә иде, хәзер әйтми дә. Сагыну артык тирәнгә китсә, кеше аны сүзсез генә кичерә башласа, хәл яман! Үтә яман! Нигә җавабың юк?!

Ә с ф а н. Биш ай гына килми тор, Фәүзия. Биш ай! Мин хатымны шушы урында бүләм. (*Ашыгып, кабаланып.*) Мәҗбүрмен...

Фәүзия кереп китә. Авансценада Ч а л күренә.

Ч а л. Мине ни өчен Чал дип атаганнарын беләсеңме?

Ә с ф а н. Кушаматсыз карак булмый.

Ч а л. Берәүләрне «Чүкеч», икенчеләрне «Кувалда» дип атыйлар. Чал дип мине акыллы булганым өчен атадылар. Миңа моннан котылып китәргә биш ай калды. Биш ай!

Ә с ф а н. Акыллы җан иясе тугры дустын кыйнатып ике кабыргасыз калдырамы?

Ч а л. Башкача чара юк иде! Әйтәм бит, тиздән ялга чыгам! Акча ягы такыр... Һаман язышасызмы?

Ә с ф а н. Язышсак ни әйтерсең?

Ч а л. Каушама. Тимим мин сиңа, башкалардан да тидермим. Ахыр чиктә, теләгәнеңне эшлә! Аннан кемгә ни зыян?.. Да, шахтада тир агызып йөз сулган синең. Әллә сагынуданмы? Алдый ич ул сине, алдаша!

Ә с ф а н. Алдашмый! Чын кеше. Ихлас дус.

Ч а л. Исбатла! Хатлар исбатмы?.. Фи-и, теләсәм мин андый хатларны көн дә дистәләп алам!

Ә с ф а н. Ялгышма, Чал. Хат язучы юк сиңа. Юк. Үзең дә яза алмыйсың. Чөнки язар сүзең юк. Дәлил диденме? Фәүзия минем янга килергә җыена.

Ч а л. Ачыкланды. Фәүзияң кеше күзе төшмәслек ямьсез синең! Яки... Үтә чыккан бозык кыз. Кеше калдыгы!

Ә с ф а н. Чал, тукта!

Ч а л. Миннән башка син кемгә кирәк?! Бөҗәк! Тузан бөртеге! Синең ишеләр көненә меңәрләп туа. Кырмыскалар. Коллар! Фу-у! Чын ирне яралар бизи! Җинаять дип аталган батырлык бизи. Менә син бүгенгә кем? Юеш ыштанлы шахтер. Шахта базына төшү өчен төрмәгә керергә кирәк идеме сиңа? Иректә дә ирешә ала идең ул ләхеткә. Төрмәдә анда, җаным, идея өчен утыралар.

Ә с ф а н. Әллә синең дә идеяң бар?

Ч а л. Минем идеям — тир түкмичә, хезмәт куймыйча гына яшәү. Эш яраткан ишәкләрнең татлы калҗасын тартып алып ашау. Синең төсле умырткасыз бөҗәкләрне үз артымнан иярү. Караклык бер чакта да очраклы хәл түгел, ул да, үзенә калса — политика! Ух, күрәсе иде синең кәнтәй әнчегеңне! Буш сүзләр белән сине, өметле каракны, хак юлдан чыгарган юләрне!

Ә с ф а н. Политикаң белән ни казандың? Нинди югарылыкка ирештең?

Ч а л. Син нәрсәгә ирешермен дип беләсең? Шалишь! Авылыгызга кайта алмыйсың, анда син — карак. Гомер буе карак, бур. Үзеңнең генә түгел, нәселеңнең, балаларыңның кушаматы «Карак!», «Әнә, бур Әсфан малае бара!» — дип, кызлы аналар абына-сөртенә тәрәзә пәрдәсен томалап куячак. Эшкә керә башласаң — карак. Керсәң дә — карак! Квартира ала башласаң — карак. Перспективаңны белмиме әллә ул ахмак кыз? Белә! Институт бетергән! Барын да белә. Психологик тәҗрибәләр үткәрә, имеш. Өметләнмә, килми ул. Килсә, башымны кисәргә бирәм, йә бик ямьсез, яки...

Ә с ф а н. Килер. Киләчәк! Мине күрергә килә. Синең янга берәү дә килмәячәк. Аерманы чамаладыңмы? Хәзер, эндәшмә, аны хурлап бер генә, сыңар гына сүз ычкындырсаң да үзеңә үпкәлә. Курыкмыйм синнән! Белмәгәндә генә курка идем синең ишеләрдән. Хәзер курыкмыйм! Минем янга кыз килә! Синең янга юк! Дәшмә, яңа срок аласым килми. Акыллы бул, сабыр гына иреккә чык! Кыздырма мине, җинаятькә этәрмә!

Икесе ике якка кереп китәләр, авансценага Ф ә ү з и я чыга.

Ф ә ү з и я. Әсфан «килми торыгыз!» дип бик нык үгетләсә дә без озакламый юлга әзерләнә башладык. Тәкатем калмаган иде, аны бик күрәсем килде. Бик! (*Кереп китә.*)

Пәрдә ачыла. Өйдә Г а й с ә  к а р т белән М ә д ә н и я.

Г а й с ә. Юлга шушы чемоданны алырсың. Ныкча да, җиңел дә.

М ә д ә н и я. Бармам, ахрысы, мин анда.

Г а й с ә. Менә син, агай...

М ә д ә н и я. Ничек итеп Фәүзияне алып барыйм ди?

Г а й с ә. Үз ихтыяры белән бара, көчләгән кеше юк. Нишләп читенсенәсең? Малаеңны богаулап читлеккә салмаганнар, шахтада эшли.

М ә д ә н и я. Эшләмәсә? Әгәр һәммәсе уйдырма булып чыкса? Әсфан үз ишләре яки аннан да яманраклар белән елышып яшәсә? Шул чакларда Фәүзия кызымның күзләренә ничекләр күренермен?

Г а й с ә. Әсфаның сезнең күзгә ничек күренер, ныграк аны уйла. Миннән яшереп посылкалар салып яттың. Тире камзулымны җир йотты. Әйтмичә хатлар яздырдың. Мин аннан ныклап йөз чөергәндә, син аны канат астыңа алдың. Шуларның да кадерен белмәсәме?

М ә д ә н и я. Сиңа әйтәм, моңарчы Әсфанга гел кире ягың белән тордың. Хат язышуларын өнәмәдең. Нигә хәзер «бар!» дип өзмәс кыстыйсың? Ник үзең бармыйсың?

Пауза.

Г а й с ә. Утырчы, карчык. Чемоданыңны куеп тор. Сөртеп тишеп бетерәсең бугай. Ник димсең... Шуны аңламагач... Күпме шатлык уртаклашкан, ничаклы хәсрәт бүлешкән картыңны аңламас хәлгә килдеңме? Әсфан алды синең барлыгыңны. Тоткынлыкта әлсерәп яткан балага шундый уңган, ягымлы кызның хат яза башлавына мин сөенмәгән дисеңме? Төннәрен түшәм санап ятканнарымны үзем генә беләм. Бу дөньядан төпчек улымны кеше итмичә китәм икән дип күпме вакытлар кайгырып йөрүемне сизгәнсеңдер... Өметем шартлап өзелде дигәндә, шушы кыз бала фатирга керде... Кызы бит, кызы! Алтын. Саф! Агроном егетне ничек борып җибәрде... А-а, горур, чая... Чибәр... Нинди югарыда ул, ә минем улым кайда? Йә, кайда? Әйт! Тегендә, тормыш төбендә. Маңгаенда мөһере. Улымның түбәнлек газабын тагын бер тапкыр, яңа рәвештә, ачыграк итеп татымасын өчен мин аларны язышты рмаска теләдем. Аралары тиз суыныр дип шикләндем. Аерма бик зур бит, карчык. Бер-ике хат язар да туктар, мәйтәм... Туктаса Әсфанга ни булырын чак кына чамалыйсыңмы? Шәйлисеңме, карчык?

М ә д ә н и я. Нигә боларны элегрәк миңа аңыштырмадың, сиңа әйтәм?

Гайсә. Үзең белми идеңме әллә, Мәдәния?

Мәдәния. Үзең бар да кайт, сиңа әйтәм.

Гайсә. Их-ма, карчык. Билемне печән төшергәндә кузгаттым дип мин сиңа дөресен әйтмәдем. Бил байтактан сызлый, авырта. Син аны бары тик кеше күзенә чыгарга оялып, качып ята дип кенә уйладың. Хак, ил-күрше күзенә кара шырпы булып кадалып йөрисем дә килмәде. Чирем дә бик җитди, бик тирәндә... Әллә кай тамырларыма тикле сызлый. Әҗәл чире килмәдеме икән дим? Юл йөреп тә әллә ни куандырып булмас. Юкса өйдә ятар идемме, Мәдәния. Бөтен буыннарым туңа, өши. Тәндә быҗыр-быҗыр салкын, чит ут йөри.

Мәдәния. Чирнең бәләкәе кагылса да күңелгә шик төшә. Картлык галәмәте.

Гайсә. Үз-үземне беләм.

Мәдәния. Алай авырырга исәп тоткач, ничек дип сине ташлап чыгып китим?

Гайсә. Кызларның берәрсен чакырырбыз. Тик син анда, малайга дим, атаң авырый дип ычкындырма. Башта яхшылап тикшер — хәбәрне кабул итеп алырлыкмы? Кеше хәсрәтен аңларлык булганмы? Әллә аңа ата-ана бөтенләй чүп тә күк түгелме?

Мәдәния. Гомергә беркая йөрмәгәнне, картың хаста чакта чыгып кит инде.

Гайсә. Ничек тә түзәрмен. Улың хаста анда, улың... Күзеңне яшь капламасын, яхшы кара, барын белеп, аңлап кайт.

Мәдәния. Чамасыз сагындым, җыламый да булмас. Рөхсәт итәсеңме?

Гайсә. Яман юлда икән, Фәүзия безгә үпкәләмәс. Бергәләп алдандык бит. Акыллы кыз ул. Безнең дә, аның да Әсфан алдында гаебе юк. Аның гаебе зур. Әгәр тагын өстәсә, бетте дигән сүз.

Пәрдә төшә. Музыка. Авансцена буйлап өчәү атлыйлар. Кулларында төен, чемодан.

Гайсә. Барыр юлыгыз да, кайтыры да уң булсын.

Фәүзия. Уң булырына ышанам.

Мәдәния. Алай ук өзеп әйтмә, кызым.

Фәүзия. Гайсә бабай, без Әсфанны алып кайтырга барабыз.

Гайсә. Биреп үк җибәрмәсләр шул.

Фәүзия. Үзе калып торса да җаны ияреп кайтыр, күңеле! Әгәр бик сагынса, үзе дә озакламас. Сагына алган кешенең җегәре арта, Гайсә бабай!

Гайсә. Изге юлга!

Үтеп китәләр. Пәрдә ачыла. Җыйнак кына бер бүлмә. Ф ә ү з и я белән М ә д ә н и я керәләр.

М ә д ә н и я. Фәүзия кызым, мин бик каушадым. Ни әйткәннәрен аңлап җиткермәдем.

Ф ә ү з и я. Шушында көтәргә кушты, Мәдәния әби. Биш-ун минуттан документларыгыз белән керерсез, диде.

М ә д ә н и я. И-и, рәхмәт яугыры. Әсфан тиз кайтыр дидеме?

Ф ә ү з и я. Эш көне тәмамлангач булыр инде анысы.

М ә д ә н и я. Бу нинди йорт диделәр?

Ф ә ү з и я. Туганнар, якыннар килсә, монда туктала-лар икән.

М ә д ә н и я. Синсез гомергә килеп табасы түгел икә-нмен.

Ф ә ү з и я. Мин булмасам, башка берәү табышыр иде.

М ә д ә н и я. Без киләсене белгән, эшкә китеп барган.

Ф ә ү з и я. Бармыйча ярамагандыр. Ярышка чыктык дип язган иде.

М ә д ә н и я. Тәгаен шушында көтәргә куштылармы?

Ф ә ү з и я. Шушында, шушында. Чак кына утырып тор, Мәдәния әби. Мин тагын комендант яныннан урап чыгыйм.

М ә д ә н и я. Озак торма.

Ф ә ү з и я. Әллә куркасың инде, Мәдәния әби?

М ә д ә н и я. Әллә нигә җаным тыныч түгел.

Фәүзия чыгып китә, Ч а л керә.

Ч а л. Исәнме-саумы, әбекәй.

М ә д ә н и я. Исән-сау гына йөрисеңме, балам.

Ч а л. Сез, мөгаен, Әсфанның әнисе буласыздыр. Шуңа охшагансыз.

М ә д ә н и я. Син аны беләсеңмени?

Ч а л. Белмичә, бергә эшлибез бит.

М ә д ә н и я. Әллә эштән кайттыгыз да? Кайда ул?

Ч а л. Хәзер кайтып җитәр. Исән-сау. Җир җимертеп эшләп йөри.

М ә д ә н и я. Җир җимертеп дисеңме?

Ч а л. Безгә башкача ярамый!

М ә д ә н и я. Һай, рәхмәт төшкере. Эшне ярата шул ул!

Ч а л. Исеме почет тактасында. Миңа ял бирделәр. Бүген-иртәгә илгә китәргә дип торам.

М ә д ә н и я. И-и, балам! Эшләгән кешегә ялы да кирәк бит аның. Кая берәр күчтәнәч бирим әле үзеңә.

Ч а л. Рәхмәт, әбекәй, кирәкми. Бернигә мохтаҗлыгыбыз юк. Эшлибез. Эшләгәч, акчасы да төшә... Син ялгыз гына килдеңме әллә, әбекәй?

М ә д ә н и я. Кая ди ялгыз, үзебезнең мөгаллимә кыз белән бергә килдек.

Ч а л. Капка төбендә бер аксак хатын тора, шулмы әллә?

М ә д ә н и я. Ниткән аксак булсын? Чибәрнең-чибәре. Уңган, юмарт җанлы, әүлиядәй холыклы. Кулыннан килмәгән эше юк. Инде башы-ахыры хәерле булсын, күктән төшкән бәхет дип, карт белән икәүләп, әле аптырап, әле хәйран калып ятабыз. Әсфаныбыз болай булып китмәсә...

Ч а л. Игелекле, әйбәт кыз, алайса?.. Сезне күргәч күңел тулып китте, әбекәй.

М ә д ә н и я. Ата-анаң бармы-соң, кайдалар?

Ч а л. Юк, әбекәй, ятим шул мин, үксез. Шул ятимлек явыз кешеләргә иптәш итте дә. Ялгыштым! Башны ташка орырлык булып ялгыштым! (*Күз яшьләрен сөртә.*) Терсәкне тешләр идек, ерак.

М ә д ә н и я. Инде моннан болай Ходай тәүфыйклы гомер бирсен дип телә.

Ч а л. Илгә генә кайтыйм! Ике куллап чытырдатып яраткан һөнәремә ябышам! Гаилә корып җибәрәм. Монтер мин. Электр эшен бик яхшы беләм. Кулымның җитезлеге бар. Машина йөртәм. Трактор белән дә дус!

М ә д ә н и я. Алтын куллы икәнсең.

Ч а л. Белгәннәр шулай диләр... «Аның кулы!» диләр... Ирекнең кадерен белмәгәнбез, әбекәй. Их, әбекәй, тиле булганбыз. Юлдашың кая китте?

М ә д ә н и я. Кантурга керде. Документларны күрсәтергә. Әсфаннар озак юанырмы икән анда?

Ч а л. Сменалары озакламый бетә. Әбекәй, бу укытучыгызның кияве бармы? Аерылып кайтканмы?

М ә д ә н и я. Юк, балам. Кыз кеше. Авылыбызда берәүгә дә карамады. Торыплар шаккатабыз инде. Әсфаныбызны якын күрде.

Ч а л. Бәхетләре булсын. Кавышсыннар, шәп яшәсеннәр.

М ә д ә н и я. Котым чыгып килгән идем, монда да ару кешеләр бар икән. Рәхмәт инде сиңа, улымны якын күргәнең өчен мең рәхмәт. Балаң турында кем авызыннан да яхшы хәбәр ишетәсе килә. Алдагы көнегездә дә бер-берегезне ташлашмагыз.

Ч а л. Әсфан кайтуга чәй куеп җибәрим әле.

М ә д ә н и я. Һай, бигрәкләр дә ягымлы бала икәнсең!

Чал, чыгып барганда, Ф ә ү з и я белән очраша.

Ф ә ү з и я. Мәдәния әби, урнаштык. Без шушы бүлмәдә кунабыз. Әсфан белән дә монда күрешәбез. Бу нинди куркыныч кеше? Абау, күзләре нинди ямьсез.

М ә д ә н и я. Алай димә, балам. Бик игелекле, бик йомшак телле, бик ягымлы кеше. Сөйләшкәндә өзелепләр китә инде менә.

Ф ә ү з и я. Кемдер кереп килә.

М ә д ә н и я. Әсфан, улым!

Ф ә ү з и я. Алдан син күреш, Мәдәния әби.

Ә с ф а н керә.

Ә с ф а н. Әни!

М ә д ә н и я. Улым, балам, йөрәк маем...

Ә с ф а н. Кара, әни, игелексез улыңны күр.

М ә д ә н и я. Улым, менә Фәүзия дә минем белән килде. Үзем генә һич эзләп табасы түгел икәнмен. Ярый аны иярткәнмен.

Ә с ф а н. Саумы, Фәүзия. Хуш килдегез.

Ф ә ү з и я. Исәнме, Әсфан.

Ә с ф а н. Шулай, ал яулыклы итеп күз алдыма китерә идем. Мин менә шушында инде. Шундый-шундый безнең хәлләр.

Ф ә ү з и я. Мин сезнең икегезне калдырып торам. Ярыймы, Мәдәния әби.

М ә д ә н и я. Нигә алай итәсең? Читме син әллә безгә?

Ф ә ү з и я. Икәү генә сөйләшәсе сүзегез булыр.

Ә с ф а н. Сүз баштан ук уртак булсын, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Ана белән бала очрашкан. Әле без дә сөйләшеп өлгерербез. Төн озын. Алдагы төн безнеке.

Ә с ф а н. Иртәгәге көн дә безнеке. Бер көнгә ял сорадым, икене бирәләр иде, көне кызганыч!

Ф ә ү з и я. Мин тирә-як белән таныша торыйм. (*Чыга*).

Ә с ф а н. Әни!

М ә д ә н и я. Улым, балам... Кошлар очып җитмәс җиргә насыйп икәнсең.

Ә с ф а н. Әни, без хәзер ул турыда сөйләшмик. Мин аны мең дә бер кат уйлаган. Мең кат кайгырырга өлгергән. Бала түгел инде мин. Очрашкан минутта ук мең дә икенче кат кайгырышып, бер-беребезнең хәсрәтен куертмыйк. Сез килдегез, рәхмәт. Әти ни хәлдә?

М ә д ә н и я. Атаң әллә кем түгел. Бирешмәскә маташа, әмма бик бетеренде, утә йончыды.

Ә с ф а н. Мин кайтканчы яши күрсен. Хәсрәтне сезгә

вагоны белән кайтарып аудардым. Ярдәмнең дә иң зурын мин күрсәтергә тиеш. Исән була күрегез!.. Монда әлләниләр уйлап ятам, әни. Кайтам, Чибәркүлгә кайтам!

Мәдәния. Күкрәгемнән таш төште, улым. Кайтсаң, котәбез генә!

Әсфан. Авылда ниләр бар? Туганнар ни хәлдә? Апалар? Ил-күрше? Бер генә нәрсә үкенечле, аз гына соңрак килә алмадыгыз! Ул китеп өлгермәде... Хәер, китерәсем дә килде шул. Әни, әни...

Пәрдә төшә. Безгә таныш музыка яңгырый. Авансцена буйлап туктаусыз елмаеп Фәүзия бара, Чал белән очраша.

Чал. Син кем? Кем дип сорыйм мин синнән?

Фәүзия. Укучыларым сездән күпкә яшьләр. Алар да миңа «сез» дип эндәшәләр.

Чал. Онытылып киттем. Димәк, сез педагог?

Фәүзия. Әйе. Исемем Фәүзия.

Чал. Анысын беләм.

Фәүзия. Кызык.

Чал. Монда иң тешләк кешеләрнең дә сере чыкмый калмый. Һәркем тормышын, үткәнен сөйләп бирә. Сөйләмәсә, сөйләтәләр! Сез киләсен мин әллә кайчан белеп тора идем.

Фәүзия. Тавышыгызда явыз киная ишетәм.

Чал. Мин хатын-кыз җәмгыятеннән күптән аерылган.

Фәүзия. Бик күптәнме?

Чал. Соңгы звонокны көтәм.

Фәүзия. Моннан кешеләр нинди уй белән чыгалар? Һәркем үзенчәдер, әлбәттә, әллә уртаклык та каламы?!

Чал. Кем бу сорауга җавап бирә алсын? Киләчәкне кем белгән? Ахмаклар сөйләнгән булыр, акыллы дәшмәс... Киләчәк караңгыда... Үзегезне күргәнче сезнең хакта бер фикердә идем, күргәч уй үзгәрде дә куйды.

Фәүзия. Димәк, сез Әсфанны якыннан беләсез?

Чал. Күрендегез дә әллә нишләттегез мине.

Фәүзия. Әсфан турында сораган идем... Хәер, сөйләмәгез. Мин сорамадым.

Чал. Әсфанның ник авылга кайтмаганын беләсезме?.. Табигате белән карак бит ул! Монда да чак эләкми калды!.. Мин шушы арада ялга чыгам... Илгә кайтам.

Фәүзия. Әсфан да озакламас, кайтыр.

Чал. Сез педагог... Бер күрүдә мәхәббәт тууына ышанасызмы?

Фәүзия. Нидер әйттегез бугай?

Чал. Ни карыйсыз анда?

Фәүзия. Ул якта күл, ахрысы? Үрдәкләр оча.

Чал. Тыңла, мин сине ошаттым. Яраттым мин сине!

Фәүзия. Рәхмәт.

Чал. Рәхмәттән тун тегеп булмый. Моңарчы җаныма беркемнең хуҗа була алганы юк иде. Кеше җанына хуҗа булырга үзем чос идем! Синең Әсфаның бөҗәк!.. Кеше итәм дигәндә, читләште. Кайсы остасы минем тәрбиямнән тартып алды дисәм... Йа Алла! Фәрештәдәй кыз! Мин сиңа хуҗа булырга һәм кол булып ялланырга телим!

Фәүзия. Сез илгә явызланып кайтасыз икән! Кызганыч. (*Китә башлый.*)

Чал. Кая?

Фәүзия. Әсфан янына барам.

Чал. Кем янына, кем? Ха-ха-ха! Адәм көлкесе!

Фәүзия. Көлсәгез дә күзләрегез салкын кала.

Чал. Нигә килдең монда? Кеме син аның? Кем син! Кем дим? Беләсем килә. Нигә безнең күзне кыздырып йөрисең? Беләсеңме, син минем бөтен идеалларымны, ышанычымны, егетлегемне, горурлыгымны җимереп ташладың!.. Кем янына килгән бит! Бөҗәк, гыйбад янына! Хурлык!

Фәүзия. «Кеме син» дигәнгә җавабым бар. Җирдәше, якташы, дусты. Җиттеме? (*Чыга.*)

Чал. Аһ! (*Чыга.*)

Пауза. Музыка. Пәрдә ачыла. Әсфан белән Фәүзия.

Әсфан (*әнисе яткан карават янына барып килә*). Йоклый...

Фәүзия. Юл буе керфек тә какмады. Юл буе сөйләшмәде диярлек. Борчылды.

Әсфан. Йокласын. Тимә.

Фәүзия. Өстенә әйбәтрәк итеп ябам.

Әсфан. Дөрес. Бездә салкынча. Борчылды дисеңме?

Фәүзия. Янды, көйде, тамактан калды. Монда ни көткәнен күз алдына китерә алмады бит ул.

Әсфан. Ә син, Фәүзия?

Фәүзия. Төрлесе булды, Әсфан... Борчылдым да, борчылмадым да. Икесе дә тигез булды.

Әсфан. Рәхмәт. Миңа ышануың өчен рәхмәт. Кеше итеп санавыңа рәхмәт. Ай, төче сүз сөйли башладым... Син килерсең дә, җебеп китеп, юк-бар сөйли башлармын дип курка идем.

Ф ә ү з и я. «Хуҗа итеп куйдым акылны», диден. Ниләр уйладың? Киләчәкне ничек күз алдына китерәсең?

Ә с ф а н. Киләчәк чакыра, ашыктыра.

Ф ә ү з и я. Теге усал күзле кешене күрдем дә, шул бутап ятмадымы икән сине дип шикләндем.

Ә с ф а н. Акыллы син! Китә ул, тиздән югала.

Ф ә ү з и я. Ул да гадел юлын тапсын... Бәби табу йортларында көнгә ничә бәби тууын статистика төгәл санап бирә. Куанышабыз... Рәшәткәле тәрәзәле йортлардан кемнәрдер борылып кайтып безнең арага катнаша торалар. Бер агымга кушылалар. Кемнәр алар? Кем каршылый аларны? Ничек итеп? Шулар турында да уйлыйм.

Ә с ф а н. Ничек яшәдең, ничек яшәргә җыенасың диден... Кайчангысын беләсең килә? Синең белән танышканга кадәрме? Әллә белгәннән соңмы?

Ф ә ү з и я. Моның әһәмияте шулай зурмы?

Ә с ф а н. Сине белгәнгә кадәр башка кеше идем, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Син яңадан тудың, сизенәм. Әнә бәләкәй Кәбир дә башка хәзер.

Ә с ф а н. Башта ачуым чыкты. Ник кеше тормышына тыкшынып маташа, димен. Укытучы булгач өйрәтергә ярата, дип каһәрләдем.

Ф ә ү з и я. Минем хатын-кыз булуымны исәпкә алмагансың, Әсфан. Хатын-кыз — тудыручы. Дөньяга яңа көч өстәүче зат. Мин синең яңадан тууыңны теләдем.

Ә с ф а н. Сине белгәнче бер катлы җүләр булганмын! Утырып чыгам да, Себер тайгасына китеп олагам, имеш. Әти-әнигә хат язмыйм, туганнарга кайдалыгымны белдермим, имеш. Һәммәсен кырт өзәм дип уйладым.

Ф ә ү з и я. Җиңел хәл иткәнсең.

Ә с ф а н. Хат ала башлагач күңел әллә нишләде. Ул чакта төзелештә эшли идем. Бермәлне подвалга инструментлар алырга төшеп барам, ашыгам шулай, «шап» иттереп маңгаем белән тимер өрлеккә бәрелдем. Күземнән ут чәчелде. Карасам, кемдер акбур белән өрлеккә зур итеп «О, милая!» дип язып куйган. Авыртуым онытылды, шушы бер сүз, ышанасыңмы, бары бер сүз җанымны тетрәтте. «И, сөеклем!» дигән бер сүз! Маңгаемны уып утырдым да, шушы бер сүзне язган кешенең тиңдәшсез зур сагышын, хисләренең чамасыз олылыгын күз алдыма китереп карадым. Җыламаган, җырламаган, эре хәрефләр белән тик бер сүз язып калдырган.

Ф ә ү з и я. Бөек француз язучысы Виктор Гюго Париждагы Алла анасы хөрмәтенә салынган атаклы собор стенасына тырнап язылган бер сүздән гүзәл Эсмеральда

һәм бөкре гашыйк Квазимоданың гаҗәеп тарихын уйлап чыгарган.

Әсфан. Нинди сүз булган ул?

Фәүзия. Рок. Язмыш.

Әсфан. Бер сүз кешене тетрәтә ала... Ә син миңа хатларың аша күпме бөек сүзләр бүләк иттең!.. Онытырлыкмы соң?!

Фәүзия. Беренче тапкыр рәсемең белән очрашкач, миңа да әллә ни булды. Рәсемеңдә елмаясың, ә хатка язган сүзләрең сап-салкын, усал, өметсез. Җан өшеткеч хатлар яза идең бит башта! Шул чак балачак хатирәләреннән берсе искә төште. Безнең авыл Кыр ягында, Әсфан, урманнар юк. Тау арасында чишмә агып ята, Бүзат чишмәсе. Тауга җиләк җыярга мендек тә, тамагым кипкәч, су эчәргә киттем. Иелеп эчәргә генә уйлыйм, кемдер колагыма: «Эчмә! Эчә күрмә!» — дип пышылдаган төсле. Чишмә шулкадәр эчәсене китереп көмеш сыман чылтырап агып ята инде!.. Кушучлап алыйм дип иеләм, кемдер итәгемнән тарта кебек. «Эчмә, эчә күрмә!» Күтәрелеп карасам, чишмә башындагы кәкре өянкедә бөгәрләнеп кап-кара җылан ята. Чыр-р иттереп кычкырдым да, тырысымны атып бәреп йөгереп качтым... Хатларың килә, рәхимсез суык хатлар. Шул чак нигәдер тал арасында бөгәрләнеп яткан, су агышын мыштым гына күзәтүче кара җылан күз алдыма килде бит.

Әсфан. Тормыш матурлыгын мин синең аша аңладым.

Фәүзия. Хәзер мин сиңа чәй әзерлим. Куе итеп, татарча эчик әле бер. Тәмле әйберләр белән сыйлыйм. Аннары син аз гына черем итеп алырсың. Чәкчәк яратасыңмы?

Мәдәния карчык саташып уяна.

Мәдәния. Кит, кит! Якын килмә!

Әсфан. Ни булды, әни?

Фәүзия. Тынычлан, Мәдәния әби.

Мәдәния. Уф Алла. Шабыр тиргә батканмын. Төшемдә... баягы кеше балта тоткан да өстемә килә... Йөгерә генә башлыйм, абынам да егылам. Шуннан теге кеше кап-кара җыланга әйләнде дә юан талга уралып ятты.

Фәүзия. Курыкма, Мәдәния әби, монда берәү дә юк, үзебез генә. Гайсә бабайга иртән телеграмма сугарбыз. Тор, бергәләп чәйләп алыйк.

Әсфан. Монда бик тыныч, әни. Әйдә, рәхәтләнеп чәй эчик.

М ә д ә н и я. Тыныч була күрсен, балам. Берүк шулай булсын!

Пәрдә төшә. Музыка. Авансценага Ф ә ү з и я чыга.

Ф ә ү з и я. Елга ел охшамый шул. Быел әллә нинди ел булды. Майдан бирле бер тамчы яңгыр төшмәде. Юкә чәчәкләре ачыла алмыйча бөрешеп киптеләр. Яфраклар июньдә саргайды. Июль аенда урман сукмаклары сары яфраклар белән түшәлде. Сары яфраклар җилсез көннәрдә дә акрын-акрын тирбәлеп җиргә коелдылар. Мондый чакта урман сукмакларыннан ашыгып үтеп булмый, ирексездән адым авырая. Иртә коелган бөршәйгән яфракларга кыеп басасы килми. Аяк атлавы авыр, эсселек сулышны буа. Игеннәр дә былтыргыдан күп кайтыш. Ә тормыш барыбер алга бара. Быелгы коры җәй үтәр, алдагысында муллык, татулык килер. Күңелне төшермибез. Мин ачык тәрәзә каршысында Әсфанга хат язып утырам. Гайсә бабай белән Мәдәния әби кодаларына барырга җыендылар. Минем нигәдер аларны җибәрәсем килми. Ялгызлыктан шикләнмәсәм дә алар өйдә чакта рәхәт, тыныч. Песи дә баядан бирле бер чыга, бер керә. Әллә ничек җайсыз. Әсфанга хат-язганда бер дә болай каушамый торган идем...

Пәрдә ачыла. Ишегалды. Киң ачылган тәрәзә каршысында Фәүзия хат язып утыра. Өйдән Г а й с ә белән М ә д ә н и я чыгалар. Гайсә таягын тотып-тотып карый да ыргыта.

М ә д ә н и я. Фәүзия кызым, күрче бу картны: кияү егете кебек юргалап йөри башлады бит.

Ф ә ү з и я. Ә? Ни диең, Мәдәния әби?

Г а й с ә. Күпне сөйләп, кешене бүлдерәсең. Хат яза!

М ә д ә н и я. Кодаларның кәефен белеп кайтыйк дип җыендык.

Ф ә ү з и я. Барыгыз, бар. Иркенләп йөрегез.

Г а й с ә. Тагын ник тукталдың?

М ә д ә н и я. Әллә бармыйбызмы, сиңа әйтәм.

Г а й с ә. Ни уйлап чыгармый бу хатын-кыз дигәнең!

М ә д ә н и я. Алайса, әйдә!

Чыгалар. Фәүзия ялгызы. Елмая-елмая хат яза. Җырлап та ала. Сак атлап, карана-карана Ч а л керә. Тәрәзәгә килә.

Ф ә ү з и я. Абау, син кем?

Ч а л. Миңа хәзер «сез» дип кенә дәшәләр.

Ф ә ү з и я. Бу... сезме?

Ч а л. Көтмәвегезне беләм... Мине берәү дә көтмәгән икән монда! Күңелле түгел! Тик Чал гадәттә көттереп тормый: капылт кына килә дә чыга.

Ф ә ү з и я. Өйгә рәхим итегез. Бу якларда күптәнме?
Ч а л. Үзең монда чык.
Ф ә ү з и я. Мин?

Өйдән ишегалдына чыга.

Ф ә ү з и я. Мин сезне тыңлыйм.
Ч а л. Әзерләп. Сине алырга кайттым.
Ф ә ү з и я. Китәргә җыенганым юк.
Ч а л. Миңа монда калырга ярамый. Ул... кайтасы бар! Ә синсез яши алмыйм.
Ф ә ү з и я. Сез адресны бутагансыз.
Ч а л. Белеп килдем. Монда кайткач үткәннәремне сызып ташларга теләдем. Сине дә онытырга!.. Юк, онытып булмый. Син минем рухи дошманым. Дошманымны оныту гадәтем юк. Мин ул малайдан менә дигән карак ясый идем. Көче, сәләте, тәвәккәллеге бар аның! Дуамаллыгы да җитәрлек. Мин аңа караклык фәненең иң нечкә серләрен өйрәтә идем. Ул минем иң өметле, иң лаеклы шәкертем иде. Син — педагог, шәкертнең остаз өчен кем булуын аңлыйсың! Кем аны минем тимер куллардан тартып алды диген? Син!! Димәк, синдә мин белмәгән яшерен көч, сәләт бар. Димәк, мин сиңа хуҗа булырга һәм ул серне ачарга тиеш.
Ф ә ү з и я. Мин Әсфанны яратам. Без бергә булырга вәгъдәләштек. Мин аны көтәм. Сез хәзер тыныч кына моннан китеп югалыгыз. Мин сезгә бер начарлык та теләмим.
Ч а л. Син аны үзең теләгән юлга бастырдың. Нигә мине йә туры юлга чыгармыйсың?
Ф ә ү з и я. Туры юлга да кешене тартып чыгарып булмый. Иң әүвәл ул үзе шунда юнәлергә тиеш. Мин белгәндә Әсфан эзләнә иде инде.
Ч а л. Чал күп сөйләшми. Андый гадәте юк. Ул кирәкле кешесен алырга гына килде. Ашык.
Ф ә ү з и я. Чибәркүлдән беркая да китмим. Гомергә.
Ч а л. Ә мин синең җаныңның ниндилеген кайда, ничек аңлармын?
Ф ә ү з и я. Бу хәлдә аңламассыз сез аны!
Ч а л. Телим! Китмисең икән, мин синең җаныңны ачып карарга телим! Тиз!
Ф ә ү з и я. Югалыгыз!
Ч а л. Иректә үз җаема гына яшәргә теләгән идем. Син миңа тыныч яшәргә ирек бирмисең. Буылам, үләм... Йә минеке буласың, йә...
Ф ә ү з и я. Кычкырам!
Ч а л. Сөрән салсаң да курыкмыйм. Йә?!

Ф ә ү з и я. Юк. Юлыңда бул.

Ч а л. Кая барсам да юлда синең шәүләң. Яки синең ишеләр. Сиңа хуҗа булырга, сытарга, изәргә телим!

Ф ә ү з и я. Юк!

Ч а л. Бар! Бар! Мә, алайса!

Пычак белән кадый.

Ф ә ү з и я (*егылып*). Хатымны тәмамларга ирек бирмәдең... явыз... Әсфан, әгәр бик сагынсаң, Чибәркүлгә бер кайтырсың! Туган җирне сагынмый мөмкин түгел! Кайтырсың! Хуш! (*Егыла.*)

Чал бер якта шашып тора да чыгып кача. Г а й с ә белән М ә д ә н и я кайтып керә.

М ә д ә н и я. Аһ!

Г а й с ә. Фәүзияне яралаганнар! Фәүзияне!

Бер якта Әсфанның шәүләсе пәйда була. Ул ачы итеп кычкыра.

Ә с ф а н. Фәүзия! Фәүзия! Нигә хатларың юк, җанашым?! Нигә тындың?! Мин яратам сине! Өзелеп сөям! Нигә тындың, бәгырем?!

П ә р д ә.

*1978*
*Займище — Казан — Переделкино*

# Әткәй җырлый да, җылый да...

*Драма ике кисәктә*
*(«Әгәр бик сагынсаң...» дилогиясенең 2 нче пьесасы)*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Фәүзия.
Әсфан.
Гайсә бабай.
Мәдәния әби.
Чал.
Кәбир — быел гына сигезенче классны тәмамлаган үсмер егет.
Сөнгать — Чибәркүлдә агроном.
Сәлимә — аның апасы, Чалның элекке хатыны.
Гөлйөзем Мәннаповна — район милиция бүлегендә тикшерүче.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Авансценага Фәүзия чыга.

Фәүзия. Сез минем авыр яраланганымны беләсездер инде? Әйе, әйе. Чал кушаматлы усал бандит яралады мине. Әсфан белән бергә утырган бандит, кыйнап кулын сындырган явыз кеше. Әсфан өчен тартышта ул миңа да үчле булып калды!.. Әмма мин Әсфанны аның тозагыннан тартып алдым! Хәзер менә ул хәлләргә төгәл өч ел узды. Җәрәхәтем төзәлде, сызламый да диярлек, каты явымнар алдыннан гына аз-маз сыкрап ала. Әмма дөньяда көенечләргә караганда сөенечләр күбрәк, кайгырып торырга да вакыт юк. Мин һаман Чибәркүл мәктәбендә балалар укытам. Шул ук фатирда торам. Гайсә бабай да бик сихәт йөри, егетләрчә. Ә Мәдәния әби, Мәдәния әби!.. Күз генә тимәсен, ул да бик сәламәт. Песиебез генә югалды, әллә адаштырдылар, әллә чирләп үлде. Яңа песи алмый торабыз әле... Авыл үз тормышы белән яши. Бу өч елда да без Әсфан белән бик күп хатлар алыштык. Больницадан чыккач та мин аның янына

барып кайттым. Бу юлы берьялгызым гына бардым. Берүзем. Сөйләшеп сүзебез бетмәде... Кара-каршы утырып туган як җырларын җырладык. Янәшә утырып киләчәккә юллар сыздык. Күңел җепләребез гел Чибәркүлгә әйләнеп кайтты. Хатирәләргә бай бәхетле бу очрашуыбыз да күңелләрдә мәңгегә калды. Бер генә мәсьәләдә Әсфан белән килешә алмадым. «Әгәр явыз Чал юлымда очрый калса, мин аның муенын борып ыргытам!» — диде Әсфан. Кирәкми, дип нык каршы төштем мин. Тимә, яшәсен, әгәр ялгыш яшәвен аңламаса, гомерендә бәхет күрмәс, башы төрмәдән чыгачак түгел, дидем. «Ул мине сагалап йөридер!» — дип өстәде Әсфан. Мин куркып киттем: мине яралап качканнан соң Чалның тотылганы юк бит әле...

Ә бүген! Бүген... Аерата бәхетле көнебез. Әсфан кайта! Чибәркүлгә кайта. Минем яныма кайта. Вәгъдәләр алыштык, мин аны көтәм. «Кайтам!» дигән телеграммасын алгач нишләргә белмәдек. Гайсә бабай өй арасында, ишегалдында мәж килә. Урамнан үткән бер кешегә дәшеп кала. Мәдәния әби иртә-таңнан пешеренә. Сизәсезме, өй тирәсендә нинди тәмле исләр таралган? Ниләр пешерә икән?.. Авызымнан су килә! Мин дә таңнан тик кенә утыра алмыйм. Хәзер мин җаныма якын Чибәркүл урамы буйлап төшеп барам. Каршыма Кәбир менеп килә. Хәтерлисезме, бишенчедә кызлар чәчен тартып интектергән, сүз тыңламыйча укытучыларның җелегенә төшкән кире малайны. Гөлҗамал апаның төпчеген онытмадыгызмы? Шул инде, шул! Ташбаш иде! Быел Кәбир сигезенчене бетерде. Мин һаман да аларның класс җитәкчесе. Кәбир дә Әсфан абыйсыннан шактый озын хатлар алды, байтак гыйбрәтләр ишетте. Үзгәрде малай! Чибәркүлдә калам, комбайнчы булам, ди. Мин сөенәм! Әйбәт, тере егет үсә Чибәркүлдә! Авылга да әйбәт егетләр бик кирәк! Кирәк! Тормыш туктамый, гел алга бара, үзгәрә. Ә тормышны бары тик әйбәт егетләр генә алга илтә. Чибәркүлгә тагын бер әйбәт егет — Әсфан кайта! Минем Әсфаным! Көтәбез. Шкафта быел яз гына тектергән ак күлмәгем эленеп тора. Мин Әсфанны көтәм. Кәбир дә көтә. Мин сөенеп туя алмыйм! Ул туып үскән урамнарга карыйм да күңелем якты нур белән тула. Кәбир белән очрашуыма да сөенәм. Әсфан абыйсын көтә белгәне өчен сөенәм. Кинәт минем башыма бер уй килә. Мин Кәбирне үз яныма дәшеп алам. Беләм, бүген ул минем яныма килергә кыймыйчарак йөри. Кунак көткән көн — иң мәшәкатьле көн. (*Кычкырып эндәшә.*) Кәбир, Кәбир! Монда килче, үскәнем!

Кәбир керә.

Кәбир. Ни кушасың, Фәүзия апа?

Фәүзия. Кил, кил. Бүген Әсфан абыең кайтасын ишеткәнсеңдер инде?

Кәбир. Ишетмичә, Гайсә бабай безнең очта өй борынча шуны әйтеп йөрде. «Кайтам» дигән телеграммасын алдык, ди.

Фәүзия. Гайсә бабаң куанычның кадерен белә ул!.. Сагындырып килгән сөенечнең бәһасе юк, Кәбир.

Кәбир. Һәй, куанмыйча!..

Фәүзия. Телеграммасы бар... «Бүген кайтам», дигән. Тик ничек кайтырын гына ачыклап әйтмәгән.

Кәбир. Аңламадым, Фәүзия апа.

Фәүзия. Табышмак! Самолет белән кайтамы, әллә поездга утырамы? Пароход белән кайтуы да бик ихтимал.

Кәбир. Самолетка утырып кайта ул!

Фәүзия (*тагын да яктырып*). Мин дә шулай дим! Тик менә... билет! Хәзер җәйнең иң шәп чагы, һәркем ялга, сәяхәткә ашыга. Билетны алай ансат кына табармын димә.

Кәбир. Нишләп поездга утырсын? Самолет юк икән, «Ракета» бар! Выжт иттереп кенә пристаньга килеп туктыйсың...

Фәүзия. Кәбир акыллым, пристаньнан кайтса, Әсфан абыең авылга нәкъ сезнең очтан керә дигән сүз. Күз-колак бул, әгәр ул күренсә, тиз үк миңа хәбәр итәргә тырыш. Мин аны югары очта көтәрмен. Аэропортка юл шуннан.

Кәбир. Мин Әсфан абыйга эндәшерменме соң?

Фәүзия. Эндәшмичә! Эндәш!

Кәбир. Мин аңа ни диярмен икән?

Фәүзия. Синме, акыллым?.. Каршысына чык та: «Әсфан абый, менә, Кәбир дигән егет мин булам»,— диген.

Кәбир. Ә ул миңа ни дияр?

Фәүзия. Улмы? Сөенер! Сөенә белә ул! «Саумы, Чибәркүл егете Кәбир»,— дип сине кочаклап ук алыр.

Кәбир. Алай димәсә?

Фәүзия. Дияр. Сагынып кайтса, шулай әйтер. Әгәр бик сагынса...

Кәбир. Ярый, Фәүзия апа, мин хәзер үк иптәш малайларны җыям. Тыңлыйлар алар мине! Әсфан абый кай яктан гына кайтып төшсә дә, сиңа хәбәр итәргә тырышырбыз.

Фәүзия. Ярый, акыллым. Ярый, үскәнем.

Икесе ике якка чыгалар. Пәрдә ачыла. Урам. Капка. Рәшәткәле койма. Гайсә бабай йорты. Менә ул үзе дә... Балта тотып койма рәшәткәләрен карап йөри, җырлый.

Гайсә.

Егет булдык, атка мендек,
Бил бирмәдек дошманга.
Билне бирмәдек дошманга —
Терәк булдык дусларга.

Их, яшь чаклар, яшь чаклар!
Дәртле, канатлы чаклар!
Инде менә килеп җитте
Картайдык дияр чаклар!

Өйдән Мәдәния чыга.

Мәдәния. Җырлыйсыңмы, сиңа әйтәм?

Гайсә. Ир кешенең кулына балта кергәч, күңеле уйнап алмый булмый икән, карчык.

Мәдәния. Кулыңа үткен балта кергәч син йорт тирәсен ныграк караштыр, файдасы күбрәк булыр. Күр инде, әле кичә генә бу койма тактасы какшап кына тора иде, бүген тәмам каерылып ук чыккан. Бәй, капкаң да җиргә салынган түгелме?

Гайсә. Тактаны мин каердым.

Мәдәния. Син?!

Гайсә. Капканы да мин ачылмый торган иттем.

Мәдәния. Әстәгыфирулла тәүбә! Тагын сул аягыннан торган. Бүгенге көнне...

Гайсә. Дәшмә, карчык. Чәпчемә юкка.

Мәдәния. Күрче моны, таңнан торып эш табалмыйча йөри. Утын вакланмаган...

Гайсә. Бүгенгә җитәрлек!

Мәдәния. Мунчага су ташымаган!

Гайсә. Бер катка җитәрлек.

Мәдәния. Бүген белән эш бетәмени? Балалар кайтыр, кунаклар килер.

Гайсә. Чәпчемә дим юкка! Дәшмә!

Мәдәния. Койма рәшәткәләрең какшап торганда ничек дәшмим ди мин? Бүген белән генә яшәмәкче буласыңмы әллә? Алда да көн бар.

Гайсә. Тукта, тукта. Син малай кайтуга ни әзерлисең?

Мәдәния. Бәрәч, ни булсын, шулпалы бәлеш. Балам шулпалы бәлешне бик ярата иде...

Гайсә. Бәлеш? Тапкансың сый!

М ә д ә н и я. Ай Аллакайгынам, синең сыең бик хәтәрдер инде, мөгезледер!

Г а й с ә. Мин аңа эш әзерлим, эш! Йортка-нигезгә яшь хуҗа кайта. Капканың салынганын күрерме-юкмы? Коймa тактасының купканын абайлармы? Мунчага су җитәр-җитмәслеген төшенерме? Монда, карчык, бәлеш ашатып кына малайны сынап булмый, валлаһи дим! Менә чалгы әзерләп куйдым. Чүкесен яхшылап. Олы юл янындагы әрәмә аланнарында печән билдән, чапсын киерелеп. Мин күзәтеп торырмын. Кулдан эш китә быел, карчык. Коймaны рәтләсен, баз түбәсен сүтеп япсын. Мин аңа: «Аны болай эшлә, тегесен тегеләй ит»,— дип, сакал сыпырып киңәш биреп йөрермен. Бер үк вакытта колхоз эшенә дә өлгерсен!

М ә д ә н и я. Йорт эшләрен онытып та бетергәндер инде.

Г а й с ә. Яклама төпчегеңне! Исенә төшсен өчен һәммә эшне әзерләп торам аңа, күзе ияләнсен.

М ә д ә н и я. Алла боерса, рәхәтләнеп бер-ике атна ял итәр.

Г а й с ә. Алла да гел-гел синең яклы гына булмас. Бүгеннән эшкә тотыныр. Дәшмә, карчык, бәлеш ашатып егетне сынап буламы? Дөрес, бәлеш тә сый!.. Әмма мин боерганда, син дәшмичәрәк торырсың, яме!

М ә д ә н и я. Ул-бу күренмиме?

Г а й с ә. И-и, күренсәме?!

М ә д ә н и я. Нишләр идең?

Г а й с ә. Ике очка да ишетелерлек итеп: «Кайтты!» — дип бер кычкырыр идем.

М ә д ә н и я. Син тинтәкне тыңлап торган мин җүләр... Фәүзия кызым кайда йөри икән?

Г а й с ә. Фәүзия дә йөрми, шөкер.

М ә д ә н и я. Нишли, сиңа әйтәм?

Г а й с ә. Көтә ул, көтә.

М ә д ә н и я. Менә, карчыгың сүзе өстен чыктымы? «Киленең итеп бетердең!» — дип көлә идеңме? Киленем була, Аллаһы боерса. Үз янымдагы яраткан киленем булачак. Кызым булачак.

Г а й с ә. Син дигәнчә дә булмады, мин дигәнчә дә эшләмәде, Фәүзия үзенекен эшләде. Үз теләгәненә иреште.

Биек-биектә гүләп самолет уза, икесе дә тыңланалар.

М ә д ә н и я. Кайта, кайта, сәмәлүткә утырып кайта.

Г а й с ә. Прахутка утырса ни диярсең?

М ә д ә н и я. Алма кебек кыз җан атып көтеп торганда, егет прахутка утырып маташамы?

Г а й с ә. Прахут тәрәзәсе янына утырып, терсәкне яңакка куеп, рәхәтләндереп күз сөендереп кайта ул. Самолеттан ни күрәсең?

М ә д ә н и я (*еламсырап*). Син сугыштан кабык арбага утырып кайткан идең.

Г а й с ә. Кайту кыйбат, карчык, кайту!

М ә д ә н и я. Сиңа әйтәм, нигә телеграммыңда ачык кына итеп әйтмәде икән?

Г а й с ә. Балаларга үз акылыңны биреп булмый. Безне утлы табага бастырды, тәки.

М ә д ә н и я. Әллә бер-бер без белмәгән исәбе бармы?

Г а й с ә. Тагын бер тактаңны каерып ыргытырмын!

М ә д ә н и я. Әстәгыфирулла, нигә?

Г а й с ә. Фәүзиянең Чибәркүлдән китәр исәбе сизелми. Мондый кыз көтеп торганда арык алашага утырып кына түгел, төньяк котыбыннан яки җәһәннәм базыннан үрмәләп кайтырсың! Кайту кыйбат!

Пауза.

М ә д ә н и я. Әйтсәм, тагын ачуланырсың инде.

Г а й с ә. Чү! Машина!

Машина узып китә.

Г а й с ә. Үтеп китте.

М ә д ә н и я. Сиңа әйтәм, кызмыйча тыңла: күңелемдә әллә нигә шом тора.

Г а й с ә. Каерам! Тәки каертасың берсен!

М ә д ә н и я. Син аңа күңел борчуларыңны сөйләгән буласың, ә ул... Каер, каер, җүләрлән әйдә! Өчесен актарып чыгар!

Г а й с ә (*сабырланып*). Җырлап юан, карчык.

М ә д ә н и я. Син җырлап та юанасың. Синең дә күңелең тыныч түгел. Кунактан кайтмый шул, төрмәдән чыгып кайта. Беләм, безнең беребезнең дә күңеле тыныч түгел. Шуңа күрә Фәүзия кызым да җанына урын табалмыйча йөри.

Өйгә кереп китәләр. Гайсә әйләнеп чыга. Машина тавышы. Гайсә тыңлана. Машина уза. Карт җырлый.

Г а й с ә.

Яши белдек, сөя белдек,
Сер бирмәдек ятларга.
Кирәк чакта яуга чаптык —
Сикереп менеп атларга.

Их, яшь чаклар, яшь чаклар!
Ерак калган сукмаклар...
Очкан чаклар, кочкан чаклар
Дөньяны тоткан чаклар.

Урам яктан бер әйләнә дә өйгә кереп китә. Бер яктан Сөнгать, икенче яктан Кәбир керәләр.

Сөнгать. Кәбир, Фәүзия апаң өйдәме икән?

Кәбир. Һәй, нишләп өйдә утырсын ди ул бүген?

Сөнгать. Бар, белеп чык.

Кәбир. Өйдә түгел дим ич!

Сөнгать. Алай да кереп чык. Миңа бик кирәк иде ул.

Кәбир. Миңа да кирәк.

Сөнгать. Мондый чакта аяк астында буталма инде син, егет.

Кәбир. Сине дә бик көтеп тормыйлар, ахрысы, Сөнгать абый. Өйләренә керергә дә шүрлисең.

Сөнгать. Колагыңны борырмын, малай.

Кәбир. Колакны борганнары бар инде, Сөнгать абый, күз барыбер күрә. Әнә ич ул, кайтып килә. Өйдә юк дип әйттемме?!

Фәүзия керә.

Фәүзия. Ә, мәңге тугры Сөнгать дус! Кәбир? Син нишләп монда?

Кәбир. Югары очның Гаптери кызы Мәликә кайткан. Самолетта очкан. «Әсфан абый күренмәдеме?» —дип сорадым. «Юк»,— диде.

Фәүзия. Ишеттем. Рәхмәт, Кәбир акыллым. Менә шундый-шундый эшләр, тугры Сөнгать дус. Димәк, ул самолетта түгел.

Сөнгать. Минем Чаллыга китеп барыш, Фәүзия. Пристаньга.

Фәүзия. Мине дә чакыруың булдымы бу?

Сөнгать. Апам бар минем. Бәхетсез бер апам. Күз көеге! Исемен телгә аласым килмәгәнгә генә моңарчы сөйләмәдем. Җәфа! Шәһәрләр дә үзгәртеп карады, кияүләр дә алыштырды бугай. Берсеннән дә уңмады: шәһәреннән дә, киявеннән дә!

Фәүзия. Бүген бәхетсез кешеләр турында тыңлыйсым килми, кичер.

Кәбир. Мин хәзер нишлим соң, Фәүзия апа?

Фәүзия. Син нишлисеңме? Мин нишлим?.. Без нишлибез?..

Сөнгать. Өеңә кайт, Кәбир.

Кәбир. Миңа кайтмаска кушылган. Әсфан абыйга минем кирәк булуым да бар. Сүзе дә булырга тиеш.

Фәүзия. Бар, үскәнем. Бар, акыллым. Рәхмәт сиңа. Әсфан абыең кайткач та безгә кунакка кил. Мин сиңа белдерермен. Самолетның рейсы бер, анда юк икән, йә поездда, йә су юлы белән кайта инде. Көтәр юлларыбыз кимеде, үзем дә каршы алырмын абыеңны.

Кәбирне озата.

Сөнгать. Мин дә шул турыда киңәшергә дип килгән идем.

Фәүзия. Һәм бәхетсез, игелексез, апаң турында сөйләргә керештеңме? Аңламадым. Нигә син бүген, нәкъ мин Әсфанны өзелеп көткәндә, тол калган, ялгыз, һөнәрсез, бәхетсез апаң турында авыз ачарга ниятләдең? Нигә бүгенгәчә телгә алмаган идең син аны?

Сөнгать. Мин сине ярата идем, Фәүзия.

Фәүзия. Беләм, тугры дустым.

Сөнгать. Яраткан кешеңә бәхетсезлекләр турында сөйлисе килми. Бәлки, шуңа да минем телемдә апама урын булмагандыр. Бәхетнең канаты ак була, бәхетнең канаты нык, сөйгән кешеңнең офыгы зәп-зәңгәр, күге биек, хыял юллары ерак. Ачулы идем мин апама! Мин аны онытырга тырыша идем.

Фәүзия. Бәхетсезләрне онытырга ярамый, Сөнгать. Бәхетсезлек мәңгелек кунак түгел!

Сөнгать. Ул үзе гаепле.

Фәүзия. Ул үзе гаеплеме? Бүгенгә бәхәсләшмим. Сөйләшербез әле. Аның турында сүз булмый калмас. Мин китим инде.

Сөнгать. Әсфанны өйдә генә каршыласаң, яхшы түгелме?

Фәүзия. Хәзер һәрвакыт мин аның янында булырга тиеш. Туган җиренә баскан беренче адымында ук аның янәшәсендә!.. Син аңлыйсыңмы? Берәрсе кырын карар... Саксыз сүз ычкындырыр! Син аңлыйсың бит! Йә тиешсез сорау биреп куяр. Күңел кылдан нечкә ул! Ә яралы күңел бигрәк тә...

Сөнгать. Аңлыйм, Фәүзия... һәм сокланам!

Фәүзия. Аңламаслык булсаң, серемне уртак итәр идемме?

Сөнгать (*бераз аптырап*). Йомышым шул гына иде: апам кайта. Бүген.

Фәүзия. Кунаккамы?

С ө н г а т ь (*әдәп өчен генә бирелгән сорауга да канатланып китә*). Кунакка гына кайтса, белдереп тә тормас идем. Мин аңа соңгы айларда байтак хатлар яздым. Сине ныграк белгән саен хатларым ешайды... Бик әйбәт авылга, яхшы кешеләр янына юлыктым дип сөенечем белән уртаклаштым. Хәбәре болай дип килде: «Төпләнә алсам, инде мин дә гомергә шул авылда, синең янда гына калыр идем»,— дип язды. Кыскача, әлегә менә шул. Әйдә, речной портка бергә барабыз.

Ф ә ү з и я (*паузадан соң*). Әгәр Әсфан поезд белән кайтса?

С ө н г а т ь. Поезд төнгә каршы гына уза. Бөгелмәдән безгә алтмыш өч чакрым. Әсфан бик соң төнлә, йә иртән генә кайтып керәчәк. Ә «Ракета»лар Казан ягыннан өзмәс узып тора. Билет табу да җиңелрәк булачак.

Ф ә ү з и я. Әгәр ул үтеп баручы башка поездга утырса?

С ө н г а т ь. Иртәрәк кайтып элгәшсә, чак кына көтәр! Син көтәсең ич әле!

Ф ә ү з и я. Чибәркүлдә мин аның ялгыз булуын теләмим. Күңелем шуны сорый, Сөнгать, тугры дус. Ә күңелемә мин бик нык ышанам.

С ө н г а т ь. Күңел зур нәрсә, аңа күп нәрсә сыя.

Ф ә ү з и я. Беләм, син мине чын күңелеңнән якын итеп чакырасың. Чын йөрәгеңнән куанасың, борчыласың. Саф кеше син, керсез. Танышканнан бирле миңа гел яхшылык кына теләдең. Шулай да, менә хәзер, Әсфан кайтып төшәр алдыннан сиңа бер сүземне әйтеп калыйм әле.

С ө н г а т ь. Син артыгын борчыласың, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Син нәкъ кирәк чакта гына, үз вакытында килеп өлгерә торган сизгер җан. Әгәр теге чакта, явыз Чал пычагыннан яраланып, канга манчылып шушы ишегалдында ятып калганда син килеп чыкмасаң, ярамны бәйләмәсәң, машинаңа утыртып больницага ашыкмасаң, операциядән соң каныңны бирмәсәң, тәүлекләр буена Мәдәния әбине алыштырып янымда утырмасаң... белмим... мин хәзер синең каршыңда басып тора алыр идемме икән?! Минем янда һушсыз яткан карт белән карчыкны да син ипкә китердең! Син иң кирәк чакта гына минем яныма килә тордың, Сөнгать дус! Күңелем сизә, бүген дә син вакытын белеп кенә килгәнсең. Бәлки, чыннан да Әсфан су юлы белән кайтыр. Шулай булуы да бик ихтимал. Тик менә минем күңел генә икеле-микеле. Ныклап кына бернәрсәне дә уйлап бетерә алмыйм. Уйлап бетермәгән хәлдә ничек синең яныңа утырып китим?.. Куркам мин, Сөнгать.

С ө н г а т ь. Нидән куркасың, Фәүзия?

Ф ә ү з и я. Куркам дидемме? Куркам микәнни? Менә сиңа әкият!

С ө н г а т ь. Әйтмәдең, Фәүзия. Мин ялгыш ишеттем.

Ф ә ү з и я. Алай да!.. Теге бандит һаман шушы тирәдә чуала кебек. Безнең кебек үк ул да Әсфанның кайтасын белә бит! Вакытын чамалый! Беркөн балалар белән урман кырыннан үтеп барам, агач арасында,шуның шәүләсе чагылып киткән кебек булды. Ә бер чакта, районда, Сабан туе көнне, каршыма берәү килә. Милиция киеменнән! Ул! Күтәрелеп карасам, юк, ул түгел... Әсфан кайтып кергәнгә кадәр күңелемә хуҗа була алмам, ахрысы! Нигә ачык итеп язмаган инде?

С ө н г а т ь. Бөгелмәгә машина җибәрик. Каршыларга иптәшләре белән Кәбир барсын. Ә син минем белән Чаллыга китәсең.

Ф ә ү з и я. Рәхмәт, Сөнгать! Чаллыда очратсаң, Әсфанны син алып кайтырсың. Танырсың! Иң чибәр, иң тыйнак егет шул булыр. Мин монда көтим инде. Гайсә бабай белән Мәдәния әбине дә ялгыз калдырасым килми.

С ө н г а т ь. Алып кайтырмын. Ә теге бандитка килгәндә... Дөрес, аның тотылганы юк. Эзлиләр. Мәгәр аның якын-тирәдә булуы мөмкин түгел!

Ф ә ү з и я. Шулайдыр, мөгаен. Карышмыйм. Тик күңел... Син, Сөнгать дус, апаң белән әдәпле бул. Бәхетсез дип аның үзенә әйтмә, башкаларга да әйттермә. Кирәкмәс.

С ө н г а т ь (*көлә*). Әйтмәм, дустым. Тик ул да әйттермәсен!

Ф ә ү з и я. Кемнең бу якты дөньяда, ирекле илдә бәхетсез исеме тагып йөрисе килсен!

Сөнгать чыга. Фәүзия ялгызы. Кая барып бәрелергә белмичә аптырап төрле якка сугыла. Өзеп-өзеп җырлый.

Ф ә ү з и я.

Ал яулыгым, ал яулыгым...
Давылларда... Җилләрдә...

Өйдән Г а й с ә чыгып килә.

Г а й с ә. Эһем, эһем... Агроном Сөнгать булдымы ул?

Ф ә ү з и я. Шул иде, Гайсә бабай.

Г а й с ә. Әйбәт егет, әйбәт. Төпле! (*Кинәт.*) Ни сөйләнгән була?

Ф ә ү з и я. Эрактан апасы кайтырга тиеш икән.

Г а й с ә. Шулай озаклап апасы турында сөйләдеме ул сиңа?

Ф ә ү з и я. Без апасы турында гына сөйләшмәдек, Гайсә бабай.

Г а й с ә. Шулайдыр, шулайдыр. Тагын ни дигән була?

Ф ә ү з и я. Апасы монда торырга ук кайта икән.

Г а й с ә. Алай, алай...

Ф ә ү з и я. Гайсә бабай нидәндер шикләнәме?

Г а й с ә. Бәбкә үстергәндә чыпчык та бөркет булып күренә ул, кызым! Их, кызым!

Өйдән М ә д ә н и я әби йөгереп чыга.

М ә д ә н и я. Харап булдык! Хараплар гына булдык!

Ф ә ү з и я. Мәдәния әби...

Г а й с ә. Ни булды? Сиңа әйтәм!

М ә д ә н и я. Беттек.

Ф ә ү з и я. Йә инде, Мәдәния әби.

М ә д ә н и я. Мичкә утырткан бәлешем тишелеп аккан.

Ф ә ү з и я. Уф...

Г а й с ә. Син тишелеп аккансың монда, карчык.

М ә д ә н и я. Улым ярата дип шулпасын күбрәк салып җибәргән идем.

Самолет тавышы. Өчесе дә бертынга туктап калалар.

Ф ә ү з и я. Кайгырма, Мәдәния әби! Бу бәлешне самолетта кайтырга тиешле Әсфан өчен салган идең, хәзер пароходта кайтучы егет өчен бәлеш ясыйбыз!

М ә д ә н и я. Бәлеш тишелү бер дә әйбәт түгел инде ул, кызым.

Г а й с ә. Тагын бер койма тактаңны каерып атам.

Ф ә ү з и я. Үзем ясашам. Мәдәния, әби. Тишелми торган итеп ясарбыз. Бик тәмле булыр! Әсфанга да ошар, күрерсең.

М ә д ә н и я. Оятка калдым. Син кермисеңмени, әткәсе?

Г а й с ә. Керәм! Тишелеп акмасын өчен бәлешеңне саклап торам!

Ф ә ү з и я. Анда күз күрер.

М ә д ә н и я. Фәүзия кызым, әле дә ярый бу дөньяда син бар! (*Гайсәгә.*) Үчекләшүдән башка эше юк.

Г а й с ә. Керәм дидем ич!

Өйгә кереп китәләр. Сәхнә бераз буш. Ч а л керә. Каранып тора.

Ч а л. Нигә кайтып җитмәде ул? Чама белән күптән авылда булырга тиеш иде!.. Очрашасы иде хәзер! Бүген

үк! Кем кемне?.. Әллә? Гаҗәп хәлләр булуы мөмкин әле алда! Мин үземнекен итәргә тиеш! Соңгы сүз барыбер минеке!

Чыга. Караңгылана. Ф ә ү з и я керә. Җырлый.

Ф ә ү з и я.

Күңелкәем, күбәләк кенәм,
Талпынасың нигә?
Ул кайтыр.
Күзләремә карап елмаер да
Ярсу йөрәгемне юатыр.
Күңелкәем, язгы ташудай
Чайкаласың нигә?
Ул кайтыр.
Кайнар учларына кулым кысып
Янган йөрәгемне юатыр.

Г а й с ә керә.

Г а й с ә. Җәйге төнне әйтер идем... Бер яктан шәфәкъ уты сүнеп бетми, икенче яктан алсу таң ярала.

Ф ә ү з и я. Төне җылы!

Г а й с ә. Бар, Фәүзия кызым, ял итеп ал. Йокла.

Ф ә ү з и я. Аз гына утырам да...

Г а й с ә. Юл кешесенең ние булмас дисең? Бар җирдә дә безнең сыман көтәләрме әллә аны? Билет булмагандыр. Иртән кояш кебек кайтыр да керер.

Ф ә ү з и я. Барысы да шулай булыр, Гайсә бабай, ышанам! Тик менә нигәдер Сөнгать тә кайтып җитми.

Г а й с ә. Ах, башсыз малай, башсыз малай! Тәки барыбызның котын алып, йокысын качырды бит. Әнә тагын берсе йөри. Йокла диләр сиңа!

М ә д ә н и я керә.

М ә д ә н и я. Качты шул йокы, качты.

Г а й с ә. Саклап торып йоклатмыйча булмас сине, карчык.

М ә д ә н и я. Бәлешем тишелгәч үк эчем жу итеп киткән иде аны... Фәүзия кызым, син дә кер!

Ф ә ү з и я. Сез керә торыгыз!

Картлар кереп китәләр. Бераздан машина туктаган, ишек ачып-ябылган тавыш ишетелә. Кабаланып С ө н г а т ь керә.

Ф ә ү з и я. Сөнгать, ничек? Ни хәлләр?

С ө н г а т ь. Әле генә сезнең ишегалдыннан кем чыгып китте?

Ф ә ү з и я. Беркем дә китмәде.

С ө н г а т ь. Әллә күземә күрендеме. Ардым. Гел йөз белән кудым. Машина утына эләгеп кемдер койма аша сикергән кебек булды.

Ф ә ү з и я (*каранып*). Берәү дә юк. Әсфан кайтмадымы? Апаң кайда?

С ө н г а т ь. Кайтмады апа. Без очрашмадык.

Ф ә ү з и я. Әсфан да юк. Пристаньда да булмагандыр шул.

С ө н г а т ь. Әсфан дисеңме? Утырып торчы, Фәүзия. Мин сиңа һәммәсен дә тезеп сөйләп бирермен.

Ф ә ү з и я. Тагын килдеме бәла?

С ө н г а т ь. Килде, Фәүзия. Түзем бул.

Ф ә ү з и я. Түзәрмен. Сөйлә тизрәк.

С ө н г а т ь. Әсфанны кулга алганнар.

Ф ә ү з и я. Ни өчен? Ни өчен? Булмас! Ялган! Сине алдаганнар, егет.

С ө н г а т ь. Гөлйөземне беләсең син.

Ф ә ү з и я. Синең дус кызыңнымы? Белмичә!

С ө н г а т ь. Аның янына милициягә кергән идем. Шунда ишеттем. Әсфан белән очрашырга да теләдем. Күрештермәделәр.

Ф ә ү з и я. Ни гаебе бар аның? Нидә гаеплиләр.

С ө н г а т ь. Гоголь урамын беләсеңдер, иң кырыйда, шуннан, ашханә яныннан «Москвич» машинасы урлап киткән, диләр.

Ф ә ү з и я. Урлап? (*Рәхәтләнеп көлә.*) Ха-ха! Мин бит Чал белән очрашканнар дип торам.

С ө н г а т ь. Мин дә ышанмадым.

Ф ә ү з и я. Мөмкин түгел! Һич! Сөнгать! Син иң кирәк чакта килеп җитә белгән сизгер һәм тугры дус. Хәзер дә мин синең ярдәмеңә мохтаҗ. Машинаң төзекме?

С ө н г а т ь. Аңладым.

Ф ә ү з и я. Үзе кайтып җитә алмаган икән, без аны алырга барабыз! Машина урлаган диләрме? Ха-ха-ха! Көлке! Мин арага Чал килеп катнашкандыр дип курыккан идем. Алайса, бик әйбәт! Әйдә!

С ө н г а т ь. Тукта, Фәүзия. Ә картлар?

Ф ә ү з и я. Әйе. Нишләргә? Әйтсәң, көн-кояшны ничек каршыларлар? Әйтми китсәк мәрхәмәтсезлек, шәфкатьсезлек була.

С ө н г а т ь. Сиңа кыен булыр. Үзем белдерәм.

Ф ә ү з и я. Сиңа да ярамый. Гайсә бабай улы өчен һаман көнләшә! Чыдамаслар да! Белмәсеннәр. Мәдәния әбинең йөрәге ярылыр. Дару эчеп кенә түзә. Ишетми торсыннар. Аңынчы без Әсфанны йолып алып кайтырбыз.

С ө н г а т ь. Белмим.

Ф ә ү з и я. Әллә син чынлап шикләнәсеңме? Әсфан шундый башсызлык кылыр дип уйлыйсыңмы? Син миңа барын да сөйләмәгәнсең! Тагын нидер беләсең! Зинһар, әйт. Үтенеп сорыйм. Бик нык үтенеп!

С ө н г а т ь. Юк, шикләнмим. Тик алай җиңел уйлама, Фәүзия. Әсфан ике тапкыр гаепләнгән, алты ел төрмәдә утырып чыккан кеше. Андый кеше икеләтә, өчләтә шик уята.

Ф ә ү з и я. Аңлыйм! Яшәп, аралашып китү җиңел булмас аңа! Менә шуның өчен дә беренче адымыннан ук мин аның янында булырга омтылган идем. Ах, дөньяга якты күз белән карап яшәүләргә ни җитә?! Тик барыбер мин аңа ышанам. Үземә ышангандай ышанам! Әйдә, тугры дустым!

Чыгалар. Машина кузгала. Сәхнә караңгылана. Пәрдә ачыла. Милиция бүлегенең бер бүлмәсе. Өстәл, урындыклар. Телефон. Бүлмәдә тикшерүче Г ө л й ө з е м  М ә н н а п о в а  Ә с ф а н н а н сорау ала.

Т и к ш е р ү ч е. Димәк, сез дөрес һәм анык күрсәтмә бирүдән баш тартасыз?

Ә с ф а н. Нигезсез гаепләүне кабул итмим.

Т и к ш е р ү ч е. Сез үзегезне гаепсез дип саныйсызмы?

Ә с ф а н. Гаебем юк. Мин моны бик җиңел исбатлый алам.

Т и к ш е р ү ч е. Өр-яңадан шуны ук башлыйбызмы?

Ә с ф а н. Йөз, мең кат сорасагыз да мин үз сүземдә калам. Әйе, егерме беренче июнь көнне поезддан төштем. Алтынчы вагоннан. Бөгелмәдән үзебезнең район үзәгенә хәтле рейсовый автобус белән кайттым. Бөгелмә автостанциясеннән нәкъ сәгать уникедә кузгалдык. Моны раслаучы билетым алдыгызда ята.

Т и к ш е р ү ч е. Әлегәчә бер сүзегез дә шик уятмый.

Ә с ф а н. Чәйханәгә кереп ике стакан чәй эчтем дә район үзәгеннән чыгып, авылыбызга — Чибәркүлгә юл тоттым.

Т и к ш е р ү ч е. Ничек?

Ә с ф а н. Ничек булсын, җәяү!

Т и к ш е р ү ч е. Гаҗәп! Нигә җәяү?

Ә с ф а н. Шулай. Җәяү.

Т и к ш е р ү ч е. Сез алты елдан артыграк өегездә булмагансыз.

Ә с ф а н. Әйе.

Т и к ш е р ү ч е. Без ачыкладык: Чибәркүлдә сезне бик нык көткәннәр. Ата-анагыз көткән. Сөйгән кызыгыз да анда икән. Ул ничек кенә көткәндер әле!

Әсфан. Сез аңа кагылмагыз. Бу бинада аның исемен телгә алмагыз!

Тикшерүче. Көтүен көтәләр, ә сез тотасыз да җәяү чыгып китәсез. Очы очка ялганмый, гражданин Гайсин!

Әсфан. Алай диярге сезнең дәлилегез юк!

Тикшерүче. Бар, гражданин Гайсин, бар! Бар икәнен сез дә беләсез. Иң яхшысы, дөресен генә сөйләп бирегез дә...

Әсфан. Сезнеңчә дөреслек ничек? Нидә ул?

Тикшерүче. Тыңлагыз алайса. Әйе, ашханәдә сез ике стакан чәй соратып алгансыз. Берсен эчеп тә бетермисез. Ашыгасыз, як-ягыгызга каранасыз, һәм, һичшиксез, тәрәзәдән ерак та түгел иясез «Москвич» торганын абайлыйсыз. Тагын да ныграк ашыга башлыйсыз. Урамга чыккач бераз икеләнеп торасыз да машинага утырасыз. Район үзәгеннән югары тизлектә чыгып китәсез. Дүртенче километрда машинаны баганага бәрдерәсез. Менә аннан соң инде сезнең сәфәр чыннан да җәяү дәвам итә! Арттан милиция килгәнне күреп әрәмәгә кереп качарга азапланасыз. Дөреслек бер һәм ул менә шундый.

Әсфан. Качарга маташуым дөрес!

Тикшерүче. Бу гаебегезне тану түгелме әллә?

Әсфан. Эш гаептә түгел лә!

Тикшерүче. Нидә соң?

Әсфан. Алты ел утырып чыккан кешене аңлагыз инде сез! Арттан бастырып милиция машинасы килә... Үзем дә сизми калдым... Кереп кителгән. Ә калганнары тоташ ялган!

Тикшерүче. Юкка киреләнәсез.

Әсфан. Әйе, «Москвич»ны күрдем. Янында беркем юк, ишеге дә ярым ачык тора иде. Бераздан ул мине юлда куып та узды.

Тикшерүче. Рульдә кем икәнен абайладыгызмы?

Әсфан. Ир кеше иде. Бөкрәеп утырган. Уйланып бара идем, җентекләп карамадым.

Тикшерүче. Нигә туктатмадыгыз? Кул күтәрдегезме?

Әсфан. Ашыга идем мин, җәяү кайтып бара идем!

Тикшерүче. Нигә?

Әсфан. Сезнең өчен моның әһәмияте бармы?

Тикшерүче. Сезне самолет белән кайтыр дип көтәләр. Поездларны белешәләр. Елга портына каршыларга баралар. Беркем дә җәяү кайтыр дип уйламый. Шул җөмләдән мин дә!..

Әсфан. И-их, сөйләмәм дигән, идем!

Тикшерүче. Мин сезне тыңлыйм.

Ә с ф а н. Сөйләп булмый аны!

Т и к ш е р ү ч е. Кайсы яктан килеп уйласаң да, сез бик ашыгырга тиеш идегез. Бик! Һәм сез ашыккансыз да!

Ә с ф а н. Ашыга идем, җимерек «Москвич»ны күргәч тә туктап тормадым. Сул канаты сытылган, фаралары ватык иде.

Т и к ш е р ү ч е. Сез шофер. Профессиональ кызыксыну да туктатмадымы сезне?

Ә с ф а н. Әйтәм бит, ашыга идем!

Т и к ш е р ү ч е. Җәяүме?

Ә с ф а н. Әйе. Шулай. Җәяү.

Т и к ш е р ү ч е. Гражданин Гайсин, сез дөресен сөйләмисез.

Ә с ф а н. Чәйне ашык-пошык кына эчтем. Күзем тәрәзәдә иде! Юлда. Урамга да ашыгып чыктым. Таныш урамнар! Арада күз күргән кешеләр дә бар кебек иде. Шунда, чәйханәдә утырганда гына, мин үземнең, ниһаять, кайтып җитүемне, Чибәркүлгә бары тик унике чакрым гына калуын ныклап аңладым. Авылга кайтып керергә кирәк иде. Мин актыккы ноктага аяк бастым... Кайту!.. Һәр чакта да сөенечле һәм җиңел түгел икән ул! Көтәләр, дидегез сез. Көткәннәрдер, ышанам. Көттерү җиңел түгел. Чөнки көттерү дә бертөсле генә булмый! Җилкәгә ике срок салып кайтуның никадәрле авыр икәнлеген, юлның иң соңгы өлешенә чыгар алдыннан чәйханәдә мин тагын бер кат уйладым. Юлның азагына унике генә чакрым калса да, уйларымның очына чыгарлык түгел иде. Сөйгән кызың дәртсенеп, өметләнеп көтсә дә аның каршысына кайтып баш июне җиңел дип саныйсызмы сез? Ә эти, әни?!. Мин китергән кара хәсрәттән вакытсыз бөкрәйгән җилкәләр... Йокысыз төннәрдә мин өстәгән җыерчыклар!.. Әти-әни күзенә ничек карарга? Елмаергамы? Җыларгамы?! Ашыга идем мин, иптәш тикшерүче, бик нык ашыга идем! Сабырсыз ашыкканга күрә юлга җәяү чыктым да! Тагын бер тапкыр уйларга, үткән юлларны күздән кичерергә, алдагы юлларга әзерләнергә кирәк иде! Анда, рәшәткә артында уйланган уйлар — бертөсле. Әмма туган туфракка аяк баскач уйлар кинәт кенә үзгәрә икән, чәбәләнә, чуала!.. Кайтып, ялгышаммы әллә дип тә уйладым. Казанда яки Чаллыда калсам, яңа төзелешләрдә, яңа кешеләр арасында минем үткәннәрне белми дә калырлар иде. Берәү дә кырын күзе белән карамас иде. Тынычрак, димәк, рәхәтрәк тә яшәр идем. Ә мин кайтыр юлга чыктым... Һәм ул ансат булган дип санасагыз бик нык ялгышасыз!

Тикшерүче (*паузадан соң*). Яхшы. Шушы вариант белән килештек ди. Машинаны кем алып киткән соң? Кем аны бәрдергән? Сезнең маңгайда тирән җәрәхәт.

Әсфан. Анысы поездда булды. Кинәт кенә тормоз салдылар да өске киштәдән авыр чемодан очып төште. Моны минем белән бергә кайткан апа да раслый ала.

Тикшерүче. Кем ул?

Әсфан. Ул үзенең кемлеген ачыклап әйтмәде, мин сорамадым. Тоткын гадәте. Сөйләмәгән кешедән көчләп әйттерү юк. Ә мин аңа барын да сөйләп бирдем! Утырып чыгуымны ишеткәч, ул үзе дә барын җентекләп сорашты. Әллә берәр якын кешесе утырамы дип тә уйладым...

Тикшерүче. Ниләр сөйләдегез инде сез аңа?

Әсфан. Барын да! Мөгаен, кирәк тә булмагандыр!.. Кәефем яхшы иде шул, юлым туры, уйларым якты иде! Аның исемен кабатлау миңа рәхәт иде! Ул да безнең районга кайтты бит! Автобуста да күрдем мин аны, чәйханәдә дә бар иде шикелле! Тизрәк шуны эзләп табыгыз сез! Яланбаш. Урта яшьләрдә. Кулында зур сары чемодан. Иңендә зәңгәр плащ!

Тикшерүче. Автобуста да аның белән сөйләштегезме?

Әсфан. Уңайсызландым! Йомык апа ул, кайгылы. Ул апа да, башкалар да минем гаепсезлекне белә. Ашханә янында башка кешеләр дә бар иде. Тизрәк эзләп табыгыз сез аларны!

Пауза. Тикшерүче телефоннан шалтырата.

Тикшерүче. Кертегез.

Әсфан бик кызыксынып карап тора, Сәлимә керә.

Әсфан. Бу сезме?! Мең рәхмәтләр яусын сезгә! Минем нинди бәлагә таруымны ишетеп тә өлгергәнсез икән! Югыйсә монда булмас идегез. Менә бәхет! Поездда минем маңгайга чемодан килеп төшкәч тә ярдәмгә сез ыргылган идегез. Чәйханәдән чыгып китүемне дә күрми калмагансыздыр. Рәхмәт сезгә! Искиткеч мәрхәмәтле, киң күңелле кеше икәнсез! Шулай дип уйлаган да идем мин аны: күпне кичергән кеше башкаларга да мәрхәмәтле була ди минем Фәүзиям. Килүегезгә рәхмәт! Ямьсез булырга ярамый миңа! Туктагыз әле, сез минем мондалыкны каян белдегез?! Сезне чакырып китерделәрме? Аңламыйм.

Т и к ш е р ү ч е. Хәзер аңларсыз. Гражданка Якупова, утырыгыз. Сез бу кешене таныйсызмы?

С ә л и м ә. Танымаска! Без бер поездда, бер купеда кайттык.

Т и к ш е р ү ч е. Сез дә шуны раслыйсызмы, Әсфан Гайсин?

Ә с ф а н (*сөенеп*). Расламыйча!

Т и к ш е р ү ч е. Бер-берегезгә карата дошманлык, үчегү кебек нәрсәләр юкмы?

Ә с ф а н. Нинди дошманлык булсын ди мондый мәрхәмәтле апага?! Чын күңелемнән рәхмәт! Миңа ямьсез булырга ярамый! Һич! Сөйләгәч, Фәүзия дә яратыр сезне, безгә кунакка килерсез.

Т и к ш е р ү ч е. Бик яхшы. Алайса, гражданка Якупова, тагын бер мәртәбә барын да сөйләп бирегез!

Ә с ф а н. Рәхмәт сезгә! Сез мине коткарырга килеп җиткәнсез ич! Чын күңелемнән рәхмәт!

С ә л и м ә (*паузадан соң*). Әшәке кеше ул! Миңа купеда ук бәйләнә башлады.

Ә с ф а н. Ничек? Ничек? Бу сезме, апа?

Т и к ш е р ү ч е. Үтенәм, бүлдермәгез.

С ә л и м ә. Бәйләнә дә бәйләнә, тәмам сыткый сагыз булды. Кул салырга азаплана. Качам, артымнан коридорга чыга! Бөгелмәгә кайтып төшкәч бөтенләй затсызланды: «Әйдә, ди, монда безне белүче юк, дигән була. Гостиницага кереп кунабыз»,— ди. Үтерепләр кыстый.

Ә с ф а н. Ялган! Яла!

Т и к ш е р ү ч е. Түземлерәк булыгыз, зинһар!

С ә л и м ә. Миңа, намыслы хатынга, шундый сүзләр кушып карады бу, сөйләсәң, чәчең үрә торыр! Хәер, ирләрне кем белми?! Һәммәсе бер чыбыктан сөрелгән, куллары озын, күңелләре дөм кара! Һәммәсе бериш. Ата этләр! Поездан төшкәч тә артымнан калмый, мин утырган автобуска сөрелеп кергән. Автобуста да гел бәйләнеп кайтты. Җитмәсә, күзен тондырып, артымнан чәйханәгә үк килеп кергән. Ышан син ирләргә!

Ә с ф а н. Нишлисез сез?

Т и к ш е р ү ч е. Дәвам итегез.

Ә с ф а н. Сөйләгән кадәресе дә минем башны бетерергә җиткән ич!

С ә л и м ә. Чәйханәдә дә күз кыса бит, оятсыз!

Ә с ф а н. Сезнең якка әйләнеп тә карамадым.

Т и к ш е р ү ч е. Сөйләп бетерегез, гражданка Якупова.

С ә л и м ә. Чәй эчкәч урамга чыктым. Ул мине сагалап тора иде. «Әнә, ди, машина әзер, хуҗасы күренми,

утырыйк та берәр аулакка ычкыныйк»,— ди. Бараммы соң?! Мин честный хатын! Аллам сакласын! Үтереп кыстый бу! Ирләр, ирләр! Һәммәсе ояттан җәяүләп качкан!

Т и к ш е р ү ч е. Җәяүләп?!

С ә л и м ә. Шуннан бу кеше ачуыннан буылып машинага утырды да җилдәй очты. Артыгын белмим. Бер-ике тапкыр кибеткә кереп чыктым. Күчтәнәчләр аласым бар иде. Кайтырга машина көтеп торганда, яныма ике милиционер килеп басты. «Чәйханәдә булдыңмы?» диләр. Булдым, дидем. Күрдеңме, диләр. Күргәнне күрмәдем дип әйтә алмадым. Мин намыслы хатын! Тагын әйтәм, машинага утырып киткән кеше менә ул! Үзе! Кем машинасыдыр, анысын белмим. Бәлки, аныкыдыр.

Пауза.

Т и к ш е р ү ч е. Хәзер ни әйтәсез, гражданин Гайсин?

Ә с ф а н. Ха-ха-ха! Ну кызык! (*Көлә.*) Әкият! Сез мине сынарга телисезме? Шаяртасызмы?

Т и к ш е р ү ч е. Эшнең шаярудан узганын һаман аңламадыгызмы?

Ә с ф а н. Кара ялганны ничек шулай чын итеп сөйләмәк кирәк? Ничек?

С ә л и м ә. Нигә ялганлыйм ди мин? Мин сезне беренче мәртәбә күрдем. Йомышым төшкәне булмады.

Ә с ф а н. Булды. (*Маңгай ярасын күрсәтә.*)

Т и к ш е р ү ч е. Маңгай ярагызның сәбәбен кабатлагыз әле.

Ә с ф а н. Өстән бу апаның чемоданы төште.

С ә л и м ә. Алдалый! Бу кешенең эче тулы мәкер. Хәйлә! Ни әйтсәң дә ир — ир инде! Үтмәс пычак белән тунар идем мин аларны! Кәләше янына кайтып бара, үзе миңа кул сала! У-у-у! Ирләр алар!

Т и к ш е р ү ч е (*аны бүлдереп*). Әлегә чыгып торыгыз.

Сәлимә чыга.

Т и к ш е р ү ч е. Инде хәзер ачыктан-ачык сөйләшик.

Ә с ф а н. Нинди сөйләшү?! Монда сүзгә урын калмаган, беткән. (*Кул хәрәкәтләре ясый.*) Мин бу апага барын да сөйләдем. Аңлыйсызмы? Нигә ачтым икән мин аңа күңел серләремне? Туган илгә якынайган саен күбрәк ачылдым. Шуңа үкенәм хәзер! Якты уйларымны, татлы хыялларымны кемгә ачып барганмын бит! Мин — бәхетле җүләр! Тинтәк! Нигә сөйләдем икән мин аңа барын да?! Әһә, хәтеремә төште. Ул башта гел зарланды, гел сукранды. Кайнар чәйне дә салкын дип, йомшак

урынны да каты дип, тимер юлчыларны сүкте. Купедашларга бәйләнде... Кешеләр явыз, кешеләр бер-берсен чәйнәп ташларга әзер, туганнар мөртәт хәзер, диде. Ничек шундый сүзләр әйтә алган кеше белән бер купеда ике тәүлек кайтмак кирәк? Минем күңел күтәрелгән саен, аның чырае караңгылана бара. Моңа ничек түзәргә кирәк? Мин аңа киресен ышандырырга тырыштым. Үгетләп, тынычландырып карадым. Юаттым! Күргән кинолардан, укыган китаплардан мисаллар китердем, ышандырып кына булмый бит! Барабыз, вакыт күп, үз тормышымны, кичергәннәремне сөйләргә тотындым мин аңа. Минем язмышта да гыйбрәтләр бар бит! Бар! Фәүзия турында да сөйләдем мин аңа! Нигә сөйләдем, нигә телгә алдым икән? Кызгандым мин бу апаны, ярдәм итәсем, күңелен күтәрәсем килде. Бәхетсез язмыш яныннан тыныч кына узып китә алмадым! Их, белгән булсам, сизенгән булсам, поездан сикереп төшеп җәяү йөгергән булыр идем!

Тикшерүче. Гражданка Якупова кая һәм ни өчен юлга чыгуы турында сөйләдеме?

Әсфан. Мин сорашмадым. Анда (*кулы белән билгесез якны күрсәтә*), үткәннәр турында кеше үзе сөйләмәсә, төпченү юк! Гел аның күңелен ачарга тырыштым. Сары чемоданы маңгайга чәчрәп төшкәч тә көлгән булдым бит әле! Их, мәми авыз!

Тикшерүче. Безнең уртак бурыч — дөреслекне табу.

Әсфан. Минем чемоданда Фәүзиядән килгән хатлар. Шулар шаһит була алмыймыни? Хатларга ышанмыйсызмы сез? Купеда тагын ике кеше бар иде. Хәер, алар тагын ни сөйләмәс?!

Тикшерүче. Без барын да ачыкларга тырышырбыз.

Әсфан. Фәүзияне чакыртыгыз! Ул белә!

Тикшерүче. Ул иртәдән бирле монда.

Әсфан. Монда?

Тикшерүче. Кәбир исемле егет тә монда.

Әсфан. Ул да?!

Тикшерүче. Агроном Сөнгать... Якупов та монда.

«Якупов» фамилиясе Әсфанга ничек тәэсир итәр икән дип сынап карый, әмма Фәүзия белән мавыккан егет моны сизми.

Әсфан. Фәүзия белә икән! Әти-әни дә белә торгандыр. Кирәкмәс иде! Яман хәбәрне тиз җиткергәнсез. Ярамый иде. Ничек түзәр алар? Ишетүләрен бер дә теләмәгән идем. «Кайта алмадым, беразга тоткарландым»,— дип телеграмма сугуыгызны үтенергә иде исәп.

Тикшерүче. Күрешми кала алмассыз.

Әсфан. Юк, юк. Әгәр гаепсезлегемне болай раслый алмасагыз, миңа бер генә юл кала!

Тикшерүче. Җүләрләнмәгез!

Әсфан. Минем күкрәктә нинди утлар кайнаганын күрә алыр кеше бармы икән?!

Тикшерүче. Бәлки, Фәүзиянең үзен генә күрергә телисездер?

Әсфан. Нинди кискен, җан өшеткеч сорау бирәсез сез! Нинди мәкерле! Мин бит аның янына төгәл өч ел кайттым. Өч ел зур ара! Мөгаен, сезнең беркемне дә сөеп караганыгыз юктыр! Салкындыр сезнең җаныгыз!

Тикшерүче (*беренче тапкыр аның җаны һәм тавышы калтыранды*). Җаным салкын булса, мин сезне күрештерергә тырышып йөрер идемме? (*Исенә килеп.*) Гафу итегез...

Чыга. Әсфан гасабиланып бүлмә буйлап йөри. Тәрәзәгә бара. Фәүзия керә.

Фәүзия. Әсфан!

Әсфан. Фәүзия!

Фәүзия. Әсфан, исәнме. Кайтуың белән котларга ярыйдырмы?..

Әсфан. Ни әйтим соң сиңа, Фәүзия? Ни әйтим?

Фәүзия. Ашыкма, дустым.

Әсфан. Әтиләр ничек? Алар да ишеттеме?

Фәүзия. Әлегә белдермәдек. Әйтә алмадым. Сүзләрен табалмадым. Мин ышанмадым, Әсфан! Хәзер дә ышанмыйм. Барысы да саташулы авыр төш сыман гына тоела. Ни булды, җаным?!

Әсфан. Ничек итеп, нинди дөрес сүзләр белән аңлатыйм икән, Фәүзия? Белмим. Исем-һушым таралды. Башым эшләми.

Фәүзия. Белергә иде бит, Әсфан. Белергә!

Әсфан. Бар мәшәкать тагын синең өскә төште, Фәүзия. Моннан торып үземне ничек аяп алыйм? Тик ышан: юк гаебем, юк! Бөтен өмет синдә. Минем сүзләремнең бәһасе юк.

Фәүзия. Бар, Әсфан, бар.

Әсфан. Әти нишләр?! Әни?! Туганнар!

Фәүзия. Мин башта арага Чал килеп кысылмадымы икән дип бик курыккан идем.

Әсфан. Чал?.. Әйе, Чал!.. Бар икән әле ул кырау тимәс шайтан таягы! Юлларыбыз мәңгегә аерылды дип ялгыш кына юанып йөргәнмен икән мин, Фәүзия!

Фәүзия. Сөйләп бетер.

Әсфан. Мин аны кичә күргән кебек булдым.

Фәүзия. Кайда?

Әсфан. Автобустан төшкәндә шәүләсе чагылып китте. Ул минем кайчан кайтасымны белеп тора! Тегендә элемтәсе бар, бар!.. «Москвич»та да ул куып узды мине!

Фәүзия. Ул?! Син боларны сөйләдеңме?

Әсфан. Үзем дә ышанып бетмәгән нәрсә! Җитмәсә, теге хатын кереп башны бутады... Шаһит хатын. Хәзер минем өскә күрсәтеп торганда, кем ышаныр?.. Күземә генә күренгәндер дип уйлыйм.

Фәүзия. Бик нык уйла, Әсфан.

Әсфан. Рульдә Чал иде! Ул!

Фәүзия. Нишләргә? Нишләргә?

Кәбир керә.

Кәбир. Исәнме, Әсфан абый! Менә, Кәбир дигән егет мин булам инде.

Әсфан. Кәбир дә килгән икән. Кәбир...

Кәбир (*бераз карап торгач*). Фәүзия апа, ул теге сүзләрне әйтмәде.

Фәүзия. Урыны башка, Кәбир, ул түгел!.. Без мондый очрашуны күз алдына да китермәдек бит!

Кәбир. Әсфан абый, нишләдең син? Нишләттеләр сине?

Әсфан. Дөньяда төрле җаннар бар, Кәбир. Мин моны элегрәк тә белә идем. Әшәкеләр арасыннан мәңгегә чыгып котылдым дип сөенгән идем. Юк икән, баштан ук туры атлап китмәсәң, аяк гел чалыш атлый икән!

Фәүзия. Дөрес түгел!

Әсфан. Дөрес атлый башласаң да сугып сындыралар икән әле аякны, Фәүзия! Их, шушы минутта югаласы иде! Җир тишегенә кереп чумасы иде! Беркем сине белмәсен иде! Бөтен дөнья онытсын иде сине! Урманнарга барып бүреләргә кушылып улыйсы иде!.. Рәхмәт сиңа, Фәүзия! Оныт бүгеннән мине! Өстеңә артык йөк, мәшәкатьләр алма! Гомер кыска, бушка узмасын яшьлегең! Оныт! Син дә оныт, Кәбир дус!

Җырлый.

Атлар чаба, чаба! Еллар ялбыр,
Эшлияләр тоташ җиз генә!
Бик сагынсаң, саргайсаң да
Кайтып булмый икән тиз генә!

Тикшерүче керә.

Т и к ш е р ү ч е. Гражданин Гайсин, без сезне чыгара алмыйбыз. Бу район прокуроры белән килешенгән.

Ә с ф а н. Мондый сүзне Фәүзия алдында әйтәләрме соң? Их, сез!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Авансценага чалгы күтәреп Г а й с ә карт керә, ак төенчек тоткан М ә д ә н и я аны озата.

М ә д ә н и я. Сиңа әйтәм, озак юанма. Йә кирәгең чыгып куяр.

Г а й с ә (*ярым көйләп*). Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм, сиңа әйтми кемгә әйтәм?!

М ә д ә н и я. Өйдә бер башым ничек чыдармын инде?

Г а й с ә (*һаман үз уйларына чумып*). Беребез кояш чыгышында, беребез баешларында.

М ә д ә н и я. Кичә дә чак-чак көтеп алдым.

Г а й с ә. Сынды сабыр канатларым... Ә? Ни дидең? Түз, карчык. Түз! Чыда! Сынма! Чатнама! Сиздермә! Яме? (*Пауза.*) Тагын аз гына озата бар инде.

М ә д ә н и я. Фәүзия кызымны озатасым бар.

Г а й с ә. Озатасың да озатасың! Озатырга бик остарып киттең әле.

М ә д ә н и я. Бер дә чыдар кук тимим. Йөрәгем шартлап урыныннан кубар төсле.

Чыгалар. Пәрдә ачыла. Бүлмә. Т и к ш е р ү ч е белән Ф ә ү з и я каракаршы утырып сөйләшәләр.

Т и к ш е р ү ч е. Әгәр сез теләсәгез, мин бу эштән баш тарта да алам.

Ф ә ү з и я. Юк, юк!

Т и к ш е р ү ч е. Күңелегездә шик калмасын дим!

Ф ә ү з и я. Сезнең ни әйтергә теләгәнегезне аңлыйм, Гөлйөзем Маннаповна!.. Әгәр эшләр болай тирәнгә китмәсә, мин бу сүземне, мөгаен, әйтмәгән дә булыр идем. Хәзер әйтәм!.. Әйе... Без Сөнгать белән Чибәркүлгә бер елны килдек... һәм бик тиз дуслаштык та бугай... Яшь белгечләр. Яңа авыл, яңа кешеләр безне еш аралаштырды... дуслаштык. Без хәзер дә якын дуслар!.. Сөнгать сезнең белән очраша башлагач, мин чын күңелемнән куандым! Тиңнәр сез!

Т и к ш е р ү ч е. Эш бүлмәсендә мәхәббәт турында сүз кузгаттык.

Фәүзия. Бәлки, монда ул турыда ешрак сөйләшергә кирәктер дә?

Тикшерүче. Белмим, инде сүзе кузгалгач, уемны дәвам итәм. Әйе, мин Сөнгатьне яратам. Яраткан кешенең көнләшүе дә табигый...

Фәүзия. Юк, юк, без Сөнгать белән дуслар гына!

Тикшерүче. Әсфан Гайсинның эшен башка кеше алып барса, уңайрак булмасмы диюем?!

Фәүзия. Күңелегез саф, вөҗданыгыз керсез икән, ахыргача алып чыгыгыз инде, Гөлйөзем Маннаповна! Мин Сөнгатьнең булачак тормыш юлдашының ышанычлы иптәш булуын телим...

Тикшерүче. Рәхмәт, Фәүзия.

Фәүзия. Мин Әсфанның керсез булуына ышанам!

Тикшерүче. Ә өйдәгеләр? Ата-анасы?

Фәүзия. Гайсә бабай шикләнә!.. Шиген белдермәсә дә, күңеле боек.

Тикшерүче. Фәүзия! Без кулдан килгәннең барын да эшлибез. Тик...

Фәүзия. Әйе... Сәлимә апа... Аның сүзләре авыр...

Тикшерүче. Өметне өзмик!

Фәүзия. Юк, юк! Өмет бит ул язмышлар бәйләнеше. Өмет — көрәш! Өмет — ышаныч! Өмет — яшәү чыганагы! Өмет — дуслык, туганлык, мәхәббәт бит ул өмет!..

Тикшерүче. Сөнгатьнең ни өчен сезгә гомергә гашыйк икәнлегенә бүген генә ышандым!.. Хәзер Гайсинны кертерләр.

Фәүзия. Туктагыз!.. Бер генә минутка. Тынычланыйм инде. Хәзер керсен.

Тикшерүче чыга, Әсфан керә.

Әсфан. Фәүзия, тагын килдеңме, кадерлем?

Фәүзия. Саумы, Әсфан.

Әсфан. Нихәлләр дип сорарга куркам.

Фәүзия. Гайсә бабай белән Мәдәния әби икәүләп сәлам әйтеп калдылар. Әлегә бик сихәтләр. Менә сиңа өчпочмаклар. Ярмалы бәрәңге. Май. Каймаклы сөт.

Әсфан. Кая шулкадәр...

Фәүзия. Аша, аша. Мәдәния әби «ашасын» дип әйтеп калды.

Әсфан. Тәгаен шулай дидеме? Әллә син мине гадәтеңчә юатырга гына телисеңме?

Фәүзия. Авылда беркем дә синең гаепле булуыңа ышанмый! Беркем дә! Һәммәбез тикшерү беткәнне көтәбез. Һәммәбез, ишетәсеңме, Әсфан.

Әсфан. Сөйләшмик әле без ул хакта.

Ф ә ү з и я. Җылы хәбәрләр барыбызга да тансык, Әсфан. Кинәнә-кинәнә сөйлим, дустым: бөтен авыл җылы караш белән сине көтә!

Ә с ф а н. Авыл турында сөйләшәсем дә, ишетәсем дә килми.

Ф ә ү з и я. Монысын синең рәнҗегән күңелең генә әйтә!

Ә с ф а н. Фәүзия! Сыең өчен мең рәхмәт! (*Пауза.*) Менә син күпме хатлар яздың. Һәммәсен күңелдә саклыйм! Очрашкачниләр сөйләшмәдек?.. Күпме акыллы сүзләрне синнән ишеттем. Куандырдың. Күңелемне баеттың. Мине кеше иттең! Тагын бер, бер генә акыллы киңәшеңне нигә жәлләдең икән миннән?! Нигә анысын кызгандың?!

Ф ә ү з и я. Күңелем тулаем ачык иде, Әсфан. Бар булганы уртак иде.

Ә с ф а н. Синең бер сүзең җитә иде, югыйсә, ымың җитә иде, ишарәң!!

Ф ә ү з и я. Тыңлыйм, Әсфан.

Ә с ф а н. Монда кайтмаган булсамчы мин! Азмы илдә шәһәрләр, гигант-төзелешләр, йөзләр, меңнәр көн саен күчеп тора! Анда һәркемнең үз язмышы.

Ф ә ү з и я. Һәркемнең язмышы ил язмышы белән бәйләнгәндә генә тормыш бөтен була, егет!

Ә с ф а н. Кайтмаган булсамчы!

Ф ә ү з и я. Син алай кинәт уйлама. Авырлык төшкәндә кисkenлектән саклан.

Ә с ф а н. Кинәт түгел! Гел уйда мин.

Ф ә ү з и я. Җырлап та аласың икән!

Ә с ф а н. Их, Фәүзия! (*Җырлый.*)

Ургый-ургый ага сулар,
Ургый алар түбәнгә.
Җырламыйм бүген шатлыктан,
Җырлыйм җаным көйгәнгә!

Ф ә ү з и я. Әсфан!

Ә с ф а н. Йокым да юк. Көнне төнгә уй белән тоташтырам. Уйларымның чиге-кырые юк. Әле дә соң түгел! Ишетәсеңме, Фәүзия?

Ф ә ү з и я. Ничек?

Ә с ф а н. Моннан чыгып китү берни түгел!

Ф ә ү з и я. Хуш, качтың ди?

Ә с ф а н. Син риза булсаң, мин әзер? Синең белән кайда да югалмыйм мин! Икәү янәшә булсак, беркем миңа шикләнеп карамас! Ышан: минем гаепсезлегем ачылыр!

Ф ә ү з и я. Беләм.

Ә с ф а н. Күземне күтәреп карый алмыйм. Авыр! Күзем

ял итәрлек бер нур бәйләме булып син генә калдың! Беркемне күрәсем килми. Мине дә күрергә теләп атлыгып торалардыр дип уйламыйм. Әти белән әнигә дә моннан ераккарак китсәм җиңелрәк булыр. Аларга да нигә күз көеге?! Китик, җаным!

Фәүзия. Китик дисең икән! Китик... Юк, Әсфан. Әти, әниең... Авыл! Минем укучыларым. Арадан берсе Кәбир. Мин аларны унынчыга кадәр алып барырга телим. Кем булырлар алар? Ничек? Минем беләсем килә, Әсфан.

Әсфан. Мин һаман тәҗрибә өчен кирәкме сиңа?

Фәүзия. Мин синең һәм башкаларның шулай уйлавыннан бик куркам! Дөрес, мин сине бик яратам. Өзелеп, өзелеп сөям. Синсез тормышны, тормышымны күз алдыма китерә алмыйм. Әмма минем тормышым сиңа мәхәббәтем белән генә чикләнмәгән.

Әсфан. Әкиятләрдәге сөт казаны булсын иде! Чумасы иде дә башка кеше булып чыгасы иде!

Фәүзия. Язмышыңа үзең хуҗа бул!

Әсфан. Тагын бер ялачы хатын килеп чыгар да... Их! Каян шулкадәр явызлык була икән кешедә, Фәүзия?

Фәүзия. Ул хатын агрономыбыз Сөнгатьнең туган апасы булып чыкты.

Әсфан. Кайда ул хәзер?

Фәүзия. Чибәркүлдә.

Әсфан. Безнең авылдамы? Кайта калсам, муенын борып ыргытам ич мин аның! Тереләй утка тыгам!

Фәүзия. Башта кайт әле.

Әсфан. Һаман сыныйсыңмы?

Фәүзия. Сизгерлегең өчен рәхмәт. Мин синең белән гомер юлын кичәсе ич, Әсфан. Алда ниләр булмас? Без барасы юлларга берәү дә чәчәк сибеп куймаган. Шәфкатьле бул!

Әсфан. Кинәт аңгырайдым. Кешеләрне аңламыйм.

Фәүзия. Ә кешеләр сине аңлый. Гаепсез, диләр.

Тавыш. «Гайсин, тикшерүче янына!»

Әсфан. Аңлагач, тикшерүче янына нигә мин йөрим? Нигә мин монда? Нигә ышанмыйлар?!

Фәүзия. Мин ышанам, Әсфан. Без сине бик сагынабыз. Көтәбез. Берүк ялгыш уйларга баш бирмә. Үтенәм! Хаклык юл ярмый калмый ул, Әсфан!

Чыгалар. Сәхнә караңгылана. Пәрдә ачылганда сәхнәдә беркем дә юк. Гайсә карт йорты. Бераздан чалгы тотып Гайсә күренә, Мәдәния әби аны озата.

Мәдәния. Кичә дә чәеңне юньләп эчмәгәнсең, сиңа әйтәм. Көн эссе, башыңа кояш капмасын.

Г а й с ә. Ярар, ярар.

М ә д ә н и я. Чәеңә карлыган яфрагы да йөздердем.

Г а й с ә. Ярар, ярар.

М ә д ә н и я. Бик тырышып талчыгып китмә тагын, ял итә-итә чап.

Г а й с ә. Ярар, ярар.

М ә д ә н и я. Сиңа әйтәм, нәрсә тартай төсле, «ярар да ярар» дип торасың?

Г а й с ә. Бу коймага тагын кем кагылган? Кичтән генә рәшәткәләрнең һәммәсен барлап, какшаганнарын кадаклап чыккан идем бит!

М ә д ә н и я. Ай Аллам, белмим.

Г а й с ә. Бүген иртәрәк кайтсам, капканы да күтәртеп куям. Мунча утыныӊ да азайган. (*Китә башлый.*)

М ә д ә н и я. Нигә урамнан гына төшмисең? Аннан турырак бит.

Г а й с ә. Кайдан туры, кайдан кыек икәнне кем белгән, карчык.

М ә д ә н и я. Ни булды икән безгә? Кем каргады икән? Кемгә зыяныбыз тиде икән?

Г а й с ә. Мин бернәрсәне генә беләм: безгә чыдарга кирәк. Түзәргә калды, түзәргә. Малай гаепсез... Шулай дип беләм. Ул чаклы ук чамадан ашкан җүләр түгел. Сабагын укыган. Монда нидер бар.

М ә д ә н и я. Мин кабартма да тыккан идем.

Г а й с ә. Төенчектә димим лә мин!

М ә д ә н и я. Әллә янына син дә барып кайтасыңмы?

Г а й с ә. Фәүзия кызыма ияреп китмәк булам, әллә нигә күңелемнең җегәре, ныклыгы юк.

М ә д ә н и я. Күрәм, икеләнәсең син.

Г а й с ә. Дәшмә, карчык. Түз, чыда. (*Чыга.*)

М ә д ә н и я. И, булыр микән безнең дә урам иңләп йөрер чагыбыз? (*Җырлый.*)

Түбәләргә тия язып, түбәләргә,
Киек казлар гына үттеләр.
Һәй, киек казлар!
Һәй, киек казлар!
Сезсез булмыйдыр язлар!
Күңелләргә тия язып, күңелләргә,
Сагышларын җиргә сиптеләр.
Һәй, киек казлар!
Һәй, киек казлар!
Сезсез кайтмыйдыр язлар!

Керео китә. С ө н г а т ь белән С ә л и м ә керәләр.

Сөнгать. Кара, кара, апа! Күзеңне ыграк ач! Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзе ботак тишеге диләр. Мондый хәлдә ботак тишеге дә күреп яшь агызыр иде. Кара!

Сәлимә. Нигә син тотасың да мине шушы йорт янына алып киләсең?

Сөнгать. Гайсә бабай! Җиде бала үстергән ата. Син бит аның берсен дә үстермәгән. Сугыш ветераны! Көчкә-көчкә аягын сөйрәп бара. Башы иелгән...

Сәлимә. Аның яшенә җитә алсам әле мин...

Сөнгать. Мәдәния әби... Гомере буе ял күрмәгән ана!.. Син бит ул эшләгәннең чиреген дә эшләмәгән! Сабыр гына тыныч картлык өметләнеп торган кеше.

Сәлимә. Минем нужам артыннан йөреп картаймаган әле.

Сөнгать. Син әллә Гайсә бабайны чыннан да печән чабарга бара дисеңме? Чапмый ул, хәле юк, әрәмә арасына керә дә яшеренеп ята. Әби дә аның печән чабарга бармаганын белә. Белә, Сәлимә апам.

Сәлимә. Син ник миннән: «Хәлең ничек?» — дип сорамыйсың?! Ник күземә шырпы төртәсең? Минем үз хәлем хәл.

Сөнгать. Сөйләшеп бетерик. Нишләдең син? Чибәркүл авылына, шушы нигезгә нинди кайгы китерүеңне аңлыйсыңмы?

Сәлимә. Ә, теге шома егетне әйтәсеңме? Кояш күк балкып кайтып килә идеме? Илгә сыймый кылана идеме?! Нәкъ мин сөйләгәнчә булды — арттырмадым да, киметмәдем дә. Андый тәрбиям юк.

Сөнгать. Ялган! Алдыйсың, апам!

Сәлимә. Минме ялганлыйм?! Ялынып-ялварып чакырып кайтардың да аягымнан юл тузаны төшмәс борын миңа җикеренәсеңме? Күрешкәннән бирле дөм орылып торасың. Читләрне жәлләгән була!

Сөнгать. Хәзер мин барын да аңлыйм.

Сәлимә. Аңласаң, кычкырмас идең!

Сөнгать. Биш тапкыр иргә чыктың. Ни өчен ирдә тора алмавың көн кебек ачык. Бер урында эштә төпләнә алмавыңның да сере билгеле. Син аяк баскан җирдә үлән үсми! Үләт, мур алып киләсең син. Аяк араңа бәла уралып йөри. Каза! Кайгы!

Сәлимә. Җикеренмә. Карганма да. Үкенерсең! Мин биш ирдән калмаган.

Сөнгать. Язгалап тордың.

Сәлимә. Мин бер иргә биш тапкыр чыктым! Телең озайтма. Ә Әсфанны әйткәндә, һәммәсе мин күрсәт-

кәнчә булды. Апаңа, намыслы хатынга кул озайтып азапланды.

Сөнгать. Туган авылы, ата-анасы, кура җиләгедәй кыз өзелеп көтеп торганда ул синең ишеләргә карап торган ди!

Сәлимә. Ирләргә ышаныч юк, җаныккачаем! Син һаман бер катлы дурак икәнсең. Әсфанны утырталар. Фәүзиясе сиңа калды. Өйлән, тормыш корып җибәр. Шәфкатьле күренә ул. Шәфкатьлеләр арасында яшәргә була. Мин дә, Аллаһы боерса, сезнең янга сыенырмын. Авылыгыз матур. Халык сабыр, кунакчыл.

Сөнгать. Кылган гамәлләреңнән, китергән кайгы-хәсрәтләреңнән соң монда кала алыр идеңме?

Сәлимә. Сиңа бәла-каза китергәнем юк. Бер тамагымны күпсенәсеңме әллә?

Сөнгать. Юк, монда кала алмыйсың.

Сәлимә. Яңгыр ява, суы сеңә. Яуган кебек тә түгел! Башка барыр урыным юк. Соңгы өметем син. Чәчрәп китсәләр дә монда калам.

Сөнгать. Ни булды сиңа, апам? Чибәр генә, сабыр гына кызчык идең.

Сәлимә. Тыңла, алайса. Мыегыңа чорна! Бала чакта бергәләп гарәп әкиятләре укый торган идек. Исеңдәме? Авызын пичәтләгән кувшинга салып явыз Гыйфритне диңгезгә ыргыталар. Йөз ел тилмерә бу диңгез тоткынлыгында. Һәм: «Коткаручыма бик күп итеп акча бирер идем!» — дип адарына. Коткармыйлар бәхетсез Гыйфритне! Юк! Тагын нәкъ йөз ел яткач: «Коткаручымның бар теләгән үтәр идем»,— дип әйтеп карый. Табылмый коткаручы! Тагын биш йөз ел кысан кувшинда газап чиккәч: «Коткаручыма җир хәзинәсен ачар идем!» — дияргә мәҗбүр була. Тагын мең ел ятып, бөтен тәненә риматиз алгач, котылырга өмете киселгәч, ачудан: «Әгәр берәрсе мине бу газаплардан коткарса, мин аны үтерер идем!» — ди... Һәм ни була? Гыйфритне диңгез төбеннән балыкчы карт тартып чыгара.

Сөнгать. Диңгезе тозлы булгандыр, әкиятеңнең тозын күрмим.

Сәлимә. Тозны күрмиләр, татып карыйлар! Әллә минем күңелдә шәфкать-мәрхәмәт калгандыр дип беләсеңме? Мең ел газап чиктем. Мең ел! Берәрсеннән рәхим-шәфкать күрдемме? Әйтик, менә синнән!

Сөнгать. Әфарин! Әсфанның бер гаебе дә юк. Син зәһәр усалланып кына аңа яла ягасың! Аның кояш күк балкып кайтуы ошамаган син явызга!

Сәлимә. Бәхетле икән... Аны бик нык көтәләр икән...

Өзелеп-өзелеп төрмәгә хатлар язганнар икән, әйдә, котылып карасын.

Сөнгать. Тот!

Сәлимә. Нәрсә бу?

Сөнгать. Юлыңа акча. Самолет белән китәсеңме, поездга утырыпмы, машина яллыйсыңмы? Теләсәң «Метеор» — озатам! Тик кит кенә! Кит, зинһар! Олак!

Сәлимә. Мин барасы җиргә акчаң җитмәс, өтек! Мин оҗмах эзлим. Таптым да. Китмим!

Фәүзия белән Кәбир керәләр.

Фәүзия. Кемне куасың болай, Сөнгать?

Сөнгать. Башыбызга төшкән бәла-казаны куам, Фәүзия.

Сәлимә. Ни зыяным тигәндер аңа, бәйләнде.

Фәүзия. Зыян ягын әлегә калдырып торыйк... Тик сезгә моннан китәргә ярамый. Ярамый.

Сөнгать. Ул минем кунагым. Гөнаһ шомлыгына каршы, аны мин чакырып кайтардым. Апа минеке. Монда минем гомер кичәсем бар. Хәзер миңа ап-ачык: апам Әсфанга яла яккан!

Кәбир. Алдаганмы?

Фәүзия. Тимәгез аңа! Кагылмагыз! Мөгаен, шулайдыр да... Тик Әсфан котылып чыгып Чибәркүлгә кайтканчы апа монда калырга тиеш. Мин Әсфанның йөрәге аяусызлануын теләмим. Закон буенча Сәлимә апага җәза төстер, бәлки... Әмма минем өчен бүгенгә бу хәлләргә Әсфанның мөнәсәбәте мөһим. Күңелендә үч ачысы калмасын аның. Мин менә шулайрак уйлыйм.

Сөнгать. Фәүзия!

Фәүзия. Синең башка фикерең бармы, Сөнгать?

Өйдән Мәдәния чыга.

Мәдәния. Кызым, балам! Кайтып та җиткәнсең икән.

Фәүзия. Мәдәния әби! Күрештерделәр. Ризыкларны тапшырдым. Тамагына бик әйбәт ашый. Ябыкмаган. Сәлам әйтеп калды.

Мәдәния. Тагын озак торырмы икән?

Фәүзия. Озакламас.

Кәбир. Мин дә шулай дим!

Сөнгать. Ишетәсеңме, апам? Ишет, тыңларга өйрән!

Фәүзия. Менә тормыш ничек бит ул, Мәдәния әби. Тагын бер адашкан күңел безнең арага килеп керде.

Мәдәния. Кемне әйтәсең син, кызым-балам?

Ф ә ү з и я. Сөнгатьнең апасы Сәлимәне әйтәм. Чибәркүлдә төпләнергә ниятләп кайткан икән.

М ә д ә н и я. Ничек диден? Ходаем-мәүләм, шул тасма тел, шул гайбәтче, яла ягучы, газиз улымның башкайларын ашаган бәндә безнең урамнарда йөрергә исәп тотамы? Бабаң казыган коеларның, чишмәләрнең суын эчәргә яскынамы? Җир йотар!

Ф ә ү з и я. Әгәр шундый шартларга да ризалашып кала икән, Сәлимә апаның узган юллары рәхәт үк булмагандыр! Аның җаны да тынычлык, татулык эзлидер, бәлки. Калсын, торсын, күрсен.

С ә л и м ә (*Сөнгатькә*). Менә, үзең күр! Үзең ишет! Туганны какканны ил кага!

С ө н г а т ь. Мәдәния әби, хафаланмагыз, китә ул. Озатам.

К ә б и р. Дөп-дөрес!

Ф ә ү з и я. Китми ул. Китә дә алмый. Шулаймы, Сәлимә апа?

М ә д ә н и я. Соң, Ходаем, ярты авылны сугыштырып, яртысын төрмәгә тыгачак бит ул!

С ә л и м ә. Китмә дип чын күңелеңнән әйтәсеңме, Фәүзия?

С ө н г а т ь. Фәүзия! Ялгышма! Юмартлыкның да кире ягы бар.

С ә л и м ә. Тик тор!

Ф ә ү з и я. Чын күңелемнән әйтәм, Сәлимә апа. Мин синең кешеләр арасындагы чынлыкны күрүеңне телим. Кеше язмышына кагылышлы гәп барганда ник арага ялган кыстырырга? Дөнья аяусыз. Дөнья хәтәр. Дөньяда хәзер һәрбер җан иясенә өчәр тонна шартлаткыч матдәләр әзерләп куелган. Көрәш көннән-көн кискенләшә бара. Илләрнең, халыкларның гына түгел, аерым кешеләрнең дә бер-берсенә мөнәсәбәте әһәмияткә ия. Кемнәр без? Кая барабыз? Ни телибез? Менә сез, Сәлимә апа, кеше. Кеше буларак дөньяда үз бурычыгызны үтисезме сез? Гаепләп сорамыйм, болай гына, беләсем килеп. Сәлимә апаны куып җибәрү ансат ул, Сөнгать дус. Нигә без гелгел ансат юл сайларга тиеш? Кая куабыз без аны? Кемнәр янына?!

М ә д ә н и я. Фәүзия, кызым-балам?!

Ф ә ү з и я. Гайсә бабай тагын печәндәдер инде?

М ә д ә н и я. Шунда инде, шунда. Кәбир балакаем, барып күз салып кына кайтчы! Көн яман кыздыра. Чирләпнитеп, хәле бетеп егылып ятмасын тагын. Фәүзия апа кайтты, диген.

Ф ә ү з и я. Бар, Кәбир акыллым.

Сәлимә. Китәм! Ну вас к черту! Каламмы соң монда! Җыен җүләр җыелган. Үз теләгем белән китәм, бел! Әйберләремне почта аша салырсың. Кара аны, бәрхет күлмәгемне алып кала күрмә! Китәм! (*Йөгерел диярлек чыгып китә.*)

Сөнгать. Апа!

Мәдәния. Китсен, китсен, ярабби...

Фәүзия. Тимә аңа, Сөнгать. Кеше күңеле бер уянмый калмас әле. Март азагында кар астына ут керә. Керми калмый, Сөнгать!

Сәхнә караңгылана.
Елга буе. Тал куаклары. Кәбир керә.

Кәбир. Гайсә бабай! Гайсә бабай!

Милиция киеменнән Чал күренә.

Чал. Әй, малай!

Кәбир. Ни бар, абый?

Чал. Син шушы авылныкымы?

Кәбир. Ә син үзең, абый, безнең районнанмы?

Чал.Ерактан дисәң дә ярый, якыннан дисәң дә дөрес.

Кәбир. Әйе, мин шушы Чибәркүлдән.

Чал. Авылыгызның агрономын беләсеңме?

Кәбир. Сөнгать абыйнымы?

Чал. Әйе.

Кәбир. Минем дус.

Чал. Алайса, яңарак кына кунакка кайткан апаны да беләсең инде?

Кәбир. Юк, аны белмим. Белергә дә теләмим.

Чал. Нигә?

Кәбир. Ялачы ул. Ялганчы.

Чал. Белмәгән кешене «ялачы» дип атыйсың, ай-яй!

Кәбир. Анысын бөтен авыл сөйли! Әсфан абыйны төрмәгә шул утырткан инде! «Машина урлап качты»,— дип өстеннән күрсәткән.

Чал. Шулай ук булганмыни? Так, так...

Кәбир. Үзе милиция, үзе шуны да белми.

Чал. Так, так...

Кәбир. Пумала белән авылдан сөрәләр иде, Фәүзия апа гына аралап калды.

Чал. Аралап дисең алайса? Авылда, диң? Калдымы?

Кәбир. Авылга бар да олылардан сораш, абый.

Чал. Вакыты җиткәч барырбыз да! Әлегә хуш!

Чыга. Кәбир ялгызы.

К ә б и р. Гайсә бабай! Гайсә бабай!

Г а й с ә керә.

Г а й с ә. Ник кычкырасың?

К ә б и р. Гайсә бабай, син монда бер кешене күрмәдеңме?

Г а й с ә. Беркемне дә күрмәдем.

К ә б и р. Әнә генә йөри ул! Әйдә, качып торабыз. Безнең район милициясе түгел ул. Мин анда хәзер бөтенесен дә беләм!

Г а й с ә. Тукта әле, улым.

К ә б и р. Монда таба килә!

Яшеренәләр. Ч а л керә. Юлдан ашыгып килүче Сәлимәне күреп туктала. Көтеп ала. С ә л и м ә керә.

Ч а л. Котың алынмасын, Сәлимә, мин йөрим әле монда.

С ә л и м ә. Син? Синме соң бу?!

Ч а л. Таныйсың ич.

С ә л и м ә. Каян килеп чыктың син, иблис?

Ч а л. Нишләп алай сөйләшәсең?

С ә л и м ә. Миннән сиңа ни кирәк, гыйфрит?

Ч а л. Аңлашасым килә.

С ә л и м ә. Аңлашасың килә? Синеңме? Син бит аңлатырга гына яратасың. Безнең арада нинди аңлашу калды икән? Белмим.

Ч а л. Мин дә шулай уйлаган идем. Онытып та бетергән идем мин сине.

С ә л и м ә. Тагын нигә эзәрлеклисең? Канымны эчеп туймадыңмы, аждаһа?!

Ч а л. Сине эзәрлекләмим. Түгел! Син арага көтмәгәндә килеп кердең. Очраклы рәвештә. Чын.

С ә л и м ә. Син дә очраклы гына үт тә кит инде ул чагында.

Ч а л. Күңел шушы якларга тарта! Китеп югалып торам да җәен тагын бер әйләнеп кайтам.

С ә л и м ә. Убырдыр син, җендер. Нинди киемгә төренгән!

Ч а л. Мин Әсфан кайтасын беләидем. Көтә дә идем. Очратасым да килә иде. Безнең исәп-хисап бетмәгән! Син минем «Москвич»ка утырып киткәнне күрдең!

С ә л и м ә. Күрмәдем.

Ч а л. Күрсәң дә сатмадың. Аядың мине. Коткардың. Алай гына да түгел, минем кан-җан дошманымны утыртып куйдың. Рәхмәт әйтергә тиешме мин сиңа? Тукта, алай гына да түгел!

С ә л и м ә. Торма юлымда, кансыз.

Ч а л. Менә мондый Сәлимә миңа ошый! Шәп!

С ә л и м ә. Үлгән җан!.. Бәхтияр иде бит синең исемең. Яратып сиңа кияүгә чыктым. Беренче тапкыр утыргач атна буе төрмә капкасын сакладым. Юк акчамны бар итеп сиңа ашарга ташыдым. Срок биргәч икешәр смена эшләдем. Тамагың ач булмасын дип посылканы өзмәдем. Котылып чыккач, сөенечемнең үлчәве булмады. Ике атнадан сине тагын камадылар. Бу юлы да ялгыш утырттылар дип ышандым. Өченче мәртәбә тотылгач кына караклыкның синең төп кәсебеңә әйләнүен күрдем. Анда да ташламадым, аягыңа егылып ялвардым. Шәһәрдән шәһәргә синең арттан ияреп йөрдем. Туганнар белән ара өзелде. Тора-бара тугры этеңә әйләндем. Урлаганыңны яшермәгән өчен мине кыйнап ташладың. Түздем. Чыдадым. Анда да мине кешегә санамадың. Мин усал күңелле кара эчле хатынга әйләндем, һәр бәхетле кешегә үчем бар иде минем, ачуым! Чөнки син минем дә җанымны суырып алдың. Хәзер каршыма ник чыктың?! Нигә елмаясың?!

Ч а л. Син көчле! Син минем дошманнарымны җиңдең!

С ә л и м ә. Кемнәрне?

Ч а л. Әсфан белән Фәүзияне!

С ә л и м ә. Синең өчен түгел. Үзем әшәке хәзер. Бозык!

Ч а л. Миңа барыбер. Миңа нәтиҗә кыйммәт!

С ә л и м ә. Ул егетнең ни гаебе бар иде соң? Без бер купеда кайттык. Карак булган. Төрмәдә утырган. Хәзер, балкып, өенә, сөйгән яры янына кайтып бара. Сөйләп сүзе бетми. Телендә ул гына! Күпме бүләкләр генә алган. Минме сине көтмәгән? Минме сине сөймәгән? Минме сиңа хатлар язмаган? Нигә соң шулай кайтмадың? Нигә сагынмадың мине? «Әгәр бик сагынсаң, кайтмый калмассың»,— дигән аңа Фәүзиясе. Минме аны әйтмәгән?! Инде хәзер үзең кебек бозык бәндәгә әйләнгәч кенә мине мактыйсыңмы?

Ч а л. Молодец икәнсең син, Сәлимә.

С ә л и м ә. Сүзләрен тыңлап кайта торгач үлә яздым. Шартлап ярыла идем, ярый, Бөгелмәгә җиттек. Бөтен гомерем, бушка узган яшьлегем күз алдыма килде. Бәхетле кешене күрсәм эчем өзгәләнә! Аңа бит син сәбәпче! Син генә!

Ч а л. Менә хәзер синең белән яшәргә була! Бир кулыңны! Бергә китәбез. Бергә яши башлыйбыз. Үч алынды. Рәхмәт!

С ә л и м ә. Кая чакырасың мине? Нинди тормышка?

Ч а л. Миңа синдәй ышанычлы дуслар гел-гел кирәк. Ялгызлык безнең өчен дә һәлакәт. Син мине коткарып калдың. Мин синңа гомерем буе бурычлы!

С ә л и м ә. Ялачы хатын кирәкме сиңа? Ялганчы хатын? Тукта, синнән үч алам дип нәкъ сиңа яхшылык эшләгәнмен булып чыга түгелме? Кая бара алам мин синең белән? Идән тастымалы булыргамы? Юк инде! Көтмә!

Ч а л. Кая барасың?

С ә л и м ә. Милициягә.

Ч а л. Егетне чыгарып, сине утыртып куячаклар.

С ә л и м ә. Фәүзия ирек бирмәс.

Ч а л. Ах, менә кемгә таянасың икән әле!

С ә л и м ә. Син дә беләсең икән аны! Таянам!

Ч а л. Кабарма. Мин барын онытма.

С ә л и м ә. Акылыңа кил. Чәчең чаларган. Күзеңнең дәрте сүнгән.

Ч а л. Миңа үзгәрергә соң инде. Мөмкин дә түгел. Йөрмә! Сак бул.

С ә л и м ә. Күзеңне чокып чыгарырмын! Мин синең куркак икәнеңне дә беләм!

Ч а л. Үземнән алда һәрчак пычак йөри. (*Пычак чыгара.*)

С ә л и м ә. Һай!

Г а й с ә карт белән К ә б и р йөгереп керәләр.

Г а й с ә. Арттан кама! Тукта, явыз!

К ә б и р. Монда килегез, монда!

Ч а л. Мин район милиция бүлегеннән.

С ә л и м ә. Нык тотыгыз аны, ычкынмасын.

Г а й с ә. Немец тылыннан ничәмә-ничә дошманны алып кайткан разведчик бабаң кулыннан алай тиз генә котыла алмассың!

К ә б и р (*Чалның пычагын эләктереп*). Яшь разведчик та ничава әле монда!

Ч а л. Минем гаебем юк.

С ә л и м ә. Җибәрмәгез!

Г а й с ә. Хәзер ачыкларбыз.

Машина туктаган тавыш. С ө н г а т ь керә.

С ө н г а т ь. Бәхтияр җизни?!

С ә л и м ә. Ул күптән Бәхтияр түгел инде.

С ө н г а т ь. Нигә тоттыгыз аны?

С ә л и м ә. Бу кеше — явыз бандит Чал!

С ө н г а т ь. Чал? Фәүзияне яралаган Чалмы?

С ә л и м ә. Сөнгать туганым!.. Әсфанның һичбер гаебе

юк. Машина урлап качкан кеше дә ул! Минем җанымны суырган кеше дә ул!

Сәхнә караңгылана.
Гайсә бабай йорты. Өйдән киенгән-ясанган Гайсә бабай белән Мәдәния чыгалар.

Мәдәния. Ай Аллам, кем каерган бу койма рәшәткәсен?

Гайсә. Кайгырма, карчык. Мин каерып куйдым аны.

Мәдәния. Хәерлегә булсын инде, хәерлегә.

Гайсә. Авыз тутырып әйтә аласың, һәммәсе хәерлегә булачак.

Мәдәния. Күңелем һаман ышанмый.

Гайсә. Утырып тор алайса, карчык. Күңелең ял итсен.

Мәдәния. Ата йорты бусагасына кайтып җиткәч әллә ниләр булды бит!

Гайсә. Бетүе хәерле, карчык, бетүе! Явыз Чал килеп капты.

Мәдәния. Чыкмаслык итеп яптылармы икән, ныгытып карап кайт, дип Фәүзия кызыма әйтә алмаганмын.

Гайсә. Булса да булыр икән явыз җан!

Мәдәния. Фәүзия кызыма рәхмәт. Улыбызны аннан аралап алды. Сиңа әйтәм, әллә нигә аягым туңа.

Гайсә. Туйда биеп җылытырсың, карчык.

Мәдәния. Туй дип авызың ачылдымы әллә?

Гайсә. Сөнгать агроном әйтеп торды, ике туйны шәплән бергә уздырабыз, ди.

Мәдәния. И Ходаем, бер эшем каралмаган.

Гайсә. Утыр диләр сиңа! Тотынды инде!

Мәдәния. Сөнгать димәктән, аның апасын күрдеңме?

Гайсә. Милициягә чакырып бик нык кисәткәннәр үзен. Чалны тотарга булышканы өчен генә жәлләп калдырганнар. Фәүзия дә бик үтенеп калдырырга сораган.

Мәдәния. Әйдә, яшәсен иректә! Яши-яши ипкә килмәсме.

Гайсә. Фәүзия кызым әйтә, ипкә киләчәк, ди.

Мәдәния. Сиңа әйтәм, Фәүзия безгә әти-әни дип дәшә башлар инде, иеме?

Гайсә. Шундый көнне яшь түгеп утырма инде.

Мәдәния. Шулаен шулай да, сиңа әйтәм.

Гайсә. Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм, сиңа әйтми кемгә әйтәм! (*Көйләп куя.*) Их, яшь чаклар, яшь чаклар!

Кәбир йөгереп керә.

К ә б и р. Кайттылар! Кайттылар!

М ә д ә н и я. Кайттылар диме, сиңа әйтәм?

Г а й с ә. Тукта! Кабатла тагын бер!

К ә б и р. Кайттылар! Сөнгать абыйның машинасын халык урап алды. Сорашалар, котлыйлар. Әй, анда! Тизрәк шунда чаптым!

Г а й с ә. Молодец, улым. Яле, сөенчегә. (*Кул сәгате бирә.*)

К ә б и р. Кирәкми иде, Гайсә бабай.

М ә д ә н и я. Сора әле, Әсфан улым шунда микән?

К ә б и р. Шунда, шунда! Ак күлмәк кигән. Фәүзия апа аның янында. Сөнгать абыйның кәләше дә шунда. Ул да бүген ак күлмәктән!

М ә д ә н и я. Ай Аллам...

Г а й с ә. Карчык, карчык! Ни булды?

М ә д ә н и я. Йөрәгем өзелеп төштеме шунда...

Г а й с ә. Хәлең киткәндер. Әйдә, керик, чак кына ятып тор.

М ә д ә н и я. Ап-ак күлмәк кигән диме? Ак күлмәге дә бар икән! Чибәркүлгә ак күлмәк киеп кайтырлык булгач, күңеле яңарган инде аның, сиңа әйтәм. Менә бетмәс куаныч!..

К ә б и р. Әсфан абый мине күреп алды да: «Нихәл, Чибәркүлнең чибәр егете Кәбир!» — дигән була.

Г а й с ә. Әйдә, карчык, әйдә!

Кереп китәләр. Кәбир аларның кереп киткәнен дә сизмичә һаман сөйләнә.

К ә б и р. Ул халык, ул халык! Тегеннән дә, моннан да йөгереп чыгалар. Әсфан абыйны кочаклыйлар. Фәүзия апага рәхмәт әйтәләр. Уйладым-уйладым да монда чаптым.

Өйдән Г а й с ә чыга.

К ә б и р. Гайсә бабай, врачны чакырып менимме әллә?

Г а й с ә. Рәхмәт, улым. Кирәкми инде. Соң.

К ә б и р. Әллә?..

Г а й с ә. Әйе, улым. Мәдәния әбиең вафат. Улын да күрә алмады... И-их, яшь чаклар, яшь чаклар... Әйләнеп кайтмас чаклар.

К ә б и р. Әнә алар! Кайтып та җитәләр!

Г а й с ә. Улым! Озаграк уз шушы араны, улым! Авыл урамнарының якты, киң икәнен күреп, кинәнеп кал! Нинди хәсрәт көтеп торганын аз гына булса да белми тор! Улым! Балам!

Ә с ф а н, Ф ә ү з и я, С ө н г а т ь, Г ө л й ө з е м керәләр.

Ә с ф а н. Әти!

Г а й с ә. Саумы, улым.

Ф ә ү з и я. Кайтып җиттек, Гайсә бабай.

Ә с ф а н. Әти диген, Фәүзия.

Ф ә ү з и я. Без кайтып җиттек, әти.

Ә с ф а н. Әни кайда соң?

Г а й с ә. Хәл җыярга гына яткан иде әле...

Ә с ф а н. Их, гомерне яңадан башларга ирек булсын иде! Синең чәчләр болай иртә агармас иде, әти!

Ф ә ү з и я. Гомернең калган өлеше матур узсын, Әсфан!

С ө н г а т ь. Дөрес.

Ф ә ү з и я. Әйдәгез, әни янына керәбез!

Г ө л й ө з е м. Мәдәния әби сөенер инде!

Г а й с ә. Әйдәгез, балалар.

Ә с ф а н. Җылама, әти! Ник җылыйсың хәзер?!

Г а й с ә. Әллә нигә җылыйсым килеп китте.

Башкалар кереп китәләр. Гайсә азга гына ялгызы кала, үксеп-үксеп елый. Музыка.

П ә р д ә.

*1980*
*Переделкино — Займище — Казан*

# *Югалган көн*

*Драматик повесть ике кисәктә*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Йосыф.
Әхмәтхан.
Зәмирә.
Карт.
Маннур.
Нәҗип.
Геолог.
Гафуров.
Чемоданлы кеше.
Хатын.
Кыз.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Кечкенә аэропорт. Бер-берсенә тар ишек белән тоташкан ике бүлмә. Гапгади җиһазлар: агач диван, агач креслолар. Уңда аппаратлар: рация, радиотелефон, селектор куелган өченче бүлмә. Башта эфирдан төрле тавышлар агыла. Йосыф, наушниклар киеп, Казан белән элемтәгә керергә азаплана. Эчкәреге бүлмәдә Геолог кәгазьләр белән мәшгуль, аның янында почмактарак сытык чырайлы Гафуров басып тора. Калган пассажирлар урта бүлмәгә тупланган: Нәҗип белән Маннур, түшәмгә карап, диванга җәелгәннәр. Хатын, кулларын артка куеп, тәрәзә каршысына баскан, берәүгә дә күрсәтмичә, нидер күши. Чемоданлы кеше бер почмакта, зур фанер чемоданы артыннан күренми дә диярлек. Картның иреннәре кыймылдый — әллә дога укый, әллә үзе белән үзе сөйләшә. Күңелләр төшенке, йөзләр сүрән.

Йосыф (*наушникларын сала*). Монда мин егерменче елымны эшлим. Егерме ел — үзе бер гомер диярлек! Безнең аэропортка самолет тәүлегенә бер тапкыр гына килсә дә күз алдымнан бихисап кешеләр узды!.. Халык тынмый, ярларына сыймый аккан язгы ташкын кебек җәен-кышын һаман ага да ага!.. Арада төрле кешеләр очрый, күңелне эретеп узганнары да бар, биш-ун минут

аралашкан арада йөрәкне өшеткән салкыннары, боз кантары кебекләре дә була!..

Эчкәреге бүлмәдә.

Гафуров. Актыккы сүзегез шулмы, Фоат Хатыпович?

Геолог (*кәгазьләрен актарып*). Соңгысы! Корыны бушка авыштырып йөрергә сезгә дә киңәш итмим!

Гафуров. Үгезне мөгезеннән эләктердем дисез инде?.. Ә ялгышсагыз, көчегез бетеп кулыгыз ычкынса?! Дөрес, сез бүгенгә — тау башында таш багана! Ә иртәгә кем булырсыз? Мәскәүдән борылып кайтканда экспедиция начальнигы булып калырмын дип өметләнәсезме әллә?

Геолог. Әлегә мин начальник. Урыныгыздан сезне мин өреп төшердем. Мин, Гафуров, онытмагыз!.. Ә хәзер комачауламагыз, эшем күп.

Гафуров. Эшләр кәкәй, Фоат Хатыпович! Сметада каралган акча җилгә очкан, сроклар узган, ә нефтьнең тамчысы да юк! Юк бит! Кәгазь җилфердәтеп түргә уза алмассыз. Хәзерге хәлдә дошманнар арттырганчы, дуслар күбәйтү ягын карарга кирәк сезгә, Фоат Хатыпович. Кирәксә, без дә тешләшә беләбез.

Геолог. Тешегезне койдым мин сезнең, Гафуров!

Кәгазьләр өстенә иелә, Гафуров ярсып алгы бүлмәгә, кешеләр янына чыга.

Хатын. Кайсы төртенмешнең сандыгы бу? Бая үткәндә дә оегымны ерта яздым.

Чемоданлы кеше. Ә син тик кенә утыр, менә минем сыман... Дөньяда тик утырудан да рәхәт ни-нәрсә бар?

Гафуров (*Маннур белән Нәҗип янына килә*). Кайсы авыллар дидегез әле сез? Авылыгызда нәселле, көчле, сугыш әтәчләре юкмы?

Маннур (*ачулы*). Җан көйдереп йөрмә диделәрме сиңа?! Очып китә алмыйча интегеп утырганда, җыен тузга язмаганны сорашып йөрисең!

Нәҗип. Маннур, йә, кызма ул кадәр! Юк, иптәш, бездә әтәч сугыштырган адәмнәр юк.

Гафуров. Караңгы яктан икәнсез! Әтәч сугыштырырга яратам! Барган бер җиремнән шәп-шәп әтәчләр табып кайтам.

Чемоданлы кеше. Тагын коя... Җиз иләктән илимени... Көтү чыкмагандыр бүген... Кем йөрсен мондыйда?

Й о с ы ф. Боз ага, боз! Ачуы кабарган кешедән салкынлык бәреп тора. Боз ага, боз, өшетә. (*Пассажирлар янына чыга.*)

М а н н у р. Үзе чыкты! Яле, Йосыф агай, сөйләп җибәр. Радиодан ни әйттеләр, туктыймы бу каһәр суккан яңгыр, юкмы?

Й о с ы ф. Яңгыр туктар, туктамый хәле юк. Боз ага әле монда, боз! Анысын кем туктатыр?

Х а т ы н. Җиңеләя башлаган дип әйткән идемме? Сентябрьдә боз ага димени?.. Бозларның яз көне акканын имчәк баласы да белә.

Й о с ы ф. Ага, ага... Эретергә кояшы гына юк.

Х а т ы н. Шашкан! Баядан бирле әллә ниләр мыгырдый.

Ч е м о д а н л ы к е ш е. Ипидер, суык монда, өшетә. Их, мунча кереп, бер-ике тустаган ачы бал чөмереп, коймак ашап өйдә генә ятасы иде... Түшәккә арканы терәп...

Тышкы ишек ачыла, К ы з керә.

М а н н у р. Әй, кызый актыгы!

К ы з. Гафу итегез, сез миңа дәшәсезме?

М а н н у р. Сиңа инде, сиңа! Ябып йөр ишегеңне. Нәләт суккан черек дөньяның һавасын иснисем килми. Яп диләр, кулың корышканмы әллә?

К ы з (*куркынып*). Ябам, ябам.

К а р т (*Маннурга*). Үз җиреӊ турында йогышсыз сүз ычкындырдың.

М а н н у р. Каһәр суксын бу җирне!.. Аннары расписание буенча мин монда түгел инде.

Н ә җ и п. Алла буласың килә инде, табигатьтән өстен торасың килә? Табигатьнең расписаниесе нык аның! Син аның кодрәтен онытып, үзеңчә әллә нинди планнар төзеп яткан буласың, ә ул тота да үзенчә эшли!

М а н н у р. Адәм баласын табигатьнең колы димәкче буласыңмы?

Н ә җ и п. Әйтәмме, әйтмимме, утырасың ич әле сумалага ябышкан шүрәле шикелле! Бик ычкыныр идең дә, шалишь, брат!

М а н н у р. Ярар, җитсен. Сүзеңнең мае юк. Студент чакта ук синең белән бер бүлмәдә яшәмәскә тырыша идем. Бу кызый актыгы сиңа ошыймы?

Н ә җ и п (*кызга карамыйча гына*). Ошый дип, ул товар, мин сатып алучысы түгел дигәндәй, керә дә чыга, ә башмагы лыч су. Туңган.

М а н н у р (*әйберләре арасыннан тальянын тартып чыгара, тартып куя*). Мондый малны кочакта җылыт-

канда ярар иде... Кайда күргәнем бар минем аны? (*Тальянын тарта.*)

Сөям сине, сөям сине...
Сөям сине, гүзәлем!..

Кайдадыр күргәнем бар минем аны!

Нәҗип. Юктыр. Безнең якныкы түгел. Аллага шөкер, бездә мондый чалбар кимиләр.

Маннур. Килешеп тора үзенә. Бар байлыгы күзгә чәчрәп керә. Безнең хатын-кызлар сыман хан заманындагыча киенмәс инде!.. Әй, чибәркәй!

Кыз. Гафу итегез, монда якында берәр җирдә чәй юкмы?

Хатын. Син миңа эндәштеңме?

Маннур. Югал күземнән, албасты! (*Кызга.*) Сез дигәндә аяк идәндә, чибәркәй. Чәйдән татлырагын табарга да була.

Кыз. Рәхмәт. Тамагым чатнады... Рәхмәт, башкасы кирәкми.

Маннур. Күрдеңме, койрык сыртта! Чибәр үзе, каһәр!.. Тормышта гүзәллек белән очрашкан саен үз тормышымның кызыксызлыгын, түбәнлеген күрәм. Җәй буе ут йотып эшләдек. Сентябрь урталарында Кырымга путевка вәгъдә иткәннәр иде, курортка!.. Ашамадым, эчмәдем, ел буе мая тупладым... Менә шундый кызыйны эләктереп ялга китеп барсаң иде ул хәзер!..

Нәҗип. Тырнакларың йомшак, ычкындырырсың.

Маннур. Каптырсак, җибәрү юк!

Нәҗип. Очты инде Кырымнар! Әле кайчан Казахстанга барып җитәсең дә районга җитәрлек күләмдә саламны кайчан табасың!

Маннур. Табылмаса, төкердем саламына! Шул җәһәннәмнән наряд алмасалар ярамаганмы? Якынракта юк идеме салам!

Нәҗип. Корылык! Утыз ике өлкәдә җәй буе бер тамчы яңгыр төшмәгән, әйтерсең лә каһәр суккан табигать бар дымын, бар яңгырын көзнең менә бүгенге көненә калдырган. Идел буенда корылык бер башланса, биш ел интектерер, дигәннәр картлар, бу юлы да рас килер, ахры.

Маннур. Яман күрәзәлек кылганнарның элекке заманда башын кых иткәннәр! Шуны да онытма. (*Гармунын тарта.*) Кайда күрдем соң мин бу сылу чәчбине!

Нәҗип. Башны кых итү читен түгел! Хуҗалык итәргә бик вакыт та безгә, кулыбыздан килми.

Кыз. Аэропорт кадәр аэропортта бер йотым чәй табылмасын инде!

М а н н у р. Хәтеремә төште! Студентлар отряды белән килде ул! Чөгендер алырга килделәр! Хәзер әнисенең итәк астына, җылыга качып бара.

Н ә җ и п. Быел студент та әллә ни кыра алмый! Басуга кирерлек түгел. Юллар кесәл, басулар боламык! Тракторлар да ашап бетерә торган түгел, берсен-берсе сөйриләр.

М а н н у р. Күкрәкләре, күкрәкләре!.. Быелгы чөгендер түгел инде, авызыңа төкерим!.. Берәр көн очмый торганда да шәп буласы икән! Кулга төшерәм мин аны. Күр дә тор.

Н ә җ и п. Мине буташтыра гына күрмә!

М а н н у р. Әй, сылукай!

Х а т ы н. Миңа дәшәсеңме?

М а н н у р. Кит диләр моннан!

Х а т ы н (*тәрәзә янына басып тышка карый*). Коя! Бөтен күкне томалаган. (*Борылып килгәндә чемоданлы кеше янынннан уза.*) Оегымны умырттым тәки! Тишелеп чыкса, бише белән түләтермен. Каерып алырмын.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Тик кенә утыр диделәрме сиңа? Акыллы киңәш бирделәр... Тик утыр. Менә минем төсле. Мин кузгалмыйм ич.

Х а т ы н. Кузгалмыйм? Юлга чыккансың бит! Бу сандыкка ни тутырдың икән? Алтынмы, көмешме? Ука белән ефәкме?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Әнә кәҗә күпне белгән...

Х а т ы н. Шуннан?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Белгән дә үлгән. Кит моннан!

Х а т ы н. Кычкырма миңа! Син, ахмак, беләсеңме, минем ирем инвалид!

Г а ф у р о в. Усал кешеләр бар, яман бәндәләр! Көнләшүдән минем «Антей» исемле әтәчемне агуладылар. Күкрәкләрен күрсәгез иде сез аның, ботларын!

М а н н у р (*Нәҗипкә*). Вәт тиле! Әтәч күкрәгенә исе киткән! Ботларына! Каптырам мин бу кызыйны! Туташкаем, сылукаем, якыннанрак танышырга вакыт җитмәдеме икән?

К ы з. Борчымагыз мине, үтенәм.

М а н н у р. Очарлыкмы һава, түгелме? Очмаса да ни зыян?

К ы з. Очсын дип теләгез инде сез, берүк.

М а н н у р (*гармунын тартып*). Кая шулай ашыгасыз? Монда да күңелле ял итәргә була.

К ы з. Кичегергә ярамый миңа. Биргән вәгъдәм бар.

М а н н у р. Вәгъдә? Кемгә?.. Мин сине беләм, син студентка. Чөгендердән качып барасың.

К ы з. Үзегез чөгендердән качасыздыр әле.

Маннур (*көлә*). Өстенә бастың! Качып барыш. Шулай да белешик: агроном мин. (*Нәҗипне күрсәтеп.*) Күрше колхоздан зоотехник, Казахстанга салам юлларга китеп барыш. Бер айга! Акчабыз да бер букча! Кыскасы, ирекле кошлар без!

Кыз. Оча гына алмыйсызмы? (*Читкәрәк китә.*)

Нәҗип. Шуны да онытма, Маннур, былтыр Белоруссиядән алып кайткан саламда колорада коңгызлары очраштыргалады. Берәмтекләп чүпләдек.

Маннур. Берсе салам дип җенләнә, икенчесенә әтәч кирәк. Кабаланма, асыл кош, китмә читкә! Үкенмәссең, ияр безгә! Авылда сине шәһәргә кайтып китте дип беләләр, шәһәрдәгеләр авылда дип уйлар. Ияр!

Нәҗип. Ике йөз гектар чөгендере су астында калган. Малларына ярты кыштан бер бөртек саламы булмаячак. Ә ул кызлар дип саташа. Йосыф! Йосыф агай, яңалыгың, бармы?

Хатын. Дәшми, карт төлке.

Йосыф. Казанда хәлләр бездәгедән яманрак — коеп түгә! Ә безнең хәлне күреп торасыз — самолет төшәрлек түгел, җир җебеп аккан.

Нәҗип. Кул кушырып утырырга ярамас, бер-бер чарасын күрергә кирәк.

Карт. Күрердән элек, чарасын табарга иде! Без түгел, әнә зур начальник та самолет көтә. (*Геолог утырган якка ишарәли.*)

Гафуров. Зурысы! (*Көлә.*) Начальникларның иң кәттәсе! Мәскәүгә арка кашытырга бара! Башкалага кош булып очар да йолкынган әтәч булып кайтыр!

Йосыф. Начальникмы, түгелме, миңа барыгыз да тигез — юлчылар.

Хатын. Кеше кешегә тиң буламы? Менә минем ирем инвалид, шахтада гарипләнеп кайтты. Ә без салам түбәле өйдә яшәп ятабыз.

Маннур. Салам түбәле өйдә ми тартмасына мәкинә тутырган кеше генә яши хәзер!

Нәҗип. Таш астыннан чыккан хатын. Алтымы-җидеме тапкыр шифер бирделәр аларга. Шиферны әвештүеш китерә дә тагын теләнергә чыгып китә.

Хатын. Кем монда теләнергә бара? Авызыңны үлчәп ач! Өлкә больницасына каралырга барам мин! Ирем инвалид! Белдеңме?

Йосыф. Ярар инде, ярар. Каралырга, имеш... Чөгендердән качасың. Закон буенча тиешле бер гектар чөгендер алудан.

Хатын. Качсам синең ни эшең бар?

Й о с ы ф. Шуны әйтәм шул, боз ага, боз.

К ы з (*Йосыфка мөрәҗәгать итеп*). Агай, бер чынаяк кына кайнар чәй табалмассызмы? Суык тидердем, ахры, өшетә.

Х а т ы н. Кит, кит, якын килмә. Чирең йогар. Минем ирем болай да инвалид.

М а н н у р (*шешә чыгара*). Кушыл безгә, чибәр кыз! Хәзер дәвалыйбыз!

Н ә җ и п. Яшер! Кеше күз алдында оялмыйча эчәр идеңме?

М а н н у р. Танышлар күренми бит!

Н ә җ и п. Күз күргән кеше юк югын да...

К а р т (*мәрткә киткән җиреннән уянып*). Юк дисезме? Үзем дә шуңа аптырап утырам: җитмеш биш ел гомеремне шушында кичтем, ә берегезне дә танымыйм.

Й о с ы ф (*үтеп барышлый*). Боз ага, елга иңләп боз ага, шуңа танымыйсың, агай. (*Чыга. Аппаратлар янына керә.*)

Н ә җ и п (*тавык ботарлап*). Син, бабай, олы кеше. Китап сүзен ятлап, намазлык өстендә утырыр чакта, бу пычракта нишләп лай ярып йөрисең?

К а р т. Син дә йөрисең, улым. Газиз җаның сиңа да кадерледер.

М а н н у р. Бутама таяк белән аякны! Без дәүләт эше белән сәфәр чыктык. Ашыгыч эш белән.

К а р т. Минем дә эшем ашыгыч, бик тә ашыгыч.

М а н н у р. Синең яшьтә ашыгып кая баралар ди?

К а р т. Казанга аяк басыйк әле, аннан күз күрер. Җир шары түгәрәк булса да, зур...

Н ә җ и п. Бәйләнмә чал сакалга, Маннур. Һәркемнең үз мәшәкате. Оныгы өйләнәдер, туйга ашыгадыр...

К а р т. Җитмеш бишне бөкләдек!.. Шуңа ашыгырга кирәк тә... Йөрәгем янганга сәфәр чыгып киткән мөсафир булырмын мин.

М а н н у р. Синең яшьтә йөрәк бәләкәй генә боз кисәгенә әйләнмимени, карт!

Х а т ы н. Әгәр бер сәгатьтән самолет килмәсә, нәләт суккан Йосыфның бер бөртек сакалын калдырмыйм.

К а р т. Яна йөрәк, яна! Эчем тулы ут минем. Менә елга-чишмәләребездән чыккан сулар челтерәп агып китә, дәрьяларга кушыла. Суыбызның һәр тамчысы нинди хезмәтләр генә күрсәтми?! Җиребез аша салынган чыбыклардан электры да җитез йөгерә. Нефте-газы берторкарлыксыз агып торсын өчен юан-юан торбалар сузылган. Берсен дә яңгыр-кар туктата торган түгел. Ә адәм баласына китәр юл юк, бүрек хәтле болыт чыкса да аның барыр юлы чикле... Ә миңа тизрәк барып җитәргә кирәк!

Х а т ы н. Зарыңны миңа сөйлә, бабай. Ирем инвалид, керер җирен генә түгел, чыгар җирен дә бик әйбәт беләм!

К а р т. Сиңа сөйләгәнче, җилгә сөйләсәм генә инде.

Х а т ы н. Йөрергә кирәк, сөйләргә! Начальниклар таш пулатларда яшәп ятканда, безнең баш очында арыш саламы! Революция булганга ничә ел?

К а р т. Чыннан да, ничә ел?

Х а т ы н (*аптырап*). Бәй, мин каян белим? Революция ясап йөргәнме?

К а р т. Мин ясаган аны революцияне! Һәм шәп итеп ясаган. Хөрәсән ялкаулары рәхәт чиксен өчен ясалмады ул!

Х а т ы н. Акырма миңа! Мин күргәнне син күрсәң... (*Читкәрәк китә.*)

Г а ф у р о в. Күпне күргән апа! Әтәч сатмыйлармы сездә? Сугыш әтәче кирәк миңа.

Х а т ы н. Мин үзем әтәч, күзеңне чукып алырмын.

Г а ф у р о в. Әйттем исә кайттым!

Х а т ы н. Тәртип юк бездә, тәртип. Шәһәрдә яшәргә була, анда тәртибе дә бар, законны да беләләр...

Ч е м о д а н л ы  к е ш е (*калкынып, үз-үзенә*). Шәһәрдә законны беләләр диме? Олы начальник янына кереп киңәшәсе инде әллә? (*Геолог утырган бүлмә ишегенә килә.*)

Г а ф у р о в. Кая үрмәлисең, ач борча?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Болай гына. Тел кычытып китте.

Г а ф у р о в. Йөрмә. Мыегы чуалган чак. Бетте баш, калды муен серәеп, диләрме әле? Шулайрак! Сезнең районда нефть эзләделәр бит, чамасыз күп акча түктеләр. Ә нефте юк! Министрлыкка отчет белән бара, Мәскәүнең үзенә! Башын култык астына кыстырып кайтарачаклар.

Х а т ы н. Син дә шулар кавеменнәнме? Машиналарыгыз урамнан үтә башласа, өй җимерелә дип торам. Җимерелсә, бише белән кайтарам инде кайтаруын.

К а р т. Нефтьне эзлиләр, ә игеннәр корый. Елга-күлләр кибә. Коеларда эчәрлек су калмады.

Н ә җ и п. Анысына ел гаепле!

К а р т. Егерме беренче елгы корылыкны да кичердем мин... Дөньясы корыды, ә чишмәләр чылтырап агып ятты.

М а н н у р. Син фиргавен заманнарын да телгә ал инде! Телеңне кыскартмаслармы? Чишмә корый дип нефть ташкынын туктатыргамы? Синең сасы коеңның Европага кирәге бармы?

К а р т. Чишмәм корыгач, җир-суларым пычранып

беткәч, ул нефть миңа нәмәстәгә? Нефть эчәрсеңме син, нефть ашарсыңмы?

Чемоданлы кеше. Әйдә, гәпләшсеннәр. Вакытлары күп. Керим дә сорашыйм әле. (*Геолог янына керә.*) Кердем әле менә.

Геолог. Эш белән икән, рәхим итегез.

Чемоданлы кеше. Болай гына... Утырып торыйммы? Аяклар... (*Утыра.*) Сине укыган кеше диләр.

Геолог. Дөрес әйтәләр.

Чемоданлы кеше. Шуны ишеттем дә...

Геолог. Сез нефтьчеме?

Чемоданлы кеше. Бәй, нишләп? Көтүче мин. Колхоз терлекләрен көтәм. Гомерем буе көтәм.

Геолог. Кыюрак булыгыз. Кычкырыбрак сөйләгез.

Чемоданлы кеше. Кычкырып сөйли алмыйм. Хатын да зарлана. Япа-ялгыз ябалак булып йөреп адәм телен онытып бетердең, хайван, ди. Сызгыра беләм. Сызгырып күрсәтимме?

Геолог. Монда уңайсыз, сөйләп кенә күрсәтегез.

Чемоданлы кеше. Сүзе табылмый. Кайдадыр сызгырып кына сөйләшә торган халыклар бар икән! Вәт әкәмәт!.. Гадәттә чыбыркы сөйләшә минем өчен.

Геолог. Чыбыркылаганны гомумән кабул итмим! Чыбыркыга буйсынмыйм да! Сөйләгез, тыңлыйм.

Чемоданлы кеше. Тыңлаучылар күп — сыерлар да тыңлый. Колаклары икешәр. Тыңлап калма, акылын да бир! Акылын! Киңәшер кешем юк. Ялгызмын. Сөйлим алайса? Бер адәм була. Хатынын, баласын ташлап чыгып китә дә читкә, шәһәргә барып өйләнә. Череп байый... Ахыр чиктә үлеп китә. Байлыгы кемгә калырга тиеш аның? Ике костюм! Өр-яңа! Йөзәр тәңкә торалар. (*Кесәсеннән, кәгазь чыгара.*) Каракүл якалы пәлтә!.. Өч процентлы алтын заемнар. Әллә ике, әллә өч мең үк... Кемгә кала байлыгы? Мондагы улынамы? Әллә теге кәнтәенәме? Анда бала-чагасы юк. Булмаган. Төшендереп бирче шуны.

Геолог (*кәгазьне алып*). Синең хуҗалыкта да кәгазь язу осталары бар икән!

Чемоданлы кеше. Хатын мәтәштерде. Энекәшләре белән. Бишәү алар.

Геолог. Хәтәр кәгазь тотып чыккансыз юлга! Тик мин юрист түгел, геолог. Мезозой, кайнозой, девон. Аңладыңмы?

Чемоданлы кеше. Киңәшеңне кызганасың алайса?

Геолог. Мәрхүмнең кеме буласың соң син?

Чемоданлы кеше. Анысын сорама, кирәкми.

Геолог. Закон нечкәлеген әйтә алмам, әмма әхлак ягына килгәндә... Әйтик, мондагы гаиләсен нигә ташлаган ул?

Чемоданлы кеше. Анысын да төпченмә.

Геолог. Баласына ярдәм итеп торганмы? Алимент түләгәнме?

Чемоданлы кеше. Анысын түләткәннәр!

Геолог. Инде авырып киткәч кем караган? Соңгы сулышында янында кеме булган? Кем җирләгән?

Чемоданлы кеше. Әле җирләнмәгән... Нижәли, чирле чагында кем караган дип закун сорар?

Геолог. Сорар. Сорарлар. Мондый чакта дөреслек өскә чыга.

Чемоданлы кеше (*сөмсере коелып*). Алай дисең әле син... Җан биргәндә янында кем булган дисең икән... (*Пассажирлар янына чыга.*)

Гафуров (*аңа каршы килеп*). Миңа артык зур кикрикле этәч кирәкми. Йоны ут кебек янып торсын!

Чемоданлы кеше. Кайда минем чумадан? Кайсыгыз кагылды аңа? Тиясе булмагыз! Төн йокламый ясадым мин аны. Бармагымны кистем. Агач череген сибеп карыйм, туктамый каны. Туфрак ябып карадым, пәрәвез, андыз тамырын... Шуннан көчкә туктады. Яманга юраган идем аны...

Маннур. Стакан аласы калган, Нәҗип дус! Бугазыннан тамакка үтми.

Чемоданлы кеше (*Маннур янына килеп*). Миңа да өлеш чыгарыгыз, зинһар. Курыксагыз, түләрмен, анлык кына бар!

Маннур. Менә бу җәһәннәм тубалын юлдан алып ыргытсаң, өлеш синеке. Эчендә ни бар аның? Нинди хәзинә?

Чемоданлы кеше. Сиңа да хәзинә кирәкме? Ни җитми?

Маннур. Ике тапкыр абындым мин аңа. Ике мәртәбә.

Чемоданлы кеше. Ә син танавыңны бик киермә, аскарак карап йөр.

Маннур. Тешемә тия! Күңелемә тия! Саруымны кайната! Эчемә ярамый! Алып бәрермен!

Чемоданлы кеше. Кагылып кара.

Маннур. Кагылсам нишләрсең?

Чемоданлы кеше. Азау тешең чүпләп учыңа тутырырмын.

Маннур. Учыңа? Шакшы учыңа минем тешләрне? (*Ачу белән чемоданга тибә, чемодан читкә китә, ачыла.*)

Маннур. Буш?!

Хатын (*иелеп*). Эчендә җил уйный.

К ы з (*гаҗәпләнеп*). Чыннан да, буп-буш.

Чемоданлы кеше. Җаныңны алам, өрәңге танау! (*Маннурга ташлана.*)

Нәҗип. Җитәр сезгә, этәчләр. Кикрикләре кызган.

Гафуров. Әтәчләр шулай гына бәргәләшәме? И-их, караңгы як!

Хатын. Сугышалар! Үтереш! Милиция!

Гафуров. «Антей» исемле этәчемне харап иттеләр, юньсезләр.

К ы з (*хатынга*). Нигә чәрелдисез, берәү дә сугышмый.

Карт. Булыр сезгә, оятсызлар! Мөсафирлар алдында илне-көнне мәсхәрә итеп сугышып ятасыз. Читтән килгәннәр бар, ни уйламаслар?

Чемоданлы кеше. Әтәчләнә, имеш. Гармун тарткан була! Иртәдән бирле шул кызны да карата алмыйсың, чөенке танау!

Маннур (*тынычланып*). Кирәгеңне алырсың әле бер.

Хатын. Тизрәк килсен бу җәфалары, Ходаем, сугышып бетәрләр болар. Сбидитель итеп йөртә башларлар...

Маннур. Һәммәсенә ачу итеп шул кызыйны кулга төшермәсәмме? Әй, сылукай!

Хатын. Мине чакырасыңмы?

Маннур. Ха-ха-ха!

Эчке бүлмәнең бусагасында Геолог күренә.

Геолог. Ни булды монда? Нигә гөжлисез?

Гафуров. Кайберәүләргә уйларга ирек бирмиләр!

Карт. Сезгә бер-ике авыз сүзем бар иде, олан, зур начальник диләр сезне.

Геолог. Эш урыны монда түгел, бабай. Берегез кереп чыкты инде! (*Чемоданлы кешегә ишарәли.*) Идән пычратудан уза алмады.

Карт. Аякларым коры минем, менә күр.

Геолог. Гафу итегез. (*Картны бүлмәгә чакыра.*) Үзенең дә, сүзенең дә рәтен тапмадым. Арылган да, ничә төн йоклаган юк. Узыгыз, бабай, утырыгыз. Монда урын җитәрлек.

Карт. Урын тарыккан юк, «Әпипә»гә биергә килмәгән. Әйтегезче, юлдаш, нигә мин шушы аэропортта беркемне, дә танымыйм?

Геолог. Самолет көткән араны табышмаклар әйтеп кыскартыйкмы? Бабай, ашыгам мин, эшем муеннан. Вакытым юк.

Карт. Син яп-яшь, ә миңа җитмеш биш! Кем ашыга да, кемнең вакыты азрак? Соравымны уенга алдың... Әйе,

улым, шәхсән исемнәрен белмәсәм дә, мин мондагы кешеләрне танырга тиеш идем. Кырык биштә, сугыш беткән җәйдә мин авылга кайттым. Печән өсте иде. Өч ел ярым окопларда ятканнан соң өйгә кайтып барам. Чаллыдан безгә җитмеш чакрым ара. Шул юлны җәяү кайтып киләм, юл буе кеше аягы өзелми. Очрап кына торалар. Очраган бер кеше миңа таныш иде.

Г е о л о г. Шуннан бирле дөньяга чыкканыгыз юкмы әллә?

К а р т. Кая барыйм мин? Нишләп йөрим? Йөрмәсәм дә кешеләрнең аз-маз үзгәргәнен чамалый идем.

Г е о л о г. Үзгәрсәләр ни гаҗәп, байтак еллар үткән.

К а р т. Йөз сызыкларыннан, кыяфәтләреннән, киемнәреннән мин аларның күңелләрен тоя идем. Ни белән шөгыльләнгәннәрен, сәфәргә нигә кузгалуларын, нужаларын, сөенечләрен, барын белеп тора идем. Безнең юллар гына түгел, күңелләр дә уртак иде. Алар да мине таный иде. Сөйләп бирмәсәм дә минем ниләр уйлап кайтуымны белеп кул сузалар иде. Сәлам биреп туганнарча каршы алалар, хуш дип озаталар иде. Русы булсын, татары булсын, чувашлар да шактый бездә, без бер идек. Ярты сүз җитә иде, ярты сүз! Иң кирәген барыбер аңлый идек. Ә менә хәзергене ал, менә шушында иртәдән бирле ярты дистә кеше утырабыз, иртәдән бирле барыгызны күзәтәм, аңламыйм! Алар да мине аңламыйлар, күрмиләр дә, чемоданга абынып китәләрме, минем аяккамы, барыбер аларга. Сәфәремнең сәбәбен ача башласам, авыз ералар. Кайда безнең борынгы туганлык? Кайда безнең мәңгелек кардәшлегебез?

Г е о л о г. Барыбыз да ашыгабыз, кая бер-береңне аңлап бетерү?

К а р т. Әгәр барын да шулай тиз аңлатып булса, нужа куып сәфәр чыгып китәр идемме мин, олан?

Г е о л о г. Тиеш санасагыз, миңа сөйләгез. Кая юл тотасыз?

К а р т. Белмим. Әйтә алмыйм. Якты дөньяда ниләр барын күреп кайтасым килде. Бар җирдә дә хәлләр шулаймы димен? Шулай икән, кем гаепле?

Г е о л о г. Минем янга кергәнсез, димәк, мине дә гаепле саныйсыз, ахры. Ачыграк сөйләшик әле, бабай.

К а р т. Менә син нефть эзлисең. Мин умартачы, чүнниктә. Сугыштан кайтканнан бирле шунда, урман арасында. Өч ел рәттән бер тамчы бал алганыбыз юк. Авыруның чәенә тамызырга, әҗәл ягасындагының иренен балларга җай юк. Син нефть эзлисең. Нигә эзлисең син аны?

Г е о л о г (*корт чаккандай урыныннан сикереп тора*).

Сез моны уйлап сөйлисезме, уйнапмы? Сезне котыртмадылармы? Дошманнарым башта ук күп булды. Дөресрәге, идеямнең дошманнары... Әмма сездән, гади кешедән моны ишетү... Үз җирегезне беләсезме? Сезнең җирне, нәкъ менә шушы төбәкне, өметсез, файдасыз саныйлар. Күп галимнәр шул фикердә тора.

Карт. Шул сәбәпле безнең җиргә дошманнарча карыйсыз да сез!

Геолог. Каты ялгыштыгыз, бабай? Киресенчә, бу төбәкне өметле дип саный килдем. Элегрәк ансат булган, каян казысаң, шуннан нефть бәреп чыга торган. Ә хәзер яңа ятмалар ачу ифрат авыр. Миңа башта ышанмадылар. Экспедициямне материаллар белән тәэмин итмәделәр. Өч ел ничек эшли алганбыздыр, шуңа исем китеп утырам. Әмма мин бер чакта да борынымны төшермәдем. Өч ел гомеремне шушы төбәккә багышладым. Хәзер дә ышанам, бар монда нефть, бар. Тик миңа ышанычлары какшады, министрлыкка чакыралар, коллегия утырышына. Башлаган эшне ябу турында сүз булачак.

Карт. Мәскәвеңә очып кит тә кайтма инде син безгә!

Геолог (*көлеп*). Табигать минем яклы! Очарга ирек бирми. (*Кинәт кайнарланып.*) Менә мисал өченгә шуны алыйк: хәзер без бикле капка артында басып торган кебек. Капка ачылса — Казанга юл! Казан сезне бөтен ил, бөтен дөнья белән бәйли. Озак та үтмәс, бу капка мәңгегә бетәр, шушы урында яңа калалар, асфальт юллар, аэропортлар салыныр.

Карт. Син, олан, капканың теге ягына карап кына фикер йөртәсең. Нигә нефть чыкканчы салынмаган ул юллар? Нигә чын аэропорт төзелмәгән? Моңарчы да кешеләр яшәгән ич монда. Мин яшәгән. Мин сезгә бал бирдем, иген иктем, мал асрадым. Кем өчен салыначак ул аэропорт? Кем өчен сузылачак ул асфальт юллар? Кеше өченме, нефть өченме? Кадерем артачакмы минем ул юллар салынгач?

Геолог. Нефть җирнең каны, куәте, нефть — җирдәге тормыш, тереклек.

Карт. Берзаманны чүнниктән кайтып киләм шулай, йа Ходай, күземә күренәме дип торам, дию пәрие дәүмәлеге буровойны сөйрәп, бодай басуын иңләп, алты трактор килә. Бодай башаклары чылбыр астында чытыр-чытыр сытылалар. Җир тетри! Каршыларына йөгереп чыктым: «Нишлисез, явызлар!» — дип кычкырам. «Нишләп җирне мәсхәрә итәсез?!» Берсе ботын ерып баскан да: «Таптабыз, кит! Барыбер юньле бодае юк аның быел!» — дип бакыра. Бодае аз икән, кадерлерәк бит инде, аңламый.

Улап-гөрләп өстемә киләләр. Үтеп киттеләр шулай. Икмәкне таптап киттеләр.

Г е о л о г. Беләм мин ул хәлне. Ул кешене эштән кудык. Яңадан алмабыз да!

К а р т. Аны кугансыздыр, ышанам. Тракторда кем утыра диген! Безнең егетләр, игенче балалары. Алары да мине аңламады, телләрен онытканнар. Игенче телен... Монда җыелганнар да: «Кая барасың?» — дип җан көйдерәләр. Аңламыйбыз бер-беребезне, аңламыйбыз!

Уртадагы бүлмәгә чыга, анда шул ук хәл: көтәләр.

М а н н у р (*гармунын тартып*). Сөям сине, сөям сине...

К ы з. Апа, берәр даруың юкмы? Башым бик авырта, чыдар чама юк.

Х а т ы н (*йомшап*). Кая барасың болай чирле килеш? Читен ул чөгендер алу, авыр эш. Качып китсәң дә сүзем юк. Начальство планны төзи дә эш бетте дип саный, таякның юан башы хатын-кыз җилкәсендә, сиңа-миңа төшә. Балчык эшен, наным, әйтмә инде. Электә берәү гомере буе читтә, җир казуда булган икән. Авылга кайтса, әнисе вафат икәнне әйткәннәр. Шелтәләп: «Әниеңнең гүр туфрагын алырга да кайтмадың!» — дигәннәр моңа. Читкә карап көрсенгән дә бичара: «Кайтмасам да кайтмадым шул, туфрак эше бигрәк авыр ла!» — дигән ди.

М а н н у р. Чамасын белеп ялганла, апа! Безнең арада андый кабахәтләр юк, булмас та!

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Нигә миңа бәйләнәсез? Ни катнашыгыз бар миндә?

Х а т ы н. Бик кирәгең бар иде!

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Йосыф, әй, Йосыф! (*Йосыф янына керә.*) Билетны тапшырырга булдым, Йосыф агай.

Й о с ы ф. Очмаска булдыңмы?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Очып ни мәгънә? Ни файда? Мондый көндә өйдә утыруың мең артык, Йосыф агай. (*Паузадан соң.*) Син минем әти картны беләдер идеңме икән, Йосыф агай?

Й о с ы ф. Кем улы соң син?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Мәхмүт иде минем әткәй.

Й о с ы ф. Мәхмүт? Скрипкәче Мәхмүтне әйтәсеңме әллә?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Әйе.

Й о с ы ф. Әткәң чалымын бер дә күрмим. Белә генә идемме, дуслар идек без әткәң белән! Олылап, скрипкәсен күтәреп безнең туйга да килгән иде.

Чемоданлы кеше. Шул үзе инде. Өйдән өйгә биләмгә йөрергә ярата иде.

Йосыф. Тыел! Сез аны: «Исәр, шашкан!» — дип яманатын чыгарып, өйдән куган идегез түгелме?

Чемоданлы кеше. Калага күчеп китте ул.

Карт. Балаларың җүләр дип мыскыллый башласын әле.

Чемоданлы кеше. Үлде ул.

Йосыф. Ничек?

Чемоданлы кеше. Адәм баласы ничек үлә? Күзен йомган да тәпиен сузган.

Йосыф. Шундый олы зат та үлемгә баш бирер икән... Скрипкәче Мәхмүт! Син шул хәбәрне тыныч кына сөйли аласыңмы? Кайчан?

Чемоданлы кеше. Бүген җирләргә тиешләр.

Йосыф. Бүген?.. Җитмәсә, самолеты да юк бит аның. Синең соңга калуың да ихтимал.

Чемоданлы кеше. Ашыгудан ни файда? Үлгән бит инде. Җаны юк, теле юк. Мәет белән ни сөйләшәсең?

Йосыф. Аның караvы синең җаның бар, телең! Салкын булса да җаның бардыр бит? Юньсез, ахмак! Кешеләр таш балбалларга баш оралар, почмакларга тәре асып шуңа табыналар. Агач сыннарны кочаклап күңел серләрен сөйлиләр. Гыйбадәтханәләрдә сынлы диварларга сыенып алмаз яшьләрен түгәләр. Ә монда атаң гәүдәсе!.. Тәне җансыз булса да, исеме, хатирәсе, кылган гамәлләре калган. Сүзең әткәңә кирәкми, сүзең сиңа кирәк. Синең үзеңә! Кеше икәнлегеңне расларга соңгы форсатың калган. Яле, күрсәтче күзләреңне!

Чемоданлы кеше (*аска карап*). Безнең белән яшәмәде. Хәзер канатланудан ни файда? Ятлар без.

Йосыф. Син аның улы. Тамырларыңда аның дәртле каны ага. Бай кеше иде бит ул Мәхмүт.

Чемоданлы кеше. Бай? Каян беләсең? Тәгаен бай идеме?

Йосыф. Күңеле чиксез дәрья кебек бай иде. Нурлы кеше иде. Кемгә барып кермәсен, урыны түрдә иде.

Чемоданлы кеше (*өметсезләнеп*). Әллә берәр җылы хәбәр әйтерсеңме дигән идем... Байдыр да, бар булганы шәһәрдәге кәнтәенә өелеп кала менә.

Йосыф. Әле шуның өчен буш сандыкны сөйрәп йөрисеңмени? Өегездән сөрелгән атаң малына хуҗа булыргамы ният? Балаларың бармы синең?

Чемоданлы кеше. Сигез җан.

Йосыф. Кызганыч, бичара балалар.

Чемоданлы кеше. Алай ук мыскыллама инде.

Й о с ы ф. Бу гүзәл дөньяга аларны юньсез кеше тудырган. Сөйләшәсем дә килми синең белән! (*Урта бүлмәгә, пассажирлар янына чыга.*) Боз ага, боз!

Н ә җ и п. Шуны сорамакчы идем, Йосыф агай. Баядан бирле нинди боз турында кабатлыйсыз сез?

Х а т ы н. Сентябрьдә нинди боз аксын ди? Шашкан!

Й о с ы ф. Яз башында, кояшлы бер көндә елга ярына төшеп утырганың бармы синең?

Н ә җ и п. Язын? Юк инде, арка кашырга да вакыт калмый минем.

Й о с ы ф. Яр буенда утырасың шулай. Кояштан тәнгә тансык җылы агыла. Күзләрне җылы нур иркәли. Шунда кинәт тирә-ягыңны сап-салкын һава биләп ала. Бер мизгелгә каушап та каласың. Күз ачмыйча да елга өсләп зур боз кантары агып килгәнен сизәсең. Үзе белән салкын алып килә ул, баз исе, гүр исе. Кешеләр дә шундый була, энекәем. Берәүләр җылы нурга чолганган була, ә икенче берәүләрдән зәһәр салкын бөркелеп тора. Бүген сезнең арада да нәкъ әнә шундыйлар бар, Нәҗип туганым.

К ы з. Өшетә. Иң кирәкмәгән чакта чирләп китсәм нишләрмен?

М а н н у р. Бозлар арасында утырсаң өшерсең дә.

Й о с ы ф. Боз барыбер эрергә тиеш. Кайчан булса да!

К а р т. Бер генә таныш йөз дә юк. Берәү генә дә!

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Нигә минем балалар өлешсез калырга тиеш? Төне буе интегеп чумадан ясадым. Һәр кадагын үз кулым белән кактым.

Г а ф у р о в. Яхшы әтәч булса сугыша инде ул, бирешми!

Х а т ы н (*сикереп тора*). Син безнең башны бутама, Йосыф агай! Киләме әҗәл тагарагың, юкмы? Ач хәзер үк аэропортыңны!

Й о с ы ф. Аннары күк капусың ач дип бәйләнерсең син.

Х а т ы н. Ачарсың да! Ачмый кара. Минем ирем инвалид. Йон очырткан төсле очырырлар.

Й о с ы ф. Пенсиягә ел ярым калды. Шуңа хәтле түзәрсең, бәлки?

Х а т ы н. Казанын үтәрмен. Мәскәвенә җитәрмен! Давай, тотма, җибәр безне!

Ишек ачыла. Ә х м ә т х а н белән З ә м и р ә керә.

Ә х м ә т х а н. Казанга регистрация бетмәдеме әле?

З ә м и р ә. Әйе, әйе... Самолет китмәдеме?

М а н н у р. Соңга калдыгыз, күптән китте.

З ә м и р ә. Кая китте?

М а н н у р. Ерак әбиеңә кунакка! Кайнар коймак ашарга.

Й о с ы ф. Телеңә агулы гөмбә үскәндер синең, Маннур. Юк, иптәшләр, юк, әлеге самолет килмәде дә...

Ә х м ә т х а н. Ишетәсеңме, Зәмирә? Килеп җиттек, өлгердек.

З ә м и р ә (*яшь аралаш*). Ишетәм, Әхмәтхан, ишетәм.

Ә х м ә т х а н. Җитәр инде, сөенечтән күз яше түгәләрме?

З ә м и р ә. Бетте, бетте, Әхмәтхан. Җыламыйм.

Ә х м ә т х а н. Якынрак кил, бит алмаларың юеш! (*Сөртә.*) Менә шулай! Кояш күк балкыдың, каракаш.

Х а т ы н. Көзге кояшның балкуы гомерле түгел, хәзер болыт каплый аны.

К а р т. Яман тел пычактан хәтәр яралый. Каян килдегез, балалар?Ерактан, ахры?

З ә м и р ә (*әрнү катыш елмаеп*). Ерактан, бабай, җәһәннәмнән.

К а р т. Таныш кешеләргә дә охшыйсыз?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Картның җәһәннәмдә дә танышлык бар икән!

Х а т ы н (*ишетеп бетермичә*). Хәзер танышсыз яшәп буламы? Кода-кодагыйсыз, танышсыз аяк атлармын димә.

Ә х м ә т х а н. Зәмирә шаярта. Алмалыдан без. Алмалыдан гына! Районның чите, анысы дөрес. Әмма безнең яклар бик матур, хәйран яклар. Һич яманларлык түгел.

З ә м и р ә. Яманларлык түгел, кая ул.

Й о с ы ф. Алмалыдан? Бу пычракта ничек килеп җиттегез?

Ә х м ә т х а н. Сөйләп бирсәң, әкият инде. Бөтенләй белмәгән егетләр «Беларусь» белән китерделәр. Ике трактор бер-берсен сөйри, әкәмәт, кәмит менә! Сөт бидоннары арасында без киләбез, кызык.

З ә м и р ә. Кирәкмәсен сөйлисең, Әхмәтхан. Кара «Волга»га утырып чыккан идек бит юлга.

Ә х м ә т х а н. Күпме генә килдек соң без аңа утырып? Ике чакрым уздыкмы икән, баттык. Машина чумган саен әйберләрне корырак җиргә ташыйбыз да хәл җыябыз... Рәхмәт яусын теге егетләргә диген. Монда килеп эләккәч җан тыныч! Өлгердек болай булгач. Исәнмесез, яхшы кешеләр!

З ә м и р ә. Сәлам бирергә дә онытып торабыз. Капкара «Волга»га утырып чыккан идек. Чәчәкләр белән бизәлгән машинага.

Ә х м ә т х а н. Радиатордагы курчак төшеп калган, әкият инде сөйләсәң.

Н ә җ и п. Яңарак өйләнешкән, ахры, сез?

Ә х м ә т х а н. Бүген иртән! Бөтен авылны җыйдык. Язылыштык та — юлга! Юллар боламыкка әйләнер дип кем уйлаган?

З ә м и р ә. Хәзер без туй сәяхәтенә китеп барабыз. Казан портында безне теплоход көтә. О-о, безнең планнар хәтәр! Зур, өч палубалы теплоход. Ике кешелек каюта. Беренче класста! Идел буйлап төшеп китәбез дә Астраханьга җитәбез. Диңгез буенда яшибез. «Валерий Чкалов» теплоходы. Исеме дә ни тора!

Ә х м ә т х а н. Зәмирәм бала кебек сөенә.

К ы з. Сез нинди бәхетле! Бик бәхетле!

К а р т. Адәм баласының бәхете үзе белән янәшә йөри, кызым.

Ә х м ә т х а н. Таптык без аны, Зәмирә белән бергәләп таптык.

М а н н у р. Ишетәсеңме, Нәҗип, салам сыйрак, кыл койрык туй сәяхәтенә китеп бара. Нинди кызны әләктергән.

Н ә җ и п. Сәяхәтегез күңелле узсын...

К а р т. Русларда да онытылып бара торган яхшы гадәт, әйдә, татарларга да керсен.

Ә х м ә т х а н. Минем ишеткәнем дә юк иде. Колхозда электрик мин, ГПТУ бетердем.

З ә м и р ә. Әхмәтхан дим, синнән паспорт сораган кеше юк ла! Минем әтием майор, отставкага чыкты да авылга кайтты. Туй сәяхәтенә дә ул өндәде.

Ә х м ә т х а н. Авылга кайтуыгыз зерә дә әйбәт булды инде, каракаш! Бөтен авыл «майор абый» дип өзелеп тора. Юлга да озатып калды, акчасын да жәлләмәде.

З ә м и р ә. Бусына ышанмагыз, Әхмәтхан үзе дә акчаны мул ала.

К а р т. Бер караганда ифрат файдалы җола икән бу. Өйләнешкәндә бер-береңне ныклап беләсеңмени? Ә юл — тормыш дигәннәр борынгылар. Михнәте дә, рәхәте дә муеннан. Шунда, олылар күзеннән читтә, бер-береңне сыныйсың.

Й о с ы ф. Син, егет, бит-кулыңны юып ал. Тракторда килгәнең әллә каян күренеп тора. Бу килеш самолетка кертмәсләр. Суым да җылынды.

К ы з. Су җылынды дисезме? Миңа бер чынаяк чәйгә өлеш чыгарасызмы?

З ә м и р ә. Чәй бездә дә бар. Хуш исле куе чәй! (*Ачык*

*буяулы термос чыгара.*) Минем әти Һиндстан чәе генә эчә.

Кыз. Чәегез бик тәмле! Үзе кап-кайнар. Кояшта җылынган кебек булып киттем.

Хатын. Термосын әйт син, аллы-гөлле, пар тургай сурәте төшерелгән.

Зәмирә. Сезгә ошадымы? Ошаса, бүләк итәм. Читенсенмәгез, безнең нәкъ шундый икәү булды. Туйга бүләк.

Хатын. Миңамы? Бөтенләйгәме? Туй бүләген кызганмыйсыңмы?

Зәмирә. Истәлек булыр. Алыгыз, ал. Тагын бирәү бар дим ич.

Хатын. Беркемнең дә моңарчы бүләк биргәне юк иде. (*Җылый-җылый, уңайсызланып кына ала.*) Юлларың уң булсын, кызым.

Нәҗип. Узыгыз мондарак, туганнар, идәне корырак.

Чемоданлы кеше. Чумаданымны алам, комачаулап тормасын.

Кыз. Утырыгыз минем янга. Жанна исемле мин. Казаннан.

Маннур. Юлдан килгән шәпкә бераз тамак чылатып алмыйсыңмы?

Әхмәтхан. Рәхмәт, абый кеше. Башта юынып, кеше рәтенә керик инде.

Йосыф белән аппаратлар бүлмәсенә узалар. Урта бүлмәдә хатын-кызлар нидер сөйләшә, көлешеп чәй эчәләр. Йосыф комганнан су салып тора, Әхмәтхан тыңлана-тыңлана юына.

Әхмәтхан. Сабый бала кебек беркатлы ул Зәмирә! Мең тавыш арасыннан да тавышын аерып алып була.

Йосыф. Сылу кызны эләктергәнсең, егет икәнсең.

Әхмәтхан. Тирә-юньдә бер иде. Ялындырды ялындыруын, барыбер минеке булды. Гаҗәп инде бер уйласаң, мине сайлады.

Йосыф. Туй сәяхәтебез сөт бидоннары арасында башланды дип үпкәләмәдеме?

Әхмәтхан. Бераз булды! Тракторда селкенүгә караганда, кеше арасына «Волга»да ялтырап килеп керү күңеллерәк иде аңа! Миңа ярый, барына да риза. Соңга калдык дип кенә курыккан идем.

Йосыф. Кылдан нечкә, кылычтан үткен Сират күперен кичтек дисеңме? Сөйкемле кешеләр сез. Килеп тә кердегез, читлектәге арысланнарны тынарга мәҗбүр ит-

тегез. Бәхетленең кодрәте бар диләр, дөрес икән. Сезгә карап күз ял итә. Музейдагы сурәтләргә караган күк текәлеп торалар бит үзегезгә.

Әхмәтхан. Зәмирәм генә янымда булсын, һичнәрсәгә исем китми.

Йосыф. Теплоходыгыз кайчан кузгала?

Әхмәтхан. Кичке сәгать унда. Зәмирә җанашым барып җиталмастай ашкынды инде менә.

Йосыф. Син бәхетле. Бәхетле кеше теләсә нинди авырлыкны да җиңел кичерә. Шуңа күрә урап-чурап тормыйм: бүген самолет булмаячак бит, егет.

Әхмәтхан. Шаяртмагыз әле, агай.

Йосыф. Җыелганнар күтә, өметләнә. Ә яңгырның туктар исәбе күренми. Монда беренче көнемне эшләмим, тәҗрибәдән чыгып әйтәм, бүген китә алмыйсыз.

Әхмәтхан. Соңга калырга ярамый! Нишләргә соң безгә?

Йосыф. Безнең кодрәт барысына да җитми, егет.

Әхмәтхан. Ничек бу хәбәрне җиткерим ди аңа? Булмый!

Йосыф. Яратса, аңлар. Ярата ул сине, егет, ярата. Яратамы?

Әхмәтхан. Утыз яктан утыз яучы йөрде. Утыз яктан утыз җил иста, ул мине сайлады.

Йосыф. Яшәгез алайса тигезлек белән, татулык-дуслык белән!

Әхмәтхан. Булсын, талашыннан да курыкмыйм. Бары да булсын.

Йосыф. Син хаклы. Менә минем ызгышыр кешем дә булмады. Сугыштан кайтып кердем, Җамалым гүрдә иде. Итәктән генә төшкән балаларны кочаклап ялгызым калдым. Япа-ялгыз гомер үткәрдем. Икмәккә туйсам, суга тилмердем.

Әхмәтхан. Әгәр Бөгелмәгә китсәк? Аннан Казанга поезд йөри бит.

Йосыф. Йөз ун чакрым. Ай-һай! Аңа өлгерсәгез дә Казанга иртәгә төш вакытында гына барып элгәшәсез.

Әхмәтхан (*тыңланып*). Ишетәсезме, Зәмирә көлә. Әле берни уйламый ул, сөенә генә. Миңа чыккач та җәбер-җәфалар күрә башласынмы аның башы?

Йосыф. Дөнья юллары прәннектән катырмаган. Күрә торсын. Миндә кунып чыгарсыз. Яман хәбәрне үз авызыңнан ишетсен. Сөйгән кешең — хәсрәтең дә уртак булыр. Хәзер чакырып кертәм.

Пассажирлар янына чыга, Әхмәтхан янына Гафуров керә.

Г а ф у р о в. Ну, егет, эләктергән син Офелияне! Баллыдыр, шикәрледер?

Ә х м ә т х а н. Нәрсә? Ни дисез? Белмим, белмим... Зинһар, эндәшмәгез миңа, кагылмагыз.

Г а ф у р о в. Алмалыдан диденҗме әле? Сездә әтәч асрамыйлармы? Сугыш әтәчләре?

Ә х м ә т х а н. Нинди әтәч? Мин берни дә аңламыйм.

Г а ф у р о в. Әтәч сугыштырырга яратам. Чукыша башласалар дөнья рәхәте. Бер-берсен чукып үтергәнче сугышалар кайчакта.

Ә х м ә т х а н. Бар бер әтәч, бар! Кызыл кикрикле. Балачаганы оча-оча талый.

Г а ф у р о в. Шундый кирәк тә миңа! Бәясеннән тормыйм.

Ә х м ә т х а н. Юк ул. Суеп ашадык. Туй мәҗлесендә ашадык. Җәдәче кесәмдә! (*Исенә килеп.*) Зинһар, бәйләнмә миңа! Нинди әтәч булсын ди монда?

Гафуров чыга, З ә м и р ә керә.

З ә м и р ә. Озак юынасың икән син. Сагынып беттем... Хәер —оҗмах ишеген шакырлык булгансың, чипчиста.

Ә х м ә т х а н. Оҗмах ишекләре кай тарафка ачыла икән, беләсе иде.

З ә м и р ә. Ә мин юлдашларыбыз белән танышып беттем. Шундый әйбәт кешеләр!

Ә х м ә т х а н. Әйбәтләрме?

З ә м и р ә. Теге кыз, Жаннаны әйтәм... Шәһәргә кайтам дип өзгәләнә инде. Әтиеңне сагынып кайтасыңмы, дим. Юк, ди. Әниең янынадыр әле, дим. Юк, дигән була. (*Көлә.*) Ә-ә, мин әйтәм, ярыңны сагынгансың икән, дим. Юк, ди. Юк та юк, үзе минем алтын балдакны киеп карады. Таман гына. Йөз егерме сум тора дигән идем, моңсуланды нигәдер.

Ә х м ә т х а н. Бәясен әйтмәсләр.

З ә м и р ә. Теге апа, ул теге апа!.. (*Көлә.*) Термоска шундый сөенде!

Ә х м ә т х а н. Юмарт син, Зәмирә. Юмарт учка гына бәхет куна дигәннәр бабайлар.

З ә м и р ә. Без икебез дә бәхетле. Авылда, авылда гына түгел, бөтен районда, кемнең туй сәяхәте рәхәтен татыганы бар? Бөтенесе бармак тешләп көнләшәчәк бездән.

Ә х м ә т х а н. Көнләшмиләр, Зәмирә җанашым, сөенәләр.

З ә м и р ә. Тизрәк Казанга барып төшәсе иде. Юл киемнәрен салып ташлап, ап-ак костюмнардан палубада

йөрербез. Барысы да безне шәһәр кешеләре дип кабул итәчәк. Юлдашлар арасында артистлар булмасмы әле?

Әхмәтхан. Шуны сорыйсым килгән иде, Зәмирә каракаш...

Зәмирә (*учы белән аның авызын каплап*). Дәшми тор. Тыңларга өйрән. Артистлар булыр, мөгаен, хәзер театрлар ял итә... Идел өстендә утлар җемелди: агы, кызылы, яшеле...

Әхмәтхан. Туктачы, Зәмирә! Әйтик, без самолетка соңга калдык, ди.

Зәмирә. Без соңга калмадык! Калмадык!

Әхмәтхан. Әгәр без килеп җиткәндә генә самолет күтәрелеп китсә, нишләр идең?

Зәмирә. Безне күреп кире төшәр иде. Бик ялыныр идем мин аңа, төрлечә инәлер идем!

Әхмәтхан. Әгәр төшмәсә? Китеп барса... пыр-пыр итеп? Юк, Зәмирә, төшмәс иде ул. Синең инәлүеңне ишетмәс иде.

Зәмирә. Сүзеңнең тозы юк, Әхмәтхан. Юк белән борчыма мине. Теплоходта төрле кеше белән танышырга туры килер. Син... матур сөйләшә беләсең ич, Әхмәтхан? Шулаймы, җаным? Иеме? Матур җырлыйсың да... (*Шыпырт кына җырлый.*)

Агыйделне иңләп-буйлап
Йөзәрсең, үрдәккәем!

Әхмәтхан (*аңа кушыла*).

Хәсрәттән соң килер шатлык,
Түзәрсең, йөрәккәем!

Зәмирә. Ахыры алай түгел лә аның!

Әхмәтхан. Ахырын кем белгән әле аның, Зәмирәм йомшагым, кадерлем!

Зәмирә. Акрын... Стеналар юка, ишетелер.

Әхмәтхан. Ишетелсен.

Зәмирә. Оят бит, Әхмәтхан, күрерләр. (*Әхмәтханга сыена.*) Их, тизрәк каютада буласы иде. Тирбәлеп-тирбәлеп агасы иде, онытыласы иде!

Йосыф керә, үбешеп торган Зәмирә белән Әхмәтханны күрмәмешкә салышып эш урынына уза, микрофонны ала.

Йосыф. «Хөрмәтле пассажир иптәшләр! Һава шартлары начар булу сәбәпле, бүген Казанга самолет очмаячак! Бүгенге билетларыгыз иртәгәгә ярый».

Зәмирә. Нәрсә диде ул?

Ә х м ә т х а н. Әйе, Зәмирә. Бүген самолет булмаячак.

З ә м и р ә. Нәрсә дидең син?

Ә х м ә т х а н. Һава шартлары начар, Зәмирә.

З ә м и р ә. Нәрсә дидең?! Кабатлама, юк, юк... Нәрсә дидең син?!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Шул ук хәл: урта бүлмәдәгеләр аптырашта калган, аргы бүлмәдә Геолог эшләп утыра. З ә м и р ә белән Ә х м ә т х а н аппаратлар янында. Радио аша Йосыф тавышы яңгырый.

Й о с ы ф. «Хөрмәтле пассажир иптәшләр! Һава шартлары начар булу сәбәпле бүген Казанга самолет очмаячак. Бүгенге билетларыгыз иртәгәгә ярый».

З ә м и р ә. Нәрсә диде ул?

Ә х м ә т х а н. Әйе, Зәмирә. Бүген самолет булмаячак.

З ә м и р ә. Нәрсә дидең син?

Ә х м ә т х а н. Һава шартлары начар, Зәмирә.

З ә м и р ә. Нәрсә дидең? Кабатлама, юк, юк... Нәрсә дидең син?

Пауза. Урта бүлмәдә.

Х а т ы н (*чинап*). Йосыф гаепле, Йосыф! Карт көзән! Казанга юньле хәбәр бирмәгән.

К а р т (*көлемсерәп*). Менә гаепле дә табылды.

Ч е м о д а н л ы к е ш е. Бөтен ил буйлап самолетлар очканда без кешедән кимме? Монда да адәм балалары аяклы-куллы.

К ы з. Чыннан да, бүгенгә юллар киселдемени? Ул ни уйлар?!

Н ә җ и п. Соңарган саен, эшләр харап, Маннур. Малтуарны саламсыз калдырабыз.

М а н н у р. Юраганым юш килә, кыз минеке хәзер. (*Гармунын тарта.*)

Сөям сине, сөям сине!..

Аппаратлар бүлмәсендә.

Й о с ы ф. Ул тиклем бетеренмәгез. Төшәсез дә бездә кунасыз. Мин бит бер башым.

З ә м и р ә. Безне бер тамчы да кызганмыйсыңмы, агай?

Й о с ы ф. Ярдәм итәргә кулдан килмәгәндә, кызганып ни файда? Кешене түбәнсетү генә була ул.

Ә х м ә т х а н (*паузадан соң*). Әйдә, Зәмирә.

З ә м и р ә. Кая? (*Пауза.*) Кая чакыра аласың син мине хәзер?

Ә х м ә т х а н. Иң элек юлдашлар янына чыгыйк.

З ә м и р ә. Нигә?

Ә х м ә т х а н. Ни күрсәк тә бергә күрербез. Илдә үлем дә күркәм, диләр. «Әйбәт кешеләр» дип үзең мактап тордың.

З ә м и р ә. Оятны кая куябыз?.. Ачык авыз мин! Планнарның нигә барын чишеп ташларга иде? Әгәр иртәгә дә самолет очмаса?.. Авылга кире кайтырга туры килсә?! Хурлык, үлем!

Й о с ы ф. Килен, үпкәләмә иреңә. Һава кәҗәләнә икән, аның инә очы кадәр дә гаебе юк.

З ә м и р ә. Инә очы кадалды йөрәгемә! (*Яшь аралаш көлә.*) Үпкәләмим!.. Әхмәтхан, колак артыңда юл истәлеге калган. (*Елый, көлә, ак кулъяулыгы белән Әхмәтханның колак артын сөртә.*)

Й о с ы ф. Менә шулай тату яшәгез. Ялгыз башка кыен, әй, кыен. Балаларым күп тә, таралдылар. Шушы юл юклыгы тиде теңкәгә, күпме якташларыбызны читкә таратты? Ниятләсәң дә кайтырмын, димә. Кайтсаң, китә алмыйча гүр газаплары чигәсең. Нефть чыга башласа, кайтырбыз, эти, дип язалар. Кем белгән.

З ә м и р ә. Бу якларда да юллар салынырмы? Театрлар булырмы?

Ә х м ә т х а н. Булдырырбыз, каракаш, барын эшләрбез! Җылама гына.

Й о с ы ф. Татулыкка ни җитә? Баш очында гел-гел кояш, аяк астында гел-гел такыр юл гына булмый шул.

З ә м и р ә белән Ә х м ә т х а н пассажирлар янына чыга.

М а н н у р. Иптәшләр! Яшь кияү белән яшь бикәчне утыртып «Валерий Чкалов» теплоходы кузгала! Юл бирегез! (*Гармунын тарта.*)

Н ә җ и п. Чи ярага вак тоз сибәм дисең инде?

М а н н у р. Яшь килен майор әтисеннән самолет сорап карасын. Хәрби самолетларга яңгырның зыяны юк.

З ә м и р ә (*салмак кына*). «Валерий Чкалов». Егерме ике сәгать ноль-ноль минутта кузгала.

Н ә җ и п. Үпкәләмәгез аңа. Усаллыктан түгел!

Ә х м ә т х а н. Барыбер очарбыз, каракаш, мин әйтте диярсең.

Г а ф у р о в. Чкалов, Чкалов... Усалрак әтәчкә шәп исем...

К а р т (*бер минутка гына урамга чыга да керә*). Кыр бөтенләй изрәгән, балалар.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Мондый пычракта сыерлар корсак асларына хәтле бата торганнар иде, самолетны әйткән дә юк...

Х а т ы н. Бер гектар чөгендердә чиләнәсем юк әле. Миңа өметләнмәсеннәр!

Н ә җ и п. Салам тапмасак, нинди йөз белән әйләнеп кайтырбыз?

Й о с ы ф (*ишек катына басып*). Аэропорт ябык. Таралырга вакыт. (*Чемоданлы кешегә эндәшә.*) Мәхмүтнең игелексез улы, монда кил.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Нәрсә бар?

Й о с ы ф. Сиңа телеграмма. Авыл советыгыздан тапшырдылар. Менә. «Күмәргә килми калма. Үләр алдыннан этиең сине күрергә бик теләде».

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Шәһәрдәге хатыны суккан.

Й о с ы ф. Күрергә теләде, дигән. Бик, дигән. Ә син билет тапшырам дип кылтаясың.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е (*кычкыра*). Көрәк бирегез миңа, көрәк! Йосыф, бармы көрәгең?

Й о с ы ф. Нәрсәгә сиңа көрәк?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Кыр изрәгән, диде бабай. Чыгып канаулар казыйм да җыелган суларны читкә агызам! Кулларыма канлы сөял чыксын, хәлем бетеп егылсам егылыйм, барыбер корытам кырны.

Й о с ы ф. Тилермә! Бер башың кырны ничек корытмакчы буласың?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Үләр алдыннан, ишетәсеңме, Йосыф агай, аның мине күрәсе килгән. Бик! Көрәк бирәсеңме, юкмы син.

Й о с ы ф. Соң инде. Озакламый караңгы төшәр.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Мин беркая да китмим. Төне буе, атна буе канаулар казып самолетлар төшәрлек итәм. Беркая да!

Бер почмакка сеңеп тына.

Й о с ы ф. Кем әйткән иде, боз кузгалмас дип? Кузгалыр!

Х а т ы н. Райсобес ябылганчы төшәргә кирәк. Урын тапсыннар. Минем ирем инвалид.

З ә м и р ә (*җәлләп*). Ирегез инвалид, үзегез авыру.

Х а т ы н. Барысы да бар миндә, җанкаем.

З ә м и р ә (*чемоданлы кешегә*). Сезнең әткәгез вафат булган икән. Бик зур бәхетсезлек бу.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Әткәм, әтием...

З ә м и р ә. Кадерле әткәгез, бердәнберегез үлгән...

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Кадерле әткәм, бердәнберем...

З ә м и р ә. Һәм сез аңа соңгы сәламегезне дә тапшыра алмыйсыз...

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Һәм соңгы сәламемне дә...

З ә м и р ә. Әткәгез белән күптәннән күрешкәнегез дә юктыр әле?

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Әткәм белән... бик күптән... күптән...

З ә м и р ә. Мин дә әткәмне өзелеп яратам. Ул безне Казанга барып җиткән дип уйлый.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Шулай дип уйлый... Казанда дип...

З ә м и р ә. Әткәгез сезне дә сөйгәндер...

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Сөйгәндер... Сөйгәндер...

З ә м и р ә. Мәгънәсез бер очраклылык аркасында бәхилләшә дә алмый каласыз.

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Очраклылык аркасында.

З ә м и р ә. Ерак та түгел, әнә генә! (*Карта янына баса.*) Самолетка утырасың да сәгать эчендә Казанда... Менә ул. Кремль. Порт. Кайсы причалдадыр теплоход «Валерий Чкалов».

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Нигә сихерлисең мине? Нигә үртисең?! Йосыф! Йосыф дим! Сасы көзән! Көрәк табып бирәсеңме миңа, юкмы?

Яңгыр шыбырдаганы ишетелә. Чемоданлы кеше көрәк тотып урамга йөгереп чыга.

Х а т ы н. Кемне жәллисең? Китмәвенә сөенә генә ул. Билетын тапшырырга йөргәнен үз колагым белән ишеттем.

З ә м и р ә. Сезне дә бик кызганам, апа. Быелгы көздә бер гектар чөгендер алу авырдыр.

Х а т ы н. Юк сүз лә анысы. Чөгендердән качмыйм, Казан больницасына каралырга барам.

М а н н у р. Мондагы больницаларда рәт беткәч, Казанга чабасыңмы? Монда бюллетень бугазлап врачларны җәфалап бетергәч, Казанны яулап алырга булдыңмы? Теләнче!

К ы з. Тавышыгыздан баш авырта.

Н ә җ и п. Менә нәрсә уйладым әле мин, Маннур.

М а н н у р. Тукта әле, кыз белән сөйләшә башлаганда гына!..

Н ә җ и п. Дөреслекнең күзенә туры карасак, без дә бит әнә шул апа хәлендә хәзер — теләнчеләр.

М а н н у р. Тагын ни уйлап чыгардың икән?

Н ә җ и п. Казахстанга салам теләнергә бармыйбызмы?

М а н н у р. Ирекле баштан чыкканмы мин теләнергә?

Н ә җ и п. Атта да бар гаеп, тәртәдә дә. Анысы хак. Гаебебез күп. Ил киң, берәр җае чыгар дибез дә койрыкны сыртка салабыз. Ил киңлеге тылсымлы таяк безнең өчен, болгыйбыз да котылабыз. Ваемсыз яшәргә, ваемсыз хуҗалык итәргә күнектек.

М а н н у р. Мин ваемсыз яшәгәнме?

Н ә җ и п. Салам юк икән — Казахстан коткарыр дибез. Икмәкне аз алсак — Кубань бар дип юанабыз.

М а н н у р. Мин урнаштырган тәртип түгел, мин бәләкәй кеше.

Н ә җ и п. Үз хакыңны даулаганда бәләкәй булырсың син! Ялкаулыкка өйрәндек. Теләнәбез, оялмыйбыз! Табабыз, дәүләт җилкәсен кимерәбез дә, һай, җиңел котылдык! — дип куанышабыз. Әгәр башкаларда булмаса, кая барып йөз суы түгәр идек? Кемгә барып ялыныр идек?

М а н н у р. Җәен корылык булганга мин гаеплеме?

Н ә җ и п. Син дә. Мин дә. Барыбыз да гаепле. Совет властеның зур юбилеен тиздән бәйрәм итәчәкбез. Идел буе гомер-гомергә корылыктан интегә. Беләбез, әмма түзәбез! Безнең җирләрне сугару турында кем баш ватарга тиеш? Җирнең киләчәге турында кем кайгыртырга тиеш? Безнең балаларга нинди кырлар каласы турында уйлыйсыңмы син? Юк! Итәк кисеп җиң ямаучылар без, теләнчеләр!

М а н н у р (*хафаланып*). Манарага менгән мәзин шикелле үкермә инде.

Н ә җ и п. Әгәр без — шушындый ваемсыз, алак-шалак, хуҗалыксыз, исрафчы халыклар — нәни утрауларда, әйтик, япон утраулары төсле утрауларда яшәсәк, биш алты елдан бер-беребезне ашарга тотыныр идек.

М а н н у р. Ни җитми сиңа, белмим. Табигать законнарын үзгәртәм дисеңме? Үзгәрт, мине бутама. Аллага шөкер, без әлеге утрауларда яшәмибез. Безгә дигән саламны ташып бетермәсләр, шыр җибәрмә, нарядың кесәңдә.

Н ә җ и п. Наряд кесәдә, күңелдә нәрсә, Маннур?

М а н н у р. Күңелдә кыз! Ал битле, чибәр Жанна. (*Нәҗипкә.*) Бәйләнмә дим мин сиңа. Син бара дигәч,

аягым тартмады. Ябалак белән сандугачны пар иттеләр. Әй, чибәр кыз! Хәзер хәбәрнең яхшысы бездә.

Кыз. Берәр җирдән самолет юнәтә аласызмы?

Маннур. Хәбәрнең аннан да шәбрәге булса?

Кыз. Башка хәбәрләрнең кадере юк.

Маннур. Хәзер бу сарыклар сөрлегешеп район гостиницасына барачаклар. Аларны коридорга тезеп салачаклар. Люкс бер генә, һәм, теләсәк, ул люкс безгә.

Кыз. Чын күңелемнән котлыйм.

Маннур. Үз чиратымда мин дә сезне котлыйм һәм түбәнчелек белән люкска чакырам. Җылы! Якты! Талгын гына музыка моңы агыла. Теплоходның беренче класс каютасыннан һич тә ким түгел.

Кыз. Ким шул, күпкә ким.

Маннур. Менә күрерсең.

Кыз. Гостиница тик тора, ә теплоход йөзә, алга бара.

Маннур. Нигә шулай киреләнәсез?

Кыз. Күрер күзгә ару гына егет үзегез... Әдәп өләшкәндә кайда калдыгыз?

Маннур. Мин бер дә ошамыйммы сезгә?

Кыз. Минем дустым бар инде.

Маннур. Син аны яратасыңмы?

Кыз (*паузадан соң*). Юк... мин аны яратмыйм.

Маннур. Яратмагач, нигә кыланасың? Ник сайланасың? Бәлки, сиңа үз самолеты булган бай әфәнде кирәктер?

Гафуров. Үз самолеты? Моннан берәр мәгънә чыгарып булмыймы? Уйла, Гафуров!.. Әйтче, чибәр кыз!

Маннур. Кит әле моннан!

Гафуров. Үз вертолеты булган егеткә ни дияр идең син?

Кыз. Кылдый-былдый арбалы чегән егетенә ияреп китәргә риза! Бүген Казанга кайтып җитә торган гына булсын. Бүген!

Карт. Әллә оча торган паласың бармы синең?

Маннур. Паласы гынамы, мең кодрәте бар ул Хөзер Ильясның! Хәзер очыртып алып китә. Тылсымчы!

Хатын. Каян килеп хәзрәте Хөзер булсын? Гомерен этәч сугыштырып уздырган бер өтек.

Нәҗип. Әйткән сүзеңнең безгә файдасы тияме?

Карт. Безнең арада хөрмәтле олы начальник бар. (*Геолог ягына ымлый.*) Бәлки, аның кылын тартып карарга дыр?

Гафуров. Ә-ә, сырт өстендә тишекле сөяк! Очыра-

лар аны, үзен очырталар, бетте ул. Әгәр ярдәм кирәк дисәгез, оештыра алам.

Маннур. Тел тегермәнең әйбәт әйләнә, хөрәсән!

Гафуров. Усаллыкка калса, эш барып чыкмас.

Хатын. Безнең авылга барып чыга калсаң, әтәчнең айгыр кебеген тотып бирәм үзеңә.

Кыз. Бүген кайтып җитәргә кирәк миңа! Бүген!

Гафуров. Мондый сылукайның сүзен җилгә җибәрә алмыйм. (*Геолог янына, эчке бүлмәгә керә.*) Фоат Хатыпович!

Геолог. Тагын ни кирәк? Кирелегемне беләсез, Гафуров, кабатлап торырга яратмыйм.

Гафуров. Башка әле минем йомышым. Анысын бүтән чакта сөйләшербез.

Геолог. Бүтән чак булмаячак. Кстати, сез җирләрен харап иткән колхоздан бер карт кергән иде. Танымадымы сезне? Белештегезме?

Гафуров. Белдермәдем.

Геолог. Кызыклы карт.

Гафуров. Комы коела башлаган карт исәр... Фоат Хатыпович, бүген самолет булмый диләр.

Геолог. Булмаса, иртәгә килер.

Гафуров. Сез ашыкмыйсыз, беләм. Сезнең урында мин дә кабаланмас идем, мөгаен. Башны кылыч астына куярга кем ашыксын?! Ләкин мин әлегә сезнең урында түгел. Миңа тизрәк Мәскәүгә барып җитәргә кирәк.

Геолог. Барып, минем өстән тагын жалоба бирергә уйлыйсызмы?

Гафуров. Анысы да безнең кулдан килә. Әгәр монда килешә алмыйбыз икән, анда сөйләшергә кала. Мин бит сезнең өчен саф хәзинә, Фоат Хатыпович. Сез замана җимеше түгел, күктә очасыз, ә мин, Гафуров, шушы кулларым белән сезгә юл ярам! Тимерне мин табам, машинаны мин юллыйм, ягулыкны уңнан-сулдан мин кайтартам, зарплата тоткарланса, эшчеләр белән мин чәкәләшәм. Кулым пычраныр дип куркып тормыйм.

Геолог. Ә мин башлаган эшемне кулым да, намусым да чиста килеш тәмамларга телим. Намусым саф килеш уңышка ирешергә!

Гафуров. Фанатик сез, Фоат Хатыпович. Тик фанатиклар заманы узды.

Геолог. Узмаган, Гафуров! Минем янга зарын сөйләргә кергән бабай фанатик түгелмени?

Гафуров. Нәкъ шушы темага гәпләшергә чакыра-

лар да инде сезне Мәскәүгә! Сагынганнар ди башкалада кайберәүләрне!

Геолог. Беттеме?

Гафуров. Бетеп җитмәде. Сезнең янга бу юлы да халык массаларының вәкиле буларак кердем.

Геолог. Миннән сезгә ни кирәк?

Гафуров. Очарга ярдәм итүегезне сорыйлар.

Геолог. Аэрофлотка катнашым юк.

Гафуров. Гади халык чиннарны хөрмәт итә, аларга ышана. Менә сез торып басарсыз да күктәге болытларны тарата алырсыз дип өметләнәләр.

Геолог. Кыланмагыз, Гафуров.

Гафуров. Үзем өчен түгел, һәрвакыттагыча халык өчен тырышам. Сез трестка шалтыратсагыз, вертолет җибәрәләр инде анысы.

Геолог. Мине чагарга ашыгасызмы?

Гафуров. Яшь кәләш белән яшь кияү сәяхәткә чыкканнар. Теплоходка соңаралар. Берсе әтисен җирләргә бара. Ике толкач Казахстанга салам юлларга ашыгалар. Ә бер Ләйлә Мәҗнүнен сагынган. Күрәсез, миңа да тырышырга сәбәпләр җитәрлек.

Геолог. Әтәч сугышларын нигә яратуыгызны төшендем, Гафуров. Кан яратасыз сез! Хәйләкәр һәм астыртын җан.

Гафуров. Аңламыйсыз сез тормышны, Фоат Хатыпович, печтек тә белмисез аны. Утыздан узып өйләнмәгән...

Геолог. Монысын каян беләсез?

Гафуров. Гөнаһлымын, начальство турында гайбәт тыңларга да, сөйләргә дә яратам.

Геолог. Яхшы. Трестка шалтыратып карыйк.

Аппаратлар бүлмәсенә уза, телефонга тотына. Гафуров пассажирлар янына чыга.

Зәмирә. Йә, интектермәгез безне, абый.

Карт. Чырае төн кебек әле моның.

Гафуров (*кызга*). Сезнең сөрмәле күзләрегез өчен тырышам! (*Зәмирәгә.*) Сезнең кара кашларыгыз алдында баш иям! Озакламый вертолет булачак.

Кыз. Рәхмәт. Сездән моны көтмәгән идем.

Зәмирә. Ишетәсеңме, Әхмәтхан?

Әхмәтхан. Ишетмәгән кая, каракаш. Гомерең буе кайгы-хәсрәт татымасаң иде. Менә шулай елмаеп кына торсаң иде.

З ә м и р ә. Хәзер без өлгерәбез дә өлгерәбез. Мин искиткеч бәхетлемен!

К а р т. Туй сәяхәте... Хәйран тамашалар бар дөньяда.

Х а т ы н. Мин җүләр! Миңа кияүгә чыгасыңмы, диде. Иярдем дә киттем. Җәяү бардык... Ә болар? Туй! Бүләкләр! Җитмәсә, вертолетка утырып Казанга очалар.

К а р т. Сәяхәтегез истәлекле башлана, балалар, күңелле очлансын.

З ә м и р ә. Рәхмәт, туганнар. (*Әхмәтханга.*) Рәхмәт, диген! Кызганыч, без бик тиз аерылышабыз. Мәгәр мондый күңелле юлдашларны мәңге онытмабыз.

Н ә җ и п. Сез дә безнең юлны бизәдегез. Матур кешеләр янында начар булып булмый бит.

Х а т ы н. Тизрәк билетны тапшырып Йосыфтан акчасын алып калырга кирәк. Нефтьчеләр бушлай алып барырлар. Йосыф, Йосыф!

М а н н у р. Ашыкма, ашка пешәрсең. Бия колынламаган, тай үсмәгән, атланып билен сындырасың.

Х а т ы н. Ярый ла синең шырт иткәнең өчен дә казна акча түли.

К ы з. Сөенечле минутларның ямен җибәрәсез. (*Зәмирәгә.*) Бәхетлеләр сез! Вертолетта очып караган юк иде моңарчы.

З ә м и р ә. Минем очкан бар. Вертолет безне, әти-әнине, иртән иртүк ерак күлгә илтеп куйды. Тирә-якта биек-биек наратлар. Очлары күренми! Коточкыч зур учак яндырдык та тирәсендә качышлы уйнадык. Кичен безне тагын вертолет килеп алды.

Ә х м ә т х а н. Вертолетта очтык дисәк, авылда ышанмаслар әле. Теплоходка урнашу белән телеграмм сугарбыз.

К а р т. Каютагыз каршына гына палубага китереп төшерә инде сезне.

З ә м и р ә. Ур-ра!

Урта бүлмә ишегендә бик нык дулкынланган Г е о л о г күренә.

Г е о л о г. Ур-ра! Ур-ра!

Н ә җ и п. Энә карагы төсле пыр-пыр очыйк әле бер.

Х а т ы н. Чикерткә төсле диген.

Г е о л о г. Нефть! Нефть! Ишетәсезме?! Төнлә скважинадан газ чыга башлаган, иртән нефть фонтаны бәргән.

Г а ф у р о в. Булмас!

М а н н у р. Безнең районда нефть? Шәп булган!

Г е о л о г. Өч ел миңа беркем ышанмады. Өч ел!

Көлделәр миннән. Инә белән кое казыйсың, диделәр. Мин җиңдем! Мин!

Гафуров (*Геолог янына килеп җитә*). Котлыйм, Фоат Хатыпович! Куаныч уртак булсын.

Геолог (*аны кочаклап*). Рәхмәт! Тик... эшкә барыбер кире кайтармыйм. Шулай, дусларым, хәзер сезнең төбәк чәчәк атачак. Монда яңа тормыш башланачак.

Карт. Шулай була күрсен берүк!

Әхмәтхан. Яхшы фал, иеме, Зәмирә.

Зәмирә. Син дә нефтькә күчәрсең, Әхмәтхан. Колхоздан котылырсың. Промыселларда электриклар кирәк булыр.

Геолог. Беләсезме, шагыйрь безнең хакта нәрсә дигән? Нефтьчеләр җир астыннан тәмуг утын чыгарып бетереп, оҗмах кына калдыралар, дигән.

Карт (*үз-үзенә*). Оҗмах дигәне нефть өчен түгел, кешеләр өчен була күрсен.

Нәҗип. Котлыйбыз. Сәфәр йөреп кайткач керәсе булырмы, әллә хәзер үк сөйләшикме? Фәттахов мин, «Якты йолдыз» колхозыннан.

Геолог. Рәхмәт, Фәттахов.

Нәҗип. Сугарулы көтүлекләр өчен ике-өч дюймлы торбалар җиткезә алмыйбыз.

Геолог. Торбаларны бирербез, Фәттахов! Коргаксыган болыннарны сугарырбыз.

Хатын. Шифер кирәк миңа! Күп тә түгел, бер түбәлек кенә. Китереп тә бирсәгез, ябып та куяр идегез? Ирем инвалид!

Геолог. Бар да булыр. Шифер да бирербез, торбалар да. Нефть! Нефть! Җиңү!

Нәҗип. Хәзер үк гариза язсам ярармы?

Карт. Җаныгызны нефтькә сатмагансыз икән... Адәм балаларына да җылы сүзегез калган икән, олан.

Геолог (*Зәмирә белән Әхмәтханга*). Туй сәяхәтенә сез чыктыгызмы? Котлыйм.

Әхмәтхан. Рәхмәт, абый.

Зәмирә. Вертолет кайчан килеп җитә соң?

Геолог. Нәрсә? Вертолет? Ә-ә, вертолет булмаячак. Юк. Әле генә Бөгелмәгә киткән. Йөкле хатынның хәле авырлашкан. Хәзер генә кузгалганнар.

Зәмирә. Ничек алай? Нигә киткән?

Геолог. ЧП. Була хәлләр, нишлисең? Иртәгә очарбыз. Хәзер Мәскәүгә куян булып түгел, арыслан булып барам!

Пауза.

Х а т ы н. Сукыр тавык юлга чыкса, буран була диләр, хак икән.

К ы з. Бүгенгә монда калабызмыни?

М а н н у р. Ишеттең ич, төпченеп җәфалама кешене.

К ы з. Мин сезнең белән сөйләшмим. Сездән ярдәм сорамыйм да. Ярдәмегезне дә алмас идем.

М а н н у р (*аптырап*). Шулкадәр үк сөймисезме мине?

З ә м и р ә. Сез... олы урында. Җаваплы хезмәттә. Сезне Мәскәүдә көтәләр.

Г е о л о г (*көлә*). Мин аларга күчтәнәчкә нефть алып барам.

З ә м и р ә. Нигә тындың? Әхмәтхан, әйт бер сүз.

Ә х м ә т х а н. Әйтеп ни файда? ЧП!

К а р т. Баш исән, Әхмәтхан дус, баш. Менә мин тугыз тапкыр яраландым. Госпиталь караватында күзне ачам да: «Баш исән, шөкер!» — дип юанам. Баш исән булсын.

Г е о л о г (*Зәмирәгә*). Бик нык күңелсезләндегез әле сез.

З ә м и р ә. Безме? Юк, юк...

К а р т. Туй сәяхәте бит... Гомер юлының башы...

Х а т ы н (*нигәдер өметләнеп*). Бөтен авыл купкан, озатып калганнар.

М а н н у р. Майор-әти акча биреп җибәргән.

Н ә җ и п. Анысы вак мәсьәлә. Яшьләрнең бәйрәме бозылган.

К ы з. Бер сәгать соңга калуның бәясен бик яхшы беләм мин!

Г е о л о г. Бер сәгатьне шулай кыйммәт бәялисезме?

К ы з. Теләсәгез, сөйләп бирә алам.

К а р т. Көзге көнгә башта ук өмет бәләкәй иде лә!

З ә м и р ә. Безнең күңелләрдә яз иде бит, бабай!

Ә х м ә т х а н. Нигә «иде» дисең, Зәмирә? Хәзер дә яз!

Тышкы ишек ачыла, Ч е м о д а н л ы к е ш е керә. Ул пычранып, җәфаланып беткән, кулында сабы сынган көрәк.

Ч е м о д а н л ы к е ш е. Бетте! Хәлем бетте!.. Җеп өзәрлек көчем калмады.

Н ә җ и п. Чыннан да шашкан икәнсең. Бер башың бөтен кырны казып бетерә аласыңмы?

Ч е м о д а н л ы к е ш е. Тик утыра алмыйм. Көтәргә чамам калмады. (*Арып-талып идәнгә чүгәли.*)

Х а т ы н. Ни булды соң сиңа? Нигә ярсыдың?

Чемоданлы кеше. «Көтте», дигән бит... «Бик күрәсе килде», дигән...

Маннур (*кызга*). Шулай ук үпкәләттеммени мин сине? Әллә сәфәрне һаман бергә дәвам итәбезме?..

Кыз ярдәм сораган шикелле Геологка карый.

Геолог. Гафу итегез, бу туташ белән сүз бар безнең.

Маннур. Шулай укмыни? Җитез кеше булып чыктыгыз тагын, аппетит та шәп! Нефть кенә эзләмисез икән!

Геолог (*кызга*). Бер сәгать соңга калуның бәясен беләм дигән идегезме? Рәхим итегез! (*Кызга кулы белән юл күрсәтә, эчкәреге бүлмәгә чакыра.*)

Хатын. Кыяк тешләп калдыңмы?

Маннур. Ашыкма, кем кемне, күрербез! (*Геолог артыннан керергә тели.*)

Нәҗип (*аның юлын бүлеп*). Ярамый... Күзеңдә хәерсез ут яна. Мәхәббәт уты янса, кертер идем!

Эчкәреге бүлмәдә.

Кыз. Бәладән йолып алдыгыз, рәхмәт.

Геолог. Вакыт бар. Фәлсәфи фикерләрегезне уртаклаша аласыз.

Кыз. Иң әүвәл бер-ике сүз сорыйсым килә. Мөмкинме? Сезнең күңел шат.

Геолог. Сәбәбен беләсез. Нефть табу җиңел түгел. Ишеттегез бит, нефть табылган! Иң бәхетле көнем бүген дисәм дә ярый.

Кыз. Сезнең рәхәт: тарихи көн! Ә башкаларның? Яныгызда гына никадәр кешеләрнең ут йотып утыруында сезнең гамь юк. Бәлки, аларның язмышлары кыл өстенә куелгандыр?

Геолог. Җылап ни файда? Кыен чаклар булды, сытылмадым. Күкне, яңгырны каһәрләп ни файда? Бүген очмасак, иртәгә кузгалырбыз.

Кыз. Күрәм, бәхетегез ташып арткан... Һәр бәхетле кеше чак кына эгоистка әверелә, бәхетенә чума да күзе томалана. Шулай түгелмени?

Геолог. Шатлыгымны да уртаклашмадыгыз. Бер сез калдыгыз! Нефть сезнең өчен дә сөенеч бит. Илебез байый, үзебез көчлерәк була барабыз.

Кыз. Бер яктан караганда бу шулай. Сезнең әтиегез үлмәгән...

Геолог. Гафу итегез, әтиегез вафатмы?

Кыз. Минеке үлсә генә кайгырырга тиешме мин?

Геолог. Минеке дә исән, Аллага шөкер.

Кыз. Кадерле әнкәгезнең бер гектар чөгендердән качып больницаларга чабасы да юктыр.

Геолог. Тукучы ул. Казанда. Фабрикада.

Кыз. Сез яшь. Теге бабай кебек ашыкмасагыз да була... Бәлки, ул үзенең соңгы сәфәренә чыккандыр?

Геолог. Сәфәрем башлана гына! Озак елларга сузылыр дип өметләнәм!

Кыз. Меңләгән терлекләргә салам әзләп интегәсегез дә юк.

Геолог. Дөньяның бар мәшәкатен миңа өяргә булдыгызмы?

Кыз. Туй сәяхәтенә дә бармыйсыз!

Геолог. Анысы булачак. Һичшиксез. Монысын эшлим! Тантаналы вәгъдә бирә алам.

Кыз. Кайчан?

Геолог. Кәләш тапкач та.

Кыз. Тапкансыз бит, шул җитмиме?

Геолог. Кәләшемнеме?

Кыз. Нефть тапкансыз. Ул сезгә барын да алыштырмыймыни?

Геолог. Гаҗәбрәк әле безнең бу әңгәмә!

Кыз. Мин җылыйм. Йөрәгем сулыгып үкси. Сез ваемсыз, көләсез. Җир асты сулышын тыңлап, җир өсте хәлләренә колак катыланган сезнең.

Геолог. Сез чибәр. Сез сылу. Ничектер, чибәр кешеләр башкалар кайгысына битараф булалар дип аңлый идем мин. Ялгышымны таныйм.

Кыз. Сезнең сөеп караганыгыз бармы?

Геолог. Мин тормышны яратам. Бөтен тулылыгы белән.

Кыз. Тормышнымы, әллә үз-үзегезнеме?

Геолог. Турысын әйткәндә, чынлап сөеп караганым юк.

Кыз. Мин сездән шушы җавапны көткән идем.

Геолог. Нишлисең, язмыш! (*Көлә.*) Утыз тулды. Башта геофакны тәмамладым. Ике елдан артык армиядә. Армиядән туры монда кайттым. Башкалар кул селтәгән участокны сайладым. Үз бәхетемә ышанам мин. Ниһаять, таптым мин аны, нефтьне таптым.

Кыз. Мәхәббәт дип башладыгыз да нефть дип бетердегез.

Геолог. Сез сөеп караган, ахры?

Кыз. Кызганычка каршы, юк. Сөелеп караганым бар. Хәзер дә бер егет сөя мине.

Г е о л о г. Гашыйкыгыз бозау икән дисәм, ачуланмагыз! Әгәр мин берәүгә гашыйк булып, аның күңеленә үтеп керә алмасам, егет исеме хәрам!

К ы з. Алдан кычкырып куймагыз... Берәр кызны сөярсез, ул сезгә әйләнеп тә карамас.

Г е о л о г. Моның булуы мөмкин түгел!

К ы з. Булган тәкъдирдә?

Г е о л о г. Хәсрәтемнән бер минут тормый үләр идем?

К ы з. Шулай шул!.. Димәк, таш яуса да, җир упса да мин бүген Казанга кайтып җитәргә тиеш. Бурычлы. Мәҗбүр. Бер сәгатькә дә соңарырга ярамый.

Г е о л о г. Уңайсыз димәсәгез сүзгә мине дә катнаштырыгыз инде.

К ы з. Көлмәгез. Без аның белән унынчыда бергә укыдык. Мин институтка уздым, ул керә алмады. Заводта эшләп йөрде дә армиягә алынды. Мәктәптә чакта анымоны сиздермәсә дә кызлар күңеле аңламыймы? Ярата иде ул мине, хәзер дә сөя. Икенче елын инде көн саен хат яза.

Г е о л о г. Һәркөн? Үзсүзле солдат!

К ы з. Һәркөн, аңлыйсызмы? Ике-өч сүз генә булса да язып сала. Ә мәхәббәтне аңлатырга сүзләр күп кирәкмени? Без бүген шул егет белән вокзалда очрашырга тиеш. Төнге поезд белән ул Казан аша узып китә.

Г е о л о г. Йөрәгегез тургай кебек шуңа тырпылдыймы? Бәхетле егет!

К ы з. Сөймим мин аны, сөймим.

Г е о л о г (*бик гаҗәпләнеп*). Яратмагач нишләп очрашасыз?

К ы з. Каршылармын дип вәгъдә биргән идем, безне, көтмәгәндә, чөгендергә җибәрделәр. Аңа хәбәр итәргә өлгермәдем. Яратышсак, кайта алмасам да аңлар иде, җәберсенмәс иде. Ә болай... Мин аны күрергә тиеш. Яратмыйм дип әйтергә тиеш. Юкка өметләнмәсен. Алданмасын, газапланмасын.

Г е о л о г. Хат аша белдерсәгез җиңелрәк булыр иде.

К ы з. Язмаган кая! Уйнап-көлеп тә, чынлап та язып карадым. Ышанмый. Ышанасы килми аның. Классташ буларак та, иптәш буларак та мин аңа барын үзем аңлатып бирергә телим. Мине ярата бит ул, мине. Мине башка берәү дә алай яратмый ич! Аны ярата алмавым бәхетсезлегемдер, мөгаен.

Г е о л о г. Бәлки, яратып та куярсыз... алдагы көннәрдә дим?

К ы з. Юк, юк... Мәхәббәт ул көтелмәгән кунак... Сиздермәстән, кинәт туарга тиеш.

Г е о л о г. Сез искиткеч гадел, акыллы кыз. Күңелегез нинди саф!

К ы з. Бүген күрешә алмасак, ул минем турыда гына түгел, кызлар, мәхәббәт турында гомумән начар уйлый башлар, ышанычын җуяр.

Г е о л о г. Соңга калуның бәясен шушы гыйбрәтләрдән чыгып чамаларгамы?

К ы з. Соңга калсам моның бик кыйммәткә төшүе бар.

Г е о л о г. Нигә боларны миңа сөйләргә булдыгыз?

К ы з. Белмим. Ярдәм соравым булды бугай. Сезнең ярдәм итә алуыгызга ышанумы? Бөтен кеше өметсез дип тамгалаган урында нефть таба алгансыз. Димәк, сез җиңә белә торган көчле кеше.

Г е о л о г. Сез миңа бик ошыйсыз.

К ы з. Ә миңа җиңеп яшәүчеләр ошый.

Г е о л о г. Өмет якты булганда, иң кыен хәлләрдән дә чыгу юлы табыла.

Аппаратлар бүлмәсендә телефон шалтырый.

Й о с ы ф. Ишетәм, ишетәм. (*Кыптырдап телефон янына килә.*) Аэропорт тыңлый.

Н ә җ и п. Нинди дер хәбәр бар!

Х а т ы н. Булса да безнең файдага түгелдер әле...

М а н н у р. Безнең хәлдә яңалыкның ниндие дә файдалы.

Й о с ы ф (*кычкыра*). Фоат Хатыпович, монда рәхим итегез.

Г е о л о г Йосыф янына керә.

Й о с ы ф. Мөслим самолеты кузгалып китә алган. Казанга оча. Анда ике буш урын бар. Озакламый самолет монда булачак.

Г е о л о г. Ике урын? Бик шәп!

Й о с ы ф. Ярдәмчегезне ияртегез дә хәерле юлга.

Г е о л о г. Гафуровнымы? Байтактан ярдәмчем түгел инде, кудым мин аны.

Й о с ы ф. Икенче итеп кемне җибәрик соң?

Г е о л о г. Аны чишү кыен түгел. Кызны, агай, кызны.

Й о с ы ф. Алай икән, алай. Хуп, мәйле. Ихтыярыгыз.

Г е о л о г. Сезнең башка кандидатыгыз бармы?

Й о с ы ф. Ялганлый алмыйм, бар. Чемоданлы кешене әйтәм.

Г е о л о г. Кем ул?

Й о с ы ф. Әткәсе якты кеше иде. Изге кеше иде, мәрхүм. Авыр туфрагы җиңел булсын.

Г е о л о г. Ул чагында кыз кала. Туктагыз, нигә кала? Нигә мин китәргә тиеш? Монда без унау. Барыбызның да китәргә хакы бар.

Й о с ы ф. Райкомнан шалтыраттылар, беренче чиратта сезне озатырга куштылар. Озатырмын да. Бирегез билетыгызны.

Г е о л о г. Монда минем ихтыяр белән дә санашсагыз икән.

Й о с ы ф. Сез дәүләт кешесе. Эш кешесе. Сезне, тагын теге юньсезне утыртам да вәссәлам! Әткәсе скрипкәче Мәхмүт иде, изге җан.

Г е о л о г. Чыгыйк та киңәшеп алыйк.

Й о с ы ф. Зинһар, бала-чагаланмагыз. Халык чуар, ярсыган. Җайсыз хәлгә мин калырмын, сезгә сүз ишеттерерләр.

Г е о л о г. Алар берни дә белмиме?

Й о с ы ф. Әлбәттә! Самолет төшкәнче таратам мин аларны. Бирегез билетыгызны.

Г е о л о г. Киңәшсез ярамый. Һәркемнең хокукы бар.

Й о с ы ф. Әйтәм бит, хокуклар күп, урын икәү генә.

Г е о л о г. Чыгыйк әле. (*Пассажирлар янына чыгалар.*) Иптәшләр!

Н ә җ и п. Гөжләмәгез әле.

К ы з. Самолет килә!

М а н н у р. Килә! Тот капчыгыңны.

Г е о л о г. Йосыф агай, белдерегез.

Й о с ы ф. Юк, сез. Хәер... Эш болайрак тора, туганнар. Алдан ук әйтеп, кисәтеп куям: үпкәләштән түгел. Мөслим самолетында ике буш урын бар. Хәзер алар монда төшеп арагыздан икәүне алып китәчәк.

З ә м и р ә. Икәүне? Димәк, без! Без!

Ә х м ә т х а н. Ашыкма, каракаш.

Х а т ы н. Һи-и, белмиләр ди. Начальство оча! Начальство!

К а р т. Үтең сытылган бәндә икәнсең, тфү!

Й о с ы ф. Беренче кеше билгеле — Фоат Хатыпович оча.

Х а т ы н. Әйтмәдемме? Йә? Барыгыз да тиң, имеш, «юлчылар», имеш.

Г а ф у р о в. Дөрес, Йосыф агай! Нефтьчеләргә киң юл! Беренче булып Фоат Хатыпович оча, икенче кеше мин.

М а н н у р. Әтәч сугыштырырга соңга каласыңмы?

Геолог (*җыелганнарга*). Сезнең фикерне ишетәсе килде.

Нәҗип. Без командировкага чыккан, барыр юл ерак.

Маннур. Хәзер райкомга шалтыратам. Барысын аякка бастырам.

Йосыф. Шалтыраттылар инде, беренче нәүбәттә Фоат Хатыповичны озатырга боердылар.

Зәмирә. Ике урын булгач, нигә дәшмисең, Әхмәтхан?

Әхмәтхан. Уңайсыз бит, җанашым. Барысы да эш белән йөри...

Зәмирә. Без эш белән түгелме?

Карт. Их-хә-хә!.. Элегрәк заманнар булса, кем китә дә кем китә дип баш ватып торыр идекме, оланнар!

Маннур. Буталма, картлач.

Геолог. Бабай дөрес әйтә. Арабызда иң өлкәне ул. Кайчаннан татарлар олыларны санга сукмый башладылар?

Карт. Акыллыдан акыллы сүз чыгар.

Йосыф. Бабай барсын, бабай!

Маннур. Ул барсынмы? Һәм син, тишек кәвеш, оялмыйча утырып та китәр идеңме? Юк артыннан йөреп, безне монда калдырып китәрсеңме?

Карт. Көтәр чамам юк. Ашыгырга кирәк миңа, ашыгырга.

Хатын. Ә мин? Мин — хатын-кыз. Күрмисезме әллә? Дүрт бала үстердем. Үзем сырхау, ирем инвалид.

Чемоданлы кеше. Синеке инвалид кына, ә минем этием үлгән. Менә телеграмма, миндә дә йөрәк! Таш түгел.

Маннур. Ә менә моны күрмисеңме, чабата! (*Командировка кәгазен болгый.*) Юлда без булырга тиеш. Сөтнемайны, ай-һай, барыгыз да яратасыз. Казахстанга без барасы, сез түгел!

Кыз (*кыюсыз гына*). Мин... мин!

Маннур. Кит әле моннан! Тибеп очырырмын!

Кыз. Шул сүзне миңа әйтәсезме?

Тавышлар, сүзләр бутала, барысы да кулларын бутап кычкыралар.

— Үлгән инде, үлгән. Синнән башка да җирләрләр. Сырлап телеграмма язарсың да бетте.

— Көтәләр! «Күрәсе килде»,— дигән.

— Кая тыгыласың?

— Район терлекләре... Әй!

Н ә җ и п (*Гафуровка*). Иптәш, ә, иптәш?..

Г а ф у р о в. Нәрсә бар?

Н ә җ и п. Хәтергә төште. Безнең күршедә генә хәтәр бер әтәч бар: тирә-юнь тавыкларының җанын ала.

Г а ф у р о в. Иди к черту! Мин очып китәргә тиеш! Эш белән соңарганда да ярый, мәгәр жалоба белән соңга калу куркыныч!

М а н н у р. Саламсыз калсак ни буласын беләсезме? Утыз ике өлкәдән Казахстанга ябырылды халык!

Х а т ы н. Өй түбәмдәге бөтен саламны бирәм, зинһар, алыгыз, монда гына калдырмагыз.

Н ә җ и п. Мондый очракта сабыр итик, Маннур. Китсеннәр. Иртәгә дә өлгерербез.

М а н н у р. Тик тор, күгәргән кендек! Хурлыкка калыргамы хәзер?!

З ә м и р ә. Без? Без дә бар ич монда, Әхмәтхан!

Берәү дә аны ишетми.

Ә х м ә т х а н. Дәшмә, Зәмирә, түз.

Й о с ы ф. Беттеме? Бетсә шул, урынны бер дип санагыз һәм мин аны бабайга бирәм.

К а р т. Рәхмәт, балалар. Мин үз чиратымны менә бу кызга бирәм. Аның интеккәнен күреп түзәрлек түгел.

Г е о л о г. Аңа урынны мин бирәм дигән идем.

Х а т ы н. Ничек? Бер кешегә ике урын? Юк инде!

К а р т. Ул чагында менә бу иптәш китсен. (*Чемоданлы кешегә күрсәтә.*)

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Мин? Мине җибәрәсезме?

Й о с ы ф. Сине инде, сине. Мәхмүтнең игелексез улы.

Г е о л о г (*кызга*). Хәерле юл телим.

К ы з. Мин бер көнгә генә кайтам. Иртәгә үк борылып киләм. Чөгендердә без. Мине иптәшләр көтәчәк.

Г е о л о г. Мин сезне эзләп табармын!

Самолет тавышы ишетелә.

З ә м и р ә. Ишетәсезме, самолет! Чын самолет!

Й о с ы ф. Җыеныгыз тизрәк! Ике минут кына торачак!

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Рәхмәт, туганнар. Мәңге онытырлык итмәдегез. (*Ишеккә ташлана.*)

Й о с ы ф. Чемоданың кала!

Ч е м о д а н л ы  к е ш е. Олактыр бер яры!.. Кулларымны канатып төне буе интектем. (*Кесәсеннән кәгазь алып җиргә бәрә.*) Хәзер кирәкми.

Йөгереп чыгып китә. Самолет тавышы көчәя, сәхнәдәгеләр өзек-өзек кычкырып сөйләшәләр.

Карт. Хәерле юлга чыгыгыз, оланнар.

Геолог (*кызга*). Туктагыз.

Хатын. Мин моны шулай гына калдыраммы? Җаннарын алырмын. Самолеттан мин каламмы соң? Койрыгына тагылып булса да китәм. (*Чыгып чаба.*)

Геолог. Юньләп танышырга да өлгермәдек.

Кыз. Берүк күздән югалтышмыйк. (*Ишеккә чигенә.*) Жанна исемле мин! (*Башкалар артыннан йөгерә.*)

Зәмирә. Нигә телеңне йоттың, Әхмәтхан? Нигә дәшмисең?

Әхмәтхан (*сабыр гына*). Хәерле юл сезгә, хәерле юл, дуслар!

Маннур. Моңа кеше ышанмас. Җәй буе кара тиргә батып эшләп йөр дә теләмәгән юлга чыгып кит... Җитмәсә, сине таптап узсыннар! Ул өтек геологның миннән ни артыклыгы бар?!

Нәҗип. Мыжлама, Маннур. Ишеттеләр. Беләләр.

Зәмирә. Нәрсә дидең син? Хәерле юл дидеңме?

Йосыф. Аллага шөкер, бары да ипләнде.

Нәҗип. Кузгалсалар, очалар.

Зәмирә белән Әхмәтханнан калганнар чыгып китә. Самолет тавышы тына.

Зәмирә. Якын дусларга хәерле юл теләп калдым дисең инде?

Әхмәтхан. Кояш күренде. Күрче, Зәмирә, нинди матур көн икән бүген.

Зәмирә. Шәп юаныч тапкансың миңа. Кояш, имеш!

Әхмәтхан. Болытлар агылып беткән.

Зәмирә. Беткән алайса?

Әхмәтхан. Идел кебек тулышып актылар шул.

Зәмирә. Идел кебек? Шунда бер почмакта «Валерий Чкалов» теплоходы да күренмиме, Әхмәтхан?

Әхмәтхан. Их, Зәмирә җанкай-каракаш! Без бит бергә! Кайгырма юкка. Теплоходны алдагы портта ук куып җитәбез аны.

Зәмирә. Йөгердем, җиталмадым, үрелдем, тоталмадым...

Әхмәтхан. Иң кирәкле кешеләр китте, шуңа сөен.

Зәмирә. Ә мин? Ә без?

Әхмәтхан. Кодаларга төшәбез дә кунабыз. Әле ярый алар бар.

З ә м и р ә. Шуларның кандалалы чоланындамы?

Ә х м ә т х а н. Нинди кандала? Искиткеч чиста, пөхтә кешеләр.

З ә м и р ә. Безнең каютада башкалар кунсынмы?

Ә х м ә т х а н. Кертмиләр, юк. Телеграмма сугарбыз, аңлатырбыз.

З ә м и р ә. Шундый-шундый хәлләр бездә, әтрәк-әләмнәр утырдылар да киттеләр, без җүләр сымак, хәерле юл теләп калдык, диербез.

Ә х м ә т х а н. Синме бу, Зәмирә?

З ә м и р ә. Синме бу, Әхмәтхан? Кодаларыңның тузанлы чоланында истәлекле беренче төнебезне үткәрергә чакырасыңмы? Кандалалар арасында кыз чагым белән хушлашырга төшимме аларга?

Ә х м ә т х а н. Кандалалар юк анда.

З ә м и р ә. Хәзер безнең авыл өстеннән генә самолет очып китәчәк. Әтиләр чыгып кул болгап калачак. Кызыбыз туй сәяхәтенә китте дип сөенешерләр. Егерме ике ел көткән көне килеп җитте, дип куанырлар.

Ә х м ә т х а н. Көтеп алалмаган көнебез җитте...

З ә м и р ә. Көткәч, нигә чарасын күрмәдең? Ир кеше!.. Менә безнең әти...

Ә х м ә т х а н. Әти. Майор-әти...

З ә м и р ә. Без хәрбиләр шәһәрчегендә торганда балаларны җыяр иде дә олимпия уеннары оештырыр иде. Мин һәрвакыт чемпионка булып кала идем. Мин җиңеп чыгарга гадәтләнгән.

Ә х м ә т х а н. Әйбәт кеше синең атаң, Зәмирә.

З ә м и р ә. Әтием дә үзеннән алга берәүне дә чыгармый иде.

Ә х м ә т х а н. Тынычлан инде!

З ә м и р ә. Теге чемоданлы өтекне күр син! Аның кай җире миннән яхшырак? Табут хәтле сандыгын калдырды да китте. Күз көеге.

Ә х м ә т х а н. Аның хәлен әйтмә инде син.

З ә м и р ә. Теге кыз... Начальник янына кереп каш сикертеп, ихахай да михахай юхаланып йөрде дә... Беренче чиратта ул!

Ә х м ә т х а н. Беравыздан ул китсен дидек.

З ә м и р ә. Нигә без китсен димәделәр? Өйләнешкәннәр китсен дип нигә берсе дә авыз ачмады? Нигә оныттылар алар безне?

Ә х м ә т х а н. Без болай бәхетле.

З ә м и р ә. Ишетәсем дә, беләсем дә килми. Минем ни гаебем бар? Мине каюта көтә, юл көтә. Акчасы түләнгән,

барысы көйләнгән. Пәрәмәчләр искерә, киемсалым таушала.

Әхмәтхан. Боларны син сөйләмисең, Зәмирә, юк. Ишетмәдем мин боларны. Сөйләмәдең дә, телгә дә алмадың. Ишетмәдем, юк. Китәрбез, без монда мәңгегә килмәгән. Көн генә шулай торсын. Бер көн югалган икән, нишләмәк кирәк.

Зәмирә. Бер генә көн югалдымы? Шулай уйлыйсыңмы, Әхмәтхан?.. Син минем сүзләрне ишетмәдеңме? Ашыкма, әле мин барын да әйтеп бетермәдем. Мин сине ир булырсың дип өметләнгән идем. Баксаң, ир түгел, җебегән салма икәнсең. Авыл гыйбаты, мокыт, мужик!

Әхмәтхан. Боларын белеп чыктың. Кияүгә дә, юлга да.

Зәмирә. Безнең белән аралашкач, азрак үзгәрдең дип уйладым. Якын килмә! Киләсе булма!

Әхмәтхан (*тәмам аптырап.*) Зәмирә каракаш!

Зәмирә. Кашымның кара түгеллеген дә белмисең ич. Буялган каш ул, буяп йөрим мин аны. Менә күр.

Әхмәтхан. Карамы кашың, түгелме, мин яратып өйләндем. Дөньяда бер матур — ул син минем өчен. Сүзләр белән ямьсезләнмә, мәгәр. Кирәкми. Мине дә рәнҗетмә. Монда беребезнең дә гаебе юк.

Зәмирә. Һәммәгез гаепле. Син дә, алар да!

Әхмәтхан (*кычкырып*). Аларның гаебе юк! Мин гаепле булып калсам да!

Зәмирә. Самолет оча, самолет бит!

Әхмәтхан. Хәерле юлга! Әнә, безнең юлдашлар кайта.

Зәмирә. Кайталар. Бәйрәмгә чыкканнармыни, авызлары ерык. Мине аларга күренеп, тагын бер тапкыр түбәнсенер дип уйлыйсыңмы?

Әхмәтхан. Юлда ни булмас дисең? Очсыз-кырыйсыз юл бит ул. Кайгырма, кирәкми. Менә көне-төне эшли башлармын. Мин көчле, җегәрем җитәрлек.

Зәмирә. Син көчлеме? Күрдек инде. Җыелган ир-ат арасында иң көчсезе син! Һәм мин шул кешенең хатыны... Иң җебегәне син! Мин шуңа ияреп юлга чыккан.

Әхмәтхан. Гаҗәпләндерәсең мине, хатын.

Зәмирә. Хатын? Хатын түгел мин сиңа. Яратмыйм, яратмыйм!

Әхмәтхан. Иртән башкачарак сөйләгән идең.

Зәмирә. Аннан соң бик күп вакыт узды, күп нәрсәләр үзгәрде.

Әхмәтхан. Син хаклы. Күп нәрсә үзгәрде. Күбесе

чәлпәрәмә килде. Ялгап, ямап кына ипкә китерерлек түгел.

Зәмирә. Җебегән гыйбатка кияүгә чыгаммы?! Йөрмә минем арттан! Өметләнмә!

Ишекне бәреп чыгып йөгерә. Әхмәтхан аның артыннан барырга талпына да туктала. Геолог, Нәҗип, Йосыф, Карт һәм Маннур керәләр. Иң ахырдан Гафуров атлый.

Карт. Хуҗа Насретдин әйткәндәй, тун да китте, гауга да бетте.

Йосыф. Мине өзгәләп ташлыйсыз дип торам.

Нәҗип. Туктагыз әле, теге хатын кайда соң?

Маннур. Чыннан да.

Йосыф. Күренми.

Нәҗип. Самолетка утырган.

Карт. Таш астыннан чыккан нәмәрсә икән.

Гафуров. Хатын-кыздан да хәйләкәр...

Йосыф. Сезне җибәрмәгәнгә әләгәчәк миңа, Фоат Хатыпович.

Маннур. Көнне бөтенләй бушка уздырдык. Югалды көн... Нигә кызлар белән сөйләшә белмим икән мин?! Күңелемдә бер усаллык чаткысы юк иде, ул аңламады!..

Нәҗип. Сиңа дигән кояш та чыгар берзаман, Маннур!

Геолог. Көн бушка узмады. Бу көн, миңа калса, барыбыз өчен дә гыйбрәтле булды. Гомумән, гомернең һәр көне санаулы, кадерле, аның бушка узуы мөмкин дә түгел.

Маннур. Сез чибәр кызның күңелен яулап алдыгыз!

Геолог. Анысы да бар! Кешеләрнең явызлыгын да, җылы күңелләрен дә күрдем мин бүген.

Йосыф. Көн матурлана! Эретер бу, бозларны калдырмас.

Әхмәтхан (*бер читтә басып тора*). Борылып кайтмады. Юк.

Йосыф. Нигә син ялгыз?

Әхмәтхан. Китте Зәмирә.

Маннур. Нәрсә? Ул да очтымы?

Әхмәтхан. Очмады, китте.

Нәҗип. Бу пычракта кая барсын ул?

Әхмәтхан. Бөтенләйгә китте. Кайтмаска.

Йосыф. Ни сөйлисең син, егет?

Карт. Андый балага һич тә охшамаган иде бит. Күзләрем шултикле зәгыйфьләндемени инде? Сөйкемле бала күренгән иде.

Г е о л о г. Буранда адашкандай җебеп төшмәгез, зинһар. Йөгерегез!

Ә х м ә т х а н. Йөгереп кенә бәхетне тотып булса икән!

М а н н у р. Кул кушырып торсаң, хатынсыз каласың, бел.

Ә х м ә т х а н. Ялгап та, ямап та төзәтерлек кенә түгел.

Пауза.

К а р т. Ничек абайламадык без моны? Ничек сизенмәдек?

Н ә җ и п. Әйе, бабай. Гаеп эшләгән күк сизәм үземне.

Г е о л о г. Бергәләп эзләп чыгыйк.

Н ә җ и п. Караңгы төшкәнче тизрәк табарга иде!

К а р т. Эзләгез, оланнар, эзләгез.

Г а ф у р о в. Соңга калынды... Соңга!..

Ә х м ә т х а н. Кирәкми. Рәхмәт барыгызга да. (*Ишеккә юнәлә.*)

Й о с ы ф. Әйберләреңне калдырма.

Ә х м ә т х а н. Иске пәрәмәчләр кемгә кирәк? (*Чыга.*)

Н ә җ и п. Безнең гаепме бу? Безнекеме?

Г е о л о г. Көн югаламы соң, югалмый ул. Барыбер эзе кала.

Пауза.

Н ә җ и п. Карагызчы, көн бөтенләй аязган.

Г е о л о г. Җил дә тынган. Һава әйбәтләнә болай булгач.

К а р т. Кояш. Бөтен җирдә кояш.

Й о с ы ф. Алар гына юк... Икесе дә юк... (*Аппаратлар бүлмәсенә уза да микрофонны ала.*)

Радиода Йосыф тавышы: «Иптәшләр, Казан аэропорты ачык. Казанга очучы самолетта буш урыннар кала... Буш урыннар!..»

П ә р д ә.

*1975—1976*
*Казан — Иске Руза*

## Эчтәлек

Кичке әңгәмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Сары чәчәк ата көнбагыш... . . . . . . . . . . . . . . 59
Җан җылысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Кар астында кайнар чишмә . . . . . . . . . . . . . . 162
Шамил Усманов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Китмәгез, тургайлар! . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Әгәр бик сагынсаң... . . . . . . . . . . . . . . . . . 317
Әткәй җырлый да, җылый да... . . . . . . . . . . . . 364
Югалган көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 402

Литературно-художественное издание

*Гилязов Аяз Мирсаидович*

**Избранные произведения**

**В пяти томах**

**Том 3**

(*на татарском языке*)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Г.Г.Зиннәтуллина, Л.Ш.Шәфыйкова, С.Н.Мифтахова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 5.12.2002.
Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы-басма табагы 23,52+ф.0,21.
Шартлы буяу-оттиск 23,84. Нәшер-хисап табагы 24,0+ф.0,36.
Тиражы 3000. Заказ Б-701.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.